# Казан утлары

4.1994





Казанда шигырь бәйрәме

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**4**

**(858)**

**1994**

КАЗАН

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

М. ХӘБИБУЛЛИН. Хан оныгы Хансәяр. *Тарихи роман* ........ 3
Ә. ХАРРАС. Гармун бәйрәме. *Шигырьләр* ........ 70
М. ӘМИРХАН. Үлмә, Әхмәтхан! *Повесть* ........ 76
РӘШ. ГАТАУЛЛИН. Агыйдел, Чулман, Идел... *Шигырьләр* ........ 106
Р. ФӘИЗОВ. Еллар үткәч... *Хикәя* ........ 111

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ШИГЪРИЯТЕННӘН

ГАШЫЙК ГОМӘР. *Шигырьләр* ........ 115

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. НИЗАМИЕВ. Тукай белән әңгәмәләр ........ 119

ҺӨНӘР ИЯЛӘРЕ

Р. МОРТАЗИН. Кырым аксакалы ........ 122

Татарстан язучыларының XII съезды алдыннан ........ 125

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. ХАФИЗОВ. Ислах, яки яманаттан ярлыкау ........ 129
Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Җавап бирер чак. *(В. Нуруллин иҗаты турында уйлану)* ........ 139

МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА

Т. КӘРИМОВ. Р. Фәхретдинев шәҗәрәсе ........ 144

ШӘҮКӘТЛЕ ЗАМАННАР

И. ХАРА-ДАУАН. Үткән зурлыкларга кайту ........ 146

ЗАМАН ҺӘМ ШӘХЕС

Б. СОЛТАНБӘК. Олпатлык ........ 161

ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ — КҮҢЕЛЛӘР ХУШЛЫГЫ

Ф. ИСЛАМОВ. Татар-мари мәдәни бәйләнешләре ........ 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ГЫЙЛӘҖИЕВА-ХӘМИДУЛЛИНА. «Сихерче»ләр кирәк дөньяга ........ 175

КОТЛЫЙБЫЗ ........ 179
УКУЧЫ СҮЗЕ ........ 183

Ә. САФИУЛЛИН. Осталар. *Юморескалар* ........ 185

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 189

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигъърият, фән,
хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание исторического романа М. ХАБИБУЛЛИНА «Внук хана Хансюяр»; повесть М. АМИРХАНОВА «Не погибай!»; рассказ Р. ФАИЗОВА «Спустя годы»; стихи А. ХАРРАСОВА, РАШИДА ГАТАУЛЛИНА.
«Из поэзии тюркских народов»: стихи крымско-татарского поэта Г. ГУМЕРА.
«Публицистика»: статья Р. НИЗАМИЕВА «Беседа с Тукаем»; статья Р. МУРТАЗИНА «Крымский аксакал».
«Навстречу XII съезду писателей Татарстана».
«Литературная критика»: статья С. ХАФИЗОВА «Перестройка или очищение»; статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА о творчестве писателя В. Нуруллина.
«К истории культуры»: статья Т. КАРИМОВА «Родословная Р. Фахрутдинова».
«Славные времена»: статья И. ХАРА-ДАУАНА «Возвращение к прошлому».
«Время и люди»: статья Б. СУЛТАНБЕКОВА «Величие».
«Дружба литератур — дружба народов»: статья Ф. ИСЛАМОВА «Татарско-марийские культурные связи».
«Библиография»: статья Р. ГИЛЯЗИЕВОЙ-ХАМИДУЛЛИНОЙ о творчестве писательницы Н. Гиматдиновой.
«На наших обложках»: «Приезд Тукая из Оренбурга в Казань» — картина художника И. Гимранова; известный писатель А. Тимергалин.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the end of M. Habibullin's novel «Hansuyar-Khan's Grandson»; M. Amirkhanov's novel «Don't Perish»; R. Phaizov's story «After Years»; the verses of A. Kharrasov, Rashid Gataullin.
«From the Poetry of Turkic Peoples»: the verses of Grimean and Tatar poet G. Gumer.
«Publicism»: R. Nizamiev's article «Conversation with Tukai»; Ph. Murtazin's article «The Crimean Wise Man».
«Meeting the XII Congress of Tatar Writers».
«Literary Critigue»: S. Khafizov's article «Reorientation or Cleaning»; Ph. Galimullin's article about creative work of the writer V. Nurullin.
«To the History of Culture»: T. Karimov's article «R. Phakhrutdinov's Genealogy».
«Renowned Time»: I. Khara-Dauna's article «Returning tothe Past».
«Time and People»: B. Sultanbekov's article «Greatness».
«Friendship Among Literature Is a Friendship Among People»: Ph. Islamov's article «Tatar and Mari Gultural Connections»
«Bibliography»: R. Gilayzieva-Khamidullina's article about creative work of the writer N. Gimatdinova.
In our covers: I. Gimranov's pieture «Tukai's Arrival from Orenburg to Kazan»; eminent writer A. Timergalin.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Радиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов, Марсель Галиев.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 9.03.94 ел. Басарга кул куелды 16.04.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 22 407. Заказ А-108. Бәясе 330 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.



**Мөсәгыйт**

**Хәбибуллин**

# ХАН ОНЫГЫ ХАНСӨЯР

ТАРИХИ РОМАН

## 27

Саксин каласын җиңел генә алып, Сүбәдәй баһадир сарайда утыра иде инде, аның янына атылып чаптар егете килеп керде. Килеп керде дә баһадирның аягына төште.

— Баһадир, атакаем, Күлкән угланны болгарлар әсир иттеләр. Углан алыша да алмады, уктан яраланган иде.

Бу «сөенчене» китергән кишектингә Сүбәдәй камчы белән сыдырып җибәрим дигән иде, тыелып калды.

— Югал күз алдымнан! — дип кычкырды ул кишектиненә. Әмма теге чыгып китә башлагач кычкырды: — Тукта! — Кишектин коты алынып, баһадирга таба борылды. — Котбый меңбашка әйт, угланны җир астыннан булса да табып алып кайтсын. Баһадир әмере, диген.

— Баш өсте, баһадир.

Сүбәдәй камчы сабы белән, чыгып кит, дип ишеккә күрсәтте. Болай да ишеккә житәр-житмәс туктап калган чаптар егет, тиз үк чыгып китте. Шуннан соң гына сукыр күзен каплаган чүпрәген рәтләде һәм Акбикәгә утырырга урын күрсәтте. Чибәр вә горур иде бикә, ул ияген чөя төшеп, баһадир күрсәткән түмәргә таба узды, утырды, туры Сүбәдәйгә карады.

«Горур, тәкәббер, мәһабәт, гүзәл», — дигән фикергә килде Сүбәдәй. Барысы белән якынлык кылмаса да, ул бик күп хатын күрде, ләкин бикә кебек тәкәббер хатынны беренче күрүе иде әле. Әйтерсең, ул Сүбәдәйгә килмәгән, ә Сүбәдәй аңа килгән. «Тик бит инде сарай да, кала да Сүбәдәйнеке, бикә җаным», — диясе килде корыч баһадирның. Әмма әйтмәде, бикә чынлап та сокланырлык иде. Горур халыктан курыкмаса да, аларны хөрмәт итә иде Сүбәдәй. Хәер, Чыңгыз хан да шундый иде. Аз гына үзенә тиң кеше белән очраштымы, аның белән тегене тиң күреп сөйләшер иде, гәрчә соңыннан күбесенең башын кистерсә дә. Ә углан зур

---

Ахыры. Башы журналыбызның 3 нче санында.

хата кылган, нигә кирәк булды икән аңа далага чыгу?.. Кем кушкан? Шундук исенә төште: үзе орышка барабыз, син миңа һич югы туп куелган бер ат алып кайт, димәдеме? Диде ич!

— Бикә, көттерүем өчен гафу итегез. Мин сезне аңламыйм, бикә, нигә безнең белән орышмадыгыз? Дөрес, капкаларны да ачмадыгыз, орышмадыгыз да?

— Без сезне мөселманнар дип белдек, баһадир. Изге китапта: «Кылычлы ике мөселман очрашып сугыша башласалар һәм шунда берсе икенчесен үтерсә, үтергәннең дә, үлгәннең дә урыны җәһәннәмдә булыр», — диелгән.

— Тик бит мин мөселман түгел, бикә.

— Мөселман булмасаң, мөселман кылганны кыл, баһадир, урының җәннәттә булыр.

Сүбәдәй ишекьяры торучы кишектинең аяк какты, теге килеп бикәне алып чыгып китте. Сүбәдәй баһадир урыныннан купты, арлы-бирле йөренергә керешкә. Гадәтләнмәгән иде ул ошбу зур бүлмәләргә, күркәм җиһазларга, аяк астындагы җем-җем иткән келәмнәргә. Аның гомере юртада узды һәм ул үзен юртада гына тыныч сизә иде, шуның өчен юрта җыючы кишектиннәрен дәште һәм йорт уртасына юртасын куярга кушты. Юрта әзер булгач, шунда кереп, мендәренә кырын төште һәм шундук йокыга китте.

## 28

Артыкны, нә кысталса да, юртадан чыгармый башладылар. Бу хәлгә ул шикләнә калды. Эчтә утырган кишектингә, тышка чыгасым бар, дисә дә, тегенең бер дә исе китмәде, әйтерсең, аңа да әйтмиләр иде. Артык башта кычкырды, ахыр түзәр әмәле калмагач, беләк юанлык хибесханә таякларын тарткаларга керешкә. Инде анда да сакчы кымшанмагач, аяк астындагы комны казый башлады. Тик сакчы шунда да аның ягына борылып карамады... Магулларда тимер юк хәлендә, ләкин арканны сүс катыштырып, кылдан үрәләр, киртәләрне каен агачыннан әзерлиләр. Кояшта кипкән каен агачы тәмам чуенга әверелә, аны хәтта тиз генә кисеп тә булмый. Хибесханәнең киртәләре каеннан иде, һәр киртә чи каеш белән бәйләнгән — чәйнәп тә өзеп булмый. Тышта төн иде инде. Артык казыды да казыды. Юрта эчендәге кишектин әллә түшенә ияген кадап йоклый, әллә юри шулай утыра. Шулчак тышкы якта ыгы-зыгы купты, кишектин башын күтәрде, бертын гаҗәпсенеп, Артыкка карап торды. Артык ни кыйрга белми читлекне селкетергә тотынды. Ләкин читлекне казыклар белән кагып, нығытып куйганнар икән. Кишектин бертын утырды да, ни бар икән дип булса кирәк, чыгып китте. Ул да түгел, кире әйләнеп керде һәм юртаны бер итеп нәрсәдер эзли башлады. Менә ул читлек янына килде, читлек таягына тотынды. Мизгел эчендә Артык аның кулыннан эләктереп алды һәм кишектиннең кулын ике киртә арасыннан тартып алды. Кишектин аһылдый-ухылдый башлады, әмма кычкырмады. Ул ничек тә кулын кире тартып алмакчы итте, әмма Артыкта көч-гайрәт мондаен ике кишектингә җитәрлек иде.

— Чиш ишек бавын, чыгар мине,— диде Артык теш арасыннан ысылдап.— Тиз, югыйсә кулың сындырам.

Кишектин йөзен чытты, авызын ачып кычкырмак итте, әмма аваз чыкмады. Артык кулны бора, каера башлады.

— Чиш ишек бавын!

Кишектин чарасыз калудан булса кирәк, авызын ачты, киселгән телен күрсәтте.

— Чиш ишек бавын, мин сине үзем белән алып китәм. Балда-майда йөздерермен.

Кишектин башын чайкады, әмма икенче мәлдә инде ишек бавын чишә башлады. Чиште. Артык атылып читлектән чыкты һәм кишектинне бәреп екты, өстенә менеп кулларын артка бәйләде, өстенә киез ташлады. Ишеккә таба кузгалган иде, кире борылып килде, кишектиннең билендәге кылычын, хәнҗәрен алды. Тышта шау-шу киләләр, кемнедер куалар иде. Артык кылычны биленә такты, ишекъяры эленеп торган садакны, җәяне алды, япма чүпрәкне ачып, тышка күз салды. Ишекъяры бер сакчы йөри, ары таба һични күренми — караңгы. Садакны иңе аша элде, җәяне дә, арканны биленә такты, сөяп куйган сөңгене кулына алды. Артык сак кына тышка атлады, сакчы борылгач кына, аның аркасына сөңге белән кадады. Кишектин аһ итте дә берьякка ауды. Ыстанда ыгы-зыгы, тавыш эленеп тора. Ун адымнар чамасында киртәгә бәйләнгән иярле ат. Артык ашыкмый гына шунда таба атлады, чөнки ай яктысы якты, аны танулары бар иде. Ат янында кеше бар икән, ул атның тышавын чишеп маташа. Артык киерелеп, аның муенына кылыч белән сыдырды. Баш өзелеп берьякка тәгәрәп китте. Артык ат тышавын кылыч белән генә кисте дә күз ачып йомганчы сикереп атка атланды. Һәм сабыр гына, әмма атын тигез юырттырып, иләү читенә юнәлде. Ыстан хәрәкәттә иде, мондый чакта кемнең кай тарафка, ни өчен баруын исәпкә алучы юк, гәрчә кагыйдә буенча һәр унбаш, һәр йөзбаш, һәр меңбаш үз сугышчыларының кайда булуын, ни эшләп йөрүен белергә тиеш булса да. Тик бу кагыйдә төп чирү өчен генә гамәлдә иде. Аны саклаучы кишектиннәр барчасыннан да бүрекләре белән аерылып торалар иде. Артык сакчы бүреген кимәгәнгә үкенеп куйды. Гадәттә, ыстанны божрага алып сакчылар тора иде, бүген алар никтер күренмәделәр. Бу божрада торучы сакчыга тап булсаң, кайсы меңбашка, йөзбашка, унбашка каравың турында әйтергә тиешсең. Аллага шөкер, божрада сакчылар юк, димәк, ыстан күчәргә җыена — күчәләр, дип уйлады Артык, атын куалап, далага чыгып сызды.

— Әйдә, тулпарым, алдыр, алдыр. Коткара күр. Мине коткарсаң, хәлвә ашатып кына тотармын үзеңне.

Кемдер аңа кычкырды, кемдер туктатмакчы итте. Алай да иң читтә сакчылар бар икән, гәрчә дала башланса да. Артык чак кына уңга алды, таллар арасына шылды. Туктады, аттан төште, тынып калды, бары тик йөрәге генә тамагына җитеп кага иде.

Ат тоягы тавышлары ишетелде, талларга житкәч, туктадылар.

Һәм бераз караңгалап тордылар да китеп бардылар. Алар күздән язгач, Артык таллар арасыннан чыкты да атына атланды...

## 29

Иртән уянуга, Сүбәдәй баһадир бавырчысыннан каз каны сорады. Җылымса канны ул йотлыга-йотлыга эчте, аннары кул аркасы белән авызын сөртте дә ишекъяры торган кишектиненә җансакчысы Чакайны чакырырга кушты. Тәге килеп кергәч, аңа урын күрсәтте.

— Сөйлә.

— Угланны таптык, баһадирым. Ун болгар саклый иде...

— Углан кайда?

— Бирелдә, сарайда.

— Нигә аны баштан ук шулай дип әйтмисең! — Сүбәдәй канлы кул аркасын итек кунычына сөртә-сөртә сикереп торды, ишеккә юнәлде. — Ярасы зурмы?

— Исән калды, сөйләшә. Авыр, мәгәр сөйләшә. Янында табиб белән бер кыз. Бездә әсир булган кыз.

Сүбәдәй әйләнеп карады, туктады.

— Аты ничек? Сөмбелме?

— Белмәдем, баһадирым.

Баһадир сарайга ашыкты, ике баскыч аша сикерә-сикерә болдырга менде, каерып тышкы ишекне ачты, эчкәре узды, ишекъяры торган сакчы аңа кызлар бүлмәсен күрсәтте. Кերә-керүгә түргә узды. Түрдә исә кыз ятагында углан Күлкән ята иде, күзләре йомык, йөзе ап-ак. Уң кулына угланның бармагын тотып табиб утыра, сул кулында — әсир кыз Сөмбел. Сүбәдәй углан янына килде, маңгаена кулын куеп карады. Угланның маңгае ут яна иде.

— Табиб, ул исән калырмы?

— Ул исән калды инде, баһадир. Хәзер йоклый, тавышланмасагыз иде. Юл буе ыңгырашып кайтты.

— Якшы,— диде Сүбәдәй һәм ишеккә таба кузгалды, әмма чыгып барганда туктады, Сөмбелгә карап торды.— Кызны күз карасы кебек саклагыз! Углан үлсә, мин аның да башын кисәм.

Юртасына кайткач, ул меңбаш Котбыйны чакыртты, теге килеп кергәч, каршысыннан урын күрсәтте.

— Безгә, мөгаллимем, Бачман баһадирга илчеләр җибәрергә кирәк. Бирелсен. Бирелсә, мин аны кичерәм.

— Бирелмәсә, баһадир?

— Бирелмәсә, орышабыз. Далага чыгып орышабыз. Калада мин сугыша белмим. Инде мин аны әсир итәм, тотам икән — тиресен туныйм. Ул баһадир минем канымны күп кайнатты.

Шулчак юртага баһадирның чаптар егете килеп керде.

— Баһадир, ыстан кучкәндә Болгар тупчысы качкан. Бер сакчыны тончыктырып үтергән, икенчесенең башын чапкан.

— Тупчыны сакларга әпәне кем куйды?

— Углан, баһадир.

— Бар кит, күземнән югал. Тукта! Тукта! — дип кинәт бакырып җибәрде Сүбәдәй.

Такай чаптар кире әйләнеп керде.

— Углан егетләренә әйт, ул тупчыны таш астыннан булса да табып, минем каршыма алып килсеннәр. Меңбаш анда Бүртә бит?

— Баш өсте, баһадир. Җиткерермен.

— Әйт үзләренә, тапмасагыз — баһадир ат коерыгына тактырачак, диең. Искәрдең!

— Искәрдем, баһадир.

Чаптары чыгып киткәч, Сүбәдәй әйтте:

— Хәер, нигә миңа ул тупчы? Бачманны җиңгәч, ул аларны үзе үк миңа китереп бирәчәк. Шулаймы, меңбаш?

— Шулай, баһадир, шулай. Угланның хәле ничек, баһадир?

— Шәптән түгел, ләкин табиб, аякка басачак, диде.

— Син аңа, баһадирым, бик каты бәрелмә инде. Егерме егете кырда ятып кала, үзе яралана. Каланы тупсыз да алдык бит әле.

Сүбәдәй бертын дәшми торды. Мөгаллим хаклы иде, нигә ул хәтле чәбәләнергә? Иң мөһиме — бала исән. Терелер.

— Табиб каян соң, мин сорамадым да?

— Бачман баһадирның табибы ул.

Сүбәдәй баһадир кишектине аша елгыр йөзбаш Җүзәкәйне чакырырга кушты. Җүзәкәй килеп кергәч, ул аңа әйтте:

— Углан кишектиннәре кулыннан Болгар атлы тупчы кача. Ул миңа исән килеш кирәк, елгыр Җүзәкәй. Иртәгә монда акчачыларым, йортчыларым, йомышчыларым, урын җәючеләрем, асыл кишектиннәрем килеп җитәр. Мин аларны барысын да калага урнаштырырмын. Котбый меңбаш, син базарбашларны, алыпсатарларын күр һәм әйт, Сүбәдәй баһадир каладагы тәүге тәртипләрне бозмай, һәммәсе ничек булган, шулай калыр, дип әйтеп әйтте, диген.

— Мин китимме, баһадир? — диде елгыр Җүзәкәй.

— Син аны җир астыннан булса да эзләп тап, йөзбаш. Юкса...

Юк, әйтмәде тел очына килгән сүзен. Әмерен үтәмәгән кешеләрне Сүбәдәй нәкъ Чыңгыз хан кебек җәзалады: көрәштереп билен сындыртты. Ләкин көрәшеп бил сындыручы Җүзәкәй йөзбаш үзе иде. Шуңа тыелып калды Сүбәдәй. Ул белә иде, Җүзәкәй кебек елгыр вә житез магул юк. Җүзәкәй елан янында — елан, үрмәкүч янында — үрмәкүч, чаян янында — чаян, юлбарыс янында юлбарыска әверелә ала. Сүбәдәй кишектиннәре арасында иң елгыр, иң хәйләкәр, иң житез яугир егетләр — йөзбаш Җүзәкәй егетләре. Бу йөзбаш һәм аның яугир егетләре турында төрле имеш-мимешләр йөри. Имеш, алар ырымчылар, сихерчеләр, тылсымга ия кешеләр. Алар белән бәйләнгәнче, бәйләнмәгәнең мең артык. Аларның кайберләре күз буа, хәнҗәр йота, ут каба. Җүзәкәй йөзбаш яугирләреннән хәтта меңбашлар да куркалар, төтәнбашлар да хәтта аларга бәйләнүдән саклана. Тегеләр үзләре дә үз дәрәҗәләрен белеп яшиләр. Һәрхәлдә, башка яугирләргә караганда балда-майда йөзәләр иде. Сүбәдәй баһадир ошбу йөзбашка бик сирәк әмер бирә, гадәттә алар ял итәләр. Ә инде әмер алдылармы, җиренә житкереп үтәмичә тынмыйлар. Шуның өчен Бүртә йөзбаш артыннан Җүзәкәйне җибәргән иде Сүбәдәй. Ул белә иде, әгәр дә мәгәр Бүртә йөзбаш аның әмерен теге йә бу сәбәп чыгып үти алмаса, Җүзәкәй башкарып чыгачак. Орыш кырында исә Җүзәкәй егетләре гел Сүбәдәй тирәсендә булдылар. Алар Сүбәдәй баһадирның гомерен саклау өчен дошман угына үз күкрәкләрен куярга да күп сорамыйлар иде. Сүбәдәй баһадир Җүзәкәй яугирләренә мул түли, чөнки аның гомерен генә сакламыйлар, данын да саклыйлар иде.

Угланның бачманлыларга әсир төшүе, яралануы Сүбәдәйнең канын кайнатты, ачуын китерде. Нинди шартларда, ничек бачманлыларга тап була углан? Ул белмәде. Ләкин угланны коткарган кишектингә бүләген кызганмас. Каланы алды, углан табылды, куанасы-киләнәсе иде, әллә нигә күңел төшенке. Чөнки Бачман баһадир белән орыш булмады әле. Гаскәре исән, көчле, куәтле, тупчыларын да саклап калды. Һич булмас димә, иртәгә үк калага һөҗүм итүе дә бар. Бачман баһадирның кылыч йөзен Сүбәдәй ике тапкыр татыды инде, орыш кырыннан кача торган сугышчы түгел. Бачманны ул алдады, хәзер хәбәр ирешкәндер инде — Сүбәдәй калада, бикәсе аның кулында. Шуннан соң нә кылыр баһадир? Башын ташка орырга житешеп, калага һөҗүм итәрме, җай көтәрме? Иртәгә үк калага һөҗүм итсә — яман, Сүбәдәй рухи яктан әзер түгел, әле төп ыстан да килеп житмәгән, ә менә бер-ике көн сабыр итсә, Сүбәдәй үзе далага чыгар. Орышыр. Орыш хәтәр булыр, Сүбәдәй бу хакта белә иде. Каласын хәйлә белән кулына төшергән өчен Бачман баһадирның Сүбәдәй белән күзгә-күз килеп сугышасы килер. Зарар юк, Сүбәдәй баһадир куркып калмас — орышыр. Орышыр һәм җиңәр. Хәзер исә ничек тә каланы сакларга, юртачылар кереп бетүгә, капкаларны ябарга һәм ышанычлы сакчылар куярга. Шуннан аңа кала иясен җиңәсе һәм бирәдән куасы гына калачак. Бачман баһадирның әсир төшкән гаскәрләрен Сүбәдәй һәр унбашка бөрәм-бөрәм бүлеп бирәчәк. Бу өлкәдә аның тәҗрибәсе бар. Тугыз арасына килеп эләккән әсир егет бик тиз сына һәм тегеләрдән калмаска тырыша. Дөрес, кайбер әсирләр арасында качып китәргә маташучылар да булгалады, ләкин андыйларны тоткан хәлдә Сүбәдәй барчасы күз алдында үзе үк кылычтан уздырды. Гыйбрәт өчен. Һәм шуннан соң унбашларга таратылган әсирләр күндәмләнеп калырлар иде.

Хәле арулана башлагач, Сүбәдәй белер әле: углан бачманлыларга ничекләр әсир төште икән? Аннары Бачман табибе, теге чибәр кыз каян килеп аның янындалар?.. Нәрсә ди бит әле ул кыз, имеш, Карлыгачны, угланы Ташбайны белә. Искитмәле хәл. Юк, моны тизрәк ачыкларга кирәк, чөнки ары таба болай яшәве мөмкин түгел. Аның кайчандыр өзелепләр яраткан һәм әле дә бәгырен телгәләп, хәтергә төшеп торган Карлыгачны, угланы Ташбайны күрәсе килә. Һәм бу хәлдә аңа Тәңресе

булышыр. Әле булса күз алдында: Сөябел аны яуга җибәрмәс өчен алдына тезләнде, ялынды, ялварды, оялтты, янады, куркытты. Янәсе, яуга китә икән, ул угланы Тайчинны алып, күрше иләүгә китеп барачак. Сүбәдәй бер сүз дә әйтмәде, әйтер чамасы калмаган иде. Түзәргә булды, сабыр итте. Чөнки белә иде, Сөябел холкын күрсәтә, аны ничек тә алып калмакчы итә, ә Сүбәдәйне әллә нигә Болгар ягы тарта. Карлыгачы, Ташбае төшләренә керә, чарасыз итә.

Яуга киткәндә Сөябел бу юлы да аны озатырга килмәде. Ул гынамы, угланы Тайчин белән дә саубуллаштырмады. Ләкин инде балигъ булган Күлкән угланын тыя алмады, Күлкән инде ата тәрбиясен алган иде. Хәер, исән-сау әйләнеп кайтса, Тайчин да аныкы булыр. Әйе, үсә-исәя төшкәч. Хәтерендә, Сөябел бик каһәрле башлагач: «Сөябел, ышан, Күлкән исән-сау булыр, мин аны күз карам кебек саклармын»,— диде. Усал һәм мәкерле җан Сөябел елаудан туктап, мыскыллы рәвештә: «Угланың түгел, үзеңнең күзең дә саклый алмадың әле»,— диде. Менә шунда инде Сүбәдәй түзмәде, тегеңә камчы белән сыдырды. Хатыны куырылып китте һәм сыгылып төште. Яңадан ул аңа бер сүз дә әйтмәде, хәтта күтәрелеп тә карамады һәм, әлбәттә инде, озатырга да килмәде. Шушы хәлдән соң Карлыгач аның төшенә тагын да ешрак керә башлады. Җитмәсә бу чибәр кыз, болай да бимазалы бәгырьгә гүя тоз сипте: имеш, Карлыгачны да, Ташбайны да белә!..

Бик ихтимал, язган булып Карлыгачын очратса, ул да аны яу йөрүдән тыярга итәр. Тик Сүбәдәй баһадирны яу йөрүдән туктата алырдай кеше тумагандыр шул әле, бер күзен генә түгел, бер кулын, бер аягын югалтса да, Сүбәдәй яу йөрер, Чыңгыз ханның, Җүси угланның васыятьнамәсен үтәр. Чөнки ул белә: яу йөрүдән бәхет тапкан кешене бу шөгыленнән туктатса үлем генә туктата алыр. Тик менә Сөябелгә биргән вәгъдәсен үти алырмы? Углан Күлкәнне исән-имин илгә әйләндереп алып кайтырмы? Монысы инде бер Тәңре кулында иде. Ул ни язган, шул булыр. Ә хәзергә бөтен көче белән Бачман баһадирга ябырылырга тиеш. Һәм аның гаскәрен тар-мар итәргә — җиңәргә!

Сүбәдәй баһадир көрсенеп куйды. Бачман баһадирны җиңәм дигән саен аның күз алдына ике тапкыр кыйналуы килде. Икесеннән дә шул Бачман баһадир тарафыннан кыйналды ич. Бусында да җиңелсә, Болгарга бара алмаса?.. Карлыгачы һәм Ташбае турында ишеткәч, күңел дигәнең сыкрап кына сызлап тора башлады. Бу сызлауга түзәр иде дә, Күлкәне кайгысы өстәлде. Дөрес, каланы ул бик җиңел кулга төшерде. Мәликә бикә хәзер аның кулында. Шуның өчен яугирләреннән кала халкын талатмады, тәртипләргә кагылдырмады. Меңбаш Котбыйга каткат тәкърарлады: «Руханиларга, һөнәрчеләргә, сәүдәгәрләргә, алыпсатарларга тидермә. Гомумән, каладагы тәртипләр ничек булган, шулай калсын. Мәликә бикәгә мин сүз бирдем һәм сүземдә торырмын. Кем дә кем минем әмерем боза, тотып үземә китер, җәзасын үзем бирермен һәм бөтен кала халкы алдында җәзалармын. Мәликә бикәнең сугышчыларын үзеңә ал, берәм-берәм унбашларыңа бүлеп бир. Кыл шуны, Котбый, сине моңа өйрәтәсе юк...»

## 30

Бачман баһадир, иртәгә үк калага һөҗүм итәбез, дисә дә, кичкә таба төмәнбашларына җансакчыларын җибәрде — һөҗүм булмый, ди. Кич якта ул янә чатырына төмәнбашларын дәштерде. Шунда кө тмәгәндә чатырга Артык баһадир килеп керде. Бачман баһадир гына түгел, чатырдагы барчасы да аягүрә торып бастылар, ни әйтергә белми аптырап калдылар.

— Артык баһадир! — диде, ниһаять, Бачман баһадир.

— Мин, баһадир, мин,— диде Артык һәм Бачман кардәше алдына үтеп, бер тезенә төште.— Кичер мине, баһадир.

— Бу ни дигән сүз тагын, баһадир!— диде Бачман һәм аны иңнәреннән тотып торгызды, кочаклаштылар.— Утыр, сөйлә. Бавырчы, кымыз китер.

— Минем тамагым тук, мин егетләрем янында булдым инде, баһадир,— диде Артык.— Тупчыларым исән-саулар икән. Ташбаем да, хан оныгы Хансөяр дә, меңбаш Юлдаш та — куанып бетә алмадым, баһадир. Раббыбыз әйткән: иң яман нәрсә — кешенең намусын, вөҗданын мәсхәрәләүдер. Мине мәсхәрәләделәр, туганнар, читлек хибесханәгә бикләп, тышка чыгармыйча мыскыл иттеләр. Иллә Аллаһы тәгалә хәлемә керде, яман халыктан котылдым. Инде шул сыңар күздән үч аласы иде, кардәшләр. Сүбәдәйнең көче бар: куәтле, иллә без туган җиребездә, туган илебез вә халкыбызны яклыйбыз.

— Без иртәгә үк калага һөҗүм итәргә уйлаган идек тә сабыр итәргә булдык, Артык баһадир. Киңәшик, киңәшле эш таркалмас, дигәннәр,— диде Бачман баһадир.— Кардәшем Артык, бәнем бикәм дә, гүзәл кызым Сөмбел дә Сүбәдәй кулында...

— Каламыз да,— диде меңбаш Буранбай.

— Әйе, калабыз да,— дип куәтләде Бачман баһадир.— Минем башта Сүбәдәйгә илчеләр җибәрәсем килә, Артык кардәш.

— Анысы кирәкмәс, баһадир. Сүбәдәй аларны кылычтан гына уздырыр, йә билләрен сындыртыр.

— Минем аны, Артык баһадир, каладан чыгарасым килә. Орыша икән, далада орышсын.

— Ул болай да каладан чыгып орышыр, канкардәш. Чөнки магуллар калада орыша белмиләр. Аларга дала кирәк.

— Меңбаш багучы Буранбай хаклы,— диде Артык, кымызга үрелеп.— Түмәнбашлар нигә дәшми утыралар соң?

— Безгә дә далада орышу кулайрак, баһадирлар,— диделәр беравыздан диярлек түмәнбашлар.

— Якшы,— диде Артык.— Орышны сөйләшкәнчә алып барабызмы? Әүвәл минем тупчылар, аннары укчылар?..

— Әйе, Артык кардәш,— диде Бачман баһадир.— Тик бүген көнен билгелик. Багучы меңбашым, син нә киңәш бирәсең?

— Берсекөнгә Сүбәдәй үзе чыгачак.

— Әйе, түзмәс ул,— диде Артык баһадир.— Түзмәс. Аның безне җиңеп, Үгәдәй ханга тизрәк сөенче җибәрәсе килә. Ашыга хәтта.

— Димәк, килештек. Берсекөнгә,— диде Бачман баһадир.— Багучым белән Артык, сез калып торыгыз. Ә сез, түмәнбашларым, китә аласыз.

Артык белән Буранбай гына калгач, Бачман баһадир үзе үк касәләргә кымыз койды.

— Артык баһадир, Сүбәдәйдә дүрт түмән чиру, миндә — ике һәм синең тупчыларың. Бу орыш безнең өчен хәерле бетәрме?

— Мин күрәзә түгел, баһадир. Мәгәр орышмый китүне дә якламас идем. Моның өчен безне Илһам хан гына түгел, халык та мактамас.

— Син хаклы, баһадир. Аллага тапшырдык алайсаң.

Бачман баһадир салган кымызны эчеп куйды һәм бертын буш касәгә карап торды. Аның күз алдына бикәсе Акбикә, кызы Сөмбел килде. Алар дошман кулында иделәр, онтылып уйга калуы чарасызлыктан иде бугай.

— Баһадир,— диде Бачман баһадирның кайгысын уртаклашырга җыенып Артык.— Раббымыз: золымнан җәберләнгән кешенең каргышына киртә булырлык җәтмә юктыр, дигән. Иншалла, без Сүбәдәйне илемездән куарбыз. Чөнки Аллаһы тәгаләнең иң яраткан сүзе — азатлык вә ирекләр...

Бағучылары, Бачман баһадир гаскәрен орышка хәзерли дип житкерүгә, Сүбәдәй баһадир да чирүен каладан алып чыкты һәм Чыңгыз хан ысулы белән тезелергә әмер бирде. Дөрес, ул хәзер чирүен нәкъ менә Чыңгыз хан кебек тезми, чирүгә бераз гына үзгәреш кертте. Үгәдәй хан аңа һәр төмәнбаш янына бер нойон биреп җибәрде. Нойоннар орышларга катнашмыйлар диярлек, әмма табыштан икеләтә өлешне үзләренә алалар. Шуның өчен Сүбәдәй алар белән аралашмады да, табынга да дәшмәде. Сүбәдәй үзенә, нойоннар үзләренә көн күрделәр. Нойоннар үзләре белән хатыннарын да алганнар иде, тегеләр бер-берсеннән көнләшеп, үзара талашып яталар, таланган әйберләрне бүләләр икән. Сүбәдәй хәтта шул хәлдә дә алар арасына кермәде, гүя аның өчен нойоннар юк иде. Табынга һәрчак төмәнбашларны дәште, алар белән киңәште. Тегеләрнең хатын-кызга нәфселәре хирыс икәнлекләрен белеп, аларга каравыш кызлар җибәреп торды. Нойоннар орышта катнашмасалар да, сугышны күзәтергә яраталар иде. Саксинга җитеп, җитди дошман очрамаганга нойоннарның эчләре поша, таланган мал булмаудан зарланалар иде. Калага кергәч, тегеләр кибетләрне таларга, сәүдәгәрләрнең товарларын тартып алырга керешкәннәр. Меңбашы Котбый шул хакта хәбәр ирештергәч, Сүбәдәй нойоннарны сарай каршына куелган юртасына чакыртты. Нойоннарны Җүзәкәй меңбаш алып килде, чөнки Котбыйга: «Баһадир үзе килсен»,— дип әтәчләнә башлаганнар икән. Әмма Җүзәкәй меңбашның талканы коры — нойоннарның кулларын бәйләп алып килгән. Юртага кергәч, Сүбәдәй нойоннарның кулларын чишәргә кушты, кунакларга утырырга мендәрләр күрсәтте, кымызчыга дәште, үзе үк касәләргә кымыз койды.

Нойоннарның барысы да диярлек Чыңгыз хан гаиләсенә теге йә бу яктан кардәш, туган кешеләр, шуңа күрә Сүбәдәй аларның ачуларын китерергә теләмәде. Шул ук вакытта биредә кем икәнен дә сиздерәсе килә иде. Сүбәдәй баһадир ач бурзай кебек көн-төн авыл-калалар яулаганда, болар үз юрталарында хатын-кызлар өстендә ауныйлар. Хак тәгалә, ул үзе белән Җүси угланның Бату атлы үсмерен алып китмәкче иде, әмма Үгәдәй хан әллә нигә каршы төште, менә боларны такты. Корылтай шулай хәл иткәч, Сүбәдәй һични кыла алмады. Олуг хан Үгәдәй күп эчә, гелән арак[1] сөреме томанында йөрер иде. Сүбәдәй аның бу кыланышын килештермәде, әмма каршы әйтергә дә кыймады — Үгәдәй хан мәрхүм Чыңгыз ханның иң яраткан углвны иде. Саксин каласына кереп утыруга, Сүбәдәй баһадир Үгәдәй ханга сөенче җибәрде. Иртәгә Бачман баһадирның гаскәрен туздыргач, Үгәдәй ханга таланган малның иң зур өлешен җибәрер. Ә менә сорыкорт нойоннарга әллә нигә күңеле ятмый. Аракы эчә-эчә йөзләре шешенгән нойоннар кымыз эчкәч җанлана төштеләр, берсе тамак кырып хәтта сүз әйтмәкче итте, ләкин иkенчесе аның кулына ябышты: дәшмә, янәсе. Нойоннарның болай да кысык күзләре, тәмам йомылып, сызык кына булып калган, зур корсакларын яшермичә, кукыраеп утыралар. Сүбәдәй баһадир нойоннарга карап-карап торды да тегеләрне кызык итәргә булды. Юк, ул аларга сәүдәгәрләрнең малларына ташланган өчен бәйләнмәс, ул аларга тәкъдим ясар. Өчесенең берсен калага тархан итеп куяр. Тик бер шарт белән: кайсысы арак эчеп исерми һәм һич югы аягында басып тора ала, шул кала тарханы була. Ә кала тарханы һәр сәүдәгәрдән, алып-сатардан ун өлеш товарның бер өлешен җыярга хокук алачак. Бу хакта әйткәч, нойоннарның күзләре ачыла төште, ачкан авызларын ябалмый тордылар. Арак эчү мәсьәләсендә аларны уздыручы, ай-һай, булырмы икән — юктыр, шуның өчен тизрәк арак китерүне сорадылар. Сүбәдәй чүлмәк белән арак соратты.

[1] Арак — магулларның кымыздан ясалган көмешкәсе.

Китерделәр. Сүбәдәй салды да бирде, салды да бирде. Тегеләр бушата гына тордылар. Ахыр үзләре эчә башладылар. Сүбәдәй көтте. Бер чүлмәк арак бетте, икенчесен китерделәр, өченчесен, бары тик дүртенчесен эчеп бетергәч кенә, тегеләрнең телләре көрмәкләнә башлады. Сүбәдәй тагын бер чүлмәк арак китертте. Монысына көчләре җитмәде. Берәмберәм ава башладылар. Бары тик берсе — Кадан нойон күзен тондырып утыра бирде.

— Кадан нойон, син җиңдең,— диде Сүбәдәй.— Тор, мин сиңа ярлык бирәм.

— Казер, казер, багатур. Казер.

Кадак нойон тәгәрәп яткан нойоннарга күз төшереп алды һәм күтәрелә башлады. Башта ул тезләнде, аннары кулларына таянды, шуннан соң гына ястык кебек арт санын күтәрә алды. Тик менә кулларын ычкындырып, гәүдәсен турайтыйм гына дигән иде, каршындагы чүлмәккә капланды. Чүлмәк ватылды, нойонның йөзе ертылды, Кадан нойон яман итеп бакырып җибәрде.

Сүбәдәй баһадир кишектиннәрен дәште, нойоннарны хатыннарына илтеп ташларга кушты, ә Каданны табибкә күрсәтегез, диде. Тәмам бурсык хәленә җитеп симергән нойоннардан Сүбәдәй шулай котылды. Ләкин котылып җитмәгән икән әле, икенче көнне иртән-иртүк аның юртасына Кадан нойон килеп керде. Чүлмәк ярган борыны шешкән, кашлары канга каткан, аскы ирене киселеп салынган, әмма үзен төз тота. Карашы усал, күзләре тонык.

— Баһадир, мин җиңдем!

— Җиңдең, җиңдең, Кадан нойон,— диде Сүбәдәй килешеп.— Утыр, сөйләшик.

— Минем баш чатный.

— Хәзер арак китерерләр.

Сүбәдәй бармак шартлатты, шундук чаршау артыннан чүлмәк белән арак чыгардылар. Сүбәдәй аракны касәләргә койды.

— Мин тархан булам,— диде, касәне кулына алуга, Кадан нойон.

— Булырсың, булырсың,— диде Сүбәдәй, касәсен кире куеп.— Тик бер шарт белән. Ошбу халыкның динен кабул итәрсең — бер. Икенчедән, Бачман баһадир бикәсенә өйләнерсең. Ул хатын Сарбай хан кызы, аксөяк. Өйләнерсең никахлап, мөселманнарча.

— Мин риза, баһадир.

Меңбаш Котбый керде, Сүбәдәй аңа күтәрелеп карады да ым кагып кына утырырга кушты.

— Меңбаш Котбый, менә Кадан нойон, кала тарханы булам, ди. Син ничек уйлыйсың, башкара алырмы?

— Әүвәл ислам динен кабул итәр.

— Итәр-итәр,— диде Сүбәдәй ашыга төшеп.— Эч әйдә, нойон. Әйе, чүлмәкне күтәреп эч. Шуны бетерә алсаң, син — тархан.

Сүбәдәй баһадир Котбыйга күз кысты, ә Кадан нойон бер дә икеләнмичә, чүлмәкне күтәреп арак эчә башлады. Эчеп бетерде һәм берьякка тәгәрәп тә китте.

Сүбәдәй табибен чакыртып алды һәм әйтте:

— Кадан нойон уянгач, кадерле даруың салып бирерсең.

— Якшы, баһадир, шулай итәрмен.

Котбый меңбаш ишеккә таба кузгалды, Сүбәдәй аңа иярде, ул угланның мөгаллиме буларак белә иде табибнең нәрсә бирәсен, ул даруны салып биргәннән соң берәүнең дә якты дөньяга кире әйләнеп кайтканы булмады әле.

— Тархан итеп ошбу калада мин угланым калдырырмын, меңбаш Котбый.

— Якшы, шулай итәрсең, баһадир,— диде Котбый һәм өстәде: — Чиру орышка әзер, баһадир, сине көтәбез.

Сүбәдәй атына сызгырды, кола ат килеп туктауга, яшьләргә хас җитезлек белән атына атланды һәм Болгар капкасына таба чапты. Чирүне шул капка аша чыгарырга боерган иде.

Чирүне ул җәя рәвешендә тездерде. Һәм ерак булмаган Бачман баһадир гаскәренә таба кузгалырга боерды. Көч аңарда икеләтә артык һәм ул җиңәсенә ышана иде.

## 32

Кояш шактый күтәрелсә дә, ике якның берсе һөҗүм итмәде. Сүбәдәй ни көтәдер, Бачман баһадир белми иде, ә менә үзе алдан ук төмәнбашлары белән сөйләшеп куйган иде — баскан җирдән кузгалмаска, бары тик дошман һөҗүм иткәндә генә орышны кабул итәргә. Бачман баһадир, җансакчыларын ияртеп, орышка тезелгән гаскәриләре каршыннан ат менеп узды.

— Кардәшләрем, азатларым! Дошман калабызны хәйлә белән кулына төшерде. Сөйгән хатыннарыбыз, нарасый балаларыбыз хәзер магуллар кулында. Без калабызны дошман кулыннан алырбыз һәм хатыннарыбызны, нарасыйларыбызны коткарырбыз! Ур-ра! Кардәшләр, ур-ра! Туганнар! Аллаһы тәгалә безнең белән! Ур-ра!

Бачман баһадир гаскәриләрен урра кычкыртты, әмма һөҗүмгә кузгалмады. Төмәнбашлар, меңбашлар белән шулай алдан ук сөйләшенгән иде. Уң канатта торучы Сөләйман бәк тә, сул канатка баскан Арыслан бәк тә, төп төмәнне җитәкләүче үзе дә, чак кына алгарак чыгып баскан тупчылар да баһадирның Ур-расын күтәреп алдылар. Ур-ра тавышы Сүбәдәй баһадирга да барып иреште. Ул ак киндергә кара ай төшерелгән әләмен күтәрергә кушты, быргычыларына уйнарга боерды. Магуллар чирүе, шуны гына көткән кебек, һөҗүмгә кузгалды.

Атлар тупылдавы, ярсынган һөррә авазлары даланы уятты, йөрәкләрне ешрак кагарга мәҗбүр итте. Бачман баһадир белә иде, бүген менә шунда, туган каласының кырында кыпчак халкының язмышы хәл ителәчәк: йә җиңелә, йә магулларны куып җибәрә. Ул чаптырып тупчылар алдында торган Артык баһадир янына килде һәм кисәткәндәй:

— Баһадир, ашыкма, якынрак җибәр! — дип кычкырып китте.

Бачман баһадир тоташ ташкын булып килгән магулларның яугирләрен ап-ачык күрә башлады, ләкин һаман гаскәрен кузгатмады. Аның янында ук байракчы. Байракларына барс сурәте чигелгән. Төсе яшел, мөселманнар төсе, табигатьнең ямьле төсе.

Артык баһадирның тупчылары гасабилана башладылар, ут алырга җыенучылар күренде. Артык алар каршына чыкты, атын арт аякларына бастырып, кычкырды:

— Тупчыларым, ашыкмагыз, минем әмерем көтегез!

Һөҗүм ташкыны күзгә күренеп якынайды, нә сабыр булырга теләгән Бачман баһадир да тупчылар ягына карап-карап алды. Вакыт кебек иде инде, аннан бер ярсыган дошманны тыеп та булмас. Ләкин Артык ашыкмады. Магуллар уктан ала башладылар, килеп җитәр-җитмәс комга уклар кадала башлады. Артык чаптырып тупчылары каршыннан узды.

— Ут алыгыз, ут!

Шул мизгелдә үк туплар гөрселди башлады. Магулларның алдан килгән җайдаклары бер читкә тайпылдылар, ә ташкын булып килгәннәре аларга бәрелер хәлгә калганда туктарга иттеләр. Китте ыгы-зыгы, һөҗүм туктады, дулаган атлар күренгәләде. Туплар тәтене таралыр-таралмас, Бачман баһадирның укчылары алга ыргылдылар. Алар каушап калган магулларны укка ала башладылар. Магуллар чигенгәндә һични белән исәпләшмиләр, аларның кайберләре — аттан егылганнары, йә булмаса атлары яраланып, ятып калганнары ишләренең иярләренә ябыша-

лар, хәтта үз яугирләрен иярдән суырып төшереп, үзләре атланалар икән. Магулларны бастыра барган Бачман баһадир моны үз күзе белән күрде. Бачман баһадир укчылары каушап калган магул яугирләрен уктан бик оста чүпләделәр, хәтта мавыгып та киттеләр бугай, куа чыктылар.

Боларның барысын да күзәтеп торган Сүбәдәй, беренче һөҗүмнең сүтелүен күреп, урт итен чәйнәде, бармак буыннары агарганчы камчы сабын кысты. Орыш кырында аның каушый торган гадәте юк иде. Ул бер тапкыр тулганган, кайсы-кая сибелә башлаган, орыш кырында чәбәләнеп ятып калган атларны, йөгерешеп, һич югы ишенең ияренә ябышып котылырга теләгән яугирләрен карап-карап торды да, ике як канатындагы төмәннәренә әләм белән ишарә ясап, һөҗүмгә кузгалырга әмер бирде.

Качып барган магулларны куа килеп, тәмам мавыгып киткән Бачман баһадир укчылары ике яктан да тулганага алырга килгән магул яугирләрен күрми калдылар. Бу хәлне күреп алган Артык баһадир җансакчыларын ияртеп, Бачман баһадир артыннан чапты. Ул магулларны куа барган һәм орыша-орыша дөньясын оныткан Бачман баһадир янына ук житте һәм:

— Безне тулганага алалар, баһадир! — дип кычкырды.

Бачман баһадир, айнып киткәндәй, эзәңгесенә басып, тирә-ягына бакты һәм укчыларына:

— Тулгана. Борылырга! — дип әмер бирде.

Аның әмерен меңбашлар йөзбашларга житкерде, бачманлылар ашыгыч төстә чигенә башладылар. Бу вакытта ике яктан да тулганага килгән магуллар аларның юлын бүләргә тырышалар иде. Тик аз гына өлгерә алмый калдылар. Артык баһадирның тупчылары атларын калдырып, тупларын корырга өлгергәннәр иде инде. Алар уң яктан Бачман баһадир укчыларын тулганага алырга ташланган магулларның каршына төштеләр, тупка ала башладылар. Туп тавышына өйрәнмәгән атлар кайсы дулап китте, кайсы магул борылып кача башлады. Бу хәлне күреп, бачманлыларны икенче яктан тулганага алырга килгән магуллар да кире борылдылар. Бачман баһадир азатлары аларны янә куа киттеләр. Баһадир үз дигәненә иреште, магулларны кала диварына кысрыкларга тотынды. Сүбәдәй чарасыз калды һәм яугирләренә калага качарга әмер бирде. Тик яугирләрнең барысы да кала капкасыннан кереп бетмәделәр, капкаларны яптылар. Бачман укчылары төрлесе-төрле якка сибелгән магул яугирләрен куып житеп укка алдылар, кылыч белән тападылар.

Кирмән-кальга диварыннан уклар ява башлагач кына, Бачман баһадир азамат егетләренә кире борылырга боерык бирде.

Орыш кырында меңнәрчә магул яугирләре ятып калса да, Бачман баһадир калага керә алмады. Калага керү өчен соң иде инде. Кояш офык артына кереп бара, тиздән көн сүнәчәк.

Баһадир гаскәрен ыстанга борды, ә мәет жыючылар эшкә керештеләр. Мөселман халкы буларак, алар орыш кырында төнгә мәет калдырмыйлар иде.

## 33

Артык баһадир, тупчылары янына кайткач, атыннан төште, кан каткан кылычын инешкә төшеп юды һәм чатырына керде, инбашын дошман угы сыдырып киткән иде, табибны дәшәргә кушты.

Табиб килде, ярасы зыянлы түгел иде, ниндидер яфрак каплап бәйләде дә китеп барды. Артык исә бавырчы кулыннан бер касә кымыз алып эчте дә чатырыннан чыкты, калкурак жиргә куелган Бачман баһадир чатырына таба китте. Җансакчылары аңа иярделәр. Артык аларга борылмый гына:

— Калыгыз,— диде һәм өстәде:— Мин кайтканда чатырда өч меңбаш та булсын, минем алар белән киңәшәсем бар.
Артык исә Бачман баһадирда озак тормады, әйләнеп тә кайтты. Меңбашлары өчесе дә чатырда иделәр инде. Бавырчы табын хәстәрләгән. Ашап-эчкәннән соң, әчкелтем кымыздан авыз иткәч кенә, Артык баһадир касәсен алдына куйды да ни өчендер хан оныгы Хансөяргә карады.
— Йә, оланнар, нә әйтергә исәбегез?
— Атам,— диде Ташбай углан.— Калада мәликә бикәбез, кызы Сөмбел.
— Беләм,— диде Артык, ул һаман хан оныгы Хансөярдән күзен алмаган иде әле.— Нә әйтерсең, Хансөяр меңбаш? Син хатыныңны магулларга сатып калдырган икәнсең бит.
— Мин аны сатмадым, атакай, ул үзе китте.
— Хак, үзе китте,— диде Ташбай.— Сүбәдәй ыстанына үтеп, баһадирның серен беләсе килгән иде.
— Белдеме соң?
— Атасы Бачман баһадирга Сүбәдәй баһадирның ыстанын ташлап калага юнәлүен җиткерүче ул, атакай.
— Әйе,— диде Артык, касә читенә чирткәләп.— Кыю бала.
— Сүбәдәй баһадир безне, атакай, төп башына утыртты,— диде хан оныгы.— Хәзер сарайда утыра.
— Утыра,— диде Артык.— Утыра мәлгунь.
Чатырга сүзсез генә Айгөл керде, табынга утырды. Артык: «Моңа ни кирәк тагын?» — дип уйласа да, килененә хәтта күз дә салмады.
— Безгә, атакай, калага үтеп керергә кирәк,— диде Ташбай.
— Соң сез анда бер тапкыр булдыгыз түгелме соң инде?
— Булдык булуын. Атам, син дә булдың ич анда.
— Әйе, мин дә булдым. Ләкин сез сәүдәгәр йөзендә, мин әсир хәлдә. Мин күргәнне сезгә күрергә язмасын, балалар.
— Атам,— диде Айгөл.— Мин сарайга керергә җир асты юлын беләм.
— Җир асты юлын? — дип сорады Артык. Ул кулындагы балдакны салды, табын уртасына куйды.— Кайсыгыз шуны үрелеп ала ала?
— Мин,— диде Ташбай, әмма балдакка буе җитмәде.
Хан оныгы Хансөяр бик озак балдакка карап торды, аннары ашъяулыкны бөтерде дә тезләрен күчереп, балдакны алды.
— Эһә, ярый-ярый, олан. Йә, аңлат, килен, нинди җир асты юлы ул?
— Дивардан ерак түгел бер ермак бар, шуннан туры сарайга үтеп керә торган юл бар. Капкаларны япкач, Сөмбел белән без сарайга һәрчак шуннан керә торган идек.
— Эһем, хан оныгы Хансөяр, син ни диярсең?
— Тәвәккәлләргә кирәк, атакай. Анам белән Сөмбелне коткарсак, Бачман атам өчен...
— Шым! Шым бул, олан. Хәзер син аңлат, килен. Ул юл кая барып чыга?
— Туры бикә бүлмәсенә, бикә ятагына, атам.
— Хуш, хуш. Шәрәфәтле бикәбезне вә аның кызын коткаруны зур дәрәҗәгә саныйм, оланнар. Тик башта мелла белән киңәшәсе иде. Аның белмәгәне юк. Ул да бит Сүбәдәй ыстанында булып кайткан кеше.
Үзен чакырасыларын белгән кебек, чатыр ишегенә мелла Хакимҗан башын тыкты.
— Баһадир өйдәме?
— Кер әле, кер, мелла. Уз, утыр,— диде Артык аңа янәшәсеннән урын биреп.— Әйт әле, мелла Хакимҗан, Сүбәдәй баһадир чирүенең төп халкы кайсы кавемнән?
— Ерактанрак башлау хәерлерәк булыр, оланнар. Борынгы заманнан ук Туран дәүләтенә караган Өнән һәм Күрәлән елгалары буйларында

төрек, манжүр, магул халыклары тереклек иткәннәр. Сигезенче гасырның урталарында уйгурлар, тугызынчы гасырның уртасында угызлар Үргән буйларын ташлагач, бүген магуллар биләмәсе булган төбәктә төркиләр бик аз калганнар. Аларның биләмәләрен, ягъни җәйләүләрен магуллар биләгән. Аларның беришләрен — татаби, бәгъзеләрен — татарлар, бәгъзеләрен магул дип атаганнар. Борынгырак заманнарда аларны ак татар, кара татар, тукыз татар, урман татарлары дип атаганнар. Чыңгыз хан аларны берләштергәч, барысын да магул дип атый башлаганнар. Бер сүз белән әйткәндә, болар әнә шул татарлар, ягъни урман татарлары дип аталган магуллар безнең җиргә яу килделәр. Магуллар үзләре гаять дәрәҗәдә надан булалар, шуның өчен мөгаллимнәрне уйгурлардан алалар. Кыска гына вакыт эчендә Чыңгыз хан кырык алты төрек-магул кабиләләрен берләштерә һәм нәүбәттәге корылтайда аны олуг хан итәләр. Әнә шул олуг ханның корыч баһадиры безнең Саксин каламызга кереп утырды, бикәбезне һәм аның гүзәл кызын әсир итте. Кылыгыз бер-бер хәл, оланнар, коткарыгыз мәликә бикәбезне вә аның кызы Сөмбелне.

— Мелла Хакимҗан, нигә син бик борынгыдан башладың әле? Мин синнән, бүген Сүбәдәй чирүендә нинди ыру-кәвемнәр бар, дип сорадым түгелме соң?

— Җалаир, барлас, кәүчин, арлат, найман ырулары бардыр, баһадир.

— Барлас вә арлат ырулары төркиләр бугай бит?

— Төркиләр, баһадир, ләкин безгә яу килгән төркиләр, күбесенең муенында тәре — нәсариләр, мәҗүсиләр.

— Кайчанга кадәр төрки төркигә каршы сугышыр икән, мелла?

— Мелла, моннан ерак түгел бер җирдән, җир асты юлы белән калага кереп була икән. Безнең шәрәфәтле бикәбезне вә аның кызын коткарасыбыз килә. Фатихаң бирсәң икән.

— Баһадир Артык, Раббымыз әйткән: Аллаһы тәгалә иң гадел гамәл — хәрәкәт иткән гамәлдер, ә иң тугрыклысы — мөэмин-мөселманнарны дошман кулыннан азат итүдер, дип. Аллаһы тәгаләнең җиһады — тугры сүздер. Хак сүз биреп, гамәл кылган адәм генә изге юлда калыр, балалар. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим, дип уң аяктан кузгалырсыз. Игелек сезгә, балалар. Бачман баһадир кызы Сөмбел дошман ыстанында үзен егетләрчә тотты, мине коткарды. Ул балага мин торган саен хәйран калам. Барча ир-атларыбызда да ул кыздагы кыюлык, батырлык, тәвәккәллек булса, Сүбәдәй безнең тарафларга аяк басарга да куркыр иде. Ак юл сезгә, балалар. Иншалла!

Мелла Хакимҗан торды да чыгып китте. Артык егетләренә күз йөртеп чыкты.

— Мин бу йөкне бер сезгә генә йөкләмимм, оланнар. Үзем дә сезнең белән барам.

— Без әзер, баһадир, без күптән коралларны, аркан-бауларны хәзерләдек инде, — диде хан оныгы Хансөяр.

— Якшы, хан оныгы Хансөяр. Сайлап ал үзеңә биш-алты елгыр егетең. Ташбай углан, син дә барасыңмы?

— Айгөл дә бара, атам, мин дә.

— Тик озын-озак җыенмагыз, ай калыкканчы төн юлына кереп калырга кирәк. Мин сезне инеш буенда көтәрмен, оланнар.

Барысы да бергә җыелгач, Артык баһадир, миңа ияреге̂з дип, алдан китте. Артык офык читенә күз ташлады. Офыкта күк кан төсенә кергән иде. «Йа Аллаһы, Мөхәммәдән-рәсүллуллаһи, офыгыңа кадәр канга буягансың, адәмнәрнең кан коюга Син дә риза түгелсеңме әллә? Бөтен тирә-юнь кан бит инде...»

Чынлап та, хәзер генә колагына дала бүреләре улаганы ишетте, бүреләр үлгән атларны ботарлыйлар, кан исеннән исергәннәр, калкып килгән айга карап улыйлар һәм йөрәккә әллә ниткән шом салалар иде.

Килене Айгөл йөгереп килеп, алга чыкты.

— Хәзер уңга борылмак кирәк, атам.
— Якшы, син алдан бар.
Бераз баргач, Айгөл кулын күтәрде, атыннан төште.
— Атларны шунда калдырабыз. Атлар янында кем кала?
— Ташбай, син калсаң,— диде Артык һәм уңайсызлану тоеп, тамак кырды.
— Юк, унбаш Газизҗан кала,— диде Ташбай.
Төн юлын бик тиз таптылар, Айгөл аларны берәм-берәм төн юлына кертеп җибәрде. Шуннан соң үзе алга үтте һәм кисәү агачына ут салды. Аннары тәвәккәл төстә:
— Әйдәгез! — диде.
Артык килененә янә бер сокланып куйды. Алдан Айгөл бара, аңа Ташбай ияргән, алар артыннан бер тотам калмый хан онычы Хансөяр атлый. Шактый баргач кына, Айгөл кисәү агачын сүндерде һәм Хансөярне янына дәште.
— Хансөяр, бу юл туп-туры бикәнең идән астына килеп чыга. Ачар капкач нәкъ бикә ятагының сәке астына туры килә. Капкачны сак кына берьякка шуыт та чыгып тыңла, бикә беркайчан да утсыз йокламый. Ут булса да, булмаса да, мине алдан уздырып җибәрерсең. Аннан калганнарыгыз күтәрелер. Инде бикә белән Сөмбел анда икән, мин аларны үзем алып төшәрмен.
Айгөлгә капкачны ачты, Хансөяр һәм аны алдан уздырып җибәрде. Айгөл сәке астыннан чыкты, колак салды. Бүлмәдә тып-тын иде, ут алмаганнар. Димәк, бикә кызлар ягында. Айгөл Хансөяргә таба иелде, чыгыгыз, дип ишарә ясады. Тәрәзәдән ай яктысы төшә, караңгыда күз өйрәнә төшкәч, кайбер әйберләр төсмерләнә башлады. Ниһаять, барысы да сәке астыннан мүкәләп чыктылар. Айгөл егетләргә чаршау артына посарга ымлады, ә баһадирны һәм Ташбайны ияртеп, ишекъяры килде. Шуннан соң гына Хансөярне дәшеп алды һәм әкрен генә ишекне ачарга кушты.
— Безгә кызлар ягына зур гына аралык аша үтәсе, ә анда тәхет ягы ишегендә һәрчак сакчы тора иде. Нишлибез?
— Мин алдан чыгам,— диде хан онычы Хансөяр һәм, аяк очларына гына басып, ишекне ачты. Үзе чыкты да ишек пәрдәсе артына качты. Кинәт тәхет ягында ыгы-зыгы купты. Кемдер:
— Ул минем хатыным! — дип кычкырды.
Бу ни хәл бу? Артык түзмәде, хан онычы Хансөяр янына чыгып басты һәм пышылдап кына:
— Бар әле, карап кил,— диде.
Хәнҗәрен кулына тоткан килеш, аяк очларына гына баса-баса, Хансөяр тәхет бүлмәсенә таба атлады. Һәм ишек янына җиткәч, туктап калды. Баягы тавыш тагын ишетелде:
— Мин аңа өйләндем. Безгә никах укыдылар. Ә ул минем ягыма да керми. Алып керегез!
Кемдер ишеккә таба килә башлады, хан онычы Хансөяр диварга сыенды. Аралыкта бары тик тәхет ишеге янында гына ут яна, ләкин ул күләгәрәк якта.
«Тәхет ягында кем? Кемгә минем хатыным?» — дип кычкырды, һич аңламалы түгел иде. Шулчак ишек ачылып китте һәм анда бер кишектин күренде. Хан онычы Хансөяр аның борылганын гына көтте дә аркасына хәнҗәрен батырды. Адәм аһ! дип тә кычкыра алмады, ишелеп төште. Хан онычы Хансөяр аны бер читкә тартып куйды һәм тәхет ягына керде. Артык баһадир аның янына килеп баскан иде инде. Әллә тагын түшәмнән төштеләр, Хансөярнең кулыннан хәнҗәрен тибеп очырдылар һәм аның алдында ике кишектин пәйда булды. Артык чаршау артына посты. Кишектиннәрнең берсе Хансөярнең артына чыкты, Артык пәрдәне эшереп кенә җибәрде дә кишектиннең аркасына хәнҗәр кадады. Моны күреп

алган кишектин тәрәзәгә ташланды, әмма барып житә алмады. Артык аның аркасына хәнҗәрен ыргытты. Кишектин кинәт сөрлегеп куйды да чалкан төште. Иң сәере шул булды, тәхеттә кап-корсаклы бер нойон утыра иде. Ул Артык белән Хансөярне күрде дә гелән өнсез калды.

— Авызына чүпрәк тык. Тавыш чыгармасын.

Хансөяр аның янына килде, идәннән күтәргән хәнҗәрен бугазына терәде.

— Бикә кайда, кызы кайда?

Нойон әллә чынлап та өнсез калган иде, ымлап кына кызлар ягына күрсәтте. Ул арада Ташбай килеп керде, аның артыннан ук Айгөл.

— Ташбай углан, бәйлә үзен, авызын томала. Әйдәгез кызлар ягына.

Кызлар ягының ишегендә ике сакчы тора. Артык егетләренә, сабыр итегез, дип кул күтәрде. Хан онығы шундук сизеп алды һәм кире тәхет бүлмәсенә йөгерде. Ул тиз генә кишектиннең өс киемен, башлыгын салдырып алды, киде, борылып килде. Артык аны күрде дә хуплап ияк какты. Хансөяр алдан атлады. Ике кулына ике хәнҗәр алды. Сакчыларга житкәч, ул баш иде, кинәт ишеккә таба борылды, сакчылар аркылы төшмәкче иткәннәр иде — икесенең дә корсагына хәнҗәр тыкты. Йөгереп Артык килде, калганнары аңа ияргәннәр. Кызлар ягына беренче булып Артык килеп керде. Керүе булды, аның башына тондырдылар, ул исәнгерәп берьякка ауды. Аның артында басып торган Хансөяр баһадирга тәпәч белән суккан кишектиннең йөзенә йолдыз атты. Теге йөзен каплады да чүгәләде, ләкин икенче берсе Хансөяргә кылыч белән ормакчы итте. Хансөяр чак кына читкә тайпылып өлгерде. Ул арада Ташбай һәм аның егетләре кызлар ягына килеп тулдылар. Айгөл баһадирның башын күтәрде, битенә суккалады. Артык күзләрен ачты. Кызлар ягында каты орыш башланды. Бер кишектин жиде кешегә каршы тора иде. Ул әллә кайчан инде кылычын югалткан — бәреп төшергәннәр, әмма аткан хәнҗәр, нә йолдыз үзенә тими, кай арададыр, күз ачып йомганчы читкә тайпылып өлгерә. Хан онығы Хансөярнең ике егете берчиттә исәнгерәп яталар. Ташбай биленнән нечкә кыл бау алып маташа, ә Хансөяр белән тагын ике елгыр егет кишектинне почмакка кысмакчы булалар. Ләкин кишектин әле мәче кебек сикереп чыга, әле якын килгән берсен тибеп очыра. Шунда хан онығы Хансөяр тәрәзәдәге пәрдәне йолкып алды, Ташбайга унгарак тайпылырга дип ым какты. Хан онығы пәрдәне төрде дә кишектин өстенә ташлады, шул ук мәлдә Ташбай аркан элмәген җайлады. Пәрдәдән котылырга теләп, кишектин гәүдәсен сулга алды, шулчак Ташбай аңа элмәкле аркан ташлады һәм кишектинне тартып екты. Өченче бер егет аның корсагына кылыч белән кадады.

— Бикә кайда? — дип сорады хан онығы Хансөяр, егетләрдән битәр үзеннән.

— Ятак ягындалардыр, ятак ягында, — дип кычкырды Айгөл.

Ул һаман Артыкның башыннан тоткан, баһадир торырга итә, алар янына Ташбай йөгереп килде, атасын күтәреп алды һәм түр яктагы сәкегә салды.

— Ни булды, атам?

— Исәңгерәтте, мәлгунь. Хәзер үтәр.

Бу вакытта хан онығы Хансөяр ятак ягына кергән иде инде. Ул килеп керүгә, Сөмбел чырыйлап кычкырып җибәрде. Хансөяр ялт итеп сул якка карады, чөнки күзенә ниндидер күләгә чалынган кебек булды. Һәм шулай да икән. Ул бар көченә уң якка сикерде һәм сәке янына ук килеп төште, аның артыннан ук аяк очына сөңге килеп кадалды. Тора-тора ук Хансөяр кишектингә хәнҗәр ташлады, ләкин теге читкә тайпылып өлгерде. Һәм әкрен генә Хансөяргә таба килә башлады. Кулында һични юк, ә кыю килә, димәк, көченә ышана. Хансөяр аңа сукмакчы итте, ләкин кишектин аның кулыннан эләктереп алды һәм идәнгә орды. Шулчак ишектә Ташбай күренде һәм тагын ике егет. Кишектин аларга таба китте, яман итеп

кычкырды да берсенең күкрәгенә, икенчесенең эченә типте, егетләр бөгелешеп төштеләр. Ләкин исән калганы баш аша сикереп, кишектиннең артына чыкты һәм касыгына типте, бермәлгә генә кишектин сыгылып алды, шул чак хан оныгы Хансөяр айныды, ул кишектиннең янәшәсендә генә аягын күреп, каты итеп чәркәсенә типте һәм биленнән хәнҗәрен алып, күкрәгенә кадады. Түр якка барып поскан бикә белән Сөмбел аның янына йөгереп керделәр, икесе дә кочтылар да еларга тотындылар.

— Тиз җыеныгыз, китәбез. Җыеныгыз. Айгөл, Ташбайны кара.— Хан оныгы Хансөярнең күзе түр якта сәкедә яткан берәүгә төште.— Бу кем? Кем анда ята?..

— Сүбәдәй баһадир угланы Күлкән,— диде бикә.

— Күлкән, баһадир угланы?! — дип гаҗәпләнде Хансөяр.

— Тимә аңа, Хансөяр,— диде Сөмбел.— Тимә. Ул авыру.

— Яхшы, калсын. Киттек. Ташбай, Ташбай. Син исән. Тор. Тор-тор. Китәбез. Егетләрне алабыз. Тизрәк. Килеп керүләре бар.

Ике егетләре үлгән булып чыкты. Ләкин аларны барыбер калдырмадылар. Артык баһадир көч-хәл белән булса да үз аягы белән атлады, Ташбайның да хәле начар иде, аны Айгөл тотып барды. Бикәнең ятак бүлмәсендә Сөмбел Хансөярнең түшенә капланды һәм үксеп-үксеп еларга тотынды.

— Йә, тынычлан, Сөмбелем, тынычлан. Әнием, тынычландыр әле үзен.

Акбикә кызын култыклап алды, иңеннән кочты һәм юата башлады. Берәм-берәм төн юлына төштеләр. Барысы да чыгып беткәч кенә, хан оныгы Хансөяр сөйгәне Сөмбелне күкрәгенә кысып, күз яше белән елап җибәрде. Аны берәү дә юатмады, берәү дә тыймады. Аның ни өчен елавын Сөмбелдән башка берәү дә аңламады.

## 34

Бикәнең югалуы, Кадан нойонның мәсхәрә ителүе, елгыр яугир Җүзәкәйнең үтерелүе Сүбәдәйне чыгырыннан чыгарды. Ошбу яман хәбәр ирешүгә, ул, башына да кияргә онытып, сарайга чапты һәм беренче очраган кишектиненә бикә белән кызын эзләп табарга кушты. Баш киемсез, моның өстенә төсе-йөзе алышынган, җитмәсә сукыр күзенең чүпрәге булмаган баһадирны күреп, кишектиннәр генә түгел, юртачылар, җыештыручылар, каравыл торучылар да ни кылырга белми өтәләнә башладылар. Миркет, туба, кыргыз, каньк, карлукъ кавемнәреннән җыелган бу халык кыпчакларны яратып бетермиләр, аларның Сүбәдәй кадәр Сүбәдәй баһадирларына каршы торуларына гаҗәпләнәләр, чөнки магулларны җиңәрлек, аларга каршы торырлык көч юк дип уйлыйлар иде. Ир-атлары баш бирмәү бер хәл, хатын-кызлары качып киткәннәр бит әле. Алар тарафында хатын-кыз ир-атка «Әйе», «Ярый» дип кенә тора — каршы әйтү дигән нәрсә юк. Ә монда бикә кадәр бикә әллә ниткән юллар белән баһадирның иң елгыр йөзбашы Җүзәкәйдән качып киткән, ул гынамы, Җүзәкәй үзе дә һәлак ителгән, бикә белән кызын саклаган кишектиннәре дә. Бу хәлгә чынлап та шаккатмаслык түгел иде. Сүбәдәй баһадир сарай болдырына ике сикерүдә менде, каерып ишекне ачты, эчкәре узды. Аның артыннан йөзбашы Бүртә, аның кишектиннәре тагылды. Аратада ук ике сакчының бөкшәеп ятуларын күреп, йөзен чытты, мәетләрне алып чыгыгыз, дип әмер бирде һәм кызлар бүлмәсенә ашыкты. Ләкин монда да куанычлы күренешкә тап булмады, ишекъяры ике мәет ята, эчкә керсә, янә коты алынды — идән уртасында елгыр кишектине ята иде, хәтта корсагына кадалган кылычы да тора. Сүбәдәй ятак ягына атлады, ишекне ачты, йөрәгенең ярсынып тибүен тоеп, бертын түр яктагы сәкегә карап торды, аннан угланы

зәгыйфь тавыш белән: «Атам!» — дигәч кенә, исенә килеп, йөгереп сәке янына килде, угланы өстенә капланды да тынып калды.

— Син исән, сиңа тимәгәннәр, олан, тимәгәннәр! — дип кабатлады ул гасабиланып.

— Атам, атам, алар Сөмбелне алып киттеләр, Сөмбелне. Ә ул бикәнең кызы булган икән, атам!

— Нәрсә? Бикәнең кызы?! Шул кызыймы?!

— Сөмбел Бачман баһадир белән бикәнең кызы, атам. Мин аны яратам, таптыр син аны, атам, таптыр.

Күлкәннең калтыравык тавышы, җан ачысы белән әйткән сүзләре Сүбәдәйнең ачуын гына кабартты. Кыз өчен ул аны орышып ташлаган да булыр иде, аның Бачман баһадир кызы икәнен белгәч, ни әйтергә аптырады, өнсез калды. Әнә кем килеп эләккән булган икән бит аның кулына. Ул кыз хәзер аның кулында булса, Бачман баһадир белән уйный белер иде. Әйе, тик менә нигә Күлкән углан ул кыз өчен өзгәләнә? Аннары табиб кая, кем карый угланны?

— Табиб кайда, углан?

— Мин аны гаиләсенә кайтарып җибәрдем, атам. Ул килер, киләм, диде.

— Килмәс ул, углан. Чөнки ул Бачман баһадир табибе иде. Мин сиңа үз табибымны җибәрәм. Ә синең ул табибың качкан булса, мин аны табармын...

— Аның гаебе юк, атам. Ул мине яхшы карады.

— Качкан булса, дим. Качмаган булса, яшәсен. Хәлең ничек соң, углан? Нигә болай озак ятасың, яраң да авыр түгел кебек?

Күлкән зәгыйфь кенә кулын күкрәк турына куйды, дәшмәде.

— Минем өметем өзделәр, атам. Сөмбелемне алып киттеләр.

— Мин сиңа ул кыздан да гүзәлрәкне табармын, углан.

— Миңа бүтән берәү дә кирәкми, атам. Миңа Сөмбел генә кирәк. Мин аны гына яратам.

Бу юлы Сүбәдәй дәшмәде, торды да әкрен генә ишеккә таба кузгалды. Ул да кайчандыр Карлыгачын шулай яраткан иде, әйе, шулай ук булмаса да аннан башка берәүне дә күрмәде. Ул белә хәзер, Карлыгачы Болгарда, угланы Ташбай да. Язганмы Тәңре аңа аларны күрергә, язмаганмы — Сүбәдәй белми иде, ләкин күңел түрендә һәрчак очрашу өмете яши.

Сүбәдәй аралыкка чыкты, тәхет бүлмәсенә таба китте. Анда тагы да хәтәррәк сурәт көткән икән. Тәхет янына берәү дә керергә кыймаган, хәер, үзе шулай тәрбияләде кишектиннәрен: кая гына булмасын, нинди җиргә генә кермәсеннәр, әүвәл үзе аяк басарга тиеш.

Ишекне каерып ачты, керде. Тәхет янында бер мәет тәгәрәп ята, ишекъяры берсе чалкан төшкән, кулларын җәйгән, әйтерсең лә яр өстенә ташланган бака. Тәхеттә авызына чүпрәк тыгылган, нечкә кыл бау белән куллары — терәкләргә, аякларын урындык аякларына бәйләнгән Кадан нойон утыра. Аның башы берьякка салынган, күзләре акайган. Сүбәдәй тәхет янына килде, Кадан нойонга кагылмакчы итте, әмма кулын шундук тартып алды. Ул исән кебек иде әле. Артына әйләнеп карамый гына:

— Чишегез үзен, алыгыз авызыннан чүпрәген,— диде.

Кул-аякларын чишеп, авызыннан чүпрәген алгач, Кадан нойонны тәхеттән алып, идәнгә сузып салдылар.

— Табибны чакырыгыз! — дип боерды Сүбәдәй.

Табиб килде, мәеткә иелде, яңакларына суккалады, авызына күзгә куеп карады, аннары нойонның күзләрен йомдырды да торып басты.

— Ул яңадан якты дөньяга әйләнеп кайтмас, баһадир. Җир куйнына озатырга кирәк.

Сүбәдәй күзен дә алмый Кадан нойонга карап торды. «Ике көн элек кенә Кадан нойонның биргән агудан үлмәвенә гаҗәпләнгән иде, тәкъдире

ерак булмаган икән — үзе үк эзләп тапкан», — дип уйлады Сүбәдәй. Кичә иртән-иртүк, берни булмаган кебек Сүбәдәй юртасына нойон Кадан килеп кергәч, чак кына аягүрә торып басмаган иде Сүбәдәй, чөнки аңа ким куйганда атка бирә торган агу эчергән иде табиб, һәрхәлдә, аңа шулай диде. Ә нойон таштай-тукмактай аның каршында басып тора. Шул ук кап-корсагы, шул ук кабак йөзенә ябышкан чикләвек чаклы гына борыны.

— Син миңа бикәне кияүгә бирергә, тархан итәргә ышандырган идең, баһадир. Атамыз Чыңгыз хан әйткән сүзендә тора торган булган, ә син аның корыч баһадиры...

— Булыр, булыр, нойон. Сарайга кер, тәхеткә утыр. Әйе, бүген үк утыра аласың. Никах укытырсың да бикә дә синеке булыр.

Шуннан соң берсүз әйтми, Кадан нойон чыгып китте. Сүбәдәй аны өенә, ягъни гаиләсенә кайтып китте дип уйлаган иде, ә ул, чыннан да, монда кереп, тәхеткә утырган, кишектиннәрдән бикәне таптыра башлаган, хәтта никах укырга мулла чакырырга кушкан. Сүбәдәй баһадирлары боерыгын алмыйча һични кылырга өйрәнмәгән кишектиннәре аңа колак та салмаганнар, әллә бар нойон Кадан, әллә юк алар өчен. Шуннан нойон арак соратып алган, анысын биргәннәр. Эчкән, җырлый башлаган һәм бераздан тагын, мулла белән бикәне китерегез, дип кишектиннәрнең җаннарына тияргә тотынган. Бәлкем, бик теңкәләренә тия башлагач, кишектиннәре Сүбәдәйгә килгән дә булырлар иде, ләкин кишектиннәр башында торган йөзбаш Җүзәкәй аңа колак та салмаган. Ә бикә белән кызны сакларга иң ышанычлы кишектиннәре белән йөзбашы Җүзәкәйне куйган иде Сүбәдәй. Барысы да һәлак булганнар...

— Нойонны, һәлак булган кишектиннәрне далага чыгарып күмегез дә өч тапкыр көтү уздырыгыз, — диде Сүбәдәй һәм чыгу юлына борылды.

Юртасына кайткач, ул күз чүпрәген табып алды, бәйләде, сорап алып, җылымса яңа суйган каз канын озаклап эчте.

Юртага меңбаш Котбый керде.

— Ишеттеңме, Котбый? — диде Сүбәдәй, мендәргә кырын төшеп.

— Без Аллаһы тәгаләгә каршы гамәл кылдык, баһадир. Безне Аллаһы тәгалә каһәрләде. Мөселман диненең кануннарын белмәгән надан вә гафил нойон бикә кадәр бикәгә өйләнергә маташкан. Әлифне таяк дип белмәгән адәм ич.

— Ул юк инде, Котбый, куеп тор. Мин синең Аллаңа рәхмәтле, мелла меңбашым, әйе, рәхмәтле. Мине зур бәладән коткарды. Нойон Кадан Чыңгыз нәселеннән, кайткач әллә ниләр сөйләп йөрер иде. Ә синең Аллаң аны үз янына алды.

— Йа Раббым, гөнаһларым булса, ярлыкый күр, — диде Котбый.

— Куй син аны, меңбаш, куй. Сине углан көтә. Шәптән түгел аның хәле, меллам, шәптән түгел. Авыруы да юк кебек, ярасы җөйләнгән, тәне таза, ә эчтән һаман сызлана.

— Гашыйк ул, баһадир. Сырхау дәрәҗәсенә житеп гашыйк. Ул кызны күз алдында күрмичә, аякка басуы шикле аның, баһадирым.

— Юк, мелла, аны йә сихерләделәр, йә аңа зәхмәт кагылган, йә ук агулы булган.

— Ук агулы булмаган, табиб тикшерде.

— Димәк, зәхмәт кагылган. Шаманны дәш, кусын җеннәрен.

Котбый дәшмәде, чөнки Сүбәдәй шаманына күбрәк ышана иде.

— Угланны тынычландыра алса, рәхим итсен, баһадир.

Котбый белә иде угланның чирен — гашыйк ул бала, гашыйк. Аңа бернинди мулла да, шаман да, табиб та кирәкми, аңа Бачман кызы Сөмбел кирәк. Авыр тойгы-кичерешләре, җан ачысы, сагышы бары тик шуннан. Әмма Сүбәдәй баһадир әйткәч, шаманны да җибәрми булмас. Йа Хода, Аллаһы тәгалә биргән дәрманны шаманнан өшкереп кенә бетереп булса икән ул! Ходай аны барыбер кабул итмәс, углан шулай ук

сырхаулар, раббыбыз каршында бәндәнең сихәтләндерү өчен углан гашыйк булган кызны килтерү лазем дә бит, бер кулына төшергән Бачман баһадир бикә белән кызын күз карасы итеп саклар. Иншалла, углан терелер, бер-бер җае чыгар, җаны тынычланыр. Угланның күнел шифасы, җан ачкычы Бачман баһадир кулында хәзер, Сүбәдәй. Бик ихтимал, калаң ташлап китсәң, ул сиңа кызын бирер. Тик белмим, синнән курка торган баһадир түгел шул ул, баш бирмәс, кызын бирү генә түгел, тынгылык бирми башлар. Ә без синең белән калада бикләнеп утырырга өйрәнмәгән. Мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек җитми сиңа, корыч баһадир. Шул сыйфаттан мәхрүм син, шуңа сине Аллаһы тәгалә торып-торып кыен хәлләргә куя. Әнә тагын иң ышанычлы йөзбаш кишектинең далага чыгарып күмдердең. Нәүбәттә кем? Угланың?.. Болай кул кушырып калада ятсаң, кыпчак-болгар сиңа тынгылык бирмәс, чөнки алар туган җәйләүләрендә, ә без килмешәкләр, җәйләү-елгалар өчен генә түгел, табигате өчен дә килмешәкләр.

Котбый мењбаш, шулай дип уйласа да, шаманны барыбер углан янына җибәрде һәм сарайны сакларга үз кишектиннәрен куйды. Тән сихәтлеге — якты күк йөзедер, дигән иде аңа беркөнне табиб. Капкорсак нойоннарны күргәч, шулай диде. Бу адәмнәр күп тә үтми бирән чиреннән китәрләр, аларны илаһи җир үз куенына алыр, чөнки хәрамга хирыс кешеләрдер, ризыкның кадерен белмиләр, тыгынганчы ашыйлар, сыгына-сыгына капкан калҗалары кире килгәнче туктамыйлар. Ә бит табиб хаклы. Аллаһы тәгалә, Ай, Кояш, Йолдызлар хасиятләрен белмиләр, кара көчләргә йөз тоталар. Синең ул халыкка алып килгән рухи ризыгын камил вә үтемле булмаса, ул халыкны кылыч белән генә җиңеп булмый, ул барыбер гасырлар үткәч булса да гафилләрдән йөз чөерер. Ә гафиллек магулларда көттәдер. Котбый мелла аларны изге юлга салырга алынды, иллә торган саен өметсезләнә, торган саен өмете өзелә. Хәерлегә булсын.

Котбый меңбаш шаман юртасына үтте, сөяк кимереп утырган котсыз йөзне углан янына барырга, углан бүлмәсенә ияләшкән шайтаннарны куарга кушты. Шаман бик тиз риза булды, җыена да башлады.

— Тик углан алай-болай зарлана башласа, борыл да чыгып кит, тенкәсенә тимә, — диде ул шаманны сарайга таба озатканда.

Шулвакыт аны тагын Сүбәдәй баһадир үз чатырына чакыртып алды.

— Утыр әле, Котбый, утыр. Син миңа киңәш ит, ары таба нә кылыйм.

— Хәрәкәт ит, баһадир. Туктаган атның аягына солы төшә.

— Ә кала белән нишлим?

— Безгә сәүдә юлын җайга салырга, калага ипле тархан табарга кирәк булыр.

— Син хаклы, Котбый меллам, хаклы. Заманында Чыңгыз атамыз тикмәгә генә мөселман имамы Мәхмүд Ялавачны уң кулында утыртмагандыр.

— Ник чакырткан идең соң, баһадир?

— Бар син углан янына, Котбый. Нигәдер ул шаманны куып җибәрепп, сине чакырырга кушкан. Юат баланы, өшкер, доган укы. Шифан тисә, каланың имамы итәм.

— Каланың имамы бар, баһадир. Тимик аңа, юкса яман бетүе бар. Халык монда диндардыр.

Котбый чыгып киткәч, Сүбәдәй тәхет ягында аунап яткан кишектинне күз алдына китерде. Бака кебек кул-аягын җәеп ята иде. Димәк, кемдер шундаен иттереп күтәреп орган ки, эчендәге әгъзалары өзелгәндер. Авыз читеннән агып чыккан канны күргәч, гомер булмаганны Сүбәдәй йөзен чөергән иде. Кадан нойонны исә нечкә генә кыл аркан белән урындыкка бәйләгәннәр. Аркан нечкә дә түгел, калын да түгел, кулга уңай. «Корык ясарга менә нинди бау кирәк», — дип уйлады Сүбәдәй һәм кишектиненә тәхет ягындагы Кадан нойонны бәйләгән кыл бауны алып килергә

кушты. Кишектине бауны китереп биргәч, ул бик озак нечкә арканга карап торды, сүткәндәй итте. Иң эчтә чи каеш икән, каешны сүс белән катыштырып ишкәннәр, аннары кыл уздырганнар. Менә ни өчен нык икән бу кыпчакларның баулары...

Кишектинен дәште, бау ишүчеләр унбашын алып килергә кушты. Күп тә үтми юртага уртача буйлы, төп кебек юан гәүдәле, тоз күзле, җирән сакаллы бау ишүчеләр остасы килеп керде.

— Кавемең? — дип сорады Сүбәдәй.

— Тохар, баһадир. Барласларга күрше күк төркиләр, борын заманда безнең бабаларымызны шулай атаганнар.

«Тагын төркиләр. Әйе, юкка гына йөртмим икән шул Котбый мелланы», — дип уйлады Сүбәдәй үз-үзеннән канәгать калып.

— Син миңа менә шушы бауның серен ачып бир. Атың кем?

— Киндербәк атлы мин, баһадир, — диде җирән сакал.

Бау ишүче оста арканны сүтеп карады, тешләде, муенына ышкыды, ахыр аягына элмәк итеп элде дә бар көченә тартты. Аркан сузылмады да, өзелмәде дә.

— Йә, ничек?

— Кыпчаклар гомер-гомергә оста бау ишүче булдылар, баһадир.

— Каладагы бөтен бау ишүчеләрне җый да минем чирүемә шундый арканнар иштер. Бәһасеннән тормам. Аңладың?

— Баш өсте, баһадир...

Юртага ышанычлы кишектиннәре килеп тулдылар.

— Нә булды?

— Баһадир, без төн юлын таптык.

— Нинди төн юлы?

— Бикәнең йокы бүлмәсендәге сәке астында капкач бар, шуны ачып, төн юлы аша далага чыгып була икән, инешкә кадәр җитә.

— Кем тапты?

— Мин, баһадир.

«Менә син булырсың да Җүзәкәй урынына йөзбаш, — дип уйлады Сүбәдәй. — Ләкин башта бер шартым үтәрсең. Миңа углан Күлкән гашыйк булган Бачман баһадир кызын урлап алып кайтырсың».

— Тыңла мине, яугир. Мин сине бүгеннән... Атың ничек?

— Тәкә Тимер, баһадир.

— Йөзбаш Тәкә Тимер, — диде ашыкмый гына Сүбәдәй. — Йөзбаш!

Кишектин шундук баһадир аягына сыгынды, маңгаен итегенә терәде.

— Йөзбаш Тәкә Тимер, үзеңә елгыр яугир егетләр сайла. Аннары бире кил. Мин сезне бер кызны урларга җибәрәм.

— Мин аны беләм, углан Күлкән сатып алган кыз ул! — диде кишектин.

— Ашыкма, йөзбаш, ашыгып куян куалар, ә мин сезне Бачман баһадир кызын урларга җибәрәм. Бер айны, ике айны йөрерсез, тик кызны урламый кайтмагыз. — Сүбәдәй казнабашын чакыртты һәм һәр кишектингә унар бәлеш акча бирергә кушты. — Акча бездән, азык-төлекне үзегез табасыз. Ак юл сезгә, кишектиннәр!

## 35

Саксинга килгәч кенә белде Сүбәдәй: кыпчак-болгарларның хатын-кызлары сәяси вә хәрби эшләргә дә катнашалар, хәтта орышларда да күренгәлиләр икән... Бу хәлгә ышанырга да була иде: күптән түгел, углан Күлкән гашыйк булган кызы сәүдәгәр сурәтендә Сүбәдәй ыстанына үтеп керә, җитмәсә угланны үзенә гашыйк итә. Бу халыкның хатын-кызларында, үз тарафларындагы хатын-кызлардагы кебек, илаһи нур балкып тора. Чыңгыз ханның атасы Йүзәкәй баһадир да, Чыңгыз үзе

дә татар хатыннарына өйләнделәр, хәтта Сүбәдәй баһадир да татар халкының хатын-кызларыннан арына алмады, өйләнгән булса да Карлыгачны очратты һәм шундаен гашыйк булды ки, әле булса күз алдына килгән саен йөрәге кысылып куя. Ә менә магул хатын-кызлары ир-атның сәясәте, хәрби эшләре белән бөтенләй кызыксынмыйлар. Шул сәбәпле гомер буена орыш-сугыш дип авыз суын корыткан, яудан кайтмаган магул ирләре белән хатыннар арасында рухи якынлык юк, ирләре өчен, орыш кырында ятып калса да, ул хәтле уфтанмыйлар, һәлак булган икән, дип елашмыйлар, бер дә икеләнмичә, күндәм рәвештә йә иренең энесенә, йә агасына кияүгә чыгалар. Әмма кыпчак-болгар хатын-кызлары ир югалтуны бик авыр кичерәләр, ул гынамы, өч көн үткәч бер, җиде көн үткәч икенче, кырык көн үткәч өченче, елы үткәч дүртенче тапкыр мәрхүмне бергәләп, искә алу гадәте бар. Каян килә ошбу халыкның хатыннарына мондый тугрылык — Сүбәдәй белми иде. Бит унтугыз язын тутырып, Күлкән углан да ил-җәйләүдә берәүгә дә күз тутырып карамады, гүя хатын-кыз аның өчен юк иде. Хәер, Сүбәдәй үзе дә бик соңгарып кына өйләнде, шуңа угланның кыланышына шаккатмады. Киресенчә, үземә охшаган, дип кинәнде. Ә менә монда килгәч, кыпчак кызын күрде дә капланды, хәзер әнә чиргә сабышып ята, әллә чын, әллә юри, бер Тәңре белә. Хак, Бачман баһадир кызы Сүбәдәйгә дә ошады, Сүбәдәй дә яратты кызны. Тик ул чакта аның Бачман баһадир кызы икәнен генә белмәде. Хәер, белгән булса нә кыласын да үз-үзенә аңлата алмас иде, әмма иманы камил, кулыннан ычкындырмас иде. Чөнки ошбу кыз ике арада сәяси мәсьәләләрне хәл итү мәслеген уйнаячак иде. Әйтик, Күлкән угланны Сөмбелгә өйләндерер иде дә кала түрәсе итеп калдырыр, ә үзе Бачман баһадир белән берләшеп, Болгарга яу йөрер иде. Килешер иде Бачман баһадир, кабиләләрне берләштергәндә Чыңгыз хан да төрле чаралар кулланды. Берсенең кызына өйләнде, икенчесенең кызын энесенә алды.

Сүбәдәй касәдәге кымызга үрелде, эчте, касәне янә кечкенә өстәлчеккә куйды. Хикмәт, Карлыгач шушы өстәл янына утырып, вак-вак кына уртлап, кымыз эчеп утырырга яратыр иде. Карлыгач янында ул Сөябелен гелән онытыр иде, әйтерсең лә аның туган җәйләвендә хатыны да, баласы да калмаган иде. Юк, Сөябел аны барыбер яратмады. Яуга киткәндә ичмасам бер тапкыр да озатырга килмәде, Карлыгач булса, өзәңгесенә тотынып басу капкасына кадәр барыр иде. Шулай да Сөябелгә өйләнгән өчен беркайчан да үкенү тоймады Сүбәдәй. Ул аны әнә шул кирелеге өчен яратты. Сүбәдәйнең һәрчак яуга китәсе килде, ә Сөябел аны теше-тырнагы белән җибәрмәскә тырышты. Ә менә Карлыгач булса нишләр иде икән? Җибәрер иде микән яуга, җибәрмәс идеме?.. Тукта-тукта, соң аны бирге тарафларга Карлыгачы тартып китермәдеме? Ник соң әле Сүбәдәй Үгәдәй ханга кирә-кирә ялварды. Теңкәсенә тиеп бетте. Имеш, аның яуламаган илләре калды, имеш, ул җәйләүләрнең үләннәре билдән. Анда байлыкның чиге-чамасы юктыр, дип үгетләде, хәтта олуг ханның үзен чакырды. Ил-җәйләүдә Сөябелен кочканда кочагында Карлыгачын күреп: «Әллә акылдан язам инде?» — дип үз-үзенә шаккатмады мыни?! Булды андый хәл, булды. Чөнки янында Сөябеле, ә күңеле Карлыгач белән мөлдерәп тулган булыр иде. Менә ул, ниһаять, Карлыгачы калган илгә килеп җитте, кул гына сузасы да... Тик беренче орышта ук шактый яугирләрен югалтты. Беренче вә икенче тапкырдагы кебек, кыпчак-болгарлар аны янә таныргa теләмиләр. Ул төрле хәйләләр корырга, орыштан йөз чөяргә мәҗбүр. Тик кайчанга кадәр болай тик ятырсың?! Котбый мелла сиңа хәрәкәттә — бәрәкәт, димәдеме?.. Каладан чыгарга, сугышырга кирәк. Сугышырга һәм Бачман баһадирны җиңәргә. Сүбәдәй өчен башка юл юктыр.

Ни өчен Бачман баһадир калага һөҗүм итмәде, ни өчен кулына бикәсе вә кызы төшүгә, Идел буйлап Болгарга юнәлде — берәү дә аңардан сорарга кыймады, хәтта Артык баһадир да. Шулай ук җиһангир илтабарның Сүбәдәй баһадирдан куркуы идеме, әллә бер-бер башка уе бар идеме?

Бу сорау бер Артыкны гына борчымый, мөгаен һәр азамат егет, һәр унбаш, йөзбаш, меңбашны борчый иде бу хәл. Хан оныгы Хансөяр дә, Ташбай да, Юлдаш та, төмәнбашлар Сөләйман һәм Арыслан бәкләр дә баһадирның бу кыланышын аңлый алмадылар. Бикәсе белән кызы үз кулына төшкәч, Бачман баһадир барлык илтабарларын чатырына чакырды һәм аксакалларына сүз бирде. Тегеләр исә карлыккан тавышлары белән: «Күчеп китәмез, Сүбәдәй безгә барыбер көн бирмәс»,— дип утырдылар.

Бачман баһадир тарафыннан зур югалту иде бу. Кала кадәр калаң дошман кулына калдырып кит инде. Ләкин хәтта шунда да аксакалларга каршы әйтүче табылмады, Бачман баһадир бикәсе белән бергә картларга ияк кагып, алар белән килешеп утырды. Кыш айлары, йә булмаса яман көзге айлар булса бер хәл, җәй уртасы ич, далада ачык һавада торырга була. Дөрес, меңләгән сугышчыларны ашату-эчерү бик тиз куркыныч фаҗигагә вә афәткә әверелеп китүе бар, ләкин бит иртәгә үк һөҗүм итәргә мөмкин. Ләкин Бачман баһадир барыбер үзенчә эшләде, икенче көнне иртән-иртүк гаскәренә Болгарга таба кузгалырга әмер бирде.

Бары тик бер көнлек юл киткәннән соң, Иделне кичеп уң як ярга чыгып, өч көн юл баргач кына, Бачман баһадир Илһам ханга чаптарын җибәрде. Анда да бикәсе белән генә киңәште, һич берәүгә бер сүз дә әйтмәде. Чаптары мондый хат алып киткән иде: **«Мин хан иям, калам югалттым, сәнең ил-җәйләвеңә ыстан туктадым. Ошбу җирдә миңа кала корырга фатиха бирсәң иде. Бачман баһадирың».**

Магулларның көч-гайрәтен ишетә торып, һәммә нәрсәдән хәбәрдар булган Илһам хан баһадирга ыстан туктаган төбәккә кала корырга рөхсәт бирә һәм хат артыннан ук осталар да җибәрә. Илһам ханнан хат алгач, Бачман баһадир аксакалларын җыеп сөйләште дә тагын өч көнлек юл өскә таба күтәрелергә кирәк дигән нәтиҗәгә килде. Өч көн баргач, Идел елгасының текә яр өстенә ыстан туктады һәм меңбашларына:

— Шул төбәктә туктарбыз. Каламыз шунда корырбыз,— диде.

Барчасы да килеп җиткәч, иртәнге якта җыен җыйды, хәлләрне аңлатты. Борын-борыннан күчеп вә җәйләп йөрергә өйрәнгән халык буларак, аксакаллар да, азамат егетләр дә баһадирларына каршы килмәделәр, шул көнне үк юрталарын утырта башладылар. Шуннан соң гына Бачман баһадир үз чатырына Артык баһадирны чакырып алды һәм аңа, Болгарга кайтып китәргә мөмкин, диде. Ләкин Артык баһадир аның тупчылар янына чыгуын сорады һәм, без биредән, Илһам ханнан рөхсәт килмичә, беркая да китмибез, дип җавап бирде. Баһадир янәшәсендә утырган бикәсенә карады, тегесе килешеп ияк каккач кына:

— Ярый, баһадир, чыгармын,— диде.

Тупчылар каршына ул бикәсе белән бергә чыкты. Ләкин баһадир нотык әйтергә җыенганны күреп, аның тирәсенә бөтен халык җыелды. Бачман баһадир арбага менеп басты, бикәсен үз янына тартып алды. Халыкка күз йөртеп чыкты.

— Бисмил-ләһир-рахмәнир-рахим! Газиз кардәшләрем, туганнарым вә азамат егетләрем! Без бабаларыбыз кулыннан алган һәм сакларга тиеш булган Саксин калабызны кан дошманыбыз Сүбәдәй кулына калдырырга мәҗбүр булдык. Аллаһы тәгалә ярлыкый күрсен безне. Бабаларыбыз гомер-гомергә күчеп, ыстан туктаган җиргә авыл вә кала кора

йөргәннәр. Без әле үзебезнең Саксин калабызга әйләнеп кайтырбыз. Ләкин безнең яңа гаилә корган угланнарыбыз, балаларыбыз бар. Ошбу кала аларга булыр. Олуг хан фатихасын бирде. Мәнем киявем хан оныгы Хансөяр, сөекле кызым Сөмбел калага үзләре исем тапсыннар.

— Сөмбел, Сөмбел булсын! — дип кычкырды алда торган Ташбай углан.

Аның артыннан барысы да:

— Сөмбел, Сөмбел! — дип күтәреп алдылар.

Аталарыннан ерак түгел басып торган Сөмбел ир-канатының куенына керде һәм күз яше белән елап җибәрде.

Бачман баһадир кулын күтәрде.

— Оланнар! Артык баһадир һәм Илһам хан каршы килмәсә, мин ошбу булачак калага тархан итеп хан оныгы Хансөярне, базарбаш итеп Ташбай меңбашны тәкъдим итәр идем.

— Ур-ра! Ур-ра, Ташбай базарбаш, Ташбай углан базарбаш!

Артык баһадир, куш кулын күтәреп дога укый-укый, битен сыпырды. Тик янә һични аңламады. Яңа салынасы каланы оланнарга калдырып, үзе китә баһадир, ни кылырга җыена?

Баһадирның янәшәсендә торган бикә үрелеп кенә Бачман ир-канатына нидер әйтте. Баһадир аңаияк какты. Бикә өстендә зәңгәрсу бәрхеткә көмеш тукылган камзул, башында нәкышлап чигелгән калфак. Болгари итек йөзенә җиткән бала итәкле күлмәге алсу-көрән төстә, калфак маңгаенда зур гына зөбәрҗәт таш. Киеме шәрәфәтле хатынның нурлы йөзенә нур өсти иде.

Җыен таралгач, Артык баһадир Бачман кардәше янына килде, беравык ни әйтергә белмичә гасабиланып торды.

— Үзең кай тарафка китәргә җыенасың соң, баһадир? — диде ул, ниһаять, янына килеп баскан угланы Ташбай белән килененә һәм хан оныгы иңеннән кочаклаган Сөмбелгә карап.

— Без синең белән, Артык баһадир, Илһам ханнан гаскәр алып, Саксинга таба юнәлербез. Без Сүбәдәйгә тынгы бирмәбез, ул каланы үзе үк ташлап китәргә мәҗбүр булыр!

— Каһәри, каһәри аңа, баһадир. Мин риза. Ә оланнар сезгә атакаегыздан фатиха. Корыгыз каланы. Аннары Саксинга кунакка килерсез, — дия-дия Артык әүвәл Ташбаеның иңеннән сөйде, аннары хан оныгы Хансөяр янына килде.

— Бер киңәшем сиңа, олан. Чакыр атаңны кала корырга. Чакыр, үкенмәссең. Аның кулында таш эри.

— Кәңәшегез өчен рәхмәт, атакай, — диде хан оныгы Хансөяр.

— Ә хәзер безгә игелек теләгез, оланнар, — диде Акбикә.

## 37

Ата-аналарын озаткач, яшьләр Илһам хан җибәргән осталарны көтеп, чатырларда тордылар. Бачман баһадир белән каладан чыгып, ияреп килгән халык өйләренә нигез дә сала башладылар. Берише урман кисәргә китте, берише ауга йөрде, көтү көтте. Атна дигәндә Болгардан йөзләгән ташчы килде. Һәм алар килү белән таш чыгара башладылар. Хан оныгы Хансөяр каланы күз алдына китереп, сызымнар сызып утырды. Ул, зарыгып, атасы артыннан җибәргән чаптарын көтте. Атасы Дәүран килсә, ул аңа сызымнарын күрсәтер һәм, атасы килешсә, сарай нигезен күтәрә башларлар иде. Шул ук вакытта бераз уңайсызлану да тоя иде: нигә әнисен дә чакырмады? Ярый ла үзе, мин дә барам, дисә, барам димәсә — әйбәт килеп чыкмас. Чөнки ул ата-анасыннан фатиха алмыйча өйләнгән иде. Башта бу нәрсә аның башына да килмәде, хәзер исә чаптары киткәч, ни өчендер барысын да

яңабаштан уйлады да үкенү тойды. Ташбайга әнә атасы, бер-ике атнадан анаң белән атаң көт, килеп төшәрбез, туй уздырырбыз, дип киткән. Шул хакта Сөмбелгә әйткәч, хатынының бер дә исе китмәде.

— Ә син тагын бер чаптар җибәр,— дип кенә котылды.

Икенче көнне хан оныгы Хансөяр әнисен дә чакырып, икенче чаптарын җибәрде.

## 38

Сүбәдәй атна буена каладан чыкмады. Багучы меңбашларыннан атна буена, җир астына төшеп югалгандай, эзе суынган Бачман баһадир гаскәрен эзләтте. Ары чаптылар яугирләре, бире чаптылар, ләкин берәү дә Бачман баһадирны шул чаклы гаскәр белән Идел аша чыгып китәр дип уйламады. Ә Бачман баһадир моны эздән яздыру өчен эшләгән иде. Хәер, кала Сүбәдәй кулында ич, Бачман баһадир җәһәннәмгә олакса ни. Дөрес, калага ул кереп утыруга, күп кенә сәүдәгәрләр, алыпсатарлар, базаркәләр Болгарга юл алдылар. Моңа да шаккатмады Сүбәдәй, берәүне дә тоткарламады. Кала хибесханә түгел, бикләп тотып булмый, аннары ул үзе үк булган тәртипләргә кысылмаска кушкан иде бит. Сүбәдәйнең ничек тә кала халкының күңелен күрәсе, каланы яулап алучы түгеллеген аңлатасы килә иде. Иллә нишләмәк кирәк, халыкның беришe аның хәленә керергә теләсә дә, күпчелеге аны аңламады һәм аңларга да теләмәде, гәрчә кала имамы: «Сүбәдәй баһадир безнең өскә Аллаһы тәгалә тарафыннан җибәрелгән, килешәек»,— дип хотбә әйтсә дә. Мелла Котбый кала руханилары белән сарай арасында йөрде, аның да ике араны килештерәсе килә иде. Тик менә калага сәүдәгәрләр керми башладылар, туры Болгарга юнәләләр. Туктатып борып кертсәң,— тагын, магуллар сәүдәгәрләрне тоталар икән, дигән сүз таралачак. Анда инде Саксинны бөтенләй урап йөри башларлар. Кала имамы бик тырышып, җомга намазы саен Сүбәдәйне игелекле вә шәфкатьле, ярдәмчел вә миһербанлы дип вәгазь укыса да, халык килмешәкне үз итмәде. Калага чыкса, капка тәрәзәләрен ябалар, кибет ишекләрен биклиләр. Кала имамы вәгазь укып торганда, меңбаш Мөхәли укчылары ниндидер бер кибетне талыйлар, җитмәсә бер ахмагы кибетченең хатынын көчли. Бу хәбәр килеп ирешүгә, Сүбәдәй йөзләгән кишектинен ияртеп, шул кибет хуҗасына китте. Кибет иясе бик тә диндар мөселман икән. Кибет түбәсенә менеп баскан да:

— Әгәр дә мәгәр ошбу явызларны баһадир җәзаламаса, ошбу калада иртәгә үк берәү дә калмас! Бу Саксин халкы күргән нәрсә түгел, көпәкөндез хатыным көчләделәр, кибетем таладылар...

Башта баһадир Сүбәдәй моңа бик үк игътибар итмәгән иде, кибет урамына ике яктан да халык җыела башлагач, янына Котбыйны чакыртып алды.

— Нә кылабыз?

— Шауларлар-шауларлар да таралырлар. Хәзер имам килә, мин аны алырга кеше җибәрдем,— диде, зур эш эшләгән кебек, башын чөя төшеп.

Ә кибетче түбәдән Сүбәдәйгә кычкырды:

— Аллаһы тәгалә сәнең хөкемең көтә, баһадир. Гадел хөкемдар булсаң, җәзала җаһил меңбашыңны.

Мөхәли меңбаш Күрәлән буеннан, Кәүчин ыруыннан, борынгы магуллар кавеменнән. Аны җәзаласа, нә әйтер яугирләре? Җәзаламаса да, кыен хәлдә калачак. Кибетче һаман акыра, хатыным көчләделәр, мөселманнар, булган хәлме бу бездә, дип дулый. Уктан аласымы әллә үзен? Аннары кибетчене генә түгел, җыелган халыкны да. Хәрәземне шулай иттеләр бит әле, халыкны куып чыгардылар да каланы яндырдылар. Халык шундук шым булган иде. Кайберләрен утка ташлатсаң да ярый.

— Икенең берен сайла, баһадир. Йә җаһил меңбашыңның билен сындыртасың, йә үзеңә дошман өстисең. Без сине, баһадир, гадел адәм дип кабул иттек, расла үзең!

Күр әле моны, ниндәен акыллы. Теленә ни килә, шуны такылдый. Әйе, Чыңгыз хан заманы булса, ул да ике дә уйламый кибетчене генә түгел, халыкны да уктан алдыртыр иде. Тик бит хәзер заманалар үзгәрде, олуг хан Үгәдәй аңа кат-кат кисәтте: калаларны җимермә, халыкларына тимә, күндәм хөкемдар тап та тархан итеп калдыр. Ясак җыяр.

— Мелла Котбый, нишлибез? Мөхәли меңбашны кайтарып җибәререм. Ә менә кибетченең хатынын көчләгән яугирне халык алдында уктан алмый булмастыр.

— Уктан алма, син аны кибетченең үзенә бир, баһадир, тамагы тыгылсын.

— Хак, кан чыгару җәзасын Тәңре дә яратмый.— Сүбәдәй артында торган кишектиненә ишарә ясады.— Мөхәли меңбашка бар, хатынын көчләгән яугирне биреп җибәрсен. Тиз йөрегез.

— Кибетче,— дип кычкырды Котбый.— Хатыныңны көчләгән яугирне алып килергә баһадир кишектиннәрен җибәрде. Төш аннан, халыкны котыртма.

Кибетче теләр-теләмәс кенә түбәдән төште. Ул арада кибетченең хатынын көчләгән яугирне дә китерделәр. Сүбәдәй яугирне күрде дә, җирәнеп, ирнен бүлтәйтте. Шыксыз һәм кирәкмәгән җәйпәк йөзле, карсак бер бәндә иде. Ияк очында берничә бөртек сакалы бар, тешләре сирәк, баһадирга караган да атыннан төшми тора.

— Синме көчләдең кибетче хатынын?

Яугир башын кырын салды, тирә-ягына күз ташлады һәм: «Нигә җыелган бу халык?» — дигәндәй, гаҗәпләнүен яшермичә, янәдән баһадирга карады. Сүбәдәй белә иде, магуллар яулаган халыкның хатын-кызларын һәрчак көчләделәр, һәрчак рәнҗеттеләр һәм моның өчен Чыңгыз хан яугирләрен беркайчан да җәзаламады. Ул гынамы, хан үзе дә ул нәрсәдән баш тартмый иде. Ләкин монда бөтенләй хәлләр башка бит. Тәңре рәхмәте белән Сүбәдәй кала тарханы итеп угланы Күлкәнне калдырачак, ә аңа ошбу халык белән яшисе. Елгыр Түкә Тимер әгәр дә мәгәр Бачман баһадир кызын да алып кайтса, дөньялар бөтенләй түгәрәкләнеп китәчәк.

— Төш атыңнан! — диде Сүбәдәй.— Төш, төш!

Яугир тәмам курка калды, магул аттан төштеме, ул инде кеше түгел, ул гүя дүрт аяклы хайван. Сүбәдәй кишектиненә яугирнең атын, коралларын алырга кушты. Шундук берничә кишектин яугирнең коралларын: сөңгесен, кылычын, ук садагын, җәясен салдырып алдылар.

— Ал кибетче, ул синеке. Телисең үтер, телисең асып куй, телисең хезмәтчең ит,— диде Сүбәдәй.— Йә, бәхилме?

— Ә товарларым? — диде кибетче, курка төшебрәк.

— Товарларың иртәгә китерерләр,— диде Сүбәдәй һәм атына камчы белән сукты да борылып китеп барды.

Кишектиннәре аңа иярделәр, ә артында шау-шу купты. Мәгәр Сүбәдәй әйләнеп карамады. Ул гомерендә беренче тапкыр яугирен халык хөкеменә биргән иде.

## 39

Мәҗлескә нойоннар гына түгел, каланың имамы һәм мөридләре дә чакырылган иде. Сарайның аш бүлмәсенә җәелгән мул табын тирәли бер якка нойоннар, икенче якка имам һәм аның мөридләре кунаклаганнар. Сүбәдәй кунаклар алдындагы бизәкле касәләргә игътибар итте. Бушлар. Кымызчы аның әмерен көтә, ул әйтүгә, касәләр-

гə кымыз коеп чыгачак. Имам вə мөридлəр дəшми-тынмый гына, күзлəрен песи кебек ярымйомган килеш дисбе тартып утыралар, ə нойоннар исə, буш кулларын кая куярга белмичə, əле буш касəгə, əле ашъяулыкка кагылып алалар. Нойоннарның гасабиланулары Сүбəдəйгə ошамый, ул аларны, гомумəн, яратмый, иллə нишлəмəк кирəк, алар аның кунаклары, иркəдəн иркəлəре, кадерледəн кадерлелəре. Нойоннарның берсе инде җир куенында ята. Нойоннар хəзер җыйган товарны өчкə генə бүлə башладылар, əмма нəфсе дигəнең корт бит ул, гелəн бəгырьне кимереп тора, дилəр. Сүбəдəй үзе — Тəңресе саклый — ул яман чирдəн ерак тора. Килгəненнəн канəгать, киткəненнəн зарланмыйча көн күрə. Тик менə Күлкəн угланына бераз мал җыеп калдырасы иде. Үзе ул монда калмас, каласы түгел, ə менə угланны калдыруы бар. Əлбəттə, сихəтлəнсə. Əллə нигə угланга һаман ит кунмый, үлми дə, терелми дə, дигəндəй, котны алып тик ята. Авызында һаман бер сүз — Сөмбел. Шайтаннан туган нəрсə булды инде ул кыз да, тəмам сихерлəп китте бит егетне. Нə шаман, нə имам, нə табиблар игə китерə алмыйлар бичараны. Бар өмет əнə шул кызда. Түкə Тимер кызны алып кайтса, ичмасам, иркенлəп сулыш алыр иде, ə болай углан янына кергəн саен бəгыре телгəлəнеп чыга. Нойоннар гаҗəпсенеп сарай бизəклəрен, дивар нəкышларын күзəтəлəр. Мондый хозур вə мəһабəт сарайларда булган халыкмы, үзлəрен тəкəббер тотсалар да, юртадан ары кая киткəннəре бар?! Əйдə, карасыннар. Гамьсез кыланалар. Кадан нойонны телгə дə алмыйлар. Үз кайгылары — кайгы. Арак эчеп, симез ит сосудан башканы белмəгəн нойоннар белəн аның сөйлəшəсе дə килми, бар хəсрəтлəре мал җыю. Ə менə имам һəм аның мөридлəренə берни дə кирəкми. Нəрсə инде бу, динме шулай сабырлата адəм баласын?

Сүбəдəй имəн бармагын күтəрде. Кымызчы касəлəргə кымыз коярга тотынды. Сүбəдəй касəне алды, күтəрде.

— Нойоннарым, имам хəзрəтлəре, мөридлəр, мин сезне ошбу мəҗлескə киңəшкə дəштем. Сез минем бер соравыма җавап бирегез: мин, Сүбəдəй баһадир, Саксин каласын яулап дөрес эшлəдемме?

Нойоннар күзгə-күз карашып алдылар, əмма берəүсе дə авыз ачып сүз əйтмəде. Бары тик имам гына тамак кырды.

— Акыллыны җүлəрдəн кылган эше вə гамəле аерыр, ди, кем. Сүбəдəй баһадир. Кан коймый диярлек каланы кулга төшерүең үлəн сəне мактау кəрəк, тик менə хөрмəткə ия нойоннарың теллəрен тешлəп, авызларын йомып утыралар. Нəмə җитми үзлəренə, җыйган маллары-мы, алган хатыннарымы?

Шəп əйтте имам, рəхмəт үзенə, җилле төшерде, нойоннар, имам хəзрəтнең сүзлəрен аңлап бетермəсəлəр дə, төшенделəр бугай, берсе тамак кырып алды, касəсенə арак коюны сорады.

— Баһадир, кичерə күр, мин арак ярата төшəм.

— Сал нойонга арак, сал-сал,— диде кымызчыга Сүбəдəй.

Нойоннар арак эчтелəр, имам белəн мөридлəр теш арасыннан гына кымыз чөмереп утырдылар. Табында табак белəн түтəрəм-түтəрəм ит тора. Үрелүче дə юк — барысы да Сүбəдəйнең ни əйтүен көтəлəр.

— Ирха Кара нойон сүзгə оста безнең,— диде Текнə нойон.

— Мин иртəгə кайтыр юлга чыгам, баһадир. Олау бир. Миңа җыйган малым бик җиткəн.

— Олуг ханга ни əйтерсең, Ирха Кара нойон?

— Баһадир, олуг хан безне көтə, чаптарым кəлде.

Сүбəдəй Ирха Кара нойонның олуг хан Үгəдəй катына аяк тибеп керүен белə, шуңа бер сүз дə əйтмəде, бары тик, олау булыр ул, булыр, дип ияк какты.

— Тик төмəнең калдырырга туры килер, нойон. Каланы кулга төшерсəк тə, дошманны җиңгəнебез юк əле. Бачман баһадирның көч җыеп, əйлəнеп килүе бар.

— Төмәнем берникадәр алтын бәлешкә калдырам, баһадир.

— Якшы, нойон Ирха Кара, мин сиңа хан исәбеннән түләрмен.

— Алайса минем төмәнем дә алып кал, мин дә кайтып китәм,— диде Текнә нойон.

— Якшы, шулай итәрмен, Текнә нойон,— диде Сүбәдәй бер сүз дәшми утырган Бүчек нойонга күз төшереп алды.— Бүчек нойон, син нәмәрсә дәшми утырасың?

— Китәргә теләгән кеше күп сөйләми. Мин төмәнем белән китәм, баһадир. Картая барган саен кешенең куәте китәр, диләр.

— Ләкин, акылы артыр, дигәннәр бабайлар.

— Артканныкы артадыр инде ул, артмаганныкы артмыйдыр, баһадир. Тик мин төмәнсез юлга чыкмам.

Менә бусы бөтенләй көтелмәгән хәл иде Сүбәдәй өчен.

— Бүчек нойон, төмәнең өчен акча ала алмам, дип курыкмасаң иде,— диде имам хәзрәтләре.— Без аны кала халкыннан җыеп булса да бирербез.

Кала имамы тагын бер тапкыр шаккатырды Сүбәдәй баһадирны, ул моны аңардан гелән көтмәгән иде. Ә бит хаклы, иртәнге намазда имам хәзрәтләре кала халкына баһадирның гозерен житкерер. Әгәр дә мәгәр кала халкы аның хәленә кереп, ошбу мөртәтләргә кирәк кадәр акча җыеп бирсә — Сүбәдәй өчен каланы алудан да зуррак жиңү булачак. Дөрес, ул акчаны Сүбәдәй халыктан болай да җыя алыр иде, әйтик, талап алса. Чыңгыз заманы булса, ике дә уйлап тормас иде. Тик бит хәзер шартлары бүтән. Аннары максаты бар: угланны Бачман баһадир кызына өйләндереп, тәхеткә утыртып калдырырга. Имам хәзрәтләре аша Сүбәдәй баһадир каланы угланга тапшырыр да илгә таба кузгалыр. Тагын бер тапкыр инанды: Болгар илен өч-дүрт төмән белән генә яулау турында уйлап та карарга ярамый. Ошбу якларга яу чыкканчы бик нык әзерләнергә, чирү тупларга, коралларны камилләштерергә. Әйе, кул астында ун-унбиш төмән чирү булганда гына Болгарга яу килергә мөмкин. Тик бу кадәр чирүне Үгәдәй хан бирерме?..

Нойоннарны һәм имам хәзрәтләрен вә аның мөридләрен озаткач, Сүбәдәй бик озак шул турыда уйланып ятты. Аннары торды да юртасына юнәлде, тик угланы исенә төшеп, кире борылды һәм Күлкән яткан кызлар бүлмәсенә керде. Сакта торган кишектиннәргә тик торырга ишарә ясап, түргә узды, йокымсырап торган угланга кулын сузды. Сак кына кагылды кебек, тик углан кинәт сискәнеп китте, аннары куырылып куйды.

— Хәлең ничек, углан?

— Түзәрлек, атам.

— Нойоннардан котылабыз, углан, кала безнеке. Китәләр, ризалаштылар.

— Бирсен Ходай,— диде углан, мөселманнарга хас Аллаһы тәгаләгә мөрәҗәгать итеп.

## 40

Яман хәбәр Сүбәдәйгә нойоннары китеп бер атна үткәч килеп иреште. Каракорымга юл алган нойоннарны болгарлар Җаек елгасы буенда көтеп торганнар һәм бар җыйган мал-мөлкәтләрен талап, яу озата барган яугирләрне туздырып, нойоннарны әсир иткәннәр. Көч-хәл белән котылып, ике яугир ошбу хәбәрне Сүбәдәйгә ирештергәч, Сүбәдәй ачуыннан аларның икесен дә камчы белән ярды. Бары тик ачуы басыла төшкәч кенә, тегеләргә арак салып бирергә кушты, сораштырырга тотынды.

— Кем талады, кем иде?

— Бачман баһадир.
Сүбәдәй сикереп торды, арлы-бирле йөренергә тотынды.
— Каян барып чыккан ул анда? Бит Идел буйлап өскә таба киткән иде...
— Безгә анысы караңгыдыр, баһадир.
— Югалыгыз күз алдымнан!

## 41

Алар чатырда яшәделәр. Кояш баеганны көтеп ала алмый интектеләр. Хан оныгы Хансөяр хатыны Сөмбелне кулыннан да төшермәс иде, тик аңа көнозын төзелеш мәйданында булырга, әмер-боерыклар бирергә туры килә, хәтта урман кисүчеләр янына да барып кайтырга җай тапмый иде. Моның өстенә Саксин каласыннан күчеп килгән гаиләләрне урнаштырырга кирәк иде. Саксин халкы күбесе өйләрне саманнан күтәрергә теләде, әмма хан оныгы Хансөяр аларга моны эшләргә кушмады. Биредә кышларның шактый салкын булуына сылтады, агач өйләр бурарга киңәш итте. Агач өйләр суктырыр өчен хан оныгы Хансөяр күрше чирмеш осталарын ялларга дип Ташбайны кодалап җибәрде. Бу халык бик күптән инде агач өйләрдә яшиләр, шуңа күрә осталары да күп, ялланып эшләргә яраталар иде. Урманнан бертуктаусыз бүрәнәләр кайта торды, осталар, Хансөяр сызымына карап, тархан сараен күтәрә башладылар. Хан оныгы Хансөяр атасы Дәүранны көтте, ләкин көтеп ала алмагач, үзенчә бурата башлады. Шул атнада анасы белән атасы килеп төштеләр. Корабта килгәннәр, осталар китергәннәр, бирнә-бүләк, кораллар, таш кисүчеләр. Әтисе белән әнисен каршыларга хан оныгы Хансөяр Сөмбелне дә елга бакалдагына алып төште. Кораб яр кырыена туктауга, беренче булып коры җиргә баскан Назлыгөл иң әүвәл киленен кочагына алды һәм күзләренә карады да үзенең яшь чакларын исенә төшереп:
— Балакаем, синмени инде Хансөяр угланның хәләле? Йа Раббым, төкле аягың белән корабка кер, аннары бергәләп чыгарбыз,— диде.
Хансөяр белән Сөмбел корабка күтәрелделәр, анда әтисе аларга бүләк-бирнә сандыкларын тапшырды һәм хезмәтчеләргә сандыкларны алып төшәргә кушты. Дәүран килененә карап торды-торды да кай ягы беләндер кыз чагындагы хатыны Назлыгөлгә охшатып:
— Углан, атаң-анаңнан фатиха алмыйча өйләнергә ничек кыйдың?— дип көлде. Шуннан Назлыгөленең иңеннән алды да:— Без дә шулай өйләнешкән идек, алма агачыннан ерак төшми икән, иншалла, безнең кебек тигез-тату яшәрсез,— диде. Һәм икесенең дә битләреннән үбеп, килен кешене кызарырга мәҗбүр итте.
— Кичерә күрегез, әтием-әнием, кичерә күрегез угланыгызны, бәхилләгез. Фатихагыз ала алмадым. Вәләкин Раббым вә мәхәббәтем шаһит, мин Сөмбелне яраттым. Атам, Сөмбел, хәтта язган идем инде, Бачман баһадир кызы. Бәхилләгез безне.
— Бәхилләми буламы, бәхилләми буламы, балакаем,— диде Назлыгөл оланнарның икесен дә кочып.— Аталары, бәхиллибезме?— дигән булды, кинаялэп.
Хан оныгы Хансөяр аталарын ярга әйдәде, хатыннарны алдан җибәреп, үзләре ярга баскач, ата кеше угланына:
— Хатының гүзәл, йөзендә фәрештә нурлары балкый, иншалла, бәхетле гомер итәрсез,— диде.
— Мин аны, атам, син әниемне яраткан кебек яраттым.
Дәүран-ата, әллә кайчангы хәлләрне исенә төшереп булса кирәк, тыенкы гына кеткелдәп көлеп алды. Аннары калага күз салды да, соклануын яшермичә:

— Хан сараен кем күтәрә? — дип сорады.
— Хан сарае түгел лә,— дигән булды хан онысы Хансөяр.
— Искәр, углан, һәр өйне хан сараена тиң итеп салсаң гына, калан матур булыр, даны еракларга таралыр. Кала яме — анда яшәгән вә көн күргән халыкның йөзедер. Матур мәһабәт өйләр кеше күңелен сафландыра, пакьләндерә, балакай. Бу хактан нә генә төзетсәң дә, онытма. Һәр нәрсәгә күңелең биреп тотынганда гына, һәр нәрсәне тәмам гашыйк булып башкарганда гына, кеше синең кулың тигән нәрсәләргә сокланыр. Нурсыз өйнең эче дә салкын булыр, ди. Акча-мал кем бирде?
— Аты яман яугир Сүбәдәй баһадир Саксин каласын басты, атам. Ил-малын алып, атам Бачман баһадир бире күчеп килергә булды. Ләкин Сүбәдәй баһадирдан үч алу нияте белән тагын кала тарафына кайтып китте.
— Мин бу хакта хәбәрдар, углан. Аларга Җик Мәргән килеп кушылган, Булат бәк ияргән һәм алар Саксинга юнәлгәннәр, дип әйттеләр. Иншалла, магул яугирләрен куарлар һәм илемездә янә тынычлык урнашыр. Урыслар белән дә ипле генә сәүдә итеп ятабыз.
— Әтием, калага Сөмбел исеме кушарга киңәш итте Бачман баһадир.
— Исемне халык бирер, каланың салынуы хак булсын, олан.
Бөтен бирнә-әйберләр чатыр тирәсенә китерелгәч, килгән осталарны урнаштыргач, кала халкы өчен үзенә күрә бәйрәм уздырдылар. Яр өстенә җыен табыны җәйделәр. Казаннан килгән мичкә-мичкә әче балны тәгәрәтеп китерделәр. Каланың бар төбәкләрендә дә бу көнне бәйрәм иттеләр. Мелла Хакимҗан манарасы күтәрелә башлаган мәчет янында кала халкына вәгазь укыды, килгән кунакларга хөтбә әйтте, кала салучыларга игелек теләде.
Шуннан уен-көлке, күңел ачу башланды. Кич ахшам намазы җиткәч кенә өйләренә, өйләре булмаганнары чатырларына, чатырлары булмаганнары яр астындагы куышларга, куышлары булмаганнары шалашларга таралыштылар. Әтиләрен яңа корган чатырга урнаштыргач, хан онысы Хансөяр хатыны Сөмбелнең күзләренә карап:
— Әйдә Иделгә төшеп, коенып менәбез,— диде.
— Әй, мин оялам, Хансөяр.
— Кемнән?
— Әнә ай калыкты, ай карап тора.
— Ай! Ай үзе дә ялангач ләбаса.
— Булса ни. Аның каравы мин оялам.
— Алайса, Сөмбел, мин сине күтәреп алып төшәм.
Шулай диде дә хан онысы Хансөяр Сөмбелне кулына күтәрде һәм йөгереп елга буена алып төште, аягына бастырды, үзе чишенә дә башлады.
— Мин куркам, Хансөяр.
— Кемнән? Монда аждаһалар юк иде кебек.
— Алайса үзең чишен дә кер, тик миңа карама.
— Кыз чагында син кыюрак идең, Сөмбел.
— Әйедер, бәлкем. Хәзер оялам да, куркам да.
Хан онысы Хансөяр суга кереп китте һәм йөзеп чума башлады. Аның артыннан калку күкрәкләрен куллары белән каплап, Сөмбел керде һәм, су биленә җитүгә, йөзә башлады. Су салкын түгел иде — мөхәррәм ае, көннәр эссе тора, кичләрен һәм төннәрен эсселек сүрелә төшсә дә, көнозын кояш кыздырган җир-су җылысын саклаган, коена торгач, тәмам судан чыгасылары килми тордылар. Коенулары төнлә белән бигрәк тә рәхәт икән. Җылымса су тәнне йомшак кына иркәли, назлый иде.
Чума-куыша, чыр-чу килеп коендылар, су чәчрәтештеләр, көлештеләр. Тагын йөзделәр, ә ай аларга көнләшкәндәй елмаеп карап торды. Ул арада көмеш табактай җемелдәп торган ай болыт астына чумды. Сөмбел үзе дә сизмәстән: «Ай!» — дип кычкырып җибәрде дә каударланып яр

буена таба ашыкты. Судан чыкты, үзалдына өшеп киткәндәй калтырана-калтырана киенә башлады.

— Сөмбел, Сөмбел! — дип кычкырды Хансөяр. — Кая киттең син?

— Мин чыктым, мин куркам, син дә чык, Хансөяр!

Хан оныгы йөзеп килеп судан чыкты, тиз-тиз генә киенде һәм җилкәләрен җыерып, өшеп-калтыранып торган Сөмбелне кулына күтәрде дә йөгерә-атлый яр өстенә алып менде, аягына бастырды, битләреннән үбеп алды, кайнар сулышы белән кулларын җылытты.

— Әллә өшедең?

— Юк ла, әллә нигә калтырата. Хансөярем, әйдә, кайтыйк...

Хансөяр аны тагын кулына күтәрде, Сөмбел тынычланып, ир-канатының муенына сарылды:

— Хансөярем, миңа шундый рәхәт...

— Мин сине шундый сагындым, Сөмбелем, шундый сагындым,— дия-дия хан оныгы хатынның беләкләреннән үпте, муен-колакларына тел-иреннәрен тигезеп алды. Сөмбел ошбу назлауга, татлы вә рәхәти ыңгырашу белән аваз салды.

Чатырга кайтып, бер юрган астына кереп яткач, аларга тагын да ләззәтлерәк булып китте. Ашыйсылары да, эчәселәре дә килмәде, Ходай тәгалә аларга тән-җан тансыклавын биргән иде, сөешеп туймас хәлгә җитеп, аунадылар, кочыштылар. Бернидән дә ояласы юк, ай да күренми, бары тик икәүдән-икәү генә. Алар ниндидер бер мәлдә икесе дә мәхәббәт мәҗнүненә әверелделәр. Сөю-назлауда, иркәләүдә вә үбешүдә бер-берсен уздырырга тырышкандай, әле укмаштылар, әле чалкан төшеп, хәлсезләнеп яттылар. Рәхәт дулкынында чайкалгандай көймәдә яталар кебек, татлы наз сүзләре күңелне җилкендерә, җанны эретә, бер тән, бер җан итә икән. Кавышкан, кочышкан саен аерылыша алмый интектеләр. Җиңелчә, әмма тыенкы гына бер-берсенең ыңгырашуын ишетү икесен дә чарасыз итте, бермәлне икесе бер матдә, бер җисем хәленә керделәр кебек тоелды. Тик кем әйтә алыр сөю вә яратуның чиге бар дип. Кем бу халәттә үзе өчен рәхәти яңа бер дөнья ләззәте ачмый да, шуны кабатларга теләми икән. Кабатламас мизгелләр, хиссияте ташып торган тойгы, җисми теләктән туган мөлдерәмә наз вә сөю-сөелү кешене тәгаен чарасыз итә икән ич. Аңарда, бигрәк тә ир-атта гүзәл затын күтәреп күккә ашу теләге туа, шул ук халәткә омтылган кочагындагы сөйгәнендә шуңа таба талпыну тоеп, ул чынлап та үзен олуг куәткә ия җан дип хис итә. Мөгаен, шушы хис, шушы тойгы, кабатланмас мизгел кешене чын мәгънәсендә кеше итәдер, ә мәхәббәт, Аллаһы тәгалә тарафыннан адәм баласына бирелгән иң кадерле, шул ук вакытта иң нәзберек, иң зәгыйфь, иң нечкә, иң күркәм тойгы вә хисләр.

Ул аны сөйде, назлады, тән-әгъзаларының һәр буынын, һәр ноктасын үбеп чыкты. Калку тыгыз күкрәк, песи борыны кебек төнлә дә җемелдәп торган ими башын үбү аның өчен хәттин ашкан ләззәт вә хис тойгысы бирсә, аның ошбу назлавыннан Сөмбел күккә ашкандай хис итте үзен.

— Хәләл ирем минем, Хансөярем,— дип күгәрчендәй гөрләде ул назга сусавын аңлатып.— Хансөярем, син мине беркайчан да, берәүгә дә бирмәссең...

Ир-канаты Хансөяр Сөмбелнең бу сүзләренә сискәнеп китсә дә, әйтер сүз таба алмады. Бары тик зиһене аша кинаяле, шикле бер уй узды: «Нигә ул алай диде?»

Икесенә дә чатыр һавасы эсселәнеп китте. Алар бер-берсен бары тик күңел күзләре белән генә күрделәр.

— Сөмбелем-җаным. Син минем хәләл җефетем, син минем багалмам, алиһәм, карлыгачым, былбылым, Ләйләм...

Мөгаен, тикмәгә генә сөю-назлау, ярату вә мәхәббәт адәм баласына Аллаһы тәгалә тарафыннан бирелгән, димәгәннәрдер, күрәсең. Борын-борын заманда, Адәм белән Һаувага җан иңдергәндә әйткән: «Ошбу

якты дөньядан мәхәббәт вә сөю китмичә ахырзаман килмәс!» Ә бит бик дөрес. Җир йөзендә адәмнәрнең бер-берләренә мәхәббәте булганда яшәү дәвам итәчәк.

Сүтелеп-таралып, кулын хәләл җефетенең нечкә биленә куеп ятканда хан оныгы Хансөяр әнә шундый фәлсәфи уйларга бирелде. Бала чагында ук аңа мөгаллимәсе Зөләйха кешеләрне ничекләр яратырга сабак бирде. Тәтеш шәех үз тәҗрибәсе белән уртаклашты, хан сәркатибе мәһди галим Кәтиб Хафиз аның якты дөньяга күзен үзенчә ачты.

Үсә-исәя төшкәч, Кәтиб Хафиз аны еш кына үзләренә алып барды, ислам динен кабул иткән хатыны Амата аңа үз белгәнен сөйләде. Аларның борынгы бабаларында аллаларның күп булуы, мәхәббәт алласы Афродита хакында сөйләде. Аматага ышансаң, борынгы грекларның олуг аллалары Зевс адәми затны бер итеп яраткан икән. Ир дә ул, хатын да, имеш. Әмма тора-бара күзәтә икән Зевс, ошбу зат куәтләнә бара, һичкемгә буйсынмый, башка аллаларны санга сукмый һәм хәтта Зевска яный башлый. Шуннан Зевс моның куәтләнеп китүен күреп, батыры Гераклга моны акылга утыртырга куша. Теге төшә дә ир вә хатын булып йөргән затны кылычы белән урталай яра икән. Яра да яңабаштан икесенә дә җан өреп, икесен ике якка җибәрә. Олуг алла Зевс Гераклның эшеннән канәгать кала. Менә шуннан соң ошбу ике зат яңадан бер зат булу өчен ниләр генә кыйланмыйлар икән, әмма кушыла алмыйлар, ди. Олуг алла боларга карап торган-торган да: «Бер-берсен назлауны, сөешүне мәхәббәт дип атагыз»,— дип әйтеп әйткән, имеш. Ир-ат белән хатын-кыз шуннан бирле бер затка әверелү өчен ничек кенә тырышсалар да, әлегә кадәр бер зат була алганнары юк, ди. Аның каравы, шушы мәхәббәт аша бу ике зат балалар таба башлаганнар.

Хансөяр яван хатыны Аматаның самими хикәятеннән тыенкы гына көлсә дә, Сөмбел белән сөешкәндә еш кына аның сүзләрен исенә төшерә иде. Амата аңа әйтте: «Ихлас мәхәббәт эчкерсез була. Мәхәббәтнең кавеме дә, теле дә, дине дә юк. Мәхәббәтнең кавеме, теле, дине — сөю-ярату вә назлаудыр». Әйе, мөгаллиме Кәтиб Хафиз бикәсе Амата аңа адәм баласына Аллаһы тәгалә тарафыннан бирелгән иң гүзәл, иң күркәм, иң татлы сыйфатларның берсен — мәхәббәтнең серен аңлаткан иде.

Мәхәббәт алласы хатын-кыз тәненә җитмеш төрле сөю вә назлау беләмәсе биргән, шуларның җидесен тапканда да һәр ир-ат сөйгәнен бәхетлеләрдән бәхетле итә ала. Амата әйтүенә ышансаң, әнә шул җитмеш беләмәне тапкан һәм назлаган ир-ат кына Аллаһы тәгалә яраткан якты дөньяга үз дәвамнарын калдырырга хаклы, дигән иде яван хатын-кызы. Аның шушы сүзләреннән соң хан оныгы Хансөяр һәр күзе төшкән хатын-кызга сокланып һәм тансыклап карар иде. Ә инде Сөмбелгә гашыйк булгач, тәүге сүзләрне беркайчан да онытмады. Бик ихтимал, Амата әйткән куәтле затка әверелә алмагандыр, әмма Сөмбеле белән кавышкан һәм якынлык кылган саен үзендә: тәнендә, җанында үзгәреш тойды һәм ошбу үзгәрешне сөйгәнендә дә күрергә теләде.

Сөмбел боларның берсен дә белми. Аматаны күргәне дә, серле хикәятләрен тыңлаганы да юк аның. Ә менә Ходай тәгалә кушыпмы, сөйгәненең һәр назын бик теләп, бар оятын читкә куеп кабул итте. Бәлкем шуңа Рәсүлемез Мөхәммәд сөю вә назлауны, хатын-кызга гашыйк булуны гөнаһка санамагандыр. Нәсара динендә бу хәл киресенчә ләбаса, һәр якынлык кылу — гөнаһ. Димәк, Рәсүлемез мәхәббәтне изге нәрсә итеп кабул иткән. Хаклы, мең тапкыр хаклы Рәсүлемез: саф мәхәббәт гөнаһ була алмый...

Әле анда, әле монда әүвәл бураләр, аннары түбәләре ябылган өйләр күтәрелә башлады. Кала салуны үз кулына алган әмир Хажи остасы Дәүран булачак Сөмбел каласын Казанга охшатырга тырышты, гәрчә өйләрне, урам сузуларны бу урындагы жир йөзенә яраштырып урнаштырса да. Бер ай дигәндә тархан сараеның түбәсен яптылар. Ә инде Сәфәр ае азагында кибетләр эшли башлады, базар һәм сәүдә үзәкләре житеште, кәрвансарай утары өлгерде. Болгар, Казан, Кашан, Тубылгытау, Жүкәтау, Сувар, хәтта урыс тарафыннан Владимир каласыннан сәүдәгәрләр күренә башлады, алыпсатарлар ишәйде.

Бачман баһадир Саксин каласын югалткан, Сүбәдәй баһадирга калдырып киткән, дигән хәбәр Болгар дәүләтенең барлык калаларына ирешкән иде инде, шуңа күрә ирекле алайлар Бачман баһадирга ярдәмгә ашыкты, ә инде Сөмбел каласы салынуын һәм базар ачылуын белгәч, теге йә бу калада төпләнеп житмәгән гаиләләр биргә күчеп килә башладылар. Хан оныгы Хансөяр аларны кабул итте, өй салырга урын күрсәтте һәм булдыралган кадәр акчалата ярдәм итте. Күчеп килүчеләр күбрәк кыпчаклар иде. Бозаулык, Кандыр, Кенәл, Саратау, Самара тарафларыннан күчеп килгән халыкка үзләренә урам салырга рөхсәт ителде. Кем куа иде кыпчак халкын ошбу төбәкләргә? Билгеле инде — магуллар. Сүбәдәй яугирләре нә игелекле булып күренергә теләсәләр дә, көтмәгәндә калаларга яу йөриләр, халыкны талыйлар һәм Саксинга таялар иде. Дүрт төмән яугирне ашатырга-эчертергә киендерергә кирәк иде, кала халкына бу хәл авыргарак килә башлагач, Сүбәдәй үзе үк тирә-якка яу йөрергә һәм кала-авылларны таларга рөхсәт биргән иде. Кыпчак-болгар халкының Сөмбел каласына күчеп килүләре шуннан иде. Күчеп килгән халыкка хан оныгы Хансөяр кинәнде дә, көенде дә. Чөнки кыпчаклар күчеп китә башлагач, Сүбәдәй баһадирның Богырыслан кебек саф кыпчаклардан торган, тана-башмаклар үрчеткән төбәкләрне үз кул астына жыюы бар иде.

Ул арада Дәүран атасы белән Назлыгөл анасының китәр көннәре килеп житте. Бакалдакка озата төшкәч, атасы Хансөярне бер читкә алып, бер киңәш бирде.

— Углан, күрәм-күзәтәм дә шиккә калам. Бу магул дигән халык һаман кыпчак-болгар халкын кысрыклый, һич булмас димә, ошбу тарафларга да килеп житәрләр. Шуның өчен гаскәр туплый башла. Төмәнбашың бар — Ташбай углан.

— Киңәшең өчен рәхмәт, атам. Мин үзем дә шулайрак уйлап тора идем.

— Әмир Хажи белән мин сөйләшермен, кирмән-кальга күтәргәч, туплар да жибәрербез. Сакланганны сакларммын, дигән Аллаһы тәгалә.

Хан аныгы Хансөяр атасын баш иеп, килешеп тыңлап торды һәм, кораб әзер булгач, кузгалдылар. Әниләре белән саубуллашканда Назлыгөл әнисе елап та алды, Сөмбел дә күз яшьләрен яшермәде. Бергә торганда әтисенең әнисенә карата жылы мөнәсәбәтен күреп, хан оныгы Хансөяр күңеленнән бәхетле бер көнләшү хисе кичергән иде.

Хан оныгы Хансөяр базаркәләрдән, алыпсатарлардан, килгән-киткән сәүдәгәрләрдән салым жыяр өчен әтисеннән бер кеше жибәрүен үтенде. Атасы аңа, әмир Хажи белән сөйләшеп карармын, дип ышандырды.

Әтисе белән әнисен озатып куйганга атна-ун көн вакыт үтмәде, көтмәгәндә гаскәр олавы белән Бачман баһадир килеп житте. Бачман баһадир олау-олау мал-байлык китергән. Бу кадәр байлыкны күз алдына да китермәгән хан оныгы Хансөяр, кич табынга утыргач, сорап куйды:

— Атам, без сездән бу хәтле байлыкны өмет итмәгән идек. Инде халкыма кыш буена ризык булды, ачка үлмәбез, дип әйтә алам.

— Кияү балакай, хәтереңдәдер, Сүбәдәй баһадир безне бик жиңел генә төп башына утырткан иде. Бу юлы мин аны кәкере каенга терәдем.

Бер үзем генә түгел, Булат бәк, Җик Мәргән. Ә ул болай булды. Сүбәдәй баһадир нойоннарын кайтарып җибәрергә уйлый. Һәм үз дигәненә ирешә. Тик бер нойон, гаскәремне дә алып китәм, ди. Сүбәдәй нойон белән килешергә мәҗбүр була, чөнки аңа олуг хан тагып җибәргән нойоннар комачаулыйлар, җитмәсә яулаганнан соң җыйган бөтен мал-мөлкәтне үзара бүлешәләр. Сүбәдәй аларны бер көн юл озата бара да кире Саксинга борылып кайта. Багучыларым миңа моны җиткереп тордылар. Менә яулаган халыкларны талап Саксиннан кузгалган байлык белән Җаекка якынлаша нойоннар. Гаскәрнең бер өлеше уң ярда кала, бер өлеше аръякка кичә. Олауларны чыгарырга керешәбез дигәндә генә, без ябырылдык. Орышсыз булмады, әмма бер генә олау да Җаекны кичә алмады. Олауларны да кулга төшердем. Ә менә Җаекны кичкән яугирләр нойоннарын да ташлап, бик тиз күздән яздылар. Без магуллар талап җыйган бөтен байлыкны алып, сезнең тарафка килдек. Ә әсир төшкән нойоннарны Илһам ханга калдырырга туры килде, хан шулай теләде.

— Мин сезнең өчен шат,— диде хан оныгы Хансөяр. Шунда гына яннарында Артык атакайның булмавын искәреп алды.

— Ул хатыны белән бүген-иртәгә килеп житәр,— диде Бачман баһадир.

— Кем, әтием?

— Артык атакай, син шул турыда сорарга җыендың түгелмени? Ташбай углан кунаклар көтсен. Айгөл, сиңа да әйтәм.

— Без көтәбез, көтәбез, баһадир,— диде Ташбай.— Бигрәк тә Айгөл. Әниемне күрәсем килә, дип җанга тиде инде.

— Без сөйләштек, оланнар, Артык баһадир килгәч, без янә бергәләп Саксинга таба кузгалырбыз. Минем Сүбәдәйне Саксиннан куасым килә.

— Илһам хан белән киңәшергә иде, атам, әүвәл.

— Башта ханга кереп фатихасын алабыз. Иншалла, хәлебезгә керер, әмир Хаҗига да сугылырга исәп юк түгел. Әзерлексез юл чыкмабыз анысы. Ярдәмгә килүчеләр дә ишәйде. Куарбыз без ул сукыр шайтанны, оланнар, куарбыз.

— Илһам хан үзе дә барса икән,— диде мелла Хакимҗан.

Әйе шул, дигәндәй, барысы да Бачман баһадирдан җавап көттеләр, әйтерсең лә Саксин каласын Сүбәдәй баһадирдан азат итү Илһам ханнан тора иде. Бер уйлаганда мелла хаклы иде. Сүбәдәй баһадир Саксинга юнәлгәндә ул Илһам хан каланы якларга гаскәр белән үзе килгән булса, ихтимал, корыч баһадирны калага да кертмәгән булырлар иде. Ләкин ни сәбәпледер Илһам хан үзе дә килмәде, хәтта гаскәрен дә җибәрмәде, бары тик бер-ике мең тупчыларын гына җибәреп котылды. Һәм, нәтиҗәдә, Саксин каласы Сүбәдәй баһадир кулына күчте. Хак, Бачман баһадир Сүбәдәй ыстанына кузгалмаган булса, бик ихтимал, каланы кулында тота да алган булыр иде. Хәзер соң инде, эш үткән, корыч баһадир калада утыра. Бүчек нойон бер төмән яугирен үзе белән алып китсә дә, тегеләрне болгарлар юлда туздырган булсалар да, магулларның төп көче Сүбәдәй кулында иде әле. Сүбәдәй баһадирның чирүенә җиңел караган илләрнең күбесе инде аның ат тояклары астында яталар иде. Бер уйлаганда, Чыңгыз ханның данын да нәкъ менә шул кеше күтәрүче иде — Сүбәдәй баһадир. Тик бит, гадәттә, яугир җиңә, хан мактала, дип әйтәләр. Һәм шулай булды да, Сүбәдәйнең җиңүләре Чыңгызга дан китерде, абруен арттырды, ә шушы җиңүләрнең башында йөргән баһадир бары тик «корыч баһадир» кушаматы алып, күләгәдә калды. Әмир Хаҗиның да, туганы олуг хан Илһам ханның, хәтта Саксин каласы тарханы Бачман баһадирның да хатасы корыч баһадирга житди дошман итеп карамаудан булды. Хак, Чыңгыз хан кул астында бер Сүбәдәй баһадир гына яу башында тормады. Чыңгыз ханның баш угланы Җүси, Сүбәдәйнең абасы Җәбәй нойон, төркиләрдән Гүяк бәк, угланнары Үгәдәй, Чыгытай, Түләк, туганнары Хөчар, Алтан, Чәчә бәк, Билгетай — һәммәсе чирү белән йөри, һәммәсе алгы сафта була һәм күбесе

орыш кырында ятып кала, ә даны, даны Чыңгыз ханга. Сәне милади белән 1223 елда Бохараны алгач, Чыңгыз хан шунда кыш чыга. Яз көне Сыр-Дәрья буйлап югары менеп, Кулан Башы дигән урында ауга йөреп ял итә, күңел ача. Ул гынамы, Иртыш якларында җәйләгән угланы Җүсине янына дәшә. Теге атасына һәдия-бүләк итеп егерме мең ат алып килә. Һәм шул урында Чыңгыз хан корылтай уздыра, шул урында рәхәт кыла, җаен җәйли. Ә бу вакытта Сүбәдәй баһадир белән абасы Җүси һәм төрки бәге Гүяк Кавказ, Днепр, Идел буйларында сугышып йөриләр — янә Чыңгыз ханның данын арттыралар. 1224 елда, кыш көнендә, Җунгариядә Чыңгыз ханга Сүбәдәй баһадир һәм абасы Җәбәй килеп кушылалар. Җинеп-җиңелеп кайткан Сүбәдәйне Чыңгыз мактамый, чөнки бик күп яугирләрен югалткан, талаган малын калдырган була, әмма баһадирга һәм абасы Җәбәйгә бик алай күтәрелеп тә бәрелми, чөнки аңа дан яулап йөрүләрен белә, бары тик Сүбәдәйгә генә, анысын да шактый нык салып алгач, мәҗлестәге табын янында: «Корыч баһадирым!» — дип әйтеп әйтә. Бары шул.

Үләсе елны Чыңгыз хан, угланы Җүсигә тапшыр дип, хат язып бирә. Анда мондый юллар була: «Углан, Сүбәдәй баһадир яулаган илләргә бар да җир-җәйләүләрен билә. Атаң Чыңгыз».

Чыңгыз ханның мөһере сугылган хатны Җүси угланга илткәндә ул вафат булган иде инде. Бирә алмады Сүбәдәй баһадир Җүси угланга хатны. Ләкин хатны кадерләп, бөти итеп күңгә тегеп, муенына тагып йөрде. Сүбәдәй баштан ук Җүси углан кул астындагы баһадир иде. Җүси углан вафат булгач та, ул анда калды. Мәгәр Чыңгыз ханны үз кулы белән күмде. «Мине Борхан Хандук тау итәгенә күмегез» дигән сүзне дә хан аңа карап әйтте. Сүбәдәй күмү мәшәкатен үз өстенә алды диярлек. Угланнар авыр хәлдә сырхаулап яткан аталарына нәкъ менә Сүбәдәй каршында бер-берсе белән телгә килмәскә, бер-берсен тыңларга ант иттеләр, ягъни бармакларын канатып, каннарын арак касәсенә агызып, нәүбәтләп эчтеләр. Олуг хан итеп угланы Үгәдәйне дә Сүбәдәй булганда билгеләде. Ә бит хан булып баш бала — Җүси калырга тиеш иде, тик ул бала юк иде инде — вафат, агулап үтергәннәр иде һәм кем диген — Чыңгыз ханның яшь хатыны Хулан... Чыңгыз угланнары арасында Җүси углан иң бәхетле, укый-яза белә торган бала иде. Сабакны аңа уйгур мөгаллимнәре бирде, дөрес, алар нәсаралар иде, ләкин Сүбәдәйгә аларның диннәре кирәкми иде ул чакта. Ислам һәм нәсара диненә ул соңрак игътибар итә башлады, Болгарга яу йөри башлагач. Сүбәдәй баһадир Җүси угланга Чыңгыз ханның әмерен китереп өлгермәде, әмма Чыңгыз хан мөһере сугылган, үз каны белән бармак баскан әмер кәгазен бирәүгә дә бирмәде дә, күрсәтмәде дә. Ул аны догалык урынына үзендә йөретте. Хатны ул бары тик Үгәдәй ханга гына күрсәтте. Теге исерек баш атасының тамгасын күрсә дә, әлләни шаккатмады, шулай да Сүбәдәй сораган чирүне бирде.

Боларның барысын да белмәсә дә, мелла Хакимҗан ошбу булган хәлләрнең күбесен ишеткән иде инде. Шуңа күрә булса кирәк, Сүбәдәй баһадир чирүе зурмы, кечкенәме — җитди карады, бу баһадир белән буласы орышка җитди килде.

Бачман баһадирга: «Илһам хан үзе барса икән», — дип бары тик шуның өчен генә әйтүе иде.

## 43

Сиземләү һәм тоемлау хисе каян килә икән кешегә?.. Бер Ходай үзе генә беләдер. Сөмбелне соңгы вакытта елга буе тартты. Гүя аны кемдер дәшә, әйди, көтә сыман, ә чарасыз калган, тәмам гасабилана башлаган Сөмбел коенасы булмаса да, елга буена төшә. Хансөяре

башы белән төзелеш эшенә кереп чумды, ә ул гелән берьялгызы. Кайсебер көнне аңа бигрәкләр моңсу булып китә. Шушындый вакытларда Иделкәе аны бигрәк тә тарта, бигрәк тә әйди, дәшә башлый. Бармаса, елгага кереп чумып чыкмаса, төне төн түгел, йокысы йокы түгел, төне буена яман төшләр күреп, саташып чыга. Ахирәте Айгөл исә, минем көмәнем бар, дип, өйдә утыра, булачак баласына кием тегә, бишек җырлары өйрәнә. Ир-канаты Ташбай бәләкәй арба белән бишек тә ясаткан икән. Ә Сөмбелгә торган саен моңсу, җан ачысы белән тулы тойгы-кичерешләре көннән-көн нәүмизләнә, нарасыйлана, әсәрләнә бара, чөнки балага уза алмый интегә. Инде ошбу якты дөньяда яшәү мәгънәсез бер могыйшәткә әверелеп бара. Күңел төшенкелеге йөзенә үк чыкты, иллә ире Хансөяре моны күрми, әллә сукырайды, әллә юри күрмәмешкә салынамы. Сәер хәл, елга буена төштеме, аңа җиңелрәк булып китә. Чәрелти-чәрелти очкан акчарлакларга, яр кырында чөкердәшкән карлыгачларга карап тора-тора да онытылып китә, уйлары еракка-еракка хыялый киләчәккә юнәлә. Ә аның бөтен хыялы — бала табу, үзен дә, Хансөярен дә бәхетле итү иде. Соңгы вакытларда үз-үзенә йомылды Сөмбел, юашланды, бәхетле үткән кыз чагы матур төш булып кына калды. Ә бит дәрманлы егетләрдәй чабып барган тулпарларны йөгәнләр, сикереп атланыр, ир-ат сафында кылычтан алышыр, очкан кошларны уктан алыр, гайрәтле айгырларга аркан ташлар иде. Соңгы вакытта исә Сөмбелнең гүя канаты каерылды. Кайчан һәм ни сәбәпле башланды әле бу төшенкелек?.. Әйе, ахирәте Айгөл килеп, чәйләп утырганда, көтмәгәндә түгәрәкләнеп килгән көмәнен күрсәткәч булды. Көмәнен күрде дә ахирәтенең, гүя Сөмбелнең тәне буйлап яшен чаткасы үтте. Нигә аңарда түгел ул көмән, нигә аны Ходай тәгалә шул бәхеттән мәхрүм итә?!

Йа Раббым, алай ук күңеленә якын алмаган булсачы. Шул мәлдә гүя аның йөзенә камчы белән суктылар, гүя аны урамга куып чыгардылар. Ул әнә шул гап-гади сәламәт һәм һәр хатын кияүгә чыккач була торган көмәннән мәхрүм иде. Аңа Ходай бу Бәхетне бирмәгән микәнни?! Ә менә ахирәте Айгөлгә биргән, җитмәсә Сөмбелнең җанын көйдереп, кай ягы беләндер каплап куйган казанны хәтерләткән көмәнен күрсәтеп, авызын ерып утыра.

— Күр әле, күр әле, ахирәтем, әллә тибешә дә инде. Тибешә, билләһи тибешә. Ташбай малай тели иде, бу тамаша тибешкәч, малай була Аллаһы теләсә,— дип гөлдерн.

Ахирәте Айгөлнең уе баласының кем булуында булса, Сөмбелнең уе әнә шул көмәннең үзендә булмавы кайгысында иде.

Ахыр, беләсе килде: ничекләр сөешәләр, ничекләр якынлык кылалар икән. Бу хакта сорагач, ахирәте гаҗәпләнде, кызарынды, колак яфракларына гүя ут капты, әмма оялмады, йөзендәге нурларына нур гына өстәлде.

— Шуны да белмисеңме, җүләрем? — диде ахирәте Сөмбелгә сынаулы караш ташлап.— Әллә соң аерым йоклыйсызмы? Беләсеңме, мин аның куеныннан да чыкмыйм. Керәм дә эрим инде менә...

— Бергәлеккә бергә йоклыйбыз анысы, ахирәтем,— дигән булды Сөмбел.

— Карале, сөя беләме соң үзе, фәрештә үпкән җиреңне таптымы?

Шаккатмалы иде бу Айгөл, әллә ниләр белә, гаҗәпләнмәслек тә түгел иде.

— Ул кай җирдә тагын? — дип сорады Сөмбел, күзләрен күтәреп карарга оялып, әмма чын вә ихластан, чөнки ул чынлап та фәрештә үпкән җирен белми иде.

— Һи-и, шуны да белмәгәч,— диде җитмәсә борынын чөя төшеп Айгөл.

Менә монысын һич тә көтмәгән иде Сөмбел. Беләм дисә — белми, белмим дисә — оят. Ничек шул хакта сорамак кирәк, аннары Айгөл каян белә ул хатын-кызның фәрештә үпкән нурлы җирен?..

— Белергә белә анысы. Рәсүлемез рәхмәте белән барысына да төшендек, бер-беребезне сөеп туя алмыйбыз.

— Ни житми соң? Балага узмыйсыңмы?

Йа Ходა, сөйләшү бу кадәр тирәнгә китәр дип һич тә уйламаган иде Сөмбел, сүзне тизрәк икенчегә борырга теләп, табындагы ризык-нигъмәтләрне кузгаткалап куйды.

— Әйдә, житешеп утыр әле, Айгөл. Чәкчәгенә дә үрел, аша, сез хәзер икәү ләбаса, ятсынып торма. Әнә хәлвәсеннән дә авыз ит, бик тәмле, Бохара сәүдәгәреннән алдым, имамыбыздан өшкертеп китердем,— дип мактады.

— Сәүдәгәрләргә ышансаң, алар мактарлар, мүкне бал итәргә дә күп сорамаслар. Мин хәзер базарга чыкмыйм, ахирәтем, Ташбай йөри. Өше дә шул булгач. Мин үзем төшсез йөзем яратам. Хәзер базарда бар да бар, Аллага шөкер. Беләсең килсә, ахирәткәем, балага узгач, әллә ни булды үземә — үлән ашыйсым килә башлады. Яз көннәре иде. Сөярби житешкән чак — аны ашадым, күңел теләми башлады. Аннары ниндидер жөнле күкәй ашадым. Жирдә үсә. Зур да түгел үзе. Аннары кузгалак, балтырган.

Ахирәте әйткән бер үләнне дә яхшылап белми иде Сөмбел. Ул далада үсте ләбаса, ә Айгөлнең әтиләре Сувардан күчеп килгәннәр иде. Әллә нинди жөнле күкәйләр, житмәсә жирдә үсә. Ул нинди ризык тагын? «Әллә шуларны ашамаганга балага узмыйммы?» — дигән шиккә калды Сөмбел. Ләкин: «Тагын ни ашадың?» — дип сорамады, сер бирмәде. Үлән ашап кына балага узсаң икән ул...

— Ярый, амин тотыйк инде, ахирәтем. Үзең дә кил. Йә Ташбаем кайтыр. Беләсеңме, ул кайчак, жүләрем, көндезен дә мине тансыклый.

— Тәнең оялмыймы соң?

— Китсәнә, ахирәтем. Изге теләк лә ул. Нинди ояты булсын ди изге теләкнең... Йә, хуш, мин китим инде. Үзең дә килеп утыр шулай...

Ахирәте Айгөл китте, әмма Сөмбел күңеленә тау-тау шом салып китте. Балага узыйм дисәң, әллә нинди үләннәр ашарга, ирең синең тәнеңдәге фәрештә үпкән жирең табарга, яратышканда көя күбәләге кебек янарга кирәк икән. Хансөяре назлаганда вә сөйгәндә Сөмбел янмадымы?.. Янды. Хәтта кочагында эреп киткәндәй тоя иде үзен, әйтерсең лә Хансөяренең аңа булган мәхәббәте кояш, ә ул нур астында яткан балавыз иде.

Ә шулай да Сөмбел үлән ашарга булды — атна буена урманга йөрде, елга буендагы әрәмәгә керде, төрле үләннәрнең тәмен татып карады, хәтта катып беткән, инде чәчкә атып койган сөярби үләнен дә тапты, тазартмый-нитми авызында әчкелтем-төче тәм тоеп, чәйнәп йөрде.

Урманга, әрәмәгә ни өчен йөрүен ир-канаты Хансөяргә әйтмәде. Юк, ул аңардан курыкмады, Хансөяре аңлаган булыр иде, мөгаен. Ул илаһи, әдәпле, инсафлы, игътибарлы, тәүфыйклы, Аллага шөкер, ул яктан бәхете мөлдерәмә тулы. Тик менә икенче яктан?..

— Син урманга берүзең йөрмә. Угырларга тап булуың бар,— диде Хансөяр көннәрдән беркөнне, аның урманга йөрүен әллә берәрсеннән ишетеп, әллә үзе күреп.

— Алар миңа тимәсләр, куркырлар. Мин коралсыз йөрмим.

— Корал белән генә әллә ни кыра алмассың. Угыр беркайчан да берүзе генә йөрми. Аннары син хатын-кыз...

— Минем алыптай егетләргә каршы торганым бар, Хансөяр. Борчылма минем өчен,— дип турсайган иде Сөмбел.

— Әллә үпкәләдең инде? Бәхәсләшмим, син кыю хатын. Бер түгел, ике-өч егеткә каршы торырлык. Кил әле минем белән көрәшеп кара. Кил инде, кил.

— Син мине күптән жиндең инде, Хансөяр. Тик...

Килде, янәшәсенә басты, иреннәре белән муенын үпте, назлап кына колак тәңкәсен тешләп алды, үбә башлады.

— Мин сине яратам, яратам, Сөмбелем, үлепләр яратам...
— Мин синнән малай көтәм, Хансөяр. Әнә Айгөл өлгертеп ята инде.
— Мин беләм, Ташбай әйтте. Син дә миңа табып алып кайт.
— Каян? Урманнанмы?
— Урманда булса, урманнан.
Ни әйтә ала иде иренә Сөмбел? Һични. Иң әүвәл ул курыкты, коты алынды. Ире дә бала тели икән ич, ул гына түгел!
— Мин бүген әче какымы, сөярби диләрме, шул үләнне табып чәйнәп йөрдем. Әче дә, татлы да кебек үзе.
— Көз көнендә нинди сөярби булсын ди.
— Шул үләнне ашасаң...
— Нинди үләнне, Сөмбелем, ни сөйлисең син!.. Тәмлеме соң үзе?
— Телең йотмалы.
— Телең дә йоттыңмы?
— Менә ич телем, йотмадым, сиңа да калдырдым,— диде Сөмбел, телен чыгарып күрсәтте.
Хансөяр аның телен тешләмәкче итте, Сөмбел ашерде. Көлештеләр. Аннары ир-канаты ишекъяры барып, келәне эләктереп килде.
— Хансөяр, нишләвең бу? Көпә-көндез! Ничек оялмыйсың?!
— Изге эшнең оятлы юк,— диде Хансөяр, Айгөлнең сүзләрен кабатлап.
Ир-канаты аның нечкә билен, зифа гәүдә-сынын, эчкә батып торган кендеген шул көнне күрде. Сөмбел башта оялды, үз-үзен кая итәргә белми куырылып килде, бары тик ир-канаты татлы итеп нәүмизләнәкинәнә назлый башлагач кына, таралып китте. Көпә-көндез булса да, сөелде-сөйде Сөмбел, оятлы турында да онытты...

Шуннан ул тагын елгага — су буена төшә башлады.
Ул үзе дә белми ни өчен күңеле су буена тартканын. Ләкин төшми дә булдыра алмады. Һәр көнне көн уртасы җитүгә, Иделгә юнәлә, ә асраулары, хезмәтчеләре түрә хатынына аптырап карап калалар. Чөнки инде берәү дә елгада коенмый, су шактый суынган иде. Сөмбел дә коенмады, бары тик итекләрен салды да тубыклары күмелгәнче суга керде, бармакларын маймычлар кытыклаганга рәхәтләнеп торды, ә кайчак кычкырып җибәрәсе килә иде. Кемгәдер зарланасы, кайгы-хәсрәтен уртаклашасы. Шунда ул яр сөзәк җирдән төшеп килүче җайдакларны күрде. Нигәдер ул алардан курыкмады. Гадәттә, азамат егетләр еш кына атларын эчерергә төшәләр һәм шуклашып, куышып-узышып киләләр. Яр сөзәк җир урман яклап, чакырым тирәсе ара. Кояш әле баемаган, ләкин яр астында эңгер түшәлә башлаган инде. Җайдаклар якыная башлагач, Сөмбел комлыкта яткан итекләренә күз төшереп алды. Ләкин ни сәбәпледер судан чыкмады. Ир-канаты кала тарханы вә түрәсе Хансөяр әмир Хажидан базарбаш соратып алып, Ташбай угланны атакай итеп билгеләде, ул хәзер үзенә азамат егетләр җыя, аларны хәрби уеннарга өйрәтә иде, шулар дип белүе иде. Вәләкин егетләр якыная башлагач, эчке бер тоемлау белән сизде, аңа таба ят кешеләр килә — киемнәре генә түгел, ат-кораллары да үзгә. Сөмбел соңгы мәлдә ашыгыбрак судан чыкты, итекләрен кия башлады. Киде һәм торып басам гына дигән иде, колак янында ук ярсып йөрәк каккан ат сулышын тойды. Алдагы җайдак чаптырып килә-килүгә, аны эләктереп тә алды, күтәреп ияренә дә аркылы салды. Сөмбел хәтта кычкырырга да өлгерә алмый калды. Батыр егет атын борды һәм җан-фәрман урман ягына чапты. Сөмбел моны чамалап белде. Аркылы төшкәнгәме, Сөмбел кычкыра алмады, кычкырса да тавышы чыкмады, хәер, чыкса да берәү дә ишетмәс иде. Капланып ятудан аның күңеле болганды, аяк-кулына терәк эзләп чәбәләнә башлады. Кыз урлауда бик күп егетлекләр күрсәткән Түкә Тимер йөзбаш кулыннан ычкыну мөмкин түгел иде. Бары тик урманга кереп кергәч кенә, йөзбаш Түкә Тимер атын туктатты һәм егетләренә кызны иярдән алырга кушты.

— Бачман баһадир кызы Сөмбел,— диде йөзбаш Түкә Тимер төрек сүзләрен вата-җимерә.— Сәне без Күлкән угланга алып кайтырмыз. Ул бик каты сырхаулый, Сүбәдәй баһадир, син дәваларсың, дип өмет итә. Үзең атланып барасыңмы, бәйләп салыйкмы?

Ике аягы белән каты җиргә баскач кына, булган хәлнең асылына төшенде Сөмбел, гәрчә башта ук яманлык сизгән булса да. Әйе, аны урладылар. Һәм Сүбәдәй баһадирның башкисәр егетләре урлады. Елга буена алты-җиде генә җайдак төшсә дә, урман авызында йөзгә якын яугир көтеп торган икән. Барысы да авызларын ачып, Сөмбелгә карыйлар. Кулында һичнинди коралы юк, булган хәлдә дә һични кыла алмас иде. Бермәлгә чарасыз калды. Өметсезлектән чак кына җылап җибәрмәде. Кычкырсаң, һич булмас димә, авызыңа чүпрәк тутырып, бәйләп атка салачаклар. Бердәнбер чара — үзе атка атланырга һәм карусыз алар теләгән җиргә барырга.

— Китерегез атыгызны, меңбаш Түкә Тимер.

— Бачман баһадир кызы мине белә! — дип гаҗәпләнде Түкә Тимер.

— Белә, йөзбаш, белә. Сүбәдәй баһадир Бачман баһадир кызы артыннан җыен әтрәк-әләмне җибәрмәс. Кыз урлауда, кеше җәбәрләүдә сиңа житкән яугир юк дигән яманатың йөри. Мине Күлкән углан биш бәлеш алтынга сатып алганда син дә бар идең.

— Бар идем, хак,— диде кинәнеп Түкә Тимер.

— Сиңа шунда Күлкән углан унбаш Түкә Тимер дип дәшкән иде.

— Дәшкән иде, Бачман баһадир кызы, дәшкән иде, хәзер мин йөзбаш, Күлкән углан иямдер. Атландырыгыз әсир кызны атка!

— Мин үзем атланам, йөзбаш Түкә Тимер.

Кузгалуга, йөзбаш Түкә Тимер атын Сөмбел белән янәшә алып китте.

— Куркасың, йөзбаш?

— Кисәтеп куям, Бачман баһадир кызы, качам дип уйлама. Үзем Болгар җирендә ятып калсам калырмын, әмма сине исән килеш бирмәм. Күлкән углан син киткәннән соң саргайды, йөзендә нур калмады. Сине таптыра да сине таптыра.

— Мин табиб түгел, йөзбаш.

— Табиб син, Бачман баһадир кызы, табиб. Атаң Бачман баһадир каласын билгән өчен Сүбәдәй баһадирдан үч алды, илгә озаткан барлык байлыгын кире талап алып калды.

— Үз байлыгын кайтарып алу талау була димени?!

— Ул мал-байлыкка Саксин кебек ике кала салып булыр иде. Хак, бер каласын салып та ята. Тик баһадир үзе калада юк, диделәр.

— Минем синең белән сөйләшәсем килми, йөзбаш. Син мине урлап алып киттең. Көчләп бәхет килми.

— Син сайрар кош, сандугач, Бачман баһадир кызы. Сайрар кошны читлектә тотучылар да бар. Читлектә утырырсың.

Сөмбел сырхаулап яткан Күлкәнне күз алдына китерергә тырышты. Болгар азамат егетләре килеп, аларны азат иткәндә Җүзәкәй яугирләре белән сугышканда да, тегеләр җиңелеп, кан эчендә ятканда да Күлкән кычкырмады. Һәм курыкмады да бугай. Аңа барыбер иде кебек. Тик әнисе белән Сөмбелне алып чыгып киткәндә генә, торырга, нидер әйтергә ымсынгандай итте. Иллә барыбер кузгалмады, бары тик күзләре генә яшь белән тулды. Ул иреннәрен кыймылдатып, Сөмбелгә: «Китмә, китмә, Сөмбел!» — диярге җыендымы, дидеме. Бәлкем шуңа, Сөмбел Күлкән өстенә ыжгырып килгән хан оныгы Хансөярне туктаткандыр. Ул мәлдә авыру Күлкәнне кызганса да, дошман күрде. Шуңа да карамастан, Хансөяргә аны үтерергә ирек бирмәде. Ни өчен? Үзе дә белмәде. Һәм ир-канатын тыеп калуда беркайчан да үкенү тоймады. Хәзер исә үзен урларга кишектиннәрен җибәргән өчен ул аңа ачулы иде. Хак, ул аңа үлем теләмәде, шул ук вакытта нәфрәтен дә яшермәде.

— Шунда туктыйбыз, елганы таң аткач кичәрбез,— диде йөзбаш Түкә Тимер, Иделнең яр башына туктап, атыннан төште.— Төшегез, ял итегез, байбичә.

Урланган хатын-кызларның үз-үзләренә кул салганнарын, суга ташланганнарын күп ишетте Сөмбел, ә менә үзен дә урларлар дип һич кенә дә күз алдына китермәгән иде. Бу хәлне кеше авызыннан ишеткәндә урланган кызлардан көнләшү кебек ят хис туар иде. Бары тик. Юк, үз-үзенә кул да салмас, суга да батып үлмәс. Ул аның каршына барыр һәм аны яратмавын турыдан-туры күзенә бәреп әйтер. Җыласын, аягына төшеп тәгәрәп үлсен, нә тәнен, нә җанын бирмәс. Ни өчендер Сөмбел Күлкән угланнан курыкмый иде. Теге вакытта өстенә атланып, кул-аякларын бәйләп, авызына чүпрәк тутырып киткән мәлен күз алдына китерүгә, хәтта чак кына кычкырып көлеп җибәрмәде. Ни генә булмасын, йөрәгенең түрендә авыру вә сырхау угланга карата кызгану хисе ята иде. Шул ук вакытта белә иде: аның сөйгәне бар — Хансөяре. Башка аңа һичкем кирәкми! Ул аны үлепләр ярата, ансыз торуны күз алдына да китерә алмый. Тик бит әле аны Хансөяреннән урлап, канатларын каерып алып киттеләр. Ул хәзер урланган кыз гына түгел, әсир ителгән хатын ләбаса... Күлкәннең атасы — алар өчен кан дошман, Сөмбел күңелендә Күлкәнгә карата ачы нәфрәт булмаса да. Аны хәзер Күлкән тарафына алып кайталар. Инде нишләргә тиеш булачак ул? Иделне кичкәндә суга ташланыргамы? Аны бәйләмәделәр, күз карасы кебек сакласалар да, кул-аягы иректә ич!

Гадәти йокы. Иярга баш куеп кына, урланган халәтең белеп, йокыга китә алсаң икән. Хансөяре нишли икән анда? Хезмәтчеләре, Идел буена төшеп китте, дигәч, йөгереп елгага килгәндер. Сөмбел, Сөмбелем! дип кычкыргандыр. Йокламады, күзләре генә камашып алды бугай, аны уяттылар да. Берничә корт һәм кымыз бирделәр. Сөмбел теләр-теләмәс кенә эчте, тозлырак корт кисәкләрен авызына капты. Ул әле булган хәлгә һаман ышанып җитми иде. Гелән төшендә генә кебек. Урманнар, таныш болыннар, әрәмәлекләр, тугайлар артта калды. Иделне кичкәч, бик озак нинди дер тарлавыктан бардылар. Аннары далага килеп чыктылар. Дала таныш иде Сөмбелгә. «Хансөярем, кая син! Батыр Ташбай, нигә син азамат егетләрең белән дошманны куа чыкмадың? Куып җиткән, тапкан булыр идең әле»,— дип үртәлде Сөмбел, иксез-чиксез дала киңлегенә күз ташлап.

Дулкынланып торган тоташ кылганнар арасыннан көнозын бардылар. Атлар җилле юыртты, йөзбаш Түкә Тимернең тизрәк калага җитәсе, Сүбәдәй баһадирга: «Йөгең үтәдем, баһадирым!» — дип әйтәсе килә иде, күрәсең. Булдырды бит, урлады бит Бачман баһадир кызын, сүзен сүз итте. Әйе, мактанырлыгы да бар икән шул.

## 44

Бачман баһадир кызын урлап алып кайттык, дип сөенче җиткергәч, Күлкән угланнан битәр, Сүбәдәй баһадир ныграк кинәнде. Кызны алып кайткан яугиргә бил каешын салып бирде, кочаклап үпте. Гомер булмаганны кыланды Сүбәдәй. Кыланырлыгы да бар иде — Бачман баһадир кызы аның кулында, димәк, Күлкән углан аякка басачак, чөнки сырхау бала: «Сөмбел, Сөмбел»,— дип авызыннан да өзми иде. Инде, һичшиксез, угланны Бачман баһадир кызына өйләндерәчәк. Киядә булган — моңа, гомумән, игътибар итмәде Сүбәдәй. Бал искерми — кыз картаймый. Аның кулында җитмеш гүзәлгә торырдай кыз бала иде. Калганын вакыт хәл итәр. Бәлкем әле, тәкәббер баһадирның кодасы ук булыр. Ул аңа угланын өйләндерер, кала имамыннан никах укытыр, аннары шәрәфәтле бикә белән тәкәббер баһадирны туйга дәшәр. Кил-

сәләр — яхшы, килмәсәләр дә, исе китмәс, туй барыбер булыр. Аннары угланы да, ниһаять, тынычланыр, терелер, йөзенә нур кунар. Югыйсә аштан калды, саргайды, чак кына кузгатсаң, сөякләре шылтырар сыман. Күлкән угланны Котбый меңбаш тәрбияләде, ислам динен кабул итәр, әле дә авызыннан Аллаһысын вә Раббысын төшерми, мөгаллиме Котбый үз дигәненә иреште, хәерлегә генә була күрсен. Инде инанды Сүбәдәй: Болгарга кул сала алмастыр. Болгарны өч-дүрт төмән яугир белән генә яулыйм димә. Ә менә Саксинны Күлкән угланына биреп калдырыр. Ары таба уйларга куркынычрак иде. Чөнки үҗәт вә үз көченә нык ышанган тәкәббер Бачман баһадир һаман тынычлана алмый икән әле. Шымчылары житкереп торалар, Тәңре шаһит. Дөрес, Бачман баһадирның, ул киткәч, килеп Күлкән угланны үтерүе дә бар. Ләкин имам хәзрәтләре үзе никах укыган һәм кавыштырган гаиләне бозарга ирек бирерме? Бирмәве дә бар, чөнки кыска гына вакыт эчендә Сүбәдәй сәүдә эшен җайлап җибәрде, халыктан җыясы ясакны бермә-бер киметте. Аннары үзе белән килгән татарлар да ислам динен кабул иттеләр, күпләре ялгыз хатыннарга йортка кереп, яшәп яталар. Котбый мелла тырыша, Сүбәдәйне Саксин халкына яман итеп күрсәтергә теләми иде. Сүбәдәй үзе дә, ислам динен тәгаен кабул итмәсә дә, мәчеткә кергәли, дога укый, белмәсә дә кушуч белән сакалын сыпырып утыргалый. Шәригать кануннарын таныган өчен үзе белән килгән татарларны биредә калдырырга булды Сүбәдәй. Дөрес, ул әле бүген-иртәгә генә Каракорымга чыгып китәргә җыенмый, әмма алдан уйлаган уй хәерлегә була, диләр бит, уйлап кую зыян итмәс. Шуның өчен үткән атнада хәлифәгә бүләкләр төяп, илчеләр җибәрде. Моны ул кала имамы киңәше белән эшләде һәм ялгышмады бугай, күрде-күзәтте: Саксин халкы аңа ул хәтле нәфрәт белән карамый башлады.

Сүбәдәй һаман исә урында яткан углан янына керде һәм:

— Сөмбелең монда, алып кайттылар,— диде.

Углан башта торырга дип калкынды, әмма куәте житмәде, күз яше белән елап җибәрде. «Менә монысы кирәкмәс иде»,— дип уйласа да, Сүбәдәй угланга бер сүз дә әйтмәде. Углан ятагы янындагы түмәргә утырды.

— Ул-л, би-иредә то-орыр, атам,— диде яшь аралаш Күлкән углан.

— Торыр, торыр, каравыш кызлар куярбыз.

— Ю-ук, кирәкми каравыш кызлар, атам, беркем дә кирәкми. Ул үзе генә торсын. Күрше бүлмәдә йоклар.

— Якшы, син дигәнчә булыр. Тынычлан. Әле кайтып кына килә. Сөенче генә житкерделәр. Иртәгә биредә булыр. Монда аның сөт инәсе бар икән, шуңарда берәр көн ял итәр, аннары алып килербез.

— Мин йоклый алмам инде, атам.

— Ә син сана. Котбый мөгаллим сабак биргәндә өйрәткән саннарны кабатла да кабатла, кабатла да кабатла.

— Якшы, шулай итәрмен, атам.

Борчулы иде углан. Ярасы да онытылды, ә бер дә алга киткәне юк. Меңбаш Котбый, углан гашыйк, дип бара. Шул да булдымы чир. Гашыйк, имеш. Гашыйк кеше күзгә күренеп сүреләме, әйтерсең кемдер канын суыра иде. Атасы кебек каз каны эчсә иде ичмасам. Каз каны түгел, Котбый мөгаллиме чучка ите бирергә дә кушмый. Ярамый, имеш. Авызыннан кире килмәс иде әле. Каракорымда бик исәпләшеп тә тормас иде, һичьюгы сагындырыр иде, монда ярамый, халыктан яхшы түгел.

— Иртәгә керер, диденме әле, атам?

— Иртәгәме, берсекөнгәме булыр, кайта инде, кайта. Сөенәсе ит, сытылып ятма.

— Мин куанычтан җылыйм, атам.

Күлкән тагын нидер әйтергә теләде, әмма әйтмәде, атасына карады. Угланның күзләре эчкә баткан, яңак сөякләре төртеп тора иде.

— Атам, җомга көннәрдә булса да мәчеткә йөрисеңме?

— Баргалыйм, олан, баргалыйм. Син сакалың кырдырыр идең, углан. Кәләш кетәсең, ә ул гүзәл бала, күз алмалы түгел.

— Чибәр,— диде бер сүз белән Күлкән һәм юка иреннәре елмаюга җәелгәндәй итте.

— Аннары чәчең дә алдыр. Килешлерәк киемнәр ки. Син, углан, үпкәләмә, яугир түгел инде син хәзер, кияү егете.— Күлкән углан янә нидер әйтергә дип авызын ачты, мәгәр янә әйтмәде.— Котбый меллаң янында кунамы?

— Куна, рәхмәт ана,— диде олан.— Мин барысын да син дигәнчә эшләрмен, атам.

«Бу ни хәл инде, нинди җебегән углан табып бирде мина Сөябел? Кемгә охшап шулай бетеренке бу олан?» — дип уйлады Сүбәдәй, ишеккә таба кузгалгач. Бер уйлаганда, ис китмәле хәл иде. Атасы «корыч» кушаматы йөртә, ә угланы урыныннан кузгала алмый ята. Әмма хагынахагы күз алдында — углан аныкы, күзе-йөзе, гәүдәсе-сыны, дигәндәй, хәтта сөйләшү гамәле дә. Кызык, Ташбае кемгә охшаган икән? Ул угланны меңбаш, диделәр. Ул болай җебеп тормыйдыр, Карлыгач кебек ут өерәдер. Карлыгач анасы сөя дә, сөелә дә белә иде. Сүбәдәй аны шул чикләргә җитеп яратты, шашам ахры, дип курка калыр иде, әле булса күз алдына килсә, тәннәре чымырдап китә. Хикмәт, кеше гомерендә гелән кабатланмас мизгелләр дә була икән. Сөябел катында ул беркайчан да шундый халәттә калмады. Ә Карлыгачта исә, әйтерсең, ниндидер мәхәббәт сихере бар иде. Гел күз алдында. Сөябел исә гелән булмаган да кебек. Дөрес, кайчак көчләгән мәле күз алдына килеп китә. Тик шул хәлдән соң кәеф кенә кырыла. Сөябелне көчләү мәлен Сүбәдәй һәрчак оялып күз алдына китерде. Әйе, рәнҗетте ул аны, мәсхәрәләде. Бәлкем, шуңа аны Сөябел өзелеп көтмәгәндер. Өчәр-дүртәр ел йөреп кайтыр иде, ә ул ичмасам бер тапкыр да юрта алдына — каршысына йөгереп чыкмады. Ә менә никахсыз хатыны Карлыгач, кайтып төшсә, юртадан йөгереп чыгар, килеп өзәңгесенә тотыныр һәм күзләренә карап: «Ашарга әзер, Сүбәдәй, әйдә, кер»,— дияр иде. Бары тик шул. Әмма шуңа да Сүбәдәйнең җаны эреп китәр иде. Әйе, татар кызлары әнә шулай әсир иттеләр магул батырларын. Мөлаемлек идеме бу, гыйффәтлелекме, тыйнаклыкмы, әмма нәкъ шул сыйфатлары белән җанны эретерләр иде. Магулларның күбесе татар кызларына өйләнеп, тегеләр ирләренә итәк тотырып бала үстерәләр иде. Шуның өчен магул нойоннары вә батырлары татар кызларына өйләнү өчен мал да, байлык та кызганмадылар. Бу хәлдән хәтта атаклы Чыңгыз хан да читтә калмады, туталы-сеңелле татар кызларына өйләнде. Хәер, Чыңгыз ханның атасы Йүзәкәй баһадир да татар кызына өйләнгән була, Чыңгыз ханның үзендә дә татар каны ага иде. Сүбәдәй дә әнә бу хәлдән читтә кала алмады — яу йөргәндә булса да татар кызына тап булды һәм өйләнде, тегесе хәзер аңардан читтә аның баласын үстереп, балигъ иткән. Сөйләделәр Сүбәдәйгә, Йүзәкәй баһадир татарларга каршы яу йөри, бер татар батырын әсир итә. Ул аны богаулап җәйләвенә алып кайта. Татар батыры аның унлап егетенең башына җиткән була. Тимерҗан атлы бу батырны алып кайткан көнне Йүзәкәй баһадирның беренче баласы туа. Һәм җитмәсә малай. Йүзәкәй баһадир әлеге батырның көч-гайрәте, җан-куәте угланына күчсен дип, татар батырын үтерә һәм аның исемен үз угланына куша — Тимерҗан. Соңыннан Тимерҗан Чыңгыз ханга әверелә, даны ерак-ерак илләргә тарала һәм аның данын таратучы янә Сүбәдәй. Шуннан соң татар батырының гайрәте исеме белән бергә Чыңгыз ханга күчмәгән дип әйтеп кара!..

Күлкән аты да ару, кайчандыр, нәселләрендә шундый атлы батыр булган, тик әллә нигә угланы бер дә батырга тартмый. Шуңа да карамастан, ул аның угланы, аның каны. Ташбаен әллә таба, әллә юк, Күлкәне

исә янында. Ул аны сәламәтләнү белән Бачман баһадир кызына өйләндерер һәм калада тархан итеп калдырыр. Бары тик шул.

## 45

Күлкән аны көтте, төшләрендә күрде, төннәр буена күз алдыннан җуя алмыйча, түшәмгә карап ятты. Биш бәлеш алтынга сатып алган каравыш кызына шулай гашыйк буласын белгән булса, бик ихтимал, алмаган да булыр иде. Иллә алмыйча да булдыра алмады шул. Күрде дә капланды. Биш бәлеш алтын гына түгел, ун, унбиш бәлеш алтын түләргә риза иде. Күрде дә гүя дөньясы асты-өскә килде, йөрәге тәгәрәп аяк астына төшеп китте, күзен ала алмас булды. Ул баштан ук ялгышты. Имеш, кызны көч белән яулый. Ә ул кыз әнә кем баласы булып чыкты, шуннан кызда тәкәбберлек, шуннан чаялык һәм кыюлык. Хәтта каравыш кыз дип белгән чакта да ул барысына да риза иде — изсен, сытсын, кул-аякларын бәйләсен, ниһаять, ат кебек тышаулап ташласын, тик китмәсен генә иде. Ә ул качты, китте. Ә инде Бачман баһадир кызы икәнен дә белгәч, Күлкән тәмам чиргә сабышты. Шуннан ул аны эзләргә кереште. Тапты. Куанычыннан нә кылырга белмәде. Һәм тагын югалтты. Чакырган булса, ул аның белән җәһәннәмгә китәргә дә риза булачак иде, чакырмады. Хәер, хәле-гамәле дә аның белән китәрлек түгел иде, җитмәсә кул сала яздылар, әле дә ул кыз саклап калды, ул тидертмәде.

Егет яралы иде, ярасы бетте, җөйләнде, ә менә рухи хастасы төзәлмәс чиргә әверелде. Каты яралы чакта да Күлкән яра әрнешүеннән ыңгырашмады, әрнүе йөрәк ярасыннан — Сөмбелне югалтудан иде. Бу мәхәббәт ярасы иде. Аның мәхәббәт ярасын беренче булып мөгаллиме Котбый күрде. Башта ул, үтәр дип булса кирәк, егетнең атасына әйтмәде, соңра Күлкән һаман саргая, сүрелә башлагач, әйтми дә булдыра алмады.

Котбый мелла Сүбәдәй баһадирны бәрелер-сугылыр дип уйлаган иде, тегесе исә меңбашын шаккатырып, угланның хәленә керде, кызны урлап алып кайтырга иң елгыр егетләрен җибәрде. Кызлар урлый-урлый халык теленә чыккан Түкә Тимер озак көттерми йөз яугире белән чыгып та китте.

Түкә Тимернең Сөмбелне урларга китүен ишеткәч, Күлкән беренче тапкыр урыныннан торды, барып, тәрәзәдән карады. Рабигыль-әүвәл аеның башы иде. Үләннәр саргайган, анда-санда пәри тубалы тәгәри, гүя бер-берсен куышалар. Кем куа үзләрен? Көзге җилләр. Тик менә адәм баласын кем куа икән? Ни эзли, ни җитми аңа? Җир-җәйләүме, елгаларымы, иге-чиге булмаган даламы? Күлкәнгә ошбу яклардагы дала ошый иде. Ни өчен? Сөмбел монда туган вә үскән булгангамы? Сөмбелне күргәч, саргая башлаган дала да аңа хозурлыгын җуймады. Һәр шайтан таягында, һәр чәчкәдә, һәр кылганда, хәтта әрем куакларында да Сөмбелнең йөзен күрде. Ни булды аңа, кай ягы белән сихерләде аны Бачман баһадир кызы? Ятса — ул, торса — ул. Йөзенә зәгъфран төсе иңде, моңсуланды, үз-үзенә йомылды, гүя уй-хис ташкыны эченә кереп чумды. Кем әйтә алар икән гашыйк кеше дивана түгел дип?! Дивана ул, әмма гакыллы дивана, инсафлы вә тәүфыйклы. Гашыйк адәм беркайчан да башкаларны рәнҗетмәс, җәберләмәс, тел тидермәс, нәкъ шул мәлдә күккә ашар халәттә була, нәкъ шул мәлдә ул зур ачышлар, тиңе булмаган могҗизалар ясарга сәләтле затка әверелә. Гашыйкның иңендә көн-төн изге фәрештәләр утырыр, ди. Һәрхәлдә, шулай ди Котбый мелла. Ул бәян иткән «Фатиха», «Фил», «Күрәем», «Магун», «Кәүсәр», «Кафирун», «Насыр», «Тәббәт», «Ихлас», «Фәләкъ», «Нас», «Сөбһанәкә», «Әттәхияту» сүрәләрен, Аллаһүммә салли, Аллаһүммә барик, Рабббәнә, кунут, әмәнтү, аятел-көрси догаларын кем өйрәтер иде. Сүрәләрне күңелдән уздырганда, догаларны укыганда Күлкән күңеленә нур өстенә

нур коелганны тоя, гүя аның иңендә чынлып та фәрештәләр утыра иде. Сүрә-догаларга тирәнтенрәк төшенә барган саен Күлкән атасыннан ерагая барды. Инде бик күп нәрсә хакында ул аның белән килешми, тик бу хакта күзенә бәреп: «Атам, син ялгышасың!» — дип әйтергә генә кыймый иде. Атасының атнага ике-өч тапкыр каз каны эчүе, кулын-авызын чайкамыйча табынга утыруы аның тәмам җанын кыйный иде.

Менә бүген дә, сөенче әйтергә кергән атасының кул аркасында каз каны күреп, йөзен чыткан иде. Ә бит, шәригать кануннарын өйрәнгәнче, атасының бу хәленә гелән игътибар итми иде. Ул аның тизрәк чыгып китүен теләде. Ә инде атасы чыгып киткәч, көрсенеп куйды.

Бик ихтимал, нәкъ менә шуның өчен Сөмбелне алып кайту сөенчесен кинәнеп каршы алмады, куанычын күрсәтә башласа да, тыелып калды. Атасы чыгып киткәч, Күлкән урыннан торды, тәрәзә канатын ачты һәм дала яклап искән саба җиленә йөзен куйды. Беренче тапкыр шатлыгы күкрәгенә сыймас булды,- ихтыярсыздан: «Сөмбелем, Сөмбел!» — дип сөйләнде...

Углан Күлкән янына аны беренче көнне үк алып бармадылар. Сәер хәләттә иде Сөмбел. Ул беренче көнне инәсе янында кунды. Елаштылар, серләштеләр. Ишекъяры ике сакчы, йортта дүрт-биш яугир йөри. Сөмбелне саклыйлар. Сүбәдәй баһадир сакчыларын нык кисәткән, күрәсең, хәтта тәрәзәгә күз төшергәләп алалар, әйдәме, янәсе.

Икенче көнне Сөмбелне Күлкән янына алып килделәр. Сөмбел аның белән тыенкы гына исәнләште. Күлкән исә бер терсәгенә күтәрелеп, аны каршы алды, хәтта саргайган йөзенә алсу нур кунды.

— Мин сине көттем, Сөмбел,— диде Күлкән.

Сөмбел ияк каккандай итте дә үз бүлмәсенә узды. Кәрә-керүгә, ятак бүлмәсенә күз йөртеп чыкты. Бернәрсәсенә дә кагылмаганнар, сөлгесенә кадәр элгән җирдә тора, урындыгы да үз урынында. Сөмбел ятагына утырды, бертын тәрәзәгә карап торды. Ахшам намазыннан соң ана бавырчы аш китерде һәм Сөмбелне күрде дә аһ итте. «Балакаем, син каян, кем алып килде?» — дип сораша башлаган иде, Сөмбел иреннәренә бармаган куйды, янәсе, шым бул. Шуннан соң кычкырып:

— Мин яратмаган аш китергән булсаң, ашамыйм,— диде.

Бавырчының ике күзе дүрт булды, табагын һәм китергән ризыкнигъмәтләрен кечкенә өстәлгә куйды да пышан гына:

— Сөбханалла-машалла, балакай, нинди җилләр ташлады үзеңне?.. Ярый, әйтмә. Утыр, аша, ашың суынганчы,— дип, борылды да чыгып китте.

Бавырчы Сөмбелнең нинди аш ятратканын белә иде, һәммәсен дә китерде, чәй янына бавырсагын да, балын да, хәлвәсен дә куйды. Тамагы ачкан икән, Сөмбел һәммәсеннән дә авыз итте, туйганчы ашады, шуннан соң гына, гадәттәгечә, көмеш кыңгыравын зеңләтте. Хезмәтче керде, күкрәгенә кулын куеп, баш иде.

— Нә йомыш, байбикә?

— Нинди байбикә булыйм мин, нигә миңа алай дисең?

— Сүбәдәй баһадир шулай дәшәргә кушты, байбикә.

Бавырчы керде, бушаган савыт-сабаларны алып китте, хезмәтче хатын таз белән комган китереп, авызын чайкатты, кулларын юдырды.

— Күлкән угланны ашаттыгызмы?

— Ашамый ул, әллә нигә тамагыма аш үтми, дип зарлана.— Бавырчы Сөмбелнең колагына иелә төшеп:— Бүген азрак чемченеп утырды ичмасам,— диде.

Сөмбел тәрәзә каршына кучеп кенә утырган иде, ике мөриден ияртеп, Котбый мелла килеп керде.

— Әссәламегаләйкем! Төкле аягың белән, балакай. Әйем, төкле аягың белән,— дия-дия, түр яктагы түмәргә барып утырды, мөридләре кырпача җәйгән киезгә тезләнеп дога кылдылар.

— Вәгаләйкем әссәлам, мелла,— диде Сөмбел.

— Дога кылыйк, балакай.

Дога кылдылар. Котбый мелла тамак кырды, сакалын сыпырып куйды, аннары йокы бүлмәсенә күз йөртеп чыкты.

— Рәхмәт инде Күлкән угланга, һичбер нәрсәгезгә тидермәде.— Дисбесен тарта башлады.— Сөбханәкәл-лаһүммә вә бихамбикә вә тәбарәкәмүкә вә тәгалә җәддүкә вә җәллә сәнаукә вә лә илаһә гайрүкә. Ягъни, балакаем, сәне мактыйм. Аллаһым! Сәне бөтен кимчелек сыйфатлардан пакълаем вә сәңа хәмд кылып, гел мактауда булырым. Сәнең мөбарәк исемең бик тә бөектер. Килеш, балакай, язмышның белән. Сәнең өчен бер егет саргая. Кер хәленә. Кулыңнан килгәнне эшлә. Раббәнә атина фиддунья хасәнәтен вә фил ахирәти хасәнәтен вә кыйна газабеннар. Ягъни, Әй, Раббымыз! Безгә дөньяда игелек бир. Безне җәһәннәм газабыннан рәхмәтең белән коткар. Хисап көне килгәч, мине вә атамны вә мөселман кардәшләремне ярлыка.

Кая кала имамы, нигә мелла Котбый аның янында, мөридләре кемнәр, килү максатлары нидән гыйбарәт? дигән сорау Сөмбелне борчыса да, асылда, аларның ни өчен килүләрен чамалый иде — әйе, ул язмышы белән килешергә, Күлкәннең хәленә керергә тиеш.

— Мин тыңлыйм сезне, Котбый мелла,— диде Сөмбел, яулык очы белән каплаган авызын ача төшеп.

— Сиңа, балакай, олан Күлкән гашыйк. Үлепләр гашыйк. Тәмам саргайды углан. Сәне көтте. Чык син аның янына, сөйләш, тереләй гүргә кертмә бичараны. Аллаһы тәгалә барыбызны да ярлыкар, адәм баласы кылмаган нәрсә түгел, адәм баласының тулы бәхете хатын-кыз кулында, дигән бабаларыбыз.

— Мелла Котбый, минем никахлы ирем бар ич. Ул әлегә мине талак әйтеп аермады, гөнаһысын кая куярмын?

— Сәне ул сатып алды, балакай. Ирең үзе үк сатып җибәрә. Бу хәл талак әйтүгә тиңдер. Әйе, Ходай тәгалә сиңа рәхмәтен биргән инде, балакай. Син әсир, бала. Әсир качса — кул китәр, ди.

— Мин аңа биш бәлешен кайтарып бирермен, Котбый мелла.

— Сөбханалла, әйтмә алай дип, балакай. Кәлимә-и шәһадәт, ягъни таныклык ителде, дәген. Мәкрух, ягъни ярамаган эш кылма, берүк. Күлкән оланны хәләл ирең дип кабул ит, бу хәлне изгелек итеп күңелеңә сал, шайтан коткысына бирелмә. Кылган гамәлеңне ялгышка чыгарма. Син, бәнем уемча, Аллаһы тәгалә насыйп иткән адәмеңә кайттың. Әлхәмделилла, барысы да бихуш булыр. Тынычлан, әмәл-чарасызга бирелмә, барысы да әйбәт булыр, тәскирәнамә дә язылыр. Шәригать кануннарын бозарга Аллаһым сакласын. Тикторганда җиһадка чакырма, балакай. Килеш. Рисаләне тезеп, китапка теркәп, мөһерен сугарбыз, бездән калмас.

Сөмбел дәшмәде. Ул уйланды. Нигә бу бәхәс аңа? Мелла белән бәхәсләшү, аның белән тартышу аны чарасыз гына итәчәк. Золымга йөз тотучы Котбый мелла түгел, Сүбәдәй баһадир. Имеш, угланы аңа үлепләр гашыйк булган да, Сөмбел аның янына чыкмаса, мәңгегә күзләрен йомачак. Шуннан ни?! Сүбәдәй баһадирнең угланы үлмәсен дип, аңа кияүгә чыгарга тиешме ул? Йа Хода, нинди кайгы-хәсрәтләр генә төшми икән бу хатын-кыз башына! Бу мелла узаман Сүбәдәй баһадирның урында сырхаулап яткан угланын тәмам әүлия ясады. Илләр, калалар җимереп, кан-җан коеп йөргән кеше әүлия була аламы!? Юктыр. Һәр халыкның ил-җае, туган теле, гореф-гадәте һәм иманы белән хисаплашмаган кеше изге була алмый. Моны гына Сөмбел беләә, аз яшәсә дә, кешеләрне аерырга өйрәнде. Тик килешмичә нәчара кыла ала ул?.. Кем аны бирелдән коткарып алып китәр дә, кем юлга чыгарыр?.. Үлемме?.. Юк, Сөмбел моңа бармас. Үзеңә кул салып кына язмыштан котылып булмый. Сәнең каһәрле үлемең киләчәк буын туганнарыңа каргыш булып төшәр. Һич югы, алар бәхетле булсыннар.

— Мелла Котбый, углан тынычлансын, мин бүген үк аның янына чыгармын. Кирәк икән көннәр буена янында утырырмын, әкиятләр сөйләрмен. Шикләнмәгез, кулымнан килгәннең барысын да кылырмын.

— Әль хасил, балакай, әль хасил. Бик әйбәт, бик күркәм фикер. Йә, балакай, амин тотыйк та без китик инде. Игелек сиңа, балакай. Иншалла, барысы да әйбәт булыр.

— Хушыгыз...

## 46

Ул берәүдән дә курыкмады, хәтта Күлкән угланның атасы Сүбәдәй баһадирдан да. Көтмәгәндә аңарда хатын булу хисе уянды. Чарасыз калудан түгел, максати юнәлештә, гәрчә моның ихласлыгына үзе үк ышанып җитмәсә дә. Әмма чаткысы бар иде инде, күңеленең төпкелегендә чәчрәп йөри башлаган иде. Сөмбел үзенең чибәр һәм зифа сынлы булуын белә, аңа үсмер чакта ук сокланып карарлар иде. Аллаһы тәгалә аңа барысын да мул итеп биргән иде. Гүзәллекне дә, акылны да, уйчанлыкны да, хәтта кыюлыкны да. Сөмбел үз дәрәҗәсен үзе бик яхшы белә иде. Ләкин бүген ул — магул баһадиры Сүбәдәй кулында әсир. Иллә кыпчак халкының гүзәл кызы лабаса ул! Аңа хәтта хан онығы Хансөяр гашыйк булды һәм чарасыз калып өйләнде. Әлбәттә, Сөмбел дә аны яратты, шунсыз кияүгә чыкмас иде. Тик менә аны ни сәбәпледер хан онығы Хансөяр биш бәлеш алтынга дошман кулына сатып җибәрде. Хак, моны Сөмбел үзе теләде, дошман ыстанына үтеп керү өчен шул юлны сайлады. Күрде-күзәтте ич, Хансөярнең аны җибәрәсе килмәде, ләкин дошман ыстанына үтеп керергә теләгән Сөмбелне туктата ала идеме ул! Юк ич. Туктата алмас иде дә, туктамас иде дә Сөмбел. Ул хәтта Күлкәннән дә курыкмады. Үз-үзенә ышанычы шулкадәр илаһи иде ки, соңра Күлкән кулына килеп эләккәч, тегеаны үзенеке итәргә ниятләгәч, хәтта көчли башлагач, чын мәгънәсендә курка калган иде. Ярый әле, Күлкән аңа ышанды, барысын да уенга кайтарып калдырды. Ләкин Сөмбел уен уйнамый иде инде. Аның күңелен бары тик бер уй — ничекләр генә булса да Күлкән кулыннан ычкынып, качып китү. Аллага шөкер, җае чыкты, ул Күлкән угланның киемнәрен киеп кача алды. Ә бит, теләгәндә, Күлкән аны җибәрми дә ала иде...

Сөмбел исә инде беләсен белгән иде: магулларны туктату мөмкин түгел, хәйлә беләнме, орышыпмы, алар барыбер үз дигәннәренә ирешерләр. Шуның өчен ошбу дошманга атасы Бачман баһадир гына түгел, Илһам хан да җитди карарга тиеш. Күп санлы чирүе, хәрби тәҗрибәсе, камил коралы булган магуллар бер Саксинда гына туктап калмаслар, тора-бара Болгарга да җитәрләр. Дошман ыстанында булгач, Сөмбел әнә шуны аңлаган иде. Аны Хәрәзем һәм Бохара мөгаллимнәре укытты, ул дөньяви хәлләрдән хәбәрдар иде. Инде кияүгә чыгу хәленә килгәндә, Хансөярне күргәнче ул берәүгә дә гашыйк булмады. Әллә бар иделәр аның өчен алар, әллә юк. Хан онығы Хансөяргә күзе төшүе дә көтмәгәндә Болгарга кунакка баргач булды. Авырып ятканда аның янына хан онығы Хансөяр керде. Кулы белән битенә, аннары маңгаена кагылгач, Сөмбелгә әллә нәрсә булды, әйтерсең лә шул сыпыруы белән бөтен булган сырхавын алып ташлады. Әле булса хәтерендә, гүя аңа канат куйдылар, ятактан күтәрелеп, очып китәр төсле иде. Шул мизгелдән ул аны яратты. Аңа әлегә үзе дә аңлап җиткермәгән мәхәббәт килде.

Ул аны көтте. Ул килде. Һәм алар өйләнештеләр. Туй булды. Ә икенче көнне диярлек алар сәүдәгәрләр сурәтендә дошман ыстанына юнәлделәр. Әле сөешүдән тәннәре сүрелмәгән, җаннары аерылмаган иде. Аларга аерылышырга туры килде. Бер мөгаллиме аңа әйткән иде: «Җисми тансыклау килер дә китәр, дәрәҗәң төшермә, намусың аяк астына салып таптарга бирмә», — дигән иде.

Сөмбел һәр көнен, һәр мәлен кат-кат күз алдыннан уздырды. Күлкән углан алып киткәндә хан оныгы Хансөяр аңа нидер әйтергә теләде бугай. әйтте дә түгелме, тик ул аны ишетмәде генә. «Кеше үз-үзенә ирекле, тели — китә, тели — кала» — дидеме? Ни генә булмасын, барысы да артта калды инде. Ул хәзер әсир, углан Күлкән кулында әсир ул...

Сөмбел әкрен генә Күлкән углан ягына таба кузгалды. Баш иелгән, күңел теләми, аяклар тартмый. Ә бит күптән генәме әле бүлмәсеннән йөгереп чыгар иде дә болдырга басып, чыгып килгән кояшны каршы алыр иде. Барысы да бетте, жимерелде, асты-өскә килде... Илләә ул исән ич әле, рухы нык, күңеле вә тәне саф. Димәк, көрәшергә була. Әйе, ул теге юлы углан Күлкәнне төп башына утыртып качып китте. Тик бит ул аны рәнҗетмәде, мыскыл итмәде. Күлкән аны кичерер. Аннары, хатын-кызда, ким куйганда, мең төрле хәйлә булырга тиеш. Меңе үк булмаса да, синдә аның чиреге бар. Аллаһы тәгалә Адәмне яратырга җиде сәгать вакыт сарыф итсә, Һауваны яратырга аңа алты сәгать вакыт та күп булган, диләр. Кем соң Һаува? Нигә ул оҗмахка чыгу белән явызлык һәм изгелек алмасын ашый да алтын табакка салып Адәмгә китерә? Адәм алтын табактагы алманың яртысы ашалган булса да, алып ашый һәм шундук Һаувага гашыйк була. Соңгысы янә билгеле, яманлык һәм изгелек алмасын ашаган өчен Аллаһы тәгалә аларның икесен дә оҗмахыннан Җиргә сөрә. Моны исә Иблис бик теләп башкара, чөнки ул Адәм белән Һауваны яратмый торган була — бигрәк тә гашыйк булып яратышуларын килештерми.

Кем соң ул Адәм? Сөмбел янына кереп барган Күлкән түгелмени?! Әгәр дә мәгәр атасы җиңә алмаган Сүбәдәй баһадирның угланын, Сөмбел тыныч юл белән изге юлга төшерә алса? Олуг мөгаллиме әйтә килә иде ич: адәм баласы һәрчак изгелек кылырга омтылыр, гүзәллеккә сокланыр, дөреслекне эзләр, дип. Башкача булганда чынлап та ошбу дөньяда яшәү мәгънәсе бер халәткә әверелер иде. Бәлкем, аңа Ходай тәгалә Күлкәнне терелтергә кодрәт бирер. Һәм ул Сөмбелнең хәленә керер, аны ригая кылыр һәм алар бары тик дуслар булып китәрләр. Әйе, башта ук ул аңа шарт куяр — алар ир белән хатын түгел, бары тик... Шуннан, шуннан ни? Үз муйның үзең үк элмәккә тыгасың түгелме?..

Кайчан ир белән хатынның дус кына булып бергә яшәгәннәрен күргәнең бар? Дустанәлек ошбу ике затта барыбер тора-бара мәхәббәткә әверелә түгелме? Әтиең белән әниең язмышы сиңа мисал түгелмени!

Бусаганы атлады, түрдәге ятакка күз төшерде, елмайды.

— Саумы-исәнме, Күлкән. Син миңа үпкәләмисеңме?

— Сөмбел, җаным, үпкәли буламы! — дип яктырып китте Күлкән, чөнки Сөмбелдән моны һич тә көтмәгән иде.

— Син үзең генә?

— Үзем генә, Сөмбел, сине көттем. Ю-ук, мин сиңа үпкәләмим, Сөмбел. Уз, утыр. Мин торалмыйм шул, әллә нигә хәлем юк. Әллә иңемә кадалган ук агулы булды инде...

Шул мәлдә Күлгән ягына дүрт кишектин керде, ишекъяры тезелешеп бастылар. Сөмбел аларга ялт итеп карады да Күлкән янына узды, ятак янындагы түмәргә утырды. Кишектиннәр аңа ошамады, чырае караңгыланып китте. Кишектиннәрнең бил каешларында кылыч, хәнҗәр. Итек башлары өскә карап тырпайган, йөз-кыяфәтләре җәйпәк, сакаллары юк, бармак башы хәтле генә борыннарының тишекләре алга карап тора. Шуңа күрәме, барысы да бер анадан туган игезәкләр кебек иде. Күлкән углан кишектиннәргә охшамаган. Очлаеп килгән йөзле, яңаклары бераз төртебрәк торса да, йөзе мөлаем, төз борынлы, иреннәре сизелми дә.

— Нә кәрәк сезгә?

— Атаңыз җибәрде, углан.

— Хәзер үк чыгып китегез! Ишетәсезме, хәзер үк!

Кишектиннәр борылып чыгып киттеләр, Сөмбел үзалдына елмаеп куйды һәм Күлкәнгә карады.

— Рәхмәт сиңа, Күлкән.

Сөмбел тыныч иде, һәрхәлдә, тыныч булырга теләде.

— Мин сине көттем, Сөмбел. Төннәрен йоклый алмый көттем.

— Көткәнсеңдер дә бит... Мине урлап алып килделәр түгелме?

— Син генә мине коткара аласың, Сөмбел. Меллам Котбый, мәчеттә Аллаһы тәгалә хуҗа булса, өйдә — хатын-кыз, ди. Синең килүең миңа шифа булачак, мин моны күңелем белән тоям, Сөмбел. Сине күргәч тә, җаным тынычланды. Ышансаң — ышан, ышанмасаң ышанма, бүген төшемә дә керден әле. Бусаганы атлап кергәндә үк ошбу якта оҗмах кошлары сайрый башлады. Син аны ишетмәдең, ә мин ишеттем, Сөмбел. Котбый мелла, изге кешеләрне фәрештәләр озатып йөриләр, ди. Син изге җан, мин моңа ышанам, моңа минем иманым камил. Мин сине юксындым, Сөмбел, бик тә юксындым. Сагышландым, саргайдым. Һәм менә син минем янымда. Юксыну — таптырыр, ди. Минем юксынуым сине эзләтте, таптырды. Раббыма рәхмәт укыйм.

Сөмбел урыныннан кузгалып, Күлкәннең күзләренә карады һәм шундаен сагыш, шундаен мәхәббәт күрде ки, кулы белән битенә кагылганын сизми дә калды. Бу хәл ничектер нәкъ менә хан оныгы Хансөяр ул сырхаулап яткандагы кебек килеп чыкты.

— Син терелерсең, Күлкән. Менә әйтте диярсең, терелерсең. Һәм без синең белән кулга-кул тотынышып далага чыгарбыз.

Бу ни хәл бу, ни сөйли ул?! Улмы, Сөмбелме бу?!

Сөмбел тагы да текәлебрәк йөзенә карады һәм бу юлы инде угланны кызганудан йөрәге кысылып куйды. Угланның ике күзеннән дә мөлдерәп яшь ага иде. Яшь бөртекләре бите буйлап тәгәрәшә, ә чыраенда елмаю төсмерләре. Сөмбел чарасыздан Күлкәннең күкрәгенә башын салды.

— Мин сине шундый көттем, Сөмбел. Бик тә көттем. Килмәсәң, үләсе идем,— диде Күлкән калтыранган куллары белән Сөмбелнең башыннан сыйпап.

Инде Сөмбел күңеленә кызгану хисе мөлдерәп тулды, йөрәген тетрәтте, ул үзенең дә күзләре яшь белән тулганны сизми дә калды.

— Син үлмисең, Күлкән, үлмисең...

Күлкән күзләрен Сөмбелнең яулык очына сөртте, аннары йөзен яулык почмагы белән каплады да тынып калды. Көчен җуйган, гайрәт вә сәламәтлектән мәхрүм ителгән, хөсетлектән азат ир-атны кызгану һәр хатын-кызга хас сыйфат. Кызгану хисе аша яратмаган кешегә кияүгә чыккан, итәк тутырып аңардан бала тапкан хатын-кызларны да очратырга була. Хатын-кыздагы кызгану хисе тигез мәхәббәттән көчлерәк тә булуы ихтимал. Ләкин кызгану аша аңа бирелеп, аны ярата башлаган хатын-кыз, ир-затында үзенә тиң көч вә гайрәт күрә башладымы — ул аның белән бер көн дә тормаячак. Тән сихәтлеге — кешенең рухи дөньясы, аның сәләтедер. Рухи хаста кешеләрне догалар укып, аякка бастырган адәмнәр бар. Ходай тәгалә биргән сәләттән мәхрүм ителгән бәндәләр, гадәттә, үзен уратып алган мохиткә рәнҗүле булалар, бу халәткә төшүенә кемнедер гаеплиләр, кемнедер каһәрлиләр. Катлаулы, четерекле гомер юлы уза адәм баласы. Бәгъзесе Аллаһы тәгалә биргәнгә, сәләтенә күрә көч салып гомер итсә, бәгъзеләре хөсетлеккә, көнчелеккә йөз тотып, гадел булмаган юлларга кереп китәләр. Андый кешеләр Аллаһы тәгалә биргән изге вә якты тойгы-хисләрдән мәхрүмдер, аларга хөсетлек, явызлык хас. Ир-атны бары тик хатын-кыз бәхетле итте һәм ары таба да шулай булыр. Нинди генә шартларда яшәмәсеннәр, күркәм холыклы вә шәфкатьле хатыннардан мәхрүм ир-атлар иң бәхетсез кешеләрдер. Уйгахискә, изге тойгыга һәм саф мәхәббәткә йөз тоткан ир-ат кына ошбу дөньяда бәхетле була ала. Ир-ат бәхете — күркәм холыклы хатын-кызда.

Бу хакта азмы-күпме Күлкән белә иде. Менә ни өчен ул, янына Сөмбел килеп утыруга, тылсымлы кулы белән йөзенә кагылуга, үзендә моңа кадәр булмаган сихәтләнү тойгысы уянуын сизде. Әйтерсең лә

бөтен тән-әгъзаларын кемдер уята башлаган, туктаган хәрәкәтен кузгатып җибәргән иде.

Кызгану хисеннән Сөмбел дә мәхрүм түгел иде, сырхаулап яткан Күлкән аның нәкъ шул хисенә килеп орынды. Ул аның хәләтенә керергә теләде, җаны-тәне белән аның сихәтләнүен, аякка басып, йөреп китүен күрәсе килде. Һәм сизде-тойды, үзе дә Күлкәннең илаһи мәхәббәтенә битараф калалмады. Берәүләр кеше күңелен көч-гайрәт белән яуласалар, икенчеләре хиссияти мәхәббәт аша яулый алалар икән. Чөнки адәм баласына гайрәт көчен Аллаһы тәгалә үзенең рәхмәт нурыннан алып бирсә кирәктер. Югыйсә каян килер иде аңа кызгану хисе?

Сөмбел аның дөп-дөп тибеп, кинәт тынып калган һәм тагын зәгыйфь кенә тибә башлаган йөрәген тыңлады һәм үзендә ошбу кешегә карата кызгану хисе ныгый барганын тойды. Ул шуны белде: Сөмбел киткәч, егеткә бик тә, бик тә авыр булган, җитмәсә яралаганнар үзен. Шуннан соң бөтенләй өметен өзгән. Тән ярасы бик тиз төзәлгән, ә менә йөрәк ярасы, Сөмбелгә карата булган мәхәббәте... Сөмбел моны аның күз яшеннән, саргаеп вә сулып калган йөзеннән, сагышлы тавышыннан тойды. Мөгаллиме аңа бер тапкыр әйткән иде: «Хатын-кыз изге хисләр өчен туа, шуның өчен аның кылган ниятләре әхлакый яктан изге булырга тиеш». Ул — хатын-кыз, аның да нияте изге, ул аңа ярдәм итәр, дәвалар, тәрбияләр, сәламәтләнүен теләп, догалар укыр. Таш йөрәкле түгел ул. Агачлар вә үсемлекләр дә бер-берсен дәвалый, ә ул — кеше, җитмәсә хатын-кыз.

— Син нигә болай аз ашыйсың, Күлкән?

— Син кушсаң, мин ашармын, Сөмбел, ашармын.

## 47

Бу хәбәр Сүбәдәй баһадирга килеп ирешкәч, ата кеше сөенеченнән ни кылырга белми арлы-бирле йөренергә кереште. Беренчедән, бу хәлгә ышанып җитмәде. Әйе, ничек инде кан дошманы баһадир Бачман кызы аның газиз сырхау угланы белән бер табында ашарга риза булсын, ди. Монда нинди дер хәйлә-мәкер юкмы икән? Инде ихластан икән, моны күктән төшкән бәхет-сәгадәт дип кабул итәргә һәм бу хәлне үз күзе белән күрергә ниятләде. Димәк, кызны урлап дөрес эшләде ул. Хәер, мондый хәлләрдә Сүбәдәй баһадир бик сирәк ялгышты, буласы орышны да ул алдан күрә белде, әйтерсең лә аңа иң кыен чакта Тәңресе ярдәмгә килә иде. Кирәк чакта ул чигенә белде һәм көтмәгәндә тагын һөҗүм итте. Шулай җиңде әрмән-гөрҗиләрнең берләшкән чирүен, шулай җиңде алан-кыпчакларны, шулай җиңде урыс вә кыпчакларны. Ә менә болгарларга һөҗүм алай килеп чыкмады, әллә инде Тәңресе йөз чөерде, әллә бер-бер халыкның каргышы төште. Башта болгарлар аның олауларын таларга керештеләр, аннары чирүнең иң батыр яугирләрен ике тау арасына алдап кертеп тападылар. Булды андый хәлләр. Хәзер исә Сүбәдәй аларны кәкре каенга терәп куйды. Бер калаларын да кулга төшерде. Инде хәзер ничек бу караны кулдан ычкынлырмаска? Хак, әлегә кадәр магуллар ил-калаларны кылыч белән яуладылар. Хәзер исә тел вә вәгазь коралын да эшкә җигәргә вакыт. Кала имамының нотыгы Сүбәдәйгә ошады, моннан үзенә күрә бер нәтиҗә ясады: кайбер калаларны үгет-нәсихәт белән дә яулап була икән. Атакулы ханнары Чыңгыз моны әллә кайчан күрә алган — имамнарга һәм сәүдәгәрләргә тиярга кушмаган. Шуның өчен Сүбәдәй баһадир мелла Котбыйны хәрби эштән азат итте, сарай мәчетенә мулла итеп куйды. Әгәр дә мәгәр болгарларның калаларын җиңел генә кулга җыя башласа, имам кебекләргә баш орырга туры килер. Имам-муллалар аша халыкның күңелен яуларга була икән ич! Аңа хәзер яугирләрдән торган чирү генә түгел, имам-муллалардан

торган руханилар да кирәк булачак. Һәм Сүбәдәй моны эшләр, малын да, байлыгын да кызганмас. Диннең никадәр кодрәткә ия икәненә Саксинны алгач кына инанды ул. Дин — халык күңеле икән, күңел көзгесе, адәм баласының иманы, илаһи дөньясы вә мәгыйшәте.

Сүбәдәй баһадир, кулларын баш астына куеп, тәхет бүлмәсенең түр яктагы сәкесендә әнә шулай уйланып ятты. Килгән мәлне йорт уртасына юртасын куйдыртып, шунда торып караган иде, өч-дүрт кичен биредә кунгач, Бачман баһадирның йокы урыны ошап китте, гелән чыкмас булды, түшәктә аунады. Һәм яугирләрен дә, халыкны да тәхет ягында кабул итә башлады. Тәхеттә утырып, кешене кабул итү аңа шулхәтле ошап китте ки, Котбый мелла белән кала имамы «Баһадир, сиңа кирәсебез килә»,— дигәч:— «Мин тәхет ягында булырмын»,— дип әйткәнен сизми дә калды.

Имам белән мелланы ул тәхеттә утырып каршы алды, аяк кагып кына исәнләште дә ике яклап, берсеннән-берсе тәбәнәеп торган түмәрләргә утырырга кушты. Тегеләр икесе ике якка утыргач, канәгать калып, тамак кырды.

— Баһадир,— диде кала имамы,— каламыз синең кулга күчү сәбәпле, мәдрәсәләремезгә балалар сабак алырга йөрми башладылар. Яугирләреңнән куркалар. Мәдрәсәләргә кереп, мулла-мөдәррисләремезне мыскыл иткәннәр, һәммәсен дә куып чыгарып, мәдрәсәләргә кереп урнашканнар. Болгар-кыпчак халкы ислам диненә йөз тота, ә безнең изге китабымыз Корьән-Кәримдә гафиллек бер дә макталмый. Әйе, кһм, баһадир Сүбәдәй, мәдрәсәләремезне яугирләреңез бушатсалар икән, оланнар сабак ала башларлар иде. Халык ризасызлык белдерә, баһадир. Гадел түрә хаклыкка омтылыр, дигәннәр борынгылар.

Үзенең бөек халык вәкиле икәнең белә иде Сүбәдәй. Ләкин әнә шул илләрне, йөзләрчә халыкларны буйсындырган халыкның язмасы юк. Мәрхүм Чыңгыз хан үзендә булган уйгур мөгаллимнәрен дә куып җибәргән иде. Ә монда кала имамы әллә ниткән балаларга сабак бирә торган мәдрәсәләр дип саташа. Нә әйтергә тиеш ул аңа. Котбый мелла бу хакта ни уйлый икән? Бит магуллар һәм аларның угланнары мөгаллимнәрдән сабак алмасалар да, укый-яза белмәсәләр дә, йөзләрчә халыкларны буйсындырдылар, ясак түләргә мәҗбүр иттеләр.

Сүбәдәй ияген чөя төште, Котбый меллага карады, янәсе, йә, син ни әйтерсең?

— Баһадирым, магуллар бик борын заманнан ук рун тамгаларыннан да, чин тамгаларыннан да баш тарткан халык. Мәгәр атамыз Чыңгыз хан үзе белән һәрчак чиңлы Җәлү Чүтсәй белән имам хәзрәтләре төркиле Мәхмүд Ялавачны вәзирләре итеп йөретте. Хәтерем ялгышмаса, бүгенге көндә имам хәзрәтләре Мәхмүд Ялавач чиннар илендә вәли вазифасын үти. Ошбу кеше, баһадирым, атамыз, Чыңгыз ханга «Яса»ны дәфтәргә төшереп бирде. Искәргән булсаң кирәк, «Яса» безнең һәммәбез өчен мәгыйшәт кануныдыр. Гафил һәм укый-яза белмәгән кеше «Яса»ны безгә җиткерә алмас иде. Укый-яза белмәгән кеше ничек «Яса»ның кануннарын төгәл үтәсен, ди. Шуның өчен, баһадирым, оланнарга сабак бирү зарури нәрсәдер. Килеш һәм меңбашларыңны җыеп әйт: юрталарына күчсеннәр, шәкертләрне мәдрәсәләренә кайтарсыннар. Имам хаклы.

Хикмәт, мелласы хаклы иде. Чирүендә дә бит яртысыннан күбрәге төркиләр. Аларның шактые үз тамгаларын белә, «Яса»ны тактадан укый ала. Күбесе татар кызларына өйләнеп, магуллар да татар балалары үстерә башладылар. Ни гаҗәптер, магул татар кызына өйләнсә дә, татар магул кызын алса да, балалары татарча сөйләшә, чөнки татарның язу тамгалары бар.

— Мин риза, имам хәзрәтләре. Яугирләрем иртәгә үк мәдрәсәләрне бушатырлар.

Сүзгә оста түгел иде Сүбәдәй, ләкин Котбый мелла һәм кала имамы белән аралаша-аралаша сүзнең тәмен белә башлады. Канатлы кош икән

ләбаса ул сүз дигәнең. Юк, агулы ук. Килеп тисә, тәмам әсир итә. Шаманы әнә сүз белән кешене үтерә дә, терелтә дә ала бит. Айлар буена түшәктә яткан угланы нишләде әнә кызның татлы сүзләреннән — тәмам җан керде үзенә, сөйләшә, ашый башлады. Бер сүз терелтте бугай аны — яратам, дигәндер. Алай ук әйтмәсә дә, хәленә кергәндер, җылы сүзләр әйткәндер. Адәм баласы өчен иң тылсымга ия сүз — яратам. Күлкән углан шуны көтә бугай Бачман баһадир кызыннан. Тик бит ул ир-ат. Чын ир-ат һәрчак атта булырга тиеш. Иң асыл ир-ат Чыңгыз хан иде. Сигез яшендә атка менде, алтмыш биш яшендә аттан егылып төшеп үлде. Бусы — Сүбәдәй баһадир белгәне. Чыңгыз хан дус-ишләрен сайлаганда да хәрби атта оста алышуына карап сайлады. Ул һәрчак орышка омтылды, илләр яулау аның өчен кәсепкә әверелде. Мал үрчетү, иген игү аның өчен ят нәрсә иде. Әйтерең бармы, Чыңгыз хан да ялан җиңү тантанасы кичермәде, җиңелгән һәм дошманыннан койрык чәнчеп качкан чаклары да булды. Тик барыбер сугыштан бизмәде. Корылтай җыйган саен җиңүләреннән бигрәк, теге йә бу дошманнан җиңелүенең сәбәпләрен тәфсилләп сөйләр иде. Җиңүне ул үтәр бәхеткә тиңләде, җиңелү минем өчен мәңгелек көенеч, дип үртәлде. Бәлкем, җиңү бәхетен Чыңгыз хан үзечә тойгандыр, чөнки чиктән ашып комсыз иде. «Яулаган дәүләтең балаларыңнан да газизрәк күреп саклаганда гына озын гомерле булырсың»,— дияр иде. Сүбәдәй баһадир аның фәлсәфи сүзләре аңламады, ул хәзер дә бар нәрсәне дә аңлап бетерми, ләкин беркайчан да комсызлыкны яратмады. Бу мәсьәләдә алар Чыңгыз хан белән икесе ике ярда басып торалар иде. Моннан соң Сүбәдәй Чыңгыз хан кылган явызлыкларны кылмас, шуның белән ул үзе яулаган татарлар, төркиләр, әрмән-гөрҗиләр, алан-кыпчаклар, урыслар, болгарлар арасында абруй казаныр. Аның тарихы нәкъ менә шул Болгар иленнән башланыр. Чөнки аның монда язмышы — Карлыгачы, Ташбае, ниһаять, Күлкән гашыйк булган Бачман баһадир кызы.

Имам хәзрәтләре һәм Котбый мелла чыгып киткәч, Сүбәдәй баһадир кишектиненнән йөзбаш Түкә Тимерне чакыртты һәм, теге килеп кергәч, төмәнбашларга, меңбашларга боерыгын җиткерергә кушты: мәдрәсәләрдән яугирләрен чыгарсыннар, һичбер балага тел-кул тидермәсеннәр, мөгаллимнәрдән гафу үтенсеннәр. Кем дә кем аның әмерен үтәми — җәзаны үзе бирәчәк.

## 48

Котбый мелла шат иде — Сөмбел Күлкән углан белән бер табында утырып ашый. Бу хакта Сүбәдәйгә җиткергәч, корыч баһадир куанычыннан арлы-бирле йөренергә тотынды.

— Әйбәт,— диде ул, бөкләп тоткан камчысы белән итек кунычына суга-суга.— Әйбәт, Котбый мелла. Рәхмәт сиңа.

— Тик, баһадир, кызны көйгә китерүе кыен булды. Кыз үзсүзле, тәкәббер, горур.

— Бер йөгән кигезгәч, адәм баласы гына түгел, ат булып ат беркая китә алмый, шундук сабырлана, иясенә буйсынырга мәҗбүр була. Син, Котбый мелла, аларны инде калдырып тор, мәдрәсәләреңне җайга сал, мөгаллимнәрне тынычландыр. Ислам динендәгеләр белем алу изге эш дип баралар икән, изге булсын, ярдәм ит, булыш. Кыскасы, меллам, мәдрәсәләрне мин синең кулыңа тапшырам.

— Аллаһы тәгалә ошбу игелегеңне онытмас, баһадир. Саксин халкы да, иншалла.

— Минем белән килгән татарларны да мәчеткә өндә. Болгар-кыпчак белән телләре бер дияргә була, өндә үзләрен, динең кабул итсеннәр. Мин аларны үзем киткән хәлдә дә биредә калдырырмын, сакласыннар каланы, угланны.

— Изге ният, изге ният, бaһадир. Барысы да әйбәт булыр, иншалла.

Котбый мелла бaһадирның аягына төшәргә иткән иде, Сүбәдәй аны туктатты.

— Килешми, килешми, мелла. Без үз кешеләр ич. Син минем угланымны укырга-язарга өйрәттең, якын киңәшчем, килешми... Бер теләгем бар сиңа, мелла, зинһарлап сорыйм. Бачман бaһадир кызын күзеңнән яздырма. Берүк барысын да үзең кара, берәүгә дә ышанма.

— Яхшы, бaһадир, шулай итәрмен. Мин күз-колак булырга мөридләрем куярмын.

— Тик кара аны, минем кишектиннәргә комачауламасыннар.

— Шулай итәрмен, бaһадир, мин аларга әйтермен, комачауламасыннар.

— Имам хәзрәтләренең хәле ничек?

— Зарланганы булмады. Ул ике хатын белән тора икән. Мөселман ир-атларына дүрт хатынга кадәр өйләнергә мөмкин.

— Кем шулай ди?

— Изге китапта әйтелгән, изге китапта, бaһадир.

— Дүрт хатын белән торырга китапларга язмыйчы да була, мелла. Атамыз Чыңгызның хатыннары җидедән узган иде.

— Кһм,— дип тамак кырды Котбый мелла.— Мин бахырыгыз өйләнсә дә, ярар бит, бaһадир?

— Болгар хатынынамы?

— Болгар хатынына йортка керергә ният бар, бaһадир.

— Йортка керергә булгач, тол хатын, димәк, кешедән калган.

— Адәм баласының тән-җаны үзе белән, бaһадир. Эш килешүдә, мәхәббәттә.

Сүбәдәй: «Нәрсә ул мәхәббәт?» — дип сорамады, ул аның ни икәнен белә иде — Карлыгачы. Аның мәхәббәтенә кул сузымы гына ара калган иде, гайрәте җитмәде. Ләкин ул аны барыбер табар.

— Йорт-байлыгына күзең кыздымы, мәхәббәтең төштеме?

— Икесе дә бар, икесе дә, бaһадир.

— Син анда орыш кырында шәһит булган кыпчакларның хатыннарына минем татарларны да кодаларга онытма.

— Онытмам, бaһадир. Онытмам, оныта буламы. Мин бит биредә каласы кеше.

Сүбәдәй бaһадир мелла Котбый янына килде, иңенә кулын куйды.

— Син минем мөгаллимем генә түгел, рухи атам да, Котбый мелла. Мин синең изгелегең онытмам. Саксин халкы белсен иде, магуллар моннан китәргә дип килмәделәр.

## 49

Хезмәтчеләр арасыннан Сөмбел моң-зарын сөйләр өчен таныш кеше эзләде. Ләкин аңа Котбый мелладан башка берәүне дә якын җибәрмәделәр. Күлкән белән ишегалдына йөрергә чыкканда да аны күзәттеләр, таныш кешесен очратса да, сөйләшергә ирек бирмәделәр. Үз сарай ишегалды, үз кешеләре йөри, ә ул берәүгә дә якын килә алмый. Кемдер сакчыларны һәркөн алыштырып тора. Күлкән бик тиз йончый, озак йөреп булмый. Менә бүген дә, көн аяз һәм матур булуга карамастан, алар болдырга таба борылдылар. Сөмбел өчен туган сарае, монда күренгән кешеләр — һәммәсе ят иде инде, әйтерсең лә аның йорты, аның туган өе дә түгел, гәрчә һәркөн таныш тәрәкләргә, йозләрчә тапкыр ишек бавына тотынса да, хәтта үзенең ятак бүлмәсе дә ят иде. Ул белә: магуллардан качып китү мөмкин эш түгел. Шуның өчен ул сабыр итәргә булды. Аннары ул Күлкәнне дә болай гына ташлап китә алмый иде инде. Яңа аякка басып йөри башлады, ул аңа хәзер гелән сабый белән бер ләбаса.

Сизде-күрде Сөмбел: көннәр кышка таба бара, гүя табигать йокларга җыена — агач яфраклары коела, үләннәр саргая. Ишек алдына Күлкән белән саф һава суларга, бераз аякларны яздырырга чыккан саен ни өчендер Сөмбел ир-канаты Хансөярне исенә төшерә. Ниләр кылып ята икән бичара? Эзлиме Сөмбелен, суга батып үлде дип, яр буена килеп, көннәр буе моңаеп тора микән?..

Аз гына вакыт арасында да Сөмбел ире Хансөярен исенә төшерде, зәңгәр күккә бакты, галәмгә күз салды, һаваның сафлыгына, кояшның җылылыгына, җилнең булмавына сөенде вә кинәнде. Күлкәнгә карап алды, хәленә керергә теләп:

— Арымадыңмы, кермибезме? — дип сорады.

Күлкән туктады, кояшка йөзен куйды һәм нурларында коенгандай ләззәтләнеп, күзләрен йомды.

— Арыдым, Сөмбел, керик инде. Хәзер, хәзер чак кына кояш нурларында коенам да...

Шунда Сөмбел аркасы белән тойды, аларга кемдер карап тора. Сөмбел бөтен ихтыяр көчен җыеп, әйләнеп карамаска тырышты. Ләкин сабыры текәнде, түзмәде, әйләнеп карады. Әлбәттә, бу Сүбәдәй баһадир иде. Сөмбел борылып карауга, Сүбәдәй китеп барды. Ул хәзер атасының тәхет ягында утыра, кешеләрне дә шунда кабул итә. Сөмбел сарайга ут та сала ала, моның өчен аны җәзаласыларын да белә, әмма әллә нигә кулы бармый, гүя кемдер тотып, тыеп тора иде.

Болдырга менгәндә Күлкән туктап ял итте, хәле юк иде әле. Сөмбел аның кулыннан тотып, бертын көтеп торды. Ябык, чандыр, бармак сөякләре төртеп тора иде Күлкәннең. Кызлар ягына кергәч, мич янына килделәр, һәм Сөмбел егетнең боз кебек кулларын учына алды.

— Әллә өшедең инде, Күлкән?

— Бик тә өшедем, Сөмбел.

— Әйдә, ят, өстеңә тире юрган ябыйм.

Киемнәрен салдырды, яткырды, өстенә тире юрган япты.

— Сандал куярга урын юк, мичне дә якмыйлар, — дип зарланды Күлкән.

Сөмбел мич ягучыны чакырды, мичкә ягарга кушты.

— Ә син, Сөмбел, уңган, барысын да беләсең, — диде Күлкән тыенкы гына елмаеп.

— Әйт әле, Күлкән, синең тереләсең, сәламәтләнәсең киләме?

— Килә, килә, Сөмбел, бик тә килә.

— Бүгеннән мин сине көненә ике тапкыр һавага алып чыгам. Ишетәсеңме, ике тапкыр. Аннары көнгә дүрт мәртәбә ашатам...

Хезмәтче утын кертте, мичне кабызып җибәрде.

— Күбрәк як, юкса угланга суык, — диде Сөмбел.

— Ярый, байбикә, шулай итәрмен.

— Мин сиңа байбикә түгел. Кем сиңа шулай әйтергә кушты?

— Баһадир, баһадир, байбикә.

— Әгәр дә мәгәр тагын бер тапкыр миңа шулай дип дәшсәң, чыбык белән суктырам үзеңне.

— Кичерә күр, балакай, Мин, баһадир кушкач кына шулай дигән идем.

— Аның исеме Сөмбел, Хикмәтулла, ишетәсеңме, Сөмбел.

— Аңладым, углан, Бачман баһадирның кызы Сөмбел атлы иде.

— Ул хәзер дә Сөмбел.

— Әйе, Сөмбел, Сөмбел, углан Күлкән.

— Куй, кирәкми, — диде Сөмбел күтәрелә башлаган Күлкәнгә.

— Дөнья белән идарә итүне Аллаһы тәгалә башта хатын-кызга биргән, диләр. Ләкин алар вәгъдәләрендә тора алмаганнар, шуннан дөнья белән идарә итүне ирләр үзләренә алганнар, — диде Күлкән. — Ир-атның хатын-кызга карата тәкәбберлеге шуннан. Кылыч күтәреп бер-берсенә яу

чабалар, кан коялар, илләр яулыйлар, калаларны җимерәләр, иллә бәхетнең хатын-кызда икәнен белмиләр.

— Син беләсенме? — дип сорады Сөмлел, аңа Күлкәннең фәлсәфәсе ошады һәм ул үзалдына елмаеп куйды. — Ә син кызык кына фикер йөртәсең, Күлкән.

— Ир-атны бәхетле итүче яу чабу түгел, Сөмбел, ир-атны бәхетле итсә, бары тик хатын-кыз бәхетле итә ала. Хатын-кызның вазифасы исә ир-затына бер булса да бала табып бирү, аның гамәлен бизәү, балаларын тәрбияләүдә ир-атка ярдәм итүдер.

— Сөйлә-сөйлә, Күлкән, матур сүзләр сөйлисең, тыңлаган саен тыңлыйсы килә.

Күлкән сөйләде, ә ул инде күңеле белән Хансөяре янында иде. Бәхетле идеме ул Хансөяре белән? Бәхетле иде. Әйе, ахирәте Айгөлнең көмәнен күргәнгә кадәр. Соңыннан ни булды соң? Берни дә булмады кебек, шулай ук сөешләр, тик күз алдыннан инде һич тә ахирәтенең йөзендәге мөлдерәп торган бәхет вә сәгадәт нурын гына җибәрә алмый изаланды. Иренә карата битараф та кала алмады, шулай ук инде тәүгечә ярата да, сөя дә белмәде, наз-сөюдән тәүге көннәрендәге кебек ир-канаты кочагында эремәде.

Сөмбелендәге бу үзгәрешне сиздеме, күрдеме соң Хансөяре?! Юк, күрмәде дә, сизмәде дә шикелле. Ул, бичара, хатыны аны шулай ук ярата дип белде, күрәсең. Ләззәт коесына чумар өчен генә ир-аттан сөелгән вә назланган хатын-кызның поты бер тиендер. Аның исеме — фәхишә. Андый хатын-кызга Аллаһы тәгалә матур тормышка ишарә ясар, әмма аңа беркайчан да ихласи мәхәббәт тоярга мөмкинлек бирмәс, ди.

Күлкән өй җылынуга изрәп йокыга киткәч, үз ягына чыкты, сәкесенә утырды. Мөгаллиме аңа әйтер иде: «Хатын-кызның бәхете инсафлы ирдә булса, ир-атның бәхете гыйффәтле туташ вә хатындадыр». Күлкән, бичара, аны ярата. Сөмбел сукыр түгел, барысын да күреп тора. Ул аңа һәрчак сокланып карады. Хәтта әнә шул карашында да самимилек ярылып ята иде. Ябык, чандыр, күзләре эчкә баткан, авызын ачса, үпкәсе күренер кебек, ә яратам дип өзгәләнә... Менә кем ярына китереп орды аны язмыш. Бөтенләй уйламаган, күзалламаган, төсмерләмәгән һәм көтмәгән хаста адәм катына. Торган җире хибесханә түгел иде, ләкин аермасын да күрмәде Сөмбел. Ул, гүя, читлектәге кош иде. Аны, гүя, урманнан тоттылар һәм читлеккә китереп яптылар. Ә бит иректә иде, сайрар кош иде.

Кем аны урлады? Нигә?..

Сүбәдәй баһадир яугирләре, Күлкән углан өчен. Корыч баһадир аны угланына кияүгә бирергә теләп. Кызы аша Бачман баһадирның ышанычын яуламакчы. Тик барырмы моңа атасы?! Юк, тагын бер тапкыр юк! Инде нишләргә тиеш ул? Упкынга ташлансынмы, әллә булмаса хатын-кыз буларак язмышы белән килешсенме?.. Килешсә ни булыр да, килешмәсә ни булыр? Хәзер аның көннән-көн рухы вә акылы ныгый бара. Юк, ул суга да, упкынга да ташланмас, үз-үзенә кул да салмас, ул җай көтәр, боерган итсә. Килер аңа ярдәм, Аллаһы теләсә, килер. Ул хәзер, гүя, табигатьнең Аллаһы тәгалә тарафыннан изге эшләр кылырга яратылган бер бөртегенә әверелде. Ул әүвәл генә чарасыз иде, хәзер ихтыяр көче ныгыды, ул хәзер бернидән дә курыкмый.

Сөмбел Аллаһы тәгаләгә мөрәҗәгать итте: Раббым, рәхимле бул бәндәңә, дип үтенде, белгән догаларын укыды. Шунда тәрәзә аша кыйгак-кыйгак кычкырган очар казлар тавышын ишетте. Йөрәге ашкынып тибә башлады. Ул сикереп торды да тәрәзәгә килеп капланды һәм тагын кыр казларының моңсуланып кычкыруларын ишетте. Күңеле тулышты, бите буйлап ага башлаган яшьләрен сизми дә калды. Күз яшьләре тып-тып тәрәзә төбенә тамды, сагышлы күз яше иде алар.

Кеше көннәрен яулау өчен аның белән ким дигәндә атна-ун көн бер табынга утырып ашау вә эчү, күрше булу кирәк икән. Атна-ун көндә син аның кимчелекләрен күрәсең, нинди аш яратканын, фәлсәфи фикерен, уй-теләген, максатын чамалыйсың. Сөмбел аның үзеннән ни теләвен белгән иде инде. Аңа бары тик күтәргә калды. Күлкән углан моңа кадәр Сөмбелгә очраган берәүгә дә охшамаган иде. Ул һәр яктан барысыннан да аерылып торды. Фикер сөреше дә, фәлсәфи уйлары да, мәхәббәткә мөнәсәбәте дә башка иде. Аның тәненә ит куна башлады, күзләрендә нур кабынды. Ул аны һаман кызгана иде әле. Сөмбел аны ир-ат итеп күрмәде, һәрхәлдә, күрмәскә тырышты, ул аның өчен гүя тәрбиягә алган бала иде. Шул ук вакытта күрде-сизде, Күлкәндә ниндидер үзгәреш башланды.

Кичке аш вакыты җитте. Сөмбел Күлкән ягына чыгарга җыенганда ишек шакыдылар.

— Керегез! — диде Сөмбел, нигәдер каушый калып.

— Бу мин, Сөмбел, мин. Мин сиңа айгөл чәчкәләре алып кердем. Шул чәчкәләр кебек гүзәл бит син, чәчләреңнән дә шундый хуш исләр килә.

Үзе елмая, битләренә алсу төс кунган, күзләре елтырый. Сөмбел чәчкәне алды, борынына якын китерде һәм ярсулы хуш истән чак кына башы әйләнеп китмәде.

— Каян алдың мондый хуш исле чәчкәләрне, Күлкән?

— Базардан. Матурмы?

— Матур гына булса икән, хуш исеннән исереп китмәле. Рәхмәт инде. — Якын ук килде, битеннән үпте. — Мең-мең яшә!

— Бу айгөлдә минем сиңа мәхәббәтем дә, өметсез гыйшкым да, сабырлыгым да, сабырсызлыгым да, Сөмбел.

Сөмбел чәчкәләрне күкрәгенә кысты, тагын бер тирән итеп хуш исле чәчкәләрне иснәде, аннары ятагына куйды.

— Тиздән ат менеп далага чыгарбыз, Сөмбел. Куышырбыз, — диде Күлкән. — Мин сине узалмам, шулай да калышмаска тырышырмын. Аннары кылганнар арасында йөрербез. Мин ул кылганнарны диңгез дулкыннарына охшатам, Сөмбел. Дулкыннар ярларга, кыяларга килеп орынсалар, кылганнар бер урында чайкалалар да чайкалалар. Кайчан мин аларны кызганып та куям, җиргә бәйләнгән алар, дулкыннар кебек кузгалып китә алсалар иде дә...

«Кем син, Күлкән? Нигә сорамый-нитми йөрәгемә килеп керәсең? Ә бит минем ирем бар, хәләлем — Хансөярем. Ничекләр мин аңа хыянәт итим?! Бүген кемне ярата ул? Күлкәннеме? Мөмкин хәлме? Юк, ул аны бары тик кызгану аша ярата. Хак, ул аңа хыянәт итмәм дип ант итмәде, кол сурәтендә ич ул хәзер. Ошбу Күлкән нә теләсә, шуны кыла ала.

— Мин сине яратам, Сөмбел. Син килмәгән булсаң, мин әллә кайчан гүр иясе булган булыр идем инде. Ходай тәгалә минем догаларым кабул итте — син минем янда. Котбый мелла: «Аллаһы тәгалә язганны күрмичерми бәндә ошбу дөньядан китмәс», — ди торган иде, миңа да Ходай сине күрергә, бергә булырга язгандыр. Мин синең янда, мин чарасыз...

— Күлкән, Күлкән, тынычлан. Мин синең янда ич. Әйдә ашарга чыгабыз. Китергәннәрдер инде.

— Сөмбел, Аллаһы тәгалә сине миңа язган. Язмаган булса, сине бөтен магул гаскәре җыелып та китерә алмаган булыр иде.

Күңел домбрасының гүя бер кылы шартлап өзелде, бәгыре парә-парә килде. Сөмбел әкрен генә кузгалды, урынына менеп ятты.

— Кил бире, Күлкән.

Углан өчен таулар ишелде, җирләр упты, бозлар китте. Күлкән ни кылырга белми аны үбә-сөя башлады. Аннары битенә битен куйды да

тынып калды, ахры тагын күз-кашларыннан, битләреннән, муеннарыннан үпте, калтыранган куллары белән изү бавын чиште. Күлкәннең үтә күренмәле калтыранган кулларын, бармакларын күреп, Сөмбел аны күкрәгенә кысты.

— Нишләвең инде, Күлкән. Күлкән дим...

— Мин сине яратам, Сөмбел. Мин синең әсирең, синең колың, бауга бәйләгән колының.

Сөмбел чарасыз калды, аның һәр теләгенә ирек бирде һәм күзләрен йомды. Аны гүя Хансөяре коча, сөя иде. Һәрхәлдә, ир-канатын күз алдында тотарга тырышты. Күлкәннең һәр хәрәкәте кочуы-сөюе, назлавы үзгә иде. Ләкин ят түгел, ят итеп кабул итмәде. Нечкә озын бармаклары белән йомшак кына сыйпый, назлый һәм шул хәл белән Сөмбелдә хиссият дулкынын кузгатып җибәрде.

— Башта вәгъдә бир, Күлкән. Соңыннан мине җибәрерсең. Ямә?

— Минем сине тотарга хакым юк, Сөмбелем. Китәргә итсәң, мине алып китәрсең. Мин синең белән качармын. Мин синең әсирең, мин синең колың, Сөмбел.

Күңеле белән Сөмбел Идел буендагы Хансөяре чатырында иде, ә чынында исә аны Сүбәдәй угланы Күлкән назлый, чарасыз калып сөя вә иркәли иде. Тора-бара хәтта Күлкәннең тавышы да ир-канаты Хансөяренекенә охшый башлады. Бит-йөзендә күз яше тойгач кына, айнып киткәндәй булды — Күлкән елый иде, күз яше белән елый. Сөмбел аны күкрәгенә кысты, каты итеп кысты.

— Мин сине яратам, Сөмбелем, яратам!

Сөмбелнең тамагы кипте, Күлкәнгә нәрсә булса дә әйтәсе, аны тынычландырасы килде.

— Күлкән, Күлкән, елама, елама. Мин синең белән ич, синең белән. Мин беркая да китмим, китмим. Тик әтиеңә әйт: безне сакламасыннар, без әсирләр түгел.

— Түгел, түгел, Сөмбел. Котбый мелла әйтте, сәне Бачман баһадир кызы кочуга, син терелерсең дип. Мин терелдем, терелдем, Сөмбел...

— Дәшмә, күп сөйләшмә, Күлкән. Ял ит. Син таза-сәламәт ир, син кодрәтле, гайрәтле һәм татлысың...

Соңыннан ул бөяттәй йомарланып, ике учын тез арасына кыстырып, оҗмах кошы тоткан сыман тын гына уйланып ятты. Гаҗәп, аның тәненә чынлап та кош кереп оялаган кебек иде. Сөмбел әкрен генә гәүдәсен сузды, Күлкәнгә таба борылды. Күлкән күзләрен йомып, мәрткә киткән кебек, тынсыз ята иде. Сөмбел курка калды, аны селеккәләргә тотынды.

— Күлкән, Күлкән, уян дим, уян. Әйдә, ашарга чыгабыз.

— Мин ашамыйм бүген, минем ашыйсым килми. Мин хәзер үлсәм дә үкенмим. Син минем сылуым, күз нурым, бердән-берем.

— Син ятып тор, Күлкән, мин хәзер. Мунча ягарга кушам.

— Куш, мин мунча яратам,— диде Күлкән аның кулына ябышып, җибәрми торды.

## 51

Сөмбел үлем турында уйламады, үлемнән курыкмый башлады ул. Үлем аның өчен түгел, ул аңа кагылмый, башкалар курыксыннар, дип уйлый иде. Саксинга урлап китергәч, аңарда үзе өчен курку башланды. Чөнки бөтен җаны-тәне белән тойды, аңарда икенче җан пәйда булды. Ә менә аның баласына җан биргән ир-зат үләргә тиеш. Тик ничек? Ничек кул күтәрер ул аңа? Бит кочагына үзе керде, үзе иңде! Ул гынамы, моңа кызгану хисе аша барды һәм бу хиснең әле дә күңелен ташлап киткәне юк. Ләкин бит чәчкәләр үлә. Күлкән дә аның өчен бары

тик чәчкә иде. Ә чәчкә кыска гомерле була. Аллаһы тәгалә һәр кеше күңеленә җиде тапкыр күз сала, дип әйтәләр. Ходай шаһит, ул монда үзе теләп килмәде, аны урладылар. Шулай ук Ходай шаһит, Күлкән аны көчләмәде, үзен алырга үзе ризалык бирде — ятим калмас өчен, хатын-кыз буларак халкы алдында үз вазифасын үтәү өчен. Дөрес, бу бәхетне ул ир-канаты Хансөярдән дә ала алган булыр иде, ләкин хәләле моңа сәләтсез булып чыкты, ә Ходай тәгалә аңа Күлкәнне язган икән. Хатын-кыз исәя башлауга өч хакыйкатьне онытмаска тиеш: тапкан баласын күрәшкә әзерләргә, үз бәхетен табарга ярдәм итәргә, белем бирергә. Аллага шөкер, Раббысы аңа бала иңдерде, димәк, хатын-кыз буларак ул үз бәхетен тапты. Һәм кемнән? Кан дошманыннан.

Аның ягына бавырчы керде, сабыр гына ашарга дәште, әмма Сөмбелнең ятагында йоклап ятучы Күлкәнне күреп, авызын ачып катып калды.

— Ул вафат, балакай?

— Юк, ул йоклый, бавырчы. Бар эшеңдә бул. Мин хәзер аны уятырмын.

— Минем сиңа сөенечем бар, балакай. Атаң бире таба яу килә икән, Сүбәдәй баһадир, утка баскан мәче кебек, кая керергә белми башлады. Гаять көттә көч белән килә икән атаң, балакаем.

Сөмбел аның янына килде, Күлкән ягына карап, кычкырып сөйләшмәскә кушты.

— Кем әйтте?

— Имам хәзрәтләре, балакаем, имам хәзрәтләре. Чынлап та киләләр, ди. Якыная башлауга, имам хәзрәтләре капкаларны ачып куярга кушты. Ә син моннан, балакай, хәзер үк кит, хәзер үк! Сүбәдәй баһадир атаңа каршы чыгарга чирүен җыя, калада ыгы-зыгы. Имам хәзрәтләре сиңа инәң йортына качып торырга кушты. Мин аның йомышын гына үтәдем, капкалар ачып йөрергә минем көчемнән килми...

Сөмбел йөрәге кага башлавын тоеп, изрәп йоклап яткан Күлкәнгә карады.

— Мине туктатырлар бит, бавырчы?

— Мин сиңа кишектин киемнәре алып килдем. Әйдә, бирәм.

— Хәнҗәр дә китердеңме?

— Хәнҗәре дә бар, уклар да. Кулдан ата торган уклар.

Сөмбел бавырчыга ияреп кызлар ягына чыкты, кече якка кереп кишектин киемнәрен киде, каймалы бүрек киде.

— Эңгер иңеп килә, ишегалдына чыкканда артыңа әйләнеп карама, минем алдан барырсың. Мин табак күтәреп чыгармын. Әйдә!

Кишектиннәрнең аларда әллә кайгылары булмады, үзара бәхәсләшәләр иде, бавырчы белән Сөмбел алар янынннан үтеп киттеләр, берсе дә туктатмады. Күрәсең, бавырчыны озатып йөрүче кишектин дип белгәннәрдер. Кала урамнарында исә аларга гелән игътибар итмәделәр. Сөт инәсе йортына җиткәч, бавырчы капка шакыды, кемдер капка шудыргычын эшерде, капканы ачты.

— И-и бәбекәем,— дип кочагына алды аны сөт инәсе.

— Мин киттем, Мөсәттика, киттем,— диде бавырчы һәм йөгерә-атлый йорт янынннан китеп барды. Сөмбел аңа хәтта рәхмәт әйтергә өлгерми дә калды. Капканы япкач, инәсе аны өйгә алып керде һәм:

— Сал әле шул зәхмәтләрнең киемнәрен,— дип, Сөмбелне чишендерә башлады.

Сөмбел чишенде дә сәке кырына утырып:

— Инәки, төшемдәме, өнемдәме бу? — дип сорады.

— Өнеңдә, өнеңдә, бәбкәем, инәң янында, исән-сау котылуыңа кинәнәсе ит. Әйдә, башта дога кылыйк әле...

## 53

Багучыларыннан болгарлар хәрәкәте турындагы хәбәре ирешү белән, Сүбәдәй баһадир төмәнбашларын чакырды һәм орышка җыенырга боерды. Тәртипле гаскәриләр буларак, иртәнге якта Сүбәдәйнең чирүе җыелган, аның әмерен көтә иде инде. Сүбәдәй исә таң атар-атмас угланы янына чапты һәм кишектиннәренә күз дә салмый кызлар ягына узды. Углан кызлар ягында юк иде. Сүбәдәй үзалдына елмаеп куйды, гәрчә елмаер чагы булмаса да. «Димәк,— дип уйлады ул,— углан белән урланган кыз уртак тел тапканнар. Бачман баһадир бик кысырыклый башласа, ул аның кызын арбага бастырып орыш кырына алып чыгар. Әлбәттә, кыз янына угланны да бастырыр. Һәм оран салучыларыннан баһадирга җиткерер: углан белән кызы никахлаштылар, ир белән хатын булып торалар. Сайла, баһадир, минем белән орышасыңмы, карендәшләсеңме? Орышсаң — кызың да китәр, чирүең дә кырылыр, инде акылыңа килеп, минем шартым кабул итәсең икән — мин балаларны калада калдырам, вәгъдә бир, син аларга кул салмассың. Һәм каланы да үзеңә калдырам. Тик бер шарт белән: углан Күлкән тархан булып утырсын».

Риза булырмы гаять зур гаскәр туплап килгән Бачман баһадир, юкмы — Сүбәдәй белми иде. Ләкин уйлаган эшен ул җиренә җиткереп башкарыр.

Киереп ишекне ачты, түр яктагы ятакта, күпертелгән түшәктә, җылы тире юрган астында угланның берүзе йоклап ятуын күреп, шикләнеп куйды. Әмма үз-үзен тынычландырырга теләп, тышка чыга торган кече ишекне ачып карады — анда берәү дә юк иде. Шуннан баһадирга каушау килде. Ул мич араларын, чаршау артларын тикшереп чыкты, сәке астына күз ташлады, шуннан коты алынып, углан йоклап яткан ятак янына килде. Угланның маңгаена кагылды, Күлкән аның кулын тотып алды һәм күзләрен дә ачмый назланып:

— Сөмбелем, җанкисәгем,— диде.

— Күлкән, Күлкән! Тор әле!

Күлкән сискәнеп уянып китте, күзләрен почмаклатып, атасына бакты.

— Сөмбел кая, атам?

— Мин аны синнән сорарга торам әле. Кая кыз?

— Кыз түгел ул, хатын, минем хатыным, атам.

— Синең хатының,— диде Сүбәдәй, ирен чите белән елмаеп, һәм ятак янәшәсендәге түмәргә утырды.— Сөмбел качкан. Ишетәсеңме, углан, Бачман баһадир кызы качкан, синең хатының!

— Ул качмады, атам, качмады. Ул монда. Кая булса чыккан гынадыр.

— Бәлкем,— диде Сүбәдәй битараф бер кыяфәттә, гәрчә углан әйткәнчә булуын бик теләсә дә.

— Атам, эзләт инде Сөмбелне,— дип күтәрелде Күлкән һәм, ятактан төшеп, кабаланып киенә башлады.

— Дөрес эшлисең, тизрәк киен. Каланы ташлап китәргә туры килмәгәе. Бачман баһадир каласына кайта. Орышка әзерлән.

— Атам, Сөмбел чынлап та качканмы?!

— Табарбыз аны, углан. Киен дә кишектиннәрең янына чык. Күрен үзләренә. Хәзер кояш чыга, Бачман баһадир калага якынлашып киләдер инде. Без могуллар калада орыша белмибез, чыгып орышырга туры килер. Җыен! Хәлең ничек?! — дип сорады ата, угланга карамый гына.

— Әллә нигә ашыйсы килә.

— Алгы якка чык, аша, җыен. Мин киттем. Болгар капкасы янында булырмын.

«Әллә соң Саксинны алып ялгыштыммы?» — дип уйлады, атын җай гына юырттырып Болгар капкасына таба барганда, Сүбәдәй баһадир.

Чирүенең һәр төмәне капкалар янына туктаганнар иде инде, аның әмерен көтәләр. Сүбәдәй артына әйләнеп карады, үзеннән бер тотам калмый килүче кишектиннәрен күреп, тынычлана төште. Алар арасында Котбый мелласын да күрергә теләгән иде ул, тапмады Котбыйны, әллә тагын җир упты үзен. Хәерле булсын, Котбый аны ул хәтле борчымый. Ә менә Бачман кызының кинәт кенә югалуы сәер иде. Ничекләр юкка чыкты кыз, кишектиннәре ничек күрмәгәннәр? Искитмәле хәл иде. Хак, ул сакта торган кишектиннәрен җәзалый да ала иде, башка чакта булса шулай итәр иде дә, тик хәзер вакыты ул түгел, һәр кишектине санаулы, аларның һәрберсе ике яугиргә тора лабаса.

Илгә кайтып киткән нойоннарны кулга төшереп, бер батман алтынга ия булып, Бачман баһадир Идел буена яңа кала кора, дип җиткергәннәр иде ич инде, шуннан соң Сүбәдәй баһадир тынычланып калган иде. Ә баһадир Бачманның үз исәбе үзендә булган икән, тагын каласын кайтарырга килгән. Тик аңа каланы Сүбәдәй тиз генә бирмәс, орыш каты булыр, далада булыр ул орыш. Ә Сүбәдәй далада сугыша белә. Аның үзеннән ике тапкыр күп санлы дошманны да алдына тезләндергәне бар. Хак, Бачман баһадир белән алай килеп чыкмады, каты чикләвек булды кыпчак җиһангиры, ләкин Сүбәдәй баһадир да дөнья арбасыннан төшеп калганнардан түгел. Тәңре шаһит, бик сирәк җиңелде ул...

Хак, Сүбәдәй теге вакытта бераз ялгышты. Бер төмән гаскәрен каты маңгай Бүчек нойон алып китмәгән булса, аңа бүген җиңелрәк булыр иде. Ләкин нәчара, үткән эшкә — салават. Аннары Котбыйның югалуы. Ул гынамы, мәчеткә йөреп, ислам динен кабул иткән татарлар: «Без мөселманнарга каршы чыкмыйбыз»,—дип Сүбәдәйне тәмам чыгырыннан чыгара яздылар. Ярый әле үзләрен кылычтан уздыра башламады, үзара орыша башлаячаклар иде. Тәңре саклады, алар да акылга утырдылар, беришe коралланып килде. Ләкин шиге бар иде Сүбәдәйнең: болар беренче орышта ук Бачман баһадир ягына чыкмасលармы? Бик ихтимал ич. Тик Сүбәдәйгә ышанудан башка чара калмаган иде, гәрчә Котбый мелланы тапмаса да, татарлар коралланагач, Сүбәдәй тынычланды. Татарлар кыю, курку белмәс халык, хөҗүмдә һәрчак алгы сафта булырлар, кирәк чакта чигенеп, кирәк чакта дошманны тулганага алырга да күп сорамыйлар. Алай да Сүбәдәй базар яныннан үткәндә Шәрекъ мәчетенә күз төшереп алды. Аннары нидер исенә төшеп, атын мәчеткә таба борды. Аның кара исәбе буенча, Котбый мелла анда булырга тиеш иде. Мәчет тирәсендә мәхшәр. Халык дулкыны әле бер якка орына, әле икенче якка сугыла. Имам хәзрәтләре халыкны тынычландырырга тели, әмма ләкин аңа һич кенә дә игътибар итүче юк.

Шәрекъ мәчете каланың урта бер җирендә, нәкъ базар янында. Базарда исә кем генә юк. Сәүдәгәрләре дә, алучысы да, ачыкавызлар да, караклар да, кесә талаучылар да, тамаша кылучылар да, алыпсатарлар да — барысы да бар биредә. Иң гаҗәбе: бу халык тәмам сарык көтүе диярсең, шау-шу килә, акыра-бакыра, һичкемне тыңламый. Ошбу мәйданга килгән саен Сүбәдәй үзендә ислам диненнән көнләшү кебек хис тууын сизә. Шул хәлгә җитеп дингә табынырга буламы? дип гаҗәпләнүе иде. Көнчелек хиссияте Котбый мелла белән бәхәсләшкәндә тагын да көчәеп китәр иде. Нигә, әйтик, ул табынган Тәңре, аның шаманы, ягъни төптәңресе артыннан бер дә болай шашынып йөрми халык? Ә бит Тәңре диненә алты мең еллар бар инде. Ислам диненең туганына, ташка үлчим, ярты гасыр да юктыр әле.

Сүбәдәй баһадир кишектиннәренә халыкны тынычландырырга боерды, ә тегеләр тынычландыра беләләр иде, берничә кешене укка алугаһым булдылар.

Халык тынычлануга, Сүбәдәй түр якка үтте, эзәңгесенә баса төшеп:

— Татарлар, минем горур татарларым! Мөселманнар! Мин сезнең мәчетләрегезне япмадым, имамнарыгызны кылычтан уздырмадым. Ара-

гызда татарлар булса, сез аны миңа күрсәтегез! Күрсәтсәгез, моны Аллаһыгыз да, мин дә аларны кичеререм. Татарлар, мөселман булып, чалма кигән яугирләрем, хәзер үк таралыгыз да коралланып, Болгар капкасы янына килегез. Мин сезне көтәм, туганкайлар. Көтәм. Без сезнең белән илләр яуладык, җәйләүләребез киңәйттек. Бу җәйләүләрне без үзебез өчен түгел, сезнең өчен дә яуладык. Коралларыгызны алыгыз да...

— Без, баһадир, хәзер мөселманнар инде. Чакырма безне. Без мөселманнарга каршы орышка чыкмабыз! — дип кычкырды берәүсе.

— Безгә мөселманнарга каршы орышу гөнаһ. Безнен Аллаһыбыздан каһәр аласымыз килми! — дип икенчесе атылып чыкты.

Сүбәдәй иң оста мәргәннәренә ияк кагып кына ишарә ясады, янәсе нәрсә карап торасыз, алыгыз укка тел бистәләрен. Кишектиннәр җәяләрен тарттылар, ике мөселман татарның чалмалары тәгәрәп китте, әмма алар янына берәү дә ярдәмгә килмәде, ярдәмгә килгәннәрне янә укка алулары бар иде.

Шунда кемдер:

— Кыр денсезләрне, кыр кяферләрне! — дип кычкырмасынмы.

Халыкка шул җитә калды. Мәйдандагы татарлар бөтенләй коралсыз килмәгәннәр икән, кишектиннәр белән уктан алыша башладылар, ул арада уктан алган кишектиннәргә халык ябырылды. Китте мәйданда суеш-кисеш, ыгы-зыгы, гауга-тавыш. Мәргән кишектиннәрне халык дулкыны урап алган, мәргән яугирләрне атларыннан сөйрәп төшерәләр, сыталар, изәләр, үзләре дә кырылалар.

Сүбәдәй баһадир җансакчы кишектиннәренә аралык ясарга кушты, тегеләр халыкны икегә аеруга, атын шунда юнәлтте. Сүбәдәй мәйданнан чыкты да туры Болгар капкасына чапты, аның Мөңкә төмәнбашны алып килеп, халыкны уктан алдырырга исәбе бар иде, капкага җитәрәк бу уеннан кире кайтты. Чирүе аның әмерен көтә икән. Килә-килүгә Сүбәдәй баһадир капкаларны ачарга, далага чыгып, төмән-төмән басарга боерды. Ул арада аның янына үз кишектиннәре белән Күлкән углан килеп җитте.

Чирү агым судай капкалардан далага агылды. Сүбәдәй яңадан мәчет мәйданына барырга кыймады. Бу аның өчен гелән көтелмәгән хәл булды, хәзер генә ул, чирүе капкадан чыга башлагач кына, мәчет янына туктаганы өчен үкенү хисе тойды. Нигә кирәк иде аңа кырмыска оясына таяк тыгарга? Ялгышты. Ләкин соң инде, хәзер капкадан чыгарга да орышка әзерләнергә. Сүбәдәй баһадир үз янына угланы Күлкәнне чакыртып алды. Угланның берни булмаган кебек атта утыруы, һични булмаган кебек дошман киләсе якка карап торуы аны тагын да тынычландырды.

— Атам, атам, кишектиннәрең Сөмбелне тапмадыларммы?

— Сөмбел турында орыштан соң, углан, орыштан соң...

— Яхшы, атам, — диде углан, атасы белән килешеп.

Сүбәдәй аңа янә гаҗәпсенеп карап алды. Шаккатмалы хәл иде, ай дигәндә ниндидер бер чәчби кыз түшәктән башын күтәрә алмаган баланы аякка бастырды да куйды. Рәхмәтле иде Сүбәдәй кызга, ул аны тапкан хәлдә дә үлем куркынычына куймаячак иде.

## 54

Чирүе далага чыгып беткәч, олауларга чират җитте. Ниһаять олаулар да чыгып бетте. Сүбәдәй баһадир өзәңгесенә басып, бик озак калага карап торды.

«Нигә ут салдырмады ул калага? Нигә яндырмады? Моңа хәтта үзе дә җавап таба алмады. Бәлкем, тагын киләсенә ышангандыр. Бик ихтимал ич. Чөнки Болгарга өч-дүрт төмән белән генә килергә ярамаганга ул тәмам инанган иде инде.

Күңеле сизә, ул әле бу калага әйләнеп киләчәк. Киләчәк һәм тәхеткә угланы Күлкәннеме, кече улы Тайчинныны утыртачак. Хак, Тайчин угланын Сөябеле бирергә теләмәс, ләкин Сүбәдәй аны барыбер алып килер. Чөнки Тәңре һәр магулны орыш өчен яраткан. Магул бәхетне бары тик орышта гына табачак, тыныч тормыш ят аңа, аның өчен тыныч тормыш — тормыш түгел.

Кала күздән язганчы киткәч кенә, Сүбәдәй баһадир ыстан туктарга боерык бирде, чөнки кояш кичкә таба авыша башлаган иде инде. Юртачыларның юрта корасы, бавырчыларның аш саласылары бар иде. Сүбәдәй баһадир яугирләрен күздән кичерү теләге белән угланы Күлкәнне һәм исән калган кишектиннәре белән чирүен карарга кереште. Һәм яугирләреннән канәгать калды. Дөрес, татарлардан меңнән артык кеше калада калган иде. Болар яуда ятып калган кыпчакларның хатыннарына йортка кергәннәрдән, әмма нишләмәк кирәк, Сүбәдәй алардан үч алырга өлгерә алмый калды. Бачман баһадирга ачулы иде ул. Иң жанын кыйнаган кеше, мөгаен, шулдыр. Ничә тапкыр орышалар бит инде. Олуг Мөхәммәд угланы солтан Җәләлетдин Чыңгыз ханның шулай жанын кыйнаган иде. Бик озак эзәрлекләде Чыңгыз Җәләлетдинне, әмма берничә елдан соң гына гаскәрен тар-мар итте. Анда да Җәләлетдинне кулга төшерә һәм алдына тезләндерә алмады: җиһангир солтанны ниндидер тегермәнче, җиде алтын бәлешкә алданып, үз тегермәнендә качып ятканда суйган иде. Килер бер көн, Сүбәдәй баһадир, боерган булса, Бачман баһадирны алдына тезләндерер.

Кич якта, юртасы янына кайткач, учак каршында әнә шулай уйланып утырды Сүбәдәй. Һәм юртасы әзер булгач, меңбашларын дәшергә кушты. Аның елгыр яугирләрен тагын бер күздән кичерәсе килә иде.

Сүбәдәй зур юртасының түр башына кунаклады, янәшәсендә Күлкән угланны утыртты. Һәм тезләренә кулларын куйды да:

— Мәгълүмдер, меңбашларым, без ошбу калада шактый яугирләребезне югалттык. Калада калучылар да булды. Килешик, без әле бу калага янә килербез һәм безгә хыянәт иткән һәр яугирне кылычтан уздырырбыз,— диде ул, һәммәсенә дә күз ташлап.

Меңбашлары орыш кырындагы кебек: уң канаттагылар — уңга, сул канаттагылар — сулга утырганнар иде. Моны килештерде, чөнки Чыңгыз хан да шушындый тәртипне яратыр иде. Әйе, орыш кырында гына түгел, табынга утырганда да һәммә кеше үз урынын белергә тиеш — тәртип шуннан башлана. Шулай да сиздe, тойды: корыч баһадир әкрен генә меңбашлары алдында абруен җуя бара иде. Баһадир күптән инде тәүге усаллыгын югалткан, аз гына гаебе булган өчен дә яугирне кылычтан уздырмый, гафу итә, кичерә белә, баһадирның йомшаруы бигрәк тә Саксин каласын алгач башланды, яугирләре арасында моны төрлечә юрарга тырышучылар булды, әмма төп сәбәбен яугирләре түгел, Сүбәдәй үзе дә белми иде. Чөнки баһадир Саксинга килгәч, Карлыгачы турында ишетте, ул гынамы, угланы да исән-имин икән, аннары гөнаһ шомлыгына каршы дигәндәй, угланы Күлкән Бачман баһадирның кызына гашыйк булып, тәмам чиргә сабышып, урынга калды, ярый әле тылсымга ия кыз угланны аякка бастырды, юкса яугирләре арасында Сүбәдәйнең абруе тагын да түбәнгәрәк тәгәрәячәк иде.

Бачман кызын тапмаулары, аны кулдан ычкындырулары Сүбәдәйнең кәефен нык кына бозды. Кишектиннәрен җәзаларга иде дә, әллә нигә кулы күтәрелми, тагын да абруен төшерүе бар. Аннары мәчет мәйданындагы көтелмәгән кырышны исенә төшерәсе дә килми. Орыш югалтусыз буламы. Сүбәдәй баһадир ла ул. Аның кем икәнен яугирләре бик яхшы беләләр. Баһадирның серле рәвештә бертын дәшми утыруы, сыңар күзе белән бораулагандай һәр меңбашына күз төшерүенә тыныч төптәңренең дә сабырын төкәндерде. Төптәңре тамак кырды, әмма бер кәлимә сүз әйтмәде. Юртага ярканат очып керде һәм күз иярмәс тизлек белән,

шәмнәрне сүндерергә теләгәндәй, очына башлады. Кемдер аны кулы белән бәреп төшерде, ике канатын да өзеп, юрта авызына ташлады.

— Тиле кош,— диде Сүбәдәй.— Фикерне өзде.

— Кош түгел ул, безнең рухыбыз,— диде төптәңре.— Ә синең тиле беткән меңбашың аның канатларын өзеп атты. Безгә аны Тәңре үзе җибәргән булгандыр. Бу хәл бик сирәк була, баһадир.

— Төптәңре, синең рухың шул ярканаты булса, мин синнән иртәгә үк йөз чөергән булыр идем. Күк-кояшның кодрәте ярканатында булуына мин ышанмыйм. Тузга язмаган сүз сөйләп утырма,— диде Сүбәдәй, төптәңре ягына карамый гына.

— Тәңребез куәте күк йөзендәдер, хак, ләкин ярканат аның рухы булуы бар, баһадир.

— Ярканаты ул бары тик ярканаты, төптәңре. Мин татарларның ислам диненә күчеп, калада калуларына, мөселманнарга каршы кылыч күтәрмибез, дип әйтүләренә аһ орып утырам, ә син нииндидер нә тычкан, нә кош булмаган җанны Тәңре рухы дип баш катырасың, төптәңре. Мин сине аңладым, төптәңре, син төптәңре түгел, ә шамакай. Хәтереңдәме, атамыз Чыңгыз хан үз төптәңресен ничек юк итте?

— Ләкин мин атамыз Чыңгыз хан төптәңресе түгел, баһадир. Мин синең сүзеңә аркылы төшмәдем, сиңа каршы кешеләр котыртып йөрмәдем. Мин ничек тә татарларны Тәңре динендә тотарга тырыштым, ә алар барыбер тыңламадылар, мәчеткә йөри башладылар, безгә мәчеткә йөрергә баһадир үзе рөхсәт бирде, диделәр. Нәтиҗәсе күз алдында, меңләгән татар калада калды , җитмәсә, йөзләгән кишектинеңнең башына җиттеләр. Ярканаты шул мөселман татарлар кулыннан һәлак булган кишектиннәреңнең рухыдыр, баһадир.

Сүбәдәй дәшмәде. Төптәңре белән бәхәсләшү аңа кыен иде. Ләкин Чыңгыз хан алар белән сөйләшә дә, көрәшә дә белә иде. Әле булса хәтерендә Сүбәдәйнең, төптәңре бик узына башлагач, ул аны үз юртасына чакыртып алды да ни өчендер туганы Тәмуг-төпчек белән булган бәхәсләрен хөкем итәргә керешә. Төптәңре туганын алдына тезләндергән, ни өчендер гафу үтенергә кушкан икән. Туганы Тәмуг иртәнге якта Чыңгызга килеп бу хакта зарланды, Сүбәдәй барысын да ишетеп торды. Төптәңренең әтисе Мөнкә дә килгән иде, Чыңгыз ханның атасы Йүзәкәйнең меңбашы булган кеше.

«Син — шаман, мин — хан,— диде аңа Чыңгыз.— Син минем эшемә кысылма, төптәңре».

«Мин, хан, бары тик Тәңрегә буйсынам. Тәңре миңа барлык ылыслар белән идарә итәргә кодрәт бирде. Синең белән дә. Шаман күк белән ике арада тора, синең белән дә идарә итә, димәк. Әйе, син дә минем кешем, хан».

«Ләкин бер кешегә ике хаким әмер бирә аламы?»

«Горурларны мин тыя төшәм, кимсетелгәннәргә рухи көч табарга ярдәм итәм, хан».

«Син минем туганым Тәмугны мыскыл иткәнсең, нойоннар карап торганда алдыңа тезләнергә кушкансың».

«Кирәк тапсам, сине дә тезләндерермен, хан»,— диде шаман.

Чыңгыз хан төптәңренең әрсезлегенә түзә алмады, кишектиннәренә шаманның билен сындырырга кушты. Юк, ул аңа туганы Тәмуг белән көрәшергә боерды, әмма төптәңре баш тартты. Шуннан Чыңгыз хан ым белән генә кишектиннәренә боерды шаманның билен сындырырга. Шаман үлде дип кереп әйткәч, атасы Мөнкә угланның бүреген күкрәгенә кысып, кычкырып елап җибәргән иде. Төптәңрене халык ярата, кимсетелгәннәр аннан ярдәм эзлиләр иде. Шуның өчен Сүбәдәйгә шаманның мәетен яшертен юртадан алып чыгып, тау битенә илтеп күмәргә кушты. Моны Сүбәдәй бик тиз башкарды. Ә иртән халык шаман мәете яткан юртага килгәндә, ул буш иде инде. Алар янына чыккан Чыңгыз хан:

«Шаманның безгә кылган явызлыгы шулкадәр күп булган ки, ул аны безгә күмәргә дә бирмәгән, Тәңребез үзенә алган»,— диде. Һәм халык шундук таралды. Мәнем шаманым да миңа каршы сүз әйтә башлады, инде мин нишләргә тиеш? Шаманның билен сындыртыргамы, кылычтан уздырыргамы? Җитмәсә орыш алдыннан?.. Янә бер гыйбрәтле хәл хәтерендә Сүбәдәйнең. Көннәрдән бер көнне атасы юртасына баш углан Җүси кайтты. Һәм атасын кинәндерде: «Мин, атам, орышмый гына дүрт-биш халыкны буйсындырдым»,— диде. Чыңгыз хан ничек дип сорап тормады, ә нойоннарга угланын мактый башлады һәм шунда Җүси угланына Сүбәдәй баһадирын бирде. «Синең беренче баһадирың, киңәшчең булыр»,— диде. Сүбәдәй баһадир яшермәде, әле дә яшерми, Җүси угланны яраткан иде. Углан чынлап та акыллы, белекле, кеше хәленә керә торган, үткен фикерле адәм иде. Нәкъ менә Җүси угланнан кешеләргә мәрхәмәтле булырга, кимчелекләрен вә ялгышларын кичерә белергә өйрәнде Сүбәдәй. «Җүси углан нишләр иде икән, җәзалар идеме шаманны, әллә игътибар итмичә, үзе белән йөртер идеме икән?»— дип уйлады Сүбәдәй. Ләкин җавап таба алмады.

— Безгә бүген яугирләр кирәк, төптәңре, ә син ниндидер ярканатны рухыбыз дип утырасың. Оял бераз,— диде Сүбәдәй, бу юлы инде төптәңренең күзләренә туры карап.

— Кәңәшем бар сиңа, баһадир. Җибәр мине найманнарга, кыргызларга. Мин сиңа күпме телисең, шул хәтле яугир яллап китерәм.

«Шуннан соң җүләр баш дип әйтеп кара төптәңрене! Җүләр түгел, башын диванага салып йөргән кешегә дә охшамаган. Тик ничекләр тиз арада җыймакчы ул яугирләрне? Ара якынмы?»

— Син хаклы, төптәңре, һичшиксез, хаклы. Тик найман-кыргызлар кайда да, без кайда, ә дошман инде кул сузар арада.

— Килешергә кирәк, баһадир, шаман белән,— диде төмәнбашы, меңбашлары да ияк кагып утырдылар.

— Моның өчен кимендә йөз бәлеш алтын кирәк булачак, меңбашларым. Миндә бу хәтле байлык юк. Һәммәбездән җыйсак кына инде.

Меңбашлар күзгә-күз карашып алдылар. Кемнең дә җыйган вә талаган алтыннарын бирәсе килми иде. Аннары хәйләкәр шаманның бар алтыннарны җыеп, кая булса таюы да бар иде. Алай да Сүбәдәй меңбашларын сынарга теләде, янчыгын чыгарды, табын уртасындагы табакка биш бәлеш алтын ташлады. Барлык меңбашлар да теләр-теләмәс кенә янчыкларын чыгардылар, кайсы бер, кайсы ике бәлеш алтын куйды.

Сүбәдәй баһадир табакны алды, төптәңрегә бирде.

— Үз вәгъдән үзең тормышка да ашыр, төптәңре. Җый яугирләр, килтер бире.

Төптәңре табакны алды да юртадан чыгып китте.

— Ак юл сиңа, төптәңре,— диде ишекъяры утырган меңбаш.

— Иртәгә орышка. Без җиңәрбез, меңбашларым, мин сезгә ышанам. Ял итегез.

## 55

Юртада икәүдән-икәү генә калгач, Күлкән углан тамак кырды. «Сөмбел турында сорарга җыена?» — дип уйлады Сүбәдәй һәм тора башлады. Угланга кыен иде, ул моны аның күзләреннән үк күрде. Хәер, нигә гаҗәпләнәсе, Карлыгачы белән Ташбаен югалткач, үзе дә ни кылырга белми өзгәләнгән иде. Аннары: «Илемдә мине Сөябелем көтә»,— дип үз-үзен алдап та карады, булмады, кайтты, күрде Сөябелен, әмма күз алдыннан бер генә көнгә дә Карлыгачы белән Ташбае китмәде.

— Минем Сөмбелем табылыр микән, атам? — диде углан.

Ул шулай диюгә, Сүбәдәй аңа әйләнеп карады һәм дәвамчысының күзләрендә яшь күреп, аптырап калды.

— Әллә табибны чакыртыйммы, Күлкән?
— Миңа үз табибым кирәк, атам — Сөмбел.
— Бачман баһадир кызы синең табибың идемени, углан? Ул синең хатының түгел идемени?
Шулай диде дә Сүбәдәй юртадан чыгып китте. Юк, ул угланны ачуланып ташлармын дип курыкмады, куркуы башка иде — тагын чиргә сабышыр. Сырхавы кузгалса, ул ни кыласын белми, тәмам чарасыз калырмын, дип уйлавы иде.
Сүбәдәй баһадир юртасыннан чыкты, кичке салкынча һаваны күкрәк тутырып сулады да бавырчысыннан каз каны сорады.
— Китер әле, казларың бардыр бит?
— Бар, баһадир, бар, Саксиннан күп итеп алдык.
Кайнар вә аеры тәмле исле канны ул бер күтәрүдә эчеп куйды һәм юртага кире керде.
— Ятыйк, йоклыйк. Иртәгә орыш. Орыштан соң Сөмбел турында кайгыртырбыз, углан,— диде ул, Күлкән ягына карамаска тырышып. Ләкин углан аңа җавап бирмәде, Күлкән йоклый иде инде. Сүбәдәй утларны сүндерде, киез өстенә ятты, өстенә тире юрган ябынды.

## 56

Кояш чыгарга өлгермәде, болгарларның хәрби тезмәсе күренде. Болгар гаскәре тартылган җәя рәвешендә баскан иде. Чыңгыз хан ысулы. Тупчылары күренми, артка куймасалар, алда юклар. Шуңа күрә Сүбәдәй үз чирүен уң канатны да, сул канатны да җәеп салды, әйтерсең лә болгарларны тулганага алырга җыена иде. Ун адымга бер яугир куйды, ә аз гына кала төшеп тагын бер яугирне бастырды. Шулай итеп магулларның чирүе күп санлы булып күренде. Ләкин моңа карап, болгарлар тезмәләрен бозмадылар һәм беренче булып һөҗүм дә итмәделәр. Сүбәдәй дә беренче булып һөҗүмгә ташланырга җыенмый иде. Ул көтте. Һәм кирәк дип таба икән, кичкә чаклы көтәр. Тәүге орышта болгарларның укчы яугирләр арасында болгавырлык китереп чыгардылар, хәтта чигенергә туры килде. Хәзер бу хәл кабатланмас, сирәгәйтеп тезелгән яугирләрне тупка алу бермә-бер кыенлашыр. Аның яугирләре болгарларны тулганага алырга тиеш, калганы осталык эше. Сүбәдәй баһадир үзе бик сирәк орышка катнашты, ул орыша башлауга, идарә итүнең шундук җеп очы югалыр иде. Шуның өчен ул бүген дә орышка катнашмас, ә алга төмәнбашларын куяр, тик угланны түгел. Күлкән угланны кичтән үк олаулар белән озатып яхшы итте, сәламәтлеге начар, кәефе юк, аннары сихерләнгән бер хәлдә тел очында һаман баһадир Бачман кызы Сөмбел. Хак, җаны түзмичә, баһадир Бачманның орышка катнашып китүе бар. Менә ул чакта инде Сүбәдәй дә аңа каршы кузгалыр, түзмәс. Теге орышта Сүбәдәй тупчыларны кулга төшерә алмады, әмма бу юлы ул аларны ничек тә кулга төшерергә тырышыр. Олуг хан Үгәдәй алдында ул бары тик туплар белән генә аклана алачак. Ни генә булмасын, ул Бачман баһадирны Саксинга кертмәскә тырышыр. Аннары качкан хәлдә дә кызы Сөмбел дә калададыр. Сүбәдәй анда әйләнеп кайтыр һәм ул сихерче кызны эзләп табар. Бачман баһадир орышка катнашканда, иң елгыр кишектиннәре белән ул аңа каршы чыгар. Бу хакта ул хәтта меңбаш Түкә Тимергә дә әйтмәде. Ләкин меңбаш аның һәр боерыгын үтәр. Хәзер дә ул аның янында тора, дикъкать белән болгарларны күзәтә. Хәтәр булыр орыш, чөнки болгарларда туплар бар, аннары Бачман баһадир буш кул белән генә үз каласын кайтарырга дип килмәгәндер — хак. Сүбәдәй баһадир янә бер мәртәбә тезелеп баскан яугирләренә күз төшереп алды һәм меңбаш Түкә Тимергә:
— Меңбашым, әгәр дә мәгәр мин кишектиннәрем белән дошманга таба кузгалам икән, ярдәмгә кил!

— Баш өсте, баһадир. Килермен!

Яңа боерык алган меңбаш, ат тоягыннан балчыклар чәчрәтә-чәчрәтә, яугирләрен урап килде. Сүбәдәй баһадир әледән-әле көнчыгыш тарафына күз төшереп алгалады. Һичбернинди өмет тотмый, мәгәр күз карашы һаман шунда тартыла. Имеш, шаман найман-кыргызларны җыеп килмиме?.. Юк, әлбәттә. Ул әле даланы да узмагандыр, аңа әле барасы да барасы, аннары җыясы да җыясы. Орыш кырында төрле хәлләр булуын искә алып, Сүбәдәй углан белән олауны Каракорым тарафына озаткан иде. Алар инде Җаек елгасына җитеп киләләрдер. Ул ничәк тә угланның орыш кырыннан ераграк китүен тели иде. Үзләре җиңелгән хәлдә һич югы алар котылыр иде. Ләкин бу хакта Сүбәдәйнең уйлыйсы килмәде. Шул ук вакытта күңелендә үзе дә аңлап бетермәгән борчылу бар иде. Менә ничәмә тапкыр болгарлар белән орыша инде, ичмасам шуларның бер генә баһадирын да алдына тезләндерә алганы булмады. Кайчак: «Нинди баш бирмәс халык!» — дип тә уйлап куйгалар иде. Тик барыбер барысын да орыш хәл итәр. Ахыр чиктә, яугирләренә ул качарга боерыр, әйе, качарга һәм яңадан һөҗүм итәргә... Кем белә, бәлкем ул тагын бер җиңү тантанасын кичерер, теге вакытта урыс-кыпчак гаскәрен җиңгән кебек. Унлап кенәзне юрта челтәре астына салып өсләренә киез җәеп, эчә-эчә тончыктырып үтергәннәр иде. Бачман баһадирны да шундый үлем көтүе бар. Аннары нинди халык бу кыпчаклар. Әле урыслар белән күршеләр, әле болгарлар белән. Сибелеп-таралып яшиләрме шулай, үзара татулыклары юкмы? Шулайдыр, татулыклары юктыр. Чыңгыз хан да бит үз угланын теге дөньяга озатты. Хак, үзе түгел, хатыны котыртуы буенча, әмма бу хакта хан белмәдемени?! Белде. Күрмәмешкә сабышты. Бирелдәге кыпчаклар гаять борынгы халык, дип мактана имамнары. Имеш, борын-борын заманда аларның бабаларының бабалары «Сак»лар ошбу төбәктә көн күргәннәр. Сәер халык. Бүген сез көн күрсәгез, иртәгә магуллар көн күрер, җәйләү кала түгел, дивар куя алмыйсың.

Түзмәде болгарлар, кузгалдылар. Сүбәдәй дә быргычысына ишарә ясады.

— Каршы кузгалырга, һөҗүмне көтмәскә! Хүр-рә!

Ике меңбашка болгарларның тупчыларын бүлеп алырга әмер бирелгән иде, алар тупчыларны тулганага алырга ташландылар. Сүбәдәй, калкурак җиргә баскан килеш, орыш кырын күзәтте. Ул күрде, Болгар тупчылары туплардан аттылар да тау ышыгында торган олауларга таба чигенә башладылар. Меңбашлар аларны куа киттеләр. Ләкин болгарларның төп көче булса кирәк, аларга аркылы төште, чәчелде, сибелде, болгана башлады орыш кыры. Сүбәдәй кашына кулын куеп, орыш кырына карады. Янына килеп туктаган Түкә Тимер меңбаш:

— Тупчылар баһадиры Артык бу, баһадир. Тупчыларын коткармакчы.

— Һәм коткара да бит, меңбаш. Коткара. Әнә безнекеләр сибелә башлады, чигенәләр түгелме соң?

— Кузгалыйммы, баһадир?

— Бергә-бергә, меңбаш. Кая миңа охшаган яугирең, бастыр аны калкулыкка. Ә үзең минем белән, минем белән!

Сүбәдәйнең йомык күзенә чүпрәк аша салкын һава керә, бераз өшетерә, ләкин ул салкынны сизәр хәлдә түгел, атына камчы белән сыдырды да кылычын суырып чыгарды.

— Хүр-рә!

Ул белә иде, аның артыннан кишектиннәре, меңбаш Түкә Тимернең яугирләре кузгалдылар. Кишектиннәре дә, меңбаш яугирләре дә тәмам башкисәрләр. Аларны һичкем туктата алмас. Теге якка да, бу якка да уклар ява башлады.

— Хүр-рә! Хүр-рә!

Ә каршы яктан бөтенләй башкачарак кычкырдылар:

— Ур-ра, Ур-ра!

Менә болгарларның алдынгы сафлары белән меңбаш яугирләре орыша да башладылар инде. Сүбәдәй баһадир атын бер читкәрәк алды, китеп барган тупчыларның артына төште. Ләкин моны күреп алган бериш болгар гаскәриләре аңа каршы кузгалды. Килер җайдан Сүбәдәй баһадир кылычын уң кулдан, сул кулга күчерде һәм каршы килүче болгарның башына чапты. Ул аңа әйләнеп карамады, икенчесенә кизәнде, аны чабып ияреннән төшерде, өченчесе каршыга килә иде, аңа сугарга ирек бирде, калканын куйды, икенче әйләнеп килгәндә җай китереп ботына чапты. Болгар акырып кычкырып җибәрде, шунда ул үзенә таба килүче Артык баһадир төркемен күрде. Алдан кылычын болгый-болгый яшь сугышчы килә, аның артыннан баһадир. Сүбәдәй моны аның очлымындагы каурыйдан белде.

— Ташбай, Ташбай, баһадирны миңа, миңа калдыр! — дип кычкыра иде.

Сүбәдәй баһадирның гүя йөрәге җиргә төшеп, ат тоягы астында калды. Ул атын кинәт берьякка борды һәм кача башлады.

— Барыгыз да минем арттан, борылабыз! — дип кычкырды ул арттан килгән кишектиннәренә, ләкин кишектиннәрнең күбесе болгарлар белән орыша башлаган иде инде.

Сүбәдәй кылычын кынысына тыкты, ук-җәясен алды һәм артына борылып, үзен куа килгән болгар баһадирына атты. Тимәде. Сирәк була торган хәл иде. Икенче угын куучы калканына тотты. Сүбәдәйнең мизгел эчендә йөрәге нәфрәт белән тулды. Гадәттә, ул беркайчан да дошман атын укка алмый иде, моңа ул яугирләрен дә өйрәтте, нинди генә җайсыз хәлгә калма, хайванга ук атма, аның бер гаебе дә юк. Һәм ул шулай иде дә. Бу хәл Чыңгыз хан чорында да язылмаган канун кебек сакланды, магуллар атларны укка алмадылар. Ат алар өчен дошман түгел иде, ә сугышчы. «Ләкин Сүбәдәй бүген беренче тапкыр үзенең иманын бозды — куа килгән баһадирның атына атты. Ат кинәт сөрлегеп куйды, болгар баһадиры баш аша атылып төште. Ләкин икенче бер болгар сугышчысы аның атын укка алды. Ук ат корсагына кадалды. Ат кинәт туктады һәм берьякка ава башлады. Сүбәдәй болгарлар белән орышта бер тапкыр бу хәлгә калган иде инде, өзәңгесеннән аякларын алды һәм берчиткә ыргылды. Шундук аның янына Түкә Тимер килеп җитте һәм:

— Баһадир, атлан! — дип кычкырды.

Ул арада магул сугышчылары болгарларны кисеп алдылар һәм Сүбәдәй белән меңбаштан аерып, орыша башладылар. Калкулыкка әйләнеп кайткач, Сүбәдәй үз урнында калган яугирне атыннан тартып төшерде һәм сикереп атка атланды, орыш кырына күз ташлады. Эшләр харап иде, магуллар качалар, кайбер төбәкләрдә орыш дәвам итсә дә, чигенәләр иде инде.

— Сугыша-сугыша чигенергә! — дип әмер бирде Сүбәдәй. Ул инде үз хәленә кергән, боерык бирер хәләттә иде. Ләкин очлымы кояшта ялтыраган, үзен куа килгән һәм: «Ташбай, Ташбай! Баһадирны миңа калдыр!» — дип кычкырган җайдакны һич кенә дә күз алдыннан куа алмады. «Углан» диде түгелме соң? Әллә соң ул орыш кырында чынлап та угланы Ташбай белән очраштымы? Йа Тәңрем, бу ни хәл инде?! Ул бит чак кына Ташбай угланын укка алмады... Сүбәдәйнең йөрәге кысылды, магуллар күзгә күренеп кача башладылар. Чаптырып Түкә Тимер меңбаш килде:

— Баһадир, Мөнки төмәнбаш яугирләре белән кача, нә кыламыз?

«Димәк, тагын болгарлардан җиңелдек!» — дип уйлады Сүбәдәй һәм атына камчы белән сукты.

Ике көн, ике төн буена кача-кача чигенделәр, бары тик Җаек елгасын кичкәч кенә, Сүбәдәй яугирләрен бер җиргә җыярга, ыстан туктарга әмер бирде... Бер төн ыстан туктап кунгач кына, Сүбәдәй, ниһаять, әрнеп,

эшнең асылына төшенде — ул тагын бер тапкыр болгарлардан җиңелде, тагын бер тапкыр качты. Алда Каракорым, яланаяк чабып үскән Күрәлән елгасы буйлары, угланы Тайчин, хатыны Сөябел иде...

Олуг хан алдында ни дип җавап тотасын Сүбәдәй баһадир белми иде әле. Ләкин бер хакыйкать ачык иде аңа: болгарларны яуларга утызкырык мең яугир белән генә килү магулларга янә җиңү китермәячәк. Камил корал һәм кимендә йөз, йөз илле мең яугир булганда гына ошбу тарафларга кабат яу килү магулларга җиңү китерәчәк.

## 56

Бу бары тик аның сере иде. Магуллар каланы ташлап китсәләр дә, Сөмбел яшеренгән җиреннән чыкмады, кеше күзенә күренмәде, гәрчә инәсе:

— Балакаем, калага атаң гаскәрләре кайта, җыен, каршы алырга чыгабыз,— дисә дә.

— Инәки, мунча як, минем әүвәл чистарынасым, юынасым килә. Аннары уйлашырбыз,— дип инәсен аптырышта калдырган иде.

Инәсе мунча якты. Сөмбел мунчада озаклап берүзе юынды, Болгардан китергән каен себеркесе белән рәхәтләнеп чабынды һәм пакьләнеп, алгы якка чыгып бераз хәл алгач кына «балакае»нә теләсә, шуны эшләргә әзер торган инәсенә әйтте:

— Кабаланма, инәки, кабаланма. Без котылдык. Азамат егетләребез дә исән-сау әйләнеп кайтсалар — шул булыр безнең бәхет.

— Йа, Хода, балакаем, атаң сабырлыклары бардыр үзеңдә, шулай итәрбез, шулай итәрбез, иншалла, барысы да әйбәт булыр. Теге, ни, Хансөяр кияү дә үз алае белән килгән икән. Ходаем, рәхмәт инде, рәхмәт, сакладың, сакладың халкыңны.

Мунчадан соң яңа киемнәр киеп, бит-йөзенә иннек-кершәннәр сөрткәч кенә, тынычлана төште Сөмбел һәм ни сәбәпледер үзалдына көлемсерәп куйды. Йомшак ак киез, кырпача һәм мендәр ташлаган түрдә утыра, ә һәр әгъзасында нindидер үзе дә белеп бетермәгән үзгәреш башлануын тоя. Сәер тойгы иде бу Сөмбел өчен: куанычлы да, куркыныч та. Тик бит моны ул үзе теләде, кызгану хисе аша үзе аның кочагына иңде. Хак, күңел төпкелегендә сыкрауга хас ят хис көйри. Кайчак ул үзен һарун әр-Рәшид хәлифәнең хатыны Зөбәйдә итеп күз алдына китерә. Тарихчылар хәлифә хатыны Зөбәйдәне гүзәллеге, ягымлылыгы, татлы телле булуы белән аңа тиң хатын юк иде, дип раслыйлар. Шул ук вакытта юмартлыгын да читкә куеп калдырмыйлар. Чөнки тиңе булмаган гүзәл шәһәрне ул салдыра. Тәбриз дип аталган бу калада бигрәк тә хәлиф ял итәргә яраткан, имеш. Әйе, милади белән 733 елда вафат булган гүзәл хәлифә хатыны Зөбәйдә түгел ул, була да алмас. Ләкин бит аның исеме белән кала сала башладылар, салдылар да инде, анда бүген меңләгән гаилә яши, сәүдәгәрләр өзелми һәм каласына исән-имин әйләнеп кайтса, ул тагын-тагын да бик күп изгелекләр кылыр. Һәм бу изгелекләрне ул ир-канаты хан оныгы Хансөяр аша эшләр. Тик моңа кадәр аның күзенә күренәсе, барысын да түкми-чәчми сөйлисе бар шул әле. Ул хәлен анасына әйтер, әйтми чарасы юктыр, ә менә ир-канаты Хансөяргә әйтү ярармы? Аңлармы ул аны, хәлемә керерме, аннан соң... мине элеккечә ярата алырмы?..

Аның язмышы анасы Акбикә кулында иде. Юк, Аллаһы тәгалә кулында, Раббысы нә язган — шул булыр. Сөмбел хәзер үз язмышына үзе җаваплы түгел, ул үз язмышын Аллаһы тәгалә кулына тапшыра. Ул гүя язгы көннәрне көтеп алучы очар кош. Һәрхәлдә, шул халәттә ул. Хәтерендә, яз килдеме, далага чыгар иде дә күктәге тургай моңына хәйран калып, тыңлап торыр иде. Моның өстенә вак кына ерганакларның елгага ашкынуларын күрер иде дә кулларын селкә-селкә күккә ашар сыман иде.

Эченә тулган шатлыктан, хәйрани табигать моңыннан сихерләнер вә тылсымланыр иде. Аны бөтен кыпчак халкы яратты, аңа сокландылар. Шушы сөйкемлелеге һәм тиңсез гүзәллеге аша ул хәтта дошманны да җиңде. Аны богаулап Каракорымга озатмадылар, ат коерыгына такмадылар. Ә бит мондый хәлләрне дә күргәне булгалады аның. Ул явыз дошманның угланын үзенә гашыйк итте. Ул аны үзенең гүзәллеге, сабырлыгы, тыйнаклыгы һәм нәүмизлеге белән саргайтты, чарасыз итте.

Фикер чылбыры өзелде, зеңләп идәнгә төште, ишектә инәсе күренде, шатлыгы йөзенә чыккан, күзләрендә — яшь.

— Балакаем, Ташбай углан, Ташбай углан килде!

— Мин нишлим, инәки?

— Чык әйдә, каршы ал. Ул сиңа сөенче китергән. Дошманны җиңгәннәр, аннары Айгөлс малай тапкан, түбәсе күктә.

— Хансөяр, Хансөяр кая соң, инәки?

— Ул дошманны куа киткән. Сүбәдәй баһадирның башына җитми кайтмыйм, дип әйткән, диләр.

— Инәки, инәки! — Сөмбел сәкедән төште, инәсенең күкрәгенә килеп капланды һәм сулкылдап елап җибәрде.— Инәки!..

— Ни булды, балакаем, ни булды? Елама, шатланасы ит. Атаң дошманны җиңеп кайта... Әллә шатлыктан елыйсыңмы?.. Ела, ела, күз яше мең чирдән коткарыр, ди. Күз нурым минем...

— Инәки, инәки, мин иремә хыянәт иттем, инәки!..

— Абау, балакаем, абау, тәүбә диген!.. Як-ягыңа төкерен...

Сөмбелнең күзләренә карады һәм барысын да аңлады инәсе. Сөт имезгән күкрәгенә кысты, бик озак башыннан сыйпады.

— Мине алар кол иттеләр, инәки. Урладылар, рәнҗеттеләр.

— Син исән-сау бит, балакаем. Килеш. Хатын-кыз башы күрмәгән нәрсә түгел. Чит ир-ат белән якынлык кылу, саф йөрәктән булса, җир өстеннән үткән болыт күләгәсе генә ул. Аллаһы тәгалә ярлыкар, үз теләгең белән моңа бармагансыңдыр...

— Үз теләгем белән, инәки, үз теләгем белән...

— Әй, балакаем, алай икән, нишләп тә булмый инде. Фәрештәләрең хөҗрәңә ул адәмнең дә исемен язып куйган булгандыр, балакай. Язмыштан узмыш юктыр. Бер дә уфтанасы итмә. Әйдә, әнә керәп тә килә инде, кузгал, җиңүчене каршы алыйк...

# ШИГЪРИЯТ



## Харрас Әюп

### Гармун бәйрәме

Урамнарда гармун бәйрәмнәре,
Бәйрәмнәрдән ничек каласың?!
Өзгәләнә гармуннары илнең,
Уятырга адәм баласын.

Өзгәләнә гармуннары илнең...
Халык җаны, димәк, буш түгел.
Әйтер сүзен ул бит гомер буе
Гармуннарга, җырга кушты гел.

Буш булалмый бүген халык җаны,
Шуңа карап гамәл кылына:
Кемдер җирдә кылыч күтәргәндә,
Гармун ала татар — кулына.

Гармун ала татар...
Җилкендерә
Эчләрендә җаны булганны.
Көйләр булып күтәрелә еллар...
Җиңеп кара шушы моңнарны!

Мәйданнарга гармуннары чыга
Ялганына каршы ятларның —
Кылычларың бер яктарак торсын
Гармуннары барда татарның...

---

Харрас ӘЮП (1946) — *шагыйрь, дистәгә якын китап («Сабыр савытлары», «Төнге кояшлар», «Таң суы» һ. б.) авторы. Казанда яши.*

Өзгәләнә гармуннары чорның,
Күңелдәген әйтеп, илдәген.
Бәйрәм генә булыр иде җирдә,
Тыңласалар халык йөрәген...

## Күтәр

Без бит болай түбән түгел идек,
Күтәр мине, күтәр, канатым! —
Ваклыклары өчен түгел,
Җирне
Аклыклары өчен яраттым.

Үткәннәргә кадәр күтәр мине,
Күтәрел дә, кире төшермә:
Түбәнлеккә төшүдән дә хәтәр
Нәрсә булсын тере кешегә?!

Биеккәрәк күтәр, биеккәрәк —
Замананың буе җитмәсен.
Үзең генә,
Үзең генә елат...
Үзең генә бары сөрт яшем!

Без бит болай түбән түгел идек,
Тарихтагы хата бу бары.
Бабайларның якты рухлары
Әле дә булса тарта югары.

Түбәннәрнең үзен уза алмый
Безнең хакта яман хәбәре.
Күтәр мине, күтәр, и канатым,
Үзебезнең күккә кадәрле!..

## Без бит ул...

Җил тузгыр... Үләннәр саргаер...
Коелыр яфраклар... —
Көз бит ул!
Көзләрдән-көзләргә сикереп
Дөрләгән — без бит ул...
Без бит ул!

Юатыр... Кайчакта елатыр...
Кагылыр җаныңа... —
Сүз бит ул!
Сүзләрдән-сүзләргә ялганып
Янган ут — без бит ул...
Без бит ул!

Какса да, сукса да —
Беркемгә

Чит түгел дөньялар — үз бит ул.
Мәңгелек буенча дөньяга
Кабынган — без бит ул...
Без бит ул!..

## Буран тынган ара...

Күкне — җиргә, җирне — күккә орды,
Атна буе котырынды буран.
Аннан тынып калды:
«Бу дөньяны
Нишләтәсең инде...» — дигән сыман.

Кар көрәде авыл агайлары.
Кар өстенә иңде караңгылык.
Җир йөзендә ак һәм кара калды,
Без кичәсе шомлы ара булып.

Тып-тын иде кышкы авыл киче.
Күңелләр көр, җаннар тыныч иде...
Яшен-картын сискәндереп кинәт,
Өстурманнан шомлы аваз килде.

Кабатланды тагын...
Бураннарда
Адашканмы әллә берәр бәндә?
Ачы итеп нигә кычкыра ул
Урман уртасында... Төн кергәндә?..

Ат җиктеләр ирләр...
Бөтен авыл
Эзләгәндер аны иртәнгәчә.
Мылтыклардан атып карадылар...
Таба гына алмадылар гәрчә.

Без кичәсе шомлы ара булып,
Җир өстендә йөрде ак һәм кара...
...Ул кич инде әллә кайда калды,
Ерагая, ерагая ара.

Тик хәтердән китми теге тавыш:
Ни дип аваз салды, кем булды ул?
Еллар буе нигә пошындырып
Искә төшә болай,
Ник моңлы ул?

Нигә әле аягына басты
Бөтен авыл ул чак, күрше-тирә?
Ак һәм кара еллар арасында
Ул аваз бит һаман ишетелә!

Ишетелә...
Бары яшь аралаш

Ишетмәскә генә салышабыз.
Җавап бирер хәлдә түгелдер шул
Давыллардан килгән тавышка без...

Нишләтәсең инде бу дөньяны —
Дулар буран...
Кар-бураннар тынгач,
Кычкырыр ул.—
Ишетсәгез әгәр,
Эзләмәгез — Өстурманда булмас...

* * *

Ишетәм көзге җилләрдә:
«И улым... балакаем!..» —
Ул каен — зират өстендә...
Син кайда, Бала Каен?!

Кайда син, кайсы якларда?
Кайда да җилдер инде...
Каенга — каен язмышы:
Җилбер дә җилбер инде!

Кайларда тамырлансаң да,
Каеннар усак булмас.
Каенда — каен башлары:
Кайгыдан бушап булмас...

Ишетәм, әнкәй, ишетәм —
Җил генә кебек ара.
Илдәге Бала Каеннар
Давылга кереп бара.
Давылга кереп бара...

* * *

Кемнәр генә жирдә яшәмәгән,
Миңа инде ни сан?!
Әллә артык зур булды бу дөнья,
Әллә инде кысан:

Иртә-кичен моңга әйләнәдер,
Башларыңны куйсаң —
Дөнья хәтле дөнья бит әле ул —
Барсын җанга җыйсаң!..

Зурлыгын да, хурлыгын да бергә
Сыйдырала җиһан.
Бар да ташлап китә тора никтер —
Дөньяларга ни сан!..

## Гомер буе...

Чирәмнәрдән табан аерылса,
Сине юньләп танымыйлар икән:
Гомер буе — малай бит син юкса...
Шул малайга «абый» диләр икән!

Чирәмнәрдән табан аерылса,
«Җаный» диләр...
«Әти» диләр беркөн.
Теге «малай» уйный шулар белән...
Малай икәнлеген сизми беркем.

Замана да берни белми икән:
Зур-зур эшләр йөкли «малай»ларга.
Авыр булса-булыр — күтәрәләр...
Җиргә җиңелрәк алар барда.

Ак сакаллы «малай» итә дөнья,
Калебеңә сала бер алласын... —
Нинди кыяфәткә кертсәләр дә,
Шул «малай»лар бездә югалмасын!

Танымаслар...
Искәрмәсләр бәлки
Гомер буе — малай булганыңны.
...Дөньялыкка нинди хәлдә бирсә,
Шулай алсын ходай бу җанымны...

* * *

Күкләргә йолдызлар чәчелгән,
Бер калка җемелдәп, бер сүнә...
Карыймын күзләрем талганчы —
Нигә соң син түгел берсе дә?!

Тирән шул дөньялар, әй тирән —
Җитәлми карашым, җитәлми...
Җирдәге сөюнең яктысы
Йолдыздан арырак микәнни?

Сине соң тәкъдирләр нигә дип
Бу чаклы еракка яшергән? —
Күкләргә ашкына гомерләр.
Алдыма йолдызлар чәчелгән...

## Ай нурында

Бар серләрен Айга сөйләгәннәр:
Гашыйкларның бүтән юлы юк.
Катлам-катлам сөю икән лә Ай —
Заманнардан килгән җыелып.

...Әй тирән дә иде Ай ул төнне,
Төпләрендә аның син идең —
Якты идең...
Мөлдерәмә тулы
Сөю аша җиргә түгелдең.

Син белдең бит җирдә мин икәнне,
Белдең бит син Айга карасым.
Тик белмәдең бугай карашымның
Мәңгелеккә анда каласын.

Гашыйклары килер дәверләрнең
Ай дип белер... Сөйләр серләрен...
Безнең сөюләр дә яктыртачак
Җирнең әле әллә кемнәрен...

* * *

Дөньяга мин сине эзләп килдем.
Эзләгәнем, шөкер, табып китәм.
Шуның өчен, акылымда килеш,
«Исәр» дигән исем тагып китәм.

Дөньяга мин сине эзләп килдем.
Эзләгәнем, шөкер, табып китәм —
Үтеп чыга алмас ут икәнсең...
Үземне мин утка ягып китәм.

Дөньяга мин сине эзләп килдем.
Эзләгәнем, шөкер, табып китәм.
Соң булса да,
өрфиядәй җанны
Иңнәреңә синең ябып китәм...

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Марат Әмирхан

# ҮЛМӘ, ӘХМӘТХАН!

ПОВЕСТЬ

Әхмәт көтмәгәндә егылды. Дөресрәге, якыннары, туганнары шулай уйлады. Чөнки ул бервакытта да, беркемгә дә үзенең чын хәлен белгертмәде. Эчендә ут янамы, дәрья котырынамы, сүтеп салырга ашыкмады, тешләрен кысып булса да түзде. Ләкин түземлек, үҗәтлек белән генә чир-хастаны җиңеп булмый икән, әҗәл кайчан да булса рәхимсезлеге белән бугаздан алырга тиештер, күрәсең. Ник дисәң, аның вазифасы шул — гомер өзү, гомер кыскарту.

Әхмәтне чир шау-шулы бер митингтан кайтышлый үзләренең ишек алдында тотты. Әйтерсең лә искәртмәстән башына күсәк белән тондырдылар! «Аһ» итте дә шул ук мизгелдә сыгылып та төште.

Нурсинә кер эләргә дип ишегалдына чыккан иде, ирен мөшкел хәлдә күргәч, үзен-үзе белештермичә тиз арада аның янына килеп тезләнде. Кер тулы чиләкләре авып, койма ягына тәгәрәде.

— Әхмәткәем, җанашым, ни булды? — дип, ул аны урыныннан кузгатырга тырышып карады.

Менә Әхмәтнең күм-күк булган иреннәре кыйшангандай булды, күз керфекләре аз гына җилпенеп куйды, әмма авызыннан сүзе чыкмады, янә изрәп төште.

Нурсинә сикереп урыныннан торды: ашыгыч ярдәм машинасы чакыртырга кирәк ләбаса! Күршеләрендә телефон бар иде, шуларга йөгерде.

Янтавына кызыл хач төшерелгән машина озак көттермәде, выжылдап килеп тә җитте. Аның үзен утыртасы түгел иделәр дә, «Әхмәт махсус исәптә, аны кая алып барырга икәнен мин генә беләм», — дигәч, күнделәр тагын.

---

Марат ӘМИРХАН (1933) — *язучы. «Таш һәйкәл», «Чулманның ак йолдызы», «Сөн моңы» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге бүләге лауреаты. Казанда яши.*

— Без сезне күптәннән кисәтеп килəбез,— диделәр хастаханәдә,— ирегезнең йөрәге гамәлгә яраклы түгел. Бердәнбер юл операция, йөрәген алыштыру.

Нурсинә ире аңына килгәнче үк ризалык кәгазенә кул куйды. Хәлбуки, Әхмәт үзенең рөхсәтен күптән биргән иде инде, соңгы сүзне хатыны әйтер дигән иде ул табибларга.

Әхмәтнең хәле, чыннан да, начар иде. Приступ арты приступ. Агарынды, хәлсезләнде мескенем, бөтен торышын, килеш-килбәтен ниндидер битарафлык, өметсезлек чаткылары биләп алды. Күзгә күренеп сүнеп бара иде ул.

* * *

Кайчандыр чая, тәвәккәл егет иде Әхмәт, таякны тоткан урыныннан сындырырга ярата иде. Шуңа күрә кыз-кыркын охшата иде үзен, Нурсинәне дә бер күрүдә әсир иткән иде ул.

Шулай бервакыт Нурсинәләр дус кызларының туган көнен яшьләр кафесында билгеләп үтәргә җыендылар. Мондый кичәгә беренче тапкыр килүләре иде. Акча күплектән түгел, юк, бигрәк тә кызык өчен, башкаларның ничек итеп күңел ачуларын карау-күзәтү өчен җөрьәт иткәннәр иде бу адымга. Элемтә техникумының беренче курс студентлары өчен бу үзенә күрә бер тәвәккәллек тә иде әле.

Берәр чынаяк кофе, икешәр печенье алып, кызлар иң аргы почмактагы өстәл янына кунакладылар. Музыка уйный. Ярым-шәрә җарияләр, бар булган хәзинәләрен берьюлы тамашага куеп, үзләре кебек үк бәйсезйөгәнсез әтәч-егетләр белән әллә нинди рәвешләргә керәләр: бөгеләләр, сыгылалар, сырышалар, кочаклашалар.

Беркемнең беркемдә эше юк, кем нәрсә тели, шуны кылана. Өстәлләрдә эреле-ваклы шешәләр, кыйммәтле ризыклар. Чиркәү кыңгырауларыдай рюмкалар чыңылдый. Шау-шу. Сүзләрдә бернинди япма юк, колаклар үрә торырлык.

Техникум кызлары, көзге чебешләр шикелле бер-берсенә елышып, шушы тамашаны күзәтәләр. Аларга игътибар итүче күренми. Озын җиңле кофта кигәннәрне монда санга сукмыйлар икән.

Зал кызганнан кыза бара, очкын чыкса, кабынып та китәр иде, шәт. Хәер, кызлар да батырая төште, акрын-акрын әлеге дулкын аларны да ялмап алды, бер-ике мәртәбә инде үз өстәлләре тирәсендә генә булса да биеп тә карадылар.

Кайту турында сүз кузгалды. Ләкин нәкъ шул вакытта кемдер аларның өстәленә шампан шешәсе китереп утыртты. Күтәрелеп карасалар, авызындагы бар булган тешләрен күрсәтеп, каршыларында урта буйлы, шома чәчле егет басып тора. Куе калын кашларын, тырпаеп торган зур колакларын исәпкә алмаганда, аны хәтта чибәр дияргә дә мөмкин иде.

— Сезләргә бездән,— диде ул күзләрен мутландырып.

— Белмәгән егетләрдән без бүләк кабул итмибез,— диеп беренчеләрдән Нурсинә уенга керде. Башкалар, аны хуплагандай, гөрләшеп алдылар. Искиткеч шат иде алар бу мизгелдә. Ниһаять, аларга да игътибар иттеләр! Кызларның һәрберсе күңеленнән генә булса да, кемнеңдер биергә чакыруы, сүз кушуы турында хыялланa иде, билгеле. Һәм менә аларның да бәхет сәгатьләре сукты бугай...

— Ошатам үзебезнең татар кызларын, инсафлы алар,— дип сөйләнә-сөйләнә, егет касәләргә шәраб агызды, өстәл өстенә конфетлар сипте.

— Танышу хакына, гүзәлкәйләр! — диде ул.— Минем исемем Әхмәт, сезләрне кем дип белик?

Кызлар ялындырып тормады, артык тыйнаклыкның биредә бәяләнмәвен күргәннәр иде инде алар. Шампан башта аларның йөзләренә алсу

төс булып кунды, аннан кан тамырлары буйлап тәпиләренә төште, телләрен чиште, рухларына иркенлек, бәйсезлек килде. Кычкырып-кычкырып көлә башладылар. Ә бераздан аларның һәрберсенә пар табылган иде инде. Монысы, мөгаен, Әхмәтнең тырышлыгы булгандыр. Ул үзе Нурсинәне сайлады. Ярым караңгы залда, әйтерсең лә, алар үзләре генә. Егет кызның колагына ул моңарчы ишетмәгән әллә нинди матур сүзләр пышылдады, гәүдә-сынының, чәче, муенының зифалыгына соклануын кат-кат әйтте.

Нурсинәнең мондый мөгамәләдән җиңелчә генә башы әйләнде, Әхмәтнең кайнар тыны, көчле куллары аның тәнен, җанын уятты, күкрәк алмалары күлмәген тишеп чыгардай булып тырпайды, үзе дә сизмәстән ул егет куенына елышканнан-елыша барды, иреннәре очрашканда да башын бормады, карышмады.

— Мин сине яратам,— дип кайнарланды Әхмәт.

— Мин дә...— дип ычкындырды Нурсинә. Һәм шунда ук үзе сүзләреннән үзе оялып та куйды. Күр инде син аны, күрмәгән-белмәгән егет белән ниләр кылана бит. Нинди ярату ди ул, йә хода, моннан да гайре башсызлыкның булуы мөмкинме соң? Ул тирә-юньгә күз салды, дус кызларын эзләде, ләкин ярым караңгы залда энә төшмәслек кеше арасыннан аларны табу җиңел эш түгел иде. Нурсинә үзен япа-ялгыз карурман эчендә калгандай хис итте.

— Әхмәт, миңа китәргә кирәк,— дип ул кулларын егетнең җилкәсеннән төшерде.

— Иртә әле, Нурсик, тагын бераз гына...

— Җитте инде, бик күңелле булды, рәхмәт, мине көтәләр...

— Кемнәр?!

— Кемнәр дип... әти... әни...

Егетнең йөзе яктырып китте.

— Ә-ә, әти-әнигә генә кул куям,— диде ул,— егетем көтә дисәң, валлаһи, йөрәгем ярыла иде.

— Бигрәк инде син...

— Чыннан да беркемең дә юкмы?

— Ничә тапкыр кабатларга инде сиңа.

— Син барыбер дөресен әйтмисең, Нурсик.

— Ничек?

— Ничек, ничек? Ә мин? Мин егет түгелмени? Егетнең дә нинди әле!

— И, мактанчык...

— Әле шулаймыни, мактанчыкмыни?!.

Әхмәт кызны күтәреп алды да, биючеләрне терсәге белән төрткәлитөрткәли, урамга алып чыкты. Тиз генә мотоциклын кабызып, Нурсинәне утыртты һәм төнге урамга ыргылды. Оста иде булса кирәк Әхмәт, бер җирдә дә тукталып тормады. Машиналар рәтен ера-ера мотоцикл түгел, велосипед та борын төртә алмастай аралардан еландай шуышты, трамвай юлларын, чокыр-чакырларны очып кына үтте, җиргә авышып бетеп текә борылышлар ясады һәм, күп тә үтми, бүрәнәдән салынган бер өйнең капка төбенә килеп тә туктады.

— Сиңа бераз гына көтәргә туры килер,— дип, Әхмәт кечкенә капканы ачты.— Мин хәзер!

Нурсинәгә боларның барысы да төш кебек кенә булып тоелды. Кечкенә вакытта күргән төшләрен ул чын дип исәпли иде, әти-әнисеннән шул төш галәмәтләрен таптырып иза чигерә иде. Хәзер, әнә, чын гамәл дә төш кебек. Нинди сихерле, нинди магнитлы егет булып чыкты соң бу Әхмәт. Бер күрүдә гашыйк итте дә куйды түгелме соң? Инде менә аңа ышанып, шәһәр читенә үк килеп чыкты. Нәрсә эшләмәк була ул, уенда ни? Үзе дә инде, кая алып барасың дип тә кызыксынмады, чат ябышты. Әле ярый, әти-әнисенә иптәш кызларымда кунам дигән иде. Бу җир тишегеннән алай тиз генә әйләнеп кайтып та булмастыр, мөгаен. Шулай

да ни көтеп утыра соң әле ул? Бәлкем, Әхмәт бер-бер усал ният белән алып килгәндер аны бирегә. Ышан син егетләргә, нинди генә сүзләр йөрми шәһәрдә хәзер? Юк-юк, кул кушырып утыру ярамас, югыйсә, соң булуы бар...

Бу вакытта Әхмәт әти-әнисен уяткан иде инде.

— Сезгә килен алып кайттым,— диде ул,— каршы алырга әзерләнегез!

— Бүген-иртәгә армиягә китәргә торасың, бу нинди галәмәт?— дип әнисе күзләрен зур ачып, улына карады.

— Башыңны җүләргә салма!— дип орышты әтисе.— Болай кызлар рәнҗетеп йөри торган булсаң, бел, бернәрсәгә дә риза-бәхиллегем юк.

— Мин чынлап әйтәм,— диде Әхмәт,— бик әйбәт кыз ул, әти,во!

— Әйбәт кызлар... Җиде төн уртасында егеткә ябышып кайтмыйлар. Әйбәт кызлар, улым, горур була, аларны зурлап, көн яктысында, бөтен халык алдында килен итеп төшерәләр. Себеркесе үз урынында түгелдер аның, улым, андыйларны куеныңа кертә күрмә, алардан ерак йөр.

— Себеркесе, себеркесе, җыен тузга язмаган сүзләр синдә инде, әти!

— Ярый, ярый, алайса кая соң ул әйбәт кызың? Күрсәт әле безгә.

— Капка төбендә генә ул!

— Әйдә соң, күрик, сөйләшик, кыз баланы көттерү килешмәс.

Урамга алар барысы бергә чыктылар. Ләкин булачак киленнән җилләр искән иде инде...

* * *

Хирург Рәфкать Мортазин дигән кеше иде. Ул шушы бүлекнең җитәкчесе дә икән. Кабарынкы иренле, ике иякле, калын гәүдәле, бармаклары гына да берсе-берсе килограммга тартадыр, мөгаен. Килеш-килбәте белән генә түгел, сөйләшү рәвеше, үз-үзен тотышы ягыннан да базардагы ит чабучыга охшатты аны Нурсинә. Операцияне кайчан ясарсыз икән, дигән соравына да: «Юлда тизрәк авария булсын да, берәр яшь егет һәлакәткә юлыксын иде дип теләгез»,— диде. Нурсинә моңа бик рәнҗеде. Соравына күрә җавабы дигәндәй, үзе дә бурычлы калмады.

— Сез бик дорфа икәнсез,— диде.

Хирург аңа озак кына карап торды, аннан соң һәр сүзенә басым ясап әйтте:

— Мин профессор, республикада йөрәккә операция ясаучы бердәнбер белгеч. Миңа һәммә кеше Рифкать Сафич, дип мөрәҗәгать итә, ә сез минем белән урам малае кебек сөйләшәсез, үзегез чибәр генә ханым...

— Гафу итегез,— дип бүлде аны Нурсинә,— белмәдем...

Профессорга бу бүлдерү дә ошамады ахры, чебен кугандай кулларын чәбәләп алды да сүзен дәвам итте:

— Беләсегез килсә, күгәрченкәем, авария генә дә аз, бу авария вакытында әлеге егетнең башына гына зыян килергә тиеш. Ә ул үзе ирегездән 8—10 яшькә кечерәк булырга тиеш. Аннан китереп, тән тукымалары, канның тәңгәл килүе шарт. Менә шушы таләпләргә җавап биргән мәрхүмнең исән йөрәген генә куя алабыз иренә, аңлашылдымы?

Нурсинәне бу сүзләр тетрәндереп җибәрде. Әйе, дип уйлады ул, Әхмәткә донор йөрәген тегеп куячаклар ич! Җә, хода, бу йөрәк әлегә юк та бит әле. Аның иясе, ихтимал, бу минутларда сөйгән кызы белән култыклашып йөридер, киләчәк турында берсеннән-берсе матуррак планнар кораладыр, бәхетле тигез тормыш хакында хыялланаладыр. Егет, әлбәттә, аның сау йөрәген зар-интизар булып көтеп ятучы Әхмәтнең дөньяда барлыгын да белми. Тик ул бүгенме-иртәгәме барыбер фаҗигагә дучар булачак. Бу инде аның маңгаенa язылган. Язмышы! Нинди гаделсезлек?! Җә, нигә инде берәүнең тормышын саклап калу өчен икенче

кешенең гомере өзелергә тиеш? Кем гаепле моңа? Әхмәтме? Алай дисәң, фаҗигаләр барыбер була тора. Әхмәт үзе дә шундый ук фаҗига корбаны ләбаса. Әлеге егет, бәлкем, үз гаебе белән юлыгыр ул авариягә. Әхмәтне исә явызларча, белә торып изделәр.

Баштагы мәлне Нурсинә иренең саташу-бастырылуларына күнә алмый азапланды. Төн уртасында капылт кына сикереп тора да, кулларын буташтыра-буташтыра стенага бәргәләнә, үксеп елый, тимәгез, дип ялвара. Кайвакыт усалланып кычкыра, үч алу белән яный. Еш кына: «Мин кенәз түгел»,— дип аклана да.

Комга ташланган балык шикелле өзгәләнә, тирли, яна-пешә. Нурсинә аны көч-хәл белән генә тынычландыра иде.

Иртән исә Әхмәт һичнәрсә булмагандай йөри. Шундый гүзәл җанашың назласын әле, саташу түгел, шашарсың да, дип җорланган була...

* * *

Нурсинә кечкенә сумкасыннан көзгесен алды да, җентекләп үзен күзәтергә кереште. Көзгедән аңа озынча ак йөзле, зур күзле, кыйгач кашлы чибәр ханым текәлеп карап тора иде. Куе коңгырт чәчләре тәлгәш-тәлгәш булып шома маңгаена яткан. Озын ак муены аның бу нәфислегенә ниндидер горурлык, мәһабәтлек һәм самимилек өсти иде.

Хатын боларга артык игътибар итмәде, чибәрлеген ул, әлбәттә, белә иде. Бу юлы аны бит алмаларында ярылып яткан эзләр борчыды. Юк, миңа еларга ярамый, Әхмәт күз яшьләремне күрергә тиеш түгел, дип күңеленә беркетеп куйды, тиз генә үзен рәткә китерде. Тик Әхмәт, ишек уемында хатыны пәйда булуга, барысын да аңлады.

Нидер, и сөйгәнем, бу яшь күздә,
Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?—

дип шигырь әйтте.

Нурсинә түзмәде, башын иренең күкрәгенә салды да сабый бала сымак елап җибәрде. Әхмәт аны тыймады да, бүлмәде дә. Әле тынычлангач та бу турыда сүз кузгатмады, киресенчә, белмәмешкә салышты, хәле хәл булуга карамастан, хатынын көлдерергә тырышты, шаярткан булды.

Буе зифа, йөзе күркәм, үзе яшь;
Күзе кара, озын керпек, каләм каш.
Йөзен якты күреп, сандым аны нур,
Булыр нур, баксам: ул — иннек тә акбур.

Шәпме— дип ул Нурсинәнең кулларын алды. Аннан үз алдына сөйләгәндәй тезеп китте:

— Дәрдемәнд! Коеп куйган шагыйрь. Аның иҗатын әти яттан белә иде. Ә мин, җүләр, татарда бөек шагыйрьләр дә, язучылар да, галимнәр дә юк, дип аның белән сүз көрәштерә идем. Янәсе, Пушкин, Бальзак, Байрон, Шекспирларга җитәме соң?! Хәер, татарга сан бар идемени, гел хурладылар, имеш, руслар ярдәм итмәсә, татар милләте әллә кайчан аяк сузган булыр иде инде. Без моңа ышандык, тарихыбызга, мәдәниятебезгә илтифат итмәдек, хәтта кайвакыт ваз кичтек. Иң аянычы, аны белмичә ваз кичтек. Телен кире каккач, аның башкасы турында сөйлисе дә юк.

— Бар кешене дә бер аршын белән үлчәмә инде,— Нурсинә,— әткәй, әнә, Дәрдемәндне яттан белгән, син үзең дә башка кеше хәзер...

— Мин башка чут, мине солдатта мәҗбүр иттеләр, татарлыкка кайтырга мәҗбүр иттеләр! Бер яманның бер яхшысы, диләрме әле?

— Җә, җә, сиңа борчылырга ярамый,— дип Нурсинә аның чәчләреннән сыйпады. Никадәр көч, түземлек үзендә, дип уйлады ул эченнән генә, нинди язмыш көткәнен белә ләбаса! Әйтерсең лә бу авыр, куркыныч операцияне аңа түгел, башка берәүгә ясаячаклар. Шигырьләр сөйләп яткан була бит әле, бәгырькәем.

Бу хәлгә Нурсинә, әлбәттә, сөенде генә. Буласы аның барыбер була инде, күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый, диләр бит. Алдан янып-көюдән ни файда. Әнә, ясалма сулыш алдыра башлагач, йөрәген стимуляторга тоташтыргач, үзгәреп китте. Шаяра, көлә, кәефе әйбәтләнде. Ходаем, операциясе дә хәвеф-хәтәрсез генә үтсә иде инде...

* * *

Әхмәт армиядә бер генә ел хезмәт итте, аның да шактый өлешен госпитальләрдә аунап үткәрде. Ахырда кулына ак билет тоттырып, кайтарып җибәрделәр.

Хәрби ант кабул иткәнче барысы да әйбәт кебек иде. Авыз тутырып сөйләрлек тәртип бозулар, мәсхәрәләүләр булмады. Чөнки яшь солдатлар үзләре генә иде, үз эшләре, аларны башкалар белән бутамадылар. Һәм дөрес эшләделәр. Яшь хәрбиләр мәктәбен тыныч кына барысы бергә укыту-өйрәтү үзәгендә узу аларга күп нәрсә бирде. Офицерлар да игътибарлы иде. Солдат хезмәте хәтта ошый да башлаган иде Әхмәткә.

Даими хезмәт итү урынына килгәч башланды мәхшәр. Килгән көнне үк сары чәчле, үгездәй таза ефрейтор аның кырыну машинкасын тартып алды.

— Ох, минем күптәнге хыялым бу, кенәз! Фәрештәнең амин дигән вакытына туры килгән икән,— диде ул иреннәрен бөрештереп.

— Сөйләп торасың тагын, рәхим итеп кырын, биреп торырмын,— диде Әхмәт.— Тик минем исемем кенәз түгел, Әхмәтхан!

— О-о, әле син хан да икәнсең! — Ефрейтор чучканыкы төсле аксыл керфекле күзләре белән Әхмәткә кадалды. Ай-һай, бу бәндә белән юлларың кисешә күрмәсен, дип калтыранып китте Әхмәт.

Әмма юллары кисешкән иде инде. Ефрейторның иреннәре янә бөреште.

— Мин сине үземә денщик итеп алам, кенәз. Урын җыю, итек майлау синең өстә, һәм дә калган башка эшләр...

Казармага старшина килеп керде, йокы вакыты җиткән икән. Әхмәт җиңел сулап куйды, шаярта гынадыр ла бу, чучка күз, дип үз-үзен юатты ул, командирлар күрәләтә шундый башбаштаклыкка юл куя ди мени, армия ич бу!

Солдатның көтеп алган иң кадерле нәрсәсе — ашау белән йокы. Мендәргә башы тиюгә, эри дә китә ул. Әгәр ирекке куйсалар, икс-өч тәүлек рәттән урыныннан тормас иде. Одеал астына чумдыңмы, бөтен күңелсезлек, барлык ару-талуларың, сагыну-сагышларың онытыла.

«Подъем!» дигән әмер яңгыраганда, Әхмәт әле яңа гына яткан кебек иде, чынында иртә икән инде. Төн бер сулышта үткән дә киткән. Ул йокы аралаш сикереп торды да, бернәрсәгә дә игътибар итмичә ашыга-ашыга урынын җыештыра башлады. Чөнки яшь хәрбиләр үзәгендә аларның һәр гамәлен секундомер белән санап-билгеләп торалар иде. Тизрәк, дип үзен-үзе камчылады ул, яңа урында сынатырга ярамый!

Колагына кемнәрнеңдер көлешкән тавышы ишетелде. Караса, селкенүче юк дәрәҗәсендә, калганнарның җылы ятакларыннан аерыласы килми иде, ахрысы, хәтта кайберләре баштанаяк ук томаланып ятканнар, бары ул да, аның белән килгән яшь солдатлар гына торып баскан.

Бераздан казармага бер сержант килеп керде. Ул учы белән күзләрен уа-уа:

— Бүген кемнәрнең чираты, физзарядкага тезелегез,— диде.

— Кенәз, физзарядканы минем өчен дә яса,— дип тешләрен ыржайтып калды кичәге ефрейтор.

Әхмәткә тәки сагыз булып ябышты бу ләгънәт, ашханәгә барыр алдыннан да ул аны бармагы белән генә үз янына чакырды. Ләкин Әхмәт аңламаганга салышты. Тегесе иренмәде, аның янына үзе килде.

— Кенәз,— диде ул, мыскыллы бер елмаюдан очлы казык тешләре күренде,— урынны җыештырмагансың ич, ә мин ике кат әйтергә күнекмәгән, армия бу, дисциплина, белдеңме?!

— Мин дә ялчы хезмәтенә күнекмәгән,— диде Әхмәт.

— О-о, гафу, кенәз, гафу...

Ефрейтор билен бөккән булды, үкчәләрендә бөтерелеп алды һәм шул уңайдан тезе белән Әхмәтнең касыгына китереп төртте. Әхмәт чайкалып китте, әмма егылмады, ефрейторның аягыннан җайлы гына эләктереп, тегене идәнгә тәгәрәтте. Әүмәкләшеп киттеләр. Шулвакыт казармага старшина килеп керде.

— Отставить, бу нинди тәртипсезлек! — дип бугазын киереп кычкырды ул.

— Менә, иптәш старшина, яшь солдат ни кылана,— диде ефрейтор мескен кыяфәткә кереп.— Үзе ямь-яшел әле, ә яман холкын күрсәтә башлады инде.

— Смирно! — дип элеккесеннән дә көчлерәк итеп бакырды старшина — рядовой Галиев, сиңа чираттан тыш өч наряд. Аннан соң, Әхмәткә генә ишеттереп теш арасыннан сөзде:— Монысы гына аз тоелса, гауптвахта да эләгер, обрезок...

— Бүтән мондый башбаштаклыкка юл куелмас, иптәш старшина,— диде ефрейтор ялагайланып.

— Яхшы, Никифоров, яшь солдат синең җаваплылыкта,— диде старшина.

— Тыңлыйм, иптәш старшина, әмерегез үтәлер!

Әхмәт икенче көнне дә ефрейторның урынын җыештырмады. Никифоров бу юлы нәрсә уйлап табар икән инде, дип борчылып йөрсә дә, үзенә карата нинди дә этлек эшләүләрен сизмәде. Исәпләре сынап карау гына иде булса кирәк, дигән фикергә килде ул шуннан соң, өйрәсе сыек түгелме, янәсе. Баш исән, ишәләр иде мәгәр, анысы хак. Маладис, Әхмәтхан, сынатмадың, дип егет үзен-үзе мактап та куйды.

Тик иртәрәк куанган икән, кичен туалетка чыкканын сагалап торып, бик шәпләп типкәләделәр үзен. Соңыннан ай буе эченнән кан килеп йөрде. Шулай-шулай, дип старшинага әйткән иде дә, тегесе, гадәттәгечә, төкерек кенә чәчте, юкны сөйләмә, янәсе, безнең рота алдынгы рота, яхшы чакта иптәшләреңә бәйләнүдән тукта, югыйсә, чыннан да, дөмбәсләп ташларлар.

Мөнәсәбәтләр тагын да киеренкеләнде. Никифоров беркемнән шикләнмичә, ачыктан-ачык мыскыл итәргә тотынды. Беркөнне Әхмәт тумбочкасыннан дуңгыз колаклары өстерәп чыгарды, инде аның артыннан «мырык-мырык», дип көлеп кала башладылар. Үзе белән килгәннәр дә читләште. Хәзер ул кенәз генә түгел, «Кенәз-Мырык» иде инде.

Әхмәт, дөресен генә әйткәндә, «кенәз» кушаматының чын мәгънәсен аңлап та бетерми иде. Бу исемне шундый ук уңыш белән руска да, чувашка да, украинга да сыларга була, дип уйлый иде. Баксаң, әлеге кушаматның нигезендә милли кимсетелү ята икән ләбаса! Моны ул әтисеннән хат аша белде.

Радио аша ишеткән, гәзитләрдән укып белгән милли мәсьәлә белән Әхмәт беренче мәртәбә йөзгә-йөз менә шулай очрашты. Бу хәл аны бик нык борчыды. Милләтләрне ул бервакытта да бер-берсеннән аерып

карамады, аңа алар барысы да тигез, тоташ бер халык кебек тоела иде. Бердәнбер ташлама үзе сөйләшкән-аңлашкан урыс теленә генә ясала иде. Чөнки ул урыс халкын иң акыллы, иң гадел, иң культуралы халык дип исәпли иде, интернационализмны да урыс халкы киемендә кабул итә иде. Шул сәбәпле башка барлык милләтләр өлкән туганга сыенырга тиеш дип саный иде.

Ләкин үз иленнән читтә урыслар аны һич тә кочак җәеп кабул итәргә җыенмыйлар икән ич, хаҗәте юк икән аның, ул фәкать хезмәтче, ялчы гына икән. Табышмак дисәң дә табышмак. Хәер, нинди табышмак булсын ди бу, кәкәйле бәрән фәлсәфәсе, бары шул. Чөнки, ничек кенә әтәчләнмәсеннәр, Никифоров та, старшина да урыс халкы дигән сүз түгел әле. Хәтта тулаем ротаны да бу исәпкә кертергә ярамый. Ләкин дә шунысы бар, Никифоровларга ирек бирсәң, бөтен көтүне пычратачакларын көт тә тор.

Әйе, бу шулай, тик әлеге явыз микроб армиягә керергә тиеш түгел иде бит. Армия ул — дәүләтнең йөзе. Армия таркалса, җәмгыять йөгәннән ычкынган көтү хәлендә калачак. Тарих күп тапкырлар дәлилләгән хакыйкать бу. Моны соң үзәктә белергә тиешләрдер ләбаса! Күрәсең, бөтен тулылыгы белән белеп бетермиләрдер. Бәлкем, язаргадыр, иш янына куш дигәндәй, аның да фикерен белеп торсыннар, зыяны тимәс.

Әхмәт соңыннан үзенең бу беркатлылыгы өчен оялып, кызарып йөрде. Көт, алырсың эт авызыннан сөяк! Әмма ул чагында оборона министрына юлланган хатын ул чын күңеленнән, файдасы тисен дип, уртак Ватан, ил турында кайгыртып язган иде. Аның уенча, Рәсәй бөтен булырга тиеш, бары бөтен Рәсәй генә башка халыкларга тыныч тормыш, бәхетле киләчәкне тәэмин итә ала. Ә армия булып армиядә моны аңлап җиткермиләр. Милләтләрне сортларга бүлеп карыйлар, мыскыл итәләр. Фаҗига ич бу!

Әхмәт түземсезлек белән җавап көтә башлады. Ихтимал, бу җавап аның шәхси тормышын да җиңеләйтеп җибәрер әле, һичьюгында башка урынга күчерерләр. Әтисе язды ич, татарстанлыларны үз төбәкләрендә хезмәт иттерү буенча җөмһүриятебездә бик зур көрәш башланды, дигән. Халык кузгалды, дип сөенгән. Казан тирәсенә кайтарсалар, шәп булыр иде ул. Нурсинә белән дә күрешү бәхетенә ирешер иде, бәлкем. Аны болай да хәзерге мәхшәрдән Нурсинә турындагы ләззәтле хыяллары гына коткарып тора да инде. Бу терәге дә булмаса, сабыр канатлары әллә кайчан сынган булыр иде инде аның. Сөю ул — юксыну һәм сагыш кына түгел, горурлык хисләре дә китерә икән. Типкедә йөргән егетне кем яратсын да, кем ихтирам итсен. Шуңа күрә ул Нурсинәгә үзе уйлап табып, солдат хезмәтенең киноларда күрсәтелә торган романтик, маҗаралы якларын күпертеп язарга тырыша иде.

Атна-ун көннән частьта ниндидер җанлылык башланды. Кунак көткәндәй казарманы, аның тирәсен чистарттырдылар, юдырдылар, кем әйтмешли, яламадылар гына. Старшина тумбочкаларны тикшереп, әллә күпме «артык» әйберләр тапты. Караватларны һәркөнне җеп сузып тигезләделәр. Солдатларны да, гомергә булмаганны, энә күзеннән үткәрде старшина, якалары юылганмы, итекләре чистартылганмы, сәдәфләр, каеш аеллары ялтырыймы?

Ни хикмәт, бу арада Әхмәтне дә тынычлыкта калдырдылар. Алай гынамы, взвод командиры үзе егетнең гаилә хәлләре, Татарстан турында сорашты, мәгънәле генә итеп кыска вакытлы ял бирү мөмкинлеге булу ихтималын да әйтте. Моның өчен, диде ул, беренче чиратта үз подразделениеңнең патриоты булу зарур, чүпне читкә чыгарудан бер файда да юк, чөнки барлык мәсьәләләр дә урында хәл ителә.

Хат турында хәбәрдар булсалар кирәк — шундый фикергә килде Әхмәт — шул ук вакытта тәгаен генә аның ни-нәрсә хакында икәнен белмиләр дә, ахрысы. Белсәләр, Әхмәтнең кылын тартып, ерактан суктырып

маташмаслар иде. Тик шунысы ачык, бу мәсьәлә аларны бик борчый. Әнә бит, ефрейторның да коерыгы кысылды, ялагай эт шикелле күзгә генә карап тора. Чынлап еласаң, яшь чыга икән ич, рота ничек яхшырды, чөнки офицерлар һаман солдатлар янында, старшина да каптеркада куна-төнә ята.

Бервакыт, чыннан да, ротага нindидер полковник килеп төште. Шул ук көнне кич Әхмәтне штабка чакырдылар. Полковник үзе генә иде. Ул кайсы ягы беләндер сәясәтче Бурбулисның карикатур сурәтен хәтерләтә. Күзләре атылып чыгардай булып бүлтәйгән, үзе ярау ат шикелле, төртсәң егылып китәр сыман. Тик ни гаҗәптер, тавышы көр, буш мичкә төбенә суккалагандай дан-доң килеп, бөереннән чыга моның.

Әхмәт устав кушканча, шартын китереп мөрәҗәгать итә башлаган иде дә, полковник кул гына селтәде. Күренеп тора, строевой офицер түгел икән.

— Җә, уз, кәгазь корты, ә? — дип елмайгандай булды. Ләкин елмаюы ирен тирәсеннән узмады. Шулай да Әхмәт җиңел сулап куйды, салдофонга ошамаган бу, аңлашырбыз, шәт, дип куанды. Димәк, аның хаты ул көткән нәтиҗәне биргән, шулай булмаса, полковник кадәр полковникны җибәрмәсләр иде. Яхшы эшләде ул язып, дөрес эшләде, ротадагылар аңа рәхмәт кенә әйтер әле.

— Сез Мәскәүдәнме? — дип сорады Әхмәт, шатлыгын баса алмыйча.

— Сорауны монда мин бирәм, — диде полковник җитдиләнеп. — Җә, сөйлә, кем бәйләнә, нәрсәдән риза түгел, милли җирлектә кыерсыту нинди фактларда күренә, армиянең таркалуын ничек дәлиллисең, һәм башкалар, һәм башкалар...

— Минем хатымда барысы да тәфсилләп язылган, — диде Әхмәт, — шуннан артыгын әйталмамдыр.

Полковник аз гына калкынып урындыгын өстәл янынарак шуыштырды.

— Да-а, — дип сузды ул аннан соң, — бик хәйләкәр җегет булып чыктың бит әле син, рядовой э-э... Галиев, кыек атып туры тигезергә ахры исәбең, ә?

— Мин тел төбегезне аңламыйм, иптәш полковник.

Вәкил, кабарынган күркә кебек кукраеп ишекле-түрле йөрештереп алды да, солдатның каршысына ук килеп туктады. Әхмәт йөзен җыерды, чөнки тегенең авызыннан сасы махмыр исе аңкып тора иде.

— Бик яхшы аңлыйсың, иптәш солдат, ә, янәсе, татарларны кыерсыталар, кимсетәләр. Ә үзегезнең исәп Россиядән аерылып чыгарга! Шулаймы? Суверенитет, декларация, конституция дигән сафсатагыз шуңа юнәлдерелгән: Россияне таркатуга. Шалишь, брат, ирек бирмәбез!..

Полковник кечкенә йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты, авыртты, ахры, тәрәзә янына барып, кулын озак кына җиңенә ышкып торды. Шуннан соң янә сүзен дәвам итте:

— Син хәйләкәр булсаң, без синнән дә хәйләкәррәк, Галиев, ә! Берәүгә тигәннәр икән, ә, чаплашканның укасы коелдымыни? Чебен тимәс чер итәр, җегет икәнсең, үзең дә махы бирмә! Ә син үзара талашудан олы сәясәт ясамакчы. Хитрый...

Әхмәтнең колаклары үрә торды. Чөнки ул сәясәттән, бигрәк тә милли сәясәттән бик еракта иде. Декларация, суверенитет, мөстәкыйльлекнең гамәлдә ни-нәрсә икәнен белми һәм белергә дә теләми иде. Ул үзе дә нәкъ әлеге вәкил кебек бүленмәс һәм бердәм Россия яклы ләбаса!

Полковник, әнә шулай, әтисе бик тырышып та булдыра алмаган милли хисләрен уятты Әхмәтнең. Дөресе, ул әле моны үзе дә төшенеп җитми, әмма башына нindидер бимазалы корт кереп оялаган иде инде. Һәм шул корт еллар буе рәсми даирәләр сеңдергән тәгълиматны кимерә башламасынмы. Ә алдагы вакыйгалар аны тагын да тизләтеп җибәрде.

Салмыш полковник (ул контрразведка кешесе иде, Әхмәтнең хатын алар дивизия почтасында ук эләктереп алганнар иде) ротадагы җирле

шовинист хулиганнарны үсендереп китте. Алар тәмам йөгәннән ычкындылар, эзәрлекләү солдат казармасыннан командирлар дәрәҗәсенә күтәрелде. Татарстан турында чираттагы уйдырма эфирга чыгуга, эте дә бете дә Әхмәтханга бармак белән төртеп күрсәтә иде, әйтерсең лә ул республиканың иң баш кешесе, әйтерсең лә указларны ул чыгара.

Тик ни хикмәт, татарлыгыннан кыенсынып-оялып йөргән Әхмәт баштагы мәлләрдәге кебек акланып маташмый иде инде, ниндидер үҗәтлеккәме, горурлыккамы охшаш хис кичерә башлады ул мондый чакларда. Димәк, Татарстан аларга тынгылык бирми, димәк, ул аларның җәрәхәтләнгән җирләренә тоз булып утыра.

Чираттагы мунча вакытында да Әхмәт элекке кебек караңгы почмакта түгел, беренче мәртәбә иң якты сәкедә юынды. Ефрейтор иярченнәре котырган эт өере кебек аны урап алдылар, эчләрен тота-тота көлгән булдылар, әллә ниләр әйтеп мәсхәрәләделәр. Әхмәт исә:

— Белəсегез килсә, марҗа кызлары татар егетләрен шуның өчен ярата да инде,— дип көлде.— Ышанмасагыз, үзләреннән сорагыз.

Моңа кадәр Әхмәтнең иң кимсенгәне сөннәт иде, әтисенә дә шуның өчен бик ачулы иде. Төптәнрәк уйлап карасаң, Әхмәтнең нәмәрсәсендә ул урыс малайларының ни катнашы бар соң , ул да бик рәхәтләнеп, киселмәгән дип, аларныкыннан көлә ала ич!..

Үзенә күрә бер кечкенә җиңүе иде бу Әхмәтнең. Ләкин аңа карап хәле үзгәрмәде, көчләр нисбәте чагыштыргысыз иде. Ихтимал, сәбәп хәрби шартларда гына да булмагандыр. Россия бу вакытта койрыгына баскан елан кебек өзгәләнә, суккалана, чагып-чагып булса да, корбанын авызыннан ычкындырмаска тырыша иде. Шушы зур сәясәтнең кайтавазы ерак Себердә хезмәт итүче Әхмәткә дә тынгы бирми иде. Элеккечә иң авыр эшне аңа кушалар, иң пычрак шөгыльләрдә— тагын ул. Башкалар кичен телевизор карый, ә Әхмәт туалет чистарта, идән юа.

Бер якшәмбедә аны ашханәгә утын ярырга җибәрделәр. Ашханәдә эшләү, бер яктан караганда, начар да түгел, рәхәтләнеп тамагың туйганчы ашыйсың ичмасам. Тик ул кара эшләрдән санала, үзен санга суккан солдат анда бармау ягын карый. Әхмәткә исә сайланырга туры килми, аның инде чираттан тыш бирелеп тә, әле үтәлмәгән нарядлары башыннан ашкан, яңалары да өстәлә тора. Аларны үтәп чыгу өчен ике ел түгел, биш ел хезмәтең дә җитмәс.

Түмәрләре ботаклы да чатаклы, өстәвенә, юеш җирдә ятып муртаеп беткәннәр иде. Ярылмыйлар, сытылалар гына. Азапланды мәгәр, хәтта берсендә балтасы аягына да тия язды, бик аздан калды.

— Фу, Япония, аяксыз калырсың, валлаһи,— дип Әхмәт балтасын читкә бәрде. Очы-кырые булырмы моның, интектерәләр бит, түзәр чамасы калмады бит инде.

Күзләре дымланды Әхмәтнең, шул рәвешле кыймшанмыйча да 10—15 минутлап утыргандыр. Бер мизгелдә аның җилкәләре калтыранудан туктады, башы турайды, тәк-тәк, дип пышылдады иреннәре, әгәр дә балта, чыннан да, ялгыш таеп китеп берәр бармагын җәрәхәтләсә? Әйтик, чәнти бармагын? Аны госпитальгә салачаклар. Ул рәтләнәчәк, билгеле. Ләкин өзелгән бармакны ялгап булмый. Армиягә андыйлар кирәкми. Һәм Әхмәтең ту-тут!

Мөмкин хәл лəбаса бу! Валлаһи! Башта авыртыр, әлбәттә. Тик нишлисең, түзәргә туры килә, аның каравы тәмугтан котылачак! Әхмәт, тәвәккәлләргә кирәк, дигән нәтиҗәгә килде. Менә кулына балтасын алды, берничә мәртәбә кизәнеп-кизәнеп карады, хәрәкәтләрен төгәл итеп билгеләргә тырышты. Барысы да туры килә иде кебек. Һәм ул тирән итеп сулыш алды да, нигәдер күзләрен чытырдатып йомып, балтасын баш очына күтәрде. Ләкин хәлиткеч хәрәкәт ясалмый калды, чөнки кемнеңдер ачулы тавышы яңгырады:

— Кенәс, утының кая, тавай-тавай, тиз бул!

Бу повар иде. Озын куллы, камыт аяклы чуваш егете. Әхмәт усал эт шикелле поварга ташланды. Орыш озакка сузылмады, чөнки тегесе каршылык күрсәтеп маташмады. Изде аны Әхмәт, бөтен ачуны аннан алды. Һәм шул җил белән частьтан үк чыгып китте. Аның башында тәгаен гына план да туган иде инде: ул армияне ташлап китәчәк, качачак бу шайтан оясыннан! Болай да күп түзде, әллә кайчан шыласы калган да бит, нишлисең, татар акылы тау менгәч кенә төшә икән шул.

Гарнизон белән поселок арасы әллә ни ерак түгел, ике-өч чакрым чамасы гына. Качып-посып йөрүче кеше өчен урыны да уңайлы, чокыр-чакырлар күп, ике ара буйдан-буйга яшь чыршы агачлары белән капланган. Барысы да уңай тора шикелле. Кояш инде таулар арасында. Аның сәләмә болыт челтәрләрендә эленеп калган кызгылт төстәге сүрән нурлары да сүнеп бара. Шырпыдай тырпайган ылысларга, үлән яфракларына дым куна башлаган, алар бүртенеп, калынаеп киткәннәр. Күзгә күренеп эңгер-меңгер пәрдәсе төшеп килә. Бу миңа файда гына, дип сөенде Әхмәт, бәладән башаяк.

Ул, як-ягына карангалап, кечкенә бер аланлыкка килеп чыкты. Ә аны көтеп торалар иде инде.

— Никипыр, кнәс! — дип кычкырып җибәрде повар.

— Тсс!

Әхмәт язмышын кабул итәргә әзерләнде, аның башка чарасы юк иде. Тегеләр дәррәү килеп җиттеләр дә башына капчык кигезделәр...

Аңа иртән кәҗәсенә үлән җыеп йөргән бер карчык тап булган. Ул госпитальдә генә уянып китте. Тәне күм-күк иде, өч кабыргасы сынган, кая тотынса, шул җире сызлый.

— Болары гына чепуха,— диде аны караган доктор,— Кайгырма, туеңа кадәр төзәтергә тырышырбыз. Йөрәгеңнең тамырларын эштән чыгарганнар, менә монысы мәсьәлә, операциясез булмаска охшый.

Әхмәт операциягә ризалык бирмәде, погонлы кешеләргә тәмам ышанычы беткән иде инде аның.

Бу гадәттән тыш хәлне хәрби прокурор тикшерде. Ул Әхмәтнең ничек итеп, нинди сәбәп белән рөхсәтсез-нисез хезмәт урынын ташлап китүен бик озаклап төпченде, поварны ни өчен тәпәләвен белергә теләде. Әхмәт, әлбәттә, чын дөреслекне әйтмәде, бәхетсезлегенә, аракы юллап чыккан идем, дип үзенә-үзе яңа чокыр гына казыды.

— Җә, хуш, шулай да булсын ди,— диде прокурор,— тик нигә син хезмәттәшләреңә яла ягасың, егетлек түгел бит бу. Әгәр, син әйткәнчә, повар урманда сине куып йөрсә, ул ничек итеп аш әзерләр иде. Солдатлар вакытында тукланган. Шаһитләре бар, барысы да язма таныклык бирде. Никифоровның да, башкаларның да алибилары шик тудырмый, син эчемлек эзләп йөргәндә алар кинофильм караганнар, ягъни культуралы ял иткәннәр. Сәгате-минуты туры килә.

Әхмәтнең дәлиле юк иде, шаһитләре дә. Ахырда бөтен гаепне аңа аударып калдырдылар. Исерек килеш ниндидер билгесез хулиганнар белән бәйләнешкән, дигән нәтиҗә чыгарды прокурор, аңа кадәр поварны кыйнап ташлаган. Әти-әниләренә дә, хәрби комиссариатка да шундый эчтәлекле рәсми хәбәр җибәрелде.

Эшне яптылар, ә Әхмәт гомерлеккә гарип булып калды.

* * *

Шифаханәдә Әхмәтнең хәле тагын начарланып китте. Бер килүендә ул хатынының кулларын салкын учына салды да:

— Гафу ит, Нурсинә, мин сине бәхетле итә алмадым,— диде.

— Син бәхетле булырга тиеш. Мин үземнең хәлемне, ни көткәнен бик яхшы аңлыйм, сүзем шул, ягъни васыятем...

Әхмәт фикерен төгәлли алмады, укол кадарга керделәр.

— Җанашым, син ялгышасың, мин бәхетле, безнең бәхетебез гомерлек,— дип пышылдады Нурсинә һәм керфекләренә кунган яшьләрен җәлт кенә сөрткәләп алды. Ләкин Әхмәт аның яшьләрен дә күрмәде, сүзләрен дә ишетмәде — дару аны йоклатып җибәргән иде инде. Нурсинә туфлиләрен салды да, аяк очларына гына басып палатадан чыгып китте.

Бу бүлектә йөрәк хастасы белән интегүчеләр ята, балалар да хәтсез. Нурсинә беренче көнне үк 6—7 яшьләрендәге бер кызчыкка игътибар итте. Почмакка чүгәләгән дә мескенем, башын тезләренә кысып, шул уңайсыз халәттә оеп калган. Нурсинә аңа сүз кушып караган иде дә, кызчык җавап кайтармады, сагышлы күзләрен зур итеп бер карап кына алды.

— Борчымагыз аны,— диде үтеп баручы табиб,— аңа шулай уңайрак.

Соңыннан белде Нурсинә: тумыштан зәгыйфь йөрәкле балаларның утыру рәвеше шулай икән, алай кан яхшырак йөри ди.

Бүген кызчык нишләптер ул урында юк иде.

— Румия күренми, мин аңа кучтәнәч алып килгән идем, шуны бирергә иде,— диде Нурсинә шәфкать туташына.

— Аңа кучтәнәчләр кирәкми инде хәзер, сеңлем,— диде шәфкать туташы.

— Ничек инде кирәкми, апа?

Бу коточкыч хәбәрдән Нурсинәнең башы әйләнеп китте, егылып китмәс өчен хәтта стенага сөялеп торды.

— Сиңа, сеңлем, ирең турында күбрәк кайгыртырга кирәк, үкенечкә калмасын...

Шәфкать туташының бу сүзләре Нурсинәгә камчы белән сыдырган дай тәэсир итте. Ул шул авыр тәэсир белән профессор бүлмәсен ачып керде.

— Рәфкать Сафич,— диде ул сулкылдый-сулкылдый.— Әхмәткә бүген үк операция ясарга кирәк , югыйсә... Югыйсә... мин ул фаҗигане күтәрә алмаячакмын... Рәфкать абый...

Профессор урыныннан торып, стаканга су агызды да Нурсинәгә сузды.

— Тынычланыйк әле, күгәрченкәем... Җә әле, менә шушы суны эчеп җибәрик әле. Менә шулай.

Рәфкатьнең тавышы гөр-гөр килеп ишетелә иде.

— Хәзер туфлиләрегезне киеп җибәрегез инде, мондый чибәр ханымга оекчан йөрү килешеп бетмәс.

— Әхмәткә бик авыр бит...

— Беләм, күгәрченкәем, беләм. Ләкин бу хәлендә ул операцияне күтәрә алмаячак, донор белән дә проблема...

— Әгәр ни... әнә... Румия... кечкенә кызчык...

— Өметне өзмик, күгәрченкәем, шайтан гына өметсез, диләр.

* * *

Профессор Мортазин белән ара яхшырып китте. Нурсинәгә ул хәзер базардагы ит чабучы кебек булып түгел, ә шәфкать фәрештәсе булып күренә иде инде.

Шушы көннәрдә генә үзәк телевидениедән йөрәк хирургиясенә багышланган тапшыру карады. Әхмәт кебек язмышлары каргаган бичараларны күрсәттеләр. Ләкин күңелләре түшәнкә түгел, тормыш арбасына чатырдатып ябышканнар. «Сырхаулык — бик авыр вазифа,— диде берсе,— безгә ихтыяр көче башкаларга караганда күп мәртәбә артыграк кирәк. Үзләрен сәламәт дип санаган кешеләр дә безнең кебек тырышса, халыкны бик күп хаста читләтеп үтәр иде». Нурсинә аның бу фикере белән

килеште. Чир — чор бит ул, чыннан да, кешегә бик зур таләпләр куя. Шуларны үти алсаң гына, син чирдән арына аласың.

Аннан соң профессорга сүз бирделәр. Мортазин белән шундый охшашлар ки, ул хәтта башта, болар бертуганнар түгел микән, дип тә уйлаган иде. Шундый ук эре сөякле, симез кеше. Ләкин берсе урыс, икенчесе татар, ничек бертуган булсыннар ди инде алар? Әмма ниндидер уртаклык бар. Бәлки, йөрәк хастасы белән шөгыльләнүче күренекле табиблар шулай юан буладыр? Һәрхәлдә, бу үзенчәлек тә Нурсинә алдында Мортазинның абруен күтәрде.

Мортазин үзе дә дустанә мөнәсәбәттә иде, хәтта киңәш-табыш итүдән дә йөз чөерми башлады. Беркөнне ул Нурсинәне коридорда очратты да, беләгеннән тотып, җыештыручыларның чүпрәк-чапрак, чиләк-себерке саклый торган ян бүлмәсенә алып керде.

— Тсс,— дип пышылдады ул бармагын иреннәренә куеп, әйтерсең лә ниндидер серен чишәргә җыена иде. Аннан соң кычкырып көлеп җибәрде. Нурсинәнең дә йөзе нурланды.

— Беләсезме, күгәрченкәем, мин нәрсә белдем?

— Әлегә юк, әмма уртаклашсагыз, белермен сыман.

— Мин чибәр ханымнар сәясәт белән кызыксынмый дип йөри идем, сез сәясәтче икән ләбаса!

Нурсинә башын чайкап куйды.

— Ялгышасыз, Рәфкать Сафич, мин ул шөгыльләрдән бик ерак торам.

— Алайса, Әхмәт.

— Әйе, ул Татар иҗтимагый үзәгенә йөри, митингтан кайтышлый егылды да ич инде.

— Вәйт, вәйт, шул ТИҮ инде.

— Әллә берәр нәрсә булдымы, Рәфкать Сафич?

— Кичә шуннан шалтыраттылар.

— Аларның талканы коры, бер-бер авыр сүз әйтмәгәннәрдер ич.

— Мин үзем дә ябалак оясына оялаган карчыга түгел, күгәрченкәем, теләсә кемне мунча кертә алам. Әйе, корырак сөйләштеләр, яшьләрчәрәк. Әхмәт өчен башыгыз белән җавап бирәчәксез, дип өркетергә тырыштылар. Мин ул кешенең үзенә дә әйттем: мин сезгә, дидем, күн тапи түгел, дидем, бөртәнә артыннан бөре куганчы, килеп сөйләшегез, дидем. Алай бик яхшы буласыгыз килә икән, дидем, берәрегез үз йөрәген бирсен, дидем.

— Сүзгә кесәгә кермисез анысы.

— Рәхмәт, ләкин дә, күгәрченкәем, бу форсаттан файдаланып калмасак, безне җир йотар иде.

— Ничек?

— Әйе, мин алардан йөрәк дауладым, тик бу бераз шүрләтеп алу өчен генә. Чынлыкта, эш эшләрдәй егетләр ич алар.Миңа шундыйлар ошый. Азмы-күпме мөстәкыйльлегебез бар икән, без моның белән аларга бурычлы... Ә форсат дигәнем даруларга карата — ох, дарулар күп кирәк булачак әле. Чит ил дарулары, кыйммәтле дарулар! Аларның бу җәһәттән дә мөмкинлекләре зур, шайтаннарның. Ник дисәң, башка мәмләкәтләр белән элемтәләре киң. Безгә менә шул җепкә тотынырга кирәк. Төшендегезме?

Әйе, армиядән кайтуга Әхмәт, Татар иҗтимагый үзәгенә барды. Милли хәрәкәттә катнашуны ул үзенең бурычы дип саный иде. Элек тотып та карамаган китапларга ябышты. Әтисенең китапханәсе шактый бай иде. Җыйган, картлач, курыкмаган. Риза Фәхретдин дисеңме, Гаяз Исхакыймы, Садрый Максудимы, Йосыф Акчурамы — барысы да бар. Мәрҗани, Сәгыйть Сүнчәләй...

Иҗтимагый үзәктә Әхмәт чандыр гына озын муенлы егеткә тап булды. Кызып-кызып сөйләшә, табада борчак куыра диярсең, ярсуыннан

кушымчаларны гына түгел, бөтен бар сүзләрне йота. Шуңа күрә аны аңлавы авыр. Әхмәт тулысынча төшенгән җөмләсе бер генә сүздән тора иде: «Азатлык!»

Чөнки ул әңгәмәсен әлеге өндәмәне өч мәртәбә кабатлап тәгәлләде.

«Исерек әллә инде бу?» — дип уйлады Әхмәт. Аның әле урам митингларының җәнҗал-экстазын күргәне юк иде. Бу мавыктыргыч романтик ашкыну чире аның үзен соңыннанрак биләп алачак.

Бүлмәгә олы яшьләрдәге күзлекле кеше килеп керде.

— Кунак бар икән,— диде ул, көлемсерәгән итеп. Ләкин чытык йөзендә бер генә мускул да хәрәкәткә килмәде. Ә менә күзләрендә ниндидер җылы нур бар иде.

— Солдат,— дип тәкъдим итте дежур егет Әхмәтне,— әлегә түмәр, бик яхшылап юнасы бар.

— Алаймени,— дип гаҗәпләнгәндәй итте күзлекле агай,— танышыйк алайса, мин Мусин булам, рәис — координатор.

— Әхмәт Галиев.

— Сезнең кебек лачыннар безгә бик кирәк,— диде Мусин.

— Әллә ни куандыра алмам шул мин сезне,— диде Әхмәт.— Мин — инвалид.

Ул кыскача гына башыннан үткәннәрне сөйләп бирде.

Мусин аны кочаклап алды. «Без моны болай гына калдыртмабыз, министрга барып җитәрбез, әмма...»

— Тотыныр урыны юк аның, абый, суга төшкән балта кебек ул — дип бүлде аны Әхмәт.

— Бу хакта соңыннан уйлашырбыз әле, солдат. Бер-бер әмәлен табарбыз барыбер, ә хәзергә син халыкка башыңнан кичкәннәрне сөйләрсең. Бу бик мөһим. Без әле парламентны да күтәрергә тиеш, законсыз булмый монда.

Әйе, Әхмәтнең үпкәләрлеге юк. Мусин сүзендә торырга тырышып карады, ләкин хәрби прокурор язмаларына якын да җибәрмәделәр. Тикшерү үткәрелгән, нәтиҗәсе тиешле оешмаларга хәбәр ителгән, дип кырт кистеләр. Хәтта депутатлык статусы да ярдәм итмәде.

Әхмәт исә, булдыра алганча, милли хәрәкәттә катнашырга тырышты, һәрхәлдә, бер митингны да калдырмады, кычкырырга өйрәнде, тупасланды, әрсезләнде. Шулай да әлегә ул урам стихиясеннән ары уза алмады. Һәм менә, йөрәге тотып, бөтенләй сафтан чыкты.

* * *

Ниһаять, операция көне дә килеп җитте. Ул тоташтан сигез сәгать барды. Нурсинәгә бу елдан да артыграк тоелды. «Йә, ходаем, түземлегеннән җуйма, җанашыма ныклык өстә, аера күрмә берүк безне, гомер бир, и раббым». Авыз эченнән генә шулай белгәннәрен укый-укый әле урындыкка сыенды Нурсинә, әле стенага килеп терәлде, әле коридор буйлап бәргәләнде. Дога-теләкләрен профессорга да юллады, операция уңышлы үтсә, мәңге онытмаска антлар итте. Шәфкать туташларына, табибларга бәхет, сәламәтлек теләде.

Операциядән соң ул Әхмәтне тулысы белән үз карамагына алачак. Исән-сау котылсын гына, җан өрәчәк ул аңа, тыны белән тартып булса да урыныннан күтәрәчәк. Кулы җинел аның, үт куыгын кисеп алгач, әнә, әнисен ничек тәрбияләгән иде, бик тиз аякка бастырдың, дип мактаганнар иде үзен.

Әхмәткә исә Нурсинәнең булышлыгы икеләтә-өчләтә кирәк иде. Ул операция йокысыннан да тиешеннән соңрак уянды. Аңына килүгә, күзләре иң элек түшәмдәге яктырткычка төште, анда бераз тукталып торганнан соң акбур стенаны сыйпап узды да, каршысында җемелдәшкән

эреле-ваклы лампочкаларда туктап калды. Шунда ук иреннәренә елмаюга охшаш дулкын кунды. Ләкин бераздан керфекләре яңадан авырайды, әмма әлеге дулкын иреннәрендә утырып калган иде.

Нурсинәнең йокысызлыктан шешенгән йөзе яктырып китте, җилкәсенә басып торган арыганлык йөге юып алгандай шул ук мизгелдә юкка чыкты. Канатлары булса, очып ук китәр иде ул.

— Әхмәт, җанашым, уян,— дип пышылдады Нурсинә,— уян, Әхмәт...

Әхмәт кибешкән иреннәрен ялмап алды. Шуннан файдаланып, Нурсинә тиз генә аның авызына юеш марляга уралган кашык кертте.

— Әхмәт, җанашым...

Әхмәтнең карашы бу юлы ниндидер сөттәй ак нәрсәгә юлыкты, бераздан бу аксыл томанлыкта күзләр, йөз, борын, иреннәр пәйда булды. Ләкин ул үзе ярым йокы хәлендә иде әле, кайда ята, ни булган аңа? Нишләптер тәне авыр, гүя су сеңгән бүрәнә, бармакларын да селкетә алмый.

— Әхмәт, котлыйм,— дип Нурсинә аны үбеп алды. Үзенең бит алмалары буйлап күз яшьләре ага, алар Әхмәтнең йөзенә тама, Нурсинә тыелырга тырыша, әмма яшьләр барыбер тама да тама...

Кинәт Әхмәт куырылып катты. «Юк, юк, мин кенәз түгел... аһ... юк...юк...»,— дип тәүге сүзләрен әйтте.

— Әхмәт, тынычлан, Әхмәт!

Әхмәт янә уянды. Ул ярым ачык күзләре белән стенадагы кара тартмага ымлады. Анда бөтен бүлмәне яңгыратып нидер дөп-дөп килә иде.

— Ә-ә,— дип елмайды Нурсинә,— ул синең йөрәгең шулай тибә, монитор.

— Минем йөрәк?!

— Әйе, җанашым, котлыйм...

— Ә син кем?

Әхмәтнең бу соравы Нурсинәне җиргә кайтарды, аңа соң, Әхмәт уянуга, дежур табибка хәбәр итәргә кушканнар иде ләбаса. Күптән түгел генә шәфкать туташы кереп, берүк соңлый күрмәгез, дип катгый рәвештә кисәткән дә иде. Ул исә, чүбек баш, барысын да онытып җибәргән...

Әхмәт өч-дүрт көннән утырып тора башлады, аннан соң акрынлап йөреп китте. Ләкин элекке уенчак, шаян Әхмәт түгел иде инде ул. Күлен танымаган бака шикелле, һаман үрсәләнә, үз-үзенә урын таба алмый.

Бу табигый хәл иде, билгеле. Уен эшмени йөрәгеңне алыштырып куйсыннар әле! Нурсинәнең, мәсәлән, врачка тешен каратырга да коты алынып тора. Бер урт тешенең төбе генә калган, сызлаштыра да. Алдырып кына ташлыйсы иде дә үзен, юк, поликлиникага баргач, керергә базмыйча кире борылып китә. Әхмәте нык аның, нинди операциягә түзде бит. Профессор да:

— Борчылма, күгәрченкәем, донорның бөтен параметрлары да туры килә, ахыры хәерле булырга тиеш,— диде. Әхмәтне чыдам, дип мактады, кадерен бел, диде.

Әхмәтен ул кеше әйтмәсә дә ярата. Яратмаса, аның белән язмышын бәйләр идемени?

Хатын-кыз өчен мәхәббәттән дә изгерәк хис бар мени ул?! Хатын-кыз яшәүнең асыл мәгънәсен мәхәббәттә күрә. Хәтта гаиләне инкарь итеп, хатын-кыз төп терәкне ир-аттан түгел, коллективтан, дәүләттән табарга тиеш дигән теорияне алга сөргән необольшевик Коллонтайлар да шәхси тормышларында гыйшыкка сусап яшәгәннәр. Нишләмәк кирәк, табигатьтән узып булмый шул, мәхәббәт — һәркемнең күңеленә салынган илаһи бер очкын ул. Шырпысын сызсаң, кабынырга гына тора. Ләкин яратуны төрле хатын-кыз төрлечә кабул итә. Берәүләргә аның ярсыган диңгездәй өермә булып дулавы ошый, икенчеләргә моңы, аһәңе якын,

өченчеләргә... Хәер, дөньяда күпме хатын-кыз булса, мәхәббәтнең дә төсмере шулкадәрдер, шөт.

Нурсинәгә исә мәхәббәт Әхмәтнең җорлыгы, дуамаллыгы аша килде. Теге вакытта Әхмәт Нурсинәне әти-әнисе янына үзе белән ияртеп алып кергән булса, ихтимал, ул аларда калган да булыр иде. Танышуның беренче көнендә үк кызны өенә алып кайт әле, моның өчен ярату, ошашу гына җитми, барыннан да элек тәвәккәллек зарур!

Аңа ул вакытта читтәге бистәдән шәһәргә эләгү җиңел булмады. Фатирларына кайта алмый иде, чөнки әти-әнисеннән «иптәш кызларымда куна калам» дип рөхсәт алган иде. Аннан соң, җиде төн уртасында ишек шакыса, артларына аварлар иде. Шуңа күрә төннең калган өлешен ул вокзалда үткәрде, техникумга да шуннан гына китте.

Ә техникум янында аны Әхмәт көтеп тора иде инде.

— Нурсик, мин сине төне буе эзләдем,— дип каршылады ул кызны.

Нурсинә ачык чырай күрсәтмәде, шык-шык басып бинага үтте.

Нурсинә аны киткәндер дип уйлаган иде инде, ә ул озын тәнәфестә (аудиторияне дә тапкан!) бер кечкенә кәрҗинне чөмәкәй тутырып капкайнар пирожкилар алып кергән.

— Әй, ач халык, ябырылың! — дип кәрҗинен өстәл өстенә китереп тә куйды.

Студентка нәрсә, аңа тәкъдим итүче генә булсын, ул уен-көлкедән, ашау-эчүдән бервакытта да баш тартмый.

— Пирожкыйларың во! — дип җорланды кайсыдыр.— Сыра да алып кергән булсаң, шушында ук туй да ясый идек.

Әхмәт иртәгә армиягә китәм дигән көнне алар беркемгә дә әйтми генә язылыштылар. Хатны ул еш язды. Ләкин нинди фаҗигагә юлыгуы турында — ләм-мим. Бер елдан кәҗә билеты тотып кайткач кына барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

— Мин икенче группа инвалид, Нурсик,— диде ул,— ташласаң да үпкәләмәм. Беләм, мин сиңа пар түгел.

Әхмәтнең бу тәкъдиме Нурсинәнең хисләрен тирәнәйтте генә. Димәк, ул сөйгәне, аның киләчәге, бәхете хакына үз бәхетеннән дә ваз кичәргә әзер! Хатын-кыз мескеннәрне хупламый, әмма мәхәббәт корбаннарына ул һәрвакыт мәрхәмәтле. Ана сөтеннән бу. Чөнки ана — үзе мәхәббәт җимеше. Менә шуңа күрә хатын-кыз бу илаһи хисне саклау өчен әллә нинди авырлыкларга да түзә. Әгәр ул мәхәббәтенә куркыныч янавын сизеп ала икән, бернинди каршылык алдында да туктап калмый, шарты туры килсә, яман көчкә үк әверелә.

Нурсинә дә шундыйрак халәт кичерә иде. Әхмәтнең үзгәрүен, үз-үзенә йомылуын авыруына сылтаса да, нидер бимазалый иде аны. Операциянең уңышлы үтүе көн кебек ачык, профессор да куркыныч чор узды дип саный. Әхмәт тә авырткан җирем юк, ди. Ә үзе боз кебек салкын, сөйләшүенең дә рәте-чираты юк. Хатыны аның кочагына атылырга ашкынып тора, наз тели, ярату көтә, ә ул күрмәмешкә салыша. Үзе башлап сөйләшми дә хәзер. Сорасаң, җавап кайтара, сорамасаң — юк, көннәр буе бер кәлимә сүз әйтмәскә мөмкин.

Боларны аңлап була, әлбәттә, Нурсинәнең бу яктан дәгъвәсе юк. Чөнки Әхмәт бик катлаулы операция кичерде, әле аның тәэсире озакка барыр. Барысына да түзәргә әзер ул һәм түзәчәк тә! Ләкин күңеле барыбер тыныч түгел. Әгәр чире, стресс шулай басып тора икән, алай булгач, нигә шәфкать туташына елмаеп карый, елмаеп сөйләшә соң ул? Моны һич тә аңламый Нурсинә. Юкса елмаюлар беренче чиратта аңа булырга тиеш иң!

Шулай беркөнне өсләренә килеп керде. Әхмәт аңа вазадан алып роза чәчәге сузып тора иде. Тегесенең балкуын күрсәң, әйтерсең лә зәңгәрсу каймалы алтын тәлинкәгә салып кояшның үзен бүләк итәләр.

Нурсинә әлеге чәчәкне шәфкать туташының кулыннан тартып алып, Әхмәтнең йөзенә бәрмәкче иде дә, палатага Рәфкать Сафич килеп керде.

Гаебен йолу өчендер, кыз чәчәкне профессорның түш кесәсенә кадаган булды.

Димәк, хикмәт авыруда гына түгел, димәк, Әхмәт инде аны элеккечә яратмый. Йа хода, кем уйлаган? Шушы хәл дөреслеккә чыкса, моңа ничекләр түзмәк кирәк? Әлегәчә әйтелгән купшы сүзләр, кылынган гамәлләр ялган гына була түгелме соң?

Әгәр инде суынгансың икән, нигә яшереп маташырга, тот та турысын гына әйт. Шулай-шулай диген, мин инде сине үз итмим диген, яңа яр таптым диген, безнең очрашу хата булган икән диген. Җете кызыл тиз уңа, диләр иде, хак икән. «Аерылышыйк»,— диде, анысы дөрес, ләкин ул чакта арада кеше юк иде. Әхмәтнең сүзләрен мәхәббәткә генә юраган иде. Хәзер ике арада халатлы күркә...

Нурсинә, күңеленең ярсуына чыдаша алмыйча, сырхауханәдән туры әнисе янына кайтты, борчу-кайгыларын беренче булып аңа чиште.

— И кызыкаем,— диде әнисе,— ул хәзер башка ич инде, аның күкрәгендә чит кеше йөрәге тибә, ләбаса! Ходай иңдергән җаны күктә адашып йөридер мәрхүмнең: ә гәүдәсе монда чит җан белән тарткалаша, гөнаһларыннан ярлыка, и ходаем.

Нурсинәнең әнисе Нәмига ханым — сакчыллыгы өчен «Саран Гата» исемле кушамат алган Печән базары мәчете мөтәвәллиенең төпчек кызы иде. Басынкы, сабыр. Ире коммунист. Шул сәбәпле, ана кызын теләгәнчә тәрбия кыла алмады, үз эченә йомылып, догаларын да кача-поса гына укып яшәргә мәҗбүр иде. Нурсинә исә, киресенчә, җиңел холыклы, аралашучан, сүзгә оста замана баласы булып үсте. Чибәрлеге генә әнисеннән иде. Аны моңарчы тормыш, яшәешнең фәлсәфи кануннары да, дини нигезләре дә кызыксындырмады. Гомумән, бу хакта әлегә кадәр уйлап та карамады. Аның кешеләргә мөнәсәбәте бары ярату-яратмау хисләре белән генә чикләнә иде. Шуна күрә әнисенең сүзләре аны тәмам аптырашта калдырды. Әгәр бу гөманлаулар хак икән, ул чагында Әхмәт башка берәү булып чыга түгелме соң? Ә кем ул башка берәү? Нурсинәнең дәгъвәләре, димәк ки урынлы түгел, чөнки ул сөйгән Әхмәт инде юк. Тәне, гәүдәсе, кул-аяклары бар, әмма ул гәүдәдә Әхмәтнең җаны юк, анда чит җан! Шуңа күрә ул Нурсинәгә тартылмый, аны кабул итми. Аңа кичекмәстән Әхмәтнең күкрәгендә тибүче йөрәкнең хуҗасы турында ныклап белергә кирәк. Хәзерге Әхмәтнең хисләрен, үз-үзен тотышын шунсыз ачыклап булмаячак!

Нурсинә җай белән генә профессордан донорның кем икәнлеген ачыклады. Авариягә эләккән мотоциклчы булып чыкты ул. 18 яшьлек егет. Исеме Роберт. Ярый әле татар икән, мөселман кешесе, дип җиңел сулап куйды хатын.

Нурсинә Роберт яшәгән фатирны бик тиз эзләп тапты, сырхауханә белән янәшә генә икән. Ял паркына чапырып итеп салынган тугыз катлы килбәтсез соры йорт.

Язмышның гаделсезлегеме бу, нindидер гөнаһ өчен Аллаһы Тәгаләнең каргышымы? Ни өчен кемнеңдер яшәве өчен икенче берәү фаҗигагә эләгергә тиеш? Сүз дә юк, һәрбер кешенең яшисе килә, ләкин аның ходай биргән гомерне менә шул рәвешле табигать үзе кирәксенмәгән алымнар ярдәмендә сузарга хакы бармы? Әхлакый яктан караганда бу үзен-үзе аклыймы?

Хатынның башында шушындый җавапсыз сораулар кайнашты. Ул әлеге бәхетсез бәндәнең ишек катына житкәч тә икеләнеп калды: дөрес эшлиме ул, болай да кайгы-хәсрәт баскан ата-ананың җәрәхәтле хәтерен яңартып кына җибәрмәсме? Беләме икән алар бу хәлне, рөхсәтләре булдымы икән? Хокукый ягы ничек икән аның? Әйтик, чит илләрдә саталар да икән ич әле кеше әгъзаларын? Аларга да дәгъва белдермәсләрме?

Аннан болай, кычытмаган җирне кашып, Әхмәткә зыян гына китермәсме? Аллага шөкер, ире исән-сау, аңлашылмаучылык та, бәлкем, үтеп китәр.

Шулай да хатын-кызга хас кызыксыну, беләсе килү бу икеләнүләрдән өстенрәк иде. Нурсинә электр кыңгыравының кызыл төймәсенә басты. Мин үз язмышыма битараф кала алмыйм, дип уйлады ул, үзем турында үзем кайгыртмасам, кем кайгыртыр минем турыда. Гомер өчен генә түгел, бәхет өчен дә көрәшергә кирәк бу дөньяда!

Ишекне озын гына буйлы аксыл чәчле ир кеше ачты. Өсте-башы пөхтә, кунак көткәндәй кырынган-ясанган, алай кайгы баскан этигә охшамаган.

Ул Нурсинәне күптәнге танышыдай елмаеп каршы алды.

— Мадам, әйдәгез, түргә узыгыз,— дип бүлмәгә чакырды.

— Рәхмәт, мин... ни... йомыш белән генә,— дип мыгырданды Нурсинә. Аның мондый төче мөнәсәбәтне үз җилкәсендә татыганы юк иде әле. Каян килгән «мадам» булсын ди инде ул.

— Бик яхшы,— дип сандугачтай сайрады хуҗа.— Утырыгыз, тынычланыгыз, аннан йомышыгызны әйтерсез. Мин хәзер кофе әзерлим, ифрат файдалы эчемлек. Сез кофе яратасызмы?

— Әйе,— диде Нурсинә, хәлбуки, ул кофе белән мавыкмый иде.

— Инде танышыйк,— диде хуҗа.— Мин Альфред буламын, музыкант, әтием Гата.

Әйтәм, куллары ак, дип уйлап алды Нурсинә.

— Альфред... Гатич... мин...

— Альфред әфәнде,— дип төзәтте аны музыкант.

— Әйе, әйе, Альфред әфәнде... ни...

— Мин сезнең йомышыгызны беләм,— дип тагын кысылды Альфред.

— Нинди зур фаҗига,— диде Нурсинә.

— Ә мин аңа әзер идем.

Нурсинәнең кашлары дугаланып алды, ничек фаҗигагә әзер булырга мөмкин икән?

— Аның маңгаена язылган иде,— дип дәвам итте музыкант.— Финал башкача була алмый иде.

Альфредның бу сүзләре дә колакка ятып бетми иде. Шуңа күрә:

— Сезнең үз улыгыз идеме Роберт?— дип сорарга мәҗбүр булды.

— Мадам...

— Гафу итегез.

— Ул бу дөньяныкы түгел иде, җаны галәмдә йөзә иде аның, бу сыйфат нәселдән килә безгә...

Альфред, сүзеннән туктап, яшькелт төстәге томанлы күзләре белән Нурсинәгә текәлде. Нииндидер буйсындыручан, үтеп ала торган караш иде бу. Нурсинә чынаягын тоткан килеш катып калды. Илаһым, килеп тотынмаса гына ярар иде, дип теләде ул, белгән догаларын исенә төшерергә азапланды.

Альфред күзләрен бер генә мизгелгә дә читкә тайпылдырмады. Нурсинә үзенең елан сихерләгән бака шикелле ихтыярсыз бер затка әверелә баруын сизә иде. Менә музыкант ирен очлары белән генә елмаеп, аның кулындагы чынаякны өстәлгә алып куйды. Аннан соң иләп кенә, тәмен белеп кенә аны чишендерергә тотынды. Нурсинә кычкырырга теләде — иреннәре ачылмады, Альфредның йөзен тырнап кара канга батырырга ниятләнде — кулларының хәле китте, типкәләргә омтылды — тезләре бөгелмәде. Күңеле өзгәләнде, йөрәге ярсыды, әмма тәне Альфредның иркәләүләрен кабул итте.

Альфред нииндидер җаен табып, нәкъ тәи теләгәнчә бармак араларына кадәр үтеп керә, һәммә әгъзәне уята, дулкынландыра, чарасыз хәлгә китерә иде. Нурсинә түземсезләнеп аңа тартыла, ә Альфред һаман суза, һаман җәфалый...

Бервакыт фатирны яңгыратып кыңгырау чылтырады. Шул ук мизгелдә Нурсинәнең гәүдәсе туп шикелле диваннан идәнгә атылды. Сихерләп торган теге билгесез көч тә юкка чыкты. Беренче уе музыкантны чәбәләү

иде, инде ташланган да иде, ләкин үзенең анадан тума диярлек ялангач икәнен күргәч, кире диванга чумды, куллары белән гәүдәсенә еландай уралды. Альфред бармагын шкаф ягына төртеп күрсәтте. Бакса, киемнәре пөхтә итеп урындык аркасына эленгән иде.

Ә каһәр суккан кыңгырау чылтырый да чылтырый. Бу черелдәү Нурсинәнең йөрәгенә энә булып кадала. Хатыныдыр инде — йә, алла, ни дип җавап тотарга? Үзе кабалана-кабалана өстенә кием элә, күңеле шул хакта үрсәләнә.

Альфред ирен очлары белән генә елмаеп алды да, ишек янагындагы ниндидер төймәгә басты. Кыңгырау шунда ук челтерәвеннән туктады.

— Сез кабахәт кеше икәнсез,— диде Нурсинә.

— Мин сезгә бер зыян да китермәдем, мадам, киресенчә, сез биш кенә минут булса да дөнья мәшәкатьләреннән арынып, ләззәт дәрьясында йөздегез. Күрәсезме, мин үзем хәтта чишенмәдем дә.

— Ә кыңгырау?— дип сораганын Нурсинә сизми дә калды.

— Кыңгырау, мадам, чыннан да серле. Ул сезнең ишеләрне уяту, гөнаһтан саклау өчен махсус эшләнгән. Югыйсә, онытыласыз бит... Роберт тагын да көчлерәк иде.

Нурсинә оялуыннан җир тишегенә керердәй булып кызарды.

Тик чыгып китәргә ашыкмады, буласы булды инде, иншалла, башка кабатланмас, килгән-килгән, һичьюгы, улы хакында күбрәк мәгълүмат җыярга кирәк, дип үзен-үзе тыеп калды. Аның уйларын белгәндәй:

— Роберт көчле иде,— дип кабатлады музыкант.

— Монда көчлеләр кирәкми мени?— дип сорады Нурсинә. Аның гапкә кереп тизрәк тынычланасы килә иде. Моны Альфред та сизде булса кирәк, ниндидер үтә бер канәгатьләнү белән кәнәфиенең йомшак мендәренә чумды.

— Ул Тәңре аңа гына биргән сәләт-мөмкинлектән шәхси мәнфәгатьләрдә файдалана башлаган иде. Бу — тирә-яктагылар өчен куркыныч нәрсә.

— Сез үзегез дә ерак китмәгәнсез, ахры...

— Мин, мадам, бәхетсез ханымнарга ярдәм кулымны гына сузам. Бу безнең тәгълиматка каршы килми, киресенчә, ярдәм итү безнең фарыз асылыбыз.

— Сез шушы этлекне ярдәм дип уйлыйсызмы?

Альфредның йөзенә кара коелды, бугазындагы гөнаһ төере бер калкынды, бер батты. Ходаем, хаталандым, ахрысы дип борчылды Нурсинә, тагын котырынмаса гына ярар иде.

— Мадам, сүзләрегезне үлчәп сөйләшегез, ачулы чакта бик яман булам мин. Ярдәм сәдака бирү генә түгел ул, канатлары ифрат киң аның. Миңа җитмеш яшьлек корткалар да йөри, сез рәхмәтле генә булырга тиешсез...

— Гафу итегез, тик мин бернәрсәне аңламыйм, шундый зур мөмкинлекләрегез була торып, улыгызны нигә йолып алмадыгыз соң?

— Моны Тәңре генә эшли ала, мадам. Ул аны үзенә кайтарды, чөнки Роберт бәлигъ булмаган яшь кызларның гыйффәтенә кагыла башлаган иде. Әнә шул догасыз шөгылен шөгыль итеп кайтканда көпә-көндез, тип-тигез урында мотоциклыннан мәтәлеп төште. Милиция бу фаҗиганең сәбәбен ачыклый алмыйча азапланды. Роберт исерек тә түгел, машинасы да төзек, ничек шулай килеп чыккан бу, дип аптырадылар. Бу Тәңренең бәддогасы иде, мин аны шундук төшендем. Алай гынамы, өйдән чыгып киткәндә кисәтеп тә калган идем, гамәлләреңдә сак бул, без Тәңре бәндәләре, дигән идем.

* * *

Бу хәлләрдән соң Нурсинә барысына да кул селтәде. Ярар ла, ни язса, шул булыр, дигән нәтиҗәгә килгән иде ул. Тик тора-бара янә үз сукмагына кайтты. Күр, бөтен шик-шөбһәләрем дөреслеккә чыга түгелме, дип уйлады, теге азгын егетнең сыйфатлары Әхмәткә күчкән ләбаса! Хәер, моңа гаҗәпләнәсе дә юк, бик тә табигый хәл. Ник дисәң, йөрәк кешенең илаһи асылы. Кешенең барлык гамәле йөрәк аша уза , барысына да йөрәк баш: йә ул теге-бу эшкә хәер-фатиха бирә, йә кире кага. Әгәр шулай булмаса, ягъни дә йөрәк баш булмаса, халык йөрәк хакында шулкадәр әйтем чыгарыр иде мени? Йөрәге кыйшайган, йөрәген таракан ашаган, йөрәгенә бет үрмәләгән, йөрәк бәгърем, йөрәге үлгән, йөрәккә кадалу, йөрәк күтәрмәү, йөрәкне дагалау, йөрәкне көйдерү, йөрәк парәм, йөрәк түрендә йөртү, йөрәк өшеткеч, йөрәк җәрәхәте... Тагын әллә ни кадәр! Нурсинә аларның ике йөздән артыгын блокнотына теркәп тә куйды.

Ул үзенең уйларын профессор белән дә уртаклашырга ниятләде. Бу юлы Мортазинның кәефле чагына туры килде. Центнерлы гәүдәсен кәнәфигә җәеп, калын иреннәрен чапылдата-чапылдата шактый ачылып сөйләште ул.

— Йөрәк турында күп мәкаль җыйгансыз,— диде ул көлемсерәп.— Ләкин дә мин шуны әйтергә тиешмен, күгәрченкәем, боларның берсе дә чын хәлгә туры килми. Алар — наданлыктан!

Мортазин беразга гына тукталып калды, әңгәмәдәшенең бу сүзләргә мөнәсәбәтен белергә теләгән иде булса кирәк. Әмма Нурсинә бәхәскә керергә базмады, төп сүз алда иде әле.

— Әйе, әйе,— дип дәвам итте сүзен профессор,— наданлыктан. Йөрәк гап-гади бер насос. Ул сыкрана да белми, еламый да, шатланмый да, кайгырмый да. Вазифасы — организмны кан белән, кислород белән тәэмин итеп тору. Күреп торасыз, аны алыштырып та куеп була. Әлбәттә, моның профессиональ яктан үз кыенлыклары бар, ләкин аңа карап мәсьәләнең асылы үзгәрми. Ә инде өйрәтүләргә, мәкальләргә килгәндә, кеше элек-электән үзенә таяныч эзләгән, нәрсәгәдер табынган, үзенең гамәлләрен аклар өчен әллә нинди гыйбарәләр уйлап тапкан. Кешегә серлелек, романтика ошый. Кеше, әйтик, салкын һәм шыксыз айны шул дәрәҗәдә идеаллаштырган ки, ул хәтта мәхәббәт символына әверелгән. Наданлык түгелме бу? Йөрәк белән дә шундый ук хәл.

— Мин сезнең белән килешә алмыйм,— диде Нурсинә.— Без яратабыз, нәфрәтләнәбез, сызланабыз, янабыз, көябез. Боларның барысын да йөрәк белән тоябыз ләбаса. Һәм һәркем үзенчә ярата, үзенчә нәфрәтләнә. Әгәр, сез әйткәнчә, йөрәк насос ролен генә үтәсә, без барыбыз да бер төрле уйлар идек, бер-беребездән рухи аермабыз булмас иде.

Профессор, гәүдәсен өстәл янынарак шуыштырды да, алдындагы кәгазьләренә күз төшереп алды. Бу — әңгәмә тәгәлләнде дигән сүз иде. Нурсинә китәргә әзерләнде.

— Күгәрченкәем, мин хирург кына,— диде Мортазин кәгазьләреннән күзен алмыйча,— кисәм, ялгыйм, тегәм. Ләкин дә шуны әйтә алам, Әхмәтең шул ук Әхмәт, бер дә борчылма, ул сине элеккечә үк сөяр. Эчендә җаны булса, билгеле.

* * *

«Әә, шул-шул менә — җан, йөрәк, могтәбәр профессор әфәнде,— дип уйланды Нурсинә.— Үзегез казыган чокырга үзегез үк төштегез түгелме?! Наданлык, янәсе, тагын әллә нинди гыйбарәләр! Башкача булса, насос диярләр иде аны. Тик нигәдер йөрәк дип бик иркә

исем кушканнар. Йөрәк йөртә кешене. Кичә, әнә, тагын шәфкать туташын Әхмәт янында күрде. Чытыкланыпмы-чытыклана. Ул йөрүләре, театрга килгән мени. Аяклары нәфис, имеш. Аяк әле ул соңыннан гына кеше күзенә бәрелә, башта йөзгә карыйлар аны. Бу яктан кызыкайның байлыгы бик сай. Дуңгыз баласыныкы кебек тумпак борын, йә, кемгә охшасын, ди. Шул Альфред, Роберт кебекләр генә күзен йомса инде, тәҗрибә өчен. Әхмәт тә шулар сыңарына әйләнде, ниенә кызыккандыр шушы кылтыкның. Хәзер инде Нурсинәгә бөтенләй игътибар да бирми башлады. Килдеңме, хәлен ничек, өйдә ниләр җимерәсез — бар кызыксынганы шул. Хет чәчләреннән генә булса да сыйпап алсын иде, тынычланып, тәннәре язылып китәр иде. Аның хәбәрендә дә юк, чистый шашкан шул дуңгыз борын белән. Оялмыйлар да ичмасам, таза кеше булса бер хәл иде, рәтләнеп тә җитмәгән бит әле.

Авыруны карый, имеш. Юк, нидер бар алар арасында, аның борчулары бер дә юкка түгел, хатын-кыз күңеле бер сәбәпсез матавыкланмый ул. Терелеп җитмәгән килеш тә шәфкать туташына кул сала башлагач, киләчәктә нинди өмет багламак кирәк аңа? Элек күзенә генә карап тора иде ич, сөешеп туя алмыйлар иде. Юк, инде, Рәфкать әфәнде, сезнең сүзләрегез ак җеп белән тегелгән ямаулык кебек әллә кайдан күренеп тора. Юатып маташканчы, дөреслекне генә ярып салсагыз, мең өлеш артык булыр иде. Насос ул су сиптерергә генә ярый, ә адәм баласын йөрәк йөртә. Җаны, тоткан кыйбласы аның йөрәгендә. Әхмәт, әнә, ничек үзгәрде. Моннан да саллырак дәлилне табып кара, бар.

Ни гамәл кылыр, анысын әлегә хәл итеп бетермәде, әмма фикере тәгаенләнгән иде инде Нурсинәнең. Әнисе әйтмешли, Әхмәтнең җаны, яралы йөрәге белән бергә, тәненнән очкан. Җан бер генә була, җан ана карынында гына иңә. Көчләп керткән җан ул инде башка зат җаны...»

* * *

Бик күп йокысыз төннәрдән соң, Нурсинә, ниһаять, аерылышырга кирәк, дигән уйда тукталып калды. Әхмәт үзе дә күптәннән шуны тукып килә иде, тиенсен рәхәткә. Шуның белән бергә, тәмам терелеп, сырхауханәдән чыкканчы бу хакта Әхмәткә белгертмәскә, сабыр итәргә карар итте. Әлегә берни сизмәсен дә, белмәсен дә. Шуңа күрә, һични булмагандай, элеккечә якты чырай белән ире янына йөрде, ашаргаэчәргә әзерләде, күңелен күрергә тырышты.

Әнисе кызының ниятен хуплады гына. Бала-чагаң юк вакытта араны өзүең хәерлерәк булыр, бәбкәм, диде, ул инде алла бәндәсе түгел, табиблар бәндәсе генә. Телевизорларда күрсәтелә торган җанлы курчак кына, диде.

Әни кеше баласына яманлык теләмәс, тәкъдирдә шулай язылгандыр инде, дип, Нурсинә үзен-үзе юатырга тырышты. Сүз дә юк, кызганыч, бик кызганыч — тик нишләмәк кирәк. Язмыштан узмыш юк, күрәсең.

Ләкин бу яшь гаиләнең баш очында куерган болытлар Нурсинә уйлаганга караганда бөтенләй башка юнәлеш алды!

Шулай беркөнне, җомга иде булса кирәк, Нурсинә базардан гранат җимеше алып кайтты да, бик әйбәтләп согын сыкты (табиблар аны бик файдалы диләр), вак кына итеп төче коймак пеширде (монысы Әхмәтнең яраткан камыры), башка тәм-томы да шактый иде. Шуларны төяп сырхауханәгә чыгып китте. Аерылышу фикеренә килгәч, ул ирен үтә бер үҗәтлек белән тәрбияли башлады, бурычка кере-керә булса да Әхмәткә ризык ташыды. Аннары хатыны авыру ирен тәрбияләмәде, дип сөйләп йөрерлек булмасын, янәсе.

Трамвайда аңа бер егет сыланды. Карап торуга күркәм генә. Төз гәүдәсе, киң күкрәге, тыгыз беләкләре спортчы булуына ишарәли. Һәр-

хәлдә, бот бүе вакытыннан ук тәмәке кортына әйләнеп, шәраб имеп үскән салам сыйракларга охшамаган. Киеме дә килешле.

Нурсинә аңа бер карауда шундый бәя бирде. Әмма ачык йөз күрсәтмәде. Егетнең дә чигенергә исәбе юк иде, ияреп трамвайдан ук төште. Нурсинә француз язучысы Андре Моруаның канатлы сүзләрен исенә төшереп көлемсерәп куйды. «Сез, хатын-кызлар,— дип яза ул,— ир-атта сезне ээзәрлекләү теләге уятырга тиешсез».

Тыныч бул, Андре әфәнде, Нурсинә атлы бер татар кызы синең васыятеңә тугрылыклы. Әнә, күрәсеңме, нинди баһадир «эзәрлекли» аны бүген. Нурсинә, әлбәттә, кемнедер үзенә каратыйм әле, дип махсус рәвештә берни дә кылмый. Шулай да аңа бик еш сүз кушалар, танышырга телиләр, күрәсең, аңарда ир-атны үзенә җәлеп итә торганниндидер хикмәтле көч бардыр.

Яшерен-батырын түгел, үзенә карата мондый игътибар аңа охшый иде. Бу үз-үзен хатын-кыз итеп тоярга булышса, икенче яктан, һәрвакыт пөхтә булырга кирәклеген дә кисәтә. Андый көннәрне ул башын югарырак күтәреп, җиргә кыюрак басып йөри. Ләкин, шуның белән бергә, күз буучы Альфредны исәпкә алмаганда, ул бервакытта да ир хатыны чикләрен үтеп чыкмады. Чөнки Әхмәтнең аны яратуын белә, ышанычлы иде аның тылы.

Ә хәзер... Хәзер, әлеге «ухажер»га да Нурсинә энә очы кадәр дә ышаныч бирмәде. Егет исә егетлеген итепме, башка сәбәп беләнме: «Син минеке булачаксың»,— дип калды.

Сырхауханәгә әнә шундый маҗаралар белән керде Нурсинә. Әхмәт ятып тора иде. Саргылт мендәрдән төшкән соры күләгә аның йөзен шомлы итеп күрсәтә, ул мәрмәр таш төсенә тартым. Чигәләре тар, гүя аларны кысып бәйләп куйганнар. Йомык күз керфекләрен карасу-күгелҗем божра камап алган. Кайсыдыр бер мизгелдә ул үлгән кешегә охшап китте.

Нурсинәнең кулындагы сумкасы идәнгә чүмәште. Нәрсәләрдер коелды, нәрсәләрдер ишелде.

— Әхмәт! Әхмәт...

Башта Әхмәтнең күзләре ачылды, аннан соң гына тавышы ишетелде:

— Ни бар, Нурсик, нәрсә булды?— диде ул тыныч кына.

— Юк, болай гына...

Нурсинә, куркынган кыяфәтен күрсәтмәс өчен, Әхмәткә арты белән борылып басты, аннан соң тәрәзә пәрдәләрен ачып куйды. Шунда гына төшенде, бу шомлылык караңгылыктан килә икән. Бүлмә гөлт итте. Әхмәтнең йөзенә дә нур кайтты.

Нурсинә алып килгән ризыкларын бушатмакчы иде дә:

— Сабыр, Нурсик,— дип Әхмәт аны туктатты,— сөйләшик әле. Ир белән хатын ак җәймә җәелгән озынча өстәлнең икесе ике ягына килеп утырдылар. Тын. Ачык тәрәзәдән ботактан-ботакка куныш шаярышкан кызгылт түшле йомры кошчыкларның чыркылдашулары аермачык ишетелеп тора.

Әхмәт түзмәде, тумбочкасыннан ипи телеме алып, аны тәрәзә төбендәге кечкенә тәлинкәгә ваклап салды. Әлеге йомры кошлар шуны гына көтеп торганнар, ахры, пырхылдап килеп тә җиттеләр.

— Чүпләнегез, чүплән,— дип сөйләнде Әхмәт үзалдына.— Дөньяның рәхәтен күрегез, кайгы-хәсрәт кичермәгез.

Нурсинә ирен күзәтеп утырды. Бөек күренә иде ул бүген. Соңгы вакытта ябыгып та китте сыман, күлмәк якасы, әнә, бушабрак калган, муены колга шикелле тырпаеп тора — кәнтәйләр артыннан йөргәч, шулай була ул, бер рәхәтнең бер михнәте. Чын Әхмәт моны бервакытта да эшли алмас иде.

Кошларны ашатканнан соң Әхмәт урынына килеп утырды. Күзләре мөлдерәмә яшь иде, тик ул аларга тамарга ирек бирмәде, үзендә ниндидер көч табып, эчкә йотты.

Нурсинә аны кызганып куйды.

— Син бик борчулы,— диде.

— Нурсинә!!!

Хак икән, мине читкә тибүе хак икән, дигән уй хатынның башында яшен булып яшьнәде. Чөнки ул аңа һәрвакыт «Нурсик» дип кенә дәшә иде бит.

Күңеленең ерак почмагында яшеренгән соңгы өмете дә шартлап өзелде Нурсинәнең.

— Бәхет телим,— диде ул нигәдер — бәхет...

Бу сүзләр ирексездән, үзеннән-үзе әйтелде. Аңа иренең тел төбе тулы мәгънәсе белән барып җитмәгән иде әле, күңелендә бу минутта үзен күптәннән ышандырырга тырышып килгән гоман гына иде. Әмма икенче мизгелдә Нурсинәнең җене кузгалды. Нindидер тыйгысыз дуамаллык белән ризыкларны бүлмә буйлап чәчәргә тотынды. Үзе сөйләнә: «Карап тор, хыянәтчеләрне без менә шулай итәбез, берәү яшь кәләш тапкан, янәсе! Ым гына кагыйм, минем арттан берьюлы йөзе иярәчәк, әле бүген дә берсе озата килде, менә дигән чибәр егет... вәйт, вәйт...»

Шулай биш-алты минутлап тузынгач, хатын урындык артын кочаклап үксергә кереште. Әхмәт бу тамашаны тыныч кына күзәтеп торды, Нурсинәнең очкылык тотуы беткәч кенә сүзен әйтте:

— Миңа синә караганда да авыррак, Нурсинә...

— Ул дуңгыз борыныңның кәҗә маен чыгарып китәм әле, менә күрерсең.

— Нинди дуңгыз борын, Нурсинә?

— Ха, күрегез, берәү сизмиләр дип уйлап йөргән ич! Чистый күзебашы тонган, ул сестраңның борынын нәфис дип белдеңме әллә?

— Сестраның ни катнашы бар монда?

— Йә, җитте, мине җүләргә санама, җәме, үз күзләрем белән күргәнне сөйлим... ул теге... Роб...

Ул Роберт турында сөйләмәкче иде дә, ничектер вакытында үзен тыеп калды.

Әхмәт ул арада хатынының беленнән алып, алдына утыртты. Нурсинә, чәбәләнеп караган иде дә, булдыра алмагач, тынып калды.

— Нурсинә,— диде Әхмәт,— бер «айт» диюеңә, йөз егет «тайт» дип торганын мин бик яхшы беләм, шуңа күрә әлеге карарга килдем дә. Син сөелергә хаклы, хаклы гына түгел, сөелергә тиешсең дә. Мин моны күп мәртәбәләр әйттем инде сиңа. Ә мин... мин, Нурсинә, ир кеше түгел инде. Һәм бу йөрәк ише генә түгел. Йөрәкне алыштырып та була икән... моны юк...

— Җүләр сатма, Әхмәт!

— Бу сүзләрне сиңа әйтергә ай ярым җыенып йөрдем мин, Нурсинә. Докторлар бик җентекләп тикшерде, психологы да, сексопатологы да. Җенси сүнүнең турыдан-туры операциягә кагылышы юк, кыйналу нәтиҗәсе, диделәр.

— Соң, Әхмәт...

— Ни әйтергә теләгәнеңне аңлыйм, Нурсинә... Ул фаҗига акрынлап килә икән, операция аны тизләтеп җибәргән. Һәм өмет тә күренми, диделәр... Ярату турында сүз чыккач, шуны да белеп тор: мин бер генә хатын-кызны яраттым, гомерлеккә яраттым. Ул хатын-кыз — син, Нурсик! Ләкин мин синең тормышыңны тәмугка әйләндерәсем килми. Бу бик зур гаделсезлек, җүләрлек булыр иде. Син әле балалар үстерергә тиеш...

— Әхмәт, Әхмәтем минем,— дип Нурсинә иренең аякларына барып сарылды.— Кичер мине, кичер! Мин бит юкса әллә нәрсәләр уйлап бетердем... Җанашым...

* * *

Җан, йөрәк мәсьәләсе Нурсинә өчен менә шулай уйламаганда хәл ителде дә куйды. Әхмәтнең: «Сине генә сөям»,— дигән сүзләре язгы ташу кебек барлык икеләнүләрен юып ташлады. Аның каршында элекке Әхмәт һәм шул элекке Әхмәтнең колакка ятышлы элекке кайнар сүзләре. Әхмәтнең Әхмәт булып калуына иң көчле дәлил менә шулар, әлеге шартларда башкасы аңа кирәкми иде әле.

* * *

Әхмәтнең, ниһаять, сырхауханәдән чыгар вакыты җитте.

— Теге борчуларыңны оныт, ул чиреңне мин үзем дәвалаячакмын, бары ышанычыңны гына югалтма,— диде аңа Нурсинә. Эчен бушаткач, Әхмәт чыннан да, тынычланып киткәндәй булды. Көлә, елмая башлады, күнеленә яраткан Дәрдемәнде кайтты. Беркөнне ул хатынын шигырь белән каршы алды:

Түгел ялгыз бөдрә чәчле,
Көрпә йөзле бүз бала;
Кай чагында яшь күнелгә
Чал сакал да ут сала.

— Менә менә шушындый Әхмәт ошый,— дип, Нурсинә иренең кочагына ташланды.

Бу ул матур, бу ул күркәм,
Бу ул.
Бу ул — хуш исле яз!
Бу ул — хуш исле таң җиле!..

Нурсиянең түбәсе күктә иде.

Операциядән соң чагыштырмача тиз тернәкләнеп китүенең тагын бер сәбәбе — яхшы дарулар иде. Милли хәрәкәт җитәкчелеге, бигрәк тә Мусин бик тырышты. Профессор әйткән даруларны Америкадан кадәр кайтарттылар. Шунда яшәүче татарлар ярдәм иткән, ди.

Өйгә кайтасы көнне Әхмәтнең документларын тутырган арада Нурсинәне профессор бүлмәсенә чакыртып алдылар. Мортазин бик җитди иде, хәтта ияkләре дә җыелып киткәндәй күренә.

— Күгәрченкәем,— диде ул карлыкканрак тавыш белән,— теге вакыттагы бәхәскә нокта куярга вакыт җитте дип уйлыйм. Дөресен әйтәм, шактый уйландым. Һәм дә сезнең борчылуларыгыз һич тә нигезсез түгел, дигән нәтиҗәгә килдем. Без бу фани дөньяда бер генә тапкыр яшибез. Шуңа күрә кешенең гомере вакытсыз өзелмәсен өчен без, табиблар, барысын да эшләргә тиеш. Табибның җирдәге изге вазифасы шул. Махсус өйрәндем, динебез дә дару, савыктыру чараларын куллануны кире какмый икән, бәндәнең саулыгына, тирә-юньдәгеләргә куркыныч тудырмаган очракта алар фарыз, диелгән. Һәркемнең үз бурычы, руханилар дин ярдәмендә халыкны туры юлдан тайпылдырмаска тырышалар, мөгаллимнәр аң-белем бирә, инженер яшәүне җиңеләйтү максатында нидер уйлап таба, табиб дәвалый. Фәлсәфи яктан мин үзем бу бүленештә бернинди хилафлык та күрмим. Инде медицина адәм баласының әгъзаларын алыштыру дәрәҗәсенә иреште. Бу әле һич тә чик түгел, киләчәктә геннар инженериясе алга чыгарга тиеш, чөнки кешенең сәламәтлеген программалаштыру зарур. Ул чагында әгъза алыштырулар булмастыр, бәлки. Аннан соң, мөгаен, җанны йөрәк белән тәңгәл куярга ярамыйдыр. Җан киңрәк төшенчә, ул әле бик аз өйрәнелгән өлкә, безнең өчен чын

мәгънәсендә карурман. Марксизм-ленинизм тәгълиматы аны кире кага, дини хорафатка гына саный иде. Күрәсез, күгәрченкәем, дөреслек уртада булса кирәк...

Нурсинә үз-үзенә Әхмәтнең операциясе турында уйламаска сүз биргән иде инде. Шулай булмыйча, көнчелеге белән күпме нахак бәла такты бит ул аңа, шуның аркасында мәхәббәт ояларын чак-чак янгын ялмап алмады. Әле дә ярый вакытында аңлаштылар, югыйсә, гаилә таркалачак иде.

Әйе, Әхмәтнең тугрылыклыгы шик-шөбһә дә, шикләнүләр дә тудырмый хәзер. Ул яктан күңеле тыныч. Ләкин теге вакыттагы җилкенүләре, тәшвишләнүләре барыбер эзсез калмады. Җан-рух дулкыны Нурсинәне ирексездән яшәеш фәлсәфәсенең иксез-чиксез дәрьясына тартып кертте. Шактый гына мәкаләләр, китапчыклар белән дә танышты хәтта. Шулай, кеше — җиһанның таҗы. Аллаһы Тәгалә аны хәтта фәрештәләрдән дә өстен итеп яраткан. Фәрештәләргә ул фәкать акыл, зиһен генә биргән, шуна күрә бу илаһи затлар гөнаһ кылмыйлар, явызлык эшләмиләр. Хайван-җәнлекләрне исә, нинди дә булса теләк-дәртләре уянганда, бернинди киртәләр алдында да туктата алмыйсың. Чөнки аларга Тәңре тарафыннан шушы сыйфат фарыз икән. Кеше менә боларның барысына да ия: акыл-зирәклек тә, теләк-омтылыш та мул аңарда. Кеше явызлык та кыла ала, яхшылык та. Гөнаһ та, тәүбә дә аңа чит түгел. Шул сәбәпле, адәм баласы шайтан коткысына бирелмәсен, үз мәнфәгатьләре эчендә генә йомылып калмасын өчен Ходай Тәгалә аңа акыл дилбегәсен тоттырган. Тик дилбегәбез генә әле бер якка, әле икенче тарафка тартылып-тартылып китә, еш кына эзеннән дә чыга. Хаклыкны исә һәркем үзенчә тәкърарлый... Сүз дә юк, кешегә гомер бер генә тапкыр бирелә. Һәм һәммәбезнең дә мөмкин кадәр озаграк, дәвамлырак яшисебез килә.

Мөселман илләрендә, мәсәлән, бала төшерү, кешегә фарыз әгъзаларны алмаштыру тыела. Шуңа да карамастан, чирләшкәләр Әмерикә, Алмания кебек мәмләкәтләргә агылалар, ди, зур-зур акчалар тотып, тузган сырхау-әгъзаларын алыштыралар, ди. Яшәү исәбенә гөнаһ җыю инде бу. Әхмәт тә нәкъ шулар сыңары.

Бер уйлаганда, бик табигый омтылыш, икенче яктан, Тәңрегә, табигатькә каршы бару. Бәндә машина түгел, аны запас частьләргә аергалау табигый халәтебезгә генә түгел, әхлак кануннарына да туры килмидер, мөгаен.

Инде кайберәүләр вафат булганчы ук бөерләрен, йөрәк-үпкәләрен саталар икән. Бәгъзеләре сатып ала. Кеше әгъзасы әнә шулай алыш-биреш әйберсенә әверелә. Бу түбәнлек, билгеле. Алай гынамы, үз-үзеңне ихтирам итмәү, хайван дәрәҗәсенә төшү. Кешенең җиде төрле әгъзасын умырып алып, янәдән файдаланырга була икән. Димәк, аны инде җиде сырхауга бүлгәлиләр. Нинди вәхшилек.

Рәфкать Сафич әйткән геннар инженериясе дә шул ук бер балык башы. Ул да бәндәнең асылын үзгәртүгә юнәлдерелгән. Тик без табигать белән көрәшеп карадык ич инде, зыяннан башка нәрсә күрдек? Сырхауларыбызның да күбесенә шул сәбәп.

Шулай да Нурсинә профессор белән бәхәскә кереп тормады.

— Безгә нинди киңәш бирәсез соң? — дип кенә сорады.

— Әйе, хәзер Әхмәт хакында, — дип тезеп китте Рәфкать Сафич. — Бу минем иң уңышлы операциям. Аңлаттым шикелле, әлеге уңышның яртысы гына миннән тора, калган яртысы донорныкы. Билгеле, Әхмәт аерым исәптә торачак. Тик ничек кенә булмасын, аның язмышы хәзер сезнең кулда. Ләкин, күгәрченкәем, минем шикләрем дә бар: сез яшь, чибәр...

Нурсинә профессорның ни нәрсәгә ишарәләвен шунда ук аңлап алды.

— Сезнең миңа алай әйтергә хакыгыз юк, Рифкать Сафич, — диде ул оялуыннан нишләргә белмичә.

— Мине дөрес аңлагыз, күгәрченкәем, сез аны ташласагыз, ул озакка тартмаячак...

— Житте, ишетәсезме, житте,— дип кызып китте Нурсинә.— Мин сезгә рөхсәт итмим!

Мортазин Нурсинәнең чәбәләнүенә игътибар итмәде, ул күрәсең, бу әңгәмәгә алдан ук әзерләнеп куйган.

— Бу гади генә очрак түгел, күгәрченкәем,— дип, үзенекен каерды ул.— Фәнгә, медицина практикасына бәйләнешле гаять дәрәжәдәге мөһим эксперимент. Һәм без әлеге мөнәсәбәтләрне сезнең белән рәсмиләштерергә тиешбез. Ягъни сез үзегезгә билгеле бер бурыч аласыз, мин үз ягымнан. Андый кәгазьне мин әзерләдем инде, танышып кул гына куясы. Аннан соң, инде аңладыгыз шикелле, мәсьәләнең бик четерекле интим ягы да бар...

Профессор Нурсинәнең игътибарын ныграк җәлеп итү нияте белән беразга гына тукталып торды.

— Гафу итегез, мин табиб, шуңа күрә чын дөреслекне яшерми-нитми әйтергә күнеккәнмен. Монысы, күгәрченкәем, сезгә кагылышлы.

Нурсинәнең озын керфекләре ачылган килеш хәрәкәтсез калды, нәфис муены алгарак сузылды.

— Миңа?

— Әйе, күгәрченкәем, сезгә. Табигатьнең үз кануннары бар, аларны берәү дә үзгәртә алмый. Әйтик, сез, инде әйткәнемчә, яшь, чибәр, ир куенында гына иркәләнер чагыгыз. Ләкин ул бәхеттән сез мәхрүм...

Нурсинә, бер селтәнүдә профессор биргән кәгазьләрне идәнгә сыпырып төшерде дә, йөгерә-атлый бүлмәдән чыгып китте.

* * *

Әхмәтнең машинага утырып кайтасы килмәде, шәһәрне күрәсем килә, кешеләр арасында буласым килә, диде. Нурсинә каршы тормады. Әйберләрен яллаган машинага салып җибәрделәр дә, култыклашып урамга чыктылар. Тирә-як гөж килеп тора. Кешеләр бергәләнеп-суккаланып каядыр ашыгалар, күзләренә ак-кара күренми, әйтерсең лә, ахырзаман алдыннан соңгы сәгатьләрен яшиләр.

Көн шактый сүрән иде. Август ае җәй хикәятенә соңгы ноктаны куярга әзерләнә. Моннан ике-өч кенә көн элек тән-сынның күрсәтергә мөмкин булган бар урыннарын ачып йөргән яшь кызлар да инде чалбаркурткага күчкән. Өлкәннәр иңнәренә плащ элгән. Ара-тирә кузовлары юешләнгән машиналар күренгәли, димәк, кайдадыр якында гына күктәге болытлар тишелеп киткән. Хәер, ул монда да озак көттермәде. Күп тә үтми яңгыр сибәли башлады. Ышыкка керергә мәҗбүр булдылар. Нурсинәнең зонты машинада киткән икән.

— Нигәдер күңел ашкына, тизрәк кайтасы иде,— диде Әхмәт.

— Үзең бит,— диде хатыны,— машинага утырып кайтырга иде...

Нурсинә тамагына кылчык утыргандай тотлыгып калды, йөрәге тибүдән туктагандай булды — алар янына Альфред килеп баскан иде. Ул иренең җиңеннән тартты, ләкин соң иде инде, музыкант аны күреп алды.

— О-о, мадам,— дип, ул Нурсинәнең каршысына ук килеп басты,— бүген безнең премьера, мин сезне концертка чакырам!

Җир ярылса, җир астына төшеп китәргә әзер иде Нурсинә. Ләкин җир ярылмады. Ул ике ут арасында калды: бер якта — музыкант, икенче якта — ире. Бу ике ут чәкәләшсә, һичшиксез, янгын чыгачак. Чөнки Әхмәт бу танышлыкны кабул итмәячәк, операция дип тормас, якалаша ук башлар. Моңа юл куярга ярамый. Тик ничек?

Әлеге уйлар Нурсинәнең башында бер-ике генә секунд бөтерелеп алды, өченче секундта ул җаен тапкан иде инде.

— Сез нахал, әфәндем, мин сезне белмим! — диде дә Альфредның яңагына сугып җибәрде. Альфред нинди кыяфәткә кергәндер, Нурсинә аңа игътибар итеп тормады, хәлнең катлауланууыннан куркып, өстерәп диярлек Әхмәтне ышыктан алып чыкты. Әхмәт бер сүз дә әйтми яшь бала сыман хатынына иярде.

Яңгыр һаман ява иде әле. Юл өстендәге чокыр-чакырларда вак-вак күлләвекләр дә хасил булган. Машина тәгәрмәчләреннән сулы боламык бөркелә, асфальтның өсте чыжылдап тора.

Нурсинәләргә юлны аркылы чыгарга кирәк иде. Ләкин хәрәкәт шундый көчле, әйтерсең лә кемдер машиналарны чылбырга тезгән дә, тик шудырып утыра. Берөзлексез агыла да агыла машина. Светофор ягына атларга туры килде, ә аңа ике-өч йөз метр чамасы, өстән явып торганда бу шактый ара.

Нурсинә бигрәк тә Әхмәт өчен курка, профессор дигәннәре бик нык кисәтте бит. Бер-ике ай аеруча сакланырга туры киләчәк, диде. Сезне эштән бушатабыз, больничный түләячәкбез, диде. Мәгәр үзе мут абзый, күр, ничек ияләштермәкче була. Беренче күрүдә үк охшамаган иде ул аңа, гәрчә бөтенесе мактый, һәммәсе тәлинкә тота үзенә. Рәфкать Сафич та, Рәфкать Сафич... Үзе, әлбәттә, зур белгеч, кулы да җиңел икән.

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, ул Альфреды каян килеп чыкты тагын?

Ничек ашкынып көткән иде Нурсинә бу көнне! Шулай булмыйча, Әхмәте белән янә пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп яши башлаячаклар бит. Өйләренә нур куначак, бәхет кайтачак.

Дөрестән дә, ул алдан ук хәстәрен күреп куйды. Менә дигән табын әзерләде, кичкә туганнары, якыннары киләчәк. Бүләге дә бар — иренә күн куртка тектерде.

Әнисен күндерү генә кыенрак булды. Без ялгышканбыз икән, әни, хикмәт бөтенләй башкада икән, дип ирен үз канаты астына алырга теләсә дә, Нәмига ханым кызының сүзендә тормавын, аумакайлыгын хупламады. Әгәр инде язмышыңны бик тә ул бәндә белән бәйлисең килсә, никах укытырга кирәк, диде. Болай зиналанып йөрү зур гөнаһ! Аннан соң туй фарыз, туйсыз кияүгә чыгуны шәригать килештерми. Алдагысында да шәригатьне боздыгыз, бу бәхетсезлекләрең, балам, шулар нәтиҗәсе, димәк ки, Аллаһы Тәгалә ул гамәлләрегезне кабул итмәгән. Бусы бөтенләй ят бәндә, гәүдәсе — бер кешенеке, җаны икенченеке. Кыямәт көне буласын да онытма, фани дөнья бер генә мизгел ул.

— Мин никахка каршы түгел,— диде Нурсинә,— әйдә соң, чарасын күрик, ярдәм ит.

— И кызым, бәбкәем, кызганам мин сине,— дип әнисе ак яулык читен күзенә каплады,— бәхеткәйләрең булмады.

— Алай димә, әни, мин берәүдән дә ким-хур түгел.

Ана белән кыз шулай да килештеләр. Ләкин Нурсинә зур түземсезлек белән көтеп алган бу көн иртәдән үк күңелсезлек артыннан күңелсезлек китерде. Хәер, иртәдән генәме соң, төне буе дигәндәй бер күрмәгән Роберт белән саташып чыкты. Имеш, таш-тау арасында йөриләр. Әллә нинди куркыныч җир. Баш очында карачкыга охшаш каурыйсыз арык кошлар оча, әледән-әле ташланалар. Инде чукып алдылар гына дигәндә, Роберт кулын болгый, тегеләр шунда ук кычкырышып читкә тайпылалар. Берсе бигрәк тә шөкәтсез, һаман Нурсинәгә каныга.

— Монысы Әхмәтеңнең җаны,— дип тешләрен ыржайтты егет,— ул гәүдәсен даулый. Ха-ха-ха...

Шунда кинәт җир убылып китте. Нурсинә ыргытылган таш шикелле упкынга очты. Шулай да, төпкә төшеп җитмәде, аны әлеге килбәтсез кош күтәреп алды, нининдидер мәгарәгә алып керде. Роберт та шунда. Кулында зур пычак.

— Мин хәзер синең йөрәгеңне кисеп алам, сез ирең белән минекен урладыгыз,— дип Нурсинәгә ташланды.

— Мин гаепле түгел,— дип кычкырды Нурсинә. Роберт аның саен котырынды:

— Икесенең берсе: йә минем йөрәкне кире кайтарасыз, йә синекен үземә тегәм. Минем дә яшисем килә! Яшисем!

Нурсинә тартыша, тырмаша, ычкынырга омтыла. Юк, тегесе чытырмандай ябышкан, һич тә ычкындырырга теләми.

— Коткарыгыз, кирәкми, коткарыгыз!..

Иртән Нурсинә шыбыр тиргә батып уянды. Йөрәге еш-еш тибә, тәне калтырый. Әхмәтемә генә ул-бу була күрмәсен, дип үрсәләнде ул. Төшен онытырга тырышты. Инде күзеннән йокы качты, ахры торып, кер үтекләргә кереште.

Ә менә бу минутта ул хәтта Әхмәтенең янәшәдә атлап баруын да хәтереннән чыгарган иде. Бервакыт исенә килсә, алар тротуар уртасында басып торалар. Әхмәтнең моңсу күзләре аңа төбәлгән.

— Минем инде чыннан да кирәгем калмаган икән, Нурсик,— диде ул.— Акланып азапланма, сиңа үпкәм юк.

— Әхмәт, борчылма, барысын да аңлатырмын...

— Кирәкми, миңа барыбер.

— Ышан, Әхмәт...

Нурсинәнең башлаган җөмләсе ярты юлда өзелде, шәһәр диварларын дер селкетеп кинәт күк күкрәде. Ул шулкадәр көчле иде ки, гүя, галәм көтүлегенә меңләгән елгыр тайны берьюлы куып чыгардылар. Аның кайтавазы дүрт-биш минуттан соң гына тынды. Әле аннан соң да торатора җимерелгән язгы яр кебек болыт эче ургылып-ургылып алды.

Нурсинә чытырдатып күзләрен йомды, куллары белән тотыныр урын эзләде. Ни өчендер хәтеренә бүгенге төше килде.

Шул куркыныч төш манзаралары салкын яңгырлы күкрәү белән бербөтен булып укмашты: хәерлегә генә булсын, ходаем! Нинди күкрәү инде бу куллар күшегерлек салкында?

Нурсинә кечкенәдән үк табигать көчләреннән куркып-өркеп яшәде. Әниләре аларны шулай өйрәтте, имеш, ай тотылу, яшен, давыл, су басу, янгын бәхетсезлек китерә. Бу Ходай Тәгаләгә күрсәтелгән игътибарсызлыктан, ди. Кеше йөгәнсезләнгән саен, алар күбрәк була, ди. Ахырзаман галәмәтләре икән ул зилзиләләр. Дөрес, мәктәптә бөтенләй башкача өйрәттеләр. Тик яшьли әнисе уяткан курку хисе барыбер калды. Бигрәк тә яшен шурләтә иде аны. Болыт кабарганын абайлап алдымы, хәзер бисмилласын әйтә, дога укып, тәрәзә-ишекләрне ябып куя.

Менә хәзер дә, күк күкрәүгә, үзе дә сизмәстән, Әхмәтнең ялгызын гына калдырып, койма ышыгына элдертте... Һәм озак та тормый искиткеч якты бер нур күзләрен кисеп үтте. Шуннан соң колакларының элпәсен ярырдай булып шартлау яңгырады...

Бу вакытта Әхмәтнең эчендә ут кайный иде. «Миңа барыбер», дип сер бирмәскә тырышса да, әлеге очрашу аның болай да җәрәхәтле күңеленә тоз булып утырды. Нурсинә бөтенләй чит кешенең янагына сукмас иде, дип офтанды ул. Димәк, алар таныш, таныш кына да түгел, бик яхшы таныш. Хатыны бу ясалма кыланышы белән тотылды гына, каракның бүреге сыман үзе янды.

Күңеленә кереп оялаган шушы уйлар сөремендә Әхмәт беренче күкрәүне сизмәде дә диярлек. Һәрхәлдә, алай ук зур игътибар бирмәде. Ә менә хатынының аны ташлап, читкә каерылуын күтәрә алмады: күрәләтә санламау ич бу! Нурсинәне чәбәкләр дәрәҗәгә җитте ул. Бәлки әле шулай эшләгән дә булыр иде, тик кинәт нииндидер бик кайнар җил аны бөтереп алды да, читкә бәрде. Бер җире авыртмады, бер җире сызланмады, фәкать якты вә җылы бер бушлыкта очуын гына тойды ул. Каурый сыман җип-җиңел. Очарга да очарга. Тик бу халәт озак дәвам итмәде, алдындагы нур акрынлап сүнде, тирә-якны шыксыз караңгылык биләп алды...

Нурсинә ниндидер әче, тәмсез искә буылып уянды.

— Минә шулай, вак алмам, әйдә, әйдә, курыкма, күзләреңне ач, күр, ничек матур икән безнең күзләребез,— дип сөйләнә-сөйләнә шәфкать туташы аңа нашатырь спирты иснәтә иде.

— Уяндымы? — дип сорады табиб.

— Табигатьне соң дәрәҗәдә бозып бетердек, Наил Моратович, инде карлы яңгырда яшен суга башлады,— диде тәмле телле ханым. Аннан соң сорауга җавап бирергә кирәк тапты, ахры, әйтте: чибәркәебез бәхетле күлмәк киеп туган икән, аллага шөкер, айныды, куркып кына егылган, күрәсең.

Нурсинә бу сүзләрне ишетеп ятты, ләкин бармагын селкетерлек тә хәле юк иде. Башы ярылырдай булып чатный, чигәләренә гүя тимер кыршау кидергәннәр. Авызы кипкән, күңелен болгатып күгәргән тимер исе килә.

— Су-у,— диде ул киндердәй каткан телен көчкә әйләндереп.

Су капкач эченә җан кереп киткәндәй булды.

— Иремнең хәле ничек? — дип сорады ул, ниһаять.

— Сезгә борчылырга ярамый, вак алмам...

— Иремнең хәле ничек? — дип мазасызланды Нурсинә.

Әхмәт җиңелчә генә ыңгырашып куйды.

— Тынычланыгыз,— дип юатты Нурсинәне шәфкать туташы,— тавыш бирә бит, җанашым, димәк ки, өмет бар.

Нурсинә башын Әхмәтнең тавышы килгән якка борды. Йөзе күренми, ә башы ак марля белән уралган, сулавы тигез. Аллага шөкер, йөрәге түзгән дип куанып куйды ул. Ләкин урамдагы хәлләр искә килүгә, тәне чымырдап китте. Нинди гаделсезлек соң инде бу, йә?! Нигә һаман бер кешене чукый соң бу рәхимсез кара кош? Ходай каршында да, кешеләр алдында да гаебе юк лабаса Әхмәтнең, нигә ул гына кыйналырга тиеш? Җир күтәрә алмастай әллә нинди кансыз бәндәләр кәеф-сафа корып, бер кайгысыз яши бирә, ә Әхмәт юлында фаҗига арты фаҗига. Күпме бәла-каза кичереп, аякка бастым, тернәкләндем генә дигәндә — янә дә уйга да килмәстәй бәхетсезлек.

Әллә соң бер-бер изге затмы Әхмәт? Ходай, яраткан, үз иткән бәндәмә сынауларымның да иң авырларын җибәрермен, дигән бит. Атабыз Адәм белән анабыз, Хәүва, әнә, нинди авырлыклар кичергәннәр...

Әллә әнисенең гоманлаулары раска килүме бу? Бәлкем, Әхмәт ниндидер ялгыш гамәле өчен Аллаһы Тәгаләнең бәддогасына юлыккандыр? Әйтелгән ич, Аллаһы Тәгалә һәрчак уяу һәм бернине дә онытмый, диелгән. Адәмне ул адәм итә, аңа тормыш бүләк итә. Ә кирәк булса, кире ала да... Аңа уйларың белән каршылык кылу да зур гөнаһ, ди. Ә төптәнрәк уйлаганда, Әхмәт әнә каршы килде. Аллаһының имтихан-сынауларына түзә алмады — операция ясатты. Ходай фарыз кылган әгъзасыннан баш тартты, үз җанын очырды. Тәңре, мөгаен, Әхмәт, син хаклы түгел, менә дәлиле, дип җибәргәндер ул яшенне? Аның урынына беркем дә шәфәгать ителми, шәфәгать аның рөхсәте белән генә, ди дога.

Җан, рух, менә шулай итеп, тагын Нурсинәнең күз уңына басты. Әйе, Әхмәт хәрам җан йөртә! Һәм шуның җәзасын алды да. Бәлкем, бу сынаудыр?

Әхмәт янә ыңгырашты. Бу ыңгырашу җан, гөнаһ, җәза турындагы уйларны да үзенә йотты, хатын күңелендә фәкать Әхмәт, аның исәнлеге өчен кайгыру хисе генә калды. Нурсинә урыныннан сикереп торды.

— Безне алтынчы сырхауханәгә алып барыгыз,— диде ул каударланып,— тизрәк!

— Вак алмам...

— Әйттем ич, алтынчыга илтегез!
— Алтынчының профиле башка, ханым,— дип сүзгә кушылды табиб.
— Доктор, иремнең хәле ничек?— Ир кеше тавышы Нурсинәне тынычландырып җибәргән иде.
— Әлегә тәгаен гына бернәрсә дә әйтеп булмый. Яшен тимәгән, анысы хак, ләкин башы имгәнгәнгә охшый, чын хәлне рентген күрсәтер.
— Шулай да безне алтынчыга илтегез!
— Әйттем ич инде...
— Аңладым, доктор, тик барыбер безгә алтынчы кирәк!
Нурсинә хәлне аңлатып бирде.

...Әхмәтнең палатасын җыештырырга да өлгермәгәннәр иде әле, аны яңадан шунда салдылар. Нурсинә исә килә-килешкә профессор бүлмәсенә бәреп керде.
— Рәфкать абый, җаным,— диде ул үкси-үкси.— Мин барысына да риза, зинһар өчен Әхмәтне, Әхмәтханымны гына коткарыгыз. Рәфкать Сафич...

# ШИГЪРИЯТ

## Рәшит Гатауллин



### АГЫЙДЕЛ, ЧУЛМАН, ИДЕЛ...

* * *

Тын. Кояш сүрелә. Агыйдел,
Агасың бәрелеп талларга.
Агасың, тынгысыз җанымны
Саласың тагын да уйларга.
Мәгънәсез дөньяны калдырып,
Калдырып җанымны күмергә.—
Талпына, җилпенә йөрәгем
Очарга, белмимен, кай җиргә?
Хисләрне уятыр, тетрәтер
Ах, нәрсә, ни генә калды соң?
Арыган, талчыккан чагымда
Башымны кайларга салыйм соң?!
Ваемсыз, бер гамьсез чакларым,
Сез зәңгәр томаннар артында...
Хәсрәтле, сагышлы моң килә,
Агыйдел, дулкыннар тавышында...
Кич. Эңгер. Моржадан ак төтен
Елыша тын гына урамга.
Бер гомерем җәл түгел, тагын бер
Ямь-яшел юллардан урарга,
Буранга, себерткән җилләргә
Йөз куеп атларда җиләргә...
Мәгънәсез, ваемсыз дөньяны
Калдырып китәргә, китәргә
Талпына, җилпенә йөрәгем,—
Тилпенә... Чакыра кайларга?

---

Рәшит ГАТАУЛЛИН (1938)—*Уфада яшәүче татар шагыйре. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Шигырьләре матбугатыбызда даими басылып килә.*

...Чайпала-чайкала Агыйдел,
Тын гына бәрелеп талларга...

* * *

Кешеләргә бүген нәрсә булган,
Дөньяларга, димен, ни булган?
Челпәрәмә килеп ватылдымы
Хыяллардан корган бу дөньям?
Бер карасаң, берни үзгәрмәгән,
Шул ук дөнья, шул ук кешеләр.
Кемдер килә, кемдер китә тора.
Имин яши минем ишеләр.
Күкләр биек. Кояш — урынында.
Җәй артыннан тагын көз килә.
Карлар ява... Гөлләр яфрак яра...
Очар кошлар үзенең иркендә.
Бер нәрсә дә үзгәрмәгән кебек,
Барысы да кебек урынында.
Барысы да бер үк күк астында
Җылы ала Кояш нурыннан.
Ә нигә соң җаным тыныч түгел.
Менә тагын җиргә бастым да,
Тар читлеккә ябып куйган кебек
Хыялларым нидән тарсына?
Күккә карыйм, җиргә карыймын да
Йөрәгемне нинди шом баса?..
Нишләрмен соң хыяллардан торган
Шушы бәллүр дөньям уалса?!

## Шушы инде

Баскан җирем кемнең туфрагы соң?
Кемнәр сөягендә басып торам?
...Алыплардай чалкан төшеп яткан
Җирнең уртасына мәгърур Урал.
Агыйделкәй ага — көмеш чылбыр.
Кыштыр-кыштыр дала җиле исә.
Аваз салсам әгәр, үткәннәрдән
Хәбәр килер микән, кичекмичә?
Кем эзләре калган бу туфракта,
Кемнәр рухы дәшә еллар аша?
Нәсел-ыру, туган тамырларым
Кемнәр белән икән, дим, тоташа?
Бөек һуннар эзе калгандыр бит,
Хәзәр кавемнәре кая киткән?
Болгар бабамнарның язмышлары
Сыдырылып кайсы җирдән үткән?!
Туфрак, сулар әгәр сөйли белсә,
Шул тауларның әгәр телен белсәң;
Тере тарих күз алдына килеп,
Үткәннәрне әгәр сөйләп бирсә,

Тетрәп куяр иде мәгъруր Урал.
Тынып калыр иде Агыйделем...
Утлар өткән, җил-давыллар үткән —
Шушы инде минем туган җирем.

## Тышаулы атларга карап

Никтер сәер... Тау буенда
Йөри тышаулы атлар...
Атлар гынамы, безнең дә —
Кайда тышаусыз чаклар?!
Кайчан соң тайлар, колыннар
Пыр тузып уйный иде.
Ә без соң — яланаяктан
(Аттан киммени таяклар!)
Бар җирне буйлый идек.
Тышаусыз иде хыяллар,
Тышаусыз иде өмет.
...Җилдәй җилдергән колыннар
Туктады нидер сизеп.
Туктады уйлар агышы,—
Авызлык кидерделәр.
Бил катмас борын тайларның
Өстенә мендерделәр...
Тарттылар, күтәрделәр дә
Сыртлары сыгылганчы.
Йөрәге ярылып, юлда
Гөрселдәп егылганчы.
Йөдәгән, йончыкканнарын
Тышаулап җибәрделәр.
...Уйларым әле дә тышаусыз,
Әле дә йөгәнсезләр.
Яңгырларда ышык тапмый
Тора тышаулы атлар.
Калды соң, калды кайларда
Тышаусыз йөргән чаклар?
Тышаулы атларга карап
Нигә соң сыкрый күңел?
...Ах, тышау гына атларда,
Ах, ярый богау түгел.

## Оныттык

Башка җирдә ямь тапмадык инде...
Гомер буе сиңа йөз тоттык.
Сагындык та машинада кайттык,
Ат җигүне мәгәр оныттык...
Таш йортларга күптән күнексәк тә,
Шәһәр исләреннән тончыктык.
Ятып иснәсәк тә печәннәрен,
Печән чабуларны оныттык.
Динебезне, туган җиребезне

Югалттык та... Хәзер ни таптык?
Тапмадык та, борынгыдан килгән
Гореф-гадәтләрне оныттык.
Айлы кичләр, салкын чишмәләрне
Юксындык та тагын без кайттык:
Әнкәйләр, дип, әй сызланган булдык,
Әнкә телен, күпләр, оныттык.
Туган җирне, урман-суны ташлап
Әллә кайда китеп олактык:
Вәгъдәләшкән ярны гына түгел,
Вәгъдәне дә хәтта оныттык...

## Адаштыр

Адаштырыр өчен барган җирдән
Җитәкләдең, язмыш, кулымнан.
Булмагачтын җирдә үз сукмагың,
Гаҗәп түгел, язсаң юлыңнан.
Мин адаштым. Бер ялгызым гына
Урманнарга кереп адаштым.
Чыгар юлларымны таба алмый,
Төшләремә чумып саташтым.
Мин адаштым салкын бураннарда,
Җиккән атлар юлны тапмады.
Адашты, дип эзләп чыкмадылар,
Әнкәй генә көткән кайтканны.
Мин адаштым болытларга карап.
Томаннарга кереп адаштым.
Караңгыга калып юлдан яздым,
Адашудан торды язмышым.
Кочагында акылымнан яздым,
Яратам, дип, башым югалттым.
Кайсыгыз соң юлдан яздырмады?
Кая килеп чыктым адашып?..
Тик мин генә юлым табалмыйча
Йөрим микән һаман саташып? —
Ак томаннар, кар-бураннар аша
Тартып алса җылы карашың:
Бу адашкан кеше дисәләр дә,
Үпкәләмәм — минем язмыштыр.
Хыялларым булып килеп кер дә,
Мәхәббәтең белән адаштыр.

## Төшендер, Тарих

Агыйделем, Чулман, Идел...
Таулар, урманнар кала.
Теплоход белән тарихка —
Болгарга китеп барам.
— Татар илендә сигез көн,—
Шулай ди Нажар ага...
Татарча сөйли теплоход,

Татарча дулкын кага...
Юлымның башы, азагы
Кайда соң? Кайда тарих?
Кайгылар башлардан ашкан,
Сөенеч алып барыйк.
Туктады безнең теплоход,
Шушымы Болгар җире?
Әллә без — алга барабыз,
Әллә кайтабыз кире?
Шушымы бабайлар торган,
Бабайлар баскан туфрак?
Сыдырылып шул җирдәнме
Дәверләр үткән дулап?!
Күптән таныш та, түгел дә,
Шушымы Болгар иле?
Ташларга кагылып исә соң
Нинди заманнар җиле?!
Нигә соң чиркәү утыра
Гасырлар кабериндә?
Сибәли яңгыр... Үткәннәр
Үтәдер бәгыремә.
Түзмәде Нажар Нәҗми дә,
Яшенә сеңде уе,
Гүя нindiдер өметне
Алдылар кабат уеп...
Сак кына син дә кагылдың
Гөлләрнең сабагына...
Утырган татар — сөяктәй! —
Урысның тамагына.
...Кузгалды безнең теплоход.
Каршыда — шәһри Казан.
Төшендер, тарих, татарга,
Бүген соң нинди заман?



## Радик Фәизов

# ЕЛЛАР ҮТКӘЧ...

хикәя

Габдрахман ага — олы, авыр гәүдәле өлкән кеше — «Татарстан» кунакханәсеннән чыкты да шундагы озын эскәмиягә утырды. Җәйге кич, инде шәһәрнең шау-шуы, хәрәкәте бераз тынып килә. Һавасы да шактый аруланган кебек. Ял итеп утырырга була. Гомере буена район финанс бүлеге мөдире булып эшләде Габдрахман ага. Инде күптән пенсия яшендә. Тик яраткан шөгылен һаман да ташлый алмый. Район советында бухгалтер. Менә аларны Казанга киңәшмәгә җыеп алганнар иде.

Эскәмиягә, аның янәшәсенә бер хәрби кеше килеп утырды. Зур дәрәҗәле, полковник, укалы погоннары ялтырап тора, үзеннән затлы хушбуй исләре килә. Чигәләренә чал кергән,туры борынлы, күркәм йөзле бу полковник Габдрахман агайга текәлеп карап-карап алды.

— Гафу итегез, Сез Габдрахман Сабитов түгелме? — диде ул кинәт саф татар телендә.

Ничектер серле итеп, ярым пышылдап бирелгән бу сораудан Габдрахман ага сискәнеп куйды. Тукта әле, кайдан белә бу хәрби аны? Болай капылт кына... нигә кирәкте ул аңа? Бик сәер бит бу!

— Әйе, мин Сабитов! — диде ул, мондый кызыксынудан ризасызлык белдерүен яшермичә.

— Н. районында финанс бүлеге мөдире?

— Мөдир түгел хәзер. Бухгалтер. Ә шуннан ни булган? — диде Габдрахман ага инде тавышын ук күтәреп.

— Тынычланыгыз, зинһар. Мин тагын бер кат гафу үтенәм Сездән. Берни дә юк, — диде полковник һәм тагын да серле итеп өстәп куйды: — Сезне минем әти кунакка чакыра...

— Ничек... кунакка? Сезнең әтиегез кем соң ул? — диде Габдрахман ага тәмам гаҗиз булып.

---

Радик Фәизов (1931) — *язучы, дистәләгән китаплар авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Арчада яши.*

— Сазиленең Вафа минем әти. Бәлки, Сез аны хәтерлисез дә булыр. Сазиленең Вафа Кәримов! — диде хәрби һәр сүзен ачык итеп һәм урыныннан торды.— Мин иртәгә нәкъ шушы вакытта Сезне алмага килермен. Әзер булырсыз дип ышанам! — диде ул хәрбиләрчә турылык белән һәм, кулын чигәсенә тидереп алды да, китеп барды.

Олы гәүдәсенә кинәттән кайнарлык йөгереп йөрәге кага башлаган Габдрахман ага эскәмиядә утырып калды. Вафа Кәримов! Хәтерли ул бу кешене, әйбәт хәтерли. Утызынчы еллар... Авылларда кулакларның йорт-җирләрен тартып алып, үзләрен Себергә куу заманы. Вафа Кәримов — кулак, сан өчен исемлеккә теркәлгән таза хәлле крәстиән генә түгел, ә тамырларын як-якка җәеп җибәргән чәерле, чын кулак! Аның әтисе Кәрим бай дистәдән артык яхшы атлар тотты, сәүдә итте. Ул үзе, үзеннән дә зәһәр өч егете әллә кая еракларга, Урта Азия, Оренбург якларына кадәр йөреп сату иттеләр. Камчат бүрек, ялтыр итекләр, затлы киемнәрдән генә йөрделәр. Ә байлыклары тулып ташыган, ул замандагы зур байларга гына хас өч буй бүрәнә йорт, шыңгырдап торган амбар-келәтләр, сукмакларына таш түшәлгән болындай ишегалды, ялтырап торган көмеш шарлар куелган алма бакчалары, буралы коелар... Кыскасы, чын алпавыт утары инде менә.

Кулакларны барлау хәбәре чыгуга, Кәрим бай үзенең карчыгы Маһитап апайны, ике егетен алды да, булдыра алган чаклы байлыгын төяп, каядыр сәфәр киттеләр. Йорттагы калган мал-мөлкәтне, атларны саклап аларның кече уллары Вафа берүзе калды. Габдрахманның кордашы, бергә уйнап үскән, әле егерме яше дә тулмаган егет. Әлбәттә инде, йортка зур комиссия керде. Габдрахман, авылның беренче комсомолларыннан буларак, бу комиссиянең әгъзасы иде. Аның кулына дәфтәр, каләм бирделәр.

— Әллә барысын да язып тормыйсыңмы, кордаш. Әллә мине үз йортымда калдырасызмы? Каравылчы итеп кенә булса да,— дигән иде шул чакта Вафа, Габдрахманны бер читкә дәшеп.— Харап итәсез, югыйсә. Без бөртекләп җыйган бу мал-мөлкәтне сез таратып кына бетерәчәксез. Җилгә очырып... Әллә үземне калдырасызмы? Мунчада гына булса да яшәп торыр идем...— дип ялварган иде.

Тик кайда ул! Комиссия сүзне коры тотты. Барлык мал-мөлкәтне, каралты-кураны язып алдылар. Вафаның үзен иртәгесен үк авылдан кудылар. Җитмәсә, хәленә кереп бер атын һәм арбасын да алырга рөхсәт итмәделәр. Бүтән авыллардан куылган кешеләр олавына утыртып, гидай чыгарып җибәрделәр.

Байтак еллар буена күңелендә нииндидер авырлык, уңайсызлану йөртте Габдрахман. Иптәш егетенең янып торган сөрмәле кара күзләре, ялварулы карашы әледән-әле исенә төште. Өеннән чыгып исә Вафа имән капка баганаларын кочып, үзенең яраткан аты Сандугачның муйнына сарылып елаган иде ул чакта... Ә утар, дөрестән дә, бик тиз таралып бетте. Йортны авыл клубы иттеләр, амбар-келәтләрне колхоз өчен авыл башына күчереп салдылар. Шуннан соң инде кемнәрдер ниинди нык капка-коймаларны сүтеп алды, бакча рәшәткәләрен сындырып бетерде. Нинди әйбәт алма, чия бирә торган җиләк-җимеш бакчасы корыды, ишегалдын чүп басты... Еллар үтә торгач, Габдрахманның күңелендәге авырлык акырынлап юылды. Дөресен генә әйткәндә, Вафа үзе дә күптән онытылган иде инде.

Байтак утырды Габдрахман эскәмиядә. Менә син, ә?.. Инде һич уйламаганда, көтмәгәндә. Әллә кайдан, еллар артындагы караңгылыктан, ачуым килмәгәе, теге дөньядан хәбәр биргән шикеллерәк. Кара син аны, исән икән әле үзе. Җитмәсә, яп-якында, Казанда оялап ята икән. Шунысы гаҗәп, Вафага инде әллә кайчангы Габдрахман нигә хаҗәт булды икән? Ничә еллар үткәч, инде картаеп үләр вакытлар җиткәч диген... Үзенең үпкә, каргыш сүзләрен әйтер өчен форсат эзләү түгелме?

Әллә: «Күрәсеңме, сезнеңчә барып чыкмады бит. Сез төзегән җимерелеп төште. Адәм каһәрләп кенә йөрдегез. Барыбер безнең әзгә әйләнеп кайттыгыз!» — дип, тантана итәргә җыенамы? Әллә, карт тиле, бер-бер мәкер белән шул замандагы үчен кайтарырга исәп тота микән, югыйсә?.. Габдрахманның күңелендә көтүе белән сораулар кайнашты. Әмма шулай да барырга кирәктер. Бернигә дә карамыйча барырга! Кирәк икән, җавабын да тотарга... Бервакытта да куркак булмады, читкә посып калмады ич Габдрахман.

Икенче көнне, ул билгеләнгән вакытта кунакханәдән чыкты. Чыгып баскан уңайга янәшәсенә кара төстәге «Волга» машинасы килеп тә туктады. «Черт» итеп кенә машинаның ишеге ачылып китте, анда полковникның елмаюлы йөзе күренде.

— Рәхим итегез, Габдрахман абзый! — диде ул килешле итеп кенә.

Машина шәһәрдәге күпкатлы йортларның берсе янына туктар, үзен шундагы бер фатирга алып керерләр, дип көтте Габдрахман. Тик алай булмады. Күпкатлы йортлар инде артта калды, шәһәр чите авылныкыннан әллә ни аерылмаган йортлар, авыл урамы башланды. Ә машина һаман да туктамый бара. Менә урам да бетте, машина ачыграк бер урынга чыкты һәм туктап калды.

Машинадан төшүгә, Габдрахман өчен шактый сәер хәлләр башланды. Алар нәкъ Кәрим байларның теге замандагы капкасы кебек биек түбәле, юан имән баганалы, челтәрле кара тимер сугып эшләнгән киң һәм нык капка каршысында басып торалар иде. Әйтерсең, бу дөньяда бернинди үзгәреш булмаган, алтмыш еллап вакыт үтеп китмәгән, бар да элеккечә сакланып калган! Ә капканы ачып кергәч, Габдрахман имәнеп үк китте. Ишегалды да нәкъ элеккечә бик иркен, машина үтә торган урыннарга, сукмакларга асфальт түшәлгән, калган урыннарда ямь-яшел үлән, уртадарак исә биек буралы кое тора иде. Рәшәткәле агач бакча, түрендәге мунча нәкъ элеккечә. Тик келәтләр урынында гына хәзер бүтән корылмалар: кызыл кирпечтән ике капкалы зур гараж, пыяла рамлы теплица, тагын әллә нинди корылмалар. Ә йорт элеккечә бер катлы түгел, ике катлы: асты кирпеч, өскә каты кәрнизләре, тәрәзә капкагалары бик матур итеп, сырлап эшләнгән нарат бүрәнә йорт иде.

Вафа Кәримов үзе Габдрахманны баскыч төбендә каршы алды. Инде бик олыгайган, юка гына гәүдәле, чәчләре тәмам сирәгәйгән бу картны Габдрахман урамда очратса, танымый да китәр иде. Аны инде тоныкланган, сөрмәледәй кара күзләреннән генә танырга була. Вафа гел авыл картларынча — башында кара бәрхет кәләпүш, аякларында ак йон оекбаш иде. Габдрахман белән ике кулын биреп күреште.

— Әйдүк, кордаш, өйгә үт! — диде ул гади генә итеп. Әйтерсең, алар арасында берни дә булмаган, инде бер гомергә тиң вакыт үтеп китмәгән, алар кичә генә күрешеп аерылышкан авылдашлар иде.

Өйгә кереп, өске катка мендeләр. Анда, иркен зал уртасындагы өстәлгә, табын әзерләнгән иде. Залдан берничә бүлмәгә ишек чыга, бер як стенада алтынлап эшләнгән стенка, зур келәм, идәндә дә калын келәм, җиһазлар бик кыйммәтле, бай һәм зәвыклы. Ә менә өстәлдә элеккечә аклы-кызыллы гади генә ашъяулык.

— Син, кордаш, кунак кеше, түргә кереп утыр. Камил улым, син дә утыр, — дип эндәште Вафа полковникка.

Өстәлдәге ризыклар да авылдагыча: беренчегә токмачлы тавык шулпасы, аннары туралган салкын ит, кайнар өчпочмак. Болар һәммәсе дә тәмле итеп әзерләнгән иде. Төрле салатлар, җиләк-җимеш күп өстәлдә. Ә инде эчемлекнеңниндиен телисең — шундые бар, төрле коньяклар, шәраблар... Кунак Вафа белән улына әрмән коньягы, ә үзенә зур шешәдән нинди-дер шәраб салды.

— Үзем ясаганы бу. Җиләк-җимеш. Миңа бүтәне бармый. Ә моның файдасын күрәм, кордаш. Күкрәкләрне йомшатып, гәүдәне язып җибәрә, — диде ул.

Табын янында өчәү генә утырдылар. Әмма ике катлы зур бу йортта яшәүчеләрнең күп икәне сиземләнә, кайдадыр, сөйләшкән, балалар көлгән тавышлар ишетелә, телевизор, музыка шаулый, монда тормыш кайный иде. Вафа инде ялгыз, карчыгы вафат иде, күрәсең. Залга берничә тапкыр бер яшьрәк ханым гына кереп чыкты.

Җае чыкканда кимен куймый иде Габдрахман. Ул тартынмыйча ашады, эчте һәм шул ук вакытта эчтән генә гел сагаеп утырды, үзен алдагы минутларга әзер тотты. Сүз башланып китәсен көтте ул. Зур сүз башланасын. Вафа тарафыннан мактану, горурлану, ә үз адресына көлү, хәтта мәсхәрә сүзләре көтте. Ә бит, дөрестән дә, Вафаның бүгенге көндә горурланыр хакы бар. Габдрахман кордашына битәрләү сүзләре әйтсә дә урынлы булыр иде. Менә, кем уйлаган бит аны... Кайчандыр авылдан чидай килеш Себер куылган кеше монда әйләнеп кайтыр, үзенә шушындый оя кора алыр, элеккедән дә битәр мул, җитешле тормышта яшәп ятыр, дип кем уйлаган?!

Габдрахман Вафаның менә-менә сүз башлавын, тормыш хәлен сөйләп бирүен, гаиләсе белән таныштыруын, һич югы Габдрахманның үзе, авылдашлары белән кызыксынуын көтте. Әмма Вафа Габдрахманга ни үткәнне искә алып, ни хәзерге хәлгә, сәясәткә мөнәсәбәтен белдереп, сыңар сүз дә әйтмәде. Алар улы белән җыен юк-бардан, һава хәлләреннән узмадылар.

Табын яныннан кузгалганда дога кылынды. Аннары Вафа Габдрахманга өйянындагы янкорманы, чынаяк плитәләр түшәлгән йөзү бассейнын, инде кичке утлар белән балкып торган теплицаларны, оранжереяны күрсәтеп йөрде. Үзенең нинди сортлы кыярлар, помидорлар, нинди чәчәкләр үстерүен тәмләп сөйләде. Тик үз гомерендә ни бер түтәл яшелчә, ни бер чәчәк үстереп карамаган Габдрахман аның сөйләгәннәрен төшенеп бетмәде. Нинди иркен, заманча итеп эшләнгән теплица, гаражда янәшә ике кара «Волга». Нинди йорт, капка коймалар! Нинди акчага, нинди байлыкка килгән бу ганимәтләр? Габдрахманның күңелендә әнә шулардан аптырап, югалып калу хисләре өстенлек итә иде.

Улы Камил машинасын чыгарып, барысы да капкага юнәлгәч, Габдрахман аганың йөрәге кага башлады. Менә хәзер була инде... Менә хәзер әйтә инде Вафа үзенең бер җилле сүзен!.. Тик Вафа һаман да үзгәрешсез калды, аның какча йөзе тыныч, уйчан һәм фәлсәфи иде.

— Исәнлектә тагын күрешергә язсын, кордаш. Калага килсәң, безгә керми калма. Инде юлны белдең,— диде ул, Габдрахман белән саубуллашканда.

Кайтып җиткәч тә кунакханәгә керергә ашыкмады Габдрахман ага. Инде тыныч калган шәһәрнең утларына карап, бераз эскәмиядә утырды. Күңелендә аның төрле чагыштырулар, Кәрим бай малае Вафа яшәп яткан утар, аның зиннәтле иркен йорты, чынаяк плитәле йөзү бассейннары, ә шулар янәшәсендә үзләре көн иткән поселок, уналты фатирлы кирпеч йортлар, карчыгы белән икесенә бирелгән кысан, шыксыз бүлмә, йортның чүп-чарга баткан ишегаллары эченә керергә куркырлык бәдрәфләре иде. Күңелдә нидәндер гарьләнү, үткән гомернең мәгънәсезлегеннән үкенү, бушлык, инде берни белән дә тутырып булмый торган бушлык иде...

# Гашыйк Гомәр

кырым-татар поэзиясе классигы

**Әй, Гомәр, мәҗнүн Гомәр,**
**гамьле Гомәр, гашыйк Гомәр,**
**Бу җиһанда һич кемгә дә**
**бер зарары юк Гомәр!**
**Яд итәрләр, мин китсәм дә,**
**халыкта — иҗатымны,**
**Белмәгәннәр белер — минем**
**һәм шигырь, һәм атымны...**

Бу юлларны кем язган? Һәм нигә без әлегәчә аның «атын, иҗатын» белмичә яшәгәнбез?

Кырым-татар әдәбиятының горурлыгы, кырымлылар үзләре атаганча, мәшһүр «саз шагыйре», унҗиденче гасырда (1621-1707 еллар) яшәгән, 25 мең юллык зур шигъри мирас калдырган Гашыйк Гомәр — Гомәр Абдулла улы иҗатыннан бу эндәш-«сәтырьләр».

Кардәш төрки халыклар авыз иҗатында һәм шигъриятендә «ашуглар»ның — гашыйк шагыйрьләрнең «саз чалып» иҗат иткән көйле шигырьләре — мәгълүм бер традиция. Шуңа да «Аслы вә Кәрим», «Гашыйк Гариб» кебек кыйссалар, аларның иҗатчылары, каһарманнары — төрки шигъриятнең канында, җанында булган. Гашыйк Гомәр — шәхесе белән дә, шигырьләре белән дә — аларның дәвамчысы, үзе дә легендар бер зат һәм халык иҗатын язма кырым-татар әдәбиятына тоташтыручы. Мәхмүт Касыймның «Йосыф-Зөләйха» сы белән башланган (XIII йөз) бу әдәбиятка 17 гасырда Әдип дигән шагыйрьнең «Сәфәрнамә», Җанмөхәммәтнең «Тугайбәй» әсәрләре өстәлә. Болар — шигъри дастаннар, тарихи зур кыйммәткә ия ядкарьләр. Бу шагыйрьләрнең замандашы, Кизләүдә (Евпатория) туып үскән Гашыйк Гомәр, әлбәттә, халык иҗаты җәүһәрләрен дә, язма әдәбият-шигърият үрнәкләрен дә яхшы өйрәнгән. Кырымдагы атаклы мәдрәсәләрдә дә, үзе сәяхәт иткән һәм яшәгән Төркия, Иран, Дагыстан, Әзәрбайҗан кебек илләрдә дә белемен даими үстерә килгән. Остазлары — Хафиз, Руми, Фирдәүси, Сәгъди һ. б., төркиләрдән — Әхмәт Ясәви, Юныс Әмрә, Фөзули кебек олуг шагыйрьләр авазы да аның шигырь рухына күчкән. Төрки әдәбиятларның уртак традицияләрен, лириканың күк һәм җир аралашкан югары сулышын, сурәтләр дөньясын, шәкли байлыгын, теле-өслүбен Гашыйк Гомәрдә аеруча калку тоясың... Ул, Юныс Әмрә кебек үк, төрекнең иң зур шагыйрьләреннән санала — шигырьләре Төркиядә төрле антологияләргә кертелгән. Ә кульязмалары — дөньяның, шул исәптән Аурупа илләренең күп китапханәләрендә кульязма килеш саклана.

1894 елда Бакчасарайның «Тәрҗеман» нәшрияты (И. Гаспралы редакциясендә) аның «Диване Гашыйк Гомәр» дип аталган тупланмасын бастырып чыгара. Безнең гасырның сиксәненче елларында исә Гашыйк Гомәр шигырьләре, ике калын том булып, хәзерге кырым-татар теленә күчермәләре белән, Ташкентта бик затлы басмада дөнья күрде. Анда — шагыйрьнең газәлләре, кошмалары, шәркылары, бәетләре, мөхәммәсләре һәм башка шигъри жанрлардагы үрнәкләре.

Бу санда олуг шагыйрьне укучыларыбызга таныту юлында беренче тәҗрибә буларак тәкъдим ителә торган шигырьләр әнә шул басмадан алынды.

* *
*

Мин, сиңа күңел биргәнгә җиһанда бер көлмәдем:
Кичтем гомерем михнәт илә, сафасын һич сөрмәдем.

Башыма күпме кайгылар килде — мин кайгырмадым,
Бер дога белмәм, гүзәл: мәүләгә сандым мин — Сине.

Син мине санламасаң да мин сине онытмадым,
Сине ташлап тиле күңел гайрегә омтылмады!

Сиңа гашыйк булып, асыл гомерем зая үтмәде,
Бер дога белмәм, гүзәл: мәүләгә сандым мин — Сине.

Йә, Илаһи, кем дә бу дәрткә, дим, дучар булмасын,
Эзләсен хәзердән соңра — дәртенә дәрман юлласын.

Әйтте Гомәр: — Гомерем соңы мәхшәргә тап булмасын! —
Бер дога белмәм, гүзәл: мәүләгә сандым мин — Сине[1].

* *
*

Кадыйр мәүләм[2], хикмәтең күп өченгә
Бер җан күрдем мәрмәр ташның эчендә:
Гомерең тәмам булып соңгы көнендә
Качырырлар кара җирнең эченә...

Мең-мең Шөкер булсын тәңрем сөбханга,
Багышладым җанны дин вә иманга.
Инде терәлгәнбез ахырзаманга:
Хәләл кая? — хәрәм керде эчеңә.

Юктан бар әйләде ул тәңре безне, —
Мөэминнәр кылсын биш вакыт намазны.
Хак алдында тәкәббер итмә йөзне, —
Иблистәй сөрерләр тәмуг эченә.

Гашыйк Гомәр моны юкка сөйләмәс,
Нәсыйхәт итәр ки, беркем тыңламас.
Дәрте күптер — һичкем дәрман әйләмәс, —
Әҗәл угы инде башы эчендә.

*Татарчага Әхмәт ГАДЕЛ күчерде.*

* * *

Гүзәл яр, сөйсәң әгәр, кил,
тап — Хиҗазда күр мине...

[1] Мәүләгә сандым — Хак тәгаләгә тиңләдем.
[2] Кадыйр мәүлә — кодрәтле Аллаһ.

Анда тапмасаң булырмын
мин — Кәгъбәдә, күр мине!

Анда да булмасам, туры
Шам-Шәриф юлына төш,
Өммия мәчете эчендә, мин —
намазда, күр мине...

Ничә ел ялвардым — шөкер,
кабул булды бу теләк:
Бер колыңа кылдың шәфкать,
әй мәләк заты мәләк!

Гашыйкны горбәттә һаман
йөртте бу язмыш-фәләк,
Исфаганда булмасам, син, кил,
Ширазда күр мине!

Тормады туктап Гомәр — ул
бар дөньяны гизәрме?
Күрмәде гомерендә синдәй
сөеклене — дилбәрне.

Бәлки туфандыр — соң язмыш,
йә урным — Сарай җире:
Карс, Тәбризләрдә... түгел,
Шәһри Назда күр мине!

* * *

Ник гүзәлгә бирдем күңел? — белмәдем:
Кичә-көндез тик егъладым, көлмәдем.
Эзләп тә — дәртемә дәва күрмәдем,
Бер дәва бир! — димен Хәким-Локманга...

Гөл-лаләләр йөземе? — миңе күптер.
Кашлары — каләмдер, керфеге — уктыр.
Һичкем белән аны тиңләмәк юктыр,
Аңа тиң — тумас, дидем, бу заманга!

Гомәр сөйләр — сүздә ялганы булмас,
Ярына кол булган — тынгылык күрмәс,
Күңел — гашыйк бер шәй, фәкыйрьмен, димәс:
Мал-мөлкәт — ни, яр өчен фида жанга?!

* * *

Әллә синең күзләр корбаны булдым? —
Йөзләреңә багып туялмадым мин.
Гыйбрәт өчен яралдыңмы җиһанга? —
Нәни миңең — аңа сыялмадым мин...

Гашыйктанмы ут-ялкын күккә ашкан?
Бәхтен бер табармы ул — хәсрәтле җан?
Кулларым һаман муйныңа чорналган,—
Сине үбәргә, аһ, кыялмадым мин.

Калды тиле күңелем янган хәлендә,
Мәүләм, ирештер моратка мине дә?!
Гашыйк Гомәр шаһит, шул сөеклемә:
— Хуш мәңгегә, гүзәл! — дия алмадым мин.

* * *

Әй, яудашлар! Гашыйк булганнан бирле
Хәсрәт-дәртләр миңа яр булып китте.
Гамь дәрьясы баштан ашканнан бирле
Вөҗүдем — бер дөя(нар) булып китте:

Кәрваным үтәлмәс илләрдә калдым,
Гариб мәҗнүн кебек, чүлләрдә калдым,
Бер гаҗәп сер тулы юлларда калдым,
Дүрт саным да — тораташ булып китте.

Хәстәдер вөҗүдем — сау хәлдә түгелдер,
Ярам — йөрәктә, ул — тәндә түгелдер,
Акыл-уем ерак — миндә түгелдер,
Сөйгәнем — аһ, ятка яр булып китте...

Әй, Гомәр, күккә ашканга моңнарым,
Зар чигеп, үксеп, үкереп егъладым.
Үпкә-гамь томаны, башымнан уралдың —
Бу дөнья — башыма тар булып китте.

*Татарчага Рәдиф ГАТАШ күчерде.*

# ТУКАЙ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘЛӘР

КИЧӘГЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕ КӨН ТУРЫНДА

**Сорау. Тукай әфәнде! Совет чорының кайбер галимнәре, үзләренчә үҗәтләнеп, Сездән «социалист» ясарга тырыштылар. Бу, чыннан да, дөреслеккә туры киләме?**

**Җавап.** Капиталистический строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үземне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм.[1]

**Сорау. Ә бит без, сәвит заманы кешеләре, 70 ел буена социализмны төзеп карадык. Булды аның уңышлары, казанышлары. Булды аның кимчелекләре, хаталары. Бүген исә социализм «шинеле»ннән үсеп чыккан байтак кына бәндәләр аны эт итеп сүгә, корымга манчый. Социализм төзү хыялы, ни генә әйтсәң дә, изге нияттән иде бит. Халык шуны, ышанып, күтәреп алды. Әмма шушы матур идеянең эчтәлеген югарыда утырган зур җитәкчеләр үзләре боздылар лабаса.**

**Җавап.** ...Социализмның уңышлы таралуы өчен үзеңнең бил багълап эшкә керешергә гайрәтең җитмәсә дә, һич булмаса, сүкмәскә вә күңелдән дошман булмаска кирәк.[2]

**Сорау. Ә шулай да социализмга мөнәсәбәтегез ничек?**

**Җавап.** Хуҗа Насретдин шикелле, атның артына карап атланмыйк. Халыкның, укый торгач, үткенләнә торгач, шул социализм фикеренә барып төшмичә хәлләре юктыр. Социализм кеби бер мөкаддәс мәзһәбкә кергәндә, матурланып, кеше булып, галим вә мәгърифәтле булып керик.

Без надан көенчә социалист булып мәйданга чыксак, койрыгына тутый кош җоннары кыстырган ала карга төсле, бөтен дөньяны көлдерербез.[3]

**Сорау. Дөньялар нык үзгәрде. Уналтынчы гасырда дәүләтчелеген югалткан татар халкы, авыр гасырларны кичеп, инде менә өр-яңадан үз дәүләтчелеген торгызу өчен көрәш башлады. 1990 елның 30 августы көнне җөмһүриятебез парламенты Татарстан Республикасының суверенитеты хакында Декларация кабул итте. Көрәш дәвам итә. Аны кайнар яклаучылар күп. Шул ук вакытта гади халыкның билгеле бер өлеше, суверенитет һәм сәясәт дигәндә, артык егылып та китми кебек. Брежнев заманында тыныч һәм рәхәтрәк яшәдек, дип кенә җибәрәләр. Миңа калса, бу — өйдәге муллык, ашау-эчү белән генә чикләнү, рухи ярлылык, ашказаны коллыгына бирелү нәтиҗәсе. Бу фикер белән килешергә мөмкинме?**

**Җавап.** Әле безнең татар кардәшләр өч яшьлек бала хөкемендә генәдер. Өч яшьлек балага да үзенең сәламәтләнүе өчен дару эчерсәң яки: тышка яланаяк, яланбаш чыкма, дисәң, билгеле, каршы торадыр.

Шуның шикелле, татарларга да: болай итсәгез, сәламәт булырсыз, тегеләй итсәгез, үзеңез өчен яхшы булыр, дисәң, «Э... э... кирәкми, э... э...» — дип киреләнәләр.[4]

**Сорау. Ә шулай да үзегез куйган соальне бүген үзегезгә бирәсе килә: безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?**

**Җавап.** Һәртөрле мөхәррирләр вә ярты мөхәррирләр, милләтемез үлгән вә яки йоклаган, дип язалар. Чынында безнең милләт үлгән үкме, әллә

йоклаган гынамы? Әгәр милләтне йоклаган дисәк, дөнья көпчәгенең бу кадәр дөбердәп әйләнүенә вә башка милләтләрнең әллә нинди каты вә йөрәк яргыч тавышлауларына уянырга кирәк иде.

Чөнки йокының, әлбәттә, бер чиге булырга кирәк. Бу турыда минем фикре касыйрем болай дип әйтә: без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, газитә битләре илә йомшак җил истерик, һәм авызына иттихад вә иттифакъ сулары салыйк; җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик...

Безнең милләт үлмәгән дә, йокламаган да, һушы гына киткән. Мәзкүр рәвешләр илә һушына китерсәк, дуст кем, дошман кем — милләт үзе аерыр.

Милләт образауный кешеләргә, һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә гажиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ.[5]

**Сорау. Тарихта күп нәрсә кабатлана, диләр. Дөрес икән. Менә «яңарып» яткан Рәсәйнең сәяси сәхнәсенә патша заманындагы Думаны өстерәп менгерделәр. Нәрсә соң ул Дума? Ул нишләргә тиеш? Бүгенге көн Думасы тегесеннән нәрсәсе белән аерыла?**

**Җавап.** Инде кара көннәр үтте, кайгы-хәсрәтләр артта калды. Дөньяда үз-үзенә зарар теләүченең булмавы табигыйдер... Бу ышанулар һәм бу өметләргә куану урынлымы? Беренчедән, бу Дума һәрбер кирәкле эшләргә катнаша алмас. Икенчедән, Дума чакырылганда да, ул бер эш турында хөкем чыгару яки бер мәсьәләне хәл итү өчен чакырылмый, тик бер төрле эшләр һәм мәсьәләләр хакында үз фикерен сөйләү өчен генә чакырыла.

Хәзер дәүләт Думасына сайлау һәм сайлану хокукына ия булган күп кенә төркемнәр бар... Дума боларның арбасына утырыр, һәм ничек булса да боларның теләкләрен булдырырга тырышыр... Думаның байлар думасы булачагын, ярлылар файдасына төзеләчәк түгел икәнен күп санлы дәлилләр белән исбат иттек.

Думаның хәзерге хәле мәче тырнагындагы тычкан хәленә бик охшашлыдыр.

Бер кеше, комган берлә салкын су алып коенганда, суны тәненә тигезмичә, читкә түккәннән соң: «Әле дә ярый тимәде» — дип куана, имеш. Думаның урта партия кешеләренең хәрәкәте дә шул кешенең коенуы кабиленнән генә булырга охшыйдыр.[6]

**Сорау. Байлар, ярлылар димәктән, безнең хәзерге җәмгыятьтә нәкъ менә шушы ике катламга бүленеш, поляризация халәте бара. Халыкны һәм хөкүмәтне талау хисабына кемнәрдер сикереп-кикереп дигәндәй байый, кемнәрдер фәкыйрьлек чоңгылына таба атлый...**

**Җавап.** Байлар, авырый башлагач та, каберен казып куялар. Фәкыйрьләрне, үлгәч тә, өч көн ишетмиләр.[7]

**Сорау. Рәсәй Думасына төрле караштагы депутатлар сайланды. Әмма дә Жириновскийның узуы хәтта дөнья матбугатын шаккаттырды. Бу сәясәтченең җиңү сәбәпләре нәрсәдә? Эзоп телендә булса да аңлатып китеп булмыймы?**

**Җавап.** Газитәләрнең язганына караганда, зур хәвеф-хәтәрләргә сабыр итүче Куропаткин государственный банктан 2.650.000 тәңкә акча алган. Тагы да акча салучының үтенүе буенча, бу акчалар Куропаткинга саф алтыннан гына бирелгән... Бу кадәр акчаны табар өчен, Куропаткин кайсы тәрегә чукынып, нинди сыерларны сауды икән?[8]

**Сорау. Җәмгыятебез ике багана арасында(социализм һәм капитализм) тетрәде, бүгенге көндә тормыш зир-зәбәр килде. Менә шулар җирлегендә гаделсезлек, явызлык өскә калкып чыкты. Адәмнәр усалланды, җаһиллектән дә, гөнаһтан да курыкмый башладылар. Дини китаплар искәрткәнчә, кыямәт көне килеп җитте кеби...**

**Җавап.** Шик-шөбһәсез — үзе! Инде эш үтте, булачаклар булды... Тиран сыйфатындагы кәһаре илә яратылмышларны асты-өстенә китерә икән. Ярабби, бу көн җәза мәйданына чыгарылган гөнаһлыларның исәбен-хисабын кем белер?

И явызлар! Монда килегез. Ничә йөз, ничә мең еллардан бирле көтелгән җәза таңы атты. Динне хурладыгыз, мөселманлыктан көлдегез! Галимнәрне танымадыгыз. Тугъры сөйләгәннәрне кыстыгыз, издегез. Алла гафилмени? Җавап бирегез! Нигә җылаган булып торасыз?..[9]

**Сорау. Безнең бүгенге көн кешеләрен ничек бәялисез? Бакыр акчаның ике ягы булган кеби, бардыр тискәреләре, бардыр әле бу тормышның өметле бәндәләре дә?..**

**Җавап.** Һич кеше һичбер кешенең ярдәм соравына колак салмыйдыр; гүя кыямәт көнендәге кеби, һәр кеше үз нәфесе белән генә мәшгульдер.

Фәкыйрьлек, мохтаҗлык бик авыр. Аны җиңеләйтүче юк... Бу күз яшьләренә, бу гөнаһсыз адәмнәрнең хурлыклы хәлләренең барчасына шул социаль төркемнәрнең тырышмавы, кайгыртмавы һәм кешелексезлеге сәбәптер.

Тота белүчеләр булса, милләтнең акчасы мәктәп вә мәдрәсәләргә дә, шәкертләргә дә, газитләргә дә — һәммәсенә җитәчәктер.

Милләт акчасының ханәкаһ конюшнәсендәге ялкау сыерларының авызына гына агып торуы дәвам итсә, без бетәчәкбез...[10]

**Сорау. Сәвит заманында бер генә партия бар иде, ул да булса «җиңүчән, оештыручан» КПСС. Инде менә хәятыбыз бакчасына үзгәрешләр җиле бәреп керде. Сәяси мәйданда әллә ничаклы яңа, яшь фиркаләр барлыкка килде. Әйтегезче, ни-нәрсә соң бу партияләр?**

**Җавап.** Миллият сакларга уңнарыбыз, хөррият сакларга сулларыбыз да булсын.

Кара кош та оча. Карга да оча. Чыпчык та оча. Черкидә дә канат бар, ул да оча. (Ләкин очу белән очу арасында аерма бар.) Арысланның гайрәте, төлкенең хәйләкәрлеге, куянның куркаклыгы, дуңгызның нәҗеслеге бар. Һичберенә дә ачуланып булмый. Алла шулай яраткан.[11]

**Сорау. Яңа — 1994 елга аяк баскан көннәр уңаеннан Рәсәйдә ун көн чамасы эшләмәделәр. Рәсми төстә бәйрәм игълан ителгән иде. Әйе, халык рәхәтләнеп ял итте, типтерде, әмма шушы вакытларда завод-фабрикалар тик торды, промышленность тармакларына ифрат зур зыян салынды. Моны ни белән аңлатырга?**

**Җавап.** Безнең милләтнең бәйрәме ел тәүлегенә анчак ике тапкыр гына буладыр.

Димәк, без бик эшчән, тырышчан бер халык икәнбез. Чөнки ел буе дөньяның һәртөрле авырлыкларын, михнәтләрен күтәрәбез дә, шул авырлыкларны өстебездән ике тапкыр гына төшереп, тынычлап торабыз.

Безнең ватандашларыбыз русларның атлаган саен бәйрәмнәре була. Алар, якшәмбене чынлап бәйрәм иткәннәре кеби, әллә нинди исемнәр илә әллә нинди бәйрәмнәр итәләр. Хәтта бер юморист: «Ел тәүлегендә 365 көн була, руслар 300 көн бәйрәм итәләр, 65 көн эшлиләр»,— дисә, бу сүз бөтенләй үк көлкегә охшап бетмәячәктер.

Моннан русларның ялкау, эшсез вә бөтен гомерләрен уйнап-көлеп үткәрүче бер халык икәнлеге, безнең исә кәеф, хозур вә ял итүләргә әһәмият бирми торган булуыбыз күренәдер. Соң, без күп эшләгәч, алар күп кәеф сөргәч, безнең алга баруыбыз, аларның артка калулары тиеш ләбаса!

Хакыйкатьтә нидәндер болай түгел: без һаман артта, һаман фәкыйрь, һаман түбәнбез. Без һаман шул инә берлә кое казыйбыз, руслар — машина берлә... Алар мәгыйшәт сәфәрендә бергәләшеп бер йөк тартып алып бармакчы булсалар, без, йөкне төрлебез төрле якка тартып, һаман бер урында әйләнәбез...[12]

**«Әңгәмәдәш» — Рашат НИЗАМИЕВ**

ИСКӘРМӘЛӘР:

[1]Габдулла Тукай. Әсәрләр, 5 томда. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1986. 3 том, 249 бит.

[2]Шунда ук. 249 бит; [3]Шунда ук. 271—272 битләр; [4]Шунда ук. 227—228 битләр; [5]Шунда ук. 40, 41, 42 һәм 186 битләр; [6]Шунда ук. 35—38 битләр; [7]Шунда ук. 61 бит; [8]Шунда ук. 162 бит; [9]Шунда ук. 9 бит; [10]Шунда ук. 264—268 битләр; [11]4 том. 46 бит; [12]Шунда ук. 57—58 битләр.

# КЫРЫМ АКСАКАЛЫ

Үз гомерендә сигез йөзгә якын көй язган Иоһанн Штраусны вальслар короле дип йөрткәннәр. Шуның кебек, замандашыбыз Рәүф Кәрим улы Акчуринны да мин йөзем үстерү даһие дип атар идем. Галимнәр арасында аңа Роман Кириллович дип эндәшәләр. Кояшлы Кырымда йөзем үстерү сәнгатен ул кырык ел буе үзләштерә. Ялтаның йөзем үстерү белгечләре әзерли торган институтында да армый-талмый эшли.

Урта Азия кояшы астында яшәгән чагында ук, дөньяны танып белергә ашкынган Рәүф дигән егет борынгы Элладаның архитектура һәм фрескаларында чагылыш тапкан йөзем тәлгәшләренә гашыйк була һәм үзенең гомерен табигатьнең шушы могҗизасын үстерүгә багышлый. Шулай итеп, Рәүф Акчурин Одессага килә, авыл хуҗалыгы институтының йөзем үстерү һәм шәраб ясау факультетына укырга керә. Бу студентның җете акылын, белемгә максатлы омтылышын һәм үҗәт тырышлыгын исәпкә алып, фәнни совет аңа аспирантурага калырга тәкъдим итә.

1956 елда Рәүф Акчурин йөзем үстерү һәм шәраб ясау буенча диссертация яклый. Моннан соң инде ул Кырымның нәкъ йөрәгендә урнашкан «Магарач» та (институтның фәнни-тәҗрибә участогында) эшли башлый. Кырымның дала өлешендә йөзем үстерү, яңа сортлар уйлап чыгару өчен яшь галим каршында чикләнмәгән мөмкинлекләр ачыла. Җитмәсә, бу чорда «Кырымны йөземле гөлбакчага әйләндерик!» дигән чакыру да ташланган була.

Рәүф Акчурин табигатьнең олуг серенә төшенү, йөзем тәлгәшләренең ни рәвешле хуш исле, терек суты белән мөлдерәп тулуына үз тәҗрибәсе аша төшенү максатын куя. Ул күпме йокысыз төннәр үткәрә, күпме иртәтаңнарны каршылый, йөзем куакларының һәр сулышын, һәр үсентесен йөрәге белән тоярга күнегә: күп төрле тәҗрибәләр ясый, ялгыша, чагыштыра һәм көннән-көн чыныга бара. Галим өчен йөзем кырлары үзе бер поэмага әйләнә. Ул йөзем яфракларына, хәтта нәни генә бөре, мыекчасына карап та теге яки бу куакның сәламәтлеген,ниндирәк уңыш бирәсен, әгәр шулай әйтергә яраса, куакның «эчке рухын» тоя белә. Нәзберек куакларга артык эсселек тә, иртә салкыннар да, вакытсыз яңгырлар да ярамый икән. Яңадан-яңа сортлар булдырып, табигатьнең төрле сынауларына каршы көрәш ысулларын эшләп, Рәүф Акчурин фәнне гамәли тәҗрибә белән бәйләп, отыры баетып чыныга бара. Аның турында мактап газеталарга язалар, эш тәҗрибәсе белән уртаклашырга килүчеләр көннән-көн күбәя бара. Акчурин өйрәтү дәресләрен кырда, йөзем куаклары арасында үткәрә. Күренекле остаз буларак, ул сүзен борынгы кытай мәкаленнән башлый: «Бер көнгә бәхетле булыйм дисәң, бер тустаган йөзем шәрабе эч, гомерлек бәхетле булыйм дисәң, йөзем куагы утырт».

Рәүф Акчуринны башта өлкән фәнни сотрудник итеп куялар. Аннары ул институтның фәнни-техник бүлеген җитәкли.

Йөземне эшкәртү монда 160 ел элек юлга салынган. Ерак та түгел кырым татарлары «Магарач» дип атаган чишмә бар. Шуның янәшәсендә — институтның эксперименталь шәраб заводы. Монда галимнәр тарафыннан шәрабның егерме дүрт төре эшләнеп дөньяга чыгарылган.

Затлы кеше үз гомерендә саваплы өч нәрсә эшли ала: бакча үстерә, китап яза, җәмгыятькә сәламәт балалар бүләк итә, диләр. Шушы нисбәттән чыгып караганда, Рәүф Кәрим улы Акчурин — мәртәбәле шәхесләрнең берсе. Ул ташлы тау итәгендә менә дигән бакча үстергән. Диңгез дулкыны шауларын тыңлап, ягымлы

кояш нурларына иркәләнеп монда персиклар өлгерә, груша, алмалар кызара, инжир, хөрмә, миндаль, лива кебек жимешләр хозурлансын өчен әкияти роза гөлләре елмаеп утыра.

Менә Шәрекътан килгән «Кара гүзәл» йөземе. Бу үсентене Рәүф әфәндегә Ташкенттан дуслары җибәргән. Башта кунак-үсенте, Кырым туфрагын үз итә алмыйча, үзен «холыксызрак» тота, хәзер инде күнегеп киткән. Шәрекътан алып килгән тәмен җуймыйча, «Кара гүзәл» борынгы Тавриданың кояш-җил-суын үз итеп, хуш-ис бөркеп утыра. Әнә — субтропик кинлекләрдә генә үсә торган гаҗәеп фейхоа. Бакчада тагын әллә ниләр, күз камаша, акыл адаша.

Мин йөзем белгечләре өчен бәһасез китапны карыйм: («Энциклопедия виноградарства», Кишинев. (1986—1987 еллар.)) беренче томына йөзем үстерү хакында 2200 мәкалә кергән. Шактые — Рәүф Акчуринныкы. Аның ике йөздән артык фәнни мәкаләләре илнең төрле шәһәрләрендә басылган. Ә инде төп хезмәте, горурлыгы — булачак агроном-бакчачылар хәзерли торган югары уку йортлары өчен дәреслек («Виноградарство». Москва. 1976.) Бу хезмәткә ул бөтен тәҗрибәсен, белемен салган. Җәмгысе Акчурин җиде китап чыгарган. Алар арасында мондый исемдәгеләре дә бар: «Кояшлы җимеш серләре», «Үзбәкстанның йөземе һәм шәраблары», «Кырым шәраблары» һ. б.

Бакча үстергән кеше балалар да үстерергә тиеш, дигән идек. Рәүф Акчуринның улы (әтисе юлына хыянәт итмәгән). Севастополь шәраб заводында баш инженер, кызы ихтиолог.

... Менә мин Рәүф Кәрим улы Акчурин тырышлыгы белән оештырылган «Магарач» институты карамагындагы музейны карап йөрим. Монда күп экспонатлар йөзем һәм шәраб белән бәйләнгән: затлы шәраб төрләре дисеңме, һәртөрле диплом һәм медальләр дисеңме, атаклы галимнәрнең рәсемнәре, нәгышлы, сәнгать әсәрләре дисеңме — һәммәсе кояшлы Кырым йөрәгендә туган табигать могҗизасын чагылдыра. Истәлек дәфтәрендә бу музейга караган атаклы шәхесләрнең рәхмәтле язмалары. Рәүф әфәнде кайбер экспонатларны аеруча горурланып күрсәтә. «Менә, шәраб ясау прессы. Моңа 200 ел инде... менә скиф балбалы. Моңа 3500 ел. Бу ятимне без институтның сараеннан табып алдык...»

Әйе, музей кеше һәм заман хәтерен бер учка җыеп, киләчәккә түкми-чәчми илтүче кадерле храм шул. Ә хәтер дигәнең гел кояшлы гына булмый. Рәүф әфәнде әле кайчан гына булып узган саташулы вакыйгаларны искә төшереп уза. 1985 елда мәгълүм указлар шаукымы, кара өермә булып, йөзем бакчаларын туздырып уза. Күз карасы кебек саклап үстергән 300 мең гектар йөзем бакчалары хәрабә хәленә китерелә! Шулай итеп, кайчандыр Парижларда гран-при алган, корольләр аяк өсте торып эчкән затлы шәраблар бетәргә мәхкүм ителә. Бу вәхшилеккә җавап итеп, «Магарач» институтының профессоры Голодрига Павел Яковлевич 1986 елда үз-үзен үтерә.

Бу указ шәраб ясау өлкәсендәге атаклы галимнәр Л. Голицын, М. Ховренко, М. Щербаков, В. Таиров, А. Егоров, М. Герасимов, А. Фролов-Багреевларның бәһасез хезмәтләренә төкерү, аяк астына салып таптау иде.

Рәүф әфәнде, бик еракта яшәсә дә, татар дөньясы белән аралашып яши. Моны өендәге музей кебек китапханәне күргәч тә аңлыйсың. Анда Тукай, Такташ, Дәрдемәнд, Туфан, Җәлил китаплары тезелеп тора. Замандашлардан Сәйфи Кудаш, Сибгат Хәким, Мостай Кәрим, Равил Фәйзуллин китаплары да бар. Һәрберсе шәхесне олылап, җылы сүзләр язып Акчурин әфәндегә үз кулы белән бүләк иткән.

Акчуриннар... Акчурин әфәнделәр өч гасыр дәвамында Россиягә тугры хезмәт иткәннәр. Алар нәселеннән чыккан күренекле дәүләт эшлеклеләрен, дипломат, фабрикант, сәүдәгәр, хәрби түрәләрне Рәүф Кәрим улы җиде буынга кадәр санап бирә ала.

Китаплар... Китапханә байлыгы хуҗаның рухи дөньясы нинди булуы хакында сөйли. Менә мин автографлы китапларны берәм-берәм кулыма алам. В. Солоухин, З. Нури, Б. Ахмадуллина, Ә. Еники, А. Вознесенский, Н. Фәттах һәм башкалар.

Менә «Таулы Кырым манзарасы» дигән картина. Моны Ринат Ибраһимов майлы буяу белән үзе ясап Акчурин әфәндегә бүләк итеп калдырган. Әнә «Биюче шүрәле» дип аталган барельеф. Бу әсәрне артист Ревдар Садыйков бүләк иткән. Ә күпме монда эреле-ваклы картиналар, гүзәл сәнгать әсәрләре. Үзе бер «Кече Третьяковка»...

Мин кулыма «Гиннес рекордлары китабы»н алам. Бу каян эләккән тагын?

— Мин бу җыентыктагы «Биш йөз яңа совет рекорды» бүлеген язган авторларның берсе. Мәскәүдән «Прогресс» нәшриятыннан җибәрделәр, — ди Рәүф әфәнде.

Аңа бик күп милләт вәкилләре үз китапларын бүләк иткәннәр. Йөзем үстерү аксакалын, Кырымның могтәбәр шәхесен бик күпләр беләләр, хөрмәт итәләр, олылыйлар диган сүз бу...

Рәүф Акчурин шәраб ясау һәм йөзем үстерү буенча хезмәт керткән бик күп галимнәр, академиклар белән дә таныш. Танышкынамы, күбесе белән якыннан аралашып, тәҗрибә уртаклашып, хезмәттәшлек иткән. Андый галимнәрдән ул Т. Катарьян, П. Благонравов, Н. Хилькевич, П. Балгарев, Н. Саенко, Х. Йосыпов, В. Малтабар, Л. Гельгар исемнәрен атый.

Рәүф әфәнде чын мәгънәсендә шәраб белгече. Аңа син күбекләнеп торган мөлдерәмә шәраблы касә бир, ул сиңа бу эчемлекнең нинди төр йөземнән эшләнгәнен, ул йөземнең нинди туфракта, нинди тау битендә яисә кайсы үзәнлектә үскәнен һич ялгышусыз әйтеп бирер. Әйе, әгәр без шампан, «Кагор», «Мускат», коньяк, «Магарач», «Мадера», «Херес», «Кара табиб», «Күктүбә», «Токай» шәрабларын эчеп, оҗмах рәшәсендә күңелне тибрәтеп алабыз икән, боларның шифалы тәме өчен атаклы галимнәр белән безгә, милләттәшебез Рәүф Кәрим улы Акчуринга да зур рәхмәт әйтергә тиешбез. Бүгенге көндә Кырым далаларында зәбәрҗәт төсендәге бакчалар җәйрәп ята икән, дөньяви бәйгеләрдә бу институт үзенең данлыклы коньяк һәм шәраблары өчен йөзләрчә медальләр белән бүләкләнгән икән, монда инде сәләтле татар галиме Рәүф Кәрим улы Акчуринның да олы хезмәте кергән дигән сүз.

**Фоат МОРТАЗИН**
Ялта

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XII СЪЕЗДЫ АЛДЫННАН

Инде хәбәр итkәнебезчә, быелның июнь башында Татарстан язучыларының чираттагы XII съезды җыелырга тиеш. Шул уңайдан редакция язучыларга берничә сорау белән мөрәҗәгать итте:

***1. Язучыларыбызның XI съезддан соң үткән биш елдагы иҗатына һәм аерым әсәрләргә карата Сез нинди фикердә?***

***2. Әдәби процессны оештыру ягыннан бу елларда Татарстан Язучылар берлеге һәм әдәби басмалар башкарган эшләрдән Сез канәгатьме? Сезнеңчә, XI съезд карарлары ни дәрәҗәдә үтәлде?***

***3. Әдәби фондның алдагы эшчәнлеге нинди булырга тиеш?***

***4. Алда торган съезддан Сез нәрсәләр көтәсез?***

***5. Иҗат берлегебез татар әдәбиятын тагын да үстерү өчен нинди мөһим чаралар үткәрергә тиеш дип саныйсыз?***

Түбәндә редакциягә килгән җавапларны урнаштырабыз.

## Ибраһим Нуруллин:

**1.** Бөтен бер язучылар коллективының биш еллык иҗатына аерым әсәрләргә туктала-туктала характеристика бирү гаять кыен. Хәтта мөмкин түгел. Мин тик соңгы биш-ун елда үзен сиздергән бер тенденция турында гына сүз әйтә алам. Ул да булса ерак һәм якын тарихыбызга игътибарның артуы. Мин биредә тарихи һәм автобиографик прозаны күздә тотам. Менә Ф. Латыйфиның «Хыянәт» романы, менә Р. Батулланың «Сөембикә»се... Менә Р. Төхфәтуллинның «Җиләкле аланнар» повесте, менә Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романы һәм А. Гыйләҗевның «Йәгез, бер дога» роман-истәлеге. Әдәбиятыбызның диапазоны киңәю һәм жанр байлыгының артуы күңелле нәрсә, әлбәттә. Тик менә тарихи жанр уңае белән бер искәрмә ясамый кала алмыйм. Безнең бүгенге тарихи романчылар (аеруча ерак тарихка багышланган әсәрләрдә), үткәндәге вакыйгаларның иҗтимагый-икътисадый нигез сәбәпләрен ачып тасвирлаудан бигрәк, шаклар катарлык мажаралар уйлап чыгару белән мавыгалар. Бу безнең беренче тарихи романнарыбызның мажаралы романга тартымрак булып чыкканлыгыннан килә микән, башка берәр сәбәбе бармы, кистереп әйтә алмыйм. Борынгы болгарларның гореф-гадәтләрен һәм дини ышануларын иҗтимагый-тарихи сәбәпләр белән бәйле рәвештә бик тә дөрес тасвирланган «Ител суы ака торур» романында хәтта Нурихан Фәттах та мажара белән мавыгудан азат түгел иде. Беренче коймак төерле була, дигәндәй, баштагы әсәрләрдә мажарага табарак авышу гафу ителсә дә, тора-бара социаль-икътисадый закончалыкларны чагылдыра торган чын тарихи романга таба адым ясау тиеш иде. Моның белән мин тарихи әсәрләрне тарихи материализм кушканча гына язарга кирәк дип әйтергә теләмим. «Дөнья һәм сугыш» (бу әсәрнең элекке тәрҗемәсе «Сугыш һәм тынычлык» иде) авторы Л. Толстой принципларыннан гына гыйбрәт алып эш итсәк тә, алга китеш булыр иде. Толстой бит тарихи вакыйгаларны аерым шәхесләрнең теләк-омтылышларыннан бигрәк, зур иҗтимагый сәбәпләрдән чыккан итеп яза. Ф. Әмирханның «Мондый олуг темалар (ачлык темасы.— И. Н.) социальный характерда язылырга тиештер» (Әсәрләр, 4-том, 85 бит) дигән сүзләрен дә һәм аның бу сүзләрне язганда марксизмнан ерак торганын да онытмыйк.

Кыскасы, хыял көчен маҗаралар уйлап чыгаруга жигү белән генә чикләнмичә, тарихчы галимнәр кебек архивларда куна-төнә ятып, тормышның үзендә барган закончалыклы тарихи вакыйгаларның серенә төшенергә тырышып язсагыз иде, каләмдәш дуслар.

**2.** Адәм баласы беркайчан да, бөтен нәрсәдән дә тулысынча канәгать булып җитә алмый. XI съездның карарлары үтәлдеме соң? Кул астымда ул карарлар булмагач, бу сорауга да хәйләләбрәк җавап бирергә туры килә. Якын үткәндә карарларның үтәлмәве (КПСС карарлары да шул исәптә) норма булып киткән иде. Әнә шуңа күрә, үткән съезд карарларының аз гына өлеше үтәлгән булса да, хәзерге идарә шактый эш башкарган дип әйтергә туры килә.

**3.** Яхшы булырга тиеш, билгеле. Конкрет бер теләгем дә бар. Татарстан җирендә язучылар өчен иҗат йорты булдыру турындагы күптәнге идеяне, ниһаять, тормышка ашырасы иде. Безнең Татарстан табигатен җир җәннәте дип атасаң да, хата булмас. Бу җирдә калкып чыккан иҗат йортына, путевка бәясенә карамыйча, БДБның барлык илләреннән язучылар теләп килерләр, чыгымнар капланыр һәм хәтта табыш та килер иде.

**4.** Бик күп каләмдәшләрем кебек үк, ике съездыбыз арасындагы әдәбиятны һәм берлек идарәсенең эшен объектив анализлап, гадел бәя бирүен, яңа идарә сайлаганда, намуслы, гадел һәм принципиаль язучыларны сайлавын көтәм.

**5.** Барыннан да элек, Татарстан республикасы Язучылары берлеге республикабыздагы барлык татар мәктәпләрен шефка алырга тиеш дип уйлыйм. Чөнки әдәбиятыбызны үстерәчәк талантлы балалар кулларына каләм алып яза башласыннар өчен аларга әдәби мөхит, әдәби атмосфера кирәк. Мәктәптә әдәбият укытуның куелышыннан кала, тере язучының килеп чыккалавы әнә шундый атмосфера урнаштыруда хәлиткеч роль уйнаячак.

Онытыла төшкән тагын бер эшне җанландырырга кирәк дип беләм. Ул да булса яшь язучылар өчен танылган, тәҗрибәле язучылар җитәкчелегендә семинарлар үткәрү.

## Гурий Тавлин:

**1.** Үткән биш ел, барыннан да бигрәк, заманында большевиклар урынсызга каһәрләп яла яккан, гомеренең яртысын туган Ватаныннан, төп укучыларыннан аерылып, мөһаҗирлектә үткәрергә мәҗбүр булган бөек әдибебез Гаяз Исхакый иҗатының халкыбызга кире кайтарылуы белән билгеләнде, дияр идем. Соңгы биш елда әдәбиятыбыз сизелерлек үсте, укучыларыбыз күләмнәре белән генә түгел, эчтәлекләре, үзенчәлекләре, тирәнлекләре белән дә игътибарга лаек күп кенә әсәрләр алдылар. Шундыйларга мин Әхәт Гаффарның «Олы юлның тузаны», Аяз Гыйләҗевның «Йөгез, бер дога!», Ринат Мөхәммәдиевнең «Кенәри — читлек кошы», Миргазиян Юнысның «Европа ат сагына», Фоат Садриевның «Таң җиле», Тәүфикъ Әйдинең «Елан угы», Рабит Батулланың «Сөембикә кыйссасы», Нурихан Фәттахның «Кичү», Җәмит Рәхимовның «Батырша», Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Илчегә үлем юк» исемле әсәрләрен кертер идем. Ул әсәрләрнең күбесе «социалистик реализм» дигән сәяси өрәктән мөмкин кадәр читләшергә тырышып язылганнар.

Тагын шунысы куанычлы, әдипләребез милли тарихыбызны яктыртуда «өлкән туганыбыз» йогынтысыннан күпмедер дәрәҗәдә котылырга тырышып тәүге адымнарын ясадылар. Әмма прозаикларыбыз бүгенге тормышны, бүгенге геройларны сурәтләүдә (алар исәбенә Ф. Садриев керми) бер урында таптанудан узмадылар.

**2.** Бу сорауга җавап бирергә кыенсынам.

**3.** Әдәби фонд — язучыларның арка терәге. Әмма бездә аның исеменә карaганда җисеме ныграк сизелсен иде.

**4.** Алда торган съезд әшнәлеккә, күптән мәгълүм элитар төркемнең хакимлек итүенә чик куярга тиеш.

**5.** Бүгенге болгавыр чорда бу сорауга да җавап табарга авырсынам.

**Ләбибә Ихсанова:**

**1.** Халык телендә «тирән сулар тын агалар» дигән гыйбарә бар. Әдәбиятыбыз да шуның ише. Бер караганда, Язучылар берлеге тирәсендә шау-шулы вакыйгалар да, зур җыелышлар да булмады. Иҗат секцияләре дә тынып калды. Ләкин әдәби тормыш, төптәге агым кебек, барыбер үз юлыннан барды. Язгы ташкын кебек шаулап килмәсә дә, яңа әсәрләр туды. Халкыбызның борынгы тарихын ачкан кызыклы романнарны, зур әдәби сөйләшүләргә нигез булган бүгенге көн әсәрләрен укыдык. Драматурглар замандашыбызның рухи дөньясына алып керде. Әдәбиятка килгән яңа исемнәр үзләрен танытып өлгерде. Купьеллык тарихлы олы әдәбият шулай булырга тиештер инде ул. Ашыкмый, кабаланмый үз эшен белеп эшләр. Чын язучыны мин теләсә нинди җимгә ташланырга әзер торган вак балык дип түгел, үз кирәген көтеп алучы төптәге җәен итеп күрәм. Бу елларда җимнәргә кытлык юк анысы, чыны да, ялганы да тулып ята. Шунысы куанычлы, көн кадагына сугыйм, кеше әйткәнче әйтеп калыйм дип, ашык-пошык язылган әсәрләр юк дәрәҗәсендә аз күренде.

**2.** Төшкә дә кермәгән гыйбрәтле чорда яшибез. Вакыйгалар гына түгел, кешеләрнең рухи кыйбласы да үзгәреп бетте. Әле кичә генә коммунистик идеалларга ант иткәннәр, шуның аркасында тормышларын бик җайлы итеп алып барган кешеләр, барыннан да уздырып, мәтәлә-кадала капитал дөньясына чаптылар. Әле кичә генә динне сүгеп аңа ышанучыларны кыерсытып көн күргәннәр чиркәүләрдә шәм куя, маңгайлары күбеп чыкканчы чукына башлады. Кирәксә дә, кирәкмәсә дә алла исеме белән сату итүчеләр күбәйде. Маңгай тирен чыгарып эшләгәннән соң ял итүнең рәхәтен татымый башладылар. Балалар мәктәптән бизде генә түгел, аларны укытырга, белем бирергә теләүчеләр мәктәптә үзләре дә бетеп бара инде. Тоташ эчкечелек, фәхишлек... Дөньяның астын өскә китергән сәбәпләрне санап кына бетерерлекме соң? Күзәтергә, уйланырга, анализ ясарга һәм күрсәтеп бирергә вакыт бик җитте. Язучыларның төп эше алдагы съездтан соң менә шул булырга тиеш. Ә моның өчен кечкенә жанрлардан бигрәк, күп планлы эпик әсәрләр кирәк булачак. Бу елларда күп кенә язучылар республикабызның политик тормышында актив катнаштылар, каләмнәрен дә онытып бетермәгәннәрдер әле алар.

**3—4.** Элекке елларда рус әдәбиятына чыгу, аның аша башка телләргә тәрҗемә ителү максат итеп куелды. Язучының иҗатына бәя биргәндә шул югарылыктан карадык. Ләкин, шул ук вакытта башка милләт укучылары урта кул язучыларның начар тәрҗемәләрен дә алгалады һәм, шуңар карап, әдәбиятыбыз турында тулаем фикер йөртте. Инде республикабыз бәйсезлек алганнан соң әдәби багланышларга мөмкинлекләр күбәйде. Чит илләр белән турыдан-туры элемтәгә керү юллары да ачылды. Шул мөмкинлектән акыл белән файдаланасы, әдәбиятыбызның алтын фондына керерлек әсәрләрне генә дөнья күләменә чыгарасы иде.

Элекке СССР территориясендәге җиде миллионга якын үз халкыбызны да онытырга ярамый. Ләкин олы бер бәла бар: базар икътисадына күчкәннән бирле китап басып чыгару һәм аны тарату ерып чыга алмаслык кыенлыкларга очрады. Ә бу проблеманы бары тик дәүләт күләмендә генә хәл итеп була. Ничек тә юлын табасы иде шуның.

**5.** Әдәбиятның алга таба үсешенә язучыларның очрашып, киңәшеп, бәхәсләшеп яшәүләре дә кирәк. Элекке рус язучылары юкка гына Телешев кичәләренә, Никитиннарның әдәби чәршәмбеләренә һәм башка салоннарга җыелмаганнардыр. Бездә әдәби секцияләр эшли иде, яхшымы-яманмы, партия өлкә комитеты оештырган «укулар»да очраша идек, айга бер булса да җыелышлар үтеп торды. Хәзер тәмам аерылып беттек. Ә очрашасы, сөйләшәсе килә. Капиталистик дөнья булгач булсын, әллә алардагы шикелле, аерым сайланган кешеләр өчен «клублар» ачып җибәрәбезме соң? Әйтик, «Язучы клубы». Бер-берсенә ышанган, бер-берсен хөрмәт итә торган язучылар гына керер анда. Ә бәлки ул беркадәр акчалы да булыр. Әмма андый утырышларда чын әдәби сөйләшү булыр иде кебек.

Әдәбият дөньясына кагылмаса да тагын бер теләгемне әйтми кала алмыйм. Элек безнең җөмһүриятебездә «Республиканың Хезмәт Батыры» дигән исем булган. Язучылардан Галимҗан Ибраһимов та шул мактаулы исемне йөрткән. Безнең хәзер үз гимныбыз, үз байрагыбыз, үз туграбыз бар. Шулар янына «Татарстанның Хезмәт Батыры» дигән исемне дә алсак, бәйсезлегебезнең тагын бер билгесе булыр иде. Ә республикада аңар лаек булырлык кешеләр җитәрлек дип уйлыйм. Алдагы съезд уңае белән, бәлки, ул мәсьәләне дә хөкүмәтебез алдында күтәрергә ярыйдыр.

## АЛДАГЫ САННАРДА УКЫГЫЗ!

# «МӘГЫЙШӘТ»

(МИЛЛИ ХИКӘЯ)

«Рәбиганы көчләп киендереп, кияү керәсе бүлмәгә яптылар...

Менә бервакыт «Кияү килде!» дигән хәбәр булды... Ләкин кияү көтүчеләр чалмасыз карт көтәләр иде, килгән карт чалмалы, төсе дә Халид агайга охшамый, кем белә, бәлки кияү булгач үзгәргәндер...

Кызның ишеген ачмакчы булдылар — бикле булды. Дөбердәттеләр, файдасыз чыкты. Килгән карт кыз бүлмәсен сорамый, Хөсәен агайның үзен сорый башлады.

Ахырда беленде ки, килгән кеше кияү түгел, хәзрәт имеш. Караңгылык белән ялгышканнар, имеш. Хөсәен чыкты.

Хөсәеннең чыгуына янә бер карт чабып килеп керде, монысы инде чыннан да кияү иде. Сачен ап-ак итеп китәрткән, мыегын җеп кеби итеп ике яклап нечкәрткән, камчат бүркен кыеклап башка алган, киң җакалары чыккан, бу — Халид агай иде.

Хөсәен, хәзрәт, Халид агай ишек алдында бергә җыелдылар.

Хәзрәт Хөсәен агайга карап:

— Халидка, кияү булып кергәнче, әйтәсе сүзем бар. Безне аулак җиргә алып керсәнә! — диде.

Бүлмәгә керделәр. Ишек бикләнде.

Хәзрәт:

— Халид, Хөсәен, син дә тыңлап тор, мин сезгә бер нәрсә укыймын, — дип, кесәсеннән бер язу чыгарып, укый башлады...»

**Бу өзек мәшһүр җәмәгать эшлеклесе һәм әдип, совет чорында хезмәтләре әллә ни басылмаган Садри Максудиның «Мәгыйшәт» (тормыш) дигән әсәреннән алынды. Садри Максудиның үзе һәм әлеге әсәре турында киңрәк мәгълүматны, хөрмәтле укучыбыз, алдагы саннарның берсеннән укып белә алырсыз.**

Сәгыйт Хафизов

# ИСЛАХ, ЯКИ ЯМАНАТТАН ЯРЛЫКАУ

Күрәзәче һәм багучының гына түгел, әдипнең дә сүзе рас килергә мөмкин икән. Хакыйкатьнең күзенә туры карарга күнеккән Аяз Гыйләжев кискенлек, дорфалыкта бары Галимҗан Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» (1913) тәнкыйте белән генә тиңләшергә мөмкин булган «Имән чикләвеге» исемле мәкаләсен чыгаргач («Шәһри Казан». 28.XI.90.), драматург Туфан Миңнуллин үзенчә аһ орып язган иде: «Мәкалә авторының Хәсән Туфанның юбилее көннәрендә олы шагыйребезнең шигъри бакчасына кереп күсәк күтәреп, кизәнеп йөрүе мине куркытты. Автор үз язмасында Такташка да кизәнә. Г. Әпсәләмов һәм Г. Бәшировка да тибә. Исемнәрен әйтмичә генә бүтән язучыларга да төкерә. Куркыныч. Әгәр дә алтмыштан узган, исеме билгеле язучы... күсәк күтәреп, урам чатына чыккан икән, аңардан үрнәк алучы әдәбият әләм-әтрәкләре табылмасмы? Аңа ияреп әдәбиятыбызның үткәнен кырып ташларга тотынмаслармы?»

Әйе, Т. Миңнуллинның «Социалистик Татарстан»да чыккан (20.XII.90) «Акылыбызга килик» репликасындагы ямьсез юрау юш килде шул. Кара шик үсеп, олпатланып болгавыр заманның әрсез, ялтыравык бер хакыйкате төсен алды. Сәясәт шарлавыгына юлыгып чарасыз төпкелдә бөтерелгән икътисад, рухият дөньялары шикелле үк, әдәбият һәм иҗатчылар даирәсе дә болгана башлады: утырган зәвекълар сөрси, кануннар таркала, сәҗдә тоткан абруйлар да уңа, төссезләнеп кала. Ияләшкән әхлакый нормалар, таныш геройлар, күнегелгән хисләр, кумирлар кызганыч, әлбәттә. Ләкин яңа хәят җиле — ислах каршында аһ-ваһларың, ләгънәтләрең белән ни кырасың соң? Язмышлар бит бүген эрелеваклы фигуралар хәрәкәте, бәхетле яисә бәхетсез очраклар белән генә бәйләнмәгән. Язмышлар бу көндә тарихи логика, иҗтимагый-сәяси көчләр һәм политик шартлар кебек эре факторларга бәйле.

Иҗтимагый дөньяда тарихи мәл.

Җәмгыять юллар чатында, сайланыш алдында тора.

Социаль төркемнәр арасындагы коллизияләр базар экономикасына барып бәйләнгән. Ә язучылар ни өчен якалаша соң? Тартыш, зилзиләгә ни сәбәп?

Демократлар органы «Шәһри Казан» үтемле, гади генә язганча, сәяси момент мондый иде: «Безгә илебезне-җиребезне, әдәбиятыбызны, мәдәниятебезне, күңел түрләребезне дистәләрчә еллар буена өелеп килгән чүп-чардан, ялганнан, икейөзлелектән арындырырга кирәк».

Йөрәгендә намус, гаделлек, гаярьлек асраган һәркем — әдипләр бигрәк тә — мөгаен, килешкәндер бу чакыру белән. Тик кулына соскы, себерке алган кеше иң элек исәпли: кайда чүп, кайда асыл орлык? Һәм тәү карашка гади генә күренгән шушы мәсьәлә, каты чикләвеккә әверелеп, бездә бәхәс, тартыш кузгатты.

Моның күзгә күренгән ягы Хәсән Туфанга барып тоташты. Татар әдәби җәмәгатьчелеге Туфанны демократлар кумиры ясап, «шагыйрьләрнең шагыйре» дип зурларга күнеккән иде. Иҗатының энҗе-мәрҗән кебек балкуында да шик юк сыман иде. Әмма мәрхүмнең нәкъ 90 еллык юбилее алдыннан Аяз Гыйләжев, Туфан поэзиясен олылаучыларның бәгырен ярып, болай дип язды: «Х. Туфанның төрмәгә ябылганчы һәм аннан соңгы иҗат үрнәкләре берчакта да халкыбызның авыр язмышын ачуга хезмәт итмәделәр... Халык язмышы, аның ачы нужасы, милләтнең киләчәге кыл өстенә куелуы Туфан иҗатында урын ала алмады».

Әдәбият галиме Нил Юзиев «Социалистик Татарстан»да бастырган «Ил бәгыренең ораны булып» (16.XII.90) мәкаләсен А. Гыйләҗев белән бәхәскә багышлый. Оппонентның көтелмәгән яссылыктагы фикерләре галимнән дә яңача уйлау, көчле дәлилләр сорый иде. Әмма болар урынына Н. Юзиев рәсми татар тәнкыйтенә хас алымнар белән авторны әдәпкә чакырды, рус әдәбият белеме туплаган кануннарны һәм сәяси доктриналарны, идеалларны төп аргумент төсендә файдаланды. Килешүгә илткән ихлас бәхәс килеп чыкмады. Тик моңа карамастан, фән докторы, әдипнең сүзен аста калдырып, Туфанны «шагыйрьләрнең шагыйре» ясады. «Шәһри Казан» редакциясен һәм гәзитә укучыларны мондый нәтиҗә, әлбәттә, канәгатьләндерә алмады. Әнәс Вафин дигән автор «Кара кан» (1.II.91) дигән язмасында А. Гыйләҗевны кайнар яклап чыкты: «Язучы, шагыйрьләребез дә, шагыйрьләрнең шагыйре Хәсән ага Туфан да, никадәр генә талантлы булмасыннар, милләт өстенә ябырылган фаҗигане күңел күзләре белән күреп, бөтен йөрәкләре белән аңлый алмадылар»,— диде ул. Әлеге автор искәрткәнчә, совет әдәбияты үзенең төп, нигез принциплары белән кеше мәнфәгатен яклауга күтәрелә алмады. «Номенклатур тормыш хуҗалары» безне якты киләчәк өчен ат урынына эшләргә трибуналардан чакырса, шагыйрь шуны ук үзенең шигырьләре аркылы эшли»,— дип, безнең язучыларның тоталитар режимга хезмәт итүләрен, Солженицын, Сахаров зирәклегенә ия була алмауларын күрсәтте.

1990 елның 4 июль санындагы «Литературная газета»да Виктор Ерофеев рус совет әдәбиятына карата шундыйрак бәя биргән иде инде. Күрше милләт драматургы үзләренең Октябрьдән соңгы әдәбиятларын рәсми, сала, либераль дигән катламнарга аерды һәм һәркайсының реализмнан, чын сәнгатьтән ерак булуы, коммунистик идеологиягә манчылуы турында язды. Аныңча, рус әдәбияты бары читтә, ак эмиграциядә генә яшәде, ә үз илендә ул җан бирде, аңа тик җеназа чыгарга калды. Аның мәкаләсе шулай аталды: «Совет әдәбиятына җеназа».

Күршеләр әдәбиятына килгән матәм шомлы, тәшвишле, әмма безнең мохиттән ерак торган бер куркыныч сыман иде. Ләкин бик тиздән үзебездә дә әдәбиятыбызга җеназа укырга әзер торучылар табылды. Әйтик, гәзиттән укыйбыз: «Радиодан чыгышларның берсендә Мөхәммәт Мәһдиев тә, революциядән соң татар әдәбиятында бер генә күренекле әсәр юк, дип чыкты». Татарстан язучыларының 1991 ел йомгакларына багышланган җыелышында Рахмай Хисмәтуллин әйткән: тоталитар системада яшәгән авыру гражданнар, чирле җитәкчеләр белән бергә, «язучыларның да рухлары хаста икән». Фаяз Дунай «Шәһри Казан» гәзитенең бер санынnан икенчесенә, анnары өченчесенә сикергән «Шаукым» мәкаләсендә язучылар иҗатын тема җәһәтеннән күзәткәч, совет әдәбияты «фаҗигале әдәбият ул» дигән нәтиҗәгә килә.

«Капиталистик җәмгыять әдәбияты түгел, нәкъ менә большевиклар төзегән «совет җәмгыяте» әдәбияты мәҗбүри халәттә тормыш-чынбарлыкны чын-чынлап ялганлап сурәтли торган әдәбиятка әверелә»,— дип яза бу автор һәм «тәртәне кирегә бору» ягын каера. Ягъни, Ф. Дунай карашынча, чын, тормышчан, милли әдәбиятны бары капитализм тергезер, янәсе...

Шул ук гәзитнең янә бер санында шагыйрь Гәрәй Рәхим һәм фән докторы Флүн Мусин «Нәрсә ул милли әдәбият?» темасына гәп коралар. Берсе «безнең көннәр 1917 елдан башланган көннәрне хәтерләтә кебек» дип, социаль һәм рухи, әдәби дөньяларда тамырыннан борылышлар башлануга ишарәләсә, икенчесе инде моны иң кирәкле шарт төсендә җөпли: «Яңарышка омтылу... инкарь итүдән башка була алмый». Болар әдәбиятыбызны чүп-чардан тазартырга җыена дисеңме? Юк, Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире Ф. Мусинның исәбе эредән икән. Бу рәсми зат инкарь себеркесен әдәбият корифейлары Г. Ибраһимов, Такташ иҗатлары өстендә селкергә җыена. Чөнки, аның карашынча, бу әдипләр «большевистик идеологиягә үтә инанган һәм бирелгән».

Шулай да иң моңсу һәм трагик апофеоз Миргазиян Юныста. Аның тәнкыйть тубы да эре калибрдан һәм бик еш, рәхимсез ата: «Совет чорында әдәбиятыбыз бик каты имгәнде. Ул тулысынча диярлек кыйбласын югалтты... Татар әдәбияты үлемгә хөкем ителгән... Язучылар үзләренең иҗат итү эшләрен икенче планга күчереп, бюрократлар армиясенә кушылалар... Укучы әдипләрнең сүзенә ышанмый... китаптан бизә».

М. Юныс татар совет әдәбиятын рәхимсез сүккән мәкаләсен җир шарының бөтен почмакларына тарала торган калын журналда («Казан утлары», 1993 ел, 10 сан) бастыра. Аннары ул Финляндиянең Лахти шәһәренә сәфәр тотып, монда җыелган бөтен дөнья әдәбиятлары вәкилләре каршына басып «Үлемгә дучар әдәбият, телсез укучылар» темасына сагышлы, зарлы доклад укый. Инглизнең үз телендә: «Партия хакимияте чорында әдәбият пропаганда бүлегенең кечкенә бер

тармагы, пропаганда ялчысы булып калу белән генә чикләнде»,— кебек сүзләр тезә. Шул уңайдан абруйлы конгресска мөрәҗәгать итеп «татар халкының туган теленнән яздырылган укучылары... әдәбияты шәфкатькә, кайгыртуга, ярдәмгә мохтаж»,— дип рәхим сорый ул. Гете, Бальзак, Сервантес токымнарыннан, Рабиндранат Тагор, Гомәр Хәйям, Рудаки оныкларының оныкларыннан нәрсә өметләнгән соң Миргазиан Юныс? Бәрәңге белән чәйдә утырган татар язучыларына күпмедер тартма гуманитар ярдәм теләнүме бу? Әллә татар язучысына әсәр язарга ярдәм итегез диюеме? Бәлки мөртәт татарларны үз теленә, диненә кайтаруда булышлык алуга өметләнүдер? Хәер, ни булса да, гозер изге нияттән чыккандыр инде. Әмма миңа горур Тукай, Җәлил, Туфаннарны үстергән, «авызың тулы кан булса да, кеше алдында төкермә!» дип яшәргә гадәтләнгән татарның «Чистай хәерчесе» кыяфәтенә кереп, читләрдә зарланып йөрүе ошамады. Чөнки мескенләнү, зар, мазохизм — гарип шөгыль. Халык өчен бигрәк тә. Үз кадерен үзе белеп, үзе башкарганнан ямь-тәм табып, алга, киләчәгенә кыю, өметле караган халык кына яшәүгә сәләтле.

Шундый уйлар белән хисләнсәң, берничә буынны тойгыландырган, синең кара, тымызык тормышыңа якты нур, хыял булып кереп киләчәккә ымсындырган, өметләндергән, шулай ук, начармы-яхшымы сиңа зәвыкъ, тәрбия биреп, дөнья танытканhәм hәрчак татарлыгыңны сиздереп торган әдәбиятның яманаты күңелне борчый. Тик бу бердәнбер хисме? «Азатлык, матурлык hәм тигезлеккә омтылыш арткан саен, тирә-юньдәге пычрак, битарафлык, ялагайлык күзгә ныграк чалына. Тукай да бит үз вакытында: «Безнең милләт үләнме, әллә йоклаган гынамы?» дип сөрән салган булган. Борчылу, кимчелекләрне күрү, жан сызлау — яхшы фал. «Халык рухы сау, димәк!» — дигән фикер-караш, хушлану тойгыларын да мул бәлдерә безнең матбугат.

Билгеле, алдан баручыларга заман hәм аның киләчәге ачыграк күренәдер. Шиксез, тормыштагы кебек әдәбиятта да үзгәртәсе, яңа нигезгә куясы нәрсәләр күптер. Әмма әдәбият кадәр әдәбиятны — олы, мөкатдәс милли байлыкны — үләләй-тереләй жирләп куярга маташуның чын ирләр шөгыле булмавы маңгай бәреп исбатлауларсыз да ачык бит. Чөнки әдәбият — жан көзгесе. Начармы-яхшымы, ул — безнең, халыкның, рухыбызның гәүдәләнеше. Көзгене ватып кына кыек авыздан котылып буламыни? Иң яхшысы: башта үз-үзеңә, жаныңа туры карап, булмышыңда нәрсә яхшы, нәрсә начар — шуны ачыклау. Хакыйкатькә төшенү. Ә аннары инде төзәтенү хәстәрләрен күрергә дә буладыр.

* * *

Октябрьдән алып безнең болгавыр заманга кадәр дәвам итеп килгән милли әдәбиятыбызга карата ислахчыларның фикер-карашлары кызык, әлбәттә. Болар яңа хәят әдәбияты hәм кан-кардәшләрдә яңача менталитет формалаштыру омтылышы белән сугарылганнар. Ләкин бүгенге әдәби мохит ислахчылардан гына тормый бит! Әнә Туфаннарны яклап икенче Туфан, Юзиев тавыш бирде. Әлеге болганышларны, астан күзәтеп, көтеп килгән галимгөләмә күпме! Ниhаять, нинди генә яманат чыгарылмасын, Г. Ибраhимов, Такташ, Җәлил, С. Хәким, Ф. Хөсни кебек совет әдәбияты классикларын яратып, идея-эстетик ләззәт алып килгән меңнәрчә укучылар бар. Аларның карашын, фикерен санга сукмаскамы?! Мин, шәхсән, Мөхәммәт Мәhдиев талантын, тәнкыйть карашларын хөрмәт итәм. Ярар, аның «соңгы чор милли әдәбиятыбызда күренекле әсәр юк», дигән сүзенә ышаныйм, ди. Ләкин шул ук вакытта мин Фәиз Зөлкарнәевнең тәнкыйть хезмәтләрен дә олылыйм. Ә ул 1991 елда басылган «Чакма чакмый ут чыкмый» китабында язган: «Әдәбиятыбыз бәhа биреп бетергесез кыйммәтле энҗәлеккә ия. Бу рухи байлык моңа кадәр юл араларына сузылган хәлдә, ярым легаль бер кыяфәттә (кинаяләр, тирән мәгънәле ишарәләр сурәтендә) яшәп килде». Галим-тәнкыйтьче замана үзгәреше, хөрлектән файдаланып бу иҗатны яңача уку, бәяләү кирәклеген мәсьәлә итеп куя. Нәрсә, бу караш игътибарга лаек түгелмени, ышандырмаслыкмыни?

Димәк, ислахчыларның сүзе соңгы сүз булмый икән әле. Киресенчә, аерым фикерләрне кылычка алып, бәхәсләшер очраклар байтак анда.

Бүгенге матбугатта даими тотрыклы, зәвыклы укучының аеруча хәтерен калдыра торган сүзләр, мөгаен мондыйлардыр: «Үлемгә хөкем ителгән әдәбият...» «хаста әдәбият...» «үле әдәбият...» Бу гыйбәрәләр тынчулык тудыра, яктыга урын калдырмый, зиhенне томалый, алда бушлык хасыйл итә. Моннан рухи

күрчеккә дә бик ерак калмый сыман... Ләкин сүзнең уйлату көче үткәнгә юнәлгән. Чөнки монда әдәбиятны җан иясе, кеше заты белән тиңләү ята. Димәк, совет әдәбияты, ислахчы карашынча да: туганда ук «үле» булмаган, балалык, җитлегү, олыгаю галәмәтләре кичергән. Чынлап та, безнең әдәбиятта мондый фасыллары күзәтергә була.

Әйтик, Рәсәйдә социаль зилзиләләр купкач, яңача аваз салган милли әдәбиятның чынбарлыкка карата аскетик оптимизмы, ашкынулы көрәш хисләре, «күптән көткән бәхетле, тигез тормышка чыктык», дип раслаулары балачак беркатлылыгын хәтерләтмимени? Ә утызынчы еллар — әдәбиятның яшьлеге. Дау килеп дөнья бүлүләр, хәят, яшәешне ватып үзгәртеп корулар шаукымы, шул юлда бетмәстөкәнмәс көрәш дәрте, рухи максимализм бары яшьлектә генә булырга мөмкин. Бу дәвердә әдәбият аз уйлый, җиңел фикерли, әмма күп хәрәкәт итә. Монда социаль, сыйнфый, психологик коллизияләр төрлелеге күзгә бәрелә. Милли иҗат шәхес культы елларын да, Бөек Ватан сугышы дәверен дә яшьлек кайнарлыгы белән уздырды. Инде 50—60 нчы елларда әдәбият — җитди, булдыклы ир уртасы сыман. Төпле уйлар, аналитик акыл һәм утырган хисләр белән хезмәткә, фәнгә, төзелешкә бирелә ул, эшлекле кешеләр төркеме тудыра. Ә җитмешенче еллардан башлап, әдәбиятыбыз кисәк уйга, гамьгә бирелде. Монда хәрәкәт, коллизияләр кимеде, геройлар галереясын картлар басты. 1982 елда бастырган бер мәкаләсендә Ф. Зөлкарнәев язган: «Хәзерге әсәрләрдә үзәк урынны алып торучы карт яки карчык образлары күбәйде». Үлем-китем, моңсу хәят тәшвишләры турында күп языла башлаган икән, димәк, язучылар да, әдәбият та картайган. Бу — җәмгыятьтә идеал, социаль перспектива югалу, идея-эстетик принципларның какшавы, гомумән, тарихи дәвернең соңгы фазиска керүе турында сөйли. Сизгерләр һәлакәтне сизенгәннәр. Әнә бит, Фәрваз Миңнуллин сиксәненче еллар башындагы татар романнарын, мондагы тарлык, сыеклык, ваклыкны күзәтеп язган: «Безгә нидер булды, С. Хәким әйтмешли, без кайдадыр нәрсәнедер югалттык...»

Бер тарихи дәвер искереп, какшап, икенчесе мәйданга чыгарга әзерләнгәндә, гадәттә, әдәбиятларда яшьләр белән картлар бәрелеше күзәтелә. Әмма мәгълүм еллардагы татар милли иҗатында тегесе дә, монысы да булмады. Безнең яшь авторларда И. Тургеневның «Аталар һәм балалар» романындагы Базаров рухы, дорфа нигилизмы түгел, ә картларча курку, өметсезлек хисе өстенлек алды. Фәүзия Бәйрәмованың «Болын» (1983) повестендагы Алсу үзенең эчке дөньясын ачып болай ди: «Әле утыз яшемә дә җитмәс борын, мин инде арыган идем, минем тормышымның алдыннан түгел, артыннан сөйрәлеп барырга да көчем, теләгем юк иде... Мин уяныргa куркам! Киләчәктән куркам! Җибәрегез мине үткәннәремә».

Шагыйрьләрдәге «Янабыз!», «Упкын аста!», «Дөнья кыл өстендә» кебек чаң сугу һәм сөрән салулар яисә «чорлар белән чорлар арасында уйга талып тора кешелек» сыман минор уйланулар да иҗтимагый һәлакәтнең якын булуын искәрткәннәр. Тик яңа идеал ачыкланып, күчешнең психологиясе генә әзерләнмәгән. Чөнки кеше сәяси доктрина лабиринтларына кереп буталган. Урындагы түрәдән җәбер күрсә дә, Сталин гаделлегенә өметләнде ул. Сталин золымын күреп, тираннан гайрәте чиксә, Ленин гуманизмы һәм демократизмына өмет баглады кеше. Инде диктаторлык чалымнары тоеп, аңардан ваз кичсә дә, абстракт коммунизм идеяләренә тугрылыгын ташламады ул. Тик кыйбласын кайсы тарафка боруына карамастан, асылда совет кешесе мәкерле доктрина колы булып калды.

Нәкъ шундый психологик аныксызлык, гаҗизлек аркасында коммунистлар хакимлек иткән җәмгыять үз эчендә сыйфат үзгәрешләре әзерләп, бер дәвердән икенче дәвергә күчәрлек сәләткә ия булмады. Бала тудырырга сәләтсез хатын кебек, нәселен, дәвамын калдыра алмады ул. Күрәмсең, нигезе, яшәү принциплары белән бу сәяси система һәлакәткә дучар ителгән булган.

Ленинның большевистик цензура халыктан яшереп тоткан архивында мондый сүзләр укырга туры килде: «Без үзебезне үзебездән һәлак иттермәсәк, дошманнан җиңдермәбез». Күрәзәлек булган үзендә! Коммунистлар илен эчке һәм тышкы дошманнар өермәсе түгел, ачлык, ялангачлык, табигать һәлакәтләре дә түгел — ә кызыл комиссар Гайдар оныклары, коммун-председатель Горбачев малайлары, власть һәм байлык өчен иманын, данын саткан мутант коммунистлар җимерде. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романында ил карты Җиһанша болай ди: «Сәвит үз баласын үзе ашый башлады. Бу хәерлегә булмас». Әйе, хәерлегә булмады. Каннибализм, әзҗүҗ-мәэмүҗ сыман, интеллектуаль элитаны, матди һәм рухи байлыкларны бетереп, ахыр чиктә сәяси системаның үзен дә ботарлап йотты.

Ил һәм җәмгыять, телиме-теләмиме, әзерме-түгелме, тарихи алмашынулар кичерә. Хәзер «совет әдәбияты» дип аталган дәвер инде тәгәлләнде. Социалистик реализм методы, КПСС җитәкчелеге, сыйнфыйлык принцибы, тенденциялелек күренешләре, шулай ук герой иҗат итүнең аерым кануннары, сәяси системаның әдәбияттагы юлдашлары буларак, режим белән бергә тарихка китә. Әмма бу алмашуларны милли әдәбият өчен һәлакәт дип кабул итәргә ярамый. Зур язмышлы, сизгер инстинктлы һәм көчле иммунитетлы татар әдәбияты үз карынында яралган Дәвамга җан һәм кан биреп калдыра алды. Җитмешенче елларга чаклы ук бездә рәсми, казна әдәбияты, социалистик реализм иҗаты белән янәшә көчле, кырыс реализмлы оппозиция әдәбияты бар иде инде. Рус әдәбияты, В. Ерофеев раслаганча, эмиграциядә яшәсә, бездә аны үз янәшәбездә күп итеп, хакыйкать һәм халык мәнфәгате өчен янып-көйгән, көрәшкән Ә. Еники, Х. Туфан, З. Мансур, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Х. Сарьян, Ш. Хөсәенев, Ә. Баянов, Т. Миңнуллин, Зөлфәт, З. Насыйбуллин, М. Әгъләмов иҗатлары тәшкил итте. Хәзер аны яңа сыйфатлар, бигрәк тә милли мәнфәгатьләр, татар рухы белән сугарып Н. Гыйматдинова, Батулла, Ә. Гаффар, В. Имамов, Ф. Бәйрәмова, З. Хәким, Җ. Рәхимов, А. Хәлим сыман яшьрәк авторлар дәвам итә.

Иншалла, иҗатка милли идеаллар белән рухланган тагын яңа яшь төркем килер. Татар әдәбияты яши бит!

Менә бәхәс нинди рәвеш алды. Берәүләр, ярсып-кызып әдәбиятыбызны «хаста, үле» дисә, икенче караш моның киресен расламакчы була. Фикер аерымлыклары кайдан, нинди нигездән килеп чыга соң?

Ислах тарафдарлары совет әдәбиятын башы-аягы белән яисә бөтен гомергә конформистик, ягъни стандарт, норматив, татарча әйтсәк, калыплашкан иҗат булды, дип саныйлар... Татар язучыларын конформист, дип атау М. Юныста да бар.

Сүз юк, андый авторлар конкрет бер әдәби дәверне алып, шундагы язучыларның иҗатларындагы аерым гөнаһларны ачсалар, конформизм барлыгына шик булмас иде. Ләкин бит ислахчылар бу сүз астында дистәләрчә елларга сузылган әдәбиятны күздә тотып, аны бер формада катып калган, эчтәлегендә идеологик стереотиплашкан, искергән һәм тәэсирлеген, иҗадилыгын югалткан, гомумән новаторлык дигән нәрсәдән мәхрүм иҗат дип аңлыйлар.

Алар ленинизм, хрущевизм, брежневизм сүз-төшенчәләрен кулланып, боларны сталинизмның сыңарлары итеп саный. Бу «изм»нарның барысын иш янында куш итеп санау дөрестер бәлки, әмма әдәби дәверләрне бер чыбыктан сөрелгән дип исәпләү, иҗатны башта конформистик, ә аннары «үле» итү белән генә килешүе кыен. Әдәбият сәясәт түгел бит. Бердән, ул иҗтимагый аңның, сәнгатьнең үзаллы өлкәсе буларак, мөстәкыйльлеккә ия. Икенчедән, Г. Ибраһимов белән Г. Кутуй яисә Х. Туфан белән С. Хәким стильләренә бер үлчәм ярамаган шикелле, утызынчы һәм алтмышынчы еллар әдәби иҗатын да бер калыпка салып булмый. Кешегә булган карашларында һәм аңа мөнәсәбәтләрендә язучыларның дә, чорның да һәркайсында гаҗәп зур үзенчәлекләр бар.

Әдәби иҗатны туктаусыз процесс итеп карый алган кеше М. Юнысның татар совет әдәбиятын «пропаганда бүлегенең кечкенә бер тармагы, пропаганда ялчысы» дип тамгалавы белән дә, мөгаен, килешмәс.

Минемчә, мәгълүм язучыбыз бу сүзләрне әйткәндә Сталин заманы идеологиясен, әдәби принципларын күздә тота. Чөнки татар әдәбиятының аеруча имгәтелгән, рәсми идеологиягә, вульгар социологизм тозагына төшкән чагы сталинизм дәверенә туры килде. Ә революция, гражданнар сугышы вакытын, яисә Еники заманындагы алтмышынчы-җитмешенче еллар әдәбиятын КПСС рупоры дип атау һич гадел түгелдер. Бу безнең бик күп каләм осталарын рәнҗеткән бәя булыр иде. Инде килешми икән, әйтсен соң М. Юныс: Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» повестенда, Такташның «Мокамай» поэмасында, яисә Ш. Хөсәеневның «Зөбәйдә — адәм баласы», Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы», Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» әсәрләрендә кайда партия пропагандасы?

М. Юныс XX гасыр татар әдәбиятына бары Сталин заманы дәрәҗәсеннән генә чыгып карый шикелле. Җитмешенче еллар татар прозасын «Биектә калу», «Табу һәм югалту» кебек талантлы повестьлары белән баеткан әдибебезгә карата «милли иҗатны яхшы беләме икән?» дигән тупас сорау кую килешмәс, әмма язучыда күзне һәм уйны томалаган метафизика галәмәте юкмы, дип чынлап шикләнергә урын кала. Шул булмаса, «Татар әдәбияты үзгәрешләр чорына әзерлексез килде» — дип аһ ормас иде ул.

Шулай итеп, безгә әдәбият дигән олы  зур, катлаулы күренешкә үз калан-чабыздан чыгып кына бакмаска, ә аны туктаусыз үсештә, үзгәрештә дип исәпләп, тарихилык принцибыннан чыгып бәяләргә дә кирәктер.

* * *

Ислахчылар, чынлап та, әдәбиятка җеназа чыгарга җыена кебек. Әнә бит, конформист диюдән тыш, М. Юныс татар язучыларын «иҗат эшләрен икенче планга күчерү»дә, бюрократлыкта һәм ялагайлыкта гаепли. Ф. Дунай безнең милли иҗатны «ялганлап сурәтли торган әдәбият» дип бара. Әле кайчан гына социалистик реализм әсәрләренә мәдхия укыган фән докторы Ф. Мусин да хәзер совет язучыларында бары тик идея-эстетик чикләнгәнлекләр генә таба һ. б.

Шулай да гаепнең аеруча зурысы А. Гыйләҗев тарафыннан ташланды. Совет чорының иң зур талант булып исәпләнгән әдипләрендә дә татар язмышы, ачы нужасы укучылар аңына барып җитәрлек хәлдә чагылыш тапмады, алар милләт гаменнән ерак тордылар, дигән карашны алга сөрә ул. «Имән чикләвеге» мәкаләсендә аның каләме белән мондый сүзләр язылган: «Туфанның төрмә-лагерь юлларын үтеп тә һаман «суллык» кизүеннән аерыла алмавын без һаман читләтеп үтәбез. Буа районына барып кайткач, ул сиксән яшьлек бәлтерәгән бабайның борчак чабуына сокланып шигырь иҗат итте. Әгәр тормышны соңгы чиккә барып тәрәлмәсә, яшьләр туган җирләрен каһәрләп колхоздан тоташ качмаса, намазлык өстендә изге сүз сөйләп утырасы карт кара тиргә батып борчак чабар идеме?...»

А. Гыйләҗев Туфанның нужалы картка булган мөнәсәбәтен шагыйрьнең дөньяга караш чикләнгәнлеге белән аңлатырга омтыла. Аныңча, Туфан «егерменче гасыр җәбер-җәфаларының, милли каршылыкларның, гарасат-сугышларның тирәнлегендә Маркс-Ленин тәгълиматы ятканын бер чакта да белә алмады».

Н. Юзиев тарафыннан бу нәрсә кире кагылса да, мин әлеге гоманны игътибарга лаек дип саныйм. «Имән чикләвеге» авторы белән бәхәсләшкән галим Н. Юзиев шагыйрьдә һич тә аерым чикләнгәнлекләр күрергә теләми. Фаҗига хакында аның төп җавабы мондый: Х. Туфан үзенең «лирикасы белән, фаҗигале язмышы, фаҗигале мәхәббәте белән, үзенең генә түгел, ә чорның да, халкыбызның да фаҗигале язмышын ачты».

Ә бит А. Гыйләҗев урынлы сорау кузгата. Бәлтерәгән борчак чабучы карт шагыйрьдә башка хисләр уятырга мөмкин булган шикелле, татар халкының да фаҗигадан башканы татырга хакы юкмыни соң?

Триумфаль төрмә лирикасыннан соң, алтмышынчы елларда, Х. Туфанның Пушкинныкы сыман «Болдино көзе» булырга тиеш иде сыман. Чөнки поэтик осталык чарланган, дәрт-моң бар әле. Ләкин кызганыч: әлеге көз җитеп, шигъри җимешләр яудырмый, илһам юк, шедевр тумый. Хикмәт чынлап та тирәндә ята булса кирәк шул. Тоткынлык хисләре — -шагыйрь өчен үткән этап, әйтеләсе әйтелгән кебек. Ә яңа поэтик ачышлар ясар өчен тулпарны башка идея-эстетик мотивлар, идеал белән сугару кирәк. Монда кеше затына яңа бер ноктадан багу зарур. Әмма кичәге тоткын сәяси доктрина лабиринтларыннан котыла алмый. Сталиннан ваз кичсә, Ленинга, коммунизмга өметләнә ул һәм, нәтиҗәдә, аның лирик герое, персонажлары ничаклы фаҗигале язмыш кичермәсен, әдәбиятның башка каһарманнары кебек үк иллюзияләр, соцреализм сыйфатлары белән сугарыла. Әлбәттә, тормышны яратуны минор хисләр аша фаҗига, моң, сагыш аркылы раслаган бу геройның татар поэзиясе өчен, милли әдәби зәвыкъ, укучы хисләре өчен гаҗәп зур яңалыгы бар. Ләкин болар гына, А. Гыйләҗевның шагыйрьнең дөньяга карашы хакындагы уйларын кире кага алмый. Безгә аның: «Х. Туфан һәм аның каләмдәшләре Солженицын сыман тоталитар режимның асылына төшенеп җитсәләр, һичшиксез, әдәбиятыбызны бөтенләй яңа идея-эстетик ачышлар, башка мәгънәле геройлар белән баеткан булырлар иде»,— дигән фикер-карашларын һәрчак истә тотарга кирәк.

Ләкин сүз сәнгатенең асылы, көче идеологик факторлардан гына торамы? Башкача әйтсәк, А. Гыйләҗевның Х. Туфанга карата тискәре бәясе өстен, хәлиткеч булып чыгамы инде? Солженицын шәкерте А. Гыйләҗев үзенең соңгы тәнкыйть чыгышларында татарның икенче зур шагыйре Муса Җәлилне дә телгә алды. Аңа карата, шулай ук, ямьсез ишаpәләр ясады. Янәсе, җимерелгән империяне Ватаным дип санаган шуның өчен шәһит киткән шагыйрьне татар киләчәктә ничек бәяләр?...

Дөньяны ничек кенә чуалчык димик, анда илаһи мантыйк галәмәтләре бар бугай. Өч ел элек Уфадагы татар мәдәният мәркәзе клубында Муса Җәлилнең тоткындагы язмышы турында чыгыш ясадым. Сорау бирүләр башлангач, клубның ул чактагы лидеры, татар ислахчыларының кәттәсе Айдар Хәлим мәсьәләне котелмәгәнчә куйды: СССР империясе таркалды, элекке шәһит китүләр хәзер мәгънәсезгә чыга, янәсе. Җәлил тоткынлыкта татар милләте өчен үзен саклап калса, яхшырак булмас идеме? А. Хәлимгә шундый җавап ишетергә туры килде: «Һич юк! Муса Җәлил трагик юлны вөҗдан кушканча сайлады, ул чын батырлык кылды».

Ислахчылар, бәлки, М. Җәлил гомерен башкачарак фараз итәргә дә җөрьәт итәләрдер? Әйтик, ул тоткынлыкта тән саклап калды, шуннан соң читләрдә Гарип Солтан сыман советка каршы пропагандист булып, яисә Солженицын сыман китаплар язып бездәге тоталитар режимны фаш итүгә күтәрелде, ди. Әйе, бу очракта Җәлил пәйгамбәр, милли герой, ягъни сәяси-идеологик планда аерым төркемне канәгатьләндергән идеал булып күтәрелергә дә мөмкин. Әмма, тьфү, тьфү! Җәлил хыянәт юлына борылган булса, замандашлары тарафыннан йөз, юк, мең кат ләгънәтләнгән зат булыр иде. Геноцид, шовинистик Сталин сәясәте тарафыннан төрле мәкерлекләрдә, солтангалиевчелектә, җидегәнчелектә, «халык дошманнары» асрауда, «Идегәй» эпосы уңае белән милләтчелектә гаепләнгән татарның кара абруена тагын шагыйрь хыянәте дә өстәлсә, кем белә, бәлки безгә дә Кырым татарлары язмышына төшәргә бик ерак калмас иде. Шөкер, Муса Җәлил үзенең тиңдәшсез рухи ныклыгы, батырлыгы һәм «Җырым белән җиңдем дошманны» мотивы белән сугарылган көчле саф поэзиясе белән заманында халкыбызның намусын, вөҗдан аклыгын саклап калды. Ул милләт абруен дөнья каршында күтәрде. Татар өчен моннан да зуррак геройлык кылган ир булырмы?

Муса Җәлил күп нәрсәләрдә күзне ача, карашларны киңәйтә. Әйе, әдәбият һәм аның принципларын билгеләүдә, язучы идеалын, дөньяга карашын формалаштыруда идеология бәхәссез роль уйный. Язучы сәясәттән дә азат түгел. Ләкин шагыйрьне зур, олы итеп һич тә идеологик аң, сәяси зирәклек ясамый. Шагыйрь өчен иң мөһиме — тормышны матурлык законнарыннан, әхлак категорияләреннән чыгып тану, бәяләү. Кайда хыянәт, кайда батырлык, матурлык нәрсәләрдән тора да, ямьсезлек, гариплек кайдан башлана? Нәкъ менә шул четерекле сорауларны ачыклаган каләм иясе зирәк тә, бөек тә! Һәм менә шунда әдәбиятның мөстәкыйльлеге, олылыгы, мөкатдәслеге ята.

Борынгы Рим, Грек җәмгыятьләреннән башлап, кешелек тарихы нинди генә сәяси-иҗтимагый корылышларны, идеологик доктриналарны белми. «Ниһаять, мәңгелек хакыйкатьне таптык, чын идеалга юлыктык!» — дип сөрән салучы «пәйгамбәрләр» күпме булган. Ләкин тәгълиматлар, доктриналар төсләрен җуйганнар, сәяси шарлатаннар онытылган. Ә менә чын шагыйрьләр, әдипләр заманнар кичеп һаман яши. Чөнки әхлак сафлыгы, җан камиллеге, рухи гармония кешелекнең иң зур идеалы булып кала. Совет әдипләре яклаган, раслаган әхлак сыйфатларының күбесе гомум-кешелек омтылышларына туры килә. Кара төрмәләр кичеп, үлем белән якалашып ап-ак калган Туфанда «әхлакый ачышлар юк!» дип әйткән затны Алла сугар. Хәер, шагыйрь кыйммәтен иң элек шагыйрь тоя. Башкорт шагыйре Шәриф Бикколның «Туфан елмаюы» шигырендә Туфан гел көлгән халәттә тора. Ул хәтта нәфрәтен дә зәһәр елмаю аша кадый.

Зарланмады,
Бөгелмәде —
Туфанга бу ят иде:
Кеше кыяфәтендәге
Илаһи бер Зат иде! —

кебек юллар шагыйрь иҗатына ачкыч булып торалар. Чыннан да, Н. Юзиев әйткәнчә, Х. Туфан лирикасында тулаем халык фаҗигасе ятмый, ләкин монда кешенең көче-куәте, фаҗигаләргә бирешмәве үзәктә тора. Моң, сагыш кичерүләр, югалтулар аша тормышны раслау, мәхәббәт тоту монда үзәк лейтмотив булып сузыла. Менә болар шул чор поэзиясе һәм, гомумән, татар әдәбияты өчен чын ачыш түгелмени?

Милләткә хезмәт итүне дә, безнең хәзерге матбугатта чыгыш ясаучы кайбер авторлар кебек, урамга һәм мәйданнарга чыгып кайнар сүзләр кычкыру, сәяси оппонентлар белән якалашу, яисә узаман кыяфәте алып, аерым кыйблага өндәү итеп кенә аңламыйк. Мондый рәвешләрдә әдип ул үз асылын җуя, ә аның язганнары исә ярсу хисләр, ашыгыч бәяләр, конъюнктур кыйммәтләр белән

сугарылып, гомердән, зур укучылар аудиториясеннән мәхрүм ителә. Без киләчәктә дә «үле» әдәбиятка йөз тотмыйбыздыр бит? Чын әдипнең милләткә хезмәте халыкта тойгыландыру-уйландыру хасиятләрен кузгатуга һәм аңарда үз-үзенә, киләчәгенә рухи ышаныч, өмет, үзара берләшү тойгыларын кочәйтүгә кайтып кала. Х. Туфан поэзиясе исә — әлеге таләпләргә тулы җавап биргән иҗат.

Шул рәвешчә, аерым шагыйрьләрне һәм, гомумән, совет чоры әдәби иҗатын кимчелекле итеп күрсәтергә теләгән һәм безнең талантлар халык мәнфәгатьләреннән еракта булды дип ышандырырга тырышкан Аяз Гыйләҗевның карашларын яклап булмый. Хәер, 1993 елның 30 сентябрендәге «Шәһри Казан» газитендә, язучы Марсель Галиев белән әңгәмәләшеп, ул үзе дә әйтә: «Әдәбиятыбыз түбәндә түгел». Менә бусы, чынлап та, дөрес бәя булыр!

* * *

Коммунистик режимның кара көчләре тарафыннан кыркылган, әмма шулай да куәтле үсенте сыман кыякланып үсеп, замандашларына рухи юлдаш булырга омтылган татар әдәбиятын һәртөрле яманаттан аралау һәм гадел бәяләү өчен, аның үзенчәлекләрен белү, нечкәлекләренә төшенү дә бик мөһим. Шул җәһәттән соңгы еллар поэзиясе өлкәсендә кызыклы күзәтүләр ясаган тәнкыйтьче Ф. Зөлкарнәевның бер фикере зур кызыксыну уята. Ул татар шигырен халыктан ераклаштырган ике сәбәпне ачып болай ди: «Беренчесе — шагыйрьне шигъри фикерен белдергәндә билгеле бер кысада бикләп тотарга тырыша торган чикләүләр (сүз иреге җитми!); икенчесе — укучыларның хәбардарсызлыгы (мәгълүмат җитми!)... Шагыйрьләребезне җитәрлек дәрәҗәдә аңлап, төбенә төшеп укый ала торган укучыларыбыз нихәтле икән?»

Сүзне тыю, чикләүләр заманында демократик рухлы әдәбият текстның юл араларына кыстырылган кинаяләр, ишарәләр яисә метафора, афоризмнар белән эш итә. Эзоп стиле, Ф. Зөлкарнәев әйткәнчә, поэзиягә генә карамый, ә 60—70 еллар прозасы һәм драматургиясе дә шул стиль белән мул сугарылган. Әйтик, Т. Миңнуллин гаҗәп уңышлы милли характерлар иҗат итүдә шартлылык алымын кыю кулланды. Аның тормыш гаделсезлекләре фаҗигаләр эчендә тереклек кылган Мәдинәсе («Ай булмаса йолдыз бар») яисә гүзәл татар картларын җанландырган Әлмәндәре («Әлдермештән Әлмәндәр») гадәти тасвир алымнары, «туры сүз» белән сурәтләнгән булсалар, мөгаен, зур сәхнә тормышы кичерә алмаслар иде. Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы» повесте да юкка гына болай аталмаган. Әдәбият галиме Р. Сверигин үз вакытында автор ишарәсен дөрес тотып алды. «Биредә Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»енә аңлы ишарә бар»,— диде. Чынлап та, классик әдип үз повестенда татарның социаль катламнарына ишарә итеп, революция китергән фаҗигаләрне ачса, Х. Сарьян «Бер ананың биш улы» язмышын үз заманының кырыс һәм рәхимсез чынбарлыгына бәйләп күрсәтте.

Сугыштан соңгы елларда ачылып киткән тагын бер бик мөһим үзенчәлеккә игътибар итәргә һаман күзебез җитми. Бу — геройларны әхлакый сынау мәсьәләсе. Дөньяга килгән һәр әсәр теге яки бу ноктадан килеп геройны сынау, характер сыйфатын ачу бит ул. Күзәтә, тикшерә китсәң, иҗат практикасында әхлакый сынау төрләре бик ишле түгел. Мәхәббәттә сынау, көрәштә сынау, хезмәттә сынау...

Әдәби геройларның кешелек кыйммәтләрен билгеләүдә яңа әхлакый нокталар табу кыюлыгы, зирәклеге Ә. Еники иҗатында бик ачык күренә. Аны үз вакытында хәтта талантлы каләмдәшләре дә аңламадылар. Мәсәлән, Мирсәй Әмир «Әйтелмәгән васыять»тәге язучы позициясен тәнкыйтьләп болай язган иде: «Автор картлар ягына, үлеп үк киткән Акъәбиләр яки әрәге бу дөньяда булса да, үзе инде сафтан чыккан Миңлебай картлар ягына кушыла. Нәтиҗәдә, укучыны алга әйдәү урынына, аны артка, иске авылга, тизәк яккан учаклар, салам түбәләр, читәннәр авылына йөз юнәлдерергә тырышу килеп чыга».

Әмма әнә шундый көтелмәгән яктан килү, геройны халык рухына бәйләп сынау, Ә. Еникига үз әсәрендә заманның рухи мокытлыгын, әхлакый гарипләген фаҗига рәвешендә ачып салырга мөмкинлек бирде.

Г. Бәширов үзенең «Җидегән чишмә» романында геройны әхлакый сынауның янә бер тирән раслады. Бу — табигатькә мөнәсәбәт. Элекке макталып килгән әдәби геройлар бу мөнәсәбәттә әсәрдә көтелмәгәнчә ачылып киттеләр. Эш, план, дип тыз-быз йөгергән колхоз рәисе, коммунист Чурмантаев рухи зәгыйфьлеген, прагматизмын инде укучыдан һич яшерә алмый.

Ш. Хөсәеновның «Әни килде» драмасында бер төркем персонажлар анага мөнәсәбәттә сыналдылар. Эштә, кешеләр каршында яисә сөйгәнең алдында әллә ничә кат битлек киярга була. Әмма синең чын йөзең, әхлак сыйфатларың иң элек сине тудырган, баккан һәм синең өчен йөрәген, саулыгын да кызганмаган ана заты каршында ачыла икән... Кешелегеңне син иң элек ата-анаң каршында күрсәт! — ди драматург.

М. Хәбибуллин «Икмәк кадере» повестенда геройларның рухи, әхлакый сыйфатларын изге төшенчә — икмәккә мөнәсәбәттә күрсәтте.

Менә шулай кешелек кыйммәтләрен билгеләүдә яңа әхлакый нокталар табу образларның эчке дөньясына, андагы төрле рухи башлангычлар хәрәкәтенә ныграк үтеп керергә һәм мөһим этик-фәлсәфи концепцияләр расларга мөмкинлек бирде.

Мин соңгы дәвер әдәбиятыбызның тагын бер мөһим үзенчәлеген аның демократизмында, кеше язмышын ачуга йөз тотуында күрер идем. Ләкин менә М. Юныс, Ф. Дунай каршы төшәләр. Алар татар әдәбиятын «берничә мәҗбүри тема эченә куып кертеп, йозаклап» куелган һәм «заман геройлары» атамасында «ясалма ситуацияләрдә ясалма лозунглар тәкърарлап тыз-быз йөгереп йөрүче, кызыл сүзле резонар дилетантлар» төркемен тасвирлаган иҗат дип күрсәтмәкчеләр. Ләкин бу тәнкыйтьчеләрнең гаделлегендә минем бераз шигем бар. Ф. Дунай «Шаукым» мәкаләсендә 35 ләп рус язучысын, рус совет әдәбияты әсәрләрен телгә ала да: «андый язмалар татар совет әдәбиятында да, мөгаен, вагонлаптыр» дип, күршеләрдәге сыйфатны татар әдәбиятына да чәпәп куя. Мондый тикшеренү принцибы белән эш итсәң, акны да кара итеп күрсәтү бер ни тормый!

Әлбәттә, кыек атсалар да, шактый туры тидерәләр әлеге авторлар. Рустагы кебек, татар әдәби иҗаты да производство коллизияләре белән мавыкты. Монда да төссез «эшем кешеләре» күп. Шулай да кеше язмышын үзгә бер моң, сагыш белән тәфсилләп сурәтләргә өйрәнгән борынгы татар әдәбияты совет чорында гына милли сыйфатыннан йөз чөерә алмады. М. Гафуриның «Кара йөзләр»енә карагыз, Һ. Такташның «Мокамай»ына багыгыз, яисә М. Галәүнең «Болганчык еллар» дилогиясенә күз ташлагыз. Болар барысы да кеше язмышларын ачкан әсәрләр түгелмени? Советча интерпретация булуга карамастан, Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр», Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Ф. Хөснинең «Утызынчы ел», «Җәяүле кеше сукмагы», М. Әмирнең «Саф күңел», И. Газиның «Онытылмас еллар» кебек күләмле әсәрләре дә милли иҗатта кеше язмышын тасвирлауның үзәктә торуын раслый. Шушы мөһим эштә тәҗрибәсе, осталыгы булмаган әдәбият Муса Җәлил, Х. Туфан, Ф. Кәрим, З. Мансур лирик геройларының үзәк өзгеч моң, драматизм белән сугарылган язмышларын бирә алыр идеме икән?

Ф. Хөсни «Йөзек кашы» повестенда каудар Айдарның «төсле» язмышын хикәя иткәч, ничектер күренмәс оппоненты белән бәхәскә кергәндәй әйтеп куйган: «Безнең чорда да кешеләрнең кайгырырга һәм шатланырга хаклары бар, безнең чорда да кешеләр сөяргә һәм сөелергә, бәхетсез булырга мөмкиннәр, әдип кешенең әнә шул әйберләр турында да әсәр язарга хакы бар».

Бу бит 1940 елда, язучылар партия әмереннән башка суларга да курыкканнар дип хәзер гоман ителгән бер вакытта әйтелгән. Шулай, безнең әдипләр олы язмышлар эзләүдән бервакытта да туктамады!

Әдәбиятыбызны җентекләп күзәтсәң, әлбәттә, аның тагын башка үзенчәлекләрен һәм нечкәлекләрен билгеләргә буладыр. Ләкин мәсьәләнең әлегә куелышы шунда: безнең әдәбият үзенең чын сыйфатлары, милли асылы белән халыкка барып җитәме? Безнең замандашлар, шул ук ислахчылар, үз әдәбиятларын беләләрме, аны җитәрлек дәрәҗәдә аңлыйлармы?

Әмма, минемчә, бөтен бәлаләрнең башы да шунда. Фән кандидатлары, докторлар, хәтта академик исемнәре алган һавалы галим-голәмәнең зур төркеме булса да, милли әдәбиятның уңыш-кимчелекләрен барлаган, үсешен төрле-төрле тенденцияләр көрәшенә бәйләп күрсәткән фәнни хезмәтләр, колачлы анализ юк бездә. КПССның өлкә комитеты заказы белән төзелгән «Татар әдәбияты тарихы»н сару кайнатып телгә алмыйк. Тәнкыйть һәм әдәбият белеменең мөшкел хәленә төшенергә тырышып карыйк. Хатип Госман, Ибраһим Нуруллин, Гали Халит кебек өлкән әдәбиятчы галимнәребез бик тырыш, югары зәвыклы, зиһенле затлар иде. Әмма һәркайсы бик гаярь һәм кайнар, үз-үзенә баш та түш иделәр, уртак, гомуми фикергә килеп бик аз эшләп калдылар, шикелле. Югыйсә, татар совет әдәбияты үзенең чын асылы, милли сыйфатлары белән шул галимнәр тарафыннан ачылырга тиеш иде.

Алтмышынчы еллар азагында тәнкыйть, фән өлкәсенә аяк баскан Флүн Мусин, Рафаэль Мостафин, Нил Юзиев бик гыйльми эрудицияле, заманча фикерле затлар булды. Һәркайсы тау-тау китап чыгарды. Совет әдәбиятын комплекслы күзаллау, колачлы анализ да бар иде шикелле үзләрендә. Ләкин үткер күзле Фәрваз Миңнуллин үзенең түбәндәге сүзләрен нәкъ шул затлар тарафына юллап әйтте бит: «Танылган рус галимнәренең, башка милләт вәкилләренең теоретик хезмәтләрен укыйлар да, татар әдәбиятыннан шуларга туры килерлек мисаллар эзләргә тотыналар... Татар язучыларының әсәрләрен шул «модный» теорияләргә бөгәрләп тыгып куялар».

Рус кафтанын татар әдәбиятына кидерергә маташу, Мәскәү-мәркәз, «абзыйлар» ни уйлый, дип гел-гел башны рус ягына юнәлтү милли иҗат практикасына да, фәнгә дә зур зыян салды. Әдәбият тарихында «ак таплар», ачылмаган күренешләр күбәйде, тиешенчә бәя алмаган язучылар, әсәрләр калды.

Мансур Вәлиев, Салих Маннапов, Ренат Мөхәммәдиевлар милли иҗатны ныграк аңлый, аның асылына күбрәк төшенә ала иде. Тик болар да җинел юл сайладылар. Теге яки бу әдипнең әсәрен укып, шәхси тәэссоратларына чумдылар, бер-берсен ишетмәделәр, күмәк сүз әйтә алмадылар алар. Эссеистик юнәлеш яшь тәнкыйтьчеләргә аерым абзыйлар каршында абруй яуларга мөмкинлек бирде бирүен, әмма зур әдәбият, тәнкыйть моннан әллә ни отмады шул.

Шулай итеп без сүз алып барган елларда татар тәнкыйте, әдәбият фәне торгынлык чорына хас ваемсызлык белән яшәде. Зур һәм урта кул юбилярларга махсус мәдхияләр язу, гөнаһсыз, югары этикага корылган әдәби күзәтүләр ясау, авторлар күңеленә хуш килерлек рецензияләр бастыру күп булды... Кыскасы, сиксәненче еллар азагына татар әдәби-эстетик фикер хәрәкәте Җамал Вәлиди, Г. Ибраһимов, Гали Рәхим кебек киң колачлы галимнәрнең чабуына да җитмәслек бер хәлгә төште. Ислахчылар белми: әдәбият түгел, ә тәнкыйть, әдәбият фәне бездә «үле» хәлдә...

Зыялыларыбызның үзара мөнәсәбәтләре рәхим-шәфкатьле, кешелекле һәм уртак максатка юнәлгән булса, әдәби иҗат һичшиксез, зуррак нәтиҗәләр яулар иде. Ләкин безнең милли әдәби мөхит, байтак матур сыйфатлардан мәхрүм, шикелле. Ни җитми монда?

Мәскәүдәге мәдәният, әдәбият тирәсендәге талашлар бер-берсен аударып, тапташып узулар рус белән яһүднең астыртын сугышыннан килеп чыга. Ә безнең иҗади зыялылар бердәмлегенә нәрсә комачаулый соң?

Фаҗигабез шунда: татарның психологиясендә, матур сыйфатлар белән беррәттән, князьлек һәм коллык галәмәтләре бергә кушылган. Үзеннән зурраклар каршында ул — куштан, ялагай, йөзе дә ап-ачык аның. Әмма үзеннән түбәннәргә булган мөгамәләсендә гаҗәп дорфа, вак, игелексез ул. Дөньясы хөсетлек белән тулы аның. Мондый әверелеш тора-бара төркем сугышларыннан да начаррак хәлләргә китерә: милләт үз-үзен ашый...

Соңгы гасырда безнең әдәбият өлешенә тирә-күршеләрдә булмаганча иң миһербансыз һәм интригалы тәнкыйть, гаҗәп догматик һәм консерватив фән, үз-үзен бетерүче мөхит туры килде. «Солтангалиевчелек»кә, «җидегәнчелек»кә һәм «Идегәй»гә бәйле, Рәсәй күләмендә «дан» чыгарган интригалар һәм үзара фаш итүләр бары тик татарда гына булды. РАПП әмеренә бирелеп, үз мәдәниятенә, әдәбиятына, халык рухына, диненә, гореф-гадәтенә иң зур таш атучылар да бездә иде. «Халык дошманы» ярлыгы тагып, бер-берсен сатучы, һәлак итешүче адәм актыкларының һәм корбаннарның күплеге ягыннан да Рәсәйдәге башка халыклар татар белән һич ярыша алмыйдыр.

... Әмма трагик хәлләр, фаҗигаләр һәм югалтулар күплегенә карамастан, «үткән мәдәниятебез, әдәбиятыбыз хәятен үтә имин, шома һәм казанышлар дәвере» дип халык күзенә ак пәрдә элүче куштан, карьерачы галим-голәмә дә бездә тупланган. Инде менә болганышлар чыгу белән татарда күршеләрдә булмаганча бер-берсен хурлау, таш атышулар галәмәте башланды. Без тагын, кыргыйлар сыман мәдәнияткә, рухыбызга, җаныбызга кизәнәбез — үз-үзебезне ашарга торабыз...

Ә әдәбият яманатына карата соңгы сүз итеп шуны әйтергә кирәк.

Безнең язучылар партиягә мөридләр булган дигәнгә ышанмагыз сез. Янәсе, партия — илаһи зат, акыл иясе әмер бирә, ә мөридләр башкара... Бу сурәт, мондый иллюзия тоталитар режим иясе КПССка гына кирәк иде. Һәм куштан, сатлык галим-голәмә аның заказын үтәде, шулай итеп күз буяды. Ләкин аңларга кирәк: әдәбият кебек олы, серле, мөкатдәс нәрсәне мөридләр булдыра алмый, аны тик чын шәхесләр тудыра. Әдәбиятыбызны олылау шәхесне, иҗат кешесен, милләттәшне зурлаудан башланыр, бәлки?

**Фоат Галимуллин**

# ҖАВАП БИРЕР ЧАК

В. НУРУЛЛИН ИҖАТЫ ТУРЫНДА УЙЛАНУ

Вакыйф Нуруллинның «Җавап бир, кеше!» дигән бик әйбәт повесте бар. Әйбәтлеге нәрсәдә, дигәндә, ул укучыны борчылдыра һәм үз яшәешенә тәнкыйть күзе белән карарга мәҗбүр итә. Әлбәттә, үткәннәргә тәнкыйть белән карау бүтән язучыларга да хас сыйфат. Шундый хистән башка иҗади үсеш, каләм көченең ныгый баруы мөмкин түгел.

В. Нуруллинның әдәбияттагы уңышлы адымы «Шинельсез солдатлар» повесте (1963) белән башланды. Уңышның сәбәбе — язучы каләменең ихласлылыгында, чынбарлыкны булганынча сурәтләвендә иде. Сугыш чоры авылының хәлен белергә теләсәң, бер дә аптырап торма, тот та шушы әсәрне укып чык. Дөрес, әсәрдә ара-тирә ясалма урыннар да тешкә тиеп ала. Мәсәлән, сугышка китүчеләрнең менә мондый җыр сузулары уйлап чыгарылган кебек:

Китәбез шул, китәбез,
Без китмичә — кем китәр?
Илне дошманнардан азат
Без итмичә — кем итәр?

Иманым камил, болай җырламады алар. Ут эченә барып керәсе кеше ул җырларны кызылга манып тормый, турыдан ярып сала:

Китәргә калгач китәрбез,
Атларга авыр итәрбез.
Калдык авыр заманага —
Бәхетсез бала икәнбез.

Сугышта хәбәрсез югалган Искәндәрнең, Герой исемен алып, ун көнгә кунакка кайтып китүен дә әлеге образны күтәрү өчен ясалган уңышсыз алым дип бәяләргә мөмкин. Шуны истә тотыйк, әдәби образны күкрәгенә тагылган орден-медальләр зурайтмый, бәлки аның кешегә хас җанын ачып бирү калку итә. Шуңа күрә, Искәндәрнең сугыштан кайтуын тасвирлауга караганда, аның киткән чактагы үз-үзен тотышы күчлерәк тәэсир калдыра. Сугышка китәсе көнне дә ул колхоз әйберләрен ташып йөри, соңгы сәгатендә генә өенә кереп ашап чыга, машинасына утыртып, авыл халкын урам әйләндерә.

— Исән булсам — кайтырмын, кайта алмасам үпкәләмәссез,— дип китеп бара. Шушы күренештә Искәндәрнең нинди егет булуы табигый генә ачылган да куйган. Хатыны Нәсиханың ул югында ирләр белән чуалуы, шул юлда дөньядан китүе оста сурәтләнә. Искәндәрне Герой итү менә ни өчен кирәк булган: их, Нәсиха, Нәсиха, әйбәт кенә торсаң, сине әнә нинди бәхет көткән, дип әйтергә теләгәндер автор. Юк, мең тапкыр юк! Тимер-томыр ялтыравыкка караганда кеше үзе кирәгрәк, кадерлерәк. Күрәбез, әсәр бинасына сыйфатсыз кирпечләр кереп калса, берникадәр зыян килә.

Сугыш чорында авыл кешеләренең фронттагылардан һич тә ким җәфа күрмәгәнлекләрен язучы уңышлы күрсәтеп бирде. Монысын тиешенчә бәяләргә кирәк. Чөнки бу вакытларның авылын шомартып сурәтләүләр белән дә очрашырга туры килгәләде.

Равил исемле үсмер малай авызыннан хикәяләнгән хәл-әхвәлләр кемне генә битараф калдырыр икән? Автордан әсәрнең дәвамын язуын үтенеп килгән хатлар шул турыда сөйли иде. Гадәттә, бу рәвешле өстәп язулар уңышлы ук чыкмый. Әмма бу очракта «Әгәр син булмасаң...» повестенда В. Нуруллин моның киресен раслады. Биредә инде без Равил белән сигезенче сыйныф укучысы буларак очрашабыз һәм физика-математика фәннәре кандидаты, үзе эшли торган өлкәдә Дәүләт бүләге алу дәрәҗәсенә күтәрелгән галим буларак аерылышабыз. «Равил язмышы ничек булып бетте?» — дигән сорауга укучылар тулы җавап алалар. Шунысы кыйммәт, бу җавап мавыктыргыч сюжет һәм сәнгать чаралары ярдәмендә бирелә.

Равилнең Рухиягә булган хисләрен эзлекле, укучы тоярлык кайнар итеп бирү В. Нуруллин каләменең камилләшә баруын күрсәтә иде. Никадәр сафлык, тыйнаклык бу үсмерләрнең үзара мөнәсәбәтләрендә! Күпме хис өермәләре, күңел каршылыклары алып килә кешегә яшьлекнең бу гүзәл чоры. Равил йөрәгендәге тойгылар давылының бер көчәеп, бер сүрелеп торуы монын шулай икәнлеген ачык күрсәтә.

Әмма автор әлеге образны тудыруда эзлекле түгел. Бу бигрәк тә Равилнең үзенә хас булмаган «йомыкыйлык» сыйфатын бик тырышып аңа тагарга теләүдә күренә. Катлаулы хәл-әхвәлләрдә, кызлар һәм иптәшләре белән мөнәсәбәттә ул нык холыклы, үз-үзенә ышанучан, олылар белән сөйләшкәндә дә уйларын дәлилле итеп әйтеп бирә белүче, физик яктан көчле үсмер итеп сурәтләнә. Мондый малай йомыкый булырмы? Андыйларны, гадәттә, «ут егет» дип атыйлар. Шунысы бар, аңарда үтә инсафлылык көчле. Бу аны артык адымнардан саклап тора һәм егетнең башкалар алдында абруен күтәрә.

Равил белән Рухия мәхәббәте — үкенечле мәхәббәт. Шулай булмаса, алар турында язып тору кирәкмәс тә иде. Чөнки бәхетле мәхәббәт — чатак-чотыклардан мәхрүм була, сюжет төзү өчен уңышлы җирлек булып хезмәт итә алмый. «Бәхетлеләр барысы да бер төрле, бәхетсезләр һәрберсе үзләренчә бәхетсез...» Гомер уртасында бу икәүнең бер-берсе өбеләп хат язышa башлаулары да әлеге сюжетның дәвам итүен күрсәтә. Кем белә, В. Нуруллин ул геройлары белән тагын бер «яшәп алыр» бәлки?

Шулай да, лирик повестьның тукымасыннан төртелеп чыгып торучы бер күренеш канәгатьсезлек калдыра. Ундурт-унбиш яшьлек Рухиянең үз әтисе өстеннән төрле җирләргә шикаять язып утыруы бик ятышлы кабул ителми. Андый хәл булмас дип әйтәсем килми, Павлик Морозовлар үрнәгендә тәрбияләнгән яшьләребез кулыннан килмәгән эш булмады. Тик биредә ул ятрак тоела.

Авторның «космополитизм» сүзен урынлы кулланмавы да әсәрнең дәрәҗәсен төшерә. «Татар теле укытучысы: «Такташның «Җир безнеке булыр. Ачулансак, шлем киертербез айга да» дигән шигъри юллары космополитизм рухы белән сугарылган»,—дигәч, «Юк, апа, Такташ дөрес язган, менә күрерсез әле, озакламый аның хыялы чынга ашачак!»— дип кычкырып, галимнәр тарафыннан әйтелгән һәм дәреслектә басылып чыккан фикергә каршы килүен... бик җентекләп, иренмичә сөйләп чыкты», Биредә «космополитизм» сүзе «космология» тәгъбире белән бирелергә тиеш иде. «Космополит» сүзе бөтенләй икенче мәгънәне белдерә бит, ягъни туган халкына, аның мәдәниятенә чит рухлы тәрбия алган, үз әлгәрләреннән аерылган кешене шулай атау гадәткә кергән. Бу мәгънәне хәзер Ч. Айтматов иҗат иткән «манкорт» сүзе белән атау да гадәткә кереп бара. Әнә шагыйрь Равил Фәйзуллинны укып карыйк әле, ул ничек мәгънәле итеп әйтә:

Космополит түгел. Шөкер. Минем
Халкым да бар, ил дә, Ватан да.
Мин тынычмын: «татарныкы» диеп
Төртеп күрсәтмимен ал таңга.

Шундый ук игътибарсызлык башка урыннарда да очрап куя. «Ике урам арасы»нда авыл хуҗалыгы техникумы тәмамлаган Кифаяны «югары белемле һөнәр иясе» дип атау да — чак кына уйлап бетермәү нәтиҗәсе. «Һәлакәт» әсәрендә сыер савучы Рәйхананы да «ханым» дип атау тормышчан түгел. «Ханым» кебек затлы сүз ул елларда кулланылса бары тик зыялылар арасында гына булгандыр. Минем үземнең сыер савучыны «ханым» дип әйтүләрен ишеткәнем булмады. Әйтелгән тәкъдирдә дә ул мыскыллык төсмере генә бирә иде. Автор үзе әйткәнчә, «ир-атлар белән шактый чуалган» Рәйхана да «ханым» булудан ерак тора. Дөрес, соңыннан ул үзенең гаделлеге һәм аналарча киң күңеллелеге белән ихтирам уята.

Әдәби әсәрдәге һәр сүз үзенә тиешле йөкләмә ала, шуңа күрә язучы аларны куллануга аеруча саклык белән якын килергә тиеш.

В. Нуруллин тормышны яхшы белә. Әтисез үсү Равилнең холкы калыплануга никадәр тәэсир итүен ышандыргыч итеп күрсәтә ул. Малайларга атаның ирләрчә үрнәге, акыллы киңәшләре бик әһәмиятле. Безнең Равил исә әнисе кочагында, башка хатын-кызлар чолганышында үсә. Әллә ничә елга бер очрашкалаган Искәндәр абыйсы, шифаханәдә ятканда бүлмәдәш булган Хатип дигән кешенең акыллы киңәшләре аңа әнә ничек ярдәм итә! Әтисез малайның китек күңелен рәнҗетүчеләр күп бу дөньяда. Шуны чынбарлыктагыча күрсәтү әсәрнең яңгырашын көчәйтә. Шул ук вакытта дөньяның яхшы кешеләре дә бихисап. Сугыш утларын кичкән мәктәп директоры Хәнифә Вәлиулловнаның малайга өлкән

сыйныфларда укырга акчаны үз исәбеннән түләп баруы да укучы күңелен йомшатып җибәрә. Гомумән, бу ханым кешене анлый белүе, хәл-әхвәлләрне дөрес бәяләве белән хөрмәт уята. Миңа ул сугыштан соңгы елларда үземә шундый ук ярдәм күрсәткән укытучыларым Ниса Хафизова, Галия Ногманова, Гөлсем Хөсәенова, Зәки Гайнанов, Каим Җиһаншин кебек укытучыларымны хәтерләтте. Миңа — сугыш ятименә — кайсы күлмәк, кайсы бишмәт, кайсы ботинка алып биреп (үз акчаларына!) никадәр игелек кылдылар бит алар. Андый кешеләр онытылмый, күңелне гомер буе җылытып тора. Баксаң, бу игелекле ханым да әдәби герой гына түгел икән бит, ул чын кеше булган! «Ике урам арасы» исемле документаль әсәрдә Хәнифә Вәлиулловнаның татар әдәбияты укытучысы икәнлеге дә әйтелә.

Тормыш юлында Хәнифә кебекләр очраган кеше адашмый, ахыр чиктә максатына илтә торган сукмакка төшми калмый. «Һәлакәт» повесте исә бу яктан капма-каршы фикерләр уята. Юлга чыктыңмы, сине төрле хәтәрләр сагалап кына тора. Гомер юлында да шулай. Әнә Фәләх тә байтак еллар шома гына бара: мәктәпне уңышлы тәмамлагач, Мәскәү институтларының берсенә барып керә. Үзе яратып йөргән Роза да аңа карата битараф түгел. Димәк, гомер юлының матур киләчәккә барып чыгачагына өмет тотарга була. Ләкин тормыш юлының як-ягында кешене ымсындырып торган нәрсәләр дә аз түгел. Шулардан менә болары аеруча хәтәр: байлык колы булу, җенси теләкләреңә баш була алмау, исереклек, әхлаксыз юллар белән түрәлеккә үрмәләү. Тик кешенең күңеле нык булса, әхлак кануннарына ихтирам белән караса, әлеге хәтәрләр яныннан күз йомып үтәргә аның ихтыяр көче җитә. Әнә шул эчке ныклыгының аерым мәлләрдә йомшарып куюы гомер бәясенә торырга да мөмкин. Наилә, Гасимә кебек, ир-ат аулауның бөтен нечкәлекләрен үзләштергән хатын-кызлар, күрер күзгә тәртипле генә Фәләхне дә үз кубызларына биетәләр. В. Нуруллин ир-атны мондый йөгәнсез аздыргычлардан сакланырга өнди, андый вакытлы мавыгуларны мәхәббәт белән бутарга ярамаганлыгын искәртә. Моннан бир-ике сәгать кенә элек үбешеп туя алмаган Гасимәнең, Фәләх бәхетсезлеккә юлыккач, тыныч күңел белән өенә кайтып китә алуы — бик гыйбрәтле күренеш. Фәләх — акыллы кеше. Әлбәттә, бу хәлләрдән ул тиешле нәтиҗәне ясар. Тик эш бик катлауланып өлгергән шул: үзенең аягы сынган, машинасына килеп бәрелгән мотоциклчы егет вафат булган, хатыны Розаның исә иренә булган соңгы ышанычы да шартлап өзелгән. Боларның һәммәсенә сәбәп бер — йөгәнсезлек. Азгын хатыннарны вакытында танып алып, алардан читләшә белмәү. Мондый нәрсәләр, әйе, әдәби әсәр битләрендә генә түгел, тормышның үзендә дә кешегә бик кыйммәткә төшә.

Тик бер генә нәрсә күңелне борчый: автор Гасимәне талантлы җырчы дип тәкъдим итә, шуның белән артистлар турында гайбәт сөйләргә яратучылар тегерменена су коя. Ә. Еникинең Рәшидәсе («Рәшә») Зөфәр иркенә ачлык-ялангачлык нәтиҗәсендә бирелә, ләкин соңыннан укучы күз алдында үзен аклый ала. Гасимә исә талантын пычрак белән буйый. Чынлыкта Гасимәләрне теләсә нинди һөнәр ияләре арасыннан табарга мөмкин иде бит. Сумкасы тулы хәмер, затлы ашау-эчү әйберләре булу хәтта аны сәүдә өлкәсендә эшләүчеләргә ныграк якынайта. Чын сәнгать кешесе андый була алмый, була икән, ул инде талант түгел. Талант һәм азгынлык — бер-берсе белән сыеша алмый торган нәрсәләр, минемчә.

Дөресен әйткәндә, әхлаксызлыкның тамырларын сәнгать кешеләре арасыннан түгел, өске катлаулардан эзләргә кирәк иде. А. Гыйләҗев «Балта кем кулында?», Р. Мөхәммәдиев «Кенәри — читлек кошы» романнарында шулай иттеләр дә. «Үзгәрүчеләрне» әнә ничек тулы итеп күрсәтеп бирде бу ике язучыбыз.

Үзгәртеп коруларны аклау өчен кайчакны «алга таба болай яшәргә мөмкин түгел иде» дигән дәлилне китерәләр. Ә менә киләчәктә дөрес итеп дөнья күрү ничек булачак, ул турыда рәтле-башлы гына сүз әйтү юк. Дөрес, коммунист җитәкчеләрнең кыланышы кырга сыймый башлаган иде. «Үзгәртүне» (дөресрәге — булганны җимерүне) башлап җибәргән Горбачев та, үзе күтәргән күсәкнең бер очы ахыр чиктә үз башына төшәр дип һич тә уйлап карамагандыр!

Күреп килдек: соңгы унъеллыкта партиянең халык алдында абруе юк чамасында иде. Коммунистларның җитәкчелек ысулларының яраксызлыгын, үсешне тоткарлавын күрсәтеп бирүгә язучыларыбыз да өлеш кертте. Шулар рәтендә В. Нуруллинны да атарга мөмкин. 1976 — 79 еллар арасында (әле партиянең, кем әйтмешли, «ыжгырып торган» вакытында) ул «Аккан су юлын табар» дигән повесть язды. Минем фикеремчә, турыдан-туры ачык итеп әйтелмәсә дә (әле ул елларда моны эшләү мөмкин түгел иде), әсәрнең объектив эчтәлегеннән килеп чыккан нәтиҗә бер: Шәйхи кебек райком секретарьлары җәмгыятьнең муенына

асылган авыр таш иде. Үтәлмәгән планны үтәлгән итеп югары оешмалар алдында яхшы атлы булып күренү дисеңме; авылның, районның язмышын чүп мисалына да күрмичә, хезмәт урынын шәхси мәнфәгатьләрдә файдалануны; үзенә ошамаган өчен генә менә дигән булдыклы кешеләргә көн күрсәтмәүме — һәммәсе дә булды. Партия билетын калкан итеп, шуның артында әхлакка хилаф гамәлләр кылуны табигый эш дип санаган Шәйхиләр читтән карап торган кешегә никадәр чирканыч тоелды. Шунысы куркыныч иде — кемгә дә булса кара гамәл кылынганда партия оешмасы секретаре «райком белән килешенгән» диде, райком исә обкомны сылтау итте, ә тегесе — үзәк комитетны. «Эт эткә, эт койрыкка» дигәндәй, сүзнең иясен табарга мөмкин булмаган хәл барлыкка килде. В. Нуруллин әсәрдә моны үтемле итеп күрсәтеп бирде. Шәйхиев кебекләрнең җәмгыять өчен авыр кискә булып әверелүенең алшартларын ачыклады.

Бу урында һәммәбез дә уйланырдай бер нәрсәгә игътибарны юнәлтәсем килә. Автор әлеге әсәрен җитмешенче елларның икенче яртысында язган. Анда Булат Вәлиев райком секретарена: «Синең шикелле намуссызлар партиядә җитәкче булып утырганда мин үземне партия әгъзасы дип саный алмыйм!» — дип чыгып китә. Ләкин мин, бу әсәр турында язып чыккан һәм В. Нуруллин иҗатын бераз белгән кеше буларак, повестьның ул еллардагы басмаларында мондый сүзләрне хәтерләмим.

Җитмешенче-сиксәненче еллар җитәкчеләре, берсеннән-берсе уздырып орденнар алды, күкрәкләренә Герой йолдызлары такты, котырына-котырына оҗмах мисалыдай йортлар салды. Әмма болар намуслы хезмәт нәтиҗәләре идеме соң? Юк, ди В. Нуруллин. Ул әлеге фикерен Булат белән Шәйхи мисалында нигезли. Булат орден алуга егерме дүрт елга сузылган фидакарь һәм намуслы хезмәте белән лаек булган. Шәйхи исә Герой йолдызын (әсәрнең унбиш ел элек язылган вариантында ул хәтта райком секретарьлыгыннан да төшеп кала) Булат кебекләргә иркенләп эшләргә ирек бирмәүе белән яулап ала. Бу районда «астына су керә» башлагач, икенче районның беренче секретаре итеп күчерелә. Әлбәттә, соңгы вариант дөреслеккә якынрак. Тик дөреслек үз вакытында җиткерелсә яхшырак буласы бит.

Моның белән нәрсә әйтергә телим: элек язган әйберләребезне хәзергегә яраклаштырып сипләмик. Алар да, үзебез кебек үк, шул вакыт җимеше. Мәгълүм әсәрләрне үзгәреш чорына «боруга» караганда, Г. Тукай әйтмешли, каләмнәр иркенәйгәч, элек әйтә алмаганнарны яңа әсәрләрдә языйк. Чөнки «заманча» сүзләр, фикерләр иске тукымада барыбер аерылып тора. Әсәр уйланганда ук анда теге яки бу карашны үткәрү өчен нигез булырга тиеш.

Ә менә авыл картларының мәчет бинасында механизаторлар училищесы ачуга ризалык бирмәүләрен, аны изге дип санауларын атеизм афәте хөкем сөргән бер вакытта искәртеп үтү, татар баласының үз ана телендә укырга тиешлеген яклап чыгу һәм тагын шундый «баш китәрлек» мәсьәләләргә кагылып үткәндә В. Нуруллинның милли рухны яклавын хәзер дә рәхмәт хисләре белән билгеләп китәргә кирәк.

Әйе, әсәрнең исеме үк диалектик характерда — «Аккан су юлын табар». Язмыш — хәрәкәттә генә була ала. Хәрәкәт исә вакытлы нәрсәләрне, ясалма каршылыкларны читкә этеп калдыра, үзе белән алга таба барырга сәләтле, киләчәге булган, мәңгелек күренешләрне генә ала. «Җавап бир, кеше!» повестындагы Ханәфи образы да әнә шулай юл читенә тибәрелгән кеше. Ул, алтмыш яшенә җиткәч, үзенең үткәннәренә йомгак ясый һәм... шул узылган гомерендәге бер генә эшен дә уңай бәяләми. Синең турыда башкалар әллә ниләр әйтергә мөмкин. Аларның белеп әйткәне бар, белмәгәне. Әмма үз-үзенә шундый рәхимсез хөкем чыгару — бик аяныч. Дөрес, Ханәфи дә, һәркемгә хас булганча, гомеренең шушылай заяга узуына, мәгънәсез булуына кемнәрнедер гаепле итәргә тырыша. Ләкин ахыр чиктә һәммәсе дә үзенә кайтып кала. Моны акылы белән аңлау аның күңелсез картлыгын тагын да бәхетсезрәк итә. Ханәфинең фаҗигасе шунда — ул, кешеләр арасында яшәп тә, картлык көнендә япа-ялгыз калган икән. Юк, ул урманда яшәми, авыл уртасында, болын кадәр өйдә тора. Тик аңа керүче дә, чыгучы да, кайтучы да, китүче дә юк. Капка төбендә утырса да, үтеп-китеп йөрүчеләр, әгәр ул үзе башлап сүз катмаса, дәшми генә узуны мәгъкуль күрәләр.

Безнең кешеләр алай ук усал түгел, алар гафу итүчән, миһербанлы, дип, В. Нуруллин белән бәхәсләшәсе дә килеп куя. Әмма кабат кайтып уйлангач, авторның әйтергә теләгәннәре белән ризалаша башлыйсың. Халык — мәрхәмәтле, киң күңелле, рәхимле. Ул әле дә Ханәфигә комачауламый, аның эшенә катышмый, шул ук вакытта битарафлык күрсәтә. Хатыны белән малае да аңардан өметләрен өзгәннәр, бу авыру, ялгыз, ярдәмгә мохтаҗ кеше өчен артык хафаланмыйлар.

Ханәфи нинди гамәлләре белән үзен кеше өчен иң яман хәлгә — ялгызлыкка дучар иткән? Капка төбендә утырган килеш ул көнен шул хакта уйланып уздыра.

Кеше үзенең бәхетле картлыгын яшьтән үк әзерләргә тиеш. Ханәфи нишләгән? Башта ул да дөрес юлда булган. Сугыштан да лейтенант дәрәҗәсе алып, күкрәгенә медальләр тагып кайта. Әгәр ул колхозчы, эшче, яисә укытучы булып эшләсә, бәлки, әйбәт кенә бер кеше булып яшәп тә китәр иде. Тик аңа районда финагент эшен тәкъдим итәләр. Берничә ел шул хезмәтне башкару аның кешелек сыйфатларын юкка чыгара.

Сугыштан соңгы һәм илленче еллардагы финагент кем ул? Ул — крестьянның бугазыннан алып налог түләтүче, түли алмаганнарның терлек-туарын, анысы да булмаса, өендәге күзгә күренердәй соңгы әйберләрен алып чыгып китүче. Бер сүз белән әйткәндә — жандарм. Мондый «эшне» теләсә кем башкара да алмый. Ханәфи үзенең кая, нинди мохиткә килеп кергәнен белгәндер, риза булган икән, димәк, мондый каты бәгырьлелеккә ул эчтән күпмедер әзер булган дигән сүз.

Укучы күрә: Ханәфигә намуслы яшәү өчен мөмкинлекләрне ходай үзе биргән. Аның хатыны Хәлимә кебекне, бар, эзләп кара. Ирен өрмәгән җиргә дә утыртмый, тәрбияле йөртә, кибетче булса да, сатып алучыларның бер тиененә дә керми. Ханәфи дә, күңеле йомшап китеп, авылда ялгыз калган әнисе турында уйлана башлый. Ниһаять, ул гаиләсе белән авылга күчеп кайта. Аңа колхозда рәислек эшен тапшыралар. Әмма финагентлык гадәте монда да артыннан калмый. Кеше исәбенә айнымыйча сәрхүшләнеп йөрүе, колхоз байлыгын үзенеке белән бутавы, күзенә чалынган һәр матур хатын-кызны ауларга омтылуы аны әкренләп түбәнгә тәгәрәтә.

Хәзер ул үзе кайчандыр рәнҗеткән кешеләрнең якты чыраена тилмереп утыра. Исмәгыйль исемле малайның арбасын печәне-ние белән ут төртеп яндырган... Каюмга авыру әнисен шифаханәгә алып бару өчен ат бирмәгән... Һи, саный китсәң, бихисап аның явызлыклары. Ләкин иң зур гөнаһысы — авылны таркатуы. Аның мәктәбен бетерүе, явызлыгы белән кешеләрне авылдан биздерүе. Аракы, зиналык белән генә мавыккан кешедә нинди затлылык булсын? Бу бәндәнең дә эче шулкадәр явызлык белән тулган, хәлен белергә килүче берденбер кеше Нурмыйга әле бүген дә борылып карамаслык дәрәҗәдә мәкерле сүзләр әйтеп җибәрә.

Кеше сөймәс шушы бәндәнең кыланышларын күргән укучы Хәлимә белән аның улы Хәсәннең изге күңеллелегенә сокланмый калмас. Үзләренә никадәр җәбер китергән Ханәфигә алар ел саен бәрәңгесен утыртышып, казып бирәләр. Моның янына пенсиясе дә өстәлгәч, яшәп ята теге. Ләкин мондый тормышны яшәү дип әйтеп буламы икән? Бары тик җан саклау гына бу. Номенклатурщикларның берсенә В. Нуруллин әнә шундый җәза бирә.

Әйе, партия номенклатурасына бер кереп алгач, мондый кешеләр гомер буе җитәкчелектә сөйрәлеп йөрделәр. Колхоз башлыгы булырга хәлләреннән килмәсә, андыйлар белән авыл советы рәисе урынын ямадылар, анда да берни майтара алмагач, бригадир иттеләр. Халык шулардан күпме михнәт күрде. В. Нуруллин, җәмгыятебезнең ярык тагарак алдында калуын күреп, «Җавап бир, кеше!» дип чаң сукты. Әмма хәзер бу хәлгә кем җавап бирә? Юк андый кеше. Менә шунысы иң аянычы да инде. Җимерергә осталар күп, юктан бар итүчеләр генә бик сирәк.

Язучы буларак, В. Нуруллин да үткәннәребез турында уйлана, бүгенгебез өчен борчыла. Каләм көче ярдәмендә җәмгыятебезне рухи савыктыру, киләчәгебезне өметле итүгә үзеннән өлеш кертергә омтыла. Әлбәттә, язучы эшчәнлегенең бу якларын уңай бәяләү белән бергә, аның хәзерге көнебез мәсьәләләренә сизгеррәк булуын да телисе килә. Кулында язучылык каләме булган кешедән халкыбыз күбрәкне көтәргә хаклы.

# Р. ФӘХРЕТДИНЕВ ШӘҖӘРӘСЕ

Халкыбызның күренекле фикер иясе Р. Фәхретдиневнең шәхесенә кагылышлы һәрбер яңа мәгълүмат аны хөрмәт итүче кешеләрдә кызыксыну уята. Галимнең үзе язган шәҗәрәсе һәм бу шәҗәрәнең Нәҗип Фәхретдинев төзегән варианты «Казан утлары» журналында (1984. № 1. 166—168 бб.) дөнья күргән иде. Шуннан соң 10 ел вакыт үтте, инде менә әлеге шәҗәрәләргә кайбер ачыклык вә төзәтмә кертү мөмкинлеге дә туды.

Р. Фәхретдинев шәҗәрәсендә Юлдаш бабай аерым урын тота. Шәҗәрәнең элек төзелгән вариантларында аның Шырдан (хәзерге Зеленодол районына кергән һәм Каюм Насыйри туган) авылыннан күчеп килүе хакында язылa. Р. Фәхретдинев ерак бабасының Кичүчат авылына кайчан күчеп утыруын телгә алмый, ә Н. Фәхретдинев исә, бу мәсьәләгә ачыклык кертеп, 1656—1657 еллар дип күрсәтә. Архив (Русия борынгы актлар дәүләт архивы, 350 ф., 2 тасв, 3801 с. б., 1359—1360 бб.) чыганаклары исә Юлдаш картның хәзерге Әлмәт якларына күчеп килүе бер гасыр соңрак булганлыгын раслый. Мәскәүдә без өйрәнгән өченче ревизия (1762 ел) материаллары (шунда ук, 350 ф., 2 тасв., 3801 с. б., 1359—1360 бб.) Юлдаш Ишкәевкә 1762 елда 72 яшь тулганлыгын күрсәтә. Димәк, ул 1690 елда туган, ә 1656—1657 еллар турында сүз алып бару урынсыз.

Кичүчат авылы рәсми чыганакларда беркайчан да Юлдаш авылы дип йөртелмәгән. Н. Фәхретдиневнең: «1918 елга кадәрле авылның чын исеме «Юлдаш» булып, кемдер Кичүчатына үзгәрттергән»,— дигән фикере дөреслеккә туры килеп бетми. Кичүчат авылының бер өлеше Юлдаш урамы яисә очы дип йөртелүе бәхәссез, ә менә аның тулаем исеме элек тә шулай булган. Н. Фәхретдиневнең югарыда күрсәтелгән фикерен ревизия материаллары һәм статистик әдәбият кире кага.

Юлдаш Ишкәев Кичүчат авылында 1747—1762 еллар арасында төпләнә. Документта 1747 елдан соң аның Керкәле авылыннан күчеп утыруы хакында әйтелә. Керкәлегә чаклы Кичүчатта да бераз яшәп алгандыр, бәлки, ләкин моңа ачыклык кертә алырлык документлар юк.

Саф татар авылы Шырданнан күчеп килгән икән, Юлдаш бабайның татар икәнлеге болай да аңлашыла шикелле. Әмма документларга таянып фикеребезне бернинди шик калдырмаслык итеп әйтү зыян итмәс. Чөнки Башкортстан матбугаты битләрендә элегрәк күренгәләгән имеш-мимешләрнең тагын бер калкып чыгуы ихтимал. Уфада кайберәүләрнең шушы юнәлештә эзләнүләр алып баруын беләбез. Монда типтәрләрнең башкорт кавеменнән чыкканлыгын «исбатлап» диссертация яклануын да искә алсак, мәсьәләнең гади түгел икәнлеге аңлашылыр. Кемнәрдер өнә шулай татар-башкорт арасына чөй кагарга тырыша. Кемдер безне тарихи дөреслектән читкә алып китеп буташтырырга маташа икән, көчле дәлилләр белән ялгыш фикерләрнең таралуына вакытында чик кую мөһим. Р. Фәхретдинев мирасы татар һәм башкорт халыкларының уртак хәзинәсе, бу зур шәхеснең милләте кем булуына карамастан, әлеге гаҗәеп байлыкны түкми-чәчми бергәләп һәм гадел өйрәнсәк, ике як та отар гына.

1762 елгы ревизия материалларында Юлдаш бабайның милләте күрсәтелмәсә дә, типтәр сословиесендә торганлыгы ачык чагыла «Типтәр»ләр турында тарихи язмалар күп. Дөррия Рамазанованың «Казан утлары»нда (1993, № 8) басылган «Урал буе татарлары: теле һәм әдәбияты» исемле зур күләмле мәкаләсен һәм Дамир Исхаковның аерым китап булып чыккан «Татары» (Яр Чаллы, 1993) хезмәтен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Авторларның икесе дә, архивлардан озак еллар дәвамында эзләнүләр алып барганнан соң, типтәрләр турында тарихи

дөреслекне тулы чагылдыруга ирешкәннәр. Шунлыктан, типтәр мәсьәләсенә аерым тукталып тормыйбыз. Авторлар ачык раслаганча, типтәр сословиесе күп милләт вәкилләреннән (татар, мари, чуваш h. б.) торган. Шулай ук башкорт сословиесенә дә башкорт, татар hәм башка милләт вәкилләре кергәнлеген документлар раслый.

Юлдаш картның hәм Кичүчат авылы халкының милләте татар, сословиесе типтәр була. Типтәрләр 1855 елда башкорт сословиесенә күчерелгәнлектән, авыл кешеләренә бирелгән рәсми документларда, сословиесен күз алдында тотып, «башкорт» дип яза башлыйлар. Моны Р. Фәхретдиневкә 1906 елда бирелгән паспорт раслый.

Юлдаш Ишкәев яшәгән заман төбәктәге татарларның зур өлеше типтәр сословиесендә исәпләнгәннәр, шуның белән бәррәттән, аларны, милләтен күз алдында тотып, татар дип йөртү традициясе 18 гасырда да яшәи, соңыннан исә сословие билгесе өстенлек ала. Моның шулай булганлыгын күп кенә документлар чагылдыра.

«Материалы по истории Башкирской АССР» (Том 4, кисәк 2. М., 1956. 156 б.) исемле җыентыкның 1764 елга караган документында Кичүчат hәм шул тирәдәге башка авыллардагы «типтәрләр» милләтләре белән аталганнар, ягъни татарлар дип күрсәтелгәннәр. Алар арасында Кичүчат авылыннан Юлдаш Ишкәев тә телгә алына.

Юлдаш Ишкәев hәм аның документта теркәлгән авылдашы Исмәгыйль Киләев ярыйсы гына хәлле кешеләр булганнар. Кичүчат авылы янындагы инешта hәрберсенең бер ташлы тегермәне эшләгән. 1762 елга чаклы Юлдаш картныңниндидер бер дәрәҗәгә (староста, старшина hәм башкалар) дә ия булуы мөмкин.

1762 елгы ревизия вакытында Юлдаш Ишкәевнең 4 улы теркәлә. Иң өлкәне — Аккол (43 яшь), икенчесе — Бикмәт (36 яшь), өченчесе — Морадым (34 яшь), дүртенчесе — Мөхәммәт (21 яшь). Аккол hәм Бикмәт — гаиләле, беренчесенең Рахманкол (17 яшь), икенчесенең Сөбханкол (17 яшь) исемле уллары була. Бикмәт hәм Сөбханкол, соңгысының улы Сәйфетдин hәм оныгы Фәхретдиннәр аша шәҗәрә Ризаэтдинга барып тоташа.


5 нче ревизия (1795 ел) материаллары Сөбханкол Бикмәтевнең Нәдер волостенда дәрәҗәле кеше — типтәрләрнең 4 нче командасы старшинасы икәнлеген күрсәтә. Бәлки башка ревизия (6—10 ревизия) материалларында, Сөбханколның улы Сәйфетдин hәм оныгы Фәхретдин хакында да әhәмиятле мәгълүматлар бардыр, аларны барлау — киләчәк эше.

Р. Фәхретдинев hәм Н. Фәхретдиневләр төзегән шәҗәрәләрдә Юлдаш бабайның дүртенче улы Мөхәммәт телгә алынмый. Аккол Биккол дип, Морадым Морад дип күрсәтелә. Шәҗәрә гасырдан гасырга, телдән телгә күчеп килгәндә кайбер исемнәр онытылуы, яисә башкачарак формада әйтелә башлавы да мөмкин, шуңа күрә гаҗәпләнергә кирәкми.

Р. Фәхретдиневнең мирасын hәрьяклап өйрәнү сорала. Кызганыч ки, бу эш әлегә үзагымына куелган. Р. Фәхретдиневкә багышланган фәнни конференцияләр оештырып hәм аның күпсанлы хезмәтләрен бастырып, бу эшкә киң колач бирәсе иде.

**Таhир КӘРИМОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# ҮТКӘН ЗУРЛЫКЛАРГА КАЙТУ



*Ирәнҗән Хара-Дауан*

Калмык халкының асыл улы Ирәнҗән Хара-Дауан 1883 елда дөньяга килә. Петербургның Хәрби-медицина академиясендә белем алганнан соң ул Маныч улусында табиб булып эшли. 1919 елда Калмык далаларын деникинчылар яулап ала. Революциядән соңгы мәхшәргә түзә алмыйча, ул эмиграциягә китә. Югославиядә яшәп, шунда монгол тарихы белән шөгыльләнә башлый.

Хара-Дауан Чыңгыз ханның (1227—1927) үлеменә 700 ел тулуга багышлап монография яза. Моңа кадәр Аурупа һәм урыс галимнәре тарафыннан берьяклы гына өйрәнелгән тарихка ул, шул чорның сәяси, мәдәни биеклегеннән торып, объектив бәя бирүне үз алдына максат итеп куя.

«Бөтендөнья тарихында җуелмас эз калдырган монголлар һәм аның бөек юлбашчысы турында соңгы чорларга кадәр тар даирәдәге ориенталистлар гына кызыксынып килде. Урыс тарихында аерым бер урын тоткан монгол чорына артык игътибар бирелмәде. Бу дәвер күңлекче тарихчылар өчен «буш» бер дәвер булып килде. Югыйсә бит нәкъ шушы дәвердән, ана карынынан чыккан кебек, Мәскәү Русе яралды»,— дип яза ул.

Ирәнҗән Хара-Дауан үз чиратында совет кешесенә билгеле булмаган күп кенә чит ил чыганакларын өйрәнә. Милләте белән калмык буларак, монгол тарихы, Азия, Шәрекъ, Бөек Дала халыкларының язмышы аның йөрәгенә якын. Туган иленнән еракта ул, гасырларны кичеп, тарих төпкеленә, ата-бабаларының үткән юлына, учак урыннарына кайта. Канлы мөһер сугылган катлаулы чорлардан ул Чыңгыз хан — бөек җиһангир образын аралап ала һәм аның мәртәбәсен кырыс заманнар фонында сурәтләп бирә. Чыңгыз хан — аклауга да, каралтуларга да мохтаҗ каһарман түгел. Ул — Тәңре тарафыннан шулай яратылган. Кешелек сәхнәсендә аңа нәкъ менә шушындый тәхет-язмыш бирелгән. Чын тарихчы үткән заманга үчле караштан чыгып түгел, ә салкын акыл, олпат сабырлык белән бәя бирергә тиеш. Ирәнҗән Хара-Дауан, бу җәһәттән караганда, күпләргә үрнәк булырлык. Кызганыч, бу хезмәтен каткат эшләргә, тагын да баетырга аның вакыты булмаган. Китап «Чингис хан как полководец и его наследие» дигән исемдә Белградта 1929 елда урыс теленда басылып чыга. 1942 елда чит ил туфрагында Хара-Дауан дөнья куя.

Иң мөһиме шул: без моңа кадәр Мәскәү күзлегеннән торып кына тарих капкасына «туп кертүгә» күнегеп яшәдек, хәзер инде менә Сарай ягыннан «типкәнне» карап карыйк, ягъни Шәрекъ зыялылары тарафыннан язылган хезмәтләрне дә укып бәя бирик.

**Дөресен әйтик, без Юнан, Рим, Мәскәү дәверенә караган мәгълүматларны күбрәк беләбез, тарихта бернинди эз калдырмаган, эшчәнлекләре чамалы король, патшаларның, хәтта аларның сөяркәләре исемнәрен хәтерлибез, ә үзебезнең ата-бабалар язмышына караган чорлар, аннан-моннан гына йолкынып, эзлексез языла килде. Тарихны эзлекле өйрәнү өчен аның чишмә башына төшәргә, дисбе кебек, бер җепкә тезеп карый белү сорала. Шул чакта гына тарих үзенең яшерен серен-догасын ача, бибаһә мирас-хәзинә сакланган мәгарәләрнең ачкыч-тылсымын бирә.**

**Ә безнең чишмәбезнең бер тармагында мәһабәт кыя булып Чыңгыз хан, аның варислары, баһадирлар тора. Алар әмереннән дөнья, гасырлар хәрәкәткә килгән. Шуны белми торып, без мең еллык тарихыбызны гадел аңлау һәм кабул итү биеклегенә ирешә алмаячакбыз.**

**Менә шуларны искәртә бу кадерле хезмәт...**

**Дөньяда хакыйкатькә якын шундый сүз йөри: Чыңгыз хан турында язган кеше озак яшәми, диләр. Ирәнҗән Хара-Дауан, көчле шәхес буларак, гомерен кыскарту исәбенә булса да, бу олы эшкә тотынган. Шунысын да искәртик: урыс галимнәре тарихны берьяклы, үз сәяси-иҗтимагый күзлегеннән чыгып, ялган дан сөремендә язсалар, Ирәнҗән Хара-Дауан исә монголларга кан-кардәш милләт вәкиле буларак, шулай ук кайчакларда артык хис-тәэсиргә бирелеп ала. Ләкин ул барыбер күрәләтә ялганлау юлына басмый. Ни генә булмасын, аның бу хезмәте татар-монгол тарихындагы шушы чорга гадел бәя бирүдә урталыкны табарга ярдәм итәчәк.**

**Ирәнҗән Хара-Дауанның бу олуг хезмәтен мин бик мавыгып тәрҗемә кылдым. Һәм ул якын киләчәктә китап булып дөнья күрер дип өметләнәм. Ә журнал укучыларына шушы әсәрнең бер бүлеген — Чыңгыз хан варисларының Аурупага яу сәфәрен чагылдырган өлешен тәкъдим итәбез.**

**Марсель ГАЛИЕВ.**

## Аурупага яу сәфәре

Чыңгыз хан үлгәннән соң матәм ике елга сузыла. 1229 елда, каганның кече улы, вакытлыча хаким булып калган Тули яңа юлбашчы сайлау һәм бүтән дәүләт мәсьәләләрен карау өчен корылтай җыя Каганның васыяте буенча, олуг хан итеп Чыңгыз ханның өченче улы Үгедәй раслана. Үгедәй тәхеткә утыруга кырык көн буена каршы килә. Аны Тули белән берлектә ханзадәләр, гаскәр башлыклары, нойоннар үгетлиләр. Яңа каган каршында беренчеләрдән булып абыйсы Чыгтай баш ия. Шулай ук Үгедәйгә акыл иясе — Йәлү-Чутсайның да сүзе үтә.

Чыңгыз хан үлгәннән соң, вакытлы хаким кул астындагы мәмләкәттә ике ел буе бернинди чуалышлар купмый, үзара ызгыш-талашлар, бүлгәләнүләр дә күренми. Бу инде монгол империясенә нигез салучы һәм төпле кануннар кертүче бөек җиһангирның тотрыклы тәртипкә буйсындырылган дәүләт-мирас калдыруы хакында сөйли. Абыйлары барында кече туганны тәхеткә менгерү монголларда сирәк очрый торган хәл. Әмма җиһангирның сайлаганы уңышлы чыга. Кыска вакытта гына хакимлек итүенә карамастан, Үгедәй Чыңгыз нәселенең иң гадел һәм укымышлы каганнарының берсе була.

Иксез-чиксез кинлекләргә җәелгән мәмләкәт җиһангирның соңгы елларында дүрт улуска бүленә. Өлкән хатыны Бүртәдән туган дүрт улының санына карап шулай хәл ителә. Җучига төньяк-көнбатыш тараф — Алтайдан Җаекка кадәрге җирләр тия; көньягы Әму-Дәрья һәм Арал диңгезенә барып тоташа. Чыгтай өлешенә Әму-Дәрьяның көньягы — Төркестанның бер өлеше; Әфганстан, Фарсыстан, Кавказ арты керә. Үгедәйгә асыл монгол йортының бөтен көнбатыш ягы, Җунгария, Көнчыгыш Төркестан бирелә. Тули карамагына найман җирләре, монгол йортының көнчыгышы, Тангот һәм Цзинь дәүләтенең яуланган өлеше кала.

Чыңгыз ханнан калган йөз егерме тугыз меңлек гаскәренең (үз васыяте буенча) йөз дә бер мене «мең батыр» гвардиясе Тулигә бирелә. «Мең батыр» гвардиясе белән тангот кабиләсеннән чыккан Чаган идарә итә. Унбиш яшендә ул әсирлеккә эләгә, Чыңгыз хан Чаганны өенә Бүртә тәрбиясенә алып кайта. Бүртә аны «бишенче улым» дип йөртә.

Тагын Тули кул астына дүрт мең кешедән торган отряд бирелә. Бу дәрбән-ойрат кабиләсеннән торган чирү белән Хотуга бәк житәкчелек итә. Әлеге кабиләнең монгол мәмләкәте каршында һәртөрле казанышларын искә алып, бәкләрне, меңбашларын үз арасыннан билгеләп куюю хокукы бирелә. (Чыңгыз хан гаскәре белән ойратлар бик күп яуларда катнашалар. Жунгариядә яшәгән ойратлар кабиләсенә хәзерге көндә Идел-Дон арасында, Төньяк Кавказда, Хажитархан, Ставрополь өлкәсендә яшәүче калмыклар да керә.



*Чыңгыз хан*
*(1155—1227)*

Әби патша вакытында Убуши хан ойратларны кире Жунгариягә алып киткәч, бу кабиләнең Көньяк Россиядә калган өлеше «калмык» дип атала башлый).

«Мең батыр» (мең уражи) Чыңгыз хан васыяте буенча сугышта катнашмаска, ә жиһангир табуты куелган Бурхан-Халдан тавын сакларга тиеш була.

Калган варисларга егерме сигезәр мең яугирдән торган гаскәрләр кала. Шулардан дүрт меңе (тугыз мең тирмә белән), өч бәкне дә кертеп, Жучи хакимлегенә бирелә. Аның гаскәренә күп санлы урыслар, чиркәсләр, кыпчаклар, мажар һәм башка кабилә кешеләре кушыла (Рәшид-эт-Дин).

Корылтайда жиһангир варислары үтәп чыгарга тиешле өч мөһим мәсьәлә карала: 1) Төньяк Кытайны буйсындырып бетерү; 2) Һиндстаннан калкып, Көнчыгыш Иранның бер өлешен яуларга өлгергән һәм фарсы тәхетенә өмет сузган Жәләл-эт-Динне юк итү; 3) Аурупага яу чыгу.

Кытайда бу чорда монголларның хәле мактанырлык булмый. Мукали үлгәннән соң, заманында Чыңгыз хан яулаган жирләрнең хәтсез өлеше кулдан ычкына.

Кытайга каршы оештырылган яңа сәфәрдә гаскәр белән Үгедәй хан үзе житәкчелек итә. Ул күп яуларда сыналган абыйсы Жәбә нойонга таяна. Цзиньнәр, гадәттәгечә, кыр сугышында жиңеләләр, әмма көчле ныгытылган кальгаларга бикләнеп, бик каты каршылык күрсәтәләр. Чыңгыз хан әйтеп калдырган васыять буенча, Сун дәүләте белән үзара килешү төзегәч кенә жиңү монголлар ягына авыша башлый. Ниһаять, 1235 елда журжәннәр династиясе жимерелә, Алтын патшалык (Суннарга бирелгән өлешен санамаганда) тулысы белән диярлек Монгол мәмләкәтенә кушыла.

Цзиньнәрнең жиңеләсе билгеле булгач, Жәләлетдингә каршы гаскәр жибәрелә. Чармаган житәкләгән бу гаскәр, артык көчәнмичә генә, жиңүләргә ирешә, яуланган жирләрне кабат кайтарып ала. Жәләлетдин көрдләргә кача һәм шунда үтерелә. Моннан соң инде монголлар хакимлеге Төньяк Һиндстанга кадәр жәелә. Солтан Бабыр тара-



*Эчке Монголиядә*
*Чыңгыз ханга куелган һәйкәл*

фыннан монда башкаласы Дәһли булган «Бөек Могол» династиясе башлана. Әзәрбайҗан, Көрдестан, Кавказ арты һәм Анадулының бер өлеше Монгол империясенә керә. Хәзер инде өченче бурыч — атларны Аурупага карату бурычы алга куела.

Көнчыгыш Аурупага сәфәр 1222—1223 еллардагы һөҗүм вакытында ук алдан хәл ителеп куела. Һәм бу җирләр Жучи өлешенә билгеләнә. Ләкин аның үлеп китүе сәбәпле, төбәк белән идарә итү аның улы Батуга кала. Аурупаны яулауда төп көч-максат Батуга төшә. Чыңгыз хан нәселеннән тагын бу походта Үгедәй улы Гүйүк, Тули улы Мәнгү һәм Чыгтайның уллары Бандар белән Кадан катнаша. Бату чирүнең юлбашчысы итеп куела. Аның ярдәмчесе итеп кайчандыр Көнчыгыш Аурупаның «һавасын иснәп» кайткан Сүбүдәй билгеләнә. Болар барысы да Цзинь кампаниясеннән соң, 1235 елда уздырылган Корылтайда хәл ителә. Походка ике ел буена бик ныклап әзерләнәләр.

Ә бу вакытта урыс кенәзләре, көнчыгыштан нинди күкрәү-яшен киләсен гамьнәренә дә алмыйча, үзара сугышып-ызгышып яталар. Аларның таркау, низаглы яшәү рәвешләре хакында монголлар бик яхшы беләләр. Әйе, кенәз Владимирның ваемсыз варислары Калка елгасы буенда нинди сабак бирелгәнен бик тиз хәтердән чыгаралар шул.

Җеп очлары Сүбүдәй кулында булган үткен шымчы һәм күзәтчеләр Көнчыгыш Аурупада гына тукталып калмыйча, тагын да арырак үтәләр. Венецианлылар аша Сүбүдәй Аурупаның һәртөрле иҗтимагый катлаулары белән бәйләнешкә керә. Рэнк фикеренчә, Папа үзе дә Сүбүдәй өчен буй җитмәс арада тормый. «Папа бер якка да катышмаска уйлыймы, төрки Азияне христианлаштыруда олуг ханга ирек куямы?.. Ни булса да, Папа изге сугыш игълан итүне һаман суза, ул кузгалганда инде бик соң була, Көнбатыш халкы монголларны Рим (Герман) императорына каршы котыртып ул китерде дип, Папаны ачыктан-ачык каһәрли» (Рэнк).

Ләкин бу вакыйгалар хакында сүз алдарак булыр, ә хәзергә... монголларның Русиягә яу чыгарга җыенган чагын күрәбез. Генерал Иванин фикеренчә, Батуның алдагы җиңүләрен, Чыңгыз ханныкы кебек үк, кыргый батырлыкка яисә гаскәрнең күп санлылыгына бәйле дип кенә карап булмый. Монда чирүнең ныклы төзелеше, тактик әзерлеге, дошманның рухи һәм матди халәтен алдан өйрәнүе, шулай ук югары хәрби җитәкчелекнең сәнгатьле алымнар куллана белү осталыгы да зур урын тота. Һәрьяклы белешмәләр, безнеңчә әйтсәк, баш штаб офицерлары юртаҗилар тарафыннан туплана. Плано Карпини мәгълүматларына караганда, монголлар Аурупаны унсигез ел эчендә яулап алырга карар кылалар. Димәк, Аурупа хакындагы белешмәләр алдан ук җыелып анык план инде төзелгән була.

Шулай итеп Русиягә каршы «татар-монгол һөҗүме» дигән атама алган яу әзерләнеп бетә. Бу яуның юнәлеш бирүчесе, акыл иясе Сүбүдәй баһадир була. Кайбер белгечләр язуынча, ул «хәрби-оператив» үзәк белән идарә итә.

Русиягә якынлашкан армиянең саны хакында төпле чыганаклар юк. Урта Азия сугышында Чыңгыз хан ике йөз утыз мең кешелек гаскәрне җитәкли, бу очракта да шуннан артык булуы һич мөмкин түгел. Әлбәттә, ул чордан соң инде унҗиде ел вакыт үткән, монгол мәмләкәтенең чикләре дә киңәйгән, халык саны да арткан. Ләкин Көнчыгышта Кытай, көньякта Фарсыстан чиген сакларга кирәк, әле Сун һәм Һиндстан яуланмаган.

Курыкканга куш күренә, урыс елъязмачылары Бату чирүен «исәпсез-хисапсыз» дип, «ат тояклары астында җир тетри, ыңгыраша», дип язалар. Җиңеп, ыргылып килгән дошманга карата мондый бәя бирү табигый, әлбәттә. Хәер, генерал Иванин Бату гаскәриләренең саны алты йөз меңгә җиткән, дип яза. Бәлки бу сан Русиягә генә түгел, Көнчыгыш Аурупага каршы 1241 елгы кампанияне дә күздә тотып әйтелгәндер. Бату Кара диңгез буе далаларында ике ел булып, Көнчыгыш Аурупадан үз хакимлеген урнаштырганнан соң, чынлап та чирүен һәртөрле күчмә кабиләләр хисабына көчәйткәндер. Генерал Иванин Бату гаскәренең этник ягын өйрәнеп, анда монголлар бер йөз алтмыш дүрт меңнән артмый, ә калганы Чыңгыз хан дәверендә яуланган кабилә яугирләреннән тора, ди. Ләкин Чыңгыз хан үлгәннән соң, Русиягә сәфәр чыкканчы тугыз ел вакыт үтә һәм бу дәвердә Жучи улусы чикләрендә бернинди дә сугыш булмый, шуңа күрә 1236 елда яңа яуланган кабиләләрдән дүрт йөз мең гаскәрине берничек тә туплау мөмкин түгел.

1236 елда Русиягә бәреп кергән Бату гаскәрендә 122 дән 150 меңгә кадәр кеше булган. Бу — дөреслеккә туры килә. Бүлгәләнеп беткән, таркау урыс кенәзлекләрен туздыру өчен бу сан артыгы белән җиткән. Бату гаскәренең күп өлешен Жучи улусына кергән мөсе-

лманнар алып тора. Монда шулай ук мәрхүм Жучиның гаскәре дә, Чыгтай, Тули һәм олуг Үгедәй ханның да хәрби көчләре була. Җәмгысы — тулы монгол чирүенең өчтән бере.

1236 елның иртә язында гаскәр Иртеш елгасының югары агымыннан һәм Көнбатыш Алтайдан кузгала. Киң фронт белән тарихи Җаек-Каспий капкасыннан чыгып, июньдә инде Иделгә килеп җитә. 1223 елгы орышны онытмаган Сүбүдәй, гаскәрнең бер өлешен алып, Кама болгарларына «сабак укытырга» китә. Тегe чакта болгарлар Сүбүдәй белән Җәбәне шактый талкып җибәргән булалар. Менә хәзер шуның үчен алу көне җитә. Болгарлар бөтенләй кырылып бетү алдында кала. Төп гаскәр алдыннан бик аз санлы болгарларны гына махсус азат итеп җибәрәләр, монгол явы хакында дәһшәтле хәбәр тарату өчен тере шаһитлар булarak кына аларны исән калдыралар.

Әмма бу очракта әлеге шаһитларның әллә ни тәэсире булмый, урыс кенәзлекләре чигендә монголлар гел каршылыкка юлыгып торалар. Батуның буйсыну таләп итүенә каршы кенәзләр аның илчеләрен кыйнап, мәсхәрә итеп җибәрәләр. Киевтә дә Мәнге белән җибәрелгән илчеләрне шулай кыйнап кайтарганнар иде бит.

1237 елда инде Бату урыс җиренә 1223 елдагы кебек дуслык-килешү эзләп түгел, ә ясак салырга һәм колларга ия булырга дип килә.

Сүбүдәй болгарларны кыерлаган арада, төп көч белән Бату кыпчак, буртас, мукшы, чиркәс җирләрен, Русьның көньяк чикләрендә Каспий һәм Азов диңгезләре арасындагы киңлекне яулап өлгерә. Шушы менә диган далага таралып, Бату гаскәре ел буе кинәнеп ала.

Кыш башында монголлар Рязань кенәзлеге чигенә килеп җитәләр. Беркемнән ярдәм алмаган Рязань кенәзе гаскәрен кырда тар-мар итеп, Пронск шәһәрен билиләр, 1237 елның 21 декабрендә, алты көнлек штурмнан соң, Рязань каласы бирелә.

Бату кыш уртасында Русиянең төньягына үтеп керә. Мондагы күлләр, елгалар, баткак сазлыклар, кара урманнар аша бары тик кышын гына үтеп буласын Бату алдан ук өйрәнеп кузгала.

Стратегик яктан чыгып караганда, башта көньяктагы урыс кенәзлекләрен яулап бетереп, аннары гына төньякка күчәргә кирәк түгел иде микән? Бу сорауга генерал Иванин бәхәскә урын калдырмаслык җавап бирә. Әгәр Бату башта Көньяк Руська һөҗүм ясаса, төньяктагы көчле кенәзлекләр каршы торыр өчен ныграк әзерләнергә өлгерерләр иде, ә инде көньяк кенәзлекләр сугышны кабул итмичә чигенерләр дә төньяклар белән кушылып өстәмә көч тупларлар иде. Бу шартларда инде сугыш халәте язгы кар суларына кадәр сузылыр, атлы гаскәр бик кыен хәлдә калыр иде. Иң дөрес юл — төньяк кенәзлекләрен кыска арада тар-мар итү. Кышкы сәфәрнең үз кыенлыклары да бар. Атларга фуражны җирле халыктан каерып алып кына котылырга була. Уңай ягы шул: дошман кышын саклану чарасы күреп, тирән чокырлар казый алмый.

Рязаньнан соң Бату Коломнаны ала. Мәскәүне бик тиз генә тез чүктереп, амбар-складларны бушатканнан соң, монголлар 1238 елның 3 февралендә башкалага — Владимирга килеп җитәләр. Дүрт көннән шәһәр бирелә. Рязаньнан Мәскәүгә, аннан Владимирга маневр ясап, Бату уң яктагы иң көчле дошман — Суздальнең олуг кенәзе Юрий биләмәсен әйләнеп үтә, аның төньякка чигенер юлын кисә. Шулай итмәсә, кенәз Юрий Бөек Новгород һәм Псков гаскәрләре белән кушылыр иде. Үз янтыгына көтмәгәндә һөҗүм ясалмасын өчен Бату Торжок шәһәре ягына махсус отряд җибәрә.

«Суздаль гаскәре төньяктарак төпләнер өчен әйләнү юллар эзләргә мәҗбүр була, шуның өчен, Сити елгасы ярына чигенеп, урын җайлый. Әмма Батуның оста, житез хәрәкәте олуг кенәзнең әзерлеген боза» (М. И. Иванин). Дүртенче мартта олуг кенәз бик уңайсыз шартларда яуга чыгарга мәҗбүр була. Сити елгасы буендагы орышта олуг кенәз һәлак була, гаскәре бөтенләй диярлек кырып салына.

Озакламый Торжок белән Тверь шәһәрләре тез чүгә. Бату хәзер инде Бөек Новгородка юл тота. Ул псковлылар барып кушылмаслык юл сайлап бара. Ләкин март азагында, кар җепши башлагач, Новгородка 200 чакрым кала гаскәрне көньякка бора.

Бу очракка карата да М. И. Иванинның үз фаразы бар:

«Новгородка ул апрель уртасында килеп җиткән булыр иде, ләкин бу төбәкләрдә кай елны март аеннан ук елгалар боздан арчыла башлый, үтеп булмаслык җепшек кар баткаклыклары пәйда була. Монголлар Рязаньнан мең чакрымга якын ара кар ерып, юл сабып үтәләр. Бары тик дала халкының атлары гына мондый юлга түзә ала, хәер, алар да күпне кичергәндер: алда әллә ни көтә — кара урманнар, Новгород сазлыклары, сугышчан шәһәрне камау... Новгород тирәсендәге юеш үлән-

нән дала атлары күбенеп кырылмас идеме?! Камау озакка сузылса, гаскәрне ничек туйдырырга?.. Шулай итеп Бату Новгородка 200 чакрым ара калгач, хәлнең аяныч булачагын аңлый... һәм нинди бай калжаны — сәүдәле Новгород белән Псковны калдырып, гаскәрен кире бора. Ул чорның бай шәһәре Смоленск та шул сәбәп аркасында исән кала».

Батуның кире кайту юлы хакында елъязмалар бик саран мәгълүмат бирәләр. Козельск шәһәренең алты көн буе батырларча саклануы хакындагы легенда аша Бату гаскәренең шул төбәктән кайтырга чыгуын белеп була. Аннан гаскәр кыпчак далаларына, Донның түбән агымына таба төшеп китә.

Шул елның Николин көнендә (бер төрле тарихчылар 9 май, икенчеләре — 6 декабрь диләр), озакка сузылмаган камалыштан соң, Киев алына. Шәһәр җимерелә, яндырыла, халкы кырып салына (монголларның аяусызлыгы киевлеләрнең Чыңгыз нәселеннән ханзадә җитәкчелегендәге илчеләрне үтерүе өчен үч алу белән аңлатыла). Моннан соң инде монголлар, Галиция кенәзлекләрен буйсындырып, Карпат тауларының итәгенә барып җитәләр. Шулай итеп Русь җирләрен яулау тәгәлләнә.

Урыс кенәзләрен тулысынча буйсындырып, ясак түләү шарты куйганнан соң, үзенең тылы турында борчылмыйча, Бату Аурупаны яулау кебек олы бурычны тормышка ашырырга керешә



*Монгол гаскәрләре яуда*

Бу авыр походтан соң, монголлар атларны да, гаскәриләрне дә ашатып ял иттерү өчен бөтен шартлары да булган Кара диңгез буе далаларында ике еллап гомер уздыралар. Бу дәвер хакында да елъязмаларда әллә ни мәгълүмат юк. Бары тик көньяк кенәзлекләрнең иң көчле шәһәре — Черниговны камаган вакытта монголларның зур-зур ташлар ыргыттырулары билгеле.

1240 елда Киев бусагасына кара болыт булып монгол чирүе якынлаша. Ни өчен бу кадәр көч кузгатыла? Югыйсә бит «урыс шәһәрләренең анасы»н азрак санлы гаскәр белән дә алырга мөмкин иде. Хикмәт шунда: Киев Көнчыгыш Аурупа илләренә ачыласы капка, аннары инде гаскәр алга ыргылачак.

алыр хәлгә җитә. Сәяси халәт моңа уңай килеп тора. Аурупа илләре хакимнәренең үзара тартышкан чагы, Папа исә үзенең мәртәбәле дәрәҗәсе белән азиат дошманнарына каршы көчләрне берләштерә алыр иде дә... әмма ул катгый карарга килүне һаман суза.

Карпат итәгендә Бату хәрби киңәшмә җыя, гаскәр башлыклары Аурупага һөҗүм итүне хуплыйлар. Моның өчен сәбәп тә чыгып тора. Мажарстан монголлардан кырык меңлек гаскәре белән качып киткән кыпчак кенәзе Кунга сыеныр урын бирә. Ә монголлар кыпчакларны үзләренең ясакчылары һәм коллары дип саный. Бату Мажарстан короле Бела IV тән кыпчакларны кайтарып бирүне сорый, әгәр инде тыңламаса, сугыш ачачагын әйтеп, уль-

тиматум җибәрә. Бела бу таләпне кире кага. Бәхәс корал теленә күчә. Монголлар, һич тә кыенсынып тормыйча, гаскәри көчне Маҗарстан белән күрше илләргә дә җәеп җибәрәләр. Ян-якта дуслык мөнәсәбәтләренә бик үк атлыгып тормаган халыкларның кораллы көчләрен болай гына калдыра алмыйлар ич алар.

Польшага күзәтчелек өчен, күпмедер байлык та талап кайту максаты белән, Киев тирәсеннән ук берничә отряд җибәрелгән була. 1240 елда бер отряд Люблинга житә, аннан табыш эләктереп, Галиция аша яңадан Киевкә кайталар. Икенче отряд Сандомирне талап чыга, Краковка килеп керә, тик анда уңышсызлыкка очрый.

Эшләр болайга киткәч, инде уң канатны ныгыту кирәклеге ачыклана. Бу максат өчен ике көчле отряд бүлеп бирелә: аның берсе Польшага, икенчесе Силезия белән Моравиягә юл тота. Сул канаттан ярдәмгә шундый ук отряд Трансильвания аша китә. Бату кул астындагы төп гаскәр Киевтән Будапештка кадәрге иң кыска араны сайлый, Карпат тауларын үтеп чыга. Уң һәм сул канаттагы отрядлар ул оборона сызыгын үткәндә ярдәм итеп торалар. Ә инде Маҗарстанда алар төп көчкә килеп кушылырга тиеш булалар.

Әлеге бурыч уңышлы үтәлә. Польшага бәреп кергән Бандар җитәкчелегендәге отряд Шидлов тирәсендә полякларны хәлиткеч җиңүгә ирешә, аннан соң монголлар Краковны яндыралар, Одер елгасын кичеп, Бреславльгә һөҗүм итәләр. Үз халкы бу шәһәрне алдан ук яндырып, ташлап китә, бары тик кальга эченә тупланганнар гына бик каты каршылык күрсәтә.

Лигниц янында, Кацбах елгасы ярында полякларның ярдәмгә килергә зур көчләре туплана икән, дигән хәбәр алынгач, Бандар гаскәренә Бреславль ныгытмасын камауны туктатырга боерык бирә, ике отрядны да туплап, дошманның утыз меңлек кыр гаскәренә каршы бара. 1241 елның 9 апрелендә Лигниц янында аяусыз каты бәрелеш була. Яу кырында алман һәм поляк рыцарьларының каймагы юк ителә. Монголлар да шактый күп югалтуга дучар булалар, ләкин барыбер җиңү Бардарга насыйп була. Орыш кырында җиңү рыцарьлар ягына авышкан бер мизгел булып ала, әмма монголлар, каушап калмыйча, үзләренең гадәти алымын кулланалар. Бу хакта соңыннан поляк, алман елъязмачылары шаккатып язалар. Аларга ул гадәттән тыш булып күренә. Монголлар бу очракта да таралып чигенә башлыйлар, дошман хәрби тәртибен бозып, чәчелеп, аларны эзәрлекләп килә. Монголлар, кинәт борылып, дошманны өлешләп-өлешләп юк итә, кыра башлый. Шушы ук алымны Калка елгасы буенда урыс кенәзләренә каршы да кулланган булалар. Монголлар, хәрби осталыклары буенча, Азиядә беренче урынны тота. Хәзер инде Лигниц сугышыннан соң, Азиянең хәрби сәнгате Аурупаныкыннан күпкә өстен икәне мәгълүм була. Монголларның рыцарьларны җиңүе аларның бөтен Көнбатыш Аурупаны яуларлык көчкә ия икәнлеген раслый.

Шулай итеп Польша һәм аны яклаган Тевтон ордены Бату гаскәре тарафыннан сафтан чыгарыла. Лигниц тирәләрен талаганнан соң, монголлар Моравиягә ябырыла, Чехия чикләренә кадәрге араны утка тотып, кылыч белән турап чыгалар. Чех короле Вацлав ачык кырда яуга чыгарга җөрьәт итми, читтә сак корырга, күршеләрен үз ягына аударырга ниятләп, илен ташлап китә. Ныгытмалы шәһәрләр Брно, Оломуцны сакларга ул кыю воеводасы Ярославны калдыра. Тәвәккәл воевода үз бурычын батырларча үти, әмма монголлар тукталып калмыйлар, аларның мәсьәләге — җиңүне хәрәкәттә эзләү, шуңа күрә көчле каршылык күрсәткән кальгаларны әйләнеп үтәләр дә, Маҗарстанның йөрәгенә җитеп килгән Батуның төп көченә кушылырга ашыгалар.

Король Бела IV Карпат сыртларында сак көйләүгә ныклы әһәмият бирми. Бату вак отрядларны сытып, 1241 елның мартында «урыс капкасы» аша Карпатны үтеп, Маҗар тигезлегенә килеп чыга. Юл уңаенда шәһәрләрне алаала корольлек башкаласына юл тота. Ике канаттан хәрәкәт иткән отрядлар да, төньяктан һәм көньяктан тау тезмәләрен үтеп, шушы үзәнлеккә төшәләр. Көньяк, ягъни сул канаттагы Кадан кул астындагы отряд Трансильванияне тез чүктереп кайтып төшә.

Король Бела үз иленең һәммә тарафына кынысыннан чыгарылган канлы кылыч тоттырып атчабарлар җибәрә. Ләкин аның болай гаскәр тупларга дигән нияте барып чыкмый. Чөнки аксөяк һәм гади халык арасында да корольнең дәрәҗәсе түбән төшкән була.

Ашыгыч кына тупланган гаскәре белән король Бела Будапештка кереп бикләнә. Үтә дә саллы ныгытылган бу шәһәрне шактый озакка сузылган кан дәрьясы коймыйча гына алырга кодрәт җитми. Ләкин монголларга күп гарнизон тупланган мондый көчле ныгытманы аркада калдыру да файдага түгел. Нишләргә? Бердәнбер юл кала: кальганы саклаучы гаскәрне ничек тә кырга

алдап чыгарырга. Ике ай буе дивар читендә торганнан соң, монголлар үзләренең күп сыналган, хәйләкәр хәрби алымын кулланып, ниятләренәирешәләр. Калкулык өстендә торган Бату дошман ягына карап шатланып кычкыра: «Болар минем кулдан ычкына алмый, әнә ничек, эт абзарындагы кебек өерелешкәннәр!». Тиссаның кушылдыгы Сайо елгасы ярында, нәкъ Сити елгасы буенда урысларны кырган кебек, дошманны бер яктан оста әйләнеп үтеп, мажар гаскәрен егып салалар. Хорват-мажарлардан торган алтмыш биш мең кешелек гаскәрнең илле алты мене яу кырында ятып кала.

Король үзе Далмациягә кача,аның туганы Коломан-Хорватия герцогы яралана һәм шул җәрәхәттән сихәтләнә алмыйча үлеп китә.

Бу җиңүдән соң инде җиңел генә кулга төшерелгән Будапешт талана, кылыч белән тураклана, ут гарасатыннан көл-күмергә әйләндерелә. Качып киткән мажар королен эзәрлекләү өчен Кадан житәкчелегендәге отряд билгеләнә. Төп гаскәр исә Мажарстанның иркен далаларында кышларга кала.

Бу чорның монгол гаскәре хакында бүгенге көнгә кадәр сакланган кыйммәтле тарихи чыганак бар. Аны шул елларның шаһите, галим, Сплитның архидиаконы язып калдырган. «Алар кыска буйлы, киң күкрәкле. Тышкы кыяфәтләре шөкәтсез: сакалсыз чырайлары җәлпәк, тупыйк борынлы, чепи күзләре бер-берсеннән ерак урнашкан. Киемнәре суык та, яңгыр да үткәрми, ике кат тиредән, мехы тышка әйләндерелгән, кабырчык сыман. Баш киемнәре күннән яки тимердән. Кораллары — кәкре кылыч, калкан, ук һәм җәя, ук очы тимердән яки сөяктән, безнекеннән дүрт бармакка озынрак. Ак яки кара байракларының ат кылыннан эшләнгән чуклары бар. Атлары бәләкәй, әмма бик чыдамнар, дагаланмаган килеш тә, кыргый кәҗә кебек, әллә нинди тарлавыкларны үтәләр, өч тәүлек тоташ чапканнан соң да аз ризык ашап, аз гына ял итүгә, тагын сафка басалар. Кешеләре дә азык-төлек ягын бик кайгыртмый шикелле, бәләкәйдән үк кырыс шартларда тәрбияләнгәннәр, күрәсең. Ипи ашамыйлар, бар ризыклары — ит, ат сөте (кымыз), ат каны эчәләр. Үзләре белән бик күп әсирләрне йөртәләр. Иң күбе кораллы куманнар (кыпчаклар). Аларны гаскәр алдыннан алып баралар, яу кырыннан тегеләрнең тайчанырга теләгәннәрен шунда ук сизеп алып үтерәләр. Монголлар үзләре сугышка бик теләп кермиләр. Һәлак булганнарын табутсыз гына күмәләр. Алар кичә алмаган елга юк. Зур елгаларны камыш көймә яисә һава өреп кабартылган бурдюк белән йөзеп чыгалар. Чатыр-тирмәләре киндердән яисә күннән. Алар коточкыч күп санлы, ләкин урдаларында бернинди кычкырыш-талаш, ыгы-зыгы күрмәссең. Алар газап-интегүне ирләрчә кичерәләр, үҗәт сугышалар».

Шул арада король Бела Загребта ун ай вакытын бушка уздырмый, монголларга каршы көч туплауны үзалдына максат итеп куя. Хорватия белән Далмациянең бер өлеше ул чакта Мажарстан карамагында була. Бела үзенең илчеләрен бөтен Көнбатыш Аурупага: Папага, Фридрих II гә, Чехия, Франция һәм Италиягә җибәрә. Бары тик Пападан гына хат килә. Ул монголларга каршы көрәшүгә фатиха бирә. Бела гаскәриләренең гөнаһларын ярлыкауны Алладан сораячагын белдерә.

Кадан отряды 1241 елның раштуасында Дунай бозын кичә, Бела эзләреннән Славония һәм Хорватия җирләрен гадәттән тыш тизлек белән үтеп, Загребны сугышып ала. Әмма король тагын качып өлгерә. Кадан Далматин кальгасы Клиссаны штурмлый, король шунда яшеренгән дип уйлый, ләкин Бела күршедә, су белән йаймаланган Трогир кальгасында була. Кадан анда хәбәрчесен җибәрә. Хәбәрче кальга дивары янына килеп хорват телендә болай дип кычкыра: «Җиңелмәс гаскәр башлыгы Бату хан әмерен җиткерәм: безгә чит каннан булган корольне һәм аның яраннарын тотып бирегез, шул чакта гына сезгә тимәячәкбез».

Король Бела корабка утырып материктан китеп өлгерә, Әдрән (Адриатик) диңгезнең Кралевац дигән кечкенә бер утравына туктала, аннары Рабе утравын сайлый. Кадан исә Клиссаны яулагач, Үгедәй каганның үлеме турында хәбәр ала, һәм бу ике кальганы да калдырып, кайту ягына кузгала. Отрядын бүлеп, диңгез буйлап җибәрә: хозур диңгез ярына урнашкан Свач, Дривает, Рагузу (Дубровник) шәһәрләре утка тотыла. Ә Каттаро шәһәре тәмам җимерелә. Босния талана, отряд Албания, Сербия, Болгарстан җирләрен тетрәтеп Бату белән кушылырга омтыла-ашыга. Бу илләрнең халыклары монгол явыннан калын урманнарга, тау араларына качып котыла.

Төп гаскәрнең кышлавыннан тагын бер отряд Австриягә фураж табу һәм ил эчендә шымчылык итү максатында җибәрелә. Бу отряд Нейштат шәһәренә житә, Венага кул сузымы ара кала, андагы халыкның бәхетенәдер, отрядны төп гаскәр тупланган урынга чакыртып алалар. Шулай итеп Бату армиясе Дунайны кичә, Болгарстанга керә, монда

аңа үз отряды белән Кадан килеп кушыла. Бату Острогон, Белград, Весприм һәм Джур калаларына һөҗүм ясый. Бу хәл 1242 елга туры килә.

Менә шунда Бату Үгедәй каганның 1241 елда үлгәнен ишетә. Кичекмәстән ул ханзадәләр белән киңәшмә җыя, монда төп мәсьәлә итеп яуланган Көнчыгыш Аурупа илләре һәм кальгалар штурмлаганда кулланылган бик күп санлы әсирләр язмышы карала. Киңәшмәдә шундый карарга киләләр: әсирләрне кырып бетерергә, яуланган илләрне үз хөкеменә калдырырга һәм гаскәрне Кара диңгез буе даласына алып чыгарга. Ә Бату үзе Корылтайда яңа каган сайлауда катнашырга тиеш була. Бату җитәкчелегендә киңәшмә кабул иткән карар тулысынча җиренә җиткереп үтәлә.

Гаскәр Бату әмере буенча Дунай тамагында җыела, монда барлау үткәреләләр. Бу урын очраклы рәвештә сайланмый. Хәрби киңәшмәдә Молдова һәм Болгарстанны Бату улусының көньяк-көнбатыш чиге итеп билгеләргә дигән карар чыгарыла. Бу улуслар белән идарә итү өчен Чыңгыз нәселеннән булган төмәнбәк Нугай билгеләнә. 1248 елда Нугай хакимлеген Сербия дә таный. Әлеге чик буе өлкәләреннән тау тезмәләре китә: Балкан сыртлары, Альп таулары дала кешесе, көтүчеләр өчен бернинди дә кыйммәткә ия булмый, шуңа күрә бу төбәкләргә үз көннәрен үзенчә күрергә мөмкинлек бирелә.

Шулай итеп монголның атлы гаскәре томырылып биләгән көнбатыш чикләр Әдрән диңгезгә килеп терәлә, Каттаро һәм Клиссо, Хорватиядә Загреб каласы, Вена тирәсендәге Нейштат шәһәреннән инде монголлар үз теләге белән кире борылалар.

Монголларның ат тоягы астында калмаган Аурупа илләре Үгедәй каганның үлеменә бурычлы. Мажарстан кампаниясе вакытында коточкыч дәһшәт тудырып, күкрәп килгән монгол чирүенә ул илләрнең берсе дә каршы торырга җөрьәт итмәс иде.

Мондагы яулар монгол гаскәренең тарихында данлы сәхифә калдыра.

Бату гаскәренең Карпат аша үтеп Сайо елгасы буендагы хәлиткеч җиңүенә кадәрге сугыш театры җәмгысы 4—5 айны эченә ала. Шушы кыска гына арада Аурупаның ике көчле мәмләкәтләре Польша һәм Мажарстан гаскәрләре юк ителә, өченче ил — Чехиянең чирүе сафтан чыгарыла, ә инде икенчел дәрәҗәдәге дошман гаскәрләрен әйтеп торасы да юк. Бу җиңүләрдә, әлбәттә, Чыңгыз ханның үзе күтәргән көрәштәше Сүбүдәй мөһим рольне уйнагандыр. Чөнки бу һөҗүмнәрнең планын ул төзи, гаскәр башына куелган яшь ханзадәләргә дә ул оста юнәлеш бирә. 1241 елгы яу шуны ачыклый: Аурупа чирүе тыгыз сафларда гына сугышырга сәләтле, аларның тупас, дорфа хәрби җитәкчеләрен елгыр, хәрәкәтчән, монгол гаскәрен шанлы җиңүләргә китергән бөек Чыңгыз ханның өйрәнчекләре, инде күпме яуларда сыналган чал чәчле гаскәр башлыклары белән чагыштырырлыкмыни!

«Көнбатыш Аурупа сәфәрендә монголларның зур, көчле гаскәре Чыңгыз хан стратегиясенә тугры кала: дошманның көчен таркатып, ваклап-өлешләп юк итү... Русиядә дә уңыш казанган бу алым Польшада да югары кимәлдә кулланыла. Чөнки монголлар бөтен дәүләт белән кубып саклануччы көчкә тап булмыйлар. Русиядә дә үзәктән таралырга омтылу үзен сиздерә, кенәзләр үз биләмәләрендә вотчина хуҗасы булырга омтылалар, аларда дәүләти һәм милли бердәмлеккә омтылу хисе җитлекмәгән була. Бу хәл Польшага да хас». (Г. Е. Грум-Гржимайло).

Аурупада «татарлар» дигән кушамат тагылган монголлар коточкыч тәэсир калдыра. Бу — кеше кавеме беркайчан да кичермәгән гарасатлы афәт дип бәяләнә. Моны көнбатышның кайбер архиерейлары Алла тарафыннан җибәрелгән җәза дип христиан карусызлыгы белән кабул итүләре хакында дулкынландырырлык итеп Матиеву Парис язып калдырган. «Алланың ихтыяры белән җибәрелгән золым ташкыны безнең өстән хакимлек иткәндә, соңгы яңалыкларны тыңлагач, королева Бланш (француз, короленең әнисе) кычкырып җибәрә: «Король Людовик, улым, сез кайда?». Король әнисе катына килеп: «Әнкәм, мин сезнең карамакта»,— ди. Шул чак ана тирән сулыш ала, күз яшенә буылып, нинди бәла якынлашканы хакында хатын-кыз буларак хәвефләнеп бәян итә: «Улым, түзеп булмаслык тавышлар ишетелә безгә, мондый куркыныч мәлдә нишләргә? Без барыбыз да, изге чиркәү белән бергә татарлар кулыннан бетәргә хөкем ителгәнбез!» Король хискә бирелмичә генә, сагышлы итеп әйтә куя: «Илаһи күкнең юатуы безгә таяныч бирә. Әгәр татарлар монда килеп җитәләр икән яки без татарлар артыннан яшәгән җирләренә барабыз икән, барыбер — без күккә ашачакбыз». Король әйткәннең мәгънәсе шул: «Без аларны җиңсәк тә, жинелсәк тә барыбер, диндарлар, газап чигүчеләр буларак, Алла катына менәчәкбез». Корольнең шушы мәгънәле сүзе

Франциянең аксөякләрен генә түгел, бөтен шәһәрләрнең гади халкын да рухландыра».

Аурупа шәһәрләрендәге кебек үк, Парижда да куркыныч афәтне туктатуны сорап гыйбадәт кылына. 1245 елда Папа Иннокентий IV Лионда киңәшмә үткәрә, менә шунда инде монгол каганына алтмыш биш яшьлек монах Плано Карпинины илче итеп җибәрергә дигән карарга киләләр. Аурупаны иңләп баручы монголларның әлегә яуланып алынмаган ил башлыклары белән мөнәсәбәтләре дә башка. Мисалга монгол каганының француз короленә мөрәҗәгатен китерик:

«Тәңре исеме белән мина буйсыныrга боерам, король Людовик, тантаналы игълан ит: тынычлык телисеңме, әллә сугышмы? Күк ихтыяры гамәлгә ашып, бөтен дөнья миңе җиһангир итеп танығач, җирдә илаһи тынычлык урнашачак, бәхетле халыклар шул чакта безнең ни кылганыбызны күрәчәкләр! Әгәр син Тәңре әмерен кире кагарга җөрьәт итәсең икән, җирем ерак, тауларым биек, дәрьям тирән, сездән курыкмыйм, дисең икән — Тәңре авырлыкларны җиңеләйтеп, ерак араны якынайтыр да безнең кодрәтне сиңа күрсәтер!»

Мәгърифәтле, гуманлы каган Үгедәй үлгәннән соңгы вакыйгаларга аз гына тукталыйк. Аның әйтеп калдырган хикмәтле сүзе бар: «Хан-хаким матди байлык туплау хакында кайгыртырга тиеш түгел, теге дөньядан барыбер әйләнеп кайта алмыйсың, шулай булгач, кылган эшеңне кешеләр йөрәгендә хәзинә итеп калдыр...» Үгедәй каганның бу сүзләре чынбарлыкта кылган эшләре белән һич тә аерылмый. Үгедәй үлгәч аның тол хатыны Түрәкә мәмләкәт белән идарә итүне үз кулына ала. Тәхеткә кемне утырту мәсьәләсендә дан яраткан Түрәкә кулы уйный. Бату ил башлыгы сайлау Корылтаенда катнашырга теләмичә Идел буе даласында торып кала. Җучи (Алтын Урда) улусында һәртөрле оештыру-дәүләт эшләрен кайгыртып йөри. Идел буенда, хәзерге Хаҗитарханнан (Әстерхан) ерак түгел урында мөселман осталары тарафыннан Алтын Урда башкаласы Сарай төзелә башлый.

Каракорымда Корылтай 1246 елда гына җыела. Түрәкә ханбикә теләге буенча, тәхеткә Үгедәйнең улы Гүйүк сайлана. Ул нибарысы ике ел хакимлек итеп кала.

Гүйүк үлгәннән соң, 1248 елда, тагын ил башлыгын сайлау мәрәкәсе кузгатыла. Бусында инде Батуның читтә каласы килми, ул Онон елгасы буенда җыелган Корылтайга кайта һәм, аның ихтыяры буенча, тәхеткә Түлинең олы улы Мәнгү сайлана.

Чыңгыз йортының өлкәне Батуның Мәнгүне сайлаганда йогынтысы никадәр көчле булганлыгына әлеге юллардан соң инанасың. Вильгельм Рубрукка Мәнгү каган болай ди:

«Кояш җиһанны ничек яктыртса, минем белән Батуның да хакими көче шулай бөтен халыкларга тарала. Без бер баштагы ике күз кебек, ике булса да, икесе дә бер тарафка карый».

Сарай шәһәрендә Батуның илчеләрне ничек кабул итүе хакында Плано Карпининың кызыклы язмасы бар. Үз күзләре белән барысын тамаша кылган Карпини болай дип яза: «Хатыннарының берсе белән Бату, император кебек, тәхеттә утыра. Аның туганнары, уллары һәм кенәзләре уртада, аннан еракта, түбәндәрәк эскәмиядә утыралар. Калганнар арырак җиргә урнаша. Ирләр уң кулда, хатын-кызлар — сулда. Илчеләрнең дә урыны сулда. Без дә, үз эшебезне кылып, сулга урнаштык. Тик, безне уңга күчерделәр...»

Бату 1256 елда үлә. Улы Сартак та үлү сәбәпле, Алтын Урда тәхетен Батуның энесе Бәркә ала. Ул мөселман динен кабул иткән беренче хан.

Бөек хан итеп Мәнгүне сайлау уңышлы чыга. Аның дәверендә Монгол мәмләкәте тагын да ныгый һәм чикләрен киңәйтә. Мәнгү хан Көньяк Кытайда сугышлар алып бара (Сун империясен тулысынча аның энесе Кубылай буйсындыра).

Мәнгү хан икенче энесе Һөләгүне Алгы Азияне яулап бетерергә җибәрә. 1252 елгы бу яуга Һөләгү бик җентекле әзерләнә.

Монгол гаскәре үтәчәк төбәктә көтүлекләр кагылынмаган килеш торсын өчен, Каракорым белән Бишбалык (Хангай сырты) арасындагы, Тунгай тауларыннан көнбатыштарак яшәүче күчмә халыкка тиз арада бу үзәнлекләрне калдырып китәргә боерыла. Шулай ук юлларны төзәтергә, тирән сулы елгалар аша күперләр салырга әмер бирелә. Фарсыстанда бик күп күләмдә он һәм шәраб әзерләнергә тиеш була. Кытайдан катапульта, ташатар, «грек уты», авыр уклар ата торган машиналарны эшләтү өчен мең кешелек белгеч — осталар чакыртыла.

Беренче бурычы итеп ул исмәгыйлиләр орденын тар-мар китерә (1256—1257 еллар) һәм Багдад хәлифәтен яулап ала. Сәләхетдиннең туганнан туганы, Сүриянең күп өлешен биләгән Насыйр Һөләгүгә буйсынуын белдерә (1259—1260 еллар).

Кубылай ханның хакимлек иткән чоры (1260—1265) монгол мәмләкәтенең чәчәк аткан дәверенә туры килә.

дип таныйлар күп тарихчылар. Аның кул астына иксез-чиксез җирләр, Аурупаның өчтән ике өлеше, Азиянең бөтенләе диярлек керә. Башкаланы ул Ханбалыкка күчерә.

1283—87 елларда Югаргы Бирма, Тонкин, Югаргы Кохинхина һәм Зонд архипелагы монгол хакимлегенә буйсындырыла.

Кубылай хан чорында Монголиягә Будда дине үтеп керә. Чыңгыз хан варисларыннан беренче булып ул, галим Пагмалама йогынтысы белән, Будда динен кабул итә. Моңа кадәр әле Монголиядә шамаилык («карашаҗин») хөкем сөргән була.

Дөнья тарихында зурлыгы ягыннан чагыштырырлык мондый биниһая олы империя бүтән булмый.

Искәндәр Зөлкәрнәйн (Александр Македонский), Наполеон Бонапартларның җиһанны яулау хыялы Кубылай хан вакытында монголлар тарафыннан гамәлгә ашып бетә яза. Монгол мәмләкәтенең сәяси колачы нинди киң булуны XIII гасырның бөек монгол Корылтайларында катнашучылардан чыгып кына да бәяләргә була. Әлеге югары форумнарда бөтен Урда, Төньяк һәм Көнчыгыш Азиянең аксакаллары, урындагы хакимият эшлекләләре, урысның олуг кенәзләре, грузин һәм әрмән патшалары, сәлҗүк солтаннары, Кирмән һәм Мосул атабәкләре катнашканнар. Монгол хакимлегенең үзәгенә административ һәм сәүдә эшләре буенча бөтен кыйтгалардан агылганнар.

Троян дәверендә Рим империясе дөньяви әһәмияткә ия була. Аның варисы — Византия империясе Юстиниан чорында чәчәк ата. Рим һәм Византия көнбатыш һәм көнчыгыш культурасын берләштерә, әмма Византия таркалганнан соң бу роль Монгол мәмләкәтенә күчеп, җир эшкәртү — диңгезчелек, күчмәлек — дала культурасын берләштерүче көчкә әверелә. Монгол йогынтысы Кытайдан алып Балканга чаклы җәелә, римлеләрнең җир әйләнәсе (orbis terrarum) Византиянең Икумен (Җиһан) дип йөртелгән мәмләкәте, боларныкы белән чагыштырганда, бер кишәрлек булып кына кала.

Монгол мәмләкәтенең менә дигән халыкара хәлен аның аерылгысыз өлеше саналган Алтын Урда да ачык чагылдырып тора.

Кубылай хан хакимлек иткән чорда хәрби уңышлардан тыш, тыныч тормыш коруга да зур әһәмият бирелә, фән һәм әдәбият үсә. Аның дәверендә хан каналы казылып бетә. Үз кул астындагы халыкларга ул мәрхәмәтсез карамый. Монголларның «азиат мәдәнияте» Аурупаныкыннан бер ягы белән дә артка калмый, киресенчә, кайбер өлкәләрдә, бигрәк тә хәрби сәнгать үсешендә, алга да китә.

Кубылай хан Азияне соңгы карышына чаклы яулап бетерергә теләпме, 1274 елда Японияга ыргылып карый. Ләкин Цусима бугазында давыл куба, күп санлы флот, гаскәриләр белән бергә диңгез төбенә китә. Утрауларга урнашкан Япон илен яуларга тырышу, берничә гасырдан соң, нәкъ шушындый аяныч нәтиҗәгә китерә. 1904—1905 елларда шул ук Цусима утравы янында урыс эскадрасы җиңелүгә дучар ителә. Бу инде җиңүләрдән баш әйләнгәннән соң җиңел генә Японияне буйсындырып, диңгез державасына әйләнәсе килү кебек хата сәясәт нәтиҗәсе. Әмма Алла-Тәңре Японияне бирми...

Монгол мәмләкәтенең бик эчкәре яшеренгән йомшаклыгы — аның үз табигый чикләреннән гадәттән тыш киңлеккә җәелүе. Аурупага килеп җиткәч, тагын да яңа илләрне колачлыйсы килү кебек табигый теләкне авызлыклап, Бату зур акыллылык күрсәткән иде.

Ә Чыңгыз хан үлгәннең беренче унъеллыгында киресенчә була. Азиядә дәүләт чикләре табигый кысаларыннан бәреп чыгып Фарсыстан, Һиндстан, Кытайгача җәелә.

Кубылай ханнан соң монгол кодрәтенең йомшый башлавы сизелә. 1369 елда милли Миннәр династиясе идарәчелегендә Кытай аерылып чыга. 1380 елда Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий Донской Куликово кырында татарларны тәүге тапкыр җиңүгә ирешә. Ләкин моның белән алар әле тиз генә монгол хакимлегеннән котыла алмыйлар, шулай да... киләчәктә азатлыкка омтылу өметенә канат куярдай рух алалар.

Мәмләкәтнең башка төбәкләрендә дә улус белән идарә итүчеләр үзәкләштерелгән хакимияттән аерылу сәясәтен үткәрәләр. В. Бартольд фикеренчә, таркалу сәбәбе — күчмәннәрнең икътисади нигезен тәшкил иткән ыруларның таркалуында.

Шәхси тормышны бәйләп торган ыру милекчелеге хан нәселенең милекчелеге саналып, дәүләтчелеккә дә күчә. Нәселнең болай баюы аның бер әгъзасының икенчесеннән бәйсезлегенә, бердәмлекне җуюга китерә... Яуланган өлкәләрдә аерым бер ханзадәләр, энеабыйлары ярдәменнән башка да үз хакимлеген урнаштырырга кызыга башлыйлар: бөтен халык табынган, Чыңгыз хан кебек кодрәтле шәхес тотып тормагач, ханзадәләр әкренләп үзләре аерым дәүләт башлыклары булып ала-

лар. Ә бу инде туган белән туган арасында кан коюга китерә» (В. Бартольд).

Шулай итеп монгол тарихында бүлену башлана, ә бу инде таркалуга, тора-бара империянең җимерелүенә якынлаштыра.

Монгол мәмләкәте таркалуының Грум-Гржимайло башка сәбәпләрен дә күрә: дәүләт белән үзәкләшкән идарәне жую, административ һәм суд хакимлегенең аралашып бетүе, өзлексез сугышлар аркасында әхлакның тупаслануы. Ә инде Кытайдагы монгол династиясенең бетүе кәгазь акчаның инфляциягә килүеннән була. Тарихта беренче тапкыр Кубылай хан тарафыннан кертелгән кәгазь акча реформасы башта сәүдәнең үсешен тизләтә, ләкин тора-бара ассигнацияләрне күпләп чыгару кризиска китерә.

Әгәр монгол империясе «дала хакиме» булып кына яшәсә, көньяк-көнбатыштан төньяк-көнчыгышка кадәр, Аурупа һәм Азияне кисеп үткән географик дөньяга Чыңгыз хан нигез салган иде бит, оныгы Бату төгәлләгән иде, менә шушы дала киңлекләрен генә биләсә, монгол мәмләкәтенең язмышы бәлки башка юлдан китәр иде. Дәверләр үткәч инде монгол ханнарының бу җирләре «Ак патша»га күчә, безнең көннәрдә бәйсезлеккә ирешкән байтак җөмһүриятләрне тәшкил итә.

Мондагы халыклар — кайчандыр Чыңгыз хан һәм аның варислары кул астында шушы үзгә бер географик дөньяда күчеп йөргән халыкларның нәселе. Шулай итеп, бу ил — географик яктан гына түгел, этнографик яктан да Чыңгыз ханнан Русиягә вә башка мәмләкәтләргә күчкән мирас булып тора.

## Болгария һәм Сербиянең вассаллыгы

Мәскәү Русе Монгол империясенә йөз елга якын бәйле яшәсә дә, монахларның кыска, әмма хаталы язган елъязмаларыннан кала, урысларның бу дәвер хакында тарихи хезмәтләре юк. Хата дип юкка әйтмәдем, мисал өчен Калка елгасы буендагы сугышны елъязмачылар 1224 елга кертәләр, ә ул, бүтән ышанычлы чыганаклар буенча, 1223 елның 31 маена туры килә.

Ә инде монголларның Балканда булулары хакында бөтенләй аз язылган. Аурупаның монголиягә барган сәяхәтчеләре Плано Карпипи, Рубрук, Марко Полодан кала тарихи язмалары бөтенләй юк. Югыйсә бит Азиядә шул чорның замандашлары, Шәрекъ тарихчылары, фарсы, гарәп, кытай язучыләрдипләре тарафыннан иҗат ителгән күпме хезмәтләр дөнья күргән. Монголларның үзләренең дә тарихчылары билгеле.

Ни өчен юк? Моны бик гади аңлатырга мөмкин. Ул чакта әлегә яшь Аурупа, борынгы Азиягә караганда рухи җәһәттән дә, матди җәһәттән дә, культура ягыннан да түбәнрәк баскычта торган.

Урыста, бигрәк тә Балкан славяннарында укый-яза белү тик монастырьларда яшәүчеләрдә генә, ул да әле яралып кына килгән хәлдә була.

Бу очракта Болгарстан һәм Сербиянең Монгол империясе белән үзара бәйләнешы хакында бүгенге заман болгар, серб, хорват һәм далмат әдәбиятында әз-мәз генә күренеп киткән мәгълүматларга нигезләнеп йөгертеп кенә үтәрбез.

Инде белүебезчә, 1241 елның декабрендә Бату бөек монгол ханы Үгедәйнең үлеме һәм үзенең Каракорымга Корылтайга кайтырга тиешлеге турында хәбәр ала. Шуның өчен гаскәр Вена тирәсеннән һәм Әдрән диңгезе буеннан җыеп алына, Дунай тамагында гаскәрне барлау үткәрелә. Киңәшмәдә Молдова белән Болгарстаннан кала яулангaн башка җирләрне үз ихтыярларына калдырырга карар кылына. Кара диңгез алды җирләренә Чыңгыз йортыннан төмәнбәге Нугай идарәче итеп куела. Тарихчылар язуынча, ул бик акыллы һәм тәвәккәл булган.

1241 елда болгар патшасы Иван Асен II үлә. Аның дәверендә дәүләт бер учка тупланып өлгерә. Асеннан соң Болгарстан белән аның регентлары идарә итә, ләкин бу дәвердә, беренчелекне даулап, төрле өлкәләрдә үзара тарткалашулар башлана. 1242 елда Нугай бәк кабул иткәндә Болгарстан таркалу алдында тора. Нугайга — Алтын Урда ханнары идарәчесенә, болгар патшалары Коломан, Михаил Асен 1257 елга кадәр ясак түләп торалар. Аннан соңгы чор турында белешмәләр юк. 1265 елда Константин патша Алтын Урда ханы Бәркә һәм Нугай бәк белән, вассал дәрәҗәсендә, Византиягә яуга бара. Константинга моның өчен берниңди ташлама ясалмый, ул моннан берниңди дә файда күрми, дип яза болгар галиме Ников (Ников. Смилец пат-

шалык иткәндә урта гасырларда татар-болгар мөнәсәбәтләре. Гадишняк. Сов. унив. 1919—1920, София).

Болгар патшаларының бөек монгол ханнарына вассаллыгы хакында Рубрук та теркәп калдырган.

Болгар-монгол мөнәсәбәтләре хакында болгар тарихи истәлекләрендә бернинди дә чыганаклар юк, бу — ул чорда болгарларның укый-яза белмәве белән аңлатыладыр, ди галим Ников. Ул үз хезмәтен язганда Византия тарихчысы Пахимер истәлекләреннән файдалана.

Шулай итеп, 1265 елда Нугай бәк үзенең күпсанлы гаскәре белән Дунай тамагында болгарлар белән кушыла да Византиягә каршы яу чыга. Ни өчен соң әле Нугай бәк болгарлар белән Византиягә каршы бара? Сәбәбе бик гади: Византия императоры Михаил III Палеологка сәлҗүкнең элеккеге солтаны Изедин килеп, Ирандагы монгол ханы Һөләгүгә каршы сугышырга ярдәм сораган була. Монголның бу көчле ханына каршы барырлык дәрманы булмаган император Изединне кулга ала, аны берничә ел әсир хәлендә ябылуда тота. Аның тәхеттә утыручы туганы Рукнединнең үтенечен дә Византия императоры җавапсыз калдыра.

Шуннан соң сәлҗүк солтаны Рукнедин, вассалы буларак, көчледән көчле кыпчак, ягъни, Алтын Урда ханы Бәркәгә мөрәҗәгать итә. Царьградта әсирлектә яткан абыйсын коткарырга ярдәм итүен үтенә. Мисыр солтаны Байбарыстан да Бәркә хан шундый ук үтенеч ала. Менә шуңа күрә дә ул Нугай бәк җитәкчелегендә гаскәрен Византиягә озата.

Монгол-болгар гаскәрләре Палеолог VIII гаскәренә көтмәгәндә һөҗүм итәләр, император үзенең яраннарын, тәртип кысаларыннан чыккан гаскәрен ташлап чигенә, Мәрмәрә диңгезе буендагы Чанос авылына кача, аннары көймәгә утырып Царьградка килә.

Сәлҗүкнең элеккеге солтаны Изедин үзенең күпмедер яраннары, казнасы белән Енос кальгасында көн итә. Монгол-болгар гаскәре Марица елгасы тамагына урнашкан бу кальганы уратып ала һәм үзенең таләбен белдерә. Изединны яраннары белән кальгадан чыгаралар, шуннан соң гаскәр кальганы тынычлыкта калдыра. Монгол-болгарлар Фракияне туздырып, кайту ягына чыгалар.

Византияне җиңгән Нугай бәк 1264—65 елның кышында, әсирлектән котылган Изединне, аңа ун мең төрек әсирен иярте, Добруҗадан Сарайга озата. Бу отряд белән җитәкчелекне Сары Салтыкка тапшыра.

Шушы походтан соң инде Нугай бәк, җиңүче сыйфатында, Византия императоры Михаил Палеологның кызы Ефросиньяга өйләнә.

Гарәпнең Рукнедин, Байбарыс, Елмуфадел кебек тарихчылары, Бәркә хан, үлеме алдыннан, Нугай бәкне Царьградны алырга һәм Изединне коткарырга җибәрде, дип язалар. Ә калган мөселман тарихчылары исә — Ән-нувәйри, әл-Макризи, Мостафа әл-Җәнәби, Абелфад Изединне коткаручы Мәңгү Тимер дип баралар.

Бәркә хан һәм аның варисы Мәңгү Тимер үлгәннән соң Алтын Урдада үзара талаш-ызгыш-чуалышлар кузгалгалап тора, Монголиянең көчле үзәк хакимияте ныклыгын җуя башлый. Бу дәвердә Бәркә ханның оныгы, бөек Чыңгыз нәселеннән булган кенәз Нугайның дәрәҗәсе бермә-бер арта.

Дипломатик һәм хәрби яктан искиткеч сәләткә ия, Византияне җиңүче кенәз Нугайның Кыпчак-Алтын Урда ханлыгында йогынтысы гаять зур була. Кара диңгез буйлары, Дунай һәм Днепр тамагы, Көньяк Русь, шулай ук Болгарстан һәм Молдова җирләренең идарәчесе буларак, ул Алтын Урда ханнарына тулысынча буйсынуны да «оныта» башлый. Мәңгү Тимердән соң аның власте аеруча ныгый төшә. Кыпчак ханлыгында һәм Монгол мәмләкәтенең югары даирәсендәге туктаусыз ызгышлар шөһрәт һәм хакимлек яратучы, зирәк Нугай бәкне күп нәрсәгә ымсындыра. Сарай ханнарын ул куя, ул төшерә башлый. Кыпчак мәмләкәтендә ул ханның үзеннән дә зуррак кимәл тота, шуңа күрә аның Балканга йогынтысының никадәр көчле булуы хакында әйтеп тә торасы юк. Аның Византия императоры кызын хатынлыкка алуы гына да Монголия, Византия, Балкан дәүләтләренең халыкара мөнәсәбәтендә абруйлы урын тотуы хакында искәртә.

Ул чакта монгол отрядлары Византия буйлап үз өйләрендәге кебек йөрделәр, дип яза Пахимер.

XIII гасырның туксанынчы елларында Нугай бәк тагын да зәһәрләнә. Балкан дәүләтләренең патшалыклары берәм-берәм аның кул астына төшәләр: менә алар — Тырново патшалыгы, Видинское, Браничевск исемле бәйсез кенәзлекләр, Серб корольлеге...

Чиксез көчкә ия Нугай бәк Тырново тәхетенә менәргә болгар патшаларына фатиха бирә. Аның көчле йогынтысы бигрәк тә патша Тертерий I вакытында югары кимәлгә җитә. Тертерий кызын Нугай бәкнең улы Чокага кияүгә бирә, ә улы Светиславны Нугай

бәк урдасына нәзер итеп җибәрә. Бу инде ышаныч казану дигән сүз. Монгол ханнары үзләренең вассалларына карата һәрчак шундый алым кулланганнар. Русның бөек кенәзләре дә, болгар патшасы да, серб короле Мимотин дә бу гадәтне кабул итеп алалар.

Тертерий үзенең кызы һәм улын корбан итсә дә, нишләптер Нугай бәк аңа салкын карый. Тертерий хәтта, тәхетен калдырып, Византиягә качып китәргә мәҗбүр була, ләкин аны император Андроник кабул итми. Шулай итеп болгарның элеккеге патшасы, качак мисалында, Әдернә каласының бер читендә яшәргә хөкем ителә, күпмедер вакыттан соң византиялеләр аны тотып зинданга ябалар.

Һәр нәрсәнең үзенә күрә сәбәбе бар: ике бояр фиркасенең башлыклары Тертерий һәм Смилец арасында барган ызгыш-көрәштә соңгысы җиңеп чыга. Аңа Нугай бәк ярдәм иткән була. Оста дипломат буларак, ул берсенең дә үсеп китүен теләми. Менә ни өчен Нугай бәк Тертерийгә кырын караган икән.

Болгарияне тез чүктергәннән соң, Нугай бәк үз көчен Сербиягә җәелдерергә уйлый. Серб короле Милютинны Тертерий кызына дипломатик өйләндерү (1287) генә җитми әле монда (икенче кызы Нугай бәк килене).

1292 елда гына Сербия үз өстеннән Нугай бәк хакимлеген таный.

Сербиянең Монголиягә буйсыну сәбәпләре мондый: Нугай бәкнең вассалы Виндинск кенәзе Шишман, болгар һәм монгол гаскәрләре башлыгы буларак, көтмәгәндә Сербиягә басып керә, илне талый, архиепископ монастыреннең дә зиннәтле байлыгын чистартмакчы була. Моңа җавап рәвешендә Серб короле Видинны яулап ала. Ә кенәз Шишман, көймә белән Дунайны кичеп, качып китә. Король Мимотин, Шишман кенәзлеге белән генә канәгатьләнми, күрше Браничевск кенәзлегенә, ягъни, Нугай бәк вассаллыгына да кул суза.

Елъязмачы серб епископы Даниил теркәп калдырганча, кенәзләр Браничевский һәм Шишманский Нугай бәккә килеп серб кенәзеннән зарланалар, моңа җавап итеп Нугай бәк шунда ук гаскәренә атларны ияргә боера. Монгол, кыпчак, алан, осетин, урыслардан торган атлы гаскәр Сербияне тар-мар итәргә дип кузгала. Король Мимотин, бу кадәрле чирүгә каршы тора алмасын аңлагач, Нугай бәккә бай бүләкләр төяп вәкилләрен җибәрә, үзенең сүзсез буйсынуын белдерә. Нугай бәк, ышанычлы булсын өчен, корольдән үнҗиде яшьлек улын — варисы Стефанны, күренекле боярлар белән бергә, үзенә бирүне таләп итә. Бу теләк канәгатьләндерелә һәм Нугай бәк, разый калып, гаскәрен кире бора.

Дөнья тарихында барлык славяннарның да берләшү мчзгеле бер генә була. Бу — Батуның Көнбатышка, Әдрән диңгез, Сплинт-Загреб-Вена сызыгына кадәрге арага сәфәреннән сон Бөек Монгол мәмләкәте кул астында берләшү чоры.

Монгол мәмләкәте тарихының әлеге заманы шуның белән әһәмиятле: ул үз кул астында көнчыгыш славяннарны (урыс) балкан славяннары белән берләштерә. Русия үзе XVIII—XIX гасырларда инде, күпме генә тырышса да, моңа ирешә алмый. Күп төрле Балкан сугышлары да, Русиянең Сербияне яклавы аркасында чыккан Аурупа сугышы да көньяк славяннар белән уртак тел табуга китерми.

«Монгол империясенең балкан славяннарына карата сәяси йогынтысы урысларныкына караганда оешканрак, ачык мәгънәдә була, дип расларга мөмкин» (П. Н. Савицкий).

Әлбәттә, заманында Византияне җиңгән Нугай бәк үз вассаллыгындагы кенәзлекләргә басып кергән Серб королен болай гына калдырмаган булыр иде. Нишләсен, нәкъ шул чорда аның Алтын Урда ханы Туктай белән арасы кискенләшә. Туктай шулай ук Чыңгыз нәселеннән була. Ул Нугай бәкнең бәйсез сәясәт алып баруын кичерә алмый. Нугай бәкнең хакимлеге отыры көчәя бара, ул инде ханнардан ераклашып, үзгә юнәлеш алмакчы, моның өчен тәхеттәгеләр аңа сабак укытырга күптән кыҗрап яшиләр, ниһаять, бу миссияне үтәү Туктай хан җилкәсенә төшә.

Каганлык (хәзерге Одесса тирәсе) янында хәлиткеч орыш башлана. Туктай хан кенәз Нугай гаскәрен челпәрәмә китерә. Нугай бәкнең яугирләре яулангап өлкәләрдән җыештырылган булса, Туктай ханныкы электән дан-шөһрәт казанган монгол-татарлардан тора. Яу кырында карт кенәз Нугай яралана, чигенеп барганда Туктай ханның яугире куып җитеп, аны атып үтерә. Бу тарихи көн 1299 елның 28 сентябре.

Шуннан соң инде Нугай бәк идарәлегендәге җирләргә Алтын Урда ханнарының тулы хакимлеге җәелә. Дунайдагы Саикҗи (Ис-акча), Болгарстанның «Тимер капка» (Демиркапу) Туктай ханның олы улы Бөгилбәккә тия, икенче улы Ирбасси Буг елгасы буйларын били.

Нугай бәк үтерелгәннән соң, аның урдасында купкан ыгы-зыгыдан файдаланып, серб варисы Стефан үзенең бо-

ярлары белән качып китә һәм туган жиренә исән-имин кайтып егыла. Серб елъязмачысы Даниил сурәтләгәнчә, Стефанның исән икәнен бирәү дә белмәгән, илгә кайтып төшүен бирәү дә ышанып көтмәгән була.


Күпмедер вакыттан соң, ул, Стефан Деганский булып, Сербия тәхетенә менә. Шуның белән Сербиянең монгол мәмләкәтенә 1292 елдан 1299 елга кадәр сузылган вассаллыгына чик куела.

Туктай хан белән орыштан соң Нугай бәкнең улы Чока, исән калган иң ышанычлы мең сугышчысы белән Болгариягә һөҗүм итә. 1299 ел азагында Тырновоны яулап ала һәм тәхеткә утыра. Болгар патшасы Тертерийның кияве буларак, ул үзенең тәхеткә хокукы барлыгын раслый. Чока белән бергә Тертерийның улы Светислав та кайта. 1301 елның 6 октябрендә Чока буып үтерелә. Бер чыганаклар буенча аны, имеш, Светислав үтерә, икенче чыганакларда — Туктай хан кушуы буенча яһүд палачы үтерә, диелә. Соңыннан Чоканың башын Кырымга, Туктай ханга юллыйлар. Шулай итеп, болгар тәхетендә, азга гына булса да (ике ел) Чока, бөек Чыңгыз ханның оныгы утыра. Бу — бәхәссез тарихи факт, дип яза галим Ников.

Болгариягә монгол йогынтысы 1242 елдан алып 1301 елга кадәр... нибарысы 59 елга сузыла.

## Булат Солтанбәк

# ОЛПАТЛЫК



Өлкән яшьтә иде ул. Шулай да аны һич кенә дә карт, дип әйтергә тел әйләнми. Туксан дүртенче сәнәсендә гизүенә карамастан, тормышны сабыйларча ярата, алдагы елларга өмет-ниятләре турында дәртләнеп сөйли ул. Үзем күреп белгән кешеләрдән кемгәдер охшатам мин аны. Кемгә? Ә-ә, яһүдләрнең мәшһүр Виктор Шкловскиена бик тә тартым ул — ике замандаш та эре гәүдәле, тик Шкловский аңардан буйга бераз кайтышрак. Икесенең дә башлары бик зур. Тормыш дигәнең бу башларны уйлар дәрьясына күп манчыган, бу башлар үзләре дә дөньяны уйлар дәрьясына еш коендырган. Тавышлары да охшаш мәйдан тоткан ике замандашның. Хәзер дә, әңгәмәләребезнең язмаларын кабат тыңлаганда да, мин аның калын тавышына рәхәтләнеп сокланам — бу тавышта калтырауның нәни тирбәлеше дә юк. Ә ул җырлап җибәргәч, ил агаеның тулы бер гасыр чамасы яшәвен онытып ук торасың!

Бакый Идрис угълы Урманче ул. Россия Федерациясенең халык рәссамы. Татарстанның Тукай бүләге иясе. Табигать аңа сәләтне өеп биргән. Ул — скульптор, рәссам, график, сәхнә бизәүче, архитектор... Болары — аның югары биеклекләргә менгән, зур бүләкләр һәм мактаулы исемнәр белән билгеләнгән иҗаты өлкәләре. Сүз җаеннан шуны да әйтик, җәмәгатьчелек фикере буенча, аның олы-олпат хезмәте әлегә бик тә саран бәяләнде. Чөнки ул революция турындагы уйдырмаларны күкләргә чөючө һәм Татарстанның нык үскән социализмга атылып керүен мактаучы картиналар ясауда катнашмады. Шундый бик зур һәм чамасыз тупас картиналарның берсен хәзер дә хәтерлим әле: алда — маршал Гречконың мөгтәбәр фигурасы, ул урындагы шулай ук олы гәүдәле эшлеклегә чираттагы байракны тапшыра. Ә тирә-яктагылар дәррәү кубып кул чабалар — йөзләре күркәм, күңелләре нечкәрүдән күзләреннән яшь агарга тора. Хәзер бу картина кайда икән? Һәм мондый соцреализмның һәр квадрат метры безнең юмарт казнабызга күпмегә төште икән? Аны үз кадерен генә кайгыртучы, алырга мөмкин булган бүләкләрнең инде барысын да эләктергән кешеләр ясавын искәртсәк, моңа тотылган чыгымның чамасызлыгын чамалавы кыен булмас. Андыйларга эчтәлек, гаделлек дигән төшенчәләр ят, аларга ясарга гына булсын. Власть башында торучы кайбер агайларның үз исемнәрен мәңгеләштерергә омтылышлары да шундый картиналар әвәләнүгә этәргеч иде. Үз кадерен генә кайгыртучы һәр җитәкче агай, йә әлеге сыман картинада горур сурәтләнеп, яки, кем әйтмешли, ашатып иярләштерелгән берәве тарафыннан китап яздырып, иң киме — бер

ялагайдан портретын ясаттырып, тарихта эз калдырырга кызып-дәртләнеп телә-де. Миңа менә мондый хәл турында сөйләгәннәр иде. Түрәләр кәнәфиендә генә утырырга күнеккән бер ханым, иртән ишеге төбенә килеп туктаган «Волга»га чыгып утырыр алдыннан, кунак бүлмәсендәге үз портретына мөкиббән китеп карый икән. Анда ул, дөрес, бөтен буена түгел, ә бил тиңентен генә сурәтләнгән, әмма кулында житәкче булуның бер билгесе — телефон тәребкәсе бар икән! Үзенә күрә аутотренинг, көн буена житәрлек кодрәт җанга салынды ягъни.

Ә Бакый ага куштанланмады. Аңа мондый эшләрне тәкъдим дә итмәделәр. Чөнки чын рәссамның карашы, ясалма ялтыравыкны үтәли ярып, тирәнгә-еракка житә. Ышанасың икән — мондый эш тапшыра калсаң, горур кыяфәтле агайның рухи бушлыгын һәм тәрбиясезлеген күрүе бик тә ихтимал Бакый Урманченың. Рәсем сәнгатендә моңа мисаллар шактый. Әйтик, испан сарае даирәсе тормышыннан алып ясалган мәшһүр картиналарны искә төшерү дә житәдер.

Халык Бакый Урманченың тиңе булмаган шәхес икәнлеген үзе исән чагында ук таныды. Хәер, исеме үк «Кем соң ул?» дигән сорауга урын калдырмый торган кешеләр гомер-гомергә булган һәм киләчәктә дә булачак. Әгәр фамилиядәшләр турында сүз бармаса, Жуковның, Тукайның, Чайковскийның, Репинның, мәсәлән, кем булуын аңлатып торасы юк. Бакый Урманче, дигәндә дә шул ук хәл. Иң киме — Иделдән Тянь-Шань тавы тармакларына хәтле арада аның кемлеге турында, дәрәҗәле исеме булу-булмавы турында, академияләргә сайлануы-сайланмавы турында сорашмыйлар. Бакый Урманче — шул җитә! Ә татарлар, башкортлар, казакълар, үзбәкләр, уйгырлар, бу исемне ишеткәч, сәнгати образлар тезмәсен күз алдына җәһәт китерәләр. Әмма Бакый Урманче фаҗигале «төньяк циклы»н да эченә алган тулы бер шигърият дөньясы да, мөстәкыйль фәлсәфә дә, музыка белән һәм аның җаны — халык җырлары белән мавыгу да бит әле. Шулай ук аның публицистикасына, Шәрыкның күп халыклары мәдәниятен тирәнтен үзләштерүенә тиешле бәя — югары бәя бирергә хаклыбыз, һәм бу бик тә зарур. Боларга аның фарсы, гарәп, төрек телләрен белүен дә, инглизчә һәм французча сүзлексез укый алуын да кертик.

**Урманченың әсәрләре Казан, Ташкент, Алма-Ата, Мәскәү музейларына һәм галереяларына куелган, аның әсәрләре поселок һәм шәһәрләр урамнарын һәм мәйданнарын, театрларны һәм мәдәният сарайларын бизи. Аның тиңдәшсез әсәрләре дә бар. Балхаш бакыр эретү комбинаты комплексындагы архитектура әсәрләре, скульптуралары, һәр татар кешесенең күңел түренә урнашкан бөек Тукайның Кырлайдагы тарихи-әдәби музей-заповедниегы бизәлеше, мәсәлән, шундыйлардан.**

Бакый аганы матбугат та таныды. Аның туксан еллыгы уңаеннан уздырылган фәнни конференция материаллары буенча, Казанда — хәзерге заман өчен һавалырак һәм сәеррәк исемдә — «Октябрь тудырган сәнгать» («Искусство, рожденное Октябрем») дигән исемдә мәкаләләр җыентыгы чыгарылды. Анда күп кенә кызыклы материаллар китерелә, аерым алганда, рәссам турында Татарстанда гына да җитмештән артык хезмәт-мәкалә басылуы турында әйтелә. Шул китапта ук искәртелгәнчә, юбиляр үзе дә утызга якын мәкалә язган икән. Бу мәкаләләрнең тематик колачы гаять киң — егерменче еллар уртасында татар җәмәгатьчелеге өчен көн кадагында саналган телне реформалаштыру проблемаларыннан алып Казандагы борынгылык истәлекләренең эшләнү-төзелү вакытын күрсәтүгә һәм архитектура даһие Корбюзье иҗатын дәртле бәяләүгә хәтле сүз бара аларда. Мәкаләләр арасында сынлы сәнгатьне үстерү, замандаш рәссамнары иҗаты, рәсем сәнгатенең музыка белән бәйләнеше турындагылары да бар. Сүз җаеннан Бакый Урманче белән күренекле татар музыканты Нәҗип Җиһанов арасында ихлас һәм ышанычлы мөнәсәбәтләр булуын да әйтик.

Шулай да минем ул чакта мәдәниятебез аксакалы янына баруым аны кабат күрү һәм аның сәнгатьнең серле дөньясы турында тәфсилле һәм кырт борылышлар ясап сөйләвен тыңлау өчен генә түгел иде. Урманченың тормышында һәм иҗади биографиясендә табышмак сыйфатындагы моментлар шактый иде. Ул чакта болар турында тәгаен әйтеп бетерелмәде, аның язмышының кайбер чуалчыкларын томанга төрергә тырышыла иде. Бу очракта менә мондый хәлне мисал итик. Урманченың беренче татар скульпторларыннан булган М. Байкиевка багышланган мәкаләсе 1929 елда басыла, ә чираттагы зур мәкаләсе 1960 елда гына чыга. Утыз ел буена «тел йотарга» нигә «ант эчкән» соң ул? Алай дисәң, иҗади хезмәтләре исемлегендә утыз бишенче елда һәм аннан соңрак язылганнары да теркәлгән бит. Ә аның үзе турында Татарстан матбугатында алтмышынчы еллар уртасында гына языла башлый.

Хәер, укучыны кызыксындыру максатыннан, читләтеп йөреп, төрле төеннәр төйнәү кирәкмәстер. Героебызның үз холкынча, турыдан сөйлик.

**Бакый Идрис угълы Урманче** егерменче елларда «солтангалиевчелек»тә (бу политик каһәр татар һәм башкорт халыкларының берничә буыны өстендә янап торды) гаепләнеп юк ителгән яки рухи көче бетерелгән татар зыялыларының менә дигән кавеменең безнең көннәргәчә исән калган бердәнбер вәкиледер, күрәсең. Ул — гарәп графикасын бетерү уңаеннан Сталинга һәм партия өлкә комитетына 1927 елда сиксән ике татар зыялысы исеменнән җибәрелгән хатка имза куючылардан реабилитациягә чаклы яшәгән бердәнбер кеше. Аның имзасы илле бишенче булып тора — «Иреклe рәссам Бакый Урманче». Бу хат татар мәдәниятен аның борынгылыгына балта чабудан, тарихи тамырларын онытгырудан саклап калу өчен кыю омтылыш иде. Барлык халыкларның рухи мәдәниятләре интернациональ бердәмлеген, хәтта аларның тулысынча кушылуын зарыгып, ярсып көтүчеләргә, моны революцион кысу юлы белән хәл итүчеләргә каршы саллы ору иде ул. Хат Галимҗан Ибраһимовның латинлаштыруга һәм бу эшкә җитәкчелек итүчеләрнең «морзалыгы»на каршы соңгы алышуы белән бер үк вакытка туры килде. Г. Ибраһимов тәгәл билгеләгәнчә, нәкъ менә «морзалык», ягъни руслашкан кайбер морзаларның туган телне һәм мәдәниятне онытуы бик күпләрне борчый иде. Әлеге сиксән ике партиясез зыялы һәм читкә һич тайпылмас коммунист Галимҗан Ибраһимов латинлаштыруның юлда әле туктап кына алу, ә юлның ахырында кириллица булачагын алдан сизәләр. Хикмәт моның кайчан эшләнәчәгендә генә иде. Шул чакта ук инде: «Нигә тартып-сузып торырга, сразы рус алфавитына күчәргә кирәк!» — дип тамак ертучылар да булды. Хәзер — мәгълүматлары чамалы, әмма митингларда өлгерлек күрсәтүче, «манкорт» сүзен еш кушып сөйләүче кайбер эшлекләләр татар мәдәниятен яклауда үзләрен юл ячучылар итеп санаган чакта — тарихыбызның бу фаҗигале сәхифәсен искә төшерү зыян итмәс. Теге заманда бу кыю зыялыларга үлем җәзасы янавын онытмыйк. Аларның батырлыгын танып, якты истәлекләренә башларыбызны иик.

Бакый Урманче, югарыда әйтелгән хатка кул куйганы өчен, дәһшәтле «СЛОН»да (Соловецкий лагерь особого назначения) чиге юк кебек тоелган дүрт елын уздыра. Аның эзе дә калмый торган «лагерь тузаны»на әйләнүе бик тә ихтимал иде. Хәтта шулай булган очракта да (тефү-тефү!) Урманчега татар мәдәниятен саклаудагы хезмәтләре талантлы һәм өметле рәссам, сәнгать белемен-мәгарифен оештыручы булып тарихка керергә җитәр иде. Бәхеткә каршы, язмышы башкача булды. Мантыйкка нигезләнеп аңлатырга тырышсаң да, монда җай килү очрагы зуррак урын тотуын танымыйча мөмкин түгел. Классик анализ методы һәм партиялелек принципы монда көчсез булып кала.

Ә Бакый Урманчега, чыннан да, күп тапкыр җай килеп тора, кем әйтмешли, аның өстенә имәннең чикләвеклесе еш ава. 1928 елның җәендә, мәсәлән, Казан художество училищесы остаханәсендә эшкә мавыгып кунып калуының да файдасы тия аңа — Казанга эш белән килгән күптәнге танышы, хәтта дусты Мирсәет Солтангалиев белән очрашмыйча кала ул. Солтангалиев исә Сталинның «автономияләштерү», дөресрәге, халыкларны сегрегацияләү планына каршы торучыларның иң көчлеләреннән санала. Бу чакта партиядән чыгарылган Солтангалиев сәяси тормыштан читкә кагылган була. Шушы килүендә Мирсәет, Урманчелар белән очрашырга теләп, Бакыйның квартирасына да керә. (Күп кенә артистлар һәм рәссамнар яшәгән бу йорт Островский урамы башында була, хәзер ул йорт сүтелгән). Бакыйның энесе Һади Шәрык халыклары Коммунистик университетында Мирсәет Солтангалиевнең лекцияләрен тыңлаган була, укытучысының күп фикерләре белән килешә ул. Әйе, Мирсәет белән Һади очрашалар һәм төн буе сөйләшеп утыралар. Солтангалиевнең исә һәр адымы органнар тарафыннан теркәлеп барыла. Һәм шымчының белдермәсендә, «икесе дә өйдән иртән сәгать сигездә чыктылар», дип күрсәтелә. Бакыйга бу очрашу турында әйтмиләр. Моны ул дүрт елдан соң гына, «җәһәннәм үк булмаган җирләр»дән әйләнеп кайткач кына, сеңлесе әйтүеннән белә.

* * *

**Егерменче** еллар уртасына Урманче сәнгать серләрен эзлекле һәм тәфсилле үзләштерергә өлгерә. Моңа ирешүдә Югары художество-техник институтта укуы, Казан художество училищесында бөек рус рәссамы Фешин белән аралашуы аеруча ярдәм итә. Һәм, ул 1928 елда ук татарның төпле профессиональ белемле зур рәссамы булып санала.

Шулай да, бу чор турында сөйләүдән элгәре, аның тормыш юлы башына әйләнеп кайтыйк әле. Чөнки нәкъ менә шул чишмә башы аның гаҗәеп-искиткеч язмышында күп нәрсәне аңлатырга нигез була. Аннары аның тормышының бу вакыты турында әйтеп бетермәүләрдән һәм яшереп калдырулардан тукылган пәрдәне күтәрү дә тиешле. Күптән түгел генә кешенең ышанычлы булуы аның пролетар-крестьян чыгышы белән билгеләнә иде, мондый затны изгелек каймасы үзеннән-үзе ураткан итеп санала иде. Әгәр аның ата-анасын Ходай Тәгалә башка сыйныфтан яки катламнан яраткан булса, бу зат зур һәм файдалы эшләр башкарса да, аның чыгышын сөйләүдән тел йотылды. Мондый хәл үзәктән читтә хәтта көчлерәк тә иде. 1989 елда чыккан китапта да, мәсәлән, Бакый Урманче авыл укытучысы гаиләсендә туган, дип раслана. Аның әтисенең бер хезмәтен-һөнәрен истә тотканда, бу, бәлки, шулайдыр. Ләкин Идрис Урманченың Сембер губернасындагы Буа өязенең кечкенә бер авылында дин хезмәтчесе булуын әйтүнең һич тә ояты-гөнаһысы юк. Хезмәттә һәм бәйрәмнәрдә татарлар, руслар, чуашлар бердәм булган бу төбәк халык势 тануына ирешкән җәмәгать эшлеклеләрен һәм мәдәният осталарын күп бирде.



*Бакый Урманче үзенең остаханәсендә.*

Сүз җаеннан шунысын да әйтик. Хәзер без диннең дә, дин хезмәтчеләренең дә җәмгыятьтә ят-чит ор булмавына акрынлап күнегәбез, руханиларның дин тотарга өндәүләренә, гыйбадәт кылучыларның күбәюенә гаҗәпләнмибез. Күптән түгел генә бит әле «мәчет», «мулла» сүзләрен колакка ят яңгырата идек. Нәкъ менә гыйбадәтханәләр кешеләрдә югары әхлак тәрбияләвен оныта идек. Диннең уңай көч-кодрәте татар авылларында аеруча сизелде. Уналтынчы гасырда дәүләтчелеген югалткан, димәк, милли белем бирүне җайлау мөмкинлеген югалткан халыкка дин тугры хезмәт итте, дини мәктәпләр һәм мәдрәсәләр белемлелекгыйлемлек һәм мәдәният формалаштыруда үзәк урынны тоттылар. Һәм бу изге эштә муллаларның өлеше бигрәк тә зур булды.

Идрис мулла булачак гаилә башлыкларының нәкъ менә остазы булган, аларга хәреф танытып, Коръән өйрәтеп белем биргән, тормыш итү кагыйдәләрен үзләштерергә булышкан. Ә укырга өйрәнгән яшьләр, Коръәнне кат-кат укудан тыш, башка китаплар белән дә кызыксыналар. 1905 елгы революциядән соң, татарча уннарча газета-журналлар чыга башлый. Оренбургта бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләр чыгарган, танылган әдәбиятчылар һәм фикер ияләре Риза Фәхретдин һәм Фатих Кәрими мөхәррирлек иткән «Вакыт» һәм «Шура» бигрәк тә киң таныла. Татар вакытлы матбугаты үзәктән ерактагы авылларга да барып житә. «Шура» журналын Идрис хәзрәт тә алдыра. Әйе, Бакыйга иҗади сәләт чаткыларын үстерүгә уңай шартлар була. Кызыклы шәхесләр белән дә еш

очраша ул. Шуларның берсе турында Бакый ага елмаеп искә алган иде: «Безнең авыл сабан туена әтинең дусты, Буа мәдрәсәсе шәкерте Һади килгәч, авыл әзмәверләренең, бу шәкерт барлык нәрсәне дә алачак, батыр да калачак, дип йөзләре кара яна иде». (Булачак күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Атласига табигать биреп тә курсәткән соң — ул баһадир гәүдәле була. Һәм 1937 елда тикшерүчегә, сорау алу беркетмәсенә: «Атласов хәлен җуеп егылды»,— дип язар өчен, яман да нык тырышырга туры килгәндер...)

**Тирә-юньне сурәтләү белән Бакый бик яшьли кызыксына башлый. Бәлки, монда, дип искә алды ул бер очрашуда, Коръән сүзләрен оста каләм белән гарәп хәрефләрендә керештереп-бизәкләп язылган шамаилләрнең дә тәэсире булгандыр, аларны һәркөнне күреп торасың, алар һәр өйдә бар иде бит. Сүз уңаеннан әйткәндә, шамаилләргә Бакый ага гомере буе битараф булмады, аларны соңгы көннәренәчә язды. Шуларның берсе миндә дә бар. Анда гарәпчә керештереп язуның чиксез борылма-бөгелешләрендә — останың нәфис каллиграфиясендә хөр омтылышы сизелеп тора.**

Ә маэстроның үз тормышында дин нинди урын тотты соң? Бакый Урманче бик тә диндар кеше иде. Аның диндарлыгы турында соңгы ун елларда рәссам белән бергә гомер иткән, иҗат кешесенең рухиятен әйбәт аңлаучы һәм үзе дә сәнгатьне белүче Флера ханым да дәлилләп сөйли. Әмма аның динлелеге, соңгы сәгатенәчә Исламның төп боерык-күрсәтмәләрен төгәл тотса да, тыныч иде, йоланы риялы үтәүдә түгел иде, уйлап-нитеп тормыйча фанатиклыкка бирелү түгел иде. Ул берәүгә дә динне көчләп тагарга тырышмады, дингә һәркем, язган булса, Хак Тәгалә ихтыяры белән килә, дип санады. Дин мәсьәләләрендә аның даими әңгәмәдәше, гаять үзенчәлекле карашлы һәм сугышчан тыелгысызлыктан читтә торучы Зәки хәзрәт булыр иде.

* * *

**1928 ЕЛНЫҢ** җәйге төнендә өендә кем кунып китүен Бакыйның белмичә калуын әйткән идек инде. Шушы вакытлардан соң, фаҗигале вакыйгалар котырына башлый, алар Урманчега да саллы итеп бәреләләр. Бу вакыйгаларны ике яктан килеп карыйк. Беренчесе — рәссамның боларга карашы, икенчесе — архивтагы яшерелгән мәгълүматлар.

Егерменче еллар ахырында сәяси хәлнең милли мәсьәләдә чагылышын күз алдына китерү өчен, икенчесеннән башлыйк. Сталин конкурентларын хәзергә әле сәяси яктан гына юк итә бара, милли кадрларга да сакланып сугарга ниятли, моны Исламга яңа һөҗүм белән бергә алып барырга була. Һәм ул, егерменче еллар башындагы кебек, татарларны беренче нәүбәттә күз уңында тота. Татарлар арасында гражданнар сугышыннан ук — Шәрыкта бөтендөнья революциясенең алдынгы отряды булу башта татарларга бирелгән чактан ук — партиянең югары даирәләре белән якыннан элемтәдә торучы эшлеклеләр шактый була. Бу рольне хуп күреп, татар функционерлары Урта Азияне советлаштыруда күп хезмәт куйдылар. Дөрес, аларны тиздән властьның югары кәнәфиләреннән селтәп ыргыта башладылар — калганын төп халык түрәләре хәл итәргә тиеш иде инде.

Ахыр килеп, Сталин һәм аның тарафдарлары тоташтан күмәкләштерү башлау алдыннан милли кадрларга карата куркуга салырлык сәяси акция кулланырга булалар. Кырым Үзәк Башкарма Комитеты башлыгы В. Ибраһимовка оештырылган хөкем һәм аны 1927 елда ату көтелгән нәтиҗәне бирмәве дә истә тотыла. Милли кадрлар арасында илдәге хәлгә карата канәгатьсезлек көчәя бара. 1928 ел ахырында — 1929 ел башында татар, башкорт һәм кырым-татар эшлекләләрен һәм зыялыларын күпләп кулга алулар башлана. Бу хәрәкәтне сәяси яктан формалаштыру һәм аңа житәкчелек итү ОГПУның фактик башлыгы Генрих Ягодага (Менжинский еш авырый) һәм Емельян Ярославскийга йөкләнә. Шул ук вакытта, Сталин инициативасы буенча, Политбюрода мөселманнарның активлыгына юл куймау турындагы мәсьәлә берничә тапкыр тикшерелә. Әлеге хәлләр бу акциягә зур әһәмият бирелүен раслый. Ә егерменче еллар башында шәхси мәктәпләрдә динне өйрәнү рөхсәт ителгән була. Хәзер исә чираттагы чикләүләр куела, мәдрәсәләр ачу тыела. Башка диннәргә карата да тыю чаралары күрелә.

Инде Бакый аганы тыңлыйк. Аның сөйләвен магнитофон тасмасына язып алган идем.

**«Минем энемә килделәр. Бармаклары белән генә ымладылар, монда чык янәһи. Шәп ат җигелгән тарантаска утырттылар. (Рәссам, онытылып китеп, шул**

**хәлне уйнаган кебек: «Читтән караганда, бу матур булгандыр,— дип әйтеп куйды.— Яхшы ат иple генә юырта, ә тарантаска җәйлап утырган ике егет тыныч кына әңгәмә корып баралар). Өемә алып кайттылар. Тентү ясадылар, рәсмилек өчендер, күршедә яшәүче артистка Арапованы пүнәтәй итеп чакырдылар. Моннан соңгы юл билгеле инде — ул «Кара күл»гә, эчке төрмәгә илтә».**

Бакыйны анда озак тотмыйлар, сорау да алмыйлар. Дөрес, аны бер тапкыр ОГПУның мондагы түрәсе Дмитрий Кандыбин янына алып керәләр, әмма бертөрле дә сорау бирмиләр һәм аны тиздән Мәскәүгә җибәрәләр. Бер шагыйрь белән бергә алып баралар Бакыйны. Алар сөйләшмиләр диярлек — бер-берсеннән, сер алу өчен юлдаш ителгәндер, дип шикләнәләр. Соңыннан, инде Соловкига китерелгәч, алар бу хәлне көлеп искә төшерәләр.

Урманчены Бутырка төрмәсенең гомуми камерасына ябалар. Монда аның танышлары да шактый икән. Берничә ай үтеп китә. Бакый, кулга алынуының сәбәбе төрек илчелегендә эшләүче танышым Шәфиевтән әйбәт буяулар табып бирүен соравым булгандыр, дип уйлый. «Моны, бәлки, контрабанда белән бәйлиләрдер,— дип баш вата ул,— чит илдән яшереп кертелгән товар алырга җыенуда гаепле саныйлардыр, бәлки?»

Мин Урманче турындагы документларны үзем күрдем. Хәл җитдирәк һәм куркынычрак була. Яшь рәссамнан, энесе Һади белән бергә, Солтангалиевчеләрнең Казандагы яшерен группасында торган, дип шикләнәләр. Сиксән ике кеше хатында аның имзасы булуын да искә төшерәләр. Әлеге хат исә бу вакытка инде контрреволюцион документ булып санала. Дөрес, имза салучылар 1928 — 1929 елларда, хаттан ваз кичүләрен әйтеп, газеталарда тәүбә итәләр (әмма ки бу тәүбә итүне, дошманның үз теләкләрен яшерергә тырышуы, дип бәялиләр). **Урманче исә газетада тәүбә итми, ул, кирсез рәвештә, миңа тәкъдим итмәделәр бит, ди.**



Бакый Урманче *(утырган, сулдан икенче)* шәкертләре һәм дуслары арасында *(1928 ел)*. Аның сул ягында — язучы Мирсәй Әмир.

Ә Бутырка төрмәсендә татар кешеләре ишәя бара. Казанда Мәхмүт Бөдәйли һәм Мидхәт Борындыков Солтангалиевчеләрнең «күзләре» итеп бәяләнәләр. Югыйсә алар сәяси эшчәнлекләрен күптән ташлаган, инде хуҗалык эшләрендә эре җитәкче урыннарда булалар. Ләкин алар электә үзенчәлекле һәм зур эшлекләләр бит. Бөдәйли — әдәбиятчы, Урта Азиядә дәүләт органнарының күренекле эшлеклесе. Монда ул «Красный Восток» политпоезды составында килә. Ә бу поездны аннан соң Коминтернның Шәрык бүлеген җитәкләгән Георгий Сәфәров алып бара. Юлга чыгар алдыннан Бөдәйлине, Г. Сәфәров һәм А. Балабанова

белән бергә, Ленин кабул итә. Г. Сәфәров РСФСРның Хәрәзмдәге илчесе вазифасын (бу вазифа үзе сәеррәк, әлбәттә) үти. М. Борындыков исә Мирсәет Солтангалиевнең туганы. Ул бригада комиссары, аннары Наркомнацта Сталинның шәхси секретаре, Татарстан республикасының Мәгариф комиссары булып эшли. Аларны, 1923 елда Солтангалиевне кулга алганнан соң, аны яклаганнары өчен, сәяси мәйданнан читләштерәләр. Алты елдан соң аларны да кулга алалар. Кискен һәм үткен сүзгә хирес Мәхмүт Бөдәйли Бутыркага эләгүен күрше камерадагыларга бик гаҗәеп ысул белән житкерә. Бакый ага бу хакта менә болай исенә төшергән иде. «Иртән камерадан тизәк-сидекне чыгару өчен ишек ачылгач, коридордан кинәт көчле тавыш ишетелде: «Ә Бөдәйли кайда монда? Аны монда китергәннәр, дигәннәр иде бит...» Бу исә Мәхмүтнең үз тавышы иде». Бераздан алар очрашалар. Башта камерада, аннары Соловкида.

Тиздән, документларга караганда, татар эшлекләләре өстеннән төп процесс өчен «фигурантлар» сайлап алына. Шуның белән беррәттән, хөкем итмичә генә, сигез елга хәтле җәза бирү хокукы булган Махсус кинәшмә аша үткәрү өчен, ун-унбиш кешелек төркемнәр оештырыла. Бу киңәшмә «Милли фирка»да торуда гаепләнүче кырым татарлары зыялылары, шулай ук Баку мусаватчылары («Тигезлек») эшен аерым хәл итә. Ягода һәм Ярославский имза куйган «Солтангалиевчеләр эше»нең йомгаклау документында «заговор»ның киң таралган булуы турында әйтелсә дә һәм «Шахта эше»нә охшаш процесска әзерлек башларга тәкъдим ителсә дә, сәяси инстанцияләр, беренче чиратта Сталин үзе, зур тавыш күтәрмәскә карар итәләр.

Ниндидер сәбәпләр аркасында, процесс, хәтта ябык рәвештә дә, булмыйча кала. Бәлки, оператив ысул белән тупланган материаллар бик тә «ясалма» тоелгандыр, ә бәлки, бүтән сәяси сәбәпләр табылгандыр. Ничек кенә булса да, «Солтангалиевчеләр эше» буенча кулга алынучыларның барысын да ОГПУ коллегиясе аша үткәрәләр. Ә ул чакта бу коллегиянең гаепләнүчеләргә үлем җәзасы бирү хокукы да була. Җитмеш алты кешедән (берсе тикшерү барганда үлә) егерме бер кешене — бу исәптә Солтангалиев, Мохтаров, Мансуров, Фирдәвес бар — атарга хөкем итәләр, калганнарын төрле срокларга тоткынлыкка ябалар. Мансуровның хатыны Р. А. Сәгыйтовада (хәзер инде ул вафат) иренең Бутырканың үлемгә хөкем ителгәннәр камерасыннан язган хатлары саклана иде. Ул гаделлек онытылмаячагына һәм исән калачагына ышануы турында яза. Беренче ай үлем җәзасы үтәлүен көткәннән соң (рухи яктан тәмам сындыру максаты беләндер, күрәсең), аларның барысына да, БҮБКның Калинин кул куйган карары нигезендә, үлем җәзасы ул чакта иң зур срок булган ун ел лагерьда тоту белән алыштырыла.

* * *

Урманченың исәлекләреннән аңлашылганча, ОГПУ 1930 ел башында ук инде аның белән кызыксынмый башлый. Бу исә аңа уңай килү — өстенә «чикләвекле имәннең чираттагысы аву» дип бәяләнергә мөмкин. Ни әйтсәң дә, ул икенче дәрәҗәдәге герой, сәясәтче түгел, «Солтангалиевчеләр заговоры»ның киң таралган булуын күрсәтергә тырышу өчен генә исемлеккә кертелгән булгандыр. Гаҗәпкә каршы, хөкем карары бик тә гадәти игълан ителә. Аны Әмәтҗан Алмаевка чакыралар, ул үзе моны, сорау алыргадыр, дип уйлый. (Алмаев исә 1928 елда, Айзенберг, Дьяков һәм Болдаев белән берлектә, «милләтчеләр» процессын әзерләүгә турыдан-туры житәкчелек итә. Монарчы ул Татарстанның беренче хөкүмәте әгъзасы, республика хәрби комиссары була, аннары ЧКның үзәк органнарына эшкә җибәрелә. ОГПУның шәрык бүлегендә эшли, Солтангалиевне җентекле тикшерүдә якыннан катнаша. ГБ лейтенанты Ә. Алмаев, «сул милләтчеләрнең контрреволюцион оешмасында катнашкан өчен», 1937 елның 14 июнендә кулга алына һәм, НКВДның һәм прокуратураның махсус комиссиясе күрсәтмәсе буенча, 20 сентябрьдә атыла. Ул 1956 елда реабилитацияләнә). Алмаев һәм Урманче 1919 елдан ук таныш булалар һәм берара үзләрен дуслар итеп тә саныйлар. Урманченың, кайчан сорау ала башлыйсыз инде, дип кызыксынуына каршы Алмаев, эш белән кызыксынмаганрак кыяфәттә, хәзер инде бер нәрсә дә кирәкми, ди һәм документка кул куюын сорый. Бу исә хөкем карары була. Биш ел... Очрашу азагында Алмаев, моның бик җинел җәза икәнлеген искәртеп, юл аягына кофе яки чәй эчәргә тәкъдим итә. Урманче:

— Кофе,— ди. Һәм Бутыркада булуы турында сөйләвен тәмамлап:— Ул вакытлар өчен башка да китермәгән эчемлек бит,— дип ихластан әйтеп куя Бакый ага.

Гомумән, утызынчы еллар башында үзенең афәтле мажаралары һәм эшне кем алып баруы, үзләрен кем «саклавы» турында сөйләгәндә, Урманче ачуын кабартмый иде. «Алар үз эшләрен эшләделәр, мин үз эшемне»,— диде ул. Бәлки, вакыт дигәнең кискен бәяне йомшарткандыр, ә бәлки, «Солтангалиевчеләр эше»нә мөнәсәбәтле тоткыннарның барысы да 1937—1938 елларда җәзалап үтерелгән булуы да моңа тәэсир иткәндер. Урманче тикшерү камераларында һәм төрмәләрдә соңыннанрак хөкем сөргән «әкәмәтләр»гә кагылмады. Законны тотарга тырышкан булу 1936 елгача сакланды бит әле.

1989 ел ахырындагы сөйләшүләр язмасыннан тагын өземтәләр китерик.

**«Соловкига җибәрәселәрен әйттеләр. Озак алып бардылар. Әмма башта ук туры Соловкига җиткермәделәр. Кемь исемле күчерү лагере бар иде, шуның «Разноволоки» дигән лагпунктында ел чамасы торгыздылар».**

Шушы пунктта ул Татарстан хөкүмәтенең элеккеге башлыгы һәм аның урынбасары Гасыйм Мансуров һәм Кашаф Мохтаров белән очраша. Алар үлем җәзасыннан котылып калган булалар. Ул чакта яңадан тәрбияләү идеясен тормышка ашыру уе була, тоткыннар партиягә чын күңелдән тугрылыкларын намуслы хезмәтләре белән исбат итәргә тиешләр ягъни; аларның баш миләрен шаплап торып «юу» өчен күп санда мәдәни-тәрбия учреждениеләре ачыла. Соловки яңадан тәрбияләүнең төрле үрнәкләрен сынау буенча үзенә күрә полигон ролен үти. Анда тоткыннар катнашында хәтта махсус журнал да чыгарыла.

Миңа әтинең дусты Мәхмүт Бөдәйли белән берничә тапкыр очрашырга туры килгән иде. Аның Соловки турында тәфсилле бизәкләп сөйләүләре Урманче сөйләгәннәр белән туры килә. «Первая жертва генсека» исемле китабымда беренче тапкыр басылган фоторәсемдә дә алар бергә: лагпунктның «Перековка» стена газетасы редколлегиясе әгъзалары — Бөдәйли, Мансуров, Борындыков һәм рәссам Урманче.


Бакый Урманче (*сулда*) Нәҗип Җиһанов һәм Габдулла Шамуков белән

Бакый Урманче утрауларга килеп эләккәндә, анда «солтангалиевчеләр» шактый җыелган була инде. Аларның кайберләре инде җәнлек үрчетү фермаларында һәм суүсемнәрдән агар-агар (әче полисахаридлар катнашмасы) табу лабораториясендә эшлиләр. Сүз уңаеннан, **бу лабораториядә мәшһүр Флоренский да бераз вакыт эшләп ала. Бакый ага, аның белән аралашу-аралашмавым турында төгәл әйтә алмыйм, диде. Кайберәүләрдән аермалы буларак, ул истәлекләрендә төгәл һәм таләпчән иде. Еш кына ул:**

**— Монысын анык кына әйтә алмыйм,— дип кырт кисә иде.**

Партизаннар хәрәкәтендә күренекле разведчик һәм язучы Петр Вершигора тупланган мәгълүматларны бервакыт өч төргә бүлгән иде: «фараз кылам», «егетләр әйтә» һәм «үзем күрдем». Ә минем әңгәмәдәшем «үзем күрдем»гә таяна иде.

Һәм тагын Урманче тавышы.

«Соловки турындагы иң әйбәт хатирәләрем — Мяг-островта балык тотуым турында. Шулай ук Гасыйм Мансуровның мине үз урынына ак һәм каракөрән төлкеләр үрчетү фермасына лаборант итеп урнаштыруы турында. Аның үзен материкка күчерделәр, ә аннары Мәскәү — Идел каналын төзергә җибәргәннәр». Монда режим үтә кырыс булмый. Һәм **Урманче, бик үк яшермичә, төньяк табигате күренешләрен, төрле рәсемнәр, портретлар ясый. Боларны ул лагерьда исән-имин саклый, азат ителгәндә сак аша да алып чыга, әмма иректә аларны югалта. Тәмам хәлдән тайган рәссамның Канаш тирәсендә зур юл капчыгын урлыйлар, ә кадерләп саклаган рәсемнәре шунда була.** Бакый ага иҗатында бу темага кабат әйләнеп кайтмый, зур югалту турында безнең соңгырак әңгәмәлә-

ребездә дә искә алырга теләмәде. Ләкин бу югалтуны бик авыр кичерүе сизелә иде. Ә Соловкида утыруы турындагы шигырьләре сакланган. Нечкә лирика белән сугарылган бу циклда, иректән мәхрүм ителү турында тамак ертып ярсымыйча, язмышка һәм җәберләүчеләргә каһәр уку ап-аермачык. 1931 елда Мяг-островта язылган шигырьләреннән берничә юлны мисал итеп китерик:

Салкын диңгез. Ялгыз утрау.
Черегән чыршы вә каеннар. Мүк арасы.
Күңелемдә — кайнар уйлар, сүнгән нурлар.
Уйлап утырам бу караңгы алачыкның
                    корымланган почмагында.

Килер бер вакыт, дим өметләнәм мин, без шул фаҗигале заманның ихлас шигъри таныкламасын Татарстанның ике дәүләт телендә дә, шәт, укый алырбыз.

**1933** ЕЛДА «Солтангалиевчеләр»нең кайберләренең язмышы яхшы якка беркадәр үзгәрә башлый. Өлкән яшьтә һәм сәламәтлеге какшау булу сәбәпле, Һ. Атласины азат итәләр. Туберкулез авыруы көчәйгәч һәм Үзәк Комитетка берничә хат язганнан соң, Солтангалиевне чыгаралар. (Күп кенә татар тоткыннары, үз башларына төшкән җәфаларда аны гаепле санап, аңа сагаеп карыйлар). Җәзаны җиңелрәк режимга кичерү өчен, Борындыков һәм Бөдәйлине материкка җибәрәләр, группаның икенчел дәрәҗәдәге кайбер әгъзаларын азат ук итәләр. Әмма бу хәл, соңыннан күренгәнчә, озак дәвам итми. Соловкида лидерлардан Мохтаров, Енбаев, Фирдәвес, яшьләрдән Һади Урманче һәм тагын берничә кеше кала. 1937 елда, Ежовның чиксез әкәмәтләре вакытында, аларның барысын да шунда атып үтерәләр. Бакый Урманче энесенең язмышы турында почта аша аңа җибәргән җылы киемнәре кире кайткач төшенә.

1933 елда рәссам үзе дә Казанга кайта. Ләкин монда да хәл катлаулы була. **Бакый электәге якын танышларының да үзенә кырын карауларын сизә. Элеккеге политзек булу ихтималы кешеләрне үз һөнәре буенча эшләүдән тыя. Шул ук Һади Атласи, укыту эшенә урнашырга кат-кат тырышып караса да, теләгенә ирешә алмый, һәм ул ОГПУга, йә эшкә керергә булышыгыз, яки кире утыртыгыз, дип мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була.** Аңа эш бирәләр, ләкин үз белгечлеге буенча түгел. Ул да шулай ук: «Шул үзе инде бу, мөгаен, аны тагын алып китәрләр!» — дигән сагаюлы чыш-пышларны еш ишетә. Һәм бу сүзләр, кызганычка каршы, дөреслеккә чыга.

Бакый Урманчены да үз юллары көтә. Яраткан Казаныннан китәргә мәҗбүр була ул. Мәскәүдә, ә аннары, сөрелгәч, Урта Азиядә эшли. Алтмышынчы еллар башында Казанга тагын кайта. Һәм аның тормышында һәм иҗатында яңа чор башлана. Әмма монысы инде тәфсилле аерым мәкалә язуны таләп итә.

Бакый ага арабыздан күптән түгел китте. Нәҗип Җиһанов та вафат булды. Аларның язмышлары төрле, һәркайсы үз кырында иген икте. Ләкин һич икеләнмичә шуны әйтергә тиешбез: алар икесе дә — егерменче гасырда татарлар арасыннан сөнгать өлкәсендә зур талантлар. Бәлки, алар кемнәргәдер комачау да кылганнардыр. Аларны үзләре янында мактап та, үзләре югында көнләшеп, усал яманлаучылар да булгандыр. Ләкин аларның татар халкының талантлы шәхесләре булулары бәхәссез!

* * *

**Бакый Урманченың җәмгыятьнең рухи тормышында тоткан урынын чын-чынлап бәяләү өчен, күпмедер вакыт узуы кирәктер, күрәсең. Кайчакта беркатлы уйлап: «Бакый Урманче — татарның Коненковы!» — диләр. Бездә гасырларга сузылган «икенче сортлылык» һәм «ятимлек» чире бар инде ул, чагыштыруыбыз белән гел кемгәдер ялагайланырга тырышабыз. Солтангалиев — «мөселман Троцкие», Сәгыйдуллин — «татар Бухарины» һәм башкалар... Ә бит бу шәхесләр башкалардан күчереп төшерелгән рәсем дә, аларның копиясе дә түгел. Алар үзләре бар! Һәм Бакый Урманче — безнең мәдәниятебезнең мөстәкыйль һәм бик зур күренеше, олы вакыйгасы. Шулай булгач, аның ядкарен саклау һәм олпат иҗатын, данын лаеклы зурлау буенча җитди һәм төпле эшләр башкарылырга тиеш. Хәзергә исә бу эшләр һич тә канәгатьләнерлек түгел.**

# ТАТАР-МАРИ МӘДӘНИ БӘЙЛӘНЕШЛӘРЕ

Идел буе, Урал алды, Урта Азия һәм Казагыстан халыклары тарихында зур университеты, данлы традицияләре булган Казан шәһәре прогрессив роль уйнады. Казанның үзенә бертөрле миссиясен алдан күргән фикер иясе А. И. Герцен «Провинциядән хатлар» (1836) дигән язмасында болай дигән иде: «... Казанның әһәмияте зур: бу ике галәмнең очрашкан һәм көрешкән урыны... Казан Азиягә Европа идеяләрен, Европага Азия характерын кертү юлында төп кәрвансарай вазифасын үти».

Казан революциягә кадәрге Рәсәйнең танылган мәдәният үзәге була. Аның «инородец» укытучылар семинариясендә, гимназияләрендә, университетында, шәһәрнең башка уку йортларында байтак халык вәкилләре белем ала. «Урыслар өчен Мәскәү нинди үзәк булган булса, урыстан тыш халыклар өчен Казан да шундый ук үзәк булды», — дигән иде күренекле лингвист профессор Н. Ф. Катанов.

1847 — 1902 елларда болын һәм тау чирмешләре, удмурт, алтай, чуваш, башкорт, казакъ, калмык һ.б. халыкларның балалары өчен беренче әлифбалар шушы шәһәрдә дөнья күрә. Әлеге халыкларның язучылары, галимнәренең беренче әсәрләре, фәнни хезмәтләре Казанда басыла. Идел буенда яшәүче урыстан тыш халыклар, шул исәптән, марилар өчен беренче мәктәпләр Казанда архиерей йортында 1707 елда ачыла. Танылган мари язучысы Йосиф Борисов үз вакытында архиерей мәктәбендә белем ала. 1732 елда архиерей мәктәбе руханилар семинариясе итеп үзгәртелә. Шушы дини уку йортында күренекле мари мәгърифәтчесе Гавриил Яковлев та белемен күтәрә. Аны 1906 елда беренче мари галиме, танылган телче, фольклорчы һәм этнограф В. М. Васильев тәмамлаган. Соңга таба рухани семинария нигезендә рухани академия оеша. Мари телендә Казанда дөнья күргән «Әлифба һәм беренче уку китабы» (1907), «Башлангыч мәктәпнең I—II бүлекләренә мәсьәләләр җыентыгы» (1908) кебек күренекле хезмәтләр авторы, танылган мари әдәбиятчысы-мәгърифәтчесе, этнограф, филолог Павел Глезденев, удмурт галиме Сергей Миловский һ.б. анда белем ала.

1817 елда архиепископ Амвросий Казан академик идарәсенә мари алфавитын төзү һәм мари теле грамматикасын язу бурычын йөкли. Бу мөһим эшкә А. Альбинский алына. Ул әлифбаны камилләштерүгә, мари теленең грамматикасын системалы итеп аңлатып бирүгә билгеле өлеш кертә. 1837 елда аның «Черемисская грамматика» исемле китабы Казанда дөнья күрә.

XIX йөзнең икенче яртысында Казанда миссионерлар җәмгыяте тырышлыгы белән мари мәктәпләре өчен И. Кедровның «Упрощенный способ обучения чтению черемисских детей горного населения» (1867), Г. Яковлевның «Упрощенный способ обучения чтению черемисских детей лугового населения» (1870) һәм «Букварь для луговых черемис» (1873), И. Удюрминскийнең «Букварь для начального обучения черемисских детей русской грамоте» (1873), П. Еруслановның «Первоначальный учебник русского языка» (1892) һәм «Букварь для восточных черемис» (1892) дәреслекләре дөнья күрә.

1864 елда Н. И. Ильминский тарафыннан оештырылган Казанның үзәк керәшен-татар мәктәбе мари, чуваш, удмурт мәктәпләре өчен укытучылар әзерләүгә билгеле өлеш кертә.

Идел буенда яшәүче урыстан тыш халыкларның мәгарифен үстерүдә, шул төбәк мәктәпләренең башлангыч класслары өчен укытучылар әзерләүдә 1872 елда ачылган Казан «инородец» укытучылар семинариясе зур роль уйный. Ул азчылык милләт халыклары өчен укытучылар әзерләү белән генә чикләнеп калмый, киң мәгънәдә белем һәм тәрбия бирү ысулларын эшләүгә кыйммәтле өлеш кертә. Монда егермедән артык милләт вәкилләре белем ала.

Кырык җиде ел эшләү дәверендә (1872—1919) бу уку йортын 1500 дән артык укучы тәмамлый. Алар арасында 243 татар, 179 чуваш, 128 мари, 110 мордва, 70 удмурт һ.б. була.

Казан «инородец» укытучылар семинариясендә мари халкының Петр Григорьев, Сергей Чавайн, Валериан Васильев, Павел Глезденев, Сергей Гаврилов, Гавриил Леонтьев, Владимир Мухин, Илья Ломберский, Андрей Эшкинин, Агрипина Боброва, Михаил Веткин, Федор Егоров кебек уллары һәм кызлары белем ала.

Казан университеты төбәкнең мәдәни һәм иҗтимагый тормышында әһәмиятле роль уйный. Октябрьгә кадәр һәм аннан соң Казан университетын мари В. Васильев, Г. Эвайн, чуваш И. Яковлев, удмурт Ашалчи Оки, мордва М. Евсевьев, В. Хохряков һ. б. тәмамлый.

Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыяте тугандаш мари халкының тарихын, рухи һәм матди тормышын, мәдәниятен өйрәнүгә зур өлеш кертте. Аның гыйльми язмаларында (ул 34 том булып дөнья күрде) марилар турында аеруча кыйммәтле фәнни тикшеренүләр басыла. Мәсәлән, 1908 елдан җәмгыятьнең хакыйкый әгъзасы В. М. Васильевның «Бөре һәм Сарапул өязе чирмешләренең җырлары», «Чирмеш җырларының характеры һәм төзелеше турында», С. К. Кузнецовның «Этнограф истәлекләреннән», «Чирмешләрнең женси азгынлыкка мөнәсәбәте», «Мариларның дини карашлары һәм гореф-гадәтләре» һ. б. заманында шактый игътибар казана.

1889 елда Казанда И. Н. Смирновның «Чирмешләр» дигән хезмәте рус телендә дөнья күрә.

Мари халкының беренче училищелары, мәктәпләре ачылу Казан университеты һәм аның Н. И. Лобачевский, П. С. Кондырев, О. М. Ковалевский, Г. И. Солнцев кебек танылган галимнәренең актив эшчәнлегенә бәйләнгән.

Тугандаш мари халкының үзаңын үстерүдә, мари әдәбиятын тудыруда, педагогик фикерен баетуда Казанда 1907—1912 елларда чыгып килгән «Марла календарь» әһәмиятле роль уйный.

Совет властеның беренче көннәреннән алып Казан Идел-Урал буе тугандаш халыкларының фәнни-тикшеренү эшләрен үстерүдә, культура дәрәҗәләрен күтәрүдә тагын да күбрәк ярдәм күрсәтә башлый.

1918 елның 12—24 февральләрендә Казанда мари халкының милли съезды уздырыла. Аннары монда бер-бер артлы төрле милли вакытлы матбугат барлыкка килә. Татарстан АССР төзелү көннәрендә аларның саны иллеләп артып китә, шуларның дүртесе марича басыла.

Совет властеның беренче елларында Казанда һ. б. төбәкләрдә мари телендә «Войва ивер» («Сугыштан хәбәрләр», 1915—1917), «Ужара» («Таң», 1917—1918), «Йошкар кече» («Кызыл кояш», Казан-Краснококшайск, 1918—1931), «Йошкар солтак» («Кызыл сугышчы», апрель-июнь 1919), газитләре һәм «Куралше» («Сабанчы» 1918), «У илыш» («Яңа тормыш» Казан—Мәскәү, 1922—1927) журналлары дөнья күрә, аларга тау марилары шивәсендә басылган матбугатны да кушсак, күренеш тагын да тулылана төшәр. Бу вакытта Алабугада «Марий коммунист» (1919 елда редакторы Иван Ижболдин), «Тул» («Ут», 1920—1921) газитләре чыгарыла. Казанда урнашкан мари китап нәшриятында 1918—1919 елларда күренекле педагог, дәреслекләр авторы Николай Орлов эшли. Бу елларда Казанда мари мәктәпләренә ярдәмгә байтак китаплар бастырып чыгарыла. Алар арасында С. Гавриловның «Марийско-русский словарь» (1920), «Горномарийский-русский словарь» (1935), Н. Никольскийнең «Основы инородческого просвещения» (1919) һ. б. китаплар да була.

1920 елда Казанда мари мәгариф хезмәткәрләре съезды уздырыла. Шул ук елда анда Татар коммунистик университеты һәм Көнчыгыш халыкларының югары өлкә партия мәктәбе эшли башлый, соңгысында мари бүлеге дә була.

Казан университеты каршында оештырылган дәүләт эшче факультетларының мари һәм удмурт бүлекләрендә эшләү өчен Н. Никольский, Е. Емельянов, И. Михеев, И. Яковлев кебек профессорлар, тәҗрибәле галимнәр чакырыла. 1924 елда бу факультетның мари бүлегендә 30 кеше укый. Алар арасында булачак язучы К. Крылов (Александр Ток), архитектор А. Суриков, киноактер һәм шагыйрь Кирил Иванов (Иван Кырля), инженерлар К. Смирнов, А. Бурков, В. Смирнов, Т. Лебедев, П. Павловский, К. Орлов, архитектор һәм педагог К. Семенов та була. Укучылар мари телендә спектакльләр куялар. Университетның эшчеләр факультетыннан шәһәр советына беренче депутат итеп мари егете, элекке шахтер Зайцев сайлана.

Эшче факультетта укучылар әдәби иҗат эше белән дә шөгыльләнәләр. Әдәби смотрлар, ярышлар оештыралар. Бервакыт укучыларга хезмәт халкы тормышыннан хикәя язарга кушыла. Хикәя өчен беренче бүләкне А. Ток, икенче бүләкне (ашханәдә ике атна буе төшке аш ашау) булачак татар язучысы А. Шамов ала. Туган теленнән тыш татар, башкорт, урыс телләрен дә яхшы белгән, Казандагы совет-партия мәктәбен тәмамлаган А. Ток соңрак «Татар халык авыз иҗаты», «Татар халык җырлары» дигән җыентыклар төзеп, мари телендә бастырып чыгара.

1922 елның августында Казан югары халык мәгарифе институты Көнчыгыш педагогия институты исемен ала. 1925 — 1927 елларда монда өстәмә рәвештә мари теле һәм мәдәнияте, удмурт теле һәм мәдәнияте, чуваш теле һәм мәдәнияте бүлекләре оештырыла. Мари мәдәнияте һәм халык мәгарифенең күренекле вәкилләре, В. Мухин, О. Шабдар, О. Тыныш, О. Сурикова, А. Ельчибаев, К. Четкарев, К. Валитбаев һ. б. Казан Көнчыгыш педагогия институтының мари теле һәм мәдәнияте бүлеген тәмамлыйлар. 1929 — 1930 елларда бу югары уку йортында доцент вазифасын Г. Г. Кармазин башкара. В. М. Васильев, В. Т. Соколов кебек мари галимнәре, мордва галиме М. Е. Евсевьев шулай ук бу институтта педагогик эшчәнлекләрен дәвам итәләр. Бу уку йорты М. Аюпова, И. Ижболдин, И. Болдырев, А. Айзенвард кебек сәләтле педагогларга белем бирә. Казан Көнчыгыш педагогия институтында укыганда, О. Шабдар Татарстан республикасының 10 еллыгы исемендәге Казан педагогия техникумында мари теле һәм әдәбияты фәннәрен укыта һәм ике ел дәвамында Казан университетында мари бүлеге студентлары белән дәресләр дә алып бара.

1930 — 1931 елларда милли бүлекләр базасында Йошкар-Ола, Ижевск һәм Чабаксар шәһәрләрендә мөстәкыйль педагогия институтлары оеша. М. Горький исемендәге Казан авыл хуҗалыгы институты базасында Мари политехник институты эшли башлый.

Кыскасы, тугандаш мари халкы мәдәнияте һәм халык мәгарифен үстерүгә актив өлеш керткән күренекле вәкилләрне Казан тәрбияләп җитештерә. Бу җәһәттән В. Васильев, В. Мухин, С. Чавайн, И. Ключников-Палантай кебек зыялыларның тормыш юлы һәм иҗаты зур игътибарга лаеклы.

В. Васильевның бөтен аңлы тормышы Казан белән бәйле була. Казан Башкортстанның Яңавыл төбәгеннән килгән гади крестьян малаена университет белеме бирә, аның фәнни һәм педагогик эшчәнлеген үстерүгә булышлык итә. Ул житмеш сигез еллык гомеренең егерме елдан артыгын Казанда үткәрә. 1906 елда В. Васильев мари телендә беренче «Марла календарь» төзи, мондый календарьлар җиде ел дәвамында даими дөнья күрә. Эчтәлеге, формасы белән ул Казанда татар телендә чыгып килгән К. Насыйриның календарьларына якын була. Без ныклы ышаныч белән әйтә алабыз: тугандаш татар халкының телен яхшы белгән В. Васильев бу календарьлар белән дә таныш булгандыр. Ул 1907 елдан Казан земство карамагындагы мәктәптә мари теле укытучысы булып эшли башлый. Туган һәм урыс телләре буенча төрле дәреслекләр, уку кулланмалары төзүдә актив катнаша.

Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыяте галимнең мари халкы этнографиясе мәсьәләләре буенча телдән һәм язма чыгышларына югары бәя бирә һәм 1908 елда аны үзенә әгъза буларак кабул итә. Бу мари галименең фәнни абруе үсүе, аның гыйльми-тикшеренү эшендә ирешкән хезмәтләрен югары бәяләү турында сөйли.

Ул 1918 елда Казан педагогия институты коллегиясе тарафыннан мари теле кафедрасы профессоры итеп сайлана. Совет властеның беренче елларында милләтләр халык комиссариаты каршындагы мари үзәк бүлегенең матбугат һәм мәдәният бүлекчәсендә мари телендә чыгучы басмалар редакторы булып эшли. В. Васильев Идел-Урал буе халыклары мәгърифәтчеләре белән тыгыз бәйләнештә яши, аларның хезмәтләрен, әсәрләрен өйрәнә, бу эштә аңа жирле халыкларның телен яхшы белү зур ярдәм итә. Ул мари җырларын туплау, өйрәнү белән генә чикләнми, татар җырларын да көйләре белән бергә язып ала, аларны татар телендә төрле җыентыкларда бастырып чыгара.

В. Васильев фәннең төрле тармакларына караган күп хезмәтләр яза һәм аларның шактые Казанда басылып чыга. Мәсәлән, 1906 елдан 1931 елга кадәр Казанда галимнең 50 ләп фәнни хезмәте, программа, дәреслек, методик кулланмалары дөнья күрә.

В. Васильевның бай фәнни фикере, педагогик мирасы марилар өчен генә түгел, илебезнең башка тугандаш халыклары, шул исәптән, татарлар өчен дә кыйммәтле чыганак булып санала.

Мари әдәбиятына нигез салучы Сергей Чавайнның тормыш юлы һәм иҗатын да Казаннан аерып булмый. Беренче шигырен һәм хикәясен ул Казанда яза, монда аның беренче җыентыгы дөнья күрә. Шулай итеп, беренче мари язма әсәренең тууы да Казан белән бәйләнгән.

С. Чавайн Казанда 1904—1908 һәм 1920—1923 елларда яши, укый, иҗтимагый һәм иҗади хезмәт белән шөгыльләнә. «Дезертирлар» повестенда интернациональ полк военкомы, татар язучысы Шамил Усмановның тулы канлы образын тудыра.

Мари профессионал музыкасына нигез салучы И. Ключников-Палантай тормышы һәм иҗаты да Казаннан аерылгысыз. Ул монда музыка училищесында укый, руханилар семинариясендә эшли. Казан документаль фильмнар студиясе композиторның якты истәлегенә багышланган махсус фильм төшереп, җәмәгатьчелекне ифрат сөендерде.

Беренче мари операсы «Акпатыр»ның авторы Э. Сапаев, беренче мари балеты «Урман легендасы»ның авторы А. Луппов, музыка белгече, Н. Седукин, күренекле мари галиме А. С. Петрушев һ. б. Казанда белем алдылар.

Хәзерге вакытта Мари-эл республикасы композиторлар берлеген татар музыкасын яхшы белүче, татар композиторлары, музыка белгечләре белән яхшы мөнәсәбәттә булган, Казан консерваториясен тәмамлаган композиторлар тәшкил итә. Татар һәм мари язучылары, педагоглары, тарихчылары арасында иҗади элемтәләрнең башлангычы революциягә кадәрге вакытлардан ук килә. Күренекле татар галиме К. Насыйри үзенең хезмәтләрендә татар халкының мари халкы белән гасырлардан килгән дуслыгын чагылдыра. 1900 елда галим-педагогның татар һәм мари халык әкиятләрен өйрәнүгә багышланган «Казан татарлары әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» дигән мәкаләсе басыла. К. Насыйри танылган мари әдәбиятчысы-этнографы Т. Семенов тәкъдим иткән әкиятләрдән файдалана. «Известия Казанской епархии» дигән җыентыкта 1901—1904 елларда керәшен татары М. Васильев тарафыннан мари халкының тормышына һәм көнкүрешенә багышлап язылган шактый гына очерк басыла. «Чирмешләрнең дини бәйрәмнәре», «Чирмеш масленицасы», «Чирмешләрнең язгы бәйрәмнәре» кебек мәкаләләре бу яктан аеруча кызыклы.

Мари сүз осталары Н. Лекайн «Ата-бабалар җире», О. Шабдар «Хатын-кыз язмышы», С. Чавайн «Мари ротасы», «Дезертирлар», Я. Ялкайн «Шәһәр», «Алкар» дигән зур күләмле әсәрләрендә Татарстанга, татар халкына җылы мөнәсәбәтләрен белдерәләр.

Мари әдипләре татар каләмдәшләрен һәрвакыт якын күрә. «Хәсән Туфанга хат» (И. Осмин), «Габдулла Тукайга», «Габдулла Тукай һәйкәле янында» (М. Микай), «Габдулла Тукай», «Тукай Казанга кайта», «Тукайга кунакка», «Тукай исемендәге пароход» (М. Казаков), «Татар дустыма» (С. Вишневский), «Фатих Кәримгә» (Г. Матюковский) әсәрләрендә бу дусларча мөнәсәбәтне бик ачык тоярга мөмкин. Я. Ялкайн «Шәһәр» дигән әсәрендә Муса Җәлил образын иҗат итә.

Татар язучылары да тугандаш мари халкы турында җылы фикерләр әйтәләр, аның күренекле вәкилләренә, Йошкар-Ола шәһәренә күп санлы матур әдәбият әсәрләрен багышлыйлар. Бу яктан С. Хәким, Г. Бәширов, З. Нури, С. Шакир, Р. Гәрәй иҗаты игътибарга аеруча лаек. Күрше мари халкы белән гомер буена аралашып яшәгән, аның тарихын, гореф-гадәтләрен, традициясен яхшы белгән С. Хәким мари дусларына багышлап күп санлы шигырьләрен, мәкалә һәм истәлекләрен язып калдырды. Аның «Кадерле почмак», «Югалган эзләр», «Мари кызы Улина», «Мари карты Филипп», «Нәкъ салават күпере», «Тарлюк», «Өч өянке», «Күңелемнең яртысы», «Изге күршелек» кебек шигырьләре шул хакта ачык сөйлиләр. Семен Вишневский Сибгат Хәкимгә багышлап язган «Халыклар — туганнар» дигән шигырендә мариларның татар шагыйренә булган җылы мөнәсәбәтен ачык чагылдыра. З. Нуриның «Чавайн чишмәсе», «Бәйрәмгә чакыру», С. Шакирның «Яраткан шагыйрем», «Йошкар-Ола — яраткан шәһәрем», Р. Гәрәйнең «Безнең дуслык гасырларга саклансын» (мари егете Валентинга) кебек шигырьләре дә тугандаш мари халкына, аның күренекле улы Сергей Чавайнга тирән мәхәббәт белән сугарылган.

«Соңгы елларда калын гына китап булып мари халкының җырлары басылып чыкты. Мин бу китапны дулкынланып һәм сокланып укыдым,— дип язды татар әдәбияты аксакалы Гомәр ага Бәширов.— Урман аша гына яшәүче шушы якын күршебезнең шундый бай һәм күңелләрнең иң нечкә кылларын чиертә торган шундый шигъри хәзинәсен моңарчы белми йөрүемә хәтта уңайсызланып та куйдым. Бу гаҗәеп китаптан болыннарның чәчәк исе, нарат урманнарының сагыз

исе аңкып торадыр кебек. Алай гына да түгел, беренче карауга гади генә, беркатлы гына кебек күренгән бу җырларда мари халкының гасырлар буенча тупланган зирәк акылы, дөньяның матурлыгын үзенчә күрә белүе көчле поэтик образларда күз алдына килеп баса. Шуннан чыгып мин лирик матурлыкны, сүзнең музыкаль яңгырашын яратучы һәр кешегә безнең мари дусларыбызның шушы җырларын алып укырга киңәш итәр идем». (Г. Бәширов. Бүген дә, иртәгә дә. Казан, 1974, 16—17 битләр).

Татар-мари тарихы, мәдәни бәйләнешләрен өйрәнүгә мари һәм татар галимнәреннән М. Гайнуллин, К. Сануков, Л. Арсланов, И. Галкин, А. Луппов, Я. Ханбиков, И. Иванов, М. Нигъмәтҗанов, Ф. Вәлиев, Н. Юзиев, Т. Галиуллин кебек профессорлар, К. Васин, П. Апакаев, Н. Исанбаев, Э. Нигъмәтуллин, И. Илалова, Р. Әхмәтҗанов, Ф. Гордеев, А. Васинкин, А. Китиков кебек фән кандидатлары зур өлеш керттеләр.

Татар халкы Ким Васинны яраткан әдибе, халыклар дуслыгы җырчысы дип исәпли. «Туган як тарихы һәм мәдәнияте» дигән курс буенча аның «Онар жирендә» дигән повесте, татар, урыс һ. б. милләт язучылары әсәрләре белән бергә, Татарстандагы урыс мәктәпләрендә дә яратып өйрәнелә. Танылган мари галиме, язучы Ким Кириллович горурланып дәү әнисенең әнисе Әтнә ягында туып үскән татар кызы булуы турында сөйли. «Минем каным составында татар каны да шактый бит. Шуңадыр, ахрысы, татар халкы, аның бай мәдәнияте миңа туган халкым мәдәнияте кебек үк үз һәм якын»,— ди әдип.

Без шулай ук профессор Леонид Арыслановка татар-мари халыклары арасындагы дуслыкны ныгытуга керткән өлеше өчен рәхмәт укыйбыз. Актаныш районындагы мари игенчесе гаиләсендә туып үскән галим хезмәт сөюе, тырышлыгы, тугандаш татар халкына, аның теленә булган тирән мәхәббәте нәтиҗәсендә илебездә киң танылган татар теле белгеченә әверелде.

Татар-мари театрлары арасында да иҗади багланышлар күп еллардан бирле килә. Татарстан театрлары, мәдәният йортлары сәхнәсендә мари драматурглары А. Волковның «Кызлар йөрәге», Н. Арбанның «Кара бүре» пьесалары нигезендә эшләнгән спектакльләрне татар тамашачылары бик яратып караган булсалар, татар драматурглары А. Гыйләҗевнең «Югалган бер көн», И. Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә», Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», Р. Ишморатованың «Тормыш юлында» пьесалары буенча эшләнгән спектакльләр дә мари тамашачылары күңеленә хуш килде.

Күренекле галим, сәнгать фәннәре докторы Ф. Вәлиевнең Татарстанда озак еллар дөнья күрә алмый яткан «Архитектурно-декоративное искусство казанских татар. Сельское жилище» (Йошкар-Ола, 1975), «Древнее и Средновековое искусство Среднего Поволжья» (Йошкар-Ола, 1975) монографияләрен бастырып чыгарганнары өчен мари җәмәгатьчелегенә рәхмәтебез бик күп.

Шәфкатьле Татарстан һәм Башкортстан туфрагы тугандаш мари халкына тугры хезмәт иткән һәм хезмәт итеп килүче алтмыштан артык галим, язучы, мәдәният хезмәткәрен тудырып үстерде. Аларның күбесе татар һәм башкорт телләрен дә яхшы белә. Кайбер мари язучылары һәм журналистлары Татарстан, Башкортстан мәктәпләрендә укытты. Шагыйрь Иван Осмин 1938—1940 елларда Татарстанның Менделеевск районы Эльнет мәктәбендә мари теле һәм әдәбиятыннан сабак бирә. Хезмәт герое Г. Микай да заманында шушы мәктәптә эшли. Совет властеның баштагы елларында Әгерҗе районының Бим мәктәбендә М. Кузнецов, В. Бельский, И. Ломберскийлар укыткан. Йошкар-Олада туып үскән күренекле лингвист В. А. Богородицкий экспериментал фонетика буенча Казанда кабинет-лаборатория төзүгә, югары квалификацияле белгечләр хәзерләүгә зур көч куйды.

Татарстан һәм күрше Мари-ил республикаларында халык мәгарифе, фән һәм мәдәният зур үсеш юлын узды. Идел-Урал буенда яшәүче халыкларның, шул исәптән, татар һәм мариларның ерак гасырлардан килгән дуслыгы, үзара ярдәмләшеп яшәве яңа казанышларга ирешүнең мөһим шарты булып тора.

**Фәнис ИСЛАМОВ,**
педагогия фәннәре кандидаты.

Китап күзәтү

# «СИХЕРЧЕ»ЛӘР КИРӘК ДӨНЬЯГА

Нәбирә Гыйматдинованың 1993 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган повесть һәм хикәяләр җыентыгының «Сихерче» исеме белән аталуы очраклы түгел. Китапка авторның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре тупланган. Һәм «Сихерче» повесте алар арасында иң уңышлысы, дип әйтсәк тә ялгышмабыз.

Әсәрнең төп герое — Сәвилә образы язучы дөньясында кинәттән генә пәйда булмаган. Алдарак иҗат ителгән хатын-кыз образлары аңа үзенә күрә бер баскыч кебек. Н. Гыйматдинова героинялары кайсыдыр яклары белән бер-беренә охшаш. Аларны бер исем астында берләштереп, символик рәвештә «җирдән аерылганнар» дип атап булыр иде. Әмма тагын бер кат искәртергә кирәк, бу исем символик. Чөнки ул героиняларның кайчакны кешеләрдән аерылуларын гына, ә җирнең үзенә, табигатькә, киресенчә, бик нык, гадәттән тыш нык бәйләнгән булуларын күрсәтә. Шул рәвешчә, язучы табигать белән кешелек җәмгыяте арасындагы каршылыкны бөтен кискенлеге белән укучылар күз алдына бастыра. Авторның героинялары — шушы ике як арасында бәйләүче чылбыр, арадашчы. Һәм әлеге кискенлекне күрсәтүдә Н. Гыйматдинова гротеск алымын сайлый. Шуның өчен дә образлар бераз чынбарлыктан ерак кебек тоела. «Сихерче»дәге Сәвилә, «Хыял»дагы Динә, «Талпыну»дагы Мәрьям — гадәттән тышрак шәхесләр. Болар башкалардан аерылып тора, шуның өчен дә тормышта алар япа-ялгыз диярлек.

Дөнья әдәбиятында «Күгән агачында сайраучылар» («Поющие в терновнике») дигән гүзәл әсәр бар. Автор хатын-кызның бәхетсезлеген, башка күп кенә хикәя-романнардагы кебек, социаль шартлар белән бәйләми, гаепне тулысынча ирләр өстенә аудара. Һәм тагын: «Бөек итеп яратырга, олы хискә бары тик табигатендә хатын-кыз психологиясе белән якынлык булган ирләр генә сәләтле»,— дигән нәтиҗә ясый. Н. Гыйматдинова иҗатында да шушыңа охшаш күренешкә тап булабыз.

«Ханым-солтаным» повестендагы Таһир образы — моның ачык мисалы. Әсәрдә аңа Саимә апа тарафыннан түбәндәге бәяләмә бирелә: «Хатын-кыз төсле бик чиста кеше. Кием-салымын идәнгә бәрми, элеп куя. Тартмый да, юкса тегеләрнең тәмәке исе тынга каба иде. Сүзен уйлап сөйли, ашыкмый». Менә шушы Таһир җыр ярата, күрше хатынының җырлаганын эштән бүленеп тыңлый ул. Үзе шигырьләр яза икән — мәхәббәт шигырьләре. Нәкъ шул Таһир тормыш төбенә тәгәрәп баручы Мөршидәне бернигә карамыйча олы бер хис белән ярата.

«Сихерче»дәге Тәминдар, бу җыентыкка кермәгән «Ут күбәләге» һәм «Хыял» дигән повестьлардагы Юлчы, Баязит образлары — йомшак күңелле, күпмедер дәрәҗәдә хатын-кыз табигатьле кешеләр. Юлчы белән Таһир бәхетлерәк, аларның мәхәббәтләре өчен югалтырлары юк. Сөю-сөелү эшләрендә фаҗигагә юлыксалар да, алар бу хәлләрдән кешелек горурлыкларын югалтмыйча чыгалар. Башка ир-ат геройлар Н. Гыйматдинованың мәхәббәттә сынавын күтәрә алмыйлар, матди җитешлек, дан-дәрәҗәне мәхәббәттән өстен куялар. Һәм бу күренеш күбесенчә язучының башлангыч чор иҗатына хас. «Хыял»дагы Баязит, «Ярату галәмәте»ндәге Әсһар, «Сихерче»дәге Тәминдар шундыйлардан.

«Сихерче» җыентыгына кертелгән хикәя-повестьлар авторның соңгы чор иҗаты җимешләре һәм алар язучының үсешен бик ачык күрсәтәләр. Биредә инде тормышның үзе чагыла, чынбарлыкка якын типлар төп урынны ала. «Хатын-кыз — илаһи зат, мәхәббәте өчен бөтен корбанга риза: ир-ат куркак һәм түбән җанлы, матди җитешлек өчен сөюен корбан итәргә дә күп сорамый»,— дигән берьяклы бүленеш инде монда юк. Авторның хатын-кыз героинялары да хыялыйлыктан, илаһилыктан, «җирдән аерылганлык»тан ераграк китеп, гадәтилеккә күбрәк якынайганнар. Әмма, шуңа карамастан, алар барыбер төркемнән

аерылып торалар. «Бүре каны», «Ханым-солтаным» повестьларындагы Гөлнара һәм Зөлфия, «Су хикәяте», «Ташу» хикәяләрендәге Рәфинә һәм Кәримә образлары — җир кешеләре, тормышка, кешеләр җәмгыятенә меңнәрчә җепләр белән бәйләнгәннәр. Алар ялгыз түгел, димәк, язучы җирдәге тормышны тулысынча инкарь итү дигән кыргый чиктә торып фикер йөртми.

Н. Гыйматдинованың кайбер әсәрләре халыкның йөзьеллык, меңьеллык тәҗрибәсен, ышануларын нигезләп, телдән-телгә сөйләнеп йөри торган вакыйгаларны хәтерләтә. «Язмыш», «Каргыш», «Үч» кебек, совет әдәбиятында инкарь ителеп килгән тәгъбир-төшенчәләр биредә тулы көч белән чагыла. Мәсәлән, «Ташу», «Манара», «Бер телем икмәк» хикәяләре моңа ачык мисал. Күп вакыт бу төшенчәләр, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдән узып, табигать — кеше — табигать мөнәсәбәтләре өлкәсенә килеп керә. Мәсәлән, «Бүре каны», «Сихерче» повестьлары шундыйлар рәтендә. Табигать һәм кеше арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, каршылык-бөтенлекләрне ачарга омтылыш — бу язучының баштагы иҗатыннан ук килә. Автор бу чорда «кеше — җиңүче» һәм «табигать — җиңелүче» арасындагы каршылыкларны ни әйтерен яшереп тормыйча, ачык һәм конкрет детальләр белән сурәтли. Мисал өчен «Хыял» повестендагы бер күренешне генә китерү дә җитә: йомшак бөреле тал агачын тамырыннан йолкучы бульдозер. Н. Гыйматдинованың соңгы еллардагы повесть һәм хикәяләрендә исә бу проблема бераз яшеребрәк, эретебрәк бирелә. Янәдән бу урында дәлил итеп «Бүре каны», «Сихерче» повестьларын атау урынлы булыр. Табигать үзенең табигый яшәешенә тыкшынучыларны каты җәзалый. Кеше — табигатьнең бер кисәге генә, аның акыл көче табигатьне җиңүгә, буйсындыруга түгел, ә тиешенчә, дөрес файдалануга юнәлтелгән булырга тиеш. Киресенчә булганда, табигать бездән каты һәм рәхимсез үч алачак.

Гөнаһсыз җанварның җанын кыеп аякка бастырылган Рамазан Закировның үлеме бүредән («Бүре каны») була. Кеше ялгышын табигать үзе төзәтә. Ахыр чиктә дөреслек өскә чыга. «Сихерче»дә исә адәм балаларының рухи һәм физик деградациясе аларның табигатьтән ераклашуы нәтиҗәсе буларак карала. Менә Сәвиләнең Риязга әйткән сүзләре: «Үсемлек, киек-җанвар, бөҗәк, су, һава — безне тулыландыручы, яшәтүче тере организм. Шунын берсен югалту да һәлакәткә тиң! Кара син галәм белән кеше арасындагы охшашлыкны. Әйтик, йөрәк — кояш, бавыр — җир, үпкә — һава, бөер — су, ди. Табигатькә никадәр якын булуыңны тоясыңмы инде? Ә бит кешеләр һаман саен аның белән бәйләнешен өзә бара, өзә бара. Шуның аркасында коточкыч фаҗигаларга юлыга: авырый. Дөньяга гарип-гораба туа, әшәке чир аза, им табылмый торганы... Мин синең урыныңда булсам, җир язмышын да, табигать язмышын да бертигез кайгыртыр идем».

Повестьта образлар кызыклы гына. Алар арасында Сәвилә башкаларга охшамаган булуы белән аерылып тора. Чынлап та, мондый тип кешеләр моңа кадәр әдәбияттан гына түгел, тормыштан да бик тырышып «куылдылар». Шуңа күрә Сәвиләнең һәм аның белән бергә Убыр образының да, беренче карашка, безгә артык «җирдән аерылган» булып күренүе сәер түгел. Ләкин, бернигә карамыйча, без Сәвиләнең тормышчан образ булуын раслыйбыз. Моның шулай икәненә дәлил итеп, әсәрнең башка геройларын китерү урынлы булыр. Бу — Тәминдарның хатыны Мәликә, фельдшер Сәкинә, көтүче егетләр, председатель Рияз һ. б.

Рияз образына аерым тукталып китүне кирәк дип таптык. Бу — замана герое. Аның начар белән бергә, уңай сыйфатлары да шактый. Һәм язучы моны яшерми дә. Соңгы вакытта җиргә, авыл хуҗалыгына, колхозларга булган яңа карашларны без аның авызыннан ишетәбез: «Теләгән кешеләргә җир өләшәм әле. Аны яңадан хуҗасына кайтарып бирәсе иде. Агай-эне бизгән туфрактан, исен тоймый, кадерен белми, чит-ят күрә. Хәзер аны чын хуҗа итү миннән дә тора».

Н. Гыйматдинова әсәрләрендә портрет ясау сирәк күренеш. Укучы һәр геройны күңелендә үзенә ничек кирәк, шулай ясый. Әмма Риязның, башка образлардан аермалы буларак, портреты детальләргә шактый бай. Алар да уңай якка сөйли. Әгәр дә классикларда тышкы кыяфәтнең эчке дөнья белән нык-лы бәйләнешкә куеп сурәтләнүен һәм монда күзләрнең аеруча зур роль уйнавын исәпкә алсак, Риязның нур тулы ике күзе аның яхшы күңеллелеге турында сөйләп тора.

Күзләргә Гыйматдинова әсәрендә зур игътибар бирелә. Кеше дигән сер йомгагын сүтү күзләр аша гына була ала дип өйрәтә Убыр да: «Адәм күңеле карурман кебек караңгыдыр, абага кебек күренмидер... Төшсәң, күзләр аша гына төшәрсең адәм күңеленә. Ни яман

асрый адәм, ни яхшы саклый — күздән укырсың».

Әмма кайчак күзләр дә алдый икән. Әсәрдән күренгәнчә, күзенә шулай ук нур тулуга карамастан, председательнең төпчеге Галимҗан, нигездә, әтисенең дәвамчысы булып һәм аның сыйфатларын бары тик заманага яраштырган булып чыкты.

Н. Гыйматдинованың герой һәм героинялары портретын һәр укучы үз күңелендә үзенчә ясый дип әйткән идек. Миндә Сәвилә үткен, җор телле, сабыр, сүзен тыйнак, әмма үтемле итеп, йөрәктән сөйли торган, уйчан, хыялый, әмма җилбәзәк түгел, киресенчә, басынкы булып күзалланган иде. Күбәләк канаты кебек селкенеп, лепердәп торучы зат түгел бу, югыйсә дөнья аны изәр, сытар иде. Бу — көчле һәм гайрәтле зат. Шуның өчен дә К. Тинчурин исемендәге театрда куелган «Сихерче» спектаклендә артистка тудырган Сәвилә образын кабул итә алмадым. Режиссерның аны артык хыялыйлыкка мануына, артистканың бигүк талантлы булмавы да өстәлеп, күңелсез генә нәтиҗә килеп чыккан.

Сәвилә — бөтенлеккә ирешкән шәхес. Аның омтылышлары, теләкләре, мөмкинлекләре каршылыкта түгел. Аның эчендәгесе тышындагыга тәңгәл килә. Бу — кызның бер үк вакытта бәхете дә, бәхетсезлеге дә. Көчле шәхес буларак, ул сүзендә дә, эшендә дә башкаларга яраклашудан ерак тора. Безнең кешелек җәмгыяте, күп очракта, үзенең әгъзаларыннан сер йомгагы ясый. Кайчак кешеләрдә үзләренә охшамаганнарга карата нәфрәт уяна. Шуңа да «ак каргалык»ка үзен-үзе дучар итәргә күп шәхесләр батырчылык итми. Күпләр ярашып яшәүне артыграк күрә. Риязны искә төшерик. Сәвиләнең табигатьне яклап сөйләгән сүзенә каршы ул түбәндәгечә җавап бирә:

«— Син, Сәвилә, кызык сөйләдең. Тере организм турында да, галәм белән охшашлыклар турында да. Болынны кызгануың да әйбәт. Әгәр синең сыман халыкка сөйләп бирсәм, безнең председатель акылдан язган, диярләр. Ә йодрык белән орктәсе килми, беләсеңме?

— Абруй саклыйсың, әйеме?

— Әтине «кансыз» дип сүктеләр. Мине «җүләр» дисәләр? Мин бит инде бер урталык табарга тиеш!»

Сәвилә һәрвакыт диярлек җан һәм матди житешлек дигән төшенчәләрне каршылыкка кертә. Аның өчен һәрнәрсә җан аша уздырыла, ул матди дөньяга җан тәрәзәсе аша карый. Заман туктаусыз рәвештә кешенең бәхет угын «житешлек, туклык, байлык» дигән якка тартса, Сәвилә өчен «күңел, хис» төшенчәләре беренчел булып тора. Кешенең тулы бәхете өчен боларның һәр икесе мөһим икәнне дә аңлый ул: «Авылдан кеше акча эшли алмаганга күрә генә качмый, Рияз, ямь тапмаганга да китә». Кем гаепле моңа? Һәм ничек кайтарырга авыл ямен? Һәм нәрсә ул, гомумән, авыл яме? Сәвилә карашынча, ул ямь-яшел болын, агуланмаган басу-кырлар, кешеләр арасындагы байлык, дан-шөһрәткә корылмаган, эчкерсез мөнәсәбәтләр, туганлык хисе.

Н. Гыйматдинованың әсәрләре мәгънәле символларга бай. «Сихерче»дәге ике күрше ишегалдын урталай бүлүче койма — ул урын бүлү генә түгел, ул — җаннарны да бүлү. Сәвилә һәм аның яхшы йөрәкле апасы Мәликә Тәминдарлар белән бер дөньяга сыешып яши алмыйлар. Тәминдар көчсезлеге, битарафлыгы аркасында коймәнең теге ягында калды. Гомумән, әсәрнең барлык геройлары шул Тәминдарлар калган якка сыеп бетә диярлек. Сәвилә япа-ялгыз, повесть ахырында аны апасы да ташлап китә. Иң сискәндергәне дә шул баш геройның ялгызлыгы булды. Болай барса, буыннар чылбыры өзелү ихтималы бик зур. Сәвилә күпме генә эзләсә дә, Убыр өйрәткән һәм үзе туплаган тәҗрибәсен тапшырырга үз кисәген таба алмау куркынычы бар.

«Сихерче» — эшләнеше, темасы, күтәрелгән мәсьәләләре буенча әдәбиятта вакыйга дип саналырлык әсәр. Кешелек җәмгыяте, фикер агышы бер урындарак таптана икән. В. Гюгоның атаклы «Собор...»ындагы «сихерче» һәм Гыйматдинованың сихерчесе язмышы, нигездә, уртак. Алар бары көрәш алымнары белән генә бераз аерыла.

Дөнья үлчәвенең явызлык, битарафлык салынган ягы һаман баса бара. Көннәрдән бер көнне каршы якның бөтенләй бушап калу ихтималы зур. Автор шул хакта кисәтә.

«Сихерче» җыентыгына кертелгән «Ханым-солтаным» әсәре иҗтимагыйпсихологик повесть жанрына карый. Автор шәхесләрнең күңел дөньясын мәхәббәт ситуациясе аша ача. Әсәрдә башка ситуация-проблемалар, ягъни табигатьне саклау, кешенең хезмәткә мөнәсәбәте кебек мәсьәләләр урын алса да, беренче урынга барыбер мәхәббәт ситуациясе калкып чыга. Шәхеснең эчке трагедиясен сөю эшләре аша ачу Н. Гыйматдинованың яратып һәм белеп кулланa торган алымы.

Әлеге авторның әсәрләре үзенчәлекле стильгә, мавыктыргыч сюжетка ия. Анда чор һәм милләт, кешелек өчен мөһим мәсьәлә-проблемалар тасвирый осталык белән тыгыз үрелеп бара.

Китап базары көннән-көн ярлыланган бер чорда «Сихерче» җыентыгының дөньяга чыгуы һәм матур әдәбият сөючеләрнең игътибарын җәлеп итүе куанычлы хәл.

Чоры шундый. Көчле яңа әсәрләр көтә халык. Бәлаләребез турында шәрран ярып сөйли торган әсәрләр көтә.

**Руфия ГЫЙЛӘҖИЕВА-ХӘМИДУЛЛИНА,**
**педагогия институты аспиранты**

## УЙМАК УЙЛАР

**(Әхлак турында)**

Кешеләрне яратудан да нәфисрәк сәнгать юктыр.

Е. ВИНОКУРОВ

Йөрәкне бары тик йөрәк белән генә дәваларга мөмкин.

ЛЕВИТАН, врач

Кешеләрне ярату — коточкыч кыен бурыч.

Н. ПОГОДИН

Эчкечелек — үзең теләп алган акылсызлык ул.

СЕНЕКА

Башкалар кайгысын уртаклаша белү — кешелек яшәешенең иң мөһим законы.

Ф. ДОСТОЕВСКИЙ

Дошманыңнан курыкма — ахыр исәптә, ул сине үтерә генә ала. Дустыңнан курыкма — соңгы чиктә ул сиңа хыянәт кенә итәргә мөмкин. Битарафтан курык...

МӨХӘММӘТ ӘБҮ-НАСЫЙР

Игенне үстерү авыр, кешене үстерү авыр, кальбеңдә игелекне үстерү тагын да авыррак.

Үзбәк халык мәкале

Җир ярылган тәкъдирдә, аның ярыгы шагыйрь йөрәге аша узар иде...

Һ. ҺЕЙНЕ

Явызлык эшләү өчен тәһарәт алырга кирәкми.

Татар халык мәкале

# САМАТ ШАКИРГА — 70 ЯШЬ



1962 елдан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь һәм публицист Самат Шакир (Самат Фәтхерахман улы Шакиров) 1924 елның 15 апрелендә Әтнә районының Күәм авылында туган.

Арча педучилищесын, соңыннан читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, авыл мәктәпләрендә укытучы, директор; район, өлкә газеталарында әдәби хезмәткәр, Татарстан китап нәшриятында редактор вазифаларын башкара, 1943—1945 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә.

Беренче шигыре 1939 елда, Абдулла Алиш фатихасы белән, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналында басыла. 1951 елда «Бәхетле көнем» исемле беренче китабы дөнья күрә. Хәзер ул — уннан артык шигырь китабы авторы (1984 елда сайланма характерындагы «Яраннар чәчәк аткан» исемле күләмле җыентыгы басылып чыкты).

Соңгы елларда Самат Шакир күбрәк чәчмә әсәрләр — очерклар, документаль повестьлар язды. Алар сугыш каһарманнары, бүгенге көн кешеләре — замандашларыбыз, якташларыбыз турында («Легенда егетләре», «Үлемсезләр», «Үлемне җиңгән батыр» һ.б.). Ул — каһарман полковник, мәшһүр Дахау тоткыны, шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең фронт көндәлекләрен, шигырьләрен дөньяга чыгарды, тормыш юлы турында очерк-китап язды, фронтовик әдипләр турында «Алар сафта» исемле китап төзеп нәшер итте...

1984 елда С. Шакирга «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

Юбилее белән котлап, бу санда шагыйрьнең төрле елларда язган берничә шигырен тәкъдим итәбез.

## Килмә, килмә кичен бакчага

Күкнең йолдызлары энҗе булып
Сибелгәннәр гүя юлыңа...
Син киләсең... Озын кара чәчләр
Үрелгәннәр ике толымга.

Син киләсең әкрен генә атлап,
Әллә нишләп китте күңелләр.
Сиңа карый гүя алмагачлар,
Баш ияләр гүя сөмбелләр.

Көлгән чакта битең уелып китсә,
Уелып китә минем йөрәгем.
Бу мәхәббәт нигә кинәт кабына?
Белсәң әгәр, әйтеп бир әле.

Күз карашың... Ах, ул серле күзләр
Тибрәндерер тын су өсләрен.
Тибрәнгән су кебек булырмын дип
Куркам, куркам. Аннан нишләрмен?

Зифа таллар бөгелә, юк, тал түгел,
Синең билең нәфис тал кебек.
Сине күргәч, бик, бик якын килеп
Әйтер сүзләрем дә бар кебек...

Белмәгәнмен: күңелем яшь икән шул,
Чәчләремә көмеш ятса да.
Дәртле яшьлегемне чакырып син
Килмә, килмә кичен бакчага.

*1949*

## Хис

Бу урында иске бер тегермән
Тора иде бераз янтаеп.
Кая киткән хәзер? Эзе дә юк.
Су читендә тора зур каек.

Мин янына аның килеп бастым,
Ишкәкләре тора бабайның.
Кәкре сукмаклары ник күренми
Яланаяк йөргән малайның?

Кая киткән очкыннарын сипкән,
Бәрәңгеләр күмгән учагым?
Тау өстенә менеп күз ташлауга,
Яңа төзелеш җәйде кочагын.

Башкалада белем алганнан соң
Быел кайтсам туган җиремә,
Ат саклаган җирләр елга булган,
Ул тоташкан инде Иделгә.

Башын иеп тора карагайлар,
Күренә ташлы елга ярлары...
Җитәкләгән яшь агачлар килеп
Су читенә үскән талларны.

*1955*

*
* *

Алтын тәңкә кебек Ай һавада,
Сары буяу сөрткән җиргә дә.
Карабодай сары чәчәк аткан,
Сары кунган хәтта җилгә дә.

Алтын төсе кергән яфракларга,
Алтынланып йоклый казлар да.
Алтын чаклар — егет чаклар кирәк
Алтын кичнең ямен аңларга!

*1960*

*
* *

Скрипка тотып, сеңелем Гөлназ
Башын чайкый-чайкый тирбәлә.
Кыллар түгел, гүя кемдер шунда
Моңлы итеп җырлап җибәрә...

Сеңелем уйный ничек шома итеп,
Күз иярми кайчак кулына.
Кайчак тынып кала, салмаклана...
Бу бүлмәдә гүя ул гына.

Берәүне дә күрми, ярсып, ташып
Көй агыла чишмә суы күк,
Кайчак дәртләндерә, шатландыра,
Пар ярларның бәхет туе күк.

Скрипка уйный минем сеңлем,
Һич ялгышмый баса кылларга.
Бик күпләрне үзенә соклandыра,
Күпләр әзер аңа җырларга.

Теләгем шул: ялгышмасаң иде
Тормыш кылларына басканда.
Тик бер «җырчың» булсын, ишегеңне
Кайчан гына килеп ачсам да.

*1962*

## Мин күпер янында торам

Мин күпер янында торам:
Яфраклар инде сары:
Сары яфракка төренгән.
Мул сулы Ашыт яры.
Талларның башларын ия
Көзге җил исә-исә.
Яңгыр камчысы чыжылдый,
Яфракны кисә-кисә.
Болында тора эскертләр
Моң гына башын иеп.
Торналар оча һавада:
«Язга кайтырбыз»,— диеп.
Сайрамый инде кошлар да,
Тирә-як тынып калган.
Тайлар да су эчми хәзер
Сузылып кына ярдан.
Мин күпер янында торам:
Сары яфраклар оча...
Мин бик шат, туплар шартламый,
Замана шулай торса!

*1977*

# МИЛЛӘТНЕҢ ЧЫН ХИСЛӘРЕ...

Тормышны һәм, аерым алганда, җәмгыятьне нинди генә көчләр әйдәп бармасын, элек хөкем сөргән атеистик тәрбияне хәзерге дини тәрбия, коммунистик инануны башкасы алыштырмасын — һәрчак бер олы төшенчә бар: ул — кеше күңеле, аның сафлыгы, намусы.

Язучы да әнә шуны күз уңыннан җибәрмәскә, үз алдына маяк итеп кабызырга тиеш.

Язучы бит ул игенче кебек. Игенче дә еллар коры килсә дә, яңгырлы булса да уңышны киметмәскә, ил табынына үз вакытында ризык куярга бурычлы.

Язучы тормыш ваклыкларыннан өстен, намусына һәм иманына тугры булып, алдагы офыгын ачык күргән хәлдә, иҗат газаплары белән яна-яна, һәрдаим очрап торган киртәләрне җимерә-җимерә иҗат итәргә, гади укучы өчен (чиннар, өстен катлаулар өчен түгел) хезмәт итәргә тиеш.

Соңгы еллар әдәбияты шактый үзенчәлекле, күпкырлы булса да бер төшенчә — сафлык — күңел сафлыгы, милләтебез сафлыгы үзгәрмәс булып кала.

Җил искән якка арка боручыларны күңел кабул итми. Актуаль проблемага исереп кенә иҗат ителгән әсәрләрне атап торуны кирәк санамыйм. И. Сәләховның «Колыма хикәяләре»ннән соң чыккан аваздаш әсәрләрне уку кызыклы түгел инде. Аларның тәэсир итү көче күпкә кимрәк тоела.

Мин балаларыма әкият сөйләргә яратмыйм. Бала үзе дә әкият дөньясына кереп китеп: «Әни, безнең бакчага аю килде», «мин сарай артында бүре күрдем»,— дип башына кергән юк-бар фикерләр белән азаплана.

Мин балаларыма: «Ә без кечкенә чакта...»— дип башлыйм да, әби-бабайларның гореф-гадәтләрен, әти-әниләрдән ишеткән вакыйгаларны, без кечкенә чакта уйнаган уеннар хакында сөйлим. Шактый үсә төшкәч тә бу әле аларны кызыксындыра, мавыктыра.

Һәм шул чакта...

Һәм шул чакта М. Мәһдиевның «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» әсәрләреннән өзекләр укыйбыз. «Икмәк пешерү» бүлеге үзе генә дә ни тора!

Бер-берсе белән бәйләнешеп барган вакыйгалары, сюжет сызыгы юк дип тәнкыйтькә дучар булган бу әсәрдә, барлык ваклыклардан өстен булырлык олы дәлил — автор татар иленә, татар дөньясының гади Кешесенә мәңгелек һәйкәл салды. Ул һәйкәл — сүзләр һәйкәле. Аны күрә белергә, бөтен ваклыклары белән тоярга гына кирәк. Татар дөньясының югалган, шулай да матур килеш, саф килеш сакланган милли бизәкләре, гореф гадәтләре, сүзләр байлыгы барсы да М. Мәһдиев әсәрләрендә тупланып бирелүе авторның никадәр бөек шәхес, алай гына да түгел, милләтебез горурлыгы булырлык ихтирамлы язучы икәнен раслый. Әдәбиятыбызда соңгы еллар казанышы булырлык бу әсәрләр бүгенге укучыга әти-әни, әби-бабай традицияләрен онытып килүче буынга тарихыбыз гәүһәрләре өстенә ябылган япманы ачып, милли горурлыгыбызның гүзәл сәхифәсен күрсәтү ул. Әсәр җиңелчә юмор, мавыктыргыч тел, житез фикерләү белән язылган.

Әдәбиятта милли хис, милләткә генә хас үзенчәлек кирәк. Бөек Болгар иле, гүзәл Сөембикәләре булган татар халкын «безнең милләт менә ул!» дип күрсәтерлек әсәрләребезне укучыга җиткерү чараларын әле уйлыйсы бар. Тәмле итеп әзерләнгән ризыкны матур итеп тәкъдим итәргә дә кирәк.

Әдәбиятыбыз мактанычы булырлык әсәрләрне радио-телевидение аша рекламалый да белмибез. Оят билләһи: этләр, мәчеләр ризыгына реклама ясыйлар, фәхешлекне күрсәтәләр... Ә китаплар?! Кешенең рухи ризыгына реклама юк дәрәҗәсендә.

Хәтеремдә, берничә еллар элек радио аша яңа әсәрдән өзек укыйлар. Тапшыру башына өлгермәдем, әмма мавыгып тыңлый башладым: «Моны шулай булдырып М. Мәһдиев кына яза ала» димен һәм чынлап та әсәр тәмам булгач диктор: «Сез язучы М. Мәһдиевның яңа «Бәхилләшү» романыннан өзек тыңладыгыз»,— диде. (Әсәр әле басылып чыкмаган иде.) Мин аны көтеп алдым.

Соңгы елларда язылган уңышлы әсәрләр рәтенә Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» романын да кертер идем.

Шәһәр һәм авыл бюрократларын бер чыбыкка тезеп, җәмгыятьнең җимергеч көчләрен күрсәтү һәм гади эшче, колхозчының фаҗигасен бөтен тулылыгы белән күрсәтүче бу әсәр күпләрне җәлеп итте.

Авылыбыздагы 80 яшьлек бер карт укытучыны, гомере буе татар әдәбиятын балаларга җиткерүче мөхтәрәм ханымны да бу әсәр тирән дулкынландырган.

«Иң башта сорыйм әле, минем хәтерем начарланып бара, Аяз Гыйләҗевның безнең якларга килгәне юкмы аның?— ди ул — монда безнең бөтен җитәкчеләр сурәтләнгән, хәтта читтән килеп йөрүче әрмәннәргә кадәр».

Әсәрнең иң аяныч ноктасы — хатын-кыз намусы тапталу. Ир бәхете — ил тоткасы булырдай ир юкка чыга; бала бәхете — киләчәкне алга өндәүче көч гарипләнә, барсы таплана, пычрана. Моны чорыбызның иң зур трагедиясе дип аңларга кирәктер, мөгаен. Бу әсәр татар дөньясының реаль чынбарлыгын күрсәтүе белән безне уйланырга, кабат-кабат уйланырга мәҗбүр итә. Чаң сук! Боларга каршы көрәшкә бас! И халкым, көчең җитәрме!?

Соңгы елларда уңышлы иҗат итүче тагын бер авторны атыйсым килә. Бу — Нәбирә Гыйматдинова. Мин хатын-кыз хисләрен, уйларын, омтылышын бөтен тулылыгы белән ачарга тырышкан Ә. Еники, Г. Ахунов, Г. Бәширов, Ф. Хөсниләр алдында тирән ихтирам белән баш иям. Әмма бүгенге хатын-кызларның омтылышын, ярсулы хисләрен Н. Гыйматдинова әсәрләрендә күрәм. Үрнәк алырдай, бөек идеалларга табынып яшәүче дә юк анда, хезмәте аша югары күрсәткечләргә ирешеп орден-медальләр белән дә чуарланмаганнар алар. Хатын-кыз җаны, җилкенгән күңеле бар аның әсәрләрендә. Хатыннар ярсуы, ялгызы, язмышы, оста сурәтләнүе белән көчле алар. Хатыннарның рухы нык, иманы камил, барыр офыгы якты булсын өчен кирәк аның әсәрләре. «Рухи гарип адәмгә планетаның киләчәге дә, икмәге дә, баласы да кирәкмәс иде» (Н. Гыйматдинова «Алан уртасында ялгыз йорт»).

Татар әдәбияты, татар язучыларының журнал һәм газеталардагы мәкаләләренә кадәр укып барам, радио һәм телевидение аша чыгышлары да минем өчен кызыклы. Ләкин яхшы әдәби әсәрләр укучыны канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә күп дисәм ялгыш булыр. Төрле газета-журналлар чыгару мәшәкате тарттымы, әллә илдә барган үзгәрешләр кыйблаларны югалттымы, язучыларның активлыгы кимеде. Ил гаме, милләт гаме белән янып көюче, көн кадагына сугар әсәрләр менә бүген, беркайчан да булмаганча кирәгрәк, кадерлерәк бит.

Проблемалар, бөтенләй ачылмаган өлкәләр әле тулып ята бит тормышыбызда. Язар темагыз бетеп китсә рәхим итеп авылга килегез, безнең якларга.

**Рәмзия ЖИҺАНГӘРӘЕВА,**
Әгерҗе районы Кичкетан авылы.

# Әхәт Сафиуллин

ИКЕ ЮМОРЕСКА

## ОСТАЛАР

Жәйге челләдә телевизор экранында пәри туе уйный башлагач, кооперативка шалтыраттым.

Оста җибәрербез, диделәр. Нинди бәндәгә тап булырмын, ни хәлдә килеп керер, дип шикләнеп кенә көтә башладым. Өченче көн, әнә, чакырган электромонтерын өченче каттагы үз фатирына күршебез көч-хәл белән күтәреп алып менде. Миңа да шундый бер әлкәшне җибәрерләр инде, ходаем.

Ялгышканмын. Ишегемнән елмая-елмая фәрештәдәй бер егет килеп керде. Галстуктан. Борыны да үз төсендә. Күренеп тора, юньле адәм бу.

Телевизорны кабызып җибәрдем. Анда февраль бураннары котырына. Ә бит Кара диңгез буен күрсәтәләр, шайтан алгыры!

— Күрәм,— диде оста мәгънәле генә итеп.— Хәзер карыйбыз...

Ул минем телевизорга, шәһәр урамында бөгәрләнеп яткан питон еланын күргәндәй, сәер генә күз ташлады да аның әле бер, әле икенче тоткасын боргаларга керешге. Ләкин кояшта кызынып яткан ник бер чәчбикәне күреп булсын!

— Мин аларны хәйран боргаладым инде,— дидем.— Минемчә, эчендә берәр нәрсәсе ватылган булырга тиеш...

— Эчендә-ә?! — дип сорады ул. Шунда аның чәчләре үрә торды, ә үзе нигәдер бераз чүгә төште. Бер миңа, бер телевизорга карый.

— Минемчә, шулай. Берәр лампочкасы янмадымы икән...

— Карыйк алайса,— диде егетем, бераз тынычлана төшеп.— Алай булырга да бик мөмкин.

Ул, телевизорның арткы капкачын ачып, андагы галәмәт күп лампочкаларга, үрмәкүч оясыдай үрелгән үткәргечләргә карап, тынсыз калды. Күзләрен челт-челт иттергәләп бик озак басып торды. Тик аннары гына, бераз ушына килеп, кулы белән каядыр тыгылды һәм... күзне ачыпйомып өлгергән арада, өч метр чамасы читтә торган өстәл өстенә менеп кунаклады.

— Ни булды? — мин әйтәм. Үзем егетнең февраль карыдай ак йөзенә карыйм.

— Сугыша бит бу! — ди.— Моны тизрәк ябып куярга кирәк,— ди.

— Экрандагы буран белән нишләргә?

— Ява бирсен сәнә! Ток сугып үтергәнче, кар бураны түгел, давылы да мең мәртәбә яхшырак!

---

Әхәт Сафиуллин (1936) — *прозаик, «Язларында ялгыз йөрсәң...», «Онытылган вәгъдә» китаплары авторы. Казанда яши.*

Остазыбыз калтыранган куллары белән телевизорның арткы капкачын ябып та куйды. Һәм миңа мөлдерәгән күзләрен төбәп, ялварулы тавыш белән:

— Бәлки, сантехника буенча берәр нәрсә эшләтәсегез бардыр ә?— дип сорады.

— Миңа сантехник нигә, минем телевизорым эшләми бит!

— Моның әчен белмим шул мин...— Останың хәтта ирennәре дерелдәп куйды.— Ә менә сантехника буенча ни телисез, шуны эшли алам аңысы...

Егетнең ихласлыгын күреп, күңелем йомшарып китте. Шушы әчкерсезлеге өчен аңа нинди дә булса яхшылык эшлисем килде. Кинәт кухнядагы су кранының кәне-төне елап утыруы исемә төште.

— Бер кранны алыштырасы бар иде дә, тик кранын кайдан аласың...— дип куйдым мин, өметсез генә.

— Чынлапмы?!— Егетем шатлыгыннан түшәмгә сикерде.— Кран табуы пүчтәк ул!

Чемоданын ачып җибәрүе булды — телсез калдым. Телевизор төзәтүче останың тылсымлы чемоданында ниләр генә юк иде! Барысы да сантехника буенча! Резин бәжраларлардан алып, бишенче номерлы торба ачкычына тикле бар! Вентилен, кранын әйткән дә юк инде.

— Б-б-олар телевизорга да барамыни?!— дидем мин, гаҗәпләнеп.

— Мин, гадәттә, аларның ручкаларын гына боргалыйм,— диде ул.— Ягъни инструментсыз гына маташтырам. Эченә кермим. Анда керсәң, баш чыга торган түгел! Урман-чытырман...

— Алайса, ничек эшлисең соң син?!— дип гаҗәпләндем мин.

— Эшләмичә нишлисең...— дип көрсенде егет.— Күтәрделәр мине...

— Ничек күтәрделәр?!

— Мин кооперативта сантехник булып эшли идем,— дип сөйләп китте оста.— Беркөнне шулай хуҗа чакырды да: «Менә нәрсә, иптәш Хуҗин, карыйм да, ошыйсың син миңа,— диде.— Эчмисең, тартмыйсың, зыялы үзең, шуңа күрә күтәрергә булдык сине — иртәгәдән башлап телевизор төзәтүче булып эшли башларсың»,— диде. Сез нәрсә?! Миңа телевизор да — бер, сандык та — бер, дип, каршы төшеп караган идем дә, кая ул!.. Безгә эчмәвең кыйммәтрәк, ди. Шулай итеп, телевизор төзәтүче булып киттем инде...

Егет алтын куллы слесарь икән. Күз ачып-йомганчы кранны алыштырып та куйды. Ник бер тамчы аксын икән!

— Телевизор турында бер дә кайгырмагыз,— дип тынычландырды ул.— Мин бер яхшы останы беләм. Тегеләй, бераз чылатырга яратканга сантехник итеп эшендә төшерделәр аны. Бу сандыкның эчендә нинди хәзинәләр барын ул биш бармагы кебек белә!

Икенче көнне сантехник чакырып шалтыраттым. Егет дөрес әйткән икән, ул, чыннан да, менә дигән телевизор төзәтү остасы булып чыкты. Тик башта, бер ярты алып, останың үз башын төзәт икән.

Әмәле табылды бит. Торба акса, канализация тыгылса, вентиль куярга кирәк булса — телевизор төзәтүчене чакыртам, телевизорым ватылса — сантехникны сорыйм. Күз генә тимәсен, «зәңгәр сандыгым» да эшли, кухня белән ванна бүлмәсе дә ал да гөл!

Тик менә, каһәр суккыры, башыма яңа бәла төште бит әле. Суыткычым, бизгәк тоткандай, соңгы мәртәбә калтыранып алды да җан тәслим кылды. Инде кемне чакыртыйм икән, дип уйлый-уйлый тәмам баш катты. Останы, тегү машинасы ватылды, дип чакыртсам ничек тә, урындыкларны тышлыйсы бар, дип дәшсәм ничек... Әллә электрик чакыртыйммы, яки буяучынымы икән? Аларның кайсысы суыткычлар төзәтү остасы икәнен чамалап кара! Моның өчен үзеңә дә оста булырга кирәк шул...

# ДӨНЬЯ КАЯ ТАБА ӘЙЛӘНӘ?

Их-ма! Әйләнә-тулгана дөнья дигәнең! Һаман хәрәкәттә ул. Бер карыйсың — кеше җир җимертеп эшләп йөри. Ә икенче карасаң... ул инде якты дөнья белән алыш-бирешен дә өзгән.

Юк, дөнья өч кит өстендә түгел, яхшы кадрлар өстендә тора икән, җәмәгать. Моны без хуҗабыз үлгәнгә атна-ун көнләп вакыт үтмәс борын ук аңладык. Яхшы кеше, үз эшенең остасы иде мәрхүм. Төзү һөнәрен биш бармагы кебек белә иде. Ләкин нишләмәк кирәк... Үлгән артыннан үлеп булмый шул.

Күп тә үтмәде, аның урынына башка берәүне куйдылар. Бик зыялы кеше, «сез» дип кенә сөйләшә, мин сиңайтим. Тел мәсьәләсен әйткән дә юк — үзе белән танышырга дип җыелгач, шундый итеп сөйләде! Египет пирамидаларыннан башлап, хәзерге төзүчеләрнең җәмгыятебездә тоткан урыны да, илебез төзүчеләре алдында торган бурычлар да калмады. Ник бер тапкыр тотлыксын, ник юри генә бер ялгышсын! Бирсә дә бирә икән ходай кешегә телне. Ул сөйләгән өч сәгать вакыт өч минут булып та тоелмагандыр, валлаһи! Әллә каян сизелеп тора: бер-ике генә гәзит алдырмый бу. Аның чыгышыннан соң көч-хәл белән генә өнебезгә килдек. Ә өнгә килдеңме, үзегез беләсездер, иге-чиге булмаган эш, мәшәкать алга килеп баса. Алар, әлбәттә, ил масштабыннан күпкә тар, ләкин төгәл, конкрет ягъни. Кыскача әйткәндә, без быел ундүрт катлы йорт салып, туксан алты гаиләне сөендерергә тиешбез. Тик... (менә шушы «тик» белән шыгрым тулы безнең тормыш). Йортның подвал өлешен салырга кызыл кирпеч юк. Әллә инде аны ясарга кызыл балчык беткән, әллә завод өлгерә алмый,— юк кына бит кирәкле кызыл кирпеч!

Шуңа күрә, әле яңа хуҗа энергиясен башка нәрсәгә түккәнче шушы мөһим мәсьәләне җайга салырга булышмасмы дип, аны күктән безнең конкрет бурычлар җирлегенә төшерергә булдым:

— Кызыл кирпеч белән эшләр бик начар бит әле безнең, Җәүдәт Хәбибрахманович,— мәйтәм.— Лумумба урамындагы йортны башлап җибәрә алмыйбыз. Бер атна инде — ташчылар тик утыра...

Хуҗабыз сискәнеп киткәндәй булды.

— Нинди кирпеч дидегез? — дип сорады ул аптырап.

— Кызыл кирпеч,— дидем мин.— Подвал стенасын салырга кирәк...

— Ә агы белән эшләр ничек? — дип кызыксынды Җәүдәт Хәбибрахманович.

— Силикат кирпечен әйтәсезме?

— Ә аның төсе нинди? — диде хуҗа, бик эшлекле кыяфәт белән.

— Ак, билгеле... Ә безгә хәзер кызыл кирәк...

— Менә, иптәш, э-э...— дип хуҗабыз миңа карады. Фамилиямне әйтмәкче иде бугай.

— Сибгатуллин,— дидем мин.

— Менә, иптәш Сибгатуллин, сез минем уйны бер нәрсәгә этәрдегез әле... Шулай дияргә ярасa, бер гомумиләштерүгә, ягъни. Нәрсә әйтмәкче булам мин? Шуны әйтмәкче булам, иптәшләр: безнең һәрберебез өчен инициативалы булу бик мөһим нәрсә. Аңлыйсызмы? Эшнең асылы — и-ни-ци-а-ти-ва-да! Шуңа күрә нинди дә булса мәсьәлә күтәрер алдыннан, халык әйтмешли, җиде кат уйларга, җиде тапкыр үлчәп карарга кирәк. Ә бит, беләсез булыр, уйланган кешегә чишелешен табып булмаган сорау юк дөньяда. Әйтик, менә хәзер иптәш Сибгатуллин күтәргән кирпеч мәсьәләсен генә алыйк. Ак кирпеч бар. Ә кызыл кирпеч кирәк. Ә нәрсә, иптәшләр, безнең промышленность кызыл буяу чыгармыймыни?! Ә?! Уйлап карасаң, артык берни дә сорамый ич монда! Тик инициатива гына кирәк монда, хөрмәтле иптәшләр!! Нужәли булган ак кирпечне кызыл төскә кертү шундый зур проблема инде, ә?!

Без бер-беребезгә карашып, тынсыз калдык. Кәләргә дә белмибез, еларга да. Чөнки ничәмә-ничә ел эшләп, ак кирпечне кызылга буяу мөмкинлеге турында ишеткәнебез юк иде әле.

— Бу — беренчедән,— дип сүзен дәвам итте яңа хуҗабыз.— Икенчедән, менә нәрсә, иптәшләр. Баштан ук, әйдәгез, бер-беребезне юк-бар сораулар белән борчымаска килешик... Тормышның катлаулы нәрсә икәнен барыбыз да беләбез. Анысы юк, монысы җитешми... Мин моның белән килешәм. Бүген иптәш Сибгатуллинга кирпеч кирәк, ди. Ә иртәгә иптәш Иванов белән Сидоровка, әйтик, нидер җитми, ди.— Җәүдәт Хәбибрахманович түшәмгә төртеп күрсәтте.— Ничек дип атала әле менә бу? Э-э... түшәмдәге?..

— ПК 63-12 плитәсе! — дип, чыбыркы шартлаткандай ярып салды берсе.

— Петров белән Сидоровка әнә шул плитәләр кирәк булыр. Гомумән, азмыни ул кирәк нәрсәләр!.. Бөтен нәрсә җитешле булса, җүләр дә салыр иде йортларны. Шуңа күрә тагын да шул инициатива мәсьәләсенә килеп терәләбез, иптәшләр... Бурычлар билгеле, максатыбыз изге... Алга, иптәшләр, алга! Яңа горизонтлар яуларга!

Инициатива дигәннән, Җәүдәт Хәбибрахманович үзе шактый ук өлгер кеше булып чыкты. Бер ай эчендә менә дигән итеп кабинетына ремонт ясатты, күрше бүлмәне бушаттырып, аңа үзеннән ишек уйдырды, анда телевизор, диван һәм дә тагын кирәкле башка җиһазлар куйдырды. Кыскасы, күз явын алырлык ял бүлмәсе килеп чыкты. Бераздан кабинетына әллә ниткән сөйләшү аппаратлары куеп бетерде. Андагы лампочка-төймәләрне күрсәң!;;

Тик... (менә шушы «тик» белән шыгрым тулы шул безнең тормыш). Тик план үтәлеше генә, таудан тәгәрәгән арба сыман, шалтор-шолтыр килеп, көннән-көн айдан-айга аска таба тәгәрәде.

Тагын бераздан, инде эшнең яхшыруына өмет тәмам өзелгәч, безнең хуҗаны тагын да югарыракка, берләшмәгә үк күчерделәр. Инде төзелеш буенча кирәкле тәҗрибә туплады, дип уйладылар бугай... Дөрес, инде ул яңа дачасын төзеттереп бетергән, машинасын яңага алыштырырга өлгергән иде. Инициативалы кеше эшне тиз тотарга ярата бит ул!

Әйтергә кирәк, бәхетле дә була андый кеше, шайтан алгыры. Шул ук Җәүдәт Хәбибрахмановичны алыйк. Бәхете булмаса, партия аппаратын кыскартканнан соң, төзелеш буенча шундый җаваплы урынга утыртырлар идемени аны... Хәер, монысы тәвәккәллек җимеше бугай. Май-сыр техникумына укырга кереп, корыч кою институтын тәмамлаган килеш райкомның җиңел промышленность бүлегендә эшләгән кеше өчен тәвәккәллек түгелмени бу?

Их-ма! Әйләнә-тулгана дөнья дигәнең. Һаман хәрәкәттә ул. Бер карыйсың, ике карыйсың... Әй, әйләнә дөнья, әй, тулгана... Кем өчендер яхшы булсынга әйләндерәләр...

## КАБАТ САЙЛАУЛАР НӘТИҖӘСЕ

13 мартта Татарстанда Россия Федерациясе Федераль җыелышының Федерация Советына һәм Дәүләт Думасына кабат сайлаулар үткәрелде. Рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, исемлеккә кертелгән сайлаучыларның 58,5 проценты тавыш бирүдә катнашты.

Федераль җыелышның Югары палатасына — Федерация Советына — сайлауларда катнашучыларның 91,2 процент тавышын җыеп, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев һәм Республикабыз Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин (74,1 процент) депутат итеп сайланды.

Федераль җыелышның түбән палатасына — Дәүләт Думасына исә, тавыш бирүче күпчелек сайлаучыларның ышанычын яулап, Әлмәт шәһәр Советы рәисе Г. Егоров (73,9 процент), Чаллыдан кече предприятие директоры В. Алтухов (40,8), Чистайдагы ятим балалар йорты директоры Г. Баһаветдинов (69,1), Казаннан «Республика Татарстан» газетасының сәяси күзәтүчесе О. Морозов (46,8), Татарстан халык депутаты В. Михайлов (23,9 процент) үтте.

## КЫРЫМ РЕСПУБЛИКАСЫ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — КАЗАНДА

18—20 март көннәрендә Президент Ю. А. Мешков җитәкчелегендәге Кырым Республикасы делегациясе дуслык визиты белән җөмһүриятебез башкаласында булды.

Кунакларны килгән көнне үк Казан Кремлендә Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев кабул итте. Ике республика делегацияләренең очрашуы барышында сәүдә-икътисадый хезмәттәшлек турындагы Килешүнең үтәлеше, аны үстерү перспективалары һәм якларны кызыксындырган башка мәсьәләләр тикшерелде.

## ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ — ШАРТНАМӘ

30—31 март көннәрендә Татарстан Республикасы вице-президенты В. Лихачев Россия Федерациясе Министрлар Советы Рәисе В. Черномырдин, вице-премьер Ю. Яров, РФ тышкы эшләр министры А. Козырев һәм башка рәсми кешеләр белән очрашты. Бу сөйләшүләр вакытында Россия — Татарстан мөнәсәбәтләре тикшерелде. Төп игътибар ТР белән РФ арасында 1994 елның 15 февралендә ике як та кул куйган Шартнамәне тормышка ашыру проблемаларына бирелде.

## ТАТАРСТАН ЕВРОПАГА «ТӘРӘЗӘ АЧА»

18 мартта Татарстан Республикасы вице-президенты В. Лихачев «Лендок-видео» (Россия), «Юлейсрадио» (Финляндия), «Скайлайн» (Англия) кинодокументалистларының иҗат бригадасын кабул итте. Әлеге иҗади берлек Идел буе республикалары, шул исәптән Татарстан турында күп серияле фильм төшерергә ниятли.

Вице-президент кунакларны республикадагы сәяси, икътисадый, социаль хәлләр белән таныштырды, халкыбызның күркәм традицияләре турында сөйләде. Очрашу барышында, Татарстан һәм аның башкаласы турындагы чынбарлыкны дөрес итеп күрсәтү җөмһүриятебезнең Европа илләре белән бәйләнешләрен киңәйтергә ярдәм итәр, дип билгеләп үтелде.

## МЕКСИКА ТАТАРСТАНГА ЯКЫНАЯ

«Гади генә Мария» теленовелласында баш рольне башкаручы Виктория Руффо 6—10 март көннәрендә Казанда булды. Атаклы артистканы һәм аның юлдашларын Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев кабул итте.

Мексика кунаклары, Казан университетының «УНИКС» тамаша залында, «Заря» кондитер фабрикасында, «Мелита» акционерлык җәмгыятендә һәм башка җирләрдә булып, меңнәрчә кешеләр белән очраштылар.

Республикабызда яшәүчеләрнең тирән мәхәббәтен яулаган В. Руффо, Казаннан киткәндә, шундый җылы һәм дустанә кабул итүләре өчен, эчкерсез кайнар рәхмәт сүзләрен җиткереп, Татарстанга быел тагын киләчәген белдерде. Төгәлрәк итеп әйткәндә, ул әлеге истәлекле очрашуны оештырган Татарстан тышкы икътисадый һәм мәдәни элемтәләр ассоциациясе президенты Наил Сөләйманов белән берлектә, җөмһүриятебез сабантуйларында катнашырга теләге барлыгын әйтте.

## ВАШИНГТОНДА — ТАТАРСТАН ВӘКИЛЛЕГЕ

Вашингтонда Татарстанның АКШтагы вәкиллеге эшли башлады. Беренче даими вәкил итеп 39 яшьлек Линар Латыйпов билгеләнде.

Бүгенге көндә Американың 50 гә якын фирмасы һәм банкы Татарстан белән үзара файдалы элемтәләр урнаштырдылар. Әлеге вәкиллек менә шушы эшләрне тагын да ки-

нәйтү, Америка инвестицияләрен республика икътисадына киңрәк тарту максатыннан чыгып төзелде.

## РӘССАМ БЕЛӘН ОЧРАШУ

17 мартта Президент М. Ш. Шәймиев Кремльдә Үзбәкстан һәм Татарстанның халык рәссамы, СССР Дәүләт премиясе һәм Үзбәкстанның Хәмзә исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Чыңгыз Әхмәровны кабул итте. Әлеге мәшһүр рәссам үзенең сынлы сәнгатьтә лаеклы урын алган тормышчан картиналары һәм Ташкент, Бохара, Сәмәрканд шәһәрләрендәге байтак биналарга ямь өстәп торган монументаль хезмәтләре белән дә яхшы мәгълүм. Башкалабыз Казанда да М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры залларын, елга вокзалы бинасын аның нәкышләре бизи.

Җөмһүриятебез Президенты Ч. Әхмәровны «Татарстан Республикасының халык рәссамы» дигән мактаулы исемгә лаек булуы һәм ике тугандаш халыкның рухи дөньясына дан җырлый торган әсәрләреннән торган шәхси күргәзмәсенең «Казан» милли-мәдәни үзәгендә ачылуы белән ихлас күңелдән кайнар тәбрикләде.

## ПРЕМЬЕР-МИНИСТР — КИТАП НӘШРИЯТЫНДА

Тиздән Татарстан китап нәшриятына 75 ел тула. Шул уңайдан, 31 мартта Татарстан Премьер-министры М. Г. Сабиров нәшрият һәм китап сәүдәсе хезмәткәрләре белән очрашты. Ул нәшрият эше белән танышты, җөмһүриятебездәге икътисадый хәл, бюджетны формалаштыру турында сөйләде, күп санлы сорауларга җавап бирде.

Очрашуда Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары З. Вәлиева, Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин, Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов катнашты.

## ИДЕЛ-УРАЛ ХАЛЫКЛАРЫ АССАМБЛЕЯСЕ КОРЫЛТАЕ

25—26 февральдә Чувашстан башкаласы Чабаксарда Идел-Урал халыклары ассамблеясен оештыру корылтае булды. Анда Башкортстан, Мари-Ил, Мордва, Татарстан, Удмуртия, Чувашстан республикаларыннан барлыгы 51 делегат катнашты. Җөмһүриятебездән килгән делегатлар арасында Татарстан халык депутаты, Югары Советның даими комиссиясе рәисе Фәндәс Сафиуллин, Татар иҗтимагый үзәгеннән Татарстан халык депутаты Марат Мөлеков белән Марс Шәмсетдинов, Татарстан Милли-мәдәни җәмгыятьләр берләшмәсе рәисе Аркадий Фокин, Чуваш иҗтимагый-мәдәни үзәге рәисе Николай Степанцев, Татарстан Республикасы партиясеннән КДПИнең музыка-педагогия факультеты деканы Рәгъде Халитов, Халыкара төрки яшьләр берләшмәсеннән Рәшит Минһаҗ бар иде.

Корылтайда Идел-Урал халыклары ассамблеясенең генераль секретаре итеп танылган язучы, Чуваш милли конгрессы рәисе Атнер Хузангай сайланды. Ассамблея сессияләре ел дәвамында, чиратлашып, алты республикада да уздырылачак.

## КАЗАН — ФЕСТИВАЛЬЛӘР БАШКАЛАСЫ

Мәркәзебезнең мәдәни тормышы һәртөрле вакыйгаларга бик бай. Мәшһүр җырчы якташыбыз Ф. Шаляпин исемендәге III Халыкара опера һәм балет фестивале тәмамланырга өлгермәде, Казан Идел буе пианистларын җыеп алды — пианофорум үткәрде. Март аеның икенче яртысында исә башкалабызда атаклы драматург К. Тинчурин исемендәге III Республика фестивале гөрләп узды. Анда җөмһүриятебездә эшләүче 12 профессиональ театр һәм тугандаш Башкортстаннан «Нур» театры артистлары күп санлы тамашачыларга үзләренең иң яхшы спектакльләрен күрсәттеләр.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Ватанны саклаучылар көне (23 февраль) һәм Халыкара хатын-кызлар көне (8 март) уңае белән, Татарстан язучылар берлеге урнашкан бинада фронтовик язучылар, әдибәләр һәм шагыйрәләр катнашында түгәрәк өстәл артында чәй мәҗлесләре уздырылды, истәлекле бүләкләр тапшырылды.

* * *

Язучылар берлеге идарәсенең 23 мартта булган чираттагы утырышында апрель аенда Г. Тукайга багышлап үткәрелә торган Халыкара шигърият бәйрәменә һәм җөмһүриятебез язучыларының июнь башларында үтәргә тиешле XII съездына хәзерлек мәсьәләләре каралды. Идарә карары белән, бер төркем язучыларга матди ярдәм дә күрсәтелде.

* * *

1—2 апрель көннәрендә җөмһүриятебезнең Балык Бистәсе районында «Татар әдәбияты көннәре» үткәрелде. Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, М. Маликова, Батулла, Р. Мөхәммәдиев, З. Мансуров, Л. Шагыйрьҗан, Г. Моратов h. б. каләмдәшләребез — барлыгы 30 га якын кеше — районның Котлы Бөкәш, Куки, Ямаш, Күгәрчен, Олы Елга, Тегермәнлек, Балтач (Юлсубино), Балыклы Чүкәй, Әшнәк авылларында булып, әдәбият сөючеләр белән очраштылар. Район үзәгендә үткәрелгән тарихи очрашу да күпләгән күңелләрдә якты-җылы истәлекләр калдырды.

# ЯКТЫ МОҢ

Рәссам Илгиз Гыймрановны «идән асты сәнгате» — «андерграунд» вәкиле, тоталитаризм чоры катакомбаларын ерып саф һавага чыккан урбаңизм чоры дәрвише — сталкер! — дип атыйлар. Мөгаен, бу дөрестер дә. Чөнки аның иҗаты, үзенең эчтәлеге һәм юнәлеше белән узган чор идеологиясе карынында, «иҗади берлек» сукмакларында, музей-остаханәләрдә туган сәнгать күренеше булып санала алмый, әлбәттә. Узган унъеллыкның башында мона охшаш милли хисләр белән сугарылган үзенчәлекле, тар реализмны инкяр итүче аңлы иҗат бары «читтә», тормыш төпкелләрендә, төрбә-ханәкәгә охшаулы караңгы почмакларда, шәһәр асты кое-подвалларында гына тернәкләнә алды. Ләкин шулай тар мохиттә туюына да карамастан, ул үзен иркәләнеп кенә гомер кичергән (һәм урынсызга күккә чөелгән!) официаль сәнгать тенденцияләренә каршы куя алды һәм гамьсез-битараф сәнгать тарафдарларын тешләп алырга да өлгерде. Ләкин, шул ук вакытта, Татарстанда туган оппозицион-альтернатив сәнгать, аның да аеруча усал тармагы булган авангард та 90 нчы еллар башында башка төсмерләр ала башлады. Дөресрәге, рәсем сәнгатендәге төрле юнәлешләр, иҗади хәрәкәтләр берләшеп, конструктив иҗади атмосфера булдыруда катнашырга омтылдылар. Сәнгатебез тарихына «татар халкының бәйсезлеккә омтылыш чоры» дип керәчәк 1990 — 1994 елларда туган «яңа сәнгать», элеккеге реалист осталар иҗатына яңа төсмер авазлар кертү белән бергә, позитив идеалларны, романтик хисләре белән гавәмне җилкендерерлек яшь көчләрне дә иҗат мәйданына алып чыкты. Кинәт кабынган йолдызлар арасында нәккапьче Илгиз Гыймранов та бар иде.

Әле күптән түгел генә исеме дә мәгълүм булмаган рәссам 3—4 ел эчендә дөньякүләм абруйлы иҗаткяр дәрәҗәсенә күтәрелде. Аның әсәрләре 1991 елда Англиядә, 1993 елда Венгриядә, Голландиядә, татар сынлы сәнгать күргәзмәләренә куелып, андагы тамашачының игътибарын җәлеп иткән төп вакыйгага әйләнде. Сатым вернисажларында да аның эшләре иң югары бәягә сатылдылар, әле дә чит ил сәнгать әсәрләре җыючылары, Татарстан эшкуарлары И. Гыймрановның нәкышьләрен алырга чират торалар... Аның акбүз атка менеп атланган, төрки озынча баш киеме кигән, кулына ау лачыны утырткан горур зирәк җайдагы, Милли мәдәният музееның талымлы белгечләре тарафыннан югары бәяләнеп, экспозициягә кертелде. «Саз уйнаучы», «Музыкантлар», «Өч фәрештә» исемле әсәрләре «Туран» коллекциясендә тупландылар. Гаҗәп матур уйланылган, форма ягыннан камил, татарның буй-буй кием, архитектура принципларына барып тоташкан, шәрекъ дөньясына хас белемне олылау, остазны кояшка тиңләү идеяләре белән сугарылган «Кояшлы мәдрәсә» картинасы — И. Гыймрановның иң көчле әсәрләреннән санала. Ә менә «Алтын тамга» күргәзмәсенә ул үзенең тагы да күләмлерәк, мәгърифәт, рухани тормышка мәдхия җырлаган, Казанны чын сәнгать җәүһәре, бербөтен халыклар мирасы итеп сурәтләгән «Ризалык шәһәре» дип аталган дастанын элеп куйды. Заманны тоеп, үз халкын сөеп иҗат ителгән бу әсәр — И. Гыймрановның анты, догасы, Леонардо да Винчиның «Кичке серле сөйләме» кебек («Тайная вечерня»), — татар яңарышының символы.

Әйе, И. Гыймрановның интеллектуаль сәнгате элеккеге реализм һәм ул алга сөргән «эш кешесе», «замандаш», «юлбашчы» «нефтьче» образы дигән тапталган образларны читләтеп үтеп, күңел эзләнүләреннән, сагынулардан үз халкының борынгысына, элеккеге дәүләтчелегенә, мәдәниятенә, шәркый мирасына, аңа гына хас гүзәллек эстетикасына табынган сәнгать. Ләкин шәрекъ миниатюрасына, китап, орнаментына, дивар сурәләренә йөз тоткан хәлдә, И. Гыймранов шулай ук Арувн халыклары рәссамчысына, Византия фрескаларына, Ренессанс сәнгатенең кешене олылап, зур итеп портретлап бирү традицияләренә битараф түгел. Һәм иҗади рәвештә кулланылган бу алымнар аңа татар тарихы күренешләрен, шул чор сәнгате билгеләренә төреп, заманча сурәтләүгә ярдәм итәләр, аның төсле реконструкцияләренә ямь өстиләр.

«Тукайның Оренбургтан Казанга килүе» әсәрендә дә ул Шагыйрьне һәм аны башкалага озата килүче Олаучыны, «ретро» төсмерләренә таянып (йә, атның чайкалып барышы һәм төркемнең ритуаль ырымлы хәрәкәте, Коръән, Инҗилләрдә сурәтләнгәнчә, чүл буйлап тирбәлеп-йөзеп барган кәрван белән Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә килүен хәтерләтмимени?!), тирән мәгънәле, зур «кичү» биеклегенә күтәреп сурәтли. Әсәрнең язылу стиле декоратив, тыгыз фактуралы калын өслеге, дулкын-дулкын киң ритм, гәүдәләрнең караңгы яшел, көрән фонга (мәңгелек символына) эретелүе — болар барысы да әсәргә монументальлек, борынгылык атмосферасын өстиләр, сәнгатьнең символик катламын хасил итәләр. Бирелә

рәссамның үзенә дә тансык-нурлы булган, төсле пыялалардан ясалган витражны хәтерләткән Казан шәһәре образы да сихри-тылсымлы роль уйный. Хәтта яшь шагыйрьнең түбәтәе дә зиннәтле сәнгать әсәре — шигърият символы! — буларак кабул ителә. Шушы мәгънәдә Тукайның Казанга килүе — аның яктылыкка, гүзәллеккә омтылуы, рухның туктаусыз камилләшүе булып, халкы өчен үзен корбан итәрдәй олуг шәхесләрнең язмышы борылышларына тиң зур вакыйга булып күз алдына килеп баса.

Үзенең Рембрандтка ияреп язылган, әмма татар мохитына багышланган, дөрескә татар милләтенең тел вә дине, иманы кебек олуг хәзинәгә кабаттан баш оруына ишарәләнгән «Тәүфикъсыз улның кайтуы» дигән әсәрендә М. Гыймранов борынгы сәнгатьнең мондый даһи калыпларын файдаланмый инде. Ул моны аңлы рәвештә, татар тарихының даимилеген, дәвамчанлыгын, ахыр чиктә, бөеклеген исбат итәрәк, һәм әлбәттә, бөтендөнья халыклары өчен уртак булган кыйммәтләр барлыгын искәртеп эшли. Игътибар итик: затлы киемле, төс-кыяфәтенә антропологик үзенчәлекләре бөркелгән каһарманнарын сынлы сәнгать даирәсенә чыгарып, ул татар сәнгатенең бөек узганын һәм аның провинциаль сәнгать чүплекләрендә маргиналь күренеш булып калмасына, аның бөтендөнья мәдәниятенең төп-магистраль юлыннан баруына басым ясый.

И. Гыймрановның язу ысулы да үзгәлеге белән, гадәти техникалардан аерылып торуы белән күзгә ташлана. Баналь, юка катламлы язуга каршы булган И. Гыймранов пумала белән язмыйча, сынчы коралы — юка пычакны хәтерләткән мастихин белән, буяуларны җитен тукымага сылап-сылап эшли. Шул рәвешле, ул сурәтне төрле вак-вак яссылыклар — шакмак-шакмаклар, өчпочмаклар — исәбенә нисбәтләп ясый. Бу алым аңа диварга төшерелгән борынгы мозаикалар хиссиятен тудырырга ярдәм итә. Ләкин бу нисбәтлелек һәрвакыт бик нечкә тоем белән, нәзакатьле итеп кенә бирелгән булыр. Аның картиналарында сурәтләр, әйтерсең лә меңъеллар аша безнең көннәргә килеп җиткән риваятьләр... Бер карасаң, алар вакытлар үтү белән буявы куба башлаган, әмма күреклеген югалтмаган гүзәл фрескаларны хәтерләтәләр...

...Әлбәттә, җәмгыять җилләреннән бераз ышыкланыбрак иҗат ителгән бу сәнгать үзәгенең зәгыйфь яклары да юк түгелдер. Тарихның канлы сәхифәләре биредә мәдәният, шигърият күренешләре аша тасвирлана. Шәһәрдә туып үскән, Казанның моңлы архитектурасына, таш диварларына гашыйк И. Гыймрановның геройлары шактый ук утопик, шартлы, әкияти геройлар; алар — падишаһлар, галимнәр, табиблар, музыкантлар; алар — ташпулатлар, мәчет-манаралар, гөмбәзләр... Шәһәр рәссамы И. Гыймранов иҗатында урман-таулар, чишмәләр, авыл, көтүче, игенче кебек күптән таныш манзаралар юк диярлек. Этнография, гади тормыш-көнкүреш әйберләре дә чамалы гына. Ләкин иҗатның бәйрәмчә, тантаналы образларында бүгенге тарих, аның күләмлелеге чайкала; анда борынгы затлылык белән күркәм киләчәк турындагы уй-борчулар берсә кушылып үсә. Ягъни рәссамның үз милли тарихын шулай куркусыз, киң, зур, мәһабәт итеп, комплексларсыз сурәтләвендә «яңа сәнгать» концепциясе чагылыш таба. Бигайбә, дип әйтәсе килә, мәдәниятебезгә милли азатлык хәрәкәте сулыш өргән, безнең буын кебек кыйналмаган, көчле, сәламәт рухлы яңа буын килә...

**Розалина ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Илгиз Гыймрановның «Тукайның Оренбургтан Казанга килүе» дигән картинасыннан репродукция (фрагмент).
**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган әдип Адлер Тимергалин.

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ фотосурәте.




# ЯҢА КИТАПЛАР

## CUMLE SAIR DOST BAHCESINDE




Ике ел чамасы элек — 1992 елның маенда Төркиядә, төрки халыклары тарихында беренче мәртәбә, тугандаш халыклар шагыйрьләренең зур җыены — Бөтендөнья шигырь фестивале булып узган иде. Анда дөньяның төрле континентларында яшәп, төрки телләрдә иҗат итүче күренекле шагыйрьләр катнашты; алар Төркия, Иран, Ирак, Греция, Румыния, Югославия, Болгария, Әзәрбайҗан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Молдова, Башкортстан, Кырым, Татарстаннан килгәннәр иде.


Күптән түгел генә Татарстанга рәсми визит белән килгән Төркия Язучылар берлеге урынбасары М. Җәмал бәй килеп киткән иде. Ул үзе белән әнә шул дөньякүләм әһәмияткә ия булган шигырь фестивалендә катнашкан шагыйрьләрнең чыгышлары, шигырьләре тупланган, югары зәвекъ белән нәшер ителгән сувенир-бүләк китабы да алып килгән иде. Ул китапны өстән генә актарып чыкканда да төрки шигъриятенең ничаклы бөек тарихы, данлы бүгенгесе, ышанычлы киләчәге барлыгына тагын бер мәртәбә инанасың. Тикмәгә генә ул шигырь Форумында Ю. Әмрә, А. Новаи, М. Физули исемендәге халыкара премия фонды билгеләнмәде дә инде. Шунысы куанычлы: бу китапта татар шигъриятенең күренекле вәкилләре Равил Фәйзуллин һәм Ренат Харис шигырьләре дә лаеклы урын алганнар.

Үткән 1993 елда, шушы олуг башлангычның дәвамы буларак, халыкара төрки шигырь фестивале Алматыда үтте. Андый югары дәрәҗәдәге шигырь бәйрәменең тиздән Казанда да үтәчәгенә ышанычыбыз зур.

Тышлыкның бу битендә Сез, хөрмәтле укучылар, беренче Бөтендөнья төрки халыклары антологиясе сыйфатында чыккан китапның тышлык сурәтен күрәсез.

Бәясе 330 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог